# КАЗАН УТЛАРЫ

9.1986



# КАЗАН УТЛАРЫ

АЙЛЫК ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ

ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ ОРГАНЫ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

9

1986

## Бу санда

БӨЕК ОКТЯБРЬНЕҢ 70 ЕЛЛЫГЫНА

А. ГЫЙЛӘҖЕВ, А. ЛИТВИН. **Августның алтысына кадәр...** *Роман-хроника* . . . . 3
Р. ӘХМӘТҖАНОВ. **Тукайның соңгы рәсеме.** *Шигырьләр* . . . . 77
М. ХӘБИБУЛЛИН. **Йөрәккә тамган язгы тамчылар.** *Хикәя* . . . . 82
Ә. МӘХМҮДОВ. **Атакага бара шигырьләр.** *Шигырьләр* . . . . 97
Р. ХИСМӘТУЛЛИН. **Сабан туена!** *Шигырьләр* . . . . 100
Р. ФӘИЗОВ. **Яңа күршеләр.** *Хикәя* . . . . 103

БАЛАЛАР ӨЧЕН ШИГЫРЬЛӘР

Х. ХАЛИКОВ. **Минем бабай** . . . . 111

ТАТАРСТАН — ТУГАН ТӨБӘГЕМ

Б. Ф. ЗАХАРОВ. **Җаваплылык арта.** *(Бөгелмә районы)* . . . . 113

КПССның XXVII СЪЕЗДЫ КАРАРЛАРЫН — ТОРМЫШКА

Т. ЭЙДИ. **Һөнәрле Әләзән** . . . . 116

МӘКТӘП РЕФОРМАСЫ: КЕШЕЛӘР ҺӘМ ЭШЛӘР

Ә. МӨЭМИНОВА. **Дәвам** . . . . 124

ӘДӘБИ ПОСТ — АЭС

И. НИЗАМОВ. **Нигез салганда** . . . . 128

ОСТАХАНӘ

А. ГАЙФУЛЛИНА. **Уйларны ирекккә чыгарам...** *Шигырьләр* . . . . 135
Ә. БАЯНОВ. **Яңа исем — яңа сүз** . . . . 137

ИЛЕБЕЗ ТӨНКЫЯНТЬЧЕЛӘРЕ ТАТАР ЯЗУЧЫЛАРЫ ТУРЫНДА

А. НАЛЕПИН. **Яшәү белән үлем арасында** . . . . 139

КПССның ТАТАРСТАН ӨЛКӘ КОМИТЕТЫНЫҢ ГАЗЕТА ҺӘМ ЖУРНАЛЛАР НӘШРИЯТЫ

КАЗАН

Г. РӘХИМ. Туган ил хисе . . . . . . . . . 143

Тәрҗемә турында сөйләшәбез (*Ф. Яруллин. В. Вәлиева. И. Миңнеханов.*) . . . . . 146

КОНКУРСКА

Ф. ЗӨЛКАРНӘЕВ. «Көмеш чылбыр» бөҗралары . . . . . . . . . . . . . . . 152

ӘДӘБИЯТЫБЫЗ ТАРИХЫНА

Ш. АБИЛОВ. Язучы мирасында ниләр бар? . 156
Т. ЭЙДЕЛДИНЕВ. Өметне аклаган каләм. А. Расихка 70 яшь . . . . . . . . 159
Р. КУКУШКИН. Матурлык сагында. Г. Шәрәфигә 60 яшь . . . . . . . . . . . 161
Омтылыш һәм биеклек. В. Хаковка 60 яшь . 167
В. ХАКОВ. Күңел кылларын тибрәтүче . . . 168

ТАРИХ БИТЛӘРЕННӘН

И. ИОНЕНКО. Штаб офицеры язмалары . . 174

Культура тормышы көндәлеге . . . . . . 189

Укучыларыбыз игътибарына . . . . . . . 191
Тышлыктагы сурәтләр . . . . . . . . . 192

*Баш редактор*
РЕНАТ ХАРИС

*Редколлегия*

МАРСЕЛЬ ГАЛИЕВ
ӘХӘТ ГАФФАР
МИРКАСЫЙМ ГОСМАНОВ
АЯЗ ГЫЙЛӘҖЕВ
МАРСЕЛЬ ЗАРИПОВ
МӘДИНӘ МАЛИКОВА
САЛИХ МАННАПОВ
*(җаваплы секретарь)*
ТУФАН МИҢНУЛЛИН
ФЛҮН МУСИН
РИНАТ МӨХӘММӘДИЕВ
*(баш редактор урынбасары)*
РӘФЫЙК НӘФЫЙКОВ
НУРИХАН ФӘТТАХ
РИЗВАН ХӘМИД
НИЛ ЮЗИЕВ
АЗАТ ӘХМӘДУЛЛИН

## В НАШЕМ НОМЕРЕ:

Роман-хроника А. ГИЛЯЗОВА и А. ЛИТВИНА «До шестого августа».
Рассказы М. ХАБИБУЛЛИНА, Р. ФАИЗОВА.
Стихи РАШИТА АХМЕТЗЯНОВА, А. МАХМУДОВА, Р. ХИСМАТУЛЛИНА, Х. ХАЛИКОВА.
В рубрике «Мастерская» стихи А. Гайфуллиной разбирает поэт А. БАЯНОВ.
«Решения XXVII съезда КПСС — в жизнь» — статья Т. АЙДИ из Пензенской области.
В рубрике «Татарстан — родной мой край» выступление первого секретаря Бугульминского горкома КПСС Б. Ф. ЗАХАРОВА.
«Школьная реформа: люди и дела» — очерк Э. МУКМИНОВОЙ «Продолжение».
«Литературный пост — АЭС»: статья И. НИЗАМОВА.
В рубрике «Критики страны о татарской литературе» — статья А. НАЛЕПИНА «Между жизнью и смертью».
Статья Г. РАХИМА «Чувство Родины». Продолжается дискуссия о проблемах литературного перевода.
В номере рецензируется первая книга С. Шамси.
К истории культуры: письма Г. Минского.
Материалы к юбилеям А. Расиха (70 лет), Г. Шарафи (60 лет), В. Хакова (60 лет).
«Из страниц истории». Воспоминания И. ИОНЕНКО — «Записки штабного офицера».
На нашей обложке: творчество художника И. Ахмадиева.

Безнең адрес: 420066, Казань, ул. Декабристов, 2.

Телефоннар:
баш редактор — 53-07-60,
баш редактор урынбасары — 53-07-09,
җаваплы секретарь — 53-07-09,
*бүлекләр:*
проза, поэзия, очерк — 53-07-61,
тәнкыйть, фән, сәнгать, хатлар — 53-07-63.

Техник редактор *Р. Сөләйманова.* Корректорлар *Г. Салихҗанова, А. Минһаҗева.*

Производствога бирелде 24.06.1986 ел. Басарга кул куелды 26.08.1986 ел. ПФ 05292. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70×108 1/16. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8)
Тираж 62444. Заказ В-253. Бәясе 90 тиен

КПССның Татарстан өлкә комитеты нәшрияты типографиясе, Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1986 ел.

**Аяз Гыйләҗев,**
**Алексей Литвин**

# АВГУСТНЫҢ АЛТЫСЫНА КАДӘР...

**РОМАН-ХРОНИКА**

*Бу әсәрнең төбендә документларга, истәлекләргә нигезләнгән тарихи дөреслек ята. Романда чагылыш тапкан вакыйгалар, асылда — булып үткән чын хәлләр, катнашучыларның күпчелеге — тормышта булган, яшәгән реаль кешеләр. Без мөрәҗәгать иткән сәхифәләрнең кайберләре теге яки бу күләмдә тарихи истәлекләрдә чагылыш тапкан иде инде. Мәсәлән, Рашфа монастыренда булган фаҗига, губчека председателе Г. Ш. Ольгеницкийның үлеме һәм башка кайбер күренешләр укучыга таныш тоелырга да мөмкин. Ләкин без, тарихи эзлеклелекне сакларга тырышып, ул гыйбрәтле хәлләрне әсәр тукымасыннан төшереп калдыра алмадык.*

*Әлбәттә, әсәр геройларының байтагысын без үзебез уйлап чыгардык. Әдәби персонажларыбыз, тарихи дөреслеккә һәр мизгелдә тугры калган хәлдә, чын шәхесләр белән бергә яшиләр, бергә көрәшәләр.*

*АВТОРЛАР.*

Узган гомер — искән җил! — диләр...
Узган гомер — аккан су,— дип раслый бүтәннәр.

Бардыр, гомерләре аккан су кебек эзсез-өнсез узган кешеләр дә бардыр... Атна-айлары гына түгел, еллары да ашыгып искән сукыр җил кебек үтеп киткәндер... Кемнәр килмәгән дә кемнәр кичмәгән гомер юлларын! Ә безнең гомернең атна-айлары гына түгел, көне-сәгатьләре дә тарих сукмакларында әллә никадәр тирән эз калдырды. Чоры шундый иде. «Уза, үтә китә!» — дисәләр, ышанмагыз. Әгәр кеше тарихны тудырып гомер итсә, үзе катнаша алмаган вакыйгаларга да битараф калмаса, хәтер төпкелендә әллә ничаклы вакыйгалар, исемнәр сөзелеп кала. Һәм иң кызыгы шунда ки, аларны син белгән хәтле башка берәүнең белмәве бик ихтимал.

Ни үкенечкә калса да, кичәгене бүген кабатлап булмый, узганнарны үзгәртү дә мөмкин түгел. Гадәттә, без тарих мизгелләрен аерым шәхесләр исеме белән беркетергә гадәтләнгәнбез. Чапаев дибез икән, безнең күз алдыннан гражданнар сугышының хәтәр чарпалышлары чагылып уза. Жуков дибез икән, тиңдәшсез Җиңү китергән Бөек Ватан сугышы кырлары хәтергә төшә. Алар янәшәсендәге меңнәрне без бик аз беләбез диярлек. Вакыт узган саен, белгәннәребез дә кими, тора-бара алар да бөтенләй онытылалар. Әмма тарихның асыл бер кагыйдәсе бар — кирә-

---

АЯЗ ГЫЙЛӘҖЕВ (1928) — прозаик, драматург. Күпсанлы пьесалар, «Җомга көн кич белән...», «Әтәч менгән читәнгә» һ. б. повестьлар, «Урманнар артында яшел болын» романы авторы. Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе. Казанда яши.

АЛЕКСЕЙ ЛИТВИН (1931) — Казанда туган. Профессор, тарих фәннәре докторы. В. И. Ульянов-Ленин исемендәге Казан дәүләт университетының СССР тарихы кафедрасында эшли.

ген сакларга тырыша ул! Хатлар кала, истәлекләр, көндәлекләр, болар берзаман ХӘТЕР булып төйнәләләр. Бер чорда яшәгәннәрнең аңы, уйлары бер бөтен булып оешып, алдагы буын кешеләренә куәч бара...

Кеше эшчәнлегенең мөмкинлеге чикләнгән, табигый рәвештә, мин бу вакыйгаларның күпчелегенә шәхси катнаша алмадым. Ләкин ил язмышында гаять мөһим урын тоткан ул еллар мине һәрдаим дулкынландыра, мин төрле чыганаклардан ул хәтәр хәлләргә катнашучыларның исем-фамилияләрен төгәл ачыклый алам, йөз-кыяфәтләрен, мөнәсәбәтләрен тулаем күз алдына китерәм, яшәү рәвешләрен, эш урыннарын дөрес чамалыйм — шушы кешеләрнең язмышлары белән танышып, төп вакыйгаларның үзәгенә үтеп керә алам... Юк, юк, узган гомер искән җил генә түгел, аккан суга тиңләргә дә ярамый аны, безнең гомер шаулы-давыллы иде. Һәммәсе дә хәтеремдә, әле кичә булып узган кебек, гомеремнең бик күп мизгелләрен күз алдыма китерә алам!

Истә, хәтердә!

Покровск госпиталенең шәфкать туташы Варя истә-оста югында мине коридорның аулак урынында куып җитте, җиңемнән тотты һәм кызарынып-бүртенеп:

— Сез комиссармы, әллә чекистмы? — дип сорады. Сорады да ялтырап торган күн курткамның җиңен ычкындырды. Борылдым да, көлемсерәп:

— Комиссар! — дидем мин.

Кыз кырт борылды да ашыгып китә үк башлады. Җиңгә тотынырга минем чират җитте.

— Кабаланма! — дидем.— Нигә яратмыйсың комиссарларны?

— Лыгырдыйлар алар! — диде кыз кистереп.— Үзләре кыл да кыймылдатмыйлар, башкаларны чаптыра беләләр...

Моннан өч көн элек кенә төнге чуалышларның берсендә иптәшем Кирилл яраланды. Аны озата килгәндә, Варяны — ягымлы зәңгәр күзле, сипкелле кызны — хәтерләп калган идем... Кириллның кем булуын, әлбәттә, белми иде ул.

Йөгерә-кача башлаган Варяны куып җитеп, Петерс имзасы куелган таныклыкны күрсәтергә туры килде.

— Чекист мин, чекист!

Һәр очраклы хәлгә дә игътибар итәргә күнегеп килә идем, тавышым, мөгаен, шактый кырыс булгандыр, кыз шып тукталды. Сүз берләшкәндәй, тагын да аулаграк почмакка атладык.

— Егетем бар минем... Володя Иванов. Элек юнкер иде...

— Я, я,— дидем мин, аны тынычландырырга тырышып.— Сөйлә.

— Бүген кара таңнан килеп кергән бу... Чырае көл сыман... Сөйләгәч, шундый курыктым, котым калмады... Берәр чекистны табарга булдым аннары... Сезне күрдем дә...

Варяны үзем белән ияртеп кайтырга туры килде.

Лубянкага җитәрәк артыма борылып карасам — юк кызым! Аяк очларына басып кына качарга маташа. Оча гына!

— Тукта! Нигә куркасың, җүләр?

Борылып килде кызыем...

— Сез Володяга зыян салмассызмы?

— Син ни теләр идең?

— Белмим, тегеләй дә куркам, болай да... Зинһар... Мин аның исән калуын гына телим...

Кабинетыма кергәч, мин аңа су салып бирдем, кәнәфигә утырттым, бераз тын алгач, ул шактый тынычланды, ни белгәнен сөйләп бирде.

— Элек эшемә дә килгәләп йөри иде Володя... Ярәшелгән кыз белән егет идек без... Әйтәм бит, төнгедән кайтып кына яткан идем, ишектә тавыш... Ул! Күзе-башы акайган, дер-дер калтырый. «Хәзер үк Мәскәүдән чыгып ычкынып кал, бер-ике көннән монда мәхшәр кубачак! Больше-

викларны, комиссарларны һәм совет хезмәткәрләрен рәттән асып-кисеп барачаклар. Фетнәгә мин дә катнашам! Хәзер мине тыңламасаң, харап буласың!» — ди...

Каным кайнарланып китсә дә, салкын суны аңа эчерттем.

— Ул куа, «бетәчәксең!» ди... Ә мин кая барыйм? — Кыз елаудан тагын да кечерәеп калды.— Әти чирле. Әни дә чак-чак сөйрәлеп йөри. Икесе дә типографиядә эшләделәр. Бердәнбер таянычлары мин...

Йомшак сүзләр белән аны тынычландырырга телим, «фетнә» дигәнне ишеткәндә, йомшак сүзен каян табасың?

— Володяны яратам, аңа җил-яңгыр тиюен теләмим... Сез миңа сүз бирдегез. Зинһар, исән калдырыгыз аны!

«Булып узганнарның байтагысының шаһиты мин түгел идем!» — дип, ачыктан-ачык искәрткәннән соң, беренче зат исеменнән сөйләп бару җиңел булмас, сизәм. Әмма аңым, вөҗданым миңа туктаусыз тукып тора: «Син үзең күрмәгәннәрне укып белдең... алар йөргән юлларны уздың... шуның өстенә хыялың бай, уең йөгерек, ниятең нык!»

Булып узганнар ераклашкан саен, хыял әллә ниләр тудыра ала, бик күп нәрсәләрне уйлап чыгарырга мөмкин... Акылым исә миңа кисәтә: «Син күреп яки ишетеп белгәннәргә тагын ни өстәргә кирәк? Шулай булды. Шулай иде! Әгәр башка берәү: «Юк, ул хәлләр бүтәнчәрәк иде!» — дип әйтергә җыена икән, әйдә, ул язсын, башкача исбат итеп карасын!

Соңгы вакытларда башым әйләнеп интегәм, кайчандыр арттан наган сабы белән тондырганнар иде, шуның нәтиҗәсеме, авып-авып китәрдәй булам. Иң гаҗәбе шунда, аңымны бөтенләй үк югалтмыйм, ава башлаганда да зиһенем ачык кала, күз алдымнан, тезелешеп, тарих уза... Үткәндәге якын юлдашларым белән сөйләшеп-гәпләшеп алам, шул күрешүдән җаным рәхәтләнеп, күз алларым яктырып китә. Аннан болар уза, тулаем үз хәлемә кайтып, тирә-ягыма, бүгенгегә күз төшерәм... Ә күңелнең изге түрендә әле генә сагынышып күрешкән иптәшләремнең тере шәүләләре, алар миңа туп-туры карыйлар да: «Сөйлә безнең хакта, сөйлә! Исән калучылардан бердәнбер кеше син! Син сөйләргә тиеш!» — дип такрарлыйлар...

Ул чакта вакыйгалар бер-берсен шундый ашыгыч куаладылар ки, нәрсәнең кирәк тә нәрсәнең чүп-чар икәнен үз вакытында аерып алырлык та түгел иде. Тизлеген чамасыз арттырган тарих тәгәрмәче көннәрне, атналарны ашыгып-кабаланып йомгакка чорный торды...

Шәфкать туташы Варяның кемлеген, кияү егете Володя Ивановның өен ныклап, төпле итеп күзәтеп торырга җай булмады: фетнә башланырга ифрат аз вакыт калган иде! Ике көн эчендә Варяның, госпитальдән чыккач, бары тик Володясы белән генә очрашуын, ә элекке юнкерның гел бер йортка кереп-чыгып йөрүен ачыкладык. Кече Левшинский тыкрыгындагы өченче йорт, тугызынчы квартирага сугыла егет. Бу йортка аннан башка да унбишләп кеше кереп чыкты. Май чүлмәге тышыннан билгеле дигәндәй, бу кешеләрнең офицерлар икәнлеге кыяфәтләренә сеңгән иде. Берәм-берәм киләләр дә, ялгыз-ялгыз таралалар. Артык көтәргә ярамый иде, икенче көнне кич, күз бәйләнгәндә, бер взвод чекистлар белән тавышсыз-тынсыз диярлек өй эчендәге унөч кешене кулга алдык. Арада Володя Иванов та бар иде. Нәкъ Варя әйткәнчә дер-дер калтырый иде юнкер. Тик соры күзләрендә нәфрәт уты яна...

Бу ашыгыч һәм хәвефле эш буенча материалларны мин әзерләдем һәм, кулга алынганнарның исемлеген тотып, Петерс янына кердем. Ул ашыкмый гына кәгазьгә күз йөгертеп чыкты һәм, штабс-капитан Альфред Пинку исеме турына җиткәч, бармагы белән төртте.

— Бу бәндәне латыш дивизиясендә хезмәт иткәннән бирле беләм. Кавырсыны йомшак, аннан күп нәрсәне чокып чыгарып булыр!

Пинку тәбәнәк кенә, әмма нык бәдәнле җирән кеше булып чыкты. Авыз ачарга да өлгермәдем:

— Әгәр тормышымны саклап калсагыз, бар белгәнемне түкми-чәчми сөйләп бирәм! — диде.

Сорау алудан калган кайбер язмаларым исән икән әле. Мине ул чакта чамасыз кызыксындырган һәм күңелгә туп-туры барып кадалган күрсәтмәләрнең кайберләрен куен дәфтәренә дә теркәп куйганмын!

«Безнең яшерен оешманың исеме «Ватанны һәм ирекне саклау союзы»,— дип башлады Пинку.— Максатыбыз — илдә тәртип урнаштыру һәм Германия белән сугышуны дәвам иттерү. Оешманың башында Савинков тора. Планнарыбыз шуннан гыйбарәт: немецлар Мәскәүне алган очракта ашыгыч рәвештә Казанга күчәргә һәм шунда союзниклардан ярдәм килгәнне көтәргә... Казан оешмасында бүгенге көнгә биш йөз әгъза исәпләнә, һәм анда бик күп корал да тупланган. 28 майда Казанга квартирьерлар китте. Алар Төньяк номерларына барып төшәләр дә Якобсонны сорыйлар. «Жирле оешма белән элемтәне ныгыту өчен, Виктор Иванович җибәрде»,— дип әйтергә тиешләр».

Жирән Пинку шактый күп белә икән, тагын бер адресны атады: Поперечная 2-й горы, 12 йорт, 13 квартирага барасың да шунда квартира хуҗасы Винокуров Константин Петрович аша Леонид Иванович Розановны эзләп табасың. Аңа хат һәм значок тапшырасың...

Тентү вакытында табылган «О. К.» хәрефләре басылган өчпочмаклы кәгазьнең серен дә Пинку ачып салды: катыргы кәгазь союз әгъзалары очрашу өчен пароль икән. Өчпочмакның икенче өлеше очрашасы кеше кулында булырга тиеш.

Озын-озак уйлап торыр чама калмаган, эшләр бик тирәнгә һәм хәтәргә киткән иде. Без өчәү — Леонид Заковский, Иван Владимиров һәм мин — тиз үк Казанга сәфәр чыктык. Мин җитәкче. Юлдашларымнан яшьрәк булсам да, алар миңа Сергей Сергеевич дип эндәшәләр. Без Савинков җибәргән вәкилләр сыйфатында Казанда Пинку күрсәткән адреслар буенча барып керәчәкбез. Килүебезне үзебезнекеләргә хәбәр итеп, бездән алда Казанга телеграмма китте. Анда без белгән фетнәчеләрнең төсе-бите күрсәтелгән һәм аларны ашыгыч рәвештә кулга алырга боерылган иде. (Соңыннан Казан ЧКсы председателе Григорий Олькеницкий мине бу бәндәләр белән таныштырды һәм аларны әләктереп алуның артык кыен булмавын сөйләде. Ашыгуның файдасы шул — фетнәчеләр аны-моны искәрмичә дә калганнар!)

Фетнә әзерләүчеләрнең берәмләп тә, дистәләп тә кулга алынуын белә идем инде. Әмма фетнәнең чамасыз күп тармакланып, төрле юнәлешләргә тамыр җибәрүе дә ачыкланды. Хәзер тизрәк Казанга барып җитеп, фетнәне зарыгып көтеп яткан дошманнарның тамырын корытырга кирәк иде. Бар булган көчне эшкә җигеп, фетнәне булдырмый калырга! Безнең бурыч шул!.. Авыр бурыч, чуалчык-катлаулы бурыч...

Хәзер юлдашларым турында бер-ике сүз...

Эчебез тулы ут, гамь булса да,без тыгыз, тынчу вагонда күңелле генә сөйләшеп барган булабыз — сер бирергә ярамый! Өстебездә таушала төшкән шинельләр, иңнәрдә юка солдат капчыклары. Капчыкларда кружка белән кургаш кашыктан тыш бер-ике кыерчык икмәк. Тукталышларда яньчелгән котелок белән кайнар су алып керәбез...

Леонид тап-таза, үтә егәрле эшче егет. Өстәвенә акыллы да, сизгерлеге, зирәклеге дә җитәрлек. Кыяфәте белән офицерга ук охшап бетмәсә дә, аны солдаттан күтәрелгән, шәхси батырлыгы өчен окопларда прапорщик дәрәҗәсе алган дип әйтерлек иде.

Иван ягына килгәндә, аның эш бераз четереклерәк — ул элгәре жандарм ротмистры булган, ВЧК председателенең урынбасары Александрович һәм яшерен бүлек начальнигы Блюмкин тәкъдиме белән эшкә алынган. Сул эсерлар: «Владимиров жандармериядә безнең партия кушуы буенча хезмәт итте һәм бик күп иптәшләрне кулга алынудан коткарып калды»,— дип раслап бардылар...

Менә без өчәү. Өчебез өч юлдан килеп, бер йодрык булып төйнәлгән чекистлар. Безне Казанда катлаулы һәм авыр эш көтә. Ниндиләр без, ныклармы — моны әлегә берәү дә белми...

Гадәттән тыш хәлләр Казан вокзалына барып төшүгә үк башланды. Халык күплегенә исебез китмәде, хәзер бөтен җирдә мәхшәр. Мәскәүдә дә, Казанда да ана — кызны, ата улны белерлек түгел. Без, бер-беребезне күздән югалтмаска тырышып, шул ук вакытта беребезгә беребез тагылмаска омтылып, трамвай тукталышына таба бара идек, арттан кемдер: «Сергей Сергеевич, Сережа!» — дип эндәште. Ягымлы гына хатын-кыз тавышы... Азмы әллә дөньяда адаш кешеләр, борылып карамадым, җанлы, тәртипсез ташкын уңаена ага бирдем. Трамвай ишеге каршысына бөялгән төркем арасына кысылырга ниятләп торганда гына тавыш бик якында, колак төбемдә генә яңгырады:

— Сергей Сергеевич!

Ялт итеп борылып карадым һәм сискәнеп киттем: янәшәмдә генә Зоря басып тора!

Кайчагында: «Аның кителмәгән борылышлары әллә алдан ук әзерләп куелганмы?» — дип шаккатасың... «Язмыш»,— диләр. «Маңгаеңа язылып куелганнан котылмак юк»,— дип өстиләр. «Язмыштан узмыш юк»,— дип катгый нәтиҗә чыгаралар. Билләһи, ышанырсың...

Өстемдә чит кеше киеме, ияк-яңакларны сакал баскан, күз-кашлар җыерылган, анаң очраса да, шушы кадәр ыгы-зыгыда аралап, танып алырлык түгел... Гомерем буе үз юлыма үзем хуҗа булырга, язмыштан өстен булырга, аңа баш бирмәскә омтылдым... Нигә яшәвемне белеп, ни өчен көрәшүемне ап-ачык аңласам да, юлыма, адашып, әллә кемнәр килеп кергәләде. Шундый сәер мизгелләрнең берсе иде хәзер...

Зоря, Зоря...

Без аның белән бергә бер ишегалдында үстек. Яшьтәшләр диярлек. Беренче саф мәхәббәтем, бөреләнеп уянган иң татлы хыялларым шушы кызга барып ялгана дисәм дә, ялган түгел. Алар Мәскәү ыгы-зыгысыннан, ачлыктан качып, Казанга күчеп киттеләр дә, кызның эзе югалды. Заман чуалчык, юллар чәбәләнгән, язмышлар буталган, кемнең иртәгесен белеп була? Зоряны эзләдем димим, хат язмадым, сораштырып та йөрмәдем, алай да кыз онытылмаган икән. Шушы сәер хәлдә, трамвай ишеге алдында, уңнан кысалар, сулдан изәләр, без бер-беребезгә терәлеп диярлек басып торабыз, мин сүрелмәгән хисләремнең котырып яңаруын тойдым. Бик якын, кадерле икән миңа Зоря!

Тик ничек дип дәшәргә? Ни дип? Мин яшерен, үтә яшерен командировкада. Казанда безне беркем белергә тиеш түгел! Беркем!

Тоткарлануымны күреп, иптәшләрем, гаҗәпләнеп, миңа карыйлар.

Хәлем мөшкел, катлаулы булса да, кыз яныннан дәшми-тынмый гына уза алмадым. Хәер, ул мине үзе туктатты ич!

Әйткән беренче сүзеннән егылып китәрлек иде...

— Син һаман шигырьләр язасыңмы? — диде ул, сәлам дә биреп тормыйча. Юка яулыгы астыннан бөркелеп чыккан чәчләре минем йонлач яңагыма тиеп-тиеп алды.— Мин бүген сине монда очратасымны беләидем.

Егылмадым, киресенчә, аның бу куркыныч сүзләре Казанга ни йомыш белән килүемне хәтеремә төшереп, тетрәндереп җибәрде.

— Кемнән, ничек белдең? — дип сорамыйча кала алмадым.— Узып барышлый гына мин! Казан аша үтәсем өченче көн генә мәгълүм булды.

Ул аңлатып тормады, бармагын янады һәм:

— Мин башка бер урында күрешергә телим,— диде.

Без кайда һәм ничек очрашу турында аныклап өлгермәдек, ул арада икенче трамвай килеп туктады, халык төркеме, соң дәрәҗәдә

гажәпләнгән юлдашларым белән мине өстерәп, вагон эченә алып керде, исемә килеп, кеше иңнәре аша калкынып карагандa, янымда Зоря юк иде инде...

Кемнән шулай курыкты ул? Күз карашы кемдә тукталгач, аның кашлары дерелдәп китте, ике куллап бер секундка гына минем иңнәремә ябышты?.. Шул мизгелдә мин дә ул караган якка текәлдем. Гадәттән тыш берни дә юк иде ләбаса анда! Ыгы-зыгы, этеш-төртеш, хәрәкәт... Әллә бар идеме? Күперeп торган аксыл мыеклы берәү авыр капчыкны биштәрләп аскан авыл агаеның артына посарга маташты түгелме?.. Шуны күрдеме Зоря, шуннан шүрләдеме? Нигә сүзсез-өнсез эреп югалды?

Кемдер берәүнең сагалаганын абайламаса, болай ташлап китмәс иде, Зоря акыллы кыз. Искәртергә теләдеме, кисәтергә җыендымы, нигә шулай кинәт югалды ул? Күз алдымда аның куркынган күзләре, күз алдымда томан, күз алдымда күперeп торган аксыл мыеклар... Кем иде ул? Дусмы-дошманмы?

Юлдашларым эчкәрәк узды, мин ишек катында калдым. Ачык ишек аша Казан урамнарын күзәтеп барам. Урам буйлап әрсез җил йөгерә, җил тузан болытларын өермәләп уза, ертык-пыртык кәгазь кисәкләрен бөтереп-чайкап куа. Чуар-чуар кәгазьләр, нидер әйтмәк булып, безгә ияреп баралар. Үрелеп карадым: Гостинодворская урамы буйлап барабыз икән. Акшары кубып беткән йорт почмагына сыңар кадакта эленеп торган чалыш агач тактадан укып белдем. Ул арада борыныма ысланган балык исе килеп бәрелде. Сулга борылып карадым, трамвай тәрәзәсе пыялаларының ватылып-кырылып беткәнлеген күрдем. Ябыштырылган калын кәгазьләр дә ертылып, тишелеп беткәннәр, берсе генә бөтен калган, аннан «Всем, всем, всем!» дигән шөбһәле чакыру кычкырып тора. «Всем, всем, всем!» — дип актарылды сискәнеп күңелем, «Казанга фетнә басарга өч кеше килә! Мәскәүдән!» — дип, бөтен дөньяга игълан итәләрдер кебек тоелды. Шигемне арттырып, өзәңгеләрен басып өскә күтәрелгән, ат муенына иелгән өч атлы чабып үтте... Битләрен тузан өермәсеннән томаларга тырышып,казанлылар каядыр ашыга. Борылышларда зәһәр чылтырап тавыш бирә-бирә, трамвай безне алга — куркыныч билгесезлеккә илтә. Без шәһәрнең югары ягына, Гоголь урамындагы чекага барырга тиеш. Гоголь урамы, 28 нче йорт...

Шәһәр мәйданын үтәбез. Җәяүлеләр, атлылар монда ишләрәк. Вагоннардан байтак халык шыбырдап коелып калды. Леонид кемнәндер ишетеп калып:

— Рыбноряд урамы,— дип ачыклады.

Ниһаять, без элеккеге губернатор йорты янына килеп җиттек һәм шунда төшеп калдык. Грузин һәм Новокомиссариат урамнары чатында бераз каранып торганнан соң, очраган бер хатын-кыздан Гоголь урамының кайдалыгын сораштык, якында гына икән, шунда атладык. Большая Лядская урамына кадәр әле без берни дә сөйләшмәдек. Як-ягыбызда, алда-артта шикле адәмнәр күренмәгәч, Толстой урамы чатында тукталып, бераз хәл алдык. Уйлар борчулы, хәвефле иде...

1918 ел!

Майның икенче яртысы. Гражданнар сугышы көннән-көн хәтәррәк, канлырак һәм дәһшәтлерәк була бара. Кайчагында мин үземне туктаусыз тәгәрәп, юлдагы бар нәрсәләрне кырып-себереп ташларга хәленнән килгән таш тәгәрмәчнең нәни бер өлеше итеп сизәм. Шул тәгәрмәч ничаклы тизрәк һәм нәтиҗәле әйләнсә, илдә туып килгән яңа тормышка каршы күтәрелгән кара көчләрнең актыккы көне тизрәк якынаер кебек тоям. Кара көчләрне тар-мар итеп кенә алардан котылырга мөмкин икәнлеген хәзер бәхәссез аңлыйбыз. Ничек тар-мар итәргә аларны?! Без ул чакта кызыл террорны белми идек, юк! Ә контрреволюционерлар каршылыкны көннән-көн көчәйтәләр, мәкер-явызлыкның яңадан-яңа, без белмәгән өр-яңа ысулларын уйлап таба торалар иде.

Зорянын соңгы сүзләре, яшермим, борчыды да, каушатты да. Ул хакта туктап уйламыйча ярамый: безнең ашыгыч сәфәр хакында Мәскәүгә ВЧК җитәкчеләреннән тыш Казанда бер Ольковицкий гына белергә тиеш. Зоряга хәбәр каян килеп ирешкән?..

Шунда, Гоголь урамына борылышта, юлдашларыма Зоря белгәннәрне җиткердем. Леонид күн фуражкасын салып тезенә бәрде. Иван җиргә төкерде.

— Ну?!

Өчебез дә бер мәлгә югалып калдык: Казанга аяк басуга, беренче очраган кеше синең яшерен эш белән килүеңне көне-сәгате белән ап-ачык белсен инде... Менә сиңа фетнә! Фетнәчеләр белән көрәш!

— Хатын-кыз белүе аерата яман! — диде мондый эшләрдә тәҗрибәле элекке ротмистр.— Авызлары тишек аларның!

— Кичен барын да ачыкларбыз! — дидем мин, гәрчә Зоря белән очрашырга вәгъдәләшмәсәк тә. Инде Мәскәүдән кайчан киләсемне белә алган икән, Казанда ничек тә булса эзләп табар әле дип өметләндем ул вакытта...

Элекке хуҗасының исеме белән «Набоков йорты» дип атап йөртелгән бизәкле пулаттагы кабинетында безне Ольковицкий каршылады. Тиз-тиз генә сәлам алышкач, ул Казандагы хәл белән таныштырды.

— Бездә,— диде ул, чем-кара күзләрен тутырып карап,— Савинков иярченнәреннән тыш та дошманнар җитәрлек икән. Әйе, әйе! Монархиягә турылыклы офицерлар оешмасы яшәп ята! Башлыклары генерал Попов. Алар да тик ятмый: генерал Алексеевка, Корниловка ирекләләрне озата торалар. Шуның өстенә монда фетнә әзерлиләр. Фетнә! Очраклы бер вакыйга аларның эзенә төшәргә ярдәм итте.

«Очраклы вакыйга» диюгә, колагым үрә торды: тормыш гел шундый очраклы вакыйгалар тезмәсеме әллә? Шунда ук: «Очраклы вакыйгалар күп кабатланса, алар очраклы булудан туктый»,— дип, үземне тынычландырдым.

Без Ольковицкий янына тыгызрак тартылдык, бүлмәдә киеренкелек, йөзләрдә җитдилек арта төште. Ольковицкий, тәрәзә төбенә үрелеп, папирос кабы алды, аңа ияреп, Леонид белән Иван да тәмәке кабыздылар.

— Утырам шулай бүлмәмдә, Вера Брауде килеп керде. Сез минем урынбасарымны беләсездер инде? (Леонид белән Иван җилкә җыердылар, мин: «Беләм!» — дип ияк кактым). Бер кеше ияртკән. Кешесе дә таныш, Сергей Пиантковский, бездә хезмәт комиссарының ярдәмчесе булып эшли. Вера аннан әлерәк кенә сөйләгәннәрен түкми-чәчми кабатлавын үтенде. Һәм Пиантковский безгә гаҗәп бер хәбәр китерде...

Ольковицкий урыныннан торып йөреп килде. Яшь иде Казан чекасының председателе! Студентлыгы гәүдә тотышыннан да, чыраеннан да чыгып бетмәгән иде. Кара чәчләре ак маңгаена ишелеп-ишелеп төшәләр дә, ул озын, сизгер бармаклары белән аралап аларны артка сыпырып куя. Өч-дүрт сүз әйтә дә башын калкытып, әңгәмәдәшенә сөзеп карап ала. Теләктәшлеккә чакырамы?..

— Пиантковский кичә өченче гимназиядә бергә укыган яшьлек дустын очраткан. Дусты соңыннан юнкерлар мәктәбен тәмамлаган, офицер дәрәҗәсе алган, сугышта катнашкан, яраланган, шуңа күрә хәзер өендә ята икән. Иптәшенең кыланышы сәер тоелган аңа. Башта кызып нидер әйтмәк булган, аннары кул селкеп китеп барган. Тагын борылып килгән, тагын... Шуннан тегенең колагына гына: «Син совет хезмәткәре бит? Башыңны саклыйсың килсә, тиз үк моннан табан ялтырат! Шушы көннәрдә Советларның башына җитәчәкләр — беркем рәхим-шәфкать көтмәсен! Мин дә, башка берәү дә коткарып кала алмас сине!» — дип пышылдаган да сызган... «Пиантковский иптәшенең фамилиясен атаудан баш тартты»,— диде Брауде. Без дә аны кысып карадык, әйтми! «Ишеткәнемне минуты белән китереп җиткердем, шул азмы сезгә? — диде ул.— Мин аңа явызлык теләмим, исән-сау калсын».

Ишеттергән хәбәренең безгә ни дәрәҗәдә тәэсир иткәнен белергә

теләгән кебек, Ольковницкий сүзен бүлеп, безгә күз ташлады...
— Безгә,— дип дәвам итте аннары.— Пиантковский белән укыганнарның исемлеген табып, берәм-берәм чүпләү ысулы белән эзли барып, арадан бер кешегә тукталырга туры килде. Серле кеше Варваринский чиркәве руханиенең улы офицер Сердобольский түгелме дигән шик туды. Әлегәчә аның кулга алынганы юк, сез бүген барасы йортка — Винокуров янына еш барып йөри. Шикле кеше! Хәзер ул йортны безнең өч иптәш: Несмелов, Лавринский һәм Копко күзәтәләр. Шул иптәшләр сезнең миссиянең уңышын тәэмин итәргә дә тиешләр.
Ольковницкий гостиницага түгел, аерым квартираларга урнашуыбызны хуп күрде. Леонид белән Иван чека йорты каршысындагы асты таш, өсте агач йортның икенче катындагы зур гына бүлмәгә урнаштылар. Анда Григорийның танышлары яши икән. Мин Песәй тыкрыгындагы икенче квартирага киттем. Ольковницкий мине озата барды. Элек бу квартирада аяк киемнәре мастерское тоткан кеше яшәгән, алар ирлехатынлы бер-бер артлы вафат булганнар да, йортка хуҗа булып, аларның элекке асраулары Саҗидә апа калган икән.
Мине чип-чиста җыештырылган бүлмә, кысыр токмач исе һәм ак яулыгын мәзәк итеп җилкәсенә салып бәйләгән урта яшьләрдәге апа каршылады. Ольковницкий:
— Төнгә хәтле вакытың бар, ял ит, мине башка эшләр көтә! — дип китеп тә барды. Ул үзе дә моннан ерак түгел университет тулай торагында яшәп ята икән...
Ясканып, Саҗидә апаның ике тәлинкә токмачын ашагач, мин юынып, кырынып алдым, өс-башымны бераз рәткә китердем, чишенеп, тар агач караватка ятып тордым. Уйларым томанлы һәм бик буталчык иде. Винокуровларга барырга иртәрәк иде, мин ашыгып кына киендем дә, әллә нинди чокырлы-чакырлы тыкрык аша узып, Зур Проломный урамына килеп чыктым. Монда халык шактый күп иде. Арада гаскәриләр дә, хәзер килеп сыланырга торган чытлык хатын-кызлар да күренде.

Банк янында без Зоря белән тагын йөзгә-йөз очраштык. Минем хәзерге сәгатьтә монда буласымны хәтта юлдашларым да белми... Зоря каян белде икән?.. Димәк, безнең арттан һаман күзәтәләр?..
Ишле халык, урам таптап, арлы-бирле уза, монда эз яздыру читен түгел, мин Зоряны култыклап алдым, ул карышмады. Киттек. Егет белән кыз култыклашып баралар икән, моның ни гаебе бар? Кем шикләнсен? Зоря гына сон дәрәҗәдә гасабиланган, күзгә туры карарга читенсенә, каршы килүче ир-атларга күз йөгертеп ала иде. Кемне көтә? Нигә алай сагая? Аксыл мыек эзгә төшәр дип хафаланамы? (Тьфү, каян шул мыек хәтергә бәйләнде?!) Кем ул хәзер? Кайда? Нишли?!
Сорауларны күбрәк бирен ташладым ахрысы, кызым тагын да каушабрак калды, беравык без бөтенләй сүзсез бардык. Проломныйның крепостька житәрәк ягында халык азайгач, кире борылдык. Зоряның да аулакка узарга теләмәвен сизендем...
— Мин,— диде Зоря шунда гына,— Винокуровта элемтәче булып торам. Синең башка кеше исеме белән Казанга киләсеңне хәбәр иткән телеграмманы ялгыш кына күрдем...
— Без хәзер ялгыш кына очраштыкмы?
— Сине беләм, хәтерлим... Тик ята торган кеше түгелсең. Ят кеше Казанда кая барсын? Әлбәттә, үзәк урамга төшә!
— Винокуровка телеграмманы кем суккан?
— Зинһар, артыгын төпченмә! — дип ялынды ул. Беренче тапкыр көлемсерәде.— Әйткән кадәресе дә иске танышлык хакына! — дип өстәде.
Яшьтән үк гадәти булмаган тормышка омтылган, әдәби кичәләрне калдырмаска тырышкан, яңа калкып чыккан минутлык татлы данга күмелгән җырчыларга, актерларга гашыйк булып ярым исереп, ярым тилереп, зәңгәр хыяллар дөньясында яшәгән кайнар хисле һәм ялкынлы рухлы бу кызның ниндидер ярамаган эшкә таруын мин вокзалдан ук

сизенгән идем. Аның кинәт кенә күз алдыннан югалуы тиккә түгел иде ич! Димәк, безнең тирәдә шикле берәүнең барлыгын абайлаган. Ул кемдер безнең килүне белеп, күзәтеп торган дип уйларга кала... Хәзер сер бирмәвеннән, башка бер өстәмә хәбәр дә чыгармавыннан мин Зоряның караңгы эшкә нык ук буталуын аңлап алдым. Кыскасы, вокзал янында янәшә басып торган зифа, сылу кыз юк иде инде. Зоря — гәүдәсе чак кына авырайган, керфек-кашлары оста буялган, ир-атның күңелен котыртырлык серле һәм куркыныч ханымга әйләнгән...

Моннан ары сүз ялганмады. Зоря этисенең кечкенә бер заводта механик булып эшләвен, кардәшләрендә, Казанкадан ерак түгел бер йортта фатирда торуларын сөйләде дә, култыгымнан ычкынып, ашыгып-ашыгып атлап китте, борылып кул болгады, ишетмәсәм дә аңладым: аның тулышып ташкан иреннәре «сау бул» дип пышылдады.

Безнең хәл күзгә күренеп кискенләште. Винокуров квартирасына баруның мәгънәсе калмады. Анда безнең кемлекне әллә кайчан беләләр, әзерләнеп көтәчәкләр.

Өчәүләшеп Ольткеницкий янына юнәлдек. «ЧКда юк, ашыгыч эш белән каядыр китте»,— диделәр. Хәзер ышаныч безнең өчебездә һәм ЧК билгеләгән өч иптәштә иде. Азрак түгелме?

— Бармыйк! — диде Леонид Заковский.— Көч безнең якта. Өстәмә отряд алыйк та ояларын пыр туздырыйк.

— Барыйк! — диде Иван Владимиров.— Алар белгәнне без дә белеп барабыз. Бәлки, көтелмәгән берәр нәрсә килеп чыгар?

Мине дә мәсьәләнең шушы ягы тарта иде! Күп уйлашып торырга вакыт тар, тиз үк бер карарга килдек тә, тәвәккәлләп, Винокуровлар өенә барырга булдык.

Төнге унберләр иде инде. Май төненә охшамаган: күкне тоташ болытлар сарып алган, урамнар дөм караңгы дип әйтерлек. Йортны тиз генә эзләп таптык. Йорт тирәсендә җан әсәре сизелмәде, безне беркем туктатмады. Әгәр теге өч иптәш монда булмаса?!

Тышкы ишек ачык иде, берәм-берәм эчкә уздык. Тар һәм эче исле коридор буш, ярым-йорты яктыртылган, буявы купшакланган тәбәнәк ишек төбендә дә кеше-мазар барлыгы сизелмәде.

Ишек янәгындагы патрон төбе хәтле генә җиз төймәгә басуга, ишек ачылып та китте, кысыла-кысыла эчкә кердек. Безне өч фетнәче каршылады. Парольләр алыштык. Өстәл янына чакырдылар, чәй тәкъдим иттеләр. Өстәл башында дәү, юан корсаклы җиз самавыр пар атып утыра иде. Утырыштык. Бер-беребезгә бүре булып карап та алабыз. Фетнәчеләрнең кайсысы Винокуров булуын чамалау читен түгел иде. Озын, зифа буйлы, киң ак маңгайлы, бөдрә чәчле, сөрмәле зәп-зәңгәр күзле кеше аягүрә басып чәй ясады, утырырга да ул тәкъдим итте. Борынгы бәет батырларын хәтерләткән бу кеше баш әйләнерлек дәрәҗәдә чибәр иде... Кылт итеп исемә Зоря килеп төште... Ул шушы кешенең элемтәчесе ич!.. Элемтәчесе!?. Алай гынамы?.. Шул чакта минем түземем шартлады.

— Беләсездер,— дидем мин, Винокуровның күзенә чекерәеп кереп.— Без ВЧКдан, Мәскәүдә сезнең тарафдарларыгыз тар-мар ителде, күбесе кулга алынды.

— Әйе. Бу безгә мәгълүм,— диде хуҗа тиз-тиз.— Тик сез безне өркетеп маташмагыз. Йорт безнең кешеләр тарафыннан камалган. Моннан исән-аман чыгарбыз дип өметләнмәгез.

— Ярый,— дидем мин.— Булды, өркештек. Хәзер эшкә күчик.

— Риза,— диде Винокуров.

— Сезнең сәяси житәкчелек астында Казанда офицерларның берничә отряды төзелеп, Советларга каршы восстание әзерләвегезне беләбез. Катнашучыларның исемлеген, адресларын, җыелу урыннарын, корал складларын ачып саласыз. Безгә шулар гына кирәк!

Винокуровның чибәр йөзе чалшайды, ул явыз көлемсерәде, иптәшләре бер-берсенә карашып хихылдап-гөрләшеп алды.

— Яшьлеккә яшь, ә үгезне мөгезеннән эләктерергә чамалый! — диде хуҗа күңелле генә.— Иң әүвәл безнең сорауларга җавап бирегез. Безнең!

Бу сүзнең аерым басым белән яңгыравы безне сискәндерде, янәшәмдә утырган Заковский миңа күз кысты. Борылып карадым: безнең җилкәләргә пистолетлар терәлә язган иде.

— Менә нәрсә,— дидем, ачуыма буылып.— Бала-чага уенын ташлагыз. Йортны сезнекеләр генә түгел, безнекеләр дә камаган. Моннан чебен дә очып чыга алачак түгел. Я?!

Моннан соңгы хәлләрне, атыш башланганын, ут сүнеп, ыгы-зыгының көчәюен әйле-шәйле генә хәтерлим. Шул бәрелештә наган тоткасы белән арт чүмечемә бик нык тондырганнар. Аңымны җуеп авып төшкәндә, каяндыр атылып килеп чыккан Зоря мине каплаган, үзе каты яраланып, мине пулядан саклап калган...

Икенче көнне соң гына, көн тәмам яктырып, ачылып беткәч, госпитальдә аңыма килдем. Шактый вакыт үземнең кайдалыгымны аңламыйча яттым. Кичәге вакыйгалар әүвәл тонык шәүлә рәвешендә, ахырда ап-ачык булып аңымда яңардылар. Кинәт калкындым да ми капкачымның авыртуына түзә алмыйча, ыңгырашып урыныма аудым. Тавышка шәфкать туташы керде.

— Зоря кайда? — дип сорадым мин. (Иләнгә авып төшкәндә, ыгы-зыгы уртасында мин аны күреп калганмын икән!)

— Зинһар, кузгалмагыз,— диде туташ.— Сез яралы.

— Үтенеп сорыйм.

— Сөйләшмәгез дә. Сезне бик тиз аякка бастырырга диделәр.

— Анысы шулай.

— Зоря күрше палатада. Ул да авыр җәрәхәтләнгән.

Көчсезлегемнән, чарасызлыгымнан ярсып-шашынып ятам. Ми капкачын ни беләндер тишеп, эченә кереп оялаган авыртуны тышка чыгарасым, котыласым килә.

Көн уртасында авырту сизелерлек кимеде, тынычланып, өзек-өзек йокымсырап т?алдым, хәлем бөтенләй аруланды. Күземне ачып җибәрүгә, караватым янындагы урындыкта утырган каратут йөзле, озынчарак яңаклы сөйкемле генә кызны күрдем. Аның кара, калын толымнары ак халат өстендә аерата матур күренделәр.

— Фәридә мин,— диде кыз, мөлаем гына елмаеп.— Мине Ольшеницкий җибәрде.

— Зоряның хәле ничек?

Фәриданең сылу йөзе сүрәнләнде, күзләреннән кара күләгә йөгереп узды. Җавапны көтмәскә дә була иде, алай да Фәридә:

— Зоря вафат,— дигәч, арт чүмечемне айкап-иңләп тагын сызлау дулкыны узды.

— Винокуров исән, утыра,— диде Фәридә.— Калганнарын ул үзе сөйләп бирер. Григорий Шмулевич шуны тапшыруымны гына үтенде: кичә кулга алынганнар арасында хәтәр кош бар!

— Кем ул? — дип сорадым түземсезләнеп.

— Вакытлы хөкүмәтнең элеккеге министры хатыны Никитина Валентина Васильевна.

Хәбәрнең җитдилеге мине урынымнан кубарга мәҗбүр итте, ярсып килеп кергән врачның ай-ваена да карамыйча, булдыра алган кадәр ашыгып киендем дә, Фәриданең юка, әмма көчле, җылы иңенә таянып госпитальдән чыгып киттем.

Зоряны алып киткәннәр иде инде.

«Әтисе, сеңлесе килеп алды»,— диде шәфкать туташы...

«Узган гомер — искән җил!» — дисәләр, ышанмагыз. Алай түгел. Кеше хәтеренең тирәнлеге чиксез, ул үзендә әллә никадәр байлык-хәзинә саклый. Бөтенесен дә хәтер сандыгына тутырып булмый, әмма хәтер — сакчыл хуҗа, ул берәмтекләп күп нәрсәләрне үзенә җыя. Менә

монысын аңлау-аңлату кыен: нигә әле заманында бик мөһим кебек тоелган аерым вакыйгалар бик тиз онытылалар да, үз вакытында әллә ни зур да тоелмаган хәлләрне, кайта-кайта, гомерең буе искә аласың...

Гомерснең бары тик син генә белгән вак-төякләре дә хәтергә сеңеп калмыймыни? Шул ук вакытта хәтернең теге яки бу хәлләрне бутап, ялгыш аңлап беркетеп кую очраклары да азмыни? Була, ышансаң, ялгыш аңлаганны чынга санап гомерең буе ялгышып киләсең...

Бу юлы миңа нәни генә дә ялгышырга ярамый.

Миңа Никитинаның дөрес күрсәтмәләре генә кирәк.

Чәбәләнгән җепнең очы кайдадыр булырга тиеш ич!

Әлегә йомгак зурайганнан-зурая бара, бүселә, кабара — ә җепнең очы юк. Кемдер йомгакны тырышып-тырышып урый, әйтергә кирәк, белеп, хуҗаларча оста итеп урый. Без һаман зурая барган йомгак тирәсендә чабышып йөрибез, аның туктаусыз кабаруын күреп-бәяләп торабыз, очы гына юк. Очы табылмыйча йомгакны сүтеп булмаслыгын һәркем беләдер...

Күрер күзгә бик яшь, бик нык сакланган, әмма чак кына калынаеп киткән купшы, чибәр ханым допроста үзен чиксез һавалы тотты.

Беренче сорау шул:

— Казанга ни өчен килүегез турында, мондагы танышларыгыз хакында сөйләгез. Сез сөйләргә тиеш!

— Тиеш?! Нигә сөйләргә тиеш әле мин аларны? Сезгә? — дип бүлдерде ул мине.— Мин түгел, сез миңа тиеш! Бар булганымны явызларча тартып алдыгыз да... Тиеш имеш!

Никитина күзләрен акайтып, кулларын бутап акыра-бакыра башлады. Чибәр ханымның шулкадәр ямьсезләнүен күрү үтә сәер иде. Мин, сабыр булырга тырышып, аны күзәтеп тордым, үзем туктаусыз Зоря турында уйладым. Якты дөньяда аның юклыгына күңелем ышана алмый, ышанырга теләми иде... Без тагын-тагын күрешергә тиештер кебек...

Әле Фәридә белән урамнан узганда да алда баручы кыз бер мәлгә Зоря булып тоелды... Хәтта адымнарымны ешайттым, Фәридә дә сизенеп, сәерсенеп миңа карап алды. Җиңел холыклы дип уйладымы әллә? Чит кыз да күз карашымны сизеп борылып карады, ул бөтенләй башка кеше. Зоряга бөтенләй охшамаган да икән. Әйе, бүген, менә шушы авыр мизгелләрдә миңа Зоряның исән булуы бик кирәк иде. Акылсыз кыз түгел, бәлки зур эшебездә ярдәме дә тияр иде... Кирәк иде ул миңа, бик кирәк!

Сабырлыгым шикләндердеме, әллә уйларымның читтә, еракта гизеп йөрүен сизендеме — Никитина, кинәт тыелып, тынычланып, миңа карады. «Кылана белә!» — дип уйларга өлгердем... Сүзсез чакта исертерлек чибәр ханым, акыра башласа, аждаһага әверелә икән!

Тавышым чыңлап чыкты...

— Сезне мин гаепләү акты игълан итеп, җавап алырга чакырдым. Ә сез тормышыгыздагы барлык бәла-казалар өчен мине гаепләргә маташасыз. Теләп очрашмадык, әмма сез сау-сәламәт, ә мин яралы. Сез исән, минем якын кешем җир куенында! Кем зарланырга тиеш әле монда? Ярый, тыңлагыз алайса. Сез — Никитин хатыны. Ирегез — меньшевик Керенскийның соңгы хөкүмәтендә почта һәм телеграф министры. Ирегез идән астына качкан хөкүмәт составында да министр иде. Сез Казанга Савинков вәкиле, дөресрәге, аның контрреволюцион оешмасының вәкаләтле вәкиле сыйфатында килдегез... Сезнең ирегез, Петроградтан чыгарып җибәргәндә: «Министр социалист буларак ант итәм — Совет властена каршы беркайчан да көрәшмәячәкмен»,— диде.[1] Сезнең андый сүз биргәнегез юк — әмма ирегез боерыгын үтәп йөрмисезме икән, дип шикләнәм. Сезнең төп бурычыгыз безгә мәгълүм: сез теләсә кемне —

---

[1] Ул чакта ике елдан соң Россия көньягы кооперациясе эшен алып барырмын да, аның председателе А. М. Никитин белән очрашырбыз дип кем уйлаган! Югары революцион трибунал аны контрреволюцион эшчәнлеге өчен 15 елга хөкем итте.

меньшевикларны, эсерларны, монархиягә турылыклы офицерларны «Ватанны һәм ирекне саклау Союзы»на тартырга маташасыз!

— Сүзегез — башыннан ахырына хәтле уйдырма! — диде Никитина сабырлыгын җыярга тырышып.— Мин партиядәш дусларым Якобсон белән Винокуровларга кунакка килдем. Ирем белән без төрле партияләрдә: ул меньшевик, мин уң эсер! Уң эсерлар партиясе Совет хөкүмәтенең рөхсәте белән ачыктан-ачык хәлдә яши. Ә сез минем якага ябышып, властька каршы көрәштә гаеп ташлыйсыз. Сезнең белән бу хакта сөйләшәсем килми. Сөйләшүне үземә түбәнлек дип саныйм.

Сөйләп бетерсен, бушансын ул. Чак кына көтеп тордым. Аны минем сүзсезлегем җенләндерә башлады, борын яфраклары дерелдәде, күн сумкасыннан чыгарып батист кульъяулыгы белән ирен читләрен сөртте. Бүлмәгә кыйммәтле хушбуй исе таралды. Тагын бераз көттем.

— Кәкре агачтан туры күләгә төшми! — дидем мин.— Сезне монда Виктор Иванович җибәргән. Бу исә — Савинков Борис Викторович. Сез әлерәк кенә «дусларым» дип атаган Якобсон белән Винокуров — бөтен Казанга мәгълүм совет дошманнары! Сезнең белән бергә кулга алынган генерал Попов, Ольгин белән Розанов дигән офицерлар да — фетнә әзерләүчеләр! Тиккә җыелмагансыз сез ул яшерен киңәшмәдә. Үзәктән алып килгән инструкцияләр белән таныштырырга җыелгансыз. Я, аларга нинди хәбәрләр житкердегез? Без дә белик.

Бу юлы сөйләгәндә, күземне Никитинадан алмадым, уйларымны чәчмәдем, тик аның ник бер кылы селкенсен, исе китмәгән кыяфәттә утыра бирә.

Озакка сузылган тынычлыкта бүлмәгә яшь тикшерүче Гайнулла Таһиров килеп керде...

Гайнулла Таһиров белән әлерәк кенә, мин госпитальдән чыккач та таныштык. Белгән кадәресе шул: аны ЧКга эшкә алафузовчы эшчеләре җибәргән. Егерме яшь. Шәһәрдә совет власте өчен көрәшләрдә катнашкан. Танышканда ул: «Фамилиямнең тамырында «ирек» сүзе бар, «бәйсезлек», шуңа күрә татарлар арасында Таһировлар күп очрый»,— диде. Кешене эштә дә, сүздә дә сыныйсың. Егетнең кешеләрне: «Моның белән утка да суга да керә алам, ә аның белән юк, каберең якын булмасын»,— дип, кискен аерып каравы да хәтеремә сеңеп калды... Егерме яшьтә мондый туры сүзле булу өчен үзеңнең дә утны-суны кичкән булуың зарур. Әле мин ул чагында Гайнулланың Гафур учитель мәктәбендә укуын да, татарларның бөек шагыйре Тукайны күмгәндә моңарчы татымаган хисләр кичерүен дә белми идем. «Бөек кешенең үлеме мине яңадан туарга мәҗбүр итте»,— диде ул соңрак, без якыннанрак танышкач. Аның бу сүзе турында мин ул чакта да гаҗәпләнеп уйлаган идем. Таһировча «утка-суга керерлек булу» — кешенең эшкә, хезмәткә бирелгәнлеге дә, намус-вөҗданының саф булуы да иде. Беренче очрашуда ук Гайнулла әйбәт тәэсир калдырды. Егет елгыр, житез һәм бик аңлы булып күренде. «Утка-суга керерлек кешенең төп сыйфаты нинди булуын телисең?» — дип соравыма ул: «Хаклык өчен үлә белсен»,— дип җавап бирде. «Татар халкын халык итеп шагыйребезне соңгы юлга озатканда күрдем»,— диде әңгәмәләрнең берсендә...

Ольконицкий безне җирле чекистлар белән таныштырганда: «Таһиров сәләтле, үткен. Тәҗрибә тупласа, егет үзен күрсәтәчәк»,— дигән иде...

Таһиров кукыраеп утырган Никитинага күз сирпеп алды да миңа нәни генә бер язу калдырып чыгып китте. Кәгазьгә ашыгып, хәрефләрне берсе өстенә икенчесен сикертеп, бер генә җөмлә язылган иде:

«Күрше бүлмәдә, миндә допроста Зоряны үтерүче капитан Богданов утыра».

Күрәм, Никитинаның сабырлыгы югалды, минем төсне үзгәртерлек нинди ят хәбәр китерде икән теге яшь егет дип баш вата ул хәзер. Әлегә

аның белән сөйләшерлек хәлдә түгел идем, никадәр тыныч күренергә тырышсам да, бөтен тәнемә бөркелеп ут капты. Конвоир чакыртып, Никитинаны ялгыз камерага озатырга боердым.

Таһиров бүлмәсенең ишеген ачканда тирән көрсенеп куюымны сизми дә калдым... Менә ул үтерүче... Таһировның яшьләгеннән, тәҗрибәсезлегеннән көлеп, мыскыл итеп, тезен-тезгә чәнчеп утыручы дошман!..

Кердем, миңа күтәрелеп тә карамады. Тын тартырга да өлгермәдем, тезгенне үз кулыма алдым, җаяне киереп тарттым.

— Капитан Богданов! Сез аттыгызмы?! Кызны сез үтердегезме?

— Ха! Мин хатын-кыз белән сугышмыйм.

Каян килгән боларның барысына да тәкәбберлек?

Богданов миңа озак уйларга ирек бирмәде:

— Миңа сезне үтерергә боерылган иде. Кыз үзе ыргылды. Очраклы һәлак булды,— диде.

— Ах, сез ялланган үтерүче икәнсез әле! Арттан килеп төбәгәнсез. Хатын-кызны ихтыяри-мәҗбүри үтердегез алайса? Юнкер булгансыздыр, мөгаен? Офицер намусы турында лыгырдарга яраткансыздыр?

Ул башын югары күтәрде.

— Әйе, Казанда юнкерлар училищесын тәмамладым. Әйе, офицер. Фронтта булдым. Офицер намусының иң югары ноктасы — боерыкны үтәү дип саныйм. Тагын ни кирәк?

— Әгәр сезгә боерыкны намуссыз, пычрак кеше бирсә? — дип, тизтиз бүлдердем мин Богдановны.

Таһиров, утырган урыныннан кузгалып, тәрәзә янына китте һәм йотылып тыңлый башлады.

— Кабахәт биргән боерыкны да үтисезме?

— Мин үтәүче! — диде капитан, ниһаять, сүрелеп.— Ахыр чиктә минем хакта теләсә ни уйлагыз. Ардым мин.

— Куркак җан сарык тиресе ябынып җайлашырга тырышамы? — диде мин тәмам ярсып.— Бөтенләй гаепсез кеше һәлак була. Аткан кешедә дә гаеп юк, имеш. Янәсе, боерган кешедә генә гаеп! Кем боерды? Исеме? Адресы? Тиз бул!

Халәтемнең ялгыш икәнен аңлыйм, тикшерү вакытында алай сөйләшергә хакым юклыгын да беләм, әмма үземә-үзем хуҗа була алмыйм, нәфрәтем ташып тышка чыга. Таһировның гаҗәпләнгән һәм борчылган күз карашы да мине тыя алмый... Кызып китүемнең мондый дәрәҗәдә аңымны томалавын очратканым юк иде әле, хәзер үк допросны туктатып чыгып кына китәсе дә бит, юк, киресенчә, Богданов янына очып барып җиттем, якасыннан алып кычкырырга керештем.

— Син кабахәтне хәзер атып егам! Совет властена сукыр бер тиен дә файда китермәячәгең көн кебек ачык. Кем кушты?! Кем? Шушы сорауга җавап бир! Кем?!

— Сез аны сөя идегезме? — дип сорады Богданов кинәт үзгәреп, ничектер тынычланып...— Хәзер генә асылын аңладым... Винокуров йортының үз кешесе дошманны коткарыр өчен үзен корбан итте... Сез мине ата аласыз! Әмма мин офицер булып калам, әгәр генерал Попов рөхсәт итсә, дөресрәге, кушса, барын да сөйләп бирәм. Ә хәзер... Җаныгыз ни тели, шуны кылыгыз.

«Винокуров йортының үз кешесе» дигәне өчен тагын бер тапкыр якасыннан алып, җаны бугазына килгәнче селкергә ниятем бар иде, Таһировның ишарәсен аңлап, тыелып, туктап калдым.

— Шулай булсын,— дидем, бар сабырлыгымны җыеп.— Попов та ерак түгел! Хәзер алып керерләр.

Попов та янәшә бүлмәләрнең берсендә иде, аны безнең янга Владимиров алып керде. Минем ярсыган ачулы кыяфәтемне күреп, ул башта Таһировка эндәште:

— Бераз утыра торсыннар. Сез аларга сүз алышырга гына ирек бирмәгез.

Аннары миңа борылды:
— Ә сезгә бер хәбәрем бар,— диде.
Миңа билгеләнгән кабинетка чыккач, Владимиров гафу үтенде:
— Сергей Сергеевич, сезгә чак кына ял итеп алырга иде. Аннары Попов яшәгән квартира хуҗасының допроста күрсәткәннәре белән танышып керсәгез, яхшырак булыр.
Мин күңелемнән генә аңа рәхмәт укыдым...
Попов үзенең политик партияләр белән бәйләнештә булуын катгый кире каккан, төзегән оешмасының максаты — бары тик ярлы офицерларга ярдәм итү, иганә җыю дип кенә раслаган. Винокуровны, Никитинаны бөтенләй белмим дип барган...
Кызык! Нәрсәгә өметләнә икән ул генерал?
Ул яшәгән йорт хуҗасы — шушы яшерен оешманың әгъзасы икән. Хуҗа шактый буталчык сүзләр тезеп барган. Ләкин аның соңгы йомгаклау сүзе мине сагайтты. Контрреволюционер-мещан, фәлсәфәгә биреләп болай дигән: «Бергә эшләү дәвереңең тәүге көннәреннән үк Попов үзен өметсез бер бәндә итеп танытты, аның эчендә контра ята».
— Бар булганы шушымы? — дип сорадым мин Владимировтан.
Мәсьәлә ачык та, караңгы да. Мин — Мәскәүдән килгән чекистларның җитәкчесе. Кемдер нәкъ мине юк итәргә куша. Владимировны да түгел, Заковскийны да түгел, мине... Юлдан алып ыргытырга...
Эш шуңа барып терәлде. Бу «кемдер»нең Винокуров катына безнең килүне хәбәр итеп куйган булуы ихтимал. Җепнең бер очына тотынып, болай уйларга була: ВЧК председателенең урынбасары Александрович — сул эсер. Ул Казан ВЧК председателе Олькеницкийның урынбасары Вера Браудега, шундый ук сул эсерга, партиядәшенә, безнең үтә яшерен сәфәрне белдереп куйган. Монда артык гаҗәпләнерлек урын юк. Винокуров — уң эсер. Уңнар сул эсерлар белән, бигрәк тә суллар Совет хөкүмәте составына кергәннән соң, ике ара дошманлашып беттеләр. Юк, Александрович хәбәр итмәс Винокуровка.
Алайса, Винокуров каян белгән? Аңа кем хәбәр иткән? Зоря «телеграмманы үзем күрдем» диде бит... Ах, ул исән булса!.. Хәбәр иткән кеше бу операциядә башмы, түгелме?
Таһиров ишеге төбендә чак кына тукталып тордым, юк, Попов белән Богдановның сөйләшкәннәре ишетелми, анда тып-тын. Допросны дәвам итәргә кирәк, ашыктырырга, тизрәк-тизрәк җепнең очын тотып алырга. Югыйсә, йомгак тагын да зураеп, очның бөтенләйгә гаип булуы ихтимал. Ашыгырга кирәк, ә кулдагы фактлар бик аз...
Кем, кем, кем?
Тып итеп бүлмәгә кереп бастым да, җепнең очын кулда тоткан кебек, туп-турыдан бәрдердем:
— Генерал Попов! Богдановка боерыгыз: мине юк итәргә кем кушканын әйтсен!
— Рәхим итегез, капитан,— диде Попов, шуны гына көткән сыман.— Җаныгыз ни тели, шуны сөйләгез.
— Ярый! — диде Богданов.— Алайса белегез: мин сезнең приказны үтәдем, генерал! — Поповның гаҗәпләнүенә игътибар итмичә, Богданов дәвам итте: — Без кулга алынган көнгә каршы төндә поручик Сердобольский бер капитанны алып килде. «Капитан Михайлов» — дип таныштырды. Шул капитан сезнең приказны тапшырды.
Мин Поповтан күземне алмадым.
— Нинди приказ? — диде ул.
— Винокуров квартирасында булырга, сезне сакларга, һәм, әгәр анда чекистлар була-нитә калса, командирларын, менә аны,— Богданов миңа төртеп күрсәтте,— атарга!
— Кабахәт! — диде Попов, ирен читләрен генә кыймылдатып. Кулмак төймәләремне чишкәнне сизми дә калганмын. Арт чүмечем котырып сызлаца да, аны-моны сиздермәдем...

Мин таш маңгайлы кешеләрне бер чакта да сөймәдем. Ялганчы итеп күрәм мин андыйларны, үз куркаклыкларын яшерергә азапланып, хыянәтне, астан чагуны, ваклыкны «өстән куштылар!» дип акланучы вак җаннар дип саныйм мин аларны. Әлбәттә, дөньяда күп нәрсә, бигрәк тә армиядә, тәртипкә буйсынып яши, анда приказны сүзсез һәм карышусыз үтәргә кирәк. Күзгә-күз сугышка чыккансың икән инде, икеләнергә урын калмаган: я син аны, я ул сине!.. Ә монда фронт сызыгы күзгә күренми, вакыты шундый: дусмы ул, дошманмы, тикшереп торыр ара тар, аерып алу читен... Дошман диярсең, ә ул вакытлыча гына ялгышкан, пар нарат арасында адашкан кеше булыр, киләчәктә илгә әллә ни чаклы файда китерер!

Җитәкчеләребезнең дә гап-гади җан ияләре икәнен аңлый идем, башкалар кебек аларның да хаталану ихтималы бар. Тик алар ясаган хатаны төзәтү авыррак! Кеше язмышын хәл кылганда, бигрәк тә үлем җәзасы чыгарганда уйландыра... Дөресен әйткәндә, һәркем үз бәясен, сүзенең кыйммәтен, уңай яки кимчелекле якларын тәгаен белә. Моның өчен үзеңә чит кеше күзе белән бер карап алу да җиткән. Йөрәкле һәм намуслы булырга гына кирәк. Кызганычка каршы, читтән торып үз-үзеңә карау сәләте барлык кешегә дә бирелмәгән. Кайберәүләр, читтән караган саен, үз-үзләренә ныграк гашыйк була баралар. Бу — бәндәләрнең куркыныч кимчелеге.

Богдановка карыйм да уйлыйм: монда икеләнер урын юк, дошман! Тотарга да атарга кирәк! Бу теләк мине шулкадәр ашыктыра иде ки, кул үзеннән-үзе кобурага үрелә... «Хәзер үк, хәзер үк!» Үземне тыям, кулымны утта пешкән кебек ашыгып тартып алам...

— Допросны дәвам итегез! — дип бүлмәдән йөгереп дигәндәй чыгып киттем. Владимиров белән Таһиров сорау ала калдылар...

Шактый вакыт узгач Таһиров минем янга керде. Карыйм: канәгать! Авызы ерылган.Генералдан рөхсәт алгач, Богданов шактый ачылып киткән, корал складының урынын күрсәткән.

— Ничек булды соң? — дип сорадым мин Гайнулладан.

— Бардык! — диде Гайнулла тыйнак кына.

— Таптыгызмы?

— Тапмыйча! — Гайнулланың күзләре балкып ук китте.— Отряд алып барып илле биш винтовка алып кайттык.

— Илле биш?

— Богданов анда йөз сиксән винтовка һәм бер тартма граната булырга тиеш дигән иде.

— Калганнары кая киткән?

— Безгә кадәр анда кемдер кул тыккан булса кирәк. Тартмалар ачык иде, ашык-пошык ачканнары күренеп тора. Бөтен җирдә күн итек эзләре.

Уйга калдым. Таһиров:

— Без барасын офицерларга берәрсе хәбәр итеп өлгердеме? Складны яртылаш бушатканнар. Шик тә юк!

Үз фикеренең кыюлыгына гаҗәпләнгән төсле, Таһиров сүзен йомгакларга да оялган сыман бер читкәрәк китте. Казан вокзалында башланган гаҗәп хәлләрдән чыгып фикер йөрткәндә, аның шиге бик тә урынлы, йомгак сүзендә хаклык бар иде. Йөз сиксәннән нибарысы илле биш винтовка калган. Склад урыны бүген генә мәгълүм булды... Хыянәтче безнең үз арабыздамы? Кем ул?

— Хәзер үк Поповны кертегез! — дидем мин Владимировка телефон аша. Тик Поповның җаваплары да авыр табышмакны чишәргә ярдәмче була алмады. Хыянәтче кем? Үз арабыздамы?

Хыянәтченең безнең ниятне, эшне, корган планнарны, хәрәкәтне, юлны бик ачык һәм алдан белеп торуында бернинди шик-шөбһә калмады. Белүчеләр аз булса да хәзер генә аларны бергә җыеп, чүпләү ысулы белән ачыклау җае юк иде. Болай, ашыгыч хисләргә баш биреп, кемгәдер кара

шик ташларга минем хакым юк иде. Исбатларга кирәк, какшамас, ныклы дәлилләр белән исбатларга!..

Поповның тәне тиз ачылды. Әллә мин артыгы белән кискен идемме ул очрашуда?

— Минем оешмада 400-460 офицер әгъза булып торды. Төп эшебез — аларның матди ягын кайгырту. Генерал Алексеевтан килгән инструкция нигезендә рядовой офицерларга аена 150 сум, взвод командирларына 200, рота командирларына 300 сум түләп тордым... Корал мәсьәләсенә килгәндә, складка сездән алда кем барып йөргәнен әйтә алмыйм. Владимировка склад турында беренче допроста ук әйткән идем. Складта корал аз булуын бер сүз белән генә аңлата алам: акчага корал сатып алырга тиешле кешеләр ялганлаган булып чыга. Акчаны үз ихтыяжларына тотып бетереп мине алдаганнар, ә сезне ялгыш юлга кертеп җибәрергә маташканнар!..

Әһә! Димәк, Владимиров корал складын Таһиров белән бездән элгәрәк ишеткән! Ишеткән, безгә әйтмәгән!

Таһировны чакырдым.

— Сиңа әйттемме?

— Юк,— диде Гайнулла.— Склад хакында Попов авызыннан гына ишеттем.

— Допрос беркетмәләрен тикшер!

Күтәргә чама калмады, беркетмәләрне икәү актарып чыктык: склад турында ләм-мим.

Тагын Поповны чакырттым.

— Склад турында беренче допроста ук күрсәттегезме?

— Әлбәттә!

Димәк, хыянәтче — Владимиров, минем юлдашым...

Чекада хәтсездән эшли, шул рәвештә жандармнар арасында буталган, яшертен эш ысулларын өйрәнгән... Хәзер Попов авызыннан сүз чыгуга тарафдарларына безнең складка барасыны хәбәр итеп өлгерә. Һәм тегеләр, җүләр түгел, тиз арада «кул җылытып» алалар...

Бары тик шушы бер дәлилгә нигезләнеп, бар булган шик-шөбһәләрне кушып, кешене хөкем тактасына бастырырга ярыймы? Ә хөкем аяусыз, кискен булачак! Заман бары кискенлек таләп итә. Вакыт үтә нык чикләнгән. Мәскәү аша кайта-кайта, төпченеп торырга форсат калмаган. Үз иптәшебезне йолыккалап карыйкмы, әллә фетнәчеләрдән сорауларны тизләтергәме?! Бер хыянәтченең нинди зур эшләрне дә егып сала алуын беренче тапкыр мин шунда аңладым шикелле. Заковскийны чакырдым: хәзер бердәнбер өмет аңарда. Эшче егет, ышанычлы һәм күзәтүчән.

Керде Леонид, мин аңа сынап карап торам, ул, бераз гаҗәпсенеп һәм сәерсенеп, миннән күзен алмый.

Юантык гәүдә, тупас, нык куллар... Ничек без аны «офицер, прапорщик» дип тәкъдим итә алдык икән? Егет — җир кешесе, хезмәт язган аңа, эш... Мондыйлар бер чакта да хыянәткә бармыйлар...

— Леонид,— дидем туп-туры,— Владимиров турында ни уйлыйсың?

— Начар уйламыйм,— диде ул эшлекле һәм ышанычлы тавыш белән.

— Винокуровларда чуалышта син аны күрә алдыңмы?

Аның маңгаена буразна ятты — тик озакка түгел!

— Үзен кыю һәм ышанычлы тотты. Шикләнерлек берни булмады. Ишегалдыннан ярдәмгә чекистлар кереп җиткәнче янымда булды...

Леонид шикләнүләргә ачыклык кертә алмады, мин Ольконицкийга мөрәҗәгать итеп карарга булдым.

Менә хәзер күз алдымнан уртачадан биегрәк буйлы, какча ябык йөзле Гирш Шмулевич узып китте... Җае чыкканда Казан ВЧК председателе турында бер-ике авыз сүз әйтәсем килә. Якты сүз белән яд итәсем килә көрәштәш дустымны!

Кеше, соңыннан кем генә булып китмәсен, гадәти тормыш юлы уза. Туа, үсә, ныгый, яши. Балачак, үсмерчак, егетчак артыннан балигъльк, урта яшь еллары килә. Яшьлекнең тыелгысыз дәрте сабыр акыл, тәҗрибә һәм салмаклык белән алышына. Үзгәрә кеше. Ә кайберәүләр гомер буе бала-чага булып калалар, алардан сабыйлык, беркатлылык китми диярлек, еларга кирәк чакта көлә андыйлар, көләр чакта сытылырга әзерләр. Авырга да, җиңелгә дә битараф була алар. «Ясмык булса да көн үтте, борчак булса да көн узды»,— ди татар халкы. Монда мин «көн» дигәнне «гомер» дип кенә алыштырыр идем... Шундый кешеләр дә бар: алар балачактан ук ачык зиһенле, олыларча уйга сәләтле, җитди булалар. Уйный белә андый кеше, көләргә дә оста, ләкин аның уенында — акыл, шаяруында зирәклек ята. Андыйлар дөньяга һәрдаим ачык күз белән карый, укага алданмый, асылга сатылмый, дөнья мазасын бик тиз үзенеке итә, дөнья гаме аның өчен уртак гамьгә әверелә. Григорий Ольkеницкий шундый кеше иде. Ярлы баласы! Ул дөньяга килгәндә, әтисе гаиләсен түгел, үз тамагын да туйдыра алмаслык фәкыйрь, көчсезсырхау була. Григорий ипинең тәме ачы икәнен тиз татый! Үсә, калка, нужа куа, Уфадагы бер туган апасы белән җизнәсе чакырып алмаса, белмим, кара нужада җан саклап кала алган булыр идеме икән? 1911 елда Григорий туган өяз шәһәренең полиция идарәсендә өлкән Ольkеницкий турында болай дип теркәп куялар: «Ярлы-ябагай, мал-мөлкәте юк, шул сәбәпле унҗиде яшьлек уллары Гиршны карап, тәрбия итү хәленнән килмәде, улы Уфадагы апасында яшәргә мәҗбүр».

Уфада Григорий гимназия тәмамлый, шул чакта ук үзенең фикер сәләте, иманының ныклыгы белән башкалардан аерылып тора һәм күпләргә үрнәк була. Иншаларының берсендә ул: «Кеше үз хокукы өчен даулаша белергә дә, мохтаҗларга ярдәмләшергә дә тиеш!» — дип яза.

Уфадан Петербургка бара, академик В. М. Бехтеров нигез салган атаклы психоневрологический институтка укырга керә. Аның белән бер үк вакытта бу институтта Мулланур Вахитов, Лариса Рейснерлар укый, институтта ирек рухы хөкем сөрә. Бер ел укыганнан соң Ольkеницкий ни сәбәптәндер Казан университетына күчә, шунда укый. һәм шунда, Казан каласында, 1915 елда ул язмышын большевиклар белән бәйли.

Без очрашканда, аңа егерме биш яшь иде. Бездән күпмегә генә өлкәнрәк ул, әмма шактый олырак яшьтәгеләр дә аның яныннан үзгәреп, җыелып һәм җитдиләнеп китәләр иде. Совет властеның иң явыз дошманнары — безне кимсетеп һәм түбәнсетеп караган бушбугазлар да аның янында басылып һәм юашланып калалар. Ул үзенең салмак кул хәрәкәтләре, пенснесеның тонык ялтыравы, сүзләренең сайлап һәм үлчәп әйтелүе, кыскасы, бөтен тышкы кыяфәте, эчке ныклык беркелеп торган уйчан күз карашы белән дусны күтәрә алган, дошманнарны үзенә буйсындырган искиткеч көчле шәхес иде. Бер үк вакытта аның кай жирендәдер студентлыгы калган әле, ул яшьләрчә, хис белән онытылып көлә дә ала, сүздә уен-көлкене, тапкыр тәгъбирләрне мул куллана. Нәни генә факттан җитди һәм ифрат дөрес нәтиҗә чыгара ала, хәтере нык, фикере йөгерек һәм акылы саф иде. Кыскасы, Казан чекасында мин олы шәхес, чын революционер белән очраштым...

Менә хәзер, шушы минутларда мин аның кабинетына менеп барам... Ишек катына җитәрәк шып туктадым: кая кереп барам? Нигә? Ул мине бер сүз белән егып салачак бит! «Мәскәүдә чакта ни карадыгыз? Юлдаш итеп хыянәтчене алып килдегезме?» — дисә?

Юк, аны борчып торуның кирәге юк. Владимиров артыннан ныграк күзәтергә генә кирәк!

Ольkеницкийның очрамавына куанып, тиз-тиз атлап, үземә бирелгән кабинетка кайттым...

Эшне без болай бүлешкән идек: мин, Владимиров һәм Таһиров кулга алынганнардан сорау алабыз. Һәр кичне, бик соң гына җыйналып, уртак эшкә йомгак ясыйбыз.

Ольkеницкий белән Заковский безгә оператив ярдәм оештыралар: хәзер алар поп малае Сердобольский белән капитан Михайловны эзлиләр, әлегәчә эзләренә төшә алганнары юк. Табылган, дошман булулары расланганнарны төрмәгә яба торалар. «Серле фетнә йомгагына» тегеннән дә, моннан да усал язмышлар килеп кушыла. Казан чекистлары аляпны онытттылар, нинди елгыр Таһиров та ябыгып, суырылып калды. Ул һәр иртәне: — Йокы качты әле, Сергей Сергеевич! Фетнәчеләрне тотып бетерербез, качкан йокыны ничек тотарга? — дип шаярта.

Савинковчылардан тыш генерал-майор Попов оешмасының чамадан тыш тармакланган булуы безнең эшне кинәйтте, Мәскәүгә кайчан кайтасыбызны да онытып эшкә чумдык...

Соңгы көннәрдә кулга алынганнарның эшләрен актарып утырам. Кабинетта берүзем. Ике тәрәзә. Берсе ишегалды ягына караган. Аннан ике катлы бина күренеп тора. Кайчандыр купец складлары булган озынча бу бинада хәзер төрмә. Анда совет властена каршы корал тотып чыккан кешеләр утыра. Иң куркынычлы дип саналганнар — чека урнашкан йортның подвалында. Набоков үз йортында кем урнашасын белгән диярсең, подвалын бетоннан коеп, аерым-аерым бүлмәләргә бүлеп эшләткән.

Май төне. Икенче тәрәзәмдә урам. Урамда кеше калмаган диярлек, тәрәзәмнән яз исә һәм тынлык агыла. Баш ярасы котырып сызлап ала, ләкин мин ул турыда уйламаска тырышам... Ярам турындагы уйларым Зоря янына алып китә... Ихтыяр көчемне җыеп, тешемне кысып эшкә чумганда, җәрәхәтем турында онытып торам. Җәрәхәт онытылганда, Зоря да читтәрәк кала бирә...

Соңгы көннәрдә, иптәшләрнең күзәтүләренә таянып, акыллы бер нәтиҗә ясадык: совет власте дошманнарны тегендә дә, монда да йорт алып, арендага килешеп, ашханә ачып җибәрәләр дә гөрләтеп яши башлыйлар. Кем керсә дә, шикләнерлек түгел — һәркемнең корсагы ашау сорый! Шушы туклану урыннарының хуҗалары барысы да диярлек офицерлар икәнен Фәридә Ибраһимова ачты. Үзем дә, ашарга дигән булып, шундый шикле нокталарга кереп чыккаладым. Көяз мыекларын бөтереп куйган әзмәвердәй егетләр, үгез-үгез ирләр, ялтыр куныччлы итекләрен, галәфи чалбарларын салып та тормыйча күбегән күпертеп, мактый-мактый сыра тәкъдим итәләр. Кысла да бар боларда, салкын ит тә табарга була, аракысы да мул ага...

Шундый урыннардан байтак дошманны кулга төшердек соңгы көннәрдә. Капитан Нефедов. Поручик Ольгин. Февраль революциясенә кадәр үк Керенскийның шәхси секретаре булган Борис Осипович Фликкель. Аерата бу соңгы шәхес кызыклы — аның эзенә дә ут күзле Фәридә төште. Ул аны Пассаж йортына урнашкан «Мәскәү» кафесында очраткан. Яңа ачылган диярлек бу кафе да контрларның очрашу, күрешү урынына әйләнеп киткән икән.

Ике зур кабинетка аерым-аерым бүлмәләр ялганган бу кафеда мин дә булдым. Хуҗасы офицер булмаса да, ай-һай!..

Хуҗа ханым Мария Мельгунованың теле-телгә йокмый, бер сорауга мең җавабы әзер, чәтелдәп тора. Йөзенә сары сарган, бик күп ирләргә яр булып, иртә картайган бу ханым бүлмәләрне ике мең ярым сумга сатып алган.

Мондый буталчык, тотрыксыз чорда кафе ачу уе каян башына килгән? Ике мең ярым аз акча түгел... Урынны ничек эзләп тапкан? Кем күрсәткән?

Хуҗага беренче сорауларым шул иде...

Шул көнне безнең арага полковник Сужко исеме килеп керде.

Бу исемне хәтерләгез, алда да исем-фамилияләр ишәеп китсә, гаҗәпләнмәгез! Революция — бөтен халык эше, аны яклаучылар күп булган кебек, дошманнары да житәрлек иде...

Димәк, Сужко. Сужко яшеренеп ятмый, Казан гарнизонында хезмәт итә. Мельгунова белән яшьрәк чакта таныш була, һич уйламаганда хә-



*А. Тимергалина рәсеме.*

зер аны эзләп таба, танышлыкны яңарта, кафе ачарга киңәш бирә, акчасын кызганмый, ярдәмгә үз кызын да шунда эшкә урнаштыра, ашарга көн саен шунда йөри, «искиткеч тәмле ашаталар», янәсе!.. Гарнизонда да начар ашатмыйлар, тикшердем...

Казан чекасының яшерен хезмәткәре Мөнәвәр Галимов ике-өч көн эчендә шактый нәрсә ачыклады. (Үсә милли кадрлар, алар безгә бик-бик кирәк!) Кафега ашарга күпчелеге кадетлар, эсерлар һәм офицерлар йөри икән. Башка халыкны көрәк сакаллы, әлекке офицер булуы тотышына чыккан швейцар ишеккә якын да җибәрми! Галимов үзенең отчетында: «Рус контрасының этә-бетә шул кафеда кайный»,— дип язган. •

Кафены да, «тәмле тамаклар»ны да күзәтү астына алырга туры килде.

Сорау алганда, Фликкель артык зур нәрсә әйтә алмады, «Совет властен бәреп төшерү өчен көрәштә Казан хәзер үзәк урынны алып тора, төрле яктан фетнәчеләр монда агыла»,— дип, без белгәннәрне кабатлады. Казан фетнәчеләренең кемнәр белән һәм ничек элемтә тотуларын сөйләүдән баш тартты, көрсенеп, ачы елмаеп өстәп куйды:

— Остарып барасыз! Шундый сөйкемле Фәридәгә: «Кайчандыр Керенский белән таныш идем»,— дип әйтеп тә өлгермәдем, тәбе капкачы шапылдап ябылды да...

Бу сүзенә кәефем килде: дөрес, остара барабыз!

Узганнарны үзгәртеп булмаган кебек, аның кайбер нечкә, четерекле якларын аңлап та, тулаем аңлатып та булмый. Килүебезгә күпме генә вакыт узды, мин, Мәскәүдән гадәти бер эшне башкарырга җыенып чыккан кеше, нинди зур һәм җаваплы эшкә юлыкканымны тулысы белән аңладым. Хәзер, җыйнап һәм йомгак ясап әйткәндә, без ифрат зур һәм җаваплы эш үтәп чыкканбыз икән! Казанда без Ярославльдагыдан ким булмаган фетнәнең башын һәм койрыгын кискәнбез икән! Бераз алга китеп булса да эшебезнең олылыгын дәлилләр белән беркетеп узуны кирәк санадым. Эшнең азагын белеп тотынганда, башын, башлангычын аңлау җиңелрәк була кайчакта. Мисалга иң элек 1922 елны, уң эсерлар партиясе лидерларын судка әзерләгәндә, теркәлгән материаллар арасында күземә чалынган бер офицерның тануын сезнең игътибарга тәкъдим итәсем килә. Безнең эшнең зурлыгын да, хәвефле икәнен дә раслаучы документ ич ул!

1918 елның маенда, үзләренең 8 нче советында, уң эсерлар совет властен бәреп төшерергә дигән карар чыгаралар. Аз да түгел, күп тә түгел: «бәреп төшерергә!» Алар февраль революциясе игълан иткән буржуаз-демократик Россия өчен «актык тамчы каннарына хәтле» сугышырга әзерлекләрен белдерәләр. «Бу бурычны тормышка ашыру юлында тере киртә булып большевиклар власте тора». Большевикларны юкка чыгару — барлык демократларның иң мөһим һәм кичектергесез бурычы!» — дип белдерәләр алар. Россия туфрагына интервентлар килә икән — килсен! Совет җитәкчеләрен террор юлы белән кырып бетереп була икән — булсын!

Советка каршы фетнә күтәрүнең иң уңайлы урыны итеп Идел буе — Казан шәһәре сайлана. Абрам Гоц — эсерларның иң әрсез җитәкчесе болай ди: «Әгәр бүген түгел икән — кайчан? Әгәр без түгел икән — большевикларның муенын кем сындырыр?!»

1918 елның алтынчы августында ак чехлар һәм комучлар белән Казанга бәреп кергән уң эсер Владимир Лебедев соңыннан, эмиграциягә качкач, Идел буеның ни өчен фетнә үзәге итеп сайлануы турында болай дип язды: «Идел буе большевистик үзәклардән читтәрәк, шәһәр-авылларында туктаусыз чуалышлар дәвам иткән төбәк иде. Идел буенда фронттан кайтарылган бик күп корал тупланган. Идел — табигый киртә булырак та күтәрелеш өчен уңай: аның аръягында бөтен көчне җәеп җибәрергә мөмкинлек бар иде». Казан, Лебедев сүзләре белән әйтсәк, фетнәчеләрнең һәр төрен үзенә тартырлык урын дип табыла! «Казанда —

Россия дәүләтенең барлык алтыны. Артиллерия һәм интендант хезмәте кирәк-яракларының чиксез зур запасы. Казанга шушы байлыкка кызыгып, күпме офицер гына җыйналмагандыр! Аларның күпчелеге советка каршы оешмаларга берләшеп өлгергән, көрәшне башлап та җибәргән... Кыскасы, большевикларны тар-мар китерү өчен Казаннан да кулайрак шәһәр юк. Шуның өстенә Казан — Россия дәүләтенең сәяси бер үзәге һәм Идел буе төбәгенең төп шәһәре иде».

Менә, һәммәсе үз урынында, ап-ачык...

Контрреволюцион агымның башында ул чагында Борис Савинков торган. Чит ил интервентларының акчасына төзелгән «Ватанны һәм иреkне саклау союзы»н ул партиясез оешма дип санаган. Союзга эсер белән меньшевик та, кадет белән монархист та кергән, буржуаз милләтчеләр дә, анархистлар да анда җылы урын тапканнар. Килсеннәр, керсеннәр, берберсен ашарга әзер булган группа вәкилләре дә керсен, советка каршы көрәшкә генә чыксыннар! Кем тели — шул керсен. Кем совет властена каршы — шул кеше авантюрист Савинков байрагы астына баса. Һәм алар байракны нәкъ менә Казанда күтәрергә чамалаганнар...

1920 елда, Варшавада, үз үткәннәренә «тарихи йомгак ясап», үз бәясен күтәрергә тырышып Савинков бер китап чыгарды. Китапның исеме дә авторы кебек үк, танавын күккә чөеп тора: «Большевиклар белән көрәш». Бу китапта кызыклы бер сан бар. 1918 елның маенда (димәк, без Казанга килеп төшкән көннәрдә!), Союз Россиянең 34 шәһәрендә нигезләнеп, аның биш мең ярымнан артык әгъзасы булган икән. Гади сан түгел, гади кеше анда әгъза булып керә алмаган, совет властена каршы ыжгырып торган биш мең ярым коралллы бандит, башкисәр террористлар илебезнең утыз дүрт шәһәрендә фетнәгә сигнал гына көтеп торганнар! Восстаниенең планы да бар. Бар! «Бу план нигезендә,— дип яза Савинков,— Архангельскига кергән союзниклар, безнең фетнә нәтиҗәсендә кулыбызга төшкән Ярославльгә таянып, каршылыксыз-нисез Вологданы алалар да Мәскәүгә хәвеф тудыралар. Рыбинск белән Ярославльдән соң чиратта — Муром, Владимир, Калуга... Аннан Казан... Мәскәүдә төп удар хәл ителгәннән соң (Ленин һәм башка җитәкчеләр юк ителгәч, дип тә аныклаган дошман!) башкаланы фетнә күтәргән башка шәһәрләр белән урап алу күздә тотылды. Союзниклар төньяктан узып әзерәк кенә Самараны алган ак чехларга ярдәмгә килә дә, Идел буе большевикларының өметен өзә».

Мактанчык һәм бушкуык Савинков үзенең «грандиоз планнары»н бәян иткәндә бер нәрсәне тырышып-тырышып «оныта», нәни генә төгәлсезлек «җибәрә». Ул үзенең Казанда җиңелүен танырга һәм икърар итәргә теләми! Телгә дә алмый авантюрист, үзенең Леонид кебек эшчеләрдән, Гайнулла Таһиров һәм Фәридә Ибраһимова кебек алафузовчы эшче балаларыннан җиңелүен танырга теләми. Юк! Ул сүзен вакытлыча уңыш китергән Ярославль фетнәсеннән башлап алып китә. Казанны соңыннан гына, сүз уңаенда гына телгә кертә. Ә аның иң якын ярannарыннан берсе Дикгоф-Деренталь исә, әлерәк кенә булып узган вакыйгаларга бәһа биреп, 1918 елның ноябрендә болай дип яза: «Мәскәүдә тар-мар ителгәннән соң савинковчылар май аенда Казанда ирешәчәк уңышларына йөз тотып кына яшәделәр... Мәскәү вариантын читкә куеп торып, штаб Казанга хуҗа булуны планлаштырды һәм шуны тормышка ашырырга да керешә. Максат бер һәм ул — Казан! Казанда тупланган частьләр ашыгыч ачыклана, аларның яшерен туплану урыннары билгеләнә, шәһәргә бер-бер артлы квартирьерлар озатыла».

Үтә яшерен һәм җентекләп эшкәртелгән планнар да беренче карашка юк кына сәбәп аркасында фаш ителү ихтималы барын без мисалларда күргән идек инде. Монда тагын шундыйрак хәл кабатлана: бөтенләй башка бер сәбәп белән полк командирларының берсенең квартирасында тентү була һәм «Союз»ның барлыгын гына түгел, алдагы көнгә планнарын да күрсәткән кыйммәтле яшерен кәгазьләр чека кулына төшә.

Кайчан һәм кайсы хәрби частьларның Казанга киләсе беленә. Совет власте органнары фетнәнең башы кайда икәнлекне ачыклыйлар. Кызганычка каршы, оешманың үзәге ачылмый кала. Үзәге исән калган оешма өр-яңадан фетнә әзерли башлый һәм бу юлы үзәк итеп Ярославль шәһәре сайлана...

Чекистларның, Мәскәү фетнәсен ачып, Казанда да дошман тамырына балта чабулары турында Савинков та, Дикгоф-Деренталь да артык җәелмиләр, бу факт алар файдасына түгел! Чехословак корпусының баш күтәреп Самараны алгач, Идел буйлап өскә үрмәләп, Казанга һөҗүм әзерләвен дә белмәмешкә салышалар алар. Белү генә түгел, контрреволюциянең бөтен тармаклары тоташкан булган!

Татар буржуазиясе дә читтә калмаган. Каламы соң?!

1920 елда, Казан губчека председателе Иванов совет властеның явыз дошманы буларак танылган Габделбари Батталов турында болай дигән иде: «Батталов кыенсынып-читенсенеп тормады, бәбәкләрен терәп: «Большевиклар власте өч көннән чәнчелер дип көткән идек, мәгәр ялгыштык бугай»,— дип, уен ап-ачык икърар итте. Бер үк вакытта, хәйләкәр төлке сыман, койрыгы белән себереп эзен югалтырга да тырышты. «Мин һәрбер мөселманга лазем булган кебек әз-әз генә милләтче булсам да, бүтәннәр кебек ата милләтче түгел!» — дип сөйләп азапланды».

Документлар исә бөтенләй башканы сөйли. Болак арты республикасы тар-мар ителгәч, Идел-Урал штаты төзибез дип койрык чәнчеп йөргән эшкуарлар советка каршы күтәргән коралларын ташламаганнар, мылтык-пулеметларны идән астына, уй-фикерләрен тел астына яшереп һаман нәрсәгәдер өметләнгәннәр, әзерләнгәннәр. Батталов кәгазьләре арасында 1918 елның май аенда юк ителергә тиешле партия-совет хезмәткәрләренең исемлеге теркәлгән. Мулланур Вахитов, Сәхипгәрәй Сәетгалиев, Шәһит Әхмәдиев һәм башкалар була ул кара исемлектә. Менә сиңа «ата милләтче түгел!» Менә сиңа Батталовның кыңгыр салган тәкъвә түбәтәе!

Контраның Казанда шулай күп туплануын, әлбәттә, без соңрак беләбез. Элгәре бөтенләй капма-каршы якта торган, моңарчы бер-берсенең бугазын чәйнәргә әзер төркемнәр көннәрдән беркөнне кулга-кул тотынышыр дип кем уйласын?! Төрле почмакка карап чукынган төрле милләт кешеләрен дә бер йодрык итеп туплый антисоветизм. Җөмләдән берсе, генеральный штабның элекке полковнигы, гражданнар сугышы елларында ак офицерларның психик атакаларын оештыручы Владимир Каппель, Самара эсерларының отряд командиры булырга ризалыгын сорагач: «Биш куллап риза! Сугышып карыйк! Иманым белән мин мәңге монархист, мәгәр большевиклар белән сугышырга дигәндә, теләсә нинди байрак тотарга да әзер!» — дип җавап биргән.

Менә шулай — теләсә нинди байракка табынырга, теләсә нинди иманга тукынырга әзер!..

Хакыйкатьне табу, бигрәк тә аны ачыклау ифрат читен, гадәттә, тарихны җиңүчеләр яза, ә алар үз үткәннәрен ал төскә манарга яраталар, хаталарын аклыйлар, яки, күрмәмешкә салышып, сикертеп үтәләр. Әйе, «Хакыйкать шик аша табыла»,— дип васыять иткән борынгылар. Әмма, һәр хакыйкать — замана җимеше. Күп тарихчылар, үткәннәрне актарып, аны таба да, хәзерге заманга карап дөресли. Хәтернең дөреслеген тәгаен тикшереп яисә аны төзәтеп буламыни? Берсен бик яхшы хәтерләп, икенчесен дөм онытып кара син! «Аларын оныт, оныт!» — дип, Хәтергә боерык биреп булса икән ул! Юк, үз хәтереңне җиңеп тә, җимереп тә булмый, ярамый да. Әлбәттә, үткән дәверне бөртекләп өйрәнгән галимнәр һәрчак диярлек тарихны шәхси мөнәсәбәтләреннән чыгып, шәхси тәҗрибәләренә таянып язалар. Заман таләпләрен онытып җибәреп кара син!

Мин бу мәсьәләгә һәрьяктан дөрес якынлашырга тырыштым... Иң элек — язганнарыңның дөрес булуы шарт, заман һәм кешеләр соңыннан аңа үз бәяләрен бирәчәк. Хакыйкатем бер — үткәннәр үзгәрми, аңа һәр заман биргән бәһа гына үзгәрә тора...

Әйткәнемчә, ул чакта Казанда күп нәрсә аңлашылырлык түгел иде, газеталар: «Фетнә куркынычы кимемәде, киресенчә, әлегә гел арта тора!» — дип, хәвефле хәбәрләр белән кисәтеп чыга торды. Тып-тын торган көннәрдә дә һавадан яшен исе аңкый, күк читеннән шома гына үтеп барган нәни генә ак болыт мендәре дә зилзилә, давыл хәбәрчесе кебек тоела иде.

Икеле-микеле сүзләргә урын калдырмас өчен, сөйләгәннәремнең сафраслыгын исбатларга ниятләп, ул көнге вакыйгаларга, көннәрнең агышына документлар күзе белән карап алыйк, кемнәрдер безнең рух тарихыбызны бозып: «Алай булмады!» — дип әйтмәсеннәр.

Вакыйгалар агышында мине, Гайнулла Таһировны, Ольконицкийны яки кара толымнарын җилдә җилфердәтеп революция өчен көрәшеп йөргән Фәридә Ибраһимованы күрмәсәгез, исегез китмәсен, без анда идек, шул давыллы көннәр эчендә, гарасат уртасында... Документлар чын булган кебек, безнең барлыгыбыз да чын иде, хак иде...

1918 ел, 25 май. Буржуазияне коралсызландыру максаты белән Казан губбашкармасы контрреволюциягә каршы көрәш комиссиясенә шәһәрдә тоташ тентүләр бурычын йөкли.

1918 ел, 25 май. Солдат секциясе өндәмәсендә шундый юллар бар: «Без кичергән хәвефле мизгел социализм өчен көрәштә туганлык, тигезлек, ирек өчен бөек идеяләр югарылыгына күтәрелүебезне таләп итә».

29 май. Атаман Дутовның ак казаклары белән көрәшкә Казаннан Самарага татар-башкорт батальоны чыгып китә.

29 май. Ак чехословакларның күтәрелешен басар өчен Пензага кораллы отряд озатыла.

1 июнь. Буада хәрби-революцион штаб халыкка болай дип мөрәҗәгать итә: «Революция биргән җир һәм суның кадерен белгән аңлы гражданнарны, кулга корал алып, хезмәт халкының хокукларын яклап калырга чакырабыз. Шушы армияне җитәкләгән өяз советы тирәсенә тупланыгыз! Иптәшләр, актыккы сәгать сукты! Вакыт барлык көчләрнең туплануын көтә. Акрын кыймылдарга ярамый. Коралланыгыз, иптәшләр! Яшәү яки үлем! Җир һәм ирек яки коллык!

2 июнь. Казан губбашкармасы шәһәрдә һәм губернада Хәрби хәл игълан итте. Революцион тәртипне саклау өчен оператив штаб төзелде. Алдан тәгаенләнмәгән митинглар, гражданнарның урамда тупланулары тыелды. Урамда күренгән исерекләр бер елга төрмәгә ябылып, спирт сатуда тотылганнар губернадан ук куылдылар.

7 июнь. «Революция байрагы» газетасы: «Шушы көннәрдә Казанда революциягә каршы фетнә ачылды. Күп санлы тентүләр булып, дошманнарның байтагысы кулга төште. Совет власте кулында кыйммәтле фактик материаллар тупланды. Табылган фактлар заговорчыларның Мәскәү фетнәчеләре белән тыгыз элемтәдә торуын раслады. Контрреволюционерлар арасында уң социалистлар партиясе әгъзалары да бар. Контрреволюция белән көрәш комиссиясе тикшерүләрне дәвам итә, тәмамлангач, кулда булган бар материал игълан ителәчәк».

Безгә ул чакта егерме яшь иде.

Без үзебездән күп тапкырлар тәҗрибәле, оешкан, көчлерәк һәм әзерлекле дошман белән очраштык. Безнең бер генә өстенлегебез бар иде: алар узган көн өчен көрәшсәләр, без киләчәк өчен сугыштык.

Без һәр адымда өйрәнә идек: ялгыша-ялгыша, абына-сөртенә, гарьләнгән чакларыбыз да аз булмагандыр, әмма без усалрак, кырысрак була бардык, анда да уртак эшкә намуслы хезмәтебез күбрәк өлеш керткәнен сизеп-тоеп яшәдек... Ул заманнарда без, ерак еллар узгач, ки-

ләчәктә, кемдер бераү, жып-жылы, тын һәм якты бүлмәсендә утырып, без узган юлларны тикшерер, хаталарны чокып чыгарып, соңга калып булса да, безгә акыл өйрәтер һәм хөкем чыгарыр дип уйламаган идек. Ерак еллар ачыграк күренәдер, мөгаен. Безне вак-төякләрдә гаепләүнең кирәге бармы икән? «Ул артык дәрәҗәдә сул иде»,— дип, яки: «Бу кеше кирәгеннән артык икеләнде, бик озак шикләнде»,— дип тә гаепләргә кирәкми. Безнең намуслы исемне Хәтер һәм Вакыт саклап тора. Без бит бүгенгә кайтып: ә син үзең андый гадәттән тыш шартларда ни кылыр идең дә кем булыр идең дип сорый алмыйбыз!..

Кешенең яшәү яки үлеме бары тик сиңа гына бәйле булганда, хөкем тукмагы синең кулда барында әллә бер дә икеләнеп тормас идеңме?.. Хәзер ап-ачык: дошманның — дошман, дусның дус икәнен вакыты әллә кайчан исбатлап өлгергән...

Ә без уйларга мәҗбүр идек. Менә дошман. Әлегә. Бәлки аны үгетләргә дә мөмкиндер әле, заман чуар, аңлашылып бетмәгән сызыклары әллә ничаклы. Ә үгетләп, өндәп торырга вакыт бирелмәгән. Иң кирәк чагында сүзе дә табыламы аның?!

Безнең хакта сөйләсәгез, дөреслекне кинаясез генә языгыз (кинаяләр ачыклык та кертмәс, төзәтмәс тә!), безне тере дип исәпләгез, үзләрен яклый алырлык тере дип санасагыз, сезнең хәтердә без мәңгегә калырбыз.

Юк, юк, узган гомер — аккан су түгел!

Кулга алынганнардан җавап алулар, шаһитлар белән очраштырулар, яңаларны кулга алулар — болар бер-берсе белән чиратлашып барды. Хәл бераз ачыклана һәм аныклана төште. Атна-ун көн дигәндә, без Казанда әзерләнгән фетнәнең күләмен төгәл чамалый алдык. Җавап алу беркетмәләре, шаһитлар күрсәтүе, кулга алынганнар белән иярә килгән кәгазьләр теркәлеп, калын-калын томнар тегелде, шуларны җентекләп күздән кичереп, фактларны янәшә куеп кына нигезле нәтиҗә ясап була иде.

Төннәр буе укып утырам, йокыга китә башлагач, сап-салкын су белән маңгайны, чигәләрне чылатам...

Без, күпме интегеп, көч түгеп табылган фактлар, ирешелгән нәтиҗәләр сәгате-минуты белән дошманга барып ирешмиме?.. Арада хыянәтче бар ич әле, ул исән-сау, тотылганы юк, эзе дә беленми. Бу факт безне бик нык борчыса да, эшне туктата алмыйбыз, туктатырга мөмкин дә түгел, ярамый да.

Менә Ольгин кәгазьләре арасыннан квартирьерларга бирелгән инструкция, Савинков «Союз»ы разведчикларына күрсәтмәләр һәм аның Казанга килүе турында язмалар килеп чыкты. «Гади, мөмкин кадәр эленке-салынкы киенергә, беркем белән дә сәяси сөйләшүләр алып бармаска, урнашкач та саклык чараларын онытмаска! Бер кергән рольдән чыкмаска: артист икәнсең, артист бул, йөк ташучы икән — йөк ташучы, вак-төяк сәүдәгәр...»

Ольгинга Казанда өч «явка» күрсәтелгән: безгә мәгълүм Винокуров квартирасы, 2 нче тауда Вишневский йортында Төньяк номерлары, Посадский урамында Трифонов йорты. «Монда Кузнецов яши», диелгән. (Фамилия ялган булып чыкты, андый кеше монда юк, ә Төньяк номерларында кемне эзләргә кирәклеге әйтелмәгән).

Казанда Ольгинга штабны урнаштыру буенча егермеләп кеше булышлык итәчәк, һәм алар бергәләп Мәскәүдән килгән бер полк савинковчыларны фатирга урнаштырырга тиешләр. Бусы мәгълүм. Бусы ифрат мөһим. Әгәр килгән бер квартирьер Казанда бер полк дошманны урнаштыра башласа...

Ольгин артыгын дәшми. Карыша. Теше-тырнагы белән чынбарлыкны яшерергә азаплана... Карыйм, укыйм...

Ольгин — чын исеме Василий Александрович Герцек, элекке студент, сугышта поручик. Советка каршы көрәшкә аны шәхсән Савинков тарткан.

Кулга алынган икенче квартирьер Розанов Леонид Иванович, элекке прапорщик, сүзгә юмартрак булып чыкты. Савинков союзына май башында керүен, квартирьер сыйфатында Винокуров квартирасына килеп төшүен әйтте. Ул исә Казанда 500-700 офицерны урнаштырырга тиеш була. Алар Ольгин белән бергәләп Югары Ослан, Үсия тирәләрендә шулкадәр кешелек урыннарны сайлап та өлгергәннәр инде. Беренче төркем — 200 кеше килгән, калганнар турында белми.

Белми, әлегә без дә белмибез.

Квартирьерлар тагын ничәү? Кемнәр? Күпме кешелек урыннар әзерләнгән дә шуларның күпмесе килеп өлгергән? Урамда һәр «эленке-салынкы йөргән» кешене, артист яки вак сәүдәгәрне тотып алып, якасына ябышып булмый ич! Тикшерергә кирәк, әмма тикшереп бетерә алырбызмы? Әгәр бетермәсәк?

Розановның бер сүзе мине аерата сагайтты:

— Винокуровларда квартирада торганда, Мәскәүдән телеграмма алынды. «Варя апа шимбә көнне килеп житә. Товар кабул иткәндә аерата сак булыгыз»,— диелгән иде анда...

Шимбә көнне юлдашларым белән Винокуров квартирасына мин бардым ич! Заговорчылардан килгән хәбәрне Розанов та күргән булып чыкты. Кем ул? Безнең юлны каян, ничек белә алган?

«Товарны сак кабул итү» җәһәтенә килгәндә, арт чүмечем һаман авырта, салкын су белән юганда, мин наган сабы эләккән урынны капшап-капшап карыйм. «Тагын бер-ике миллиметр!..» — диде врач ярамны теккәндә. Дошманнар мине исән калдырырга уйлаганмы, белмим, әнә шул «бер-ике миллиметр» һәм Зоря мине саклап алып калды...

Хыянәтче-провокатор мәсьәләсе һич кетмәгәндә, гап-гади хәл ителде дә куйды. Тик аңа кадәр мондый хәлләр булып узды...

Без Ольженицкий белән хыянәтчене тоту турында катлаулы план әзерләп маташканда, Мәскәүдән фельдегерь килеп төште. Ул безгә Мәскәүдә кулга алынган һәм Казан «филиалы» белән бәйләнеш тоткан «Союз» членнарының сорау алу кәгазьләрен һәм Петерсның приказын китереп тапшырды. Безгә генерал-майор Поповны, Никитинаны һәм Ольгин белән Розановны тизлек белән Лубянкага озатырга боерылган иде... Приказның бер юлы мине сагайтты... «Югарыда саналган тоткыннарны Владимиров озата кайтсын»,— дигән боерык нык кына сәерсендерде...

Алар юлда булсын, ә мин Мәскәүдән килгән беркетмәләрне йотылып укый башладым. Менә латыш укчы полкының элекке командиры Фридрих Бредисның кәгазьләре. Үзен «милләтче һәм Германиянең кан дошманы» дип атарга яраткан утыз яшьлек бу полковник Савинков «Союзы»нда разведка һәм контрразведканы җитәкләгән. Асылкош! Тыңлагыз әле, тыңлагыз! Латыш полковнигы Гоппер, капитан Пинку һәм Бредис унсигезенче елның маенда Савинков белән очрашалар, җыйнаулашып полковник Перхуров һәм генерал Рычков янына баралар, шунда булачак контрреволюцион оешманың төп асылын билгелиләр. Шул вакытта ук Бредис «Союз»га керүче офицерларны кыл иләктән үткәрә. Ирешкән хәбәрләргә ышанмыйча, Идел буе шәһәрләрендә — «Союз»ның филиалларында инспекция уздыра. Хәзер иң әһәмиятлесе: «Май башында Казанга килеп Биржа гостиницасында биш көн яшәдем»,— дип күрсәтә Бредис.

Рәхмәт Петерска! Ифрат кыйммәтле кәгазьләр җибәргән! Дөрес, Бредис Казанда ни эшләвен дә, кемнәр белән очрашуын да әйтмәгән. «Әйтмәсә дә максаты көн кебек ачык!» — дип уйладым мин. Савинков хезмәтчесе буларак, ул аның максатларын тормышка ашырган, димәк, шәһәр шартларын ачыклаган, кадрларны тикшергән һәм «Союз» җитәкчелеге Казанга күчеп килсә ни хәлдә калачагын белергә тырышкан. Казан гарнизонының саны, көче, иманы турында кайгырткан, фетнә купкан очракта гарнизон кем ягына авар? Шушы сорауларга ул монда ашыгыч җавап эзләгән булырга тиеш.

Сорауларга җавап бирерлек хәбәрдар кешеләр белән очрашмый калмагандыр Бредис. Гәрчә без күпме тикшерү алып барсак та бер авыздан да аның исемен ишетмәдек, беркем дә моңарчы аны телгә алмады. Сорашсак: «Андый офицер белән хезмәт итмәдем, белмим»,— диган җавап кына ишеттек. Бредис, мөгаен, Казанга башка исем белән килгәндер? Мәскәү кәгазьләренә аның берничә фотосы ябыштырылган иде.

Иш ишен эзли, таба да. Чекист, юл төшеп, чит шәһәргә юлыкса, иң әлек иптәше — чекистны очратырга ашыга. Бредисның Казан хәрби округының контрразведка офицерлары белән очрашу ихтималы бармы? Бар! Хәзер Казанда округ юк, губерна Идел буе хәрби округы карамагына тапшырылган, әмма аның учреждениеләре калган ич, шул килеш сакланган диярлек! Контрразведкасы да исән-имин, исеме генә башка — Хәрби контроль дип йөртелә ул хәзер.

Белештем, анда үз эшләрен шактый яхшы белгән, шпионнарны тотып алырга остарган тәҗрибәле офицерлар эшли. Ул чагында Казанга Көнбатыштан төрле сәяси партияләргә кереп-чыгып буталып йөргән әллә никадәр этрәк-әләм килеп тулган иде. Төрле илләрдән үтеп кергән шпионнар да мыж иде. Яшь Совет республикасына һәр тармакта белгеч-кадрлар бик кирәк. Апрель аенда чека Хәрби контрольне үз карамагына алды, әмма элекке кадрларны эшендә калдырды. Алафузов заводыннан килеп кенә кергән егет-кызларны чит ил шпионнары белән көрәшкә чыгарырдан элек, аларны әзерләргә кирәк иде әле...

Республикада Көнчыгыш фронт барлыкка килеп, аның штабы Казанда урнашу белән үк, армия һәм кыр контрразведкасы оешты. Әлегә бу эш яңа тернәкләнеп маташа, кадрлар җитми, ничә карасаң да җаваплылык Хәрби контрольгә кайтып кала иде. Ә анда әлеге дә баягы элекке офицерлар утыра! Күпчелеге «Фронтовиклар союзы» әгъзасы. Ә анда, балга җыелган шөпшәләр кебек, контра кереп тулган...

Ышанычлы кешегә Бредисның фотосын күрсәтеп, аның Казанда кемнәр белән очрашуын белергә кирәк иде. Тагын Ольконицкий янына кердем.

— Хәрби контрольдә ачыктан-ачык сөйләшерлек кешебез бармы?

— Нигә булмасын? — дип көлемсерәде Григорий.— Әгәр без аны эшләмәсәк инде...

— Кем ул?

— Всеволод Аристов белән Хәбибулла Вәлиуллин. Икесе дә — революциягә кадәр үк большевиклар. Аңлы, зирәк, сыналган иптәшләр. Офицерларга күз-колак та булып торалар, катлаулы эшкә дә өйрәнәләр.

Очраштык. Хәбибулла Вәлиуллин зур борынлы, киңчәрәк битле, эре сөякле кеше икән. Зур йодрыгын өстәлгә суккалап сөйләп бирде:

— Эш авыр! Сарык тиресе ябынган бүреләр эшкә гел үз ишләрен тарталар, совет властена аяк чалырга гына торалар. Германия белән Брест солыхы төзелгәннән соң большевикларга тагын да ныграк үчегәләр...

— Шпионнарны оста тоталар,— дип, сүзгә ялганды Аристов.— Немец шпионнарына худ бирмиләр. Чехословаклар Советка каршы күтәрелгәч, чех шпионнары артты. Әлерәк кенә дары заводын шартлатырга маташкан бер өерне тотып кайттылар. Чехлар файдасына шпионлык иткән кешеләрдән унсигез пулемет, мең ярым мылтык, йөз меңнән артыграк патрон табып алдык...

Хәбәрләр, хәбәрләр, хәбәрләр...

Казан, чыннан да, ак дошманнарның эре бер үзәгенә әйләнеп бара!

Савинковчылар, Попов иярченнәре, шулар өстенә хәзер ак чехословаклар...

Аристов та, Вәлиуллин да Бредисны таныдылар, алар аны Хәрби контроль начальнигы сул эсер Файерман, элекке офицерлардан Величко һәм Дугин янәшәсендә күргәннәр. (Молодцы, егетләр!) Сүз ни хакында баргандыр, анысын икесе дә белмиләр. (Һм, бусы кызганыч!)

Мин Аристов белән Вәлиуллин атаган кешеләрнең тормышы, танышлары турында белешеп торырга, күбрәк кызыксынырга тәкъдим иттем.

Озак та үтмәде, минем янга, кабаланып, Вәлиуллин килеп керде. Ул үзе югында, Дугинның өстәл тартмасын ачкан, аннан яшерен тартма тапкан. Тартмада бер төргәк өндәмә! «Эшче-крестьяннарга» адресланган өндәмәгә... «Ватанны һәм ирекне саклау союзы» дип кул куелган.

Өндәмәдә Керенский заманында ук телгә кергән бик әшәке ялган кабатлана иде: «Большевиклар — немец шпионнары!»

Ак чехлар кузгалышын алар болай аңлаткан иде:

«Халык комиссарлары советы үзенең хыянәтчел сәясәтен дәвам итеп, граф Мирбахның боерыгын үтәп, көнбатышка — немецлар белән көрәшкә барырга чыккан алтмыш мең кешелек чехословак корпусын баш күтәрергә мәҗбүр итте. Граф Мирбах чехларны коралсызландырырга боерды, Халык Комиссарлары Советы аңа буйсынды».

Өндәмә дәһшәтле сүзләр белән тәмамлана иде:

Барыгыз да коралланыгыз! Бетсен Халык Комиссарлары советы! Аларны себереп ыргытып кына без икмәк һәм ирек алачакбыз! Яшәсен Россиядә бердәмлек һәм тәртип! Яшәсен туачак Учредительное собрание! Яшәсен хөр бөек Ватан!»

— Ничек сайрарга керешкәннәр болар! — дидем мин Вәлиуллинга.— Дугинны бер минут кичекмәстән кулга алырга!

Дугинны таба алмадылар... Ул качып өлгергән, кемдер аңа безнең киләсен белдергән иде. Көл савытында янып бетмәгән папиросы ята.

Кем, кем?!

Казан шәһәре мисалында без бик күп нәрсәләрне ачыклый алдык: контрреволюциянең илдә ифрат киң җәелгәнлеге һичшиксез дөрес иде. Аның вәкилләре совет органнарына кереп оялыйлар, хәрби оешмаларга үтеп керәләр, хәтта чекистлар арасында да посып яшиләр. Болай уйларга безнең тулы хакыбыз бар иде. Ераз алгарак китеп булса да генерал Поповның, Ольгин белән Розановның атылуын әйтеп узыйм. Аларның гаепләре искиткеч зур һәм күп санлы дәлилләр белән ныгытылган иде.

Алардан да алда минем юлдашым Владимиров үзен-үзе атып үтерде...

Олькеницкий белән без: «Владимиров — хыянәтче һәм провокатор!» — дигән ныклы фикергә килгәндә, аны ашыгыч кына Мәскәүгә чакыртып алдылар һәм аның чуар язмышының азагы шунда тәмамланды...

Провокаторлар һәм хыянәтчеләр каян туалар? Бу сорауга бер төсле генә җавап биреп булмый. Тауга һәркем бер юлдан менсә дә, төшкәндә һәркем үз юлын, кыскарак юлны сайлый. Бер нәрсә ачык: хәтта рухи ихтыяҗларга нигезләнгән провокаторлыкны да аклап булмый!

Владимиров мисалына кайтыйк. Чын исеме Штримпфлер Карл, туганда ук провокатор булган. Баеп киткән руслашкан немец гаиләсендә дөньяга килеп, кадетлар корпусында чакта ук әләккә, гайбәткә, астан сүз йөртергә маһир булуы тиешле даирәләргә бик тиз барып җитә. Андыйларны бик тиз күрәләр дә «карандашка алалар»!.. Вакыты җиткәч «тиешле даирәләр» аны эшкә дәшәләр, жандарм корпусында хезмәт итсә дә, ул мундир кими, кемлеген беркемгә күрсәтми...

Шомакай, житез, төчекәй һәм һәрвакыт аек акыллы Карл студентлар, интеллигентлар арасына балавызга кергән инә кебек кенә үтеп керә, ышаныч яулап, аларны сүз ачыклыгына котырта, сүз алырга ирешә. Соңыннан бу тирәдә кулга алулар башлана! Штримпфлер ул арада икенче бер шәһәргә ычкынып өлгерә. Анда да шул ук хәл кабатлана.

Табигате белән тәмам азынган, бозылган Карл охранкага хезмәт итүе белән генә әрсез күңелен тәкәндерә алмый! Ул ике якка, озакламыйча өченче якка да теләсә кемне сата башлый. Жандармнарга эсерлар планын ирештерсә, эсерларга жандармнар планын илтеп сата

Социал-демократлар арасына елышып, боларның икесен дә аларга сата башлый...

Дзержинскийның урынбасары Петр Алексеевич Александрович, революциягә чаклы «Дмитриевский» яки «Пьер Ораж» исемнәре белән атаклы эсер, Штримпфлерны жандарм буларак белә, Карл аны һәм якыннарын бер моментта куркынычтан коткарып калган була. Бармагыңны бирсәң — кулыңнан коры калырсың. Александрович мондый гыйбрәтне исеннән чыгара, Карлны бер белеп алгач, аңа еш мөрәҗәгать итә, файда да күрә.

1918 елның гыйнварында сул эсерлар Совет хөкүмәте составына кереләр, аларның вәкилләре күп санлы совет учрежденияләренә урнашты. ВЧКның Коллегия әгъзалары Михаил Емельянов, Владимир Волков, Петр Сидоров сул эсерлар иде. Сул эсер Александрович ВЧК председателе Дзержинскийның беренче урынбасары булып алгач ук... Карлны хәтеренә төшерә. Ә аны эзләп торасы да юк, шунда ул, аяк арасында урала, дәшүгә, үрмәләп килеп тә житә. Ул чекада хезмәт итә башлый һәм шушы хезмәтенең тагын кемнәргә кирәк булуы турында көн-төн баш вата. Элекке танышларыннан берәү аны Бредис белән очраштыра. Һәм чека хезмәткәре, Владимиров фамилияле немец Штримпфлер уң эсерларга, монархистларга һәм башка төрдәге совет дошманнарына тез чүгә-чүгә хезмәт күрсәтә башлый.

Бредис ахмак түгел, үзе разведчик, ул Дзержинскийның кемлеген аңлап өлгергән, үз тормышын саклап калу нияте белән яраннарын уңнан-сулдан атый башлый, арада Владимировның да фамилиясе калкып чыга... Бу эш белән Александрович үзе шөгыльләнә, жандарм идарәсендә сакланган документларга юлыга. Карлның ничә якка койрык болгавын ачыклагач, Владимировны ашыгыч рәвештә Казаннан Мәскәүгә чакырта. Казанда да аның эзенә төшү ихтималы барын ул бик дөрес чамалый!

Кайткан көнне үк кичен Владимиров камерасына керә, пистолетын суза да:

— Менә корал. Нишләргә икәнен әйтмим. Югыйсә иртәгә сине хурлыклы рәвештә атачаклар! — ди.

Владимиров — вак җан, тырнаклары белән таш идәнне тырнап еларга тотына, ялына, ялвара.

Иртән кереп карасалар, гәүдәсе әллә кайчан суынып беткән...

Әйткәнемчә, хыянәтнең төп табигатен аңлату кыен. Күп тә вакыт узмады, революциягә хыянәте, сул эсерларның советка каршы фетнәсенә актив катнашканы өчен июль башларында Александровичны да аттылар. Бу уңай белән Дзержинскийга шаһит сыйфатында чыгыш ясарга да туры килде. Соңыннан ул болай дип язды:

«Александровичка тулаем ышана идем. Комиссиядә без бергә эшләдек, мин аның икейөзлеләнгәнен күрмәдем. Һәр очракта да ул минем белән килешеп эшләде... Гәрчә мин хәзер дә аның аңлы рәвештә хыянәтче булуын уема да китерә алмыйм... Әлбәттә, дәлилләр ышанычлы, һәм бу хакта ике фикернең булуы мөмкин түгел!»

Хөкүмәт белдерүендә Александровичның хыянәтчел эшләре атаклы провокатор Азеф эшчәнлеге белән бер дәрәҗәгә куелды...

Болар да минем өчен соңрак ачыкланды. Ул чакта телеграф бер җөмлә генә ирештерде: «Владимиров — хыянәтче».

Без — Олькеницкий, мин һәм Заковский — өчәүләшеп җиңел сулап куйдык һәм бер-беребезгә карадык...

— Бер Владимиров кына микән безнең үз арабызда йөргән дошман? — дип куйды Леонид. Аның бу сүзләре тагын да ныграк уйландырды.

Казанга килеп төшүемә ничә көн генә әле. Нинди кыска ара, ә шул көннәрдә кичергәннәрне, очрашкан кешеләрне, тикшергән документларны күз алдыннан уздыра башласаң, хәйран калырлык. Сажидә апаның

Гайнулланың ерак кардәше икәнен бүген генә белдем. Гап-гади йомыш белән ашыгып кына өемә кайтсам, түремдә тирләп-пешеп чәй эчеп Гайнулла утыра... Ашыга! Баш кагып кына сәлам бирдем дә, берни белмәгән кешe сыман, тиз генә чыгып та киттем. Димәк, Сажидә апа минем кем булуымны белә? Әллә белмиме? Аның Гайнулланың кардәше булуы кәефемне күтәреп җибәрде: бер яктан минем яшәешем тыныч, йорт хуҗам ышанычлы кеше...

Бүген, бөтенесен онытып торып, Арча кырына Зоряның каберенә барып кайтырга кирәк. Зоряның кайда күмелүен дә Гайнулла ачыклаган иде.

Июнь башы. Җылы кич. Батып барган кояшны беренче тапкыр күрәм ахрысы. Урамнардан төрле яктан искән җил арганлыгымны үзе белән ияртеп алып китә кебек. Ешрак буласым килсә дә, зиратка сирәк барам, барган саен Зоряның я әти-әнисен, я туганнарыннан берәрсен очратмый калмыйм. Кызларының кем аркасында һәлак булуын алар бик яхшы беләләр, шул сәбәпле минем белән очрашканда тагын да кырысланыбрак, сагышланыбрак калалар. Нишлисең, житкән кызлары кара кабердә ята, ә мин исән, теп-тере килеш алар каршысында басып торам... Аларга да уңайсыз, миңа да читен. Бармый да ярамый, барасым, үз гомере бәрабәренә мине саклап калган серле кызга хөрмәтемне җиткерәсем килә...

Урамда атлылар очрый, чыңгылдап трамвай узып китә. Мин җәяү генә барам, алым да, ялым да шул. Җәяү барганда, уйлар читкә китми, уйлар Зоряга гына барып ялганалар...

Арча кыры. Шәһәрнең чите. Моннан торып халкы йөз мең кешедән ашып киткән Казанны тулысы белән күз алдына китереп була. Зират капкасы төбендәге хәерчеләрне тиз-тиз узып китәм.

Бүген кабер янында Зоряның әнисе белән сеңлесен очраттым. Әнисе, кич җылы булса да, кара шәл ябынган. Сеңлесе — унбиш-уналтыга җитеп килә торган сөйкемле генә кыз икән. Элек, Мәскәүдә чагында, мин аны чак кына тазарак бәдәнле, оялчан гына бала дип белә идем, хәзер ул буйга тартылган, беренче күрүемдә иманеп киттем: Зоряга шул кадәр охшаса да охшар икән! Әнисе, мин килеп, кабер өстенә чәчәкләремне куюга, шәле белән ярты йөзен каплап, кызын бер читкәрәк тартты, әмма кыз (ул да мине Казанда беренче мәртәбә күрә ич!), кызыксыныпмы, китәргә ашыкмады... Алар, аналы-кызлы, зират таләпләре рөхсәт иткәнчә генә бераз эрепләшеп тә алдылар.

Басып торам. Зиратта гына була торган, башка бер җирдә дә очрамаган тынлык. Кешеләр монда җан авазы белән, сүзсез сөйләшәләр. Тик мин Зоряның әнисе ни әйткәннәрне ишетмим... Сеңлесе минем хакта ни уйлый икән — белмим. Бу билгесезлек мине борчый, җанымны талый, гаеплеме мин алар алдында, түгелме — моны мин дә, башка берәү дә ачыклый алачак түгел иде.

Тынлык. Тынлык сагындыра бу араларда... Тик бу тынлыкта йөрәгеңнең тибешен, вакытның мыштым гына агуын, яшәүнең мәгънәсен яки мәгънәсезлеген ачыграк тоясың...

Зоряның үлеме шушы якты көннәр бәрабәренә булса да акланамы соң? «Сабыйларның бер тамчы күз яше өчен бөтен дөньяны бирергә була һәм кирәк тә!» — дип раслаган Достоевский хаклыдыр бәлки? Тик үзе үк «Үсеп барган һәр күзәнәк эчендә, кагыйдә буларак, чиксезчамасыз җимерү инстинкты да яшеренеп ята!» — дип тә раслаган түгелме? Моны ничек аңларга? Ничек кабул итәргә? Без үзебезне укымышлы, алга киткән кешеләр дип исәплибез, тормышны яңача төзергә омтылабыз. Ә дөньяда дошманлык, нәфрәт, үтереш-кырылыш кимиме соң? Зоряның үлеменнән соң кимедеме? Яки ни булса да яхшырдымы? Яктырдымы?..

Ә мин? Мин — киләчәккә омтыла торган бер яшь кеше. Минем җаныма гына булса да тәэсир итмәдемени аның вакытсыз үлеме? Шушы

тынлыкта мин, бүгенге белән саубуллашканда, аның исемен гомергә яхшылык белән искә алырга хәтеремә беркетеп куймадыммыни?..

Йөрәгем өзгәләнә, агач арасыннан тын гына узып киткән кешеләр дә, тонык май күгендә ялтырый башлаган ай урагы да мине бүлдерә алмый. Минем уйларым киләчәккә нәкъ менә Зоря белән бергә, җитәкләшеп, дуслашып агылалар... Мин алга таба бары тик аның белән барам.

Исемә килеп, башымны күтәрсәм, кояш күптән баеган, Зоряның әнисе дә, сеңлесе дә монда юк, мин китергән чәчәкләр генә көндезге кебек үк хуш ис таратып яталар.

«Хуш, Зоря!»

Аның белән баш кагып саубуллаштым да капкага атладым, озын чикмән кигән зират каравылчысы капканы бикләп маташа иде инде. Капка төбендә мине Зоряның әнисе белән сеңлесе көтеп торалар икән. Әнисе Таняны (кызның исеме шунда гына хәтеремә төште!) алып китәргә теләгән, кыз тартыла һәм һичшиксез мине көтә иде. Шул чагында әнисе, кызны куеп торып, миңа каршы китте һәм яшьле күзләрен миңа төбәп:

— Сез һәлак иттегез аны, сез! — дип кабатлады.

— Әни! — дип инәлде Таня.

— Дөрес түгелме әллә? — диде ана, яшьле күзләрен яшермичә.

— Кем уйлаган бит,— дидем мин, ни әйтергә белми аптырап.

— Сез генә гаепле! — дип кабатлады ана.

Таня, үпкәләп, аны читкәрәк тартты, мин, китәргә дә яхшысынмыйча, калырга базмыйча, аларга якынрак килдем.

— Зоря шикле кешеләр белән аралаша башлагач, нигә аны тыймадыгыз? — дип кинәт кабынды Таня.— Винокуров йомышын үтәп, шәһәр буенча чаба башлаганда, нигә аны туктатмадыгыз?

Гаилә сере чәчелеп таралганда, иң яхшысы китеп бару иде дә бит, мине нидер тота, Зоря хакында күбрәк беләсем килә... Менә бит: Таня апасының шөбһәле юлга тап булганын да, юлның азагы яхшы түгеллеген дә белеп яшәгән ләбаса! Иртә өлгергән кыз, иртә. Әллә бик иртә түгелме? Заманы шундый бит, тиз ага, гомерне, яшәүне ашыктыра, Таня да зирәк кыз булса кирәк, барын да күреп, белеп һәм борчылып яшәгәндер. Минем ул кыз янынннан тиз генә аерылып китәсем килми, без өчәүләшеп акрын гына караңгы урам буйлап барабыз. Әллә каян гына чыккан болытлар көнбатышны, кичке шәфәкъне каплыдылар, кайдадыр еракта атыш тавышлары яңгырады. Бу тавыш миңа кыюлык бирде:

— Мин сезне озата барам,— дидем.

Караңгыда да абайладым: Таня сөенде, әнисе бер сүз дә дәшмәде. Бара-бара, Таня тагын миңа эндәште:

— Сез нигә безгә кергәләп йөрмисез, Сергей Сергеевич? — диде.— Кергәләгез.

— Уңайсыз,— дидем мин.— Хәсрәтне искә төшереп, җәрәхәтне яңартып йөрисем килми.

— Сез кермәде дип, аның язмышы үзгәрмәс, Зоря терелеп кайтмас,— диде ныклык белән Таня.— Әти һаман: «Ул харап итте!» — дип кабатлый. Ә мин каршы төшәм... Әлегә миңа! Ә сез читләшәсез. Керегез, әти белән дә сөйләшегез. Зоря сезне якын итә иде.

Әнисе шелтә тавышы белән:

— Күп сөйләшәсең,— дип куйды.

— Күп сөйләшәм икән, күп уйлыйм да! — диде Таня. Бусы инде олыларча иде.

— Яхшы. Әгәр дә шулай икән, иртәгә үк керергә тырышырмын.

Әтисе һаман миңа бик нык рәнҗи икән... Димәк, шул ук кичтә керергә кирәк иде. Бүген үк! Тик бүген кич капитан Нефедовтан сорау алу билгеләнгән. Капитанны Гайнулла Таһировка тапшырган идек, бүген иртән, ул бик уңайсызланып кына:

— Авыр аның белән көрәшү, Сергей Сергеевич! — диде.— Сизәм: әллә ниләр белә, ә тартып алуы кыен! Гел әйләндереп-тулгандырып йөртә, бутый, уйны чуалта.

Егеткә ярдәм итәргә кирәк иде...

Очрашу үтә җитди булыр дип күңелем сизә, ашкына, ярсый. Никадәр ярсып ашкынсам да, Зоря кабере янында әнисен һәм сеңлесен очрату кич буе күңелемнән китмәде. Чынлап караганда, аның вафатында өлешчә минем гаебем дә бар ич! Юк, хәзергесен, Винокуров квартирасында очрашуыбызны гына әйтмим, элеграк, Мәскәүдә, әле ул сабыйлыктан чыгып барган дәвердә, без еш-еш һәм бик теләп, сагынышып диярлек күрешә идек. Есенин шигырьләрен укый идем мин аңа, яраткан шагыйремнең җан авазына үзем язган юлларны да кушып җибәрә идем. Музейларда була идек, концертларда; мин аңа тормыш турында югары пафос белән, гашыйкларча, аллы-гөлле, чуклы-чачаклы итеп сөйли торган идем. Аның төпсез күзләренең комсызланып, комарланып, яшәргә очып-омтылып янганын шул чакларда нигә күрмәгәнмен икән? Әллә үзем белән артык мавыгып китеп, аңа күзем җитеп бетмәдеме?.. Күзгә күренгән офык артында сихри офыклар, әкиятләр дөньясы бар дип беренче тапкыр мин ышандырмадыммы ул сизгер җанны?!

Үзеңне гаепле итеп сизгәндә, зәһәр, тәҗрибәле дошман белән очрашу файдасыз, миңа бераз тынычланырга, уйларны читкә куеп, аңны ачыкларга кирәк иде...

Нефедовны яныма соң гына китерделәр. Подвалдан, дошманнарның хәтәре, усалы утыра торган урыннан.

Керде. Утырды. Чыраенда ник бер бөртек курку-каушау булсын!

— Беләм,— дип башлады ул сүзен, тиешле протокол кагыйдәләрен үтәгәннән соң,— сезне шәһри Казандагы идән асты оешмаларының эшчәнлеге кызыксындыра.

— Үтә нык кызыксындыра,— дидем мин.

— Безне контрреволюционерлар дип яманлыйсыз инде?

— Ә сез үзегезне кем дип атар идегез?

— Без бу исемне икебез ике мәгънәдә кулланабыз,— диде ул сүзен өстен чыгарырга тырышкан көр тавыш белән.

— Сез безне шулай атыйсыз, ә без сезне!

— Без ни өчен андый исемгә лаек булдык инде?

— Сез халык сайлап куйган Учредительное собраниене куып тараттыгыз. Властьны тартып алдыгыз! Кем контрреволюционердыр, әлегә билгесез, без — үзенчә яшәргә теләгәннәргә ирек бирүче, ә сез дөньяны марксизм кысасына кертеп буарга әзерләнәсез!

Хаклы Гайнулла Таһиров, Нефедов сүзгә саран түгел, сүзләр белән ифрат оста уйный!

— Дәвам итегез,— дидем, Нефедов тукталып, текәлеп миңа карагач. Әгәр бүген мин Зоряның баш очында тормаган булсам, бүген генә яшәү һәм үлем турында зират туфрагына басып уйланмасам, мөгаен, эшне кызурак тотар идем. Гади эшче егет, намуслы һәм саф күңелле Гайнулла Таһировның үчен алырга да тырышыр идем! Гайнулла әйтеп бетермәсә дә, Нефедовның аны кимсетергә маташуы миңа ачык иде... Ләкин мин бүген ашыкмадым. Сабыр гына, үз алдыма уйланып сүземне дәвам иттем.— Сез безнең киләчәкне тоташ өметсезлектә күрәсез. Борынгылар әйтеп калдырган, «ике якны да тыңлап бетер», һәркемнең бәясе — үзе яклаган эше микъдарында.

— Иманымны аңлавыгызны гына телим,— диде Нефедов төкселәнеп.

— Иманыгыз ачык! — дидем сүз агышын үз кулыма алып.— Сез инде, әлбәттә, февраль революциясендә туган, ә мин — октябрь баласы. Әле бу — февраль октябрьдән өстен диган сүз түгел!

— Күрәм, сез укымышлы кеше.— Ул, тукталып, нидер уйлады.— Аңлы кешенең очтагы бер алма өчен алмагачны кисеп аударуын кабул

итүе кыен. Сез, тормышка ашмас буш хыялларга батып, дөньяны кан белән тутыруыгызны сизәсезме, юкмы?! Ышанам, сез мине бетерәчәксез. Бүгенгә көч сездә! Максатыгызның дәвамын һәм азагын аңлап кына бетермим: ни өчен тырышасыз?

— Ә сез? — дип кискен бүлдердем мин аны.— Без яңа дөнья төзибез. Хуҗалары эшче-крестьян булачак дөнья. Матур дөнья. Комачауламагыз безгә, барыр юлда янәшә басыгыз. Бергә барсак, сезне юк итү турында беркем дә уйлап карамас. Корбаннар хаҗәтме безгә?

— Бөтен аңлы җиһан ябырылып, сезгә каршы чыкканда, нишләп мин сезгә тагылырга тиеш соң?

— Ияregez. Безнең юлыбыз якты, һәркемгә ачык. Без яшертен яшәмибез. Иң гади, крестьян да аңларлык.

Ул бер минутка гына тынып алды.

— Сез эшче-крестьян дәүләте төзисез. Ә мин — нәселдән килгән дворян, интеллигент. Сезнең дәүләттә миңа урын бармы? Әллә кичә генә безнең аяк астында йөргәннәргә хезмәт итәргә кушар идегезме? Сез безне «вакытлы» дип атадыгыз. Ә үзегез?! Бер нәрсәне онытмагыз берүк: без шундый илдә яшибез ки, шундый халык арасында, шау-шулар чоры гына үтсен, ун-унбиш елдан патшасыз, юлбашчысыз, әйдәп баручы алласыз барыбер көн күрә алмассыз... Әллә ул затны патшадан да әйбәтрәк, мәрхәмәтле булыр дип өметләнәсезме? Юкка!

Юк-бар сөйләп, вакытын алган Нефедовны туктатасым да килә, тыңлавы да кызык, бу кадәр ачыктан-ачык сөйләнгән офицерны очратканым юк иде әле, Нефедов дошманлыгын яшермәү генә түгел, аны нигезли, дәлилләр таба, ышандырырга тырыша.

— Сезнең сүз ташкынын буар өчен сыңар сүз җитә! — дидем мин кинәт ярсып.— Әллә һәр фикерегезне аерым-аерым ватып-җимереп ташлыйммы? Сез, шома сүзләргә сокланып, үз-үзегезне генә тыңларга өйрәнгәнгә охшыйсыз! Миңа сезнең максатны аңлау кыен: хаклы булуыгызны исбатлап, мине үзегезгә теләктәш итәргә җыенмыйсыздыр ич?

— Юк инде,— диде явыз елмаеп Нефедов.— Әйтеп кенә бетерим. Мин университет узган, сугышны күргән, ул да бер югары мәктәп, сезнең Маркс белән Ленинны җитәрлек укыган, мин сезнең белән бер рәттә була алмыйм. Үзем иярер тә, сезне тагып та...

Телефон шалтырады. Таһировны сорадылар. Фәридә тавышы булды ахрысы. «Юк»,— дип җавап бирдем дә Нефедовка текәлеп карадым. Киң маңгай, матур бөтерелгән борын яфраклары кыймыл-кыймыл килә, йөз бераз саргайган, сөрмәле күзләренең агындагы тамырлар ачык беленә башлаган. Нигә шулай озак утырам мин бу карачкы белән? Турыдан-туры аңлашуга күчәргә вакыт түгелме?!. Тукта, ул китә торган кеше, югала торган сыйныф вәкиле, аңлы, әзерлекле вәкиле, аның җанын белгән уйларны белеп калыйк.

Аның чибәр, солтанатлы йөзенә яшерен явызлык тантанасы чыкты, ул үзен безнең барыбыздан да, безнең юлбашчыларыбыздан да, без иманган иманнан да өстен саный иде булса кирәк.

— Сез бүгенгә — власть, ләкин тормыш дилбегәсен кулыгызга мәңгегә алдык дип ирәймәгез. Без дә канлы көрәшкә чыгуыбызның сәбәбен һәм максатын ачык белә иде. Сез миңа якты һәм якын киләчәк өчен көрәшәбез дисез. Укыдым мин рухи аллаларыгызны! Алар үзләрен материалист дип саный, әмма минем алардан да идеалистрак затларны очратканым юк иде. Әллә кайдагы оҗмах өчен кеше һаман интегергә, газапланырга риза булырмы? Бусын Гайсә пәйгамбәрдән «чәлдергәннәр». Хак тормыш белән буйсынып яшәгәннәргә ул да оҗмах вәгъдә итә. Ә сез?! «Бер-берсенә бүре» булып ерак гасырлардан килгән кешеләрнең кайчан исә бертуганнарча, бер-берсен хөрмәт итеп, тигезлектә яши алуларына ышанасызмы?... Бер-берсен тураган грузин белән әрмән туганлашырмы? Хәзер сез Россиянең каймагын — дворяннарны бетерәсез. Ә чиратта кем? Тигезлек вәгъдә итеп, сез тигезсезлектән тотынды-

гыз. Сезгә ышанмаган, сезнең планнарга шикләнгәннәрне юлдан алып ыргытасыз. Алдагы көндә дә сезгә ышанмаучылар табылыр. Аларны тәрбия итә алырбыз дип өметләнәсезме? Көч белән куркытып урнаштырылган хакыйкать чын була алмый. Сез шулай көчләп корган тормыш берзаман эчтән таркала башлар. Ул чакта сез аптырап, югалып калачаксыз. Тигезлек дисез, ә үзегез кешеләрне ничек кенә аерасыз әле! Мал-мөлкәтенә, милләтенә, ата-анасының кем булуына карап аерасыз. Тигезлекме бу? Ата-ананы сайламыйлар...

Олысымаклыгын онытып, шашып-кызып киткән капитанны көч-хәл белән туктаттым:

— Сез киләчәккә күзегезне чытырдатып йомып карыйсыз. Йомык күз алдында кара ноктлар, ямьсез шәүләләр генә уйный. Мин сезне аңладым, житәр. Күптән түгел генә капитан Богданов белән аңлаштык. Ул агач маңгайлы явыз дошман, әй! Ә сез аңа караганда йөз тапкыр куркынычрак, сез — рухи дошман. Акыллы дошман. Бездә Маяковский дигән шәп бер шагыйрь бар.— Киеренкелегемне аз гына йомшартыр өчен шагыйрьнең заманга багышланган бер шигырен укыдым.

Революция царя лишит царева званья.
Революция на булочную бросит голод толп.
Но тебе какое дать названье,
Вся Россия, смерчем скрученная в столб?

Менә шулай. Безне кем дип атарга? Без икебез дә россияннар, бер чор кешеләре. Әмма шундый капма-каршы якка бастык ки, сезнең тарафдарыгыз, көрәштәшегез, бер гаепсез кызны, яшьлек дустымны атып үтерә. Ике дә уйлап тормый! Ә сез иске заманны, әнә шундый кансыз башкисәрләр үстергән заманны сагынып, купшы сүзләр аттырасыз. Сез бүгенгене аңламыйсыз, капитан Нефедов, киләчәкне фараз кылып, тирәнтен хаталанасыз. Киләчәктә дә акыллы кешеләр булыр, алар үз проблемаларын үзләренчә хәл кыла алыр. Бүгенгенең алдынгы идеяләре җиңәчәк, мин шуның өчен көрәшәм. Учредительное собраниене телгә алдыгыз. Җөмләдән, ул совет хөкүмәтенең ризалыгы белән җыелды. Ул чакта ук Советлар — халык властеның камил формасы булачак — күпчелек исеменнән хөкем йөртә иде. Учредительное собрание ялгыш старт алды, советларга каршы китте, аның өндәмәләре, сезнең ишләрне җылытып, тарихны артка сөйрәргә көчәнде. Халыкның күпчелеге советлар ягында, сез моны беләсез! Инде тигезлек идеяләренә күз салсак, бүгенгә безнең сафларда меңнәрчә дворяннар, интеллигент вәкилләре дә эшли. Хәзер, бу теоретик бәхәсне туктатып, эшкә күчик. «Союз»га кайчан кердегез дә аның Казандагы эшчәнлеге, әгъзалары турында ниләр беләсез?

— Боевиклар группасында идем. Бурычым бер — сезнең кебекләрне теге дөньяга озату.

— Богдановның сыңары икәнсез!

— Кем ни булдыра ала инде!

— Сердобольский кайда? Михайлов? Полковник Сужко турында ни әйтә аласыз?

— Бу сорауларның берсенә дә җавап бирмим. Мин офицер.

— Тез асты йомшакмы?

— Әйе, минем куллан килми торган эшләр дә бар.

— Туры сорауга җаваптан тайчанасыз инде алайса?

— Дөп-дөрес аңладыгыз...

Конвой чакырып Нефедовны одиночкага озатканда, аны ныграк сакларга боердым...

Алда сөйләнәчәк вакыйгага минем катнашым була алмады... Ишеткән-белгәннәремне һәм шулай булу мөмкинлеген сөйлим...

Ольскеницкийга шалтыраттым:

— Юлдан язган Винокуровны ник чыгарып җибәрдегез?

Бу сорауны бүген миңа Гайнулла Таһиров биргән иде. Гаҗәпләнүеннән күзләрен шар итеп, минем янга атылып керде дә тавышы-өне бетеп:

— Винокуровны ирекка чыгарып җибәргәннәр! — диде...

Аерым камераның ни икәнен анда утырган кеше генә аңлый.

Анда уйландыра.

Уй сине көчли, хәтер газаплый, көне-төне үкенечләр дәрьясында агасың. Камерада «уй да мин», башка беркем юк. Стеналар нык, тәрәзә тар гына, ул да түшәм астында диярлек, биектә. Җитмәсә ишегалды ягыннан аны агач тартма белән томалап куйганнар. Ишек катында өстә йөргән сакчының аяк тавышлары да төнлә-төнлә, дөнья тынгач кына ишетелә, урамнан атлылар үткәне дә беленми. Калын, мүкләнгән юеш түшәмнән эч пошырып тып та тып су тама.

Константин Петровичның Винокуровның уйланырга вакыты җитәрлек. Мул аның вакыты! Уйланырлык үткәне дә бар. Хәтер казнасында күпме чүп-чар, ничаклы хатын-кыз назы, күпме шашкын истәлекләр саклана. Камера уртасындагы бердәнбер агач урындыкта утыра-утыра да, калкынып, Уайльд шигырьләрен укый башлый...

Соңгы тапкыр шигырьне кемгә укыган иде соң әле ул? Әйе, теге Мәскәүдән күченеп килгән, шашкын хисле, шигърияткә һәм матурлыкка мәҗнүннәрчә гашыйк Зоряга бугай... Әллә университет студенткасы гүзәл Тамарага укыдымы? Сексны алла иткән Лизага да укыган иде шикелле... Исемнәр, исемнәр, алар я чакрым баганалары, я зират ташлары шикелле хәтердә тезелешеп калалар икән... һәр исем аерым бер тарих...

Ничек болай булды?

Нигә килеп капты ул?

Бу сорауны ул үзенә мең кат бирде. Меңнән артык.

...Менә ул — Казан кызлар гимназиясенең география укытучысы. Кызлар гимназиясе! Ул класска килеп кергәндә, гимназисткаларның күзләрендә тоташ ут кабына, битләре аллана, күкрәкләре дерелди башлый. Аның сихри күзләренә карап, класс бер мәлгә телсез кала. Аның гөрләп торган йомшак тавышыннан кызларның күзләренә яшь тыгыла, бугазлары кымырҗый. Дәртлерәк гимназисткалар аны төшләрендә күреп саташып уяналар. Хушбуй сипкән зәңгәр кәгазьләргә Надсоннан, Мережковскийдан чүпләп шигырьләр язалар. Күпме хатлар килә аңа! Кызлар каны шашып-кайнап тамырлар буйлап чапкан өлкәнрәк класс укучыларын май кичләрендә ул теләсә кая чакыра ала. Килми калырлар дип уйламый... Аның белән күрешер өчен гимназисткаларның атлыгып торганын, көнләшеп, бер-берсенең чәчләрен йолыкканын ул бик яхшы белә, көнчелек янәшәсендә әләк бар, әләк булган урында кемгәдер яшәү җиңел. Ул бу уңай кагыйдәне бик шәп үзләштерде, иркен яшәде, рухи өстенлеккә, тәкәбберлеккә гадәтләнде...

1905 елдан ул — эсер! Винокуров шушы партиядә торуына чиксез шат! Патшага, царизмга нәфрәтен кайбер фиркале салам сыйраклар кебек сүз белән генә белдерми ул, нәфрәтен эше белән, гамәле белән ныгыта! Ул царизмның тугры ялчыларын үтергән, ирекле крестьян Россиясе турында хыялланган сугышчан партия әгъзасы! Аерата Казан эсерлары белән горурлана Винокуров, үзен һәм фикердәшләрен Александр II гә аткан Дмитрий Каракозов, Александр III кә үлем әзерләгән Александр Ульянов группасына кергән Василий Осипанов кебекләрнең тугры варислары итеп саный.

1906 елның мартын онытырга ярыймы соң? Эсерлар комитеты тулы составында жандармнарның губерна идарәсенә бомба ташлады. Атыш башланды, һәм вице-губернатор Кобяко яраланды! Җиңеш!

Шартлаткыч матдәләр ясау лабораториясе оештыру дисеңме, террор актлар үтәргә сәләтле боевиклар тәрбияләү дисеңме, һәммәсен булдырдылар, күпне татыдылар, кулга алуларны, сөргеннәрне, дар агачла-

рын... Фикердәшләренең күпмесе, богау чыңлатып, Россиядән ерак Себергә узды...

Тора-бара аларга «контрреволюционерлар» дигән исем ябышты.

Колегаев элек-электән кисәтә килде:

— Әгәр элеккечә яшәсәгез, иске ысуллардан баш тартмасагыз, яңа агымнарны кабул итмәсәгез — революционердан контрага әйләнгәнегезне аңышмый да калырсыз!

Әйе, Андрей Лукич Колегаев, сул эсер, большевиклар белән гөрләтеп эшләргә кереште, республиканың җир эшләре халык комиссары вазифасын башкарды, күптән түгел генә Казан губбашкармасының рәисе итеп сайланды.

Юл башында бергә иделәр, хәзер исә Константин Петрович чеканың ялгыз камерасында утыра һәм Колегаев аны хөкем итәчәк! Икенче яктан караганда, әгәр эсерлар җиңгән булса, урыннар алышыныр иде. Нишләтер иде икән Винокуров губбашкарма рәисен?!

Бер мизгелгә ул хыялында губбашкармага менеп утырды һәм эсерлар партиясенә хыянәт итеп большевикларга кушылган элекке юлдашларына җәза бирә башлады... Һичшиксез, ул аларны ипи белән суга утыртыр! Һәммәсен одиночкаларга бикләр! Шушы кан ката торган шыксыз төрмәгә! Колегаевны судсыз-нисез аттырыр... Аның ишеләргә көн күрсәтмәскә кирәк...

Хыялларны уйлар алыштырды, гаҗәп хәл, Россия хөкүмәтенең соңгы ике составына да Казан эсерлары керде: Керенский хөкүмәтендә С. Маслов җир эшләре министры булды, Ленин хөкүмәтендә менә Колегаев.

Уйлар, уйлар...

Ялгыз камерада, таш читлектә чакта да иркен агыла алар, уйга төрмә юк, уй һәрвакыт ирекле кош...

«Уйлыйм икән — яшим дигән сүз», анысы да куаныч. Коры куаныч, мәгәр яшим дигән сүз... Уйлары өзлексез сикергәләп шушы урынга житкәч, Винокуров ачы елмайды — нишләргә? Чекадан ничек чыгып котылырга?

Уйлар, тыгызланып, бер-берсен алмаштырдылар...

Быел гыйнварда, кыш уртасында, Казанга уң эсерлар партиясе Үзәк комитеты члены сыйфатында Сергей Каллистов килеп төште. Казан комитеты председательлеген һәм «Халык эше» газетасының редакторлык вазифасын үз кулына алды. (Шаярма, Үзәк Комитет әгъзасы!) Партиянең сигезенче советы утырышында: «Советларга каршы чыкмыйбыз, алар белән килешенеп яшибез. Алай гына түгел, советлар белән кулга-кул тотынышып эшләүгә күчәбез»,— дип көтелмәгән белдерү ясады. Тик күпчелек аны тыңламады, өндәмәләрен уенга алдылар, арттагы рәтләрдән берәү әче итеп сызгырды. Казанда посып яткан Калинин дигән бәндә шыпырт кына Мәскәүгә китте, анда Савинков белән күреште. Икесе дә әшнәләр, заманында икесе дә Керенский тирәсендә юргаладылар, серләре килешә. Калинин Казанга дәртләнеп, «яңа идеяләр белән баеп» кайтты. Савинков исеменнән сөйләп, ул Казан эсерларына болай диде: «Совет власте белән көрәштә барлык ысуллар законга сыячак: террор, тагын бер мәртәбә террор! Союзниклар белән бергә булырга, хәрбиләр һәм карагруһлар белән берләшеп көрәшергә». Казанлылардан Бартольд, Якобсон, Ильинский һәм башкалар (шул җөмләдән Винокуров та), советларны бәреп төшерү өчен фетнә күтәрергә кирәк, дип кычкырдылар.

Ниһаять, офыкта, озын күлмәк итәкләрен җилфердәтеп, Никитина пәйда булды. Ул үзен Савинков «Союз»ы штабының әгъзасы дип атады. «Союз»ның паспортлары һәм квартиралар өчен ул җаваплы икән, хәзер, штаб боерыгы буенча, ике меңнән артык офицерны квартира белән тәэмин итәргә килгән. Бу ике мең кеше «Союз» җитәкчеләре белән бергәләп Казанга күчәчәк һәм алар, җирле әгъзалар белән берләшеп, Совет властена каршы восстание күтәрәчәк...

Өметле бу хәбәрләр Винокуровны күккә чөйделәр. Ул, аерата дәртләнеп, көнен-төнен белмичә, Никитинага ярдәмгә ташланды. Никитинаны казанлылар «ур-ра!» кычкырып каршыладылар, бу гомуми күтәрелеш Сергей Каллистовка да тәэсир итми калмады, ул да восстание идеясенә кушылды: «Күпчелек кайда — мин шунда!»

Килештеләр... Мәскәү белән ара ныгыды... Винокуров Щетинкин номерларында Никитина белән куныл та чыкты...

Шул вакытта гына һәлакәт!

Өмет яңарганда, якын киләчәк шундый кызыктыргыч чакта — төрмә камерасы...

Уйлар усал, алар Винокуровны туп-туры стенага териләр: губернада хәрби хәл игълан ителгән, ә аның квартирасында атыш булып алды. Корбаннар бар, яралылар... Мәскәүдән килгән чека вәкиле яралы... Димәк... аны... «хәрби вакыт законнары белән» хөкем итәчәкләр. Хәл мөшкел, үтә мөшкел...

Юк, юк, кулына килеп эләксә, Колегаевны Проломный урамындагы фонарь баганасына сул аягыннан астырып куяр иде ул...

Тикшерүче Таһиров: «Вакыт аз, белгәннәреңне тизрәк сөйлә»,— дип кабатлый. Барыннан да бигрәк аны офицерлар арасындагы элемтә, корал һәм восстаниенең ни дәрәҗәдә әзер булуы кызыксындыра.

Аның вакыты аз, ә Винокуровның...

Өмет тә бар: «Исән калуын калырмын, әлегә чекада беркемне дә атканнары юк». Монысын ул тәгаен белә. Срок әзрәк эләксен өчен кемгә таянырга булыр иде?

Аның акылы, камера кысасына гына сыймыйча, давылланып, тышка ташлана, гомернең соңгы айларын, елларын капшап бара, таяныр кеше эзли...

Юстиция комиссары Мартын Межлаук... Яшь, революциягә җаны-тәне белән тугры кеше... Ул ярамас. Әллә ревтрибуналның яңа председателе Иван Мохов белән сөйләшеп карарга мы? Эх, элеккеге йомшак табигатьле, намуслы Вихорев булса!.. Сызгырып кына чыгып китәр иде Винокуров!.. Әле ярый Мәскәүдән, ВЧКдан килгән кешене үтермәгәннәр...

Менә ул ялгыз камерада. Әгәр теге... Зоря исән булса, юлын табып, төрмәгә дә килеп керә алыр иде. Тик тормас иде ул! Әһә! Тагын бер өмет калган икән әле...

Винокуров бер генә мизгелгә үзенең утыруын онытып, соңгы сөяркәсенең йомшак кулларын, фәрештә тавышы шикелле иркә тавышын хәтергә төшерде... Юк, ул берни кыла алмас, ире губернада мәгълүм, дәрәҗәле кеше. Дөрес, кирәк тапса, һәрбер хатын газиз ирен уч төбендә камаринскийга биетә ала, Лиза да төшеп калганнардан түгел, ирен башмак астыннан чыгармый, әмма бу юлы хәл артык авыр, артык дәрәҗәдә катлаулы. Чека кадәр чекадан иблис анасы да тартып чыгара алмас!

Винокуров кинәт тетрәнеп алды, татлы, исерткеч хыяллар каядыр упкынга очты, күгәргән түшәмнән су тамчылары кабаланыбрак идәнгә тыпырдый башлады, камера ишеген кыяр-кыймас кына кемдер ача кебек тоелды. Колакка ишетелдеме? Күзгә күренәме? Саташу шушы була икән! Иң яхшысы бүтән якка карарга да хәтерне тоташ эшкә жигеп уйларга да уйларга кирәк. Кинәт аның колагына һич көтелмәгән сүзләр ишетелде. Караңгы камерада шыпырт кына, ул күрешергә килгән бәхетле-татлы мизгелләрдә яңгыраган сүзләр кабатланды: «Син мине һаман яратасыңмы? Мине элеккедән дә ныграк телисеңме?»

Константин Петровичның маңгаена салкын тир бәреп чыкты: «Шашам, ша-шам!» Ул күзләрен авырттырып йомды: «Беттем! Беттем!»

Кинәт аның йон баскан яңаклары тирәли йоп-йомшак куллар сыйпанып йөри башлады. Аның куллары! «Әҗәлем житкән икән!»

Күзләрен кысып кына ачып караса — каршысында ул! Лиза!

— Лиза!

— Акрын!

Ул! Сөекле, назлы җан. Сөенеченнән телсез калган Винокуров байтак вакыт өнсез утырды, ишек шакыдылар, ул бераз айнып:

— Ничек килеп кердең син монда? — дип сорады.

— Мин синең коткаручы фәрештәң!

— Фәрештәләр дә чекага үтеп керә алмый!

— Мин сине алып чыгарга дип кердем.

«Төш күрәм яки акылдан шашам!» — дип сызланды Винокуровның тәкатьсез калган күңеле.

Лиза төрмә диварларына сыймас тавыш белән чыркылдады:

— Тыңла... Башта иремнән мин үтендем... Аннан мин аны бик каты иркәләдем!.. Сине иркәләгән кебек, син дип белеп!.. Аннан ул синең өчен үтенде. Олькеницкий иремнең гозеренә колак салган: «Әгәр шәһәрдән чыкмаска, сәясәт белән шөгыльләнмәскә сүз бирсә, иреккә чыгарабыз»,— дигән. Иң актыктан Григорий Шмулевичтан мин ялварып сорадым... «Камерасына кереп, үзем алып чыгам!» — дидем. Түбәнсенеп тормадым. «Нинди романтично!» — дип әйттем, яшермәдем. Син дә ризалаш. Ни сорасалар да, күн, яме,җаным!

— Синең һаман шаяртасың килә! Алай да ничек монда үтеп керә алдың?— Винокуров түшәмгә, калын стеналарга, тимер ишеккә ымлады.— Кош та үтеп керә алмас җир!

— Кош үтмәгән җирдән мәхәббәт уза! Җыен, чыгабыз!

Лизаның янында булуына һаман ышанып бетә алмыйча, Винокуров курка-курка гына ишеккә юнәлде, коридорда ачкычлары белән уйнап, түземсез кыяфәт белән киң җилкәле кызылармеец көтеп тора иде, ул аларны сүзсез генә үткәреп җибәрде, буш камераның тимер ишеге шартлап ябылды...

Ул, Лизаның кулыннан тотып, тар һәм текә баскычтан менәргә булышты... Иң элек ишегалдында баскыч төбендә үк үсеп утырган өч купшы юкәне күрде. Юкәләрнең дымсу-йомшак яфраклары әкрен генә җилдә тирбәлә. «Лизаның куллары да шушы яфраклар кебек йомшак»,— дип, сәер уй уйлады ул кинәт... Шәһәрдән чыкмау турындагы кәгазьгә кул куйдырганнан соң аны Олькеницкий янына керттеләр. Гирш Шмулевич аңа җирәнеп карады.

— Артык җүләрләнмәгез! Һәр адымыгызны күзәтәчәкбез. Үзегезгә дә, сезне яклаган кешегә дә кыен ясамагыз. Шау-шусыз, гади генә яшәгез, хезмәт итегез. Менә шул,— диде ул.

Яшәмиме соң?! Гади яшәргә дә, шау-шусыз гомер кичәргә дә шатланып риза Константин Петрович. Төрмәнең ялгыз камерасыннан котылып, көнгә чыккан кеше бүтәнчә уйлый аламы соң?! Сикерә-сикерә риза!

Урамда аны күперенке бантик иреннәрен ялаштырып, түгәрәк соры күзләрен уйнатып, Лиза көтеп тора иде, алар җитәкләштеләр, капка төбе саклаган кызылармеец аларга бармак янап тешен ыржайтты...

Гайнулла Таһировның тәшвишле соравына мин Олькеницкий сүзләре белән җавап бирдем:

— Винокуровнымы? Кая бара ала ул? Тамгалы бүре! Аны төрмәдән коткару — революциянең какшамас көченә ышану. Әлбәттә, бүренең башын бүреккә салсаң да, урманга карый, аны күздән ычкындырырга ярамас...

Белмим, Гайнулланы минем җавап канәгатьләндердеме, юкмы, минем күңелдә юшкын уелып калды, җанны нидер тырнады. Олькеницкий белән килешеп бетмәдем! Әлбәттә, шушы көнгә кадәр Таһиров та, мин дә ата мәче Винокуровның шәһәрдә бик җаваплы эш башкаручы берәүнең хатыны белән гыйшык-мыйшык уйнавын бөтенләй белми идек...

Казан фетнәсен ачуның истә калган вакыйгаларын мин сезгә тезеп сөйләп барам. Чынлыкта исә һәммәсе дә мин язганнарга караганда авыррак, четереклерәк иде.

Без контрреволюциянең әзерлекле, оешкан,белемле кешеләре белән күзгә-күз килдек, алар белән сөйләшү җавап алу, алар корган мәкер йомгакларын чишү тәҗрибәсез, өчле-тугызлы гына уку эләккән намуслы, эчкерсез, хәйлә серләрен бөтенләй белмәгән егетләргә ифрат кыен иде. Офицерларны чекерәеп күзгә кереп торган хак дәлилләр белән стенага китереп терәсәң дә, күпчелек туры сүздән баш тарта, булганнарның киресен, яки үз файдасына үзгәртеп сөйли, тикшерүне кире якка, ялгышларга алып кереп китәргә тырыша иде. Шуны да онытмыйк: май урталарында Казанда бөтен шәһәрдә чекистлар саны уннан артмый иде! Казанның яшь чекистлары аз-азлап, бөртекләп, җыелганнарны чыдамлык белән бергә туплап, нигезле бер эзгә төшеп кенә совет властена каршы оешкан заговорның көч-куәте турында тулы хакыйкатьне ача бардылар.

Ул чагында мине аерым бер эзлеклелек гаҗәпләндерде...

Унсигезенче елда бөтен илдә, барлык милләтләр, халыклар арасында, шул җөмләдән Казанда да контрреволюция бердәм җанланып китә! Интервентлар белән эчке контра бер таякның ике башы булсын да ди, алар элек тә каршы булдылар, калдыклары җанланып та куйсын ди... Әмма татар, рус, украиннарның, латыш-яһүдләрнең, кавказлыларның нәкъ бер вакытта, нәкъ менә унсигезенче елда оешып, күтәрелеп чыга алуларының сере кайда?! Татар милләтенә бармак аша караган рус-украин буржуазиясе, көне килеп җиткәч тә, тавышын үзгәртте, алар бердәм рәвештә Казандагы милли буржуазиянең күтәрелешен яклап, аның Советларга каршы көрәшен тоташтан хупладылар. Мәсәлән, унсигезнең февраль-мартында, «Болак арты республикасы» көннәрендә, рус-украин буржуазиясе дә «Идел-Урал мөселман штатлары» таләп итеп чыктылар... Бөтенләй акылга сыймаслык хәл!

Унсигезенче елның мартында совет властена каршылык тагын да оешканрак төс ала. Яшерен оешмаларның Мәскәү, Казан һәм башка бик күп шәһәрләрдә бер үк вакытта, бер үк формаларда калкып чыгуы куркынычны арттыра иде. Сигез йөз чакрым ераклыкта урнашкан казанлылар, тылсымлы таяк фәрманы белән, күз ачып йомганчы мәскәүле фетнәчеләргә кушылып китәләр. Бәлки бу оешмалар кемдер берәүнең ихтыярына буйсынып, элегрәк үк әзерлек эшләрен башлагандыр? «Союз»ның Үзәк штабы оешканда, алар инде яшәп ятканнардыр бәлки? Элгәрге яшерен оешмалар пешеп өлгереп «Союз» составына кушылып киткәннәрдер?

Мондый сораулар байтак җыелгач, мин, махсус хат язып, Петерска юлладым, аннан киңәш сорадым. Хатны да махсус кеше аша җибәрдем. Элемтә начар, элемтә шактый ышанычсыз иде ул көннәрдә... Хатка җавап көткән арада да эш туктап тормады, сорау алулар, күзгә-күз очраштырулар туктаусыз дәвам итте, уйландыра торган материаллар һаман арта иде...

Кулга алынган офицерлардан берәү: «Мин уң эсерларның Казан комитеты членнары Бартольд һәм Ивановский белән элемтәдә идем. Ивановский мине «Союз»га тартты, ашыгыч рәвештә ышанычлы кешеләрне табарга, корал җыярга, Учредительное собраниене яклап, Советларга каршы көрәшкә өндәргә боерды»,— дип белдерде. Өндәве ничек булгандыр, билгесез, мәгәр егерме револьвер белән утыз винтовка табып өлгергән.

Икенчесе: «Безнең «өчлек»нең командиры полковник Петров иде. Савинков «Союзы»на кергәндә, өч йөз сум акча бирделәр. Шәһәрдә фетнә башлануга шәһәр телеграфын яулап алырга куштылар»,— диде.

Бер офицерның куенынnan карагруһчыларның Киевта нәшир ителә торган «Киевлянин» газетасы чыкты. Өр-яңа саны! Анда совет властеның культура өлкәсендәге гамәлләрен бозып күрсәтә торган мәкалә каләм белән билгеләп куелган иде.

«Ун яше тулган балаларны большевиклар партиясенә язарга, мәктәпләрне Луначарский әфәнде карамагына тапшырырга, буйсынмаган-

нарны уку йортларыннан куып чыгарырга... Иске режимның хорафат калдыкларын, җөмләдән — Мәскәүнең изге урыннарын, тарихи изге храмнарны, сарайларны, музейларны юк итәргә»...

Имеш, Совет власте шундый күрсәтмәләр биргән!

— Сез шушы тузга язмаганнарга ышанасызмы? — дип сорадым офицердан. Елмая! Авызы тулы алтын теш!

— Мин — юк. Ә кемнәрдер ышанып куюы бик ихтимал.

Җавабы шул, тайчанып та тормый кабахәт.

Чекадан, Олькеницкий тәкъдиме белән, «өчлек»ләрнең берсенә Николай Углов кертелгән. Кергән, урнашкан, эшли... Аны чакыртып алдым. Үз квартирамда очраштык. Сәҗидә апа каядыр чыгып киткән иде, өй аулак... Углов чандыр гына, маңгай туры сизелерлек яктырган пеләш дип әйтерлек урта яшьләрдәге кеше икән.

— Ивановский белән гимназиядә бергә укыдык. «Өчлек»кә шул тәкъдим итте. Офицерлардан Богданов, Лебедев һәм Нефедовлар белән дә ул таныштырды. Очрашкаладык. Бергәләп шешә тирәсендә гәпләшкән чаклар да булды. Сүздән сүз чыгып, өчесенең дә полковник Сужкога буйсынуларына төшендем...

— Сужко?! Таныш исем.

— Саксызлык күрсәттем,— диде кул аркасы белән маңгай тирен сөртеп Углов.— Сужконың кайда, кемнәр белән очрашуын күзәтергә тотындым. Кем уйлаган бит: Сужконың үз кешеләре, тән сакчылары һәр адымда саклый икән!.. Берәвесе белән маңгайга-маңгай бәрелешә яздык. Чак качып котылдым... Мин аны, ул мине танып калды. Хәзер «өчлек»тә калуымны мәгънәсезлек дип саныйм.

— Өстәп ни әйтә аласыз?

Углов бераз уйланып утырды.

— Шигем бар... Богданов белән Нефедов исемен кайта-кайта телгә алдылар. Сужко исемен әйтеп, әллә мине тикшерделәр инде, әллә башка бер нәрсә. Әгәр Сужко «Союз»ның Казандагы җитәкчесе булса, өч офицер, авыз ачып, аның исемен миңа тәкрарлап торыр идеме?

Углов хаклы, монда нидер бар. Сужко артыннан без байтактан күзәтәбез, әмма ныклап бәйләнерлек бер хәбәр дә кергәне юк. Әллә күзәтүчеләрнең кавырсыны катмаганмы, әллә төлкедәй хәйләкәр полковник эзен оста яшерәме? Әйе, ул «Москва» кафесында булгалый. Бусын Фәридә Ибраһимова ачыклады. Бу хәбәрне Угловка җиткергәч, ул полковник артыннан атна буе тагылып йөрде, әмма без көткән дәлилләрне кулына төшерә алмады. Углов аптыраудан гаҗиз иде. Ул күрсәткән Богданов, Нефедовлар күптән кулда. Угловны «Союз»га тәкъдим иткән иптәше Лебедев белән Самарага чыгып сызганнар. Богданов белән Нефедов кулга алынгач, нидер сизенгәннәрме, әллә тәҗрибәсез Углов аларны шикkә төшергәнме?.. Шунысы шиксез: алар өчәүләшеп «Союз»га яңарак кергән кешегә Сужко исемен юкка гына телгә кертмәгәннәр. Ни теләгән алар?

Соңгы көннәрдәге материалларда безнең игътибар үзәгендә торган шул ук фамилияләр яңгыраган: Сужко, Петров, Ахтамиров һәм, ниһаять, генерал фон Ахте белән полковник Почтин.

Боларны кулга алу безгә берни тормый иде. Адреслары билгеле, исән, монда яшиләр... Тик алар гаепсез булып чыкса? Гаеплеләрнең юри, тикшерүне буташтырыр өчен тугры кешеләрнең исемнәрен атау очраклары булмадымы әллә?

Ул чакта, хезмәт иясе вәкилләрен даими хәрби хезмәткә чакырып, Кызыл Армия төзелеп кенә килә иде. Тәҗрибәле, белемле офицер кадрларга һәр тарафта кытлык. Элекке офицерлардан байтагысы, намуслы кешеләр буларак, хезмәт халкына хезмәткә күчтеләр. Революция көннәрендә җиңүче халык ягына баскан Казан гарнизоны офицерлары большевик прапорщиклардан Николай Ершов, Якуб Чанышев, полковник Руанетө белән капитан Евгений Масальский турында миңа, горурланып,

Ольkеницкий сөйләгән иде. Болары дөрес сафларга кичә басканнар, иртәгә алар арасына яңа көчләр киләчәк. Һич югында без шуны телибез, шуны көтәбез. Әгәр без гарнизон офицерларын капыл-копыл кулга алсак, ашык-пошык хөкем итсәк, башкаларга бу кире тәэсир итәчәк. Бигрәк тә хәзер, Казанда Көнчыгыш фронтының Үзәге оешып килгәндә, армиягә ирекле язылудан даими хәрби хезмәткә күчү чорында, бу моментны истән чыгарырга ярамый иде. Контрреволюциянең тоташ агитациясе тәэсирендә бүгенгә икеләнебрәк торган хәрбиләрне тоташтан дошман ягына аударачак иде мондый кинәтлек. Юк, исбатларлык, дәлилләр халык арасында белдерерлек булганда гына офицерларны кулга алырга кирәк. Монда кыек атарга һич тә ярамый. Революциягә чын күңелдән бирелгән сугышчылар азмы әллә?! Май аенда шәһәрдә күңелле булып язылганнардан алты мең кызыл армеец иде. Бу кадәр сугышчы Идел буе шәһәрләренең берсендә дә юк!

Савинков «Союз»ына кергәндә, офицерлар ант биргәннәр. Антны да безгә Углов хәбәр итте. Болай диелгән анда: «Үз иманыңа якыннардан күбрәк кешене «Союз»га тартырга... Корал туплап, кирәк чагында Совет власте вәкилләрен тар-мар итеп, «учредилка» игълан итәргә...»

Петерстан һаман хат булмавына эчем поша иде. Казан фетнәсе тулаем бастырылмаса да, күпмедер вакытка тоткарланган булуын, байтак дошманнарның фаш ителүен истә тотып, мин Петерска шалтыраттым һәм Мәскәүгә кайтырга рөхсәт сорадым. «Казан чекистлары үзләре дә башкарып чыгачак, биредә бик шәп яшьләр үсә!» — дип, казанлы иптәшләремә ышаныч белдердем.

Петерс әлегә кайтмаска кушты.

— Казан майда гына түгел, июньдә дә иң әһәмиятле стратегик үзәкләрнең берсе булып кала. Шуннан торып Көнчыгыш фронтының уңышларын һәм куркынычсызлыгын тәэмин итү — безнең бүгенге төп бурычыбыз,— диде.

«Безнең», димәк,— минем дә...

Петерс хаклы булып чыкты...

Без май азагында, июнь башында күргәннәр әле «чәчәкләре» генә булган икән. Аз-маз баш-күз алырга да өлгермәдек, вакыйгалар тагын да куерып, хәвефләрәк төс алды. Иң мөһиме: кемдер бу вакыйгаларга үзе теләгән юнәлеш биреп тора, әле бер урында, әле икенче бер төштә безнең йомшак якларны капшап таба. Карыйсың, гарнизонга барып кереп, анда чуалыш кузгатып ала. Завод-фабрикаларда забастовка, саботаж оештыра, я кемне дә булса ерткычларча үтереп, халыкны куркытып-тетрәндереп тота.

Кем кулында соң бу дилбегә? Советка каршы акцияләрне бер кулда тотучы бармы? Булса — кем?

Уйлар тезелешеп тагын артка йөгерәләр, һәммәсен җай белән сөйләп бирим булмаса...

Җылы һәм тыныч июнь кичендә Зоряның әтисе белән сөйләшү ансат булмады. Теләсә нинди дәһшәтле, усал офицерлар алдында да каушап калмаганны, бу юаш, кирәгеннән артык нык өшәнгән, көмеш сәгать чылбырын түш кесәсенә чыгарып салган бу кеше белән сөйләшкәндә иң зарури сүзләр онытылды, маңгаема тоташ дым бәреп чыкты, җәрәхәтем элеккедән дә ныграк сызлады... Сәгать чылбыры аның бердәнбер байлыгы иде булса кирәк, бик кадерле бераэр хатирәседер дип уйладым, өс-башы шактый таушалган, чалбарының тез башлары сизерәгән бу кеше минем белән очрашуны көтмәгәндер дә ахрысы. Мин өйләренә барып кергәч, аптырап калды...

Мин аны юатырга тырышмадым, юату сүзләре артык та, файдасыз да иде. Таня безнең бер сүзгә дә катнашмады, хәсрәтле кеше буларак, куулларын тез өстенә куеп, бер почмакта, болай да артык булмаган йортның иң караңгы почмагында тик кенә утырып торды, алай да бик бирелеп тыңлап утырды.

— Революция корбансыз гына була алмый,— дидем мин, бераз дөнья хәлләреннән хәбәрләр алышканнан соң, мөмкин кадәр сабыр булырга тырышып.— Кирәккә дә, кирәкмәскә дә кан күп коела.

— Минем өчен коеламы ул кан? — диде Зоряның әтисе.— Минем өчен түгел ләбаса! Революциядән качып, мин монда килдем. Ә ул мине һаман артымнан эзәрлекли. Миңа аннан берни дә кирәкми!..

— Революциягә сез дә кирәк! — дидем мин.— Һәркем, үз өлешен бирмичә торып, бу чуалчык чорны уза алмый.

— Тыныч яшәргә телим! Минем сүзем шул...

— Тыныч яшәү мөмкин түгел. Диңгез дулкынланганда чайкалмаган кораб юк...

Аңлата алдыммы мин аңа, юкмы, белмим. Безнең сүз ялганмады, бер юнәлеш алмады. Ул мәгърипкә карап табынды, мин башка якка тарттым...

Алардан кузгалганда, ачык тәрәзәләргә сабыр зәңгәр сыеклык яткан иде инде. Таня мине озата чыкты. Бер нәрсә өчен хуҗаларга рәхмәт укыдым: алар Таняны чыгудан тыймадылар, дәшмәделәр. Тәрәзә турыннан узганда, әнисенең кара шәле күземә чалынып калды, ул каядыр омтылып, кулларын алга сузып, очып китәрдәй булып Таняга йотылган иде. Хәвеф-хәтәрләрдән аралап калырга теләдеме ул, шуңа омтылдымы?

Без Казанка елгасы яры буйлап ары да, бире дә берничә кат урап килдек. Монда тын, һава саф, үләннәргә мул булып чык коелган иде. Куерып үскән куаклар арасыннан шыпырт кына сөйләшкән кеше тавышлары килде, трубкасын капкан, ишкәкләрен күтәргән йөнтәс чырайлы карт узып китте. Ул борылып-борылып безгә карады.

— Китик моннан,— диде Таня.

Без, җитәкләшеп, Большая Проломная дип аталган үзәк урамга атладык, крепость астыннан шунда барып чыктык. Таня мине Казанка буйлары, аръякта күренеп торган кое шәмәхә әрәмәләр турында сөйләп, таныштырып барды, үзәк урамның исеме дәһшәтле патша Иван Грозный заманыннан ук калганын әйтеп бирде. Мәскәү гаскәрләре хан крепосте стенасын шартлатып кына шәһәрне ала алганнар икән.

Аның бер темадан икенчесенә җиңел генә күчүе, хәсрәткә баткан күңелемне аз гына бушатырга тырышканлыгы күренеп тора иде. Мин ничектер җиңеләеп калдым, Таняга апасы турында, Мәскәү, яраткан шагыйрьләрем турында сөйли башладым. Арадагы читенсенүнең эзе дә калмады, йортта өебездә торган шәүлә-томан таралды, күңелле үк булып китте. Сөембикә манарасы тирәсен чуарлап, күктә кыяр-кыймас кына яшькелт йолдызлар кабынды. Кызлар белән янәшә барганда, аййолдызларга күз ташламыйча ярамый, күңелеңдә сер булып сакланган шигырьләрне тышка чыгармыйча ярамый! Төрле шагыйрьләрнең мине әсәрендергән шигырьләрен сөйләдем, әле ул чакта миңа аз таныш булган Борис Пастернакның шушы юллары Таняга аерата ошады.

В тот день всю тебя, от гребенок до ног<br>
Как трагик в провинции драму Шекспирову<br>
Носил я с собою и знал назубок,<br>
Шатался по городу и репетировал...

Таня кинәт тутады, каршыма чыгып басты, күзләремә карады һәм:

— Сез минем апамны сөя идегезме? — дип сорап куйды.— Тик дөресен әйтегез.

— «Әйе» дип әйтергә кыенсынам,— дидем мин.— Күбрәк балачагын хәтерлим мин аның. Зурайгач, беләсең, бик аз очраштык. Әмма ул бик әйбәт кыз иде, миңа бик ошый иде. Җаны тере иде аның, омтылышы бар иде. Үзе белән ияртә ала торган җан иде! Боларын мин һич икеләнмичә әйтә алам... Аннары, ул минем өчен үзен корбан итте. «Сөймәдем» дияргә намусым кушмый, вөҗданым. Мөгаен, без бик якын булганбыздыр...

Таня үзен олыларча тота, сүзләрен үлчәп сөйли, гомумән, апасы вафатыннан соң ул кинәт житдиләнеп, олы кыз булып калды.

Проломный урамыннан без, Болак аркылы салынган бердәнбер таш күпер аша чыгып, вокзал янына уздык.

Вокзал — Зоря белән Казанда беренче очрашкан урын... Аның наз белән тәшвишләнеп: «Син һаман шигырьләр язасыңмы әле?» — дип сораганы колак төбемдә чыңлап тора. «Син һаман мине сөясеңме?» — дип соравы булдымы бу аның? «Сөя» дип ышандымы, шуның өчен утлы ук аның юлына аркылы төштеме?..

Вокзалда мине Вәлиуллин эзләп тапты.

— Сергей Сергеевич,— диде ул. Аның карлыккан тавышы, йөзенә бәреп чыккан каушавы — ниндидер гадәттән тыш хәл барлыгының билгесе иде. Мин Таняны чак кына читтәрәк калдырдым.

— Гафу ит, Таня, мин хәзер...

Вәлиуллин миңа иелә төшеп:

— Сезне хәзер үк чекага килеп житсен диделәр,— диде.

Хушлашканда, Таня минем кулны жибәрми торды.

— Әтиләр янында бигрәк читен хәзер,— диде ул. Сүзләре моңсу булса да, жыламады, елмайды, шуннан чыгып, мин Танянын апасы кебек үк сизгер жанлы олы кыз булып житкәнен аңладым. Үзенең житкән кыз икәнен расларга теләгәндәй, ул, аяк очларына басып, минем яңак битеннән чак кына үбеп алды.— Беләм, Сезне чакыралар, эзлиләр. Борчылмагыз, ахыры хәерле булыр.

— Нәрсәнең ахыры?

— Һәммәсенең дә! — диде Таня чыраена чегән хатыннарыдай серлесихерле төс чыгарып.— Беләм: Сез минем апамны ярата идегез. Чын күңелдән аны Сез генә яраттыгыз... Мин Сезне апамны яраткан өчен яратам. Килеп йөрегез, зинһар, мине ялгыз калдырмагыз. Әти белән әнине зарланмаска күндерермен мин, зарланып яшәүнең беркемгә дә файдасы юк.

Ул тагын — икенче битемнән үбеп алды да саубуллашып китеп барды. Берни сорамады, бары аңлады. Барын кабул итте.

Чекада мине Аристов белән Вера Брауде бик борчылып көтәләр иде.

Эш ашыгыч булса да, куркынычлы хәбәрләр дулкын кебек өстеөстенә килеп торсалар да, жае чыкканда, Вера Петровна Брауде хакында да бер-ике сүз әйтеп китүне вөжданым куша...

Үтә гайрәтле һәм үтә матур хатыннар сирәк була.

Вера Брауде сирәк очрый торган шундый гали затларның берсе иде. Аның кыз чагындагы фамилиясе Булич, ул атаклы затлар нәселеннән, аның бабалары арасында философ-демократ П. Я. Чаадаев һәм бөек рус химигы А. Н. Бутлеровлар бар. Яшьтән үк тере, хәрәкәтчән һәм туры сүзле Вера Булич уналты яшеннән революцион хәрәкәткә катнаша башлый. Мең тугыз йөз дүртенче елда, затлы кызлар институтында тәрбияләнгәндә «Ходай фәрманнары» дәресенә йөрми. Директор, чакырып алып, аны нык кына пешерә.

— Йөрмисеңме?

— Йөрмим!

— Нигә йөрмисең?

— Библия — экиятләр жыентыгы. Минем экият тыңлыйсым килми.

Вера Булич чыгып киткәч, директор, куркынып, почмакка карый:

— Я хода! Рус дворян кызы Библияне әкиятләр тупланмасы дип атый...

Олькеницкийның урынбасары булып эшләгән Брауде, сул эсер булуына да карамастан, революциягә бөтен барлыгы белән ышанып хезмәт итә. Казан чекистларының нәтижәле эшчәнлегендә рус дворян кызының да мактаулы өлеше бар!

Кабаланып, Вера Петровна кабинетына барып кердем.

— Гарнизонда хәлләр бик күңелсез,— диделәр алар.— Контра коралды күтәрелеш оештырмыймы?

— Сәбәп? — дидем мин.

Озын, матур муенын каплап торырлык көрән күлмәк кигән Вера Петровнаның болай ук кызып киткәнен күргәнем юк иде әле. Инде ул шулай ярсыган икән, гарнизонда хәлләр чыннан да яман булырга тиеш...

— Хәлебез кыен, аны берни белән чагыштырырлык түгел. Хәрби частьләрдән килгән информацияләрне, төрле-төрле хатлардан тапкан мәгълүматларны, кулга төшкән телефон сөйләшүләрен бергә туплагач, советка каршы коткы таратучыларның, көрәшкә өндәүчеләрнең исемлеге, байтагысының адреслары ачыкланды. Аларны кулга алып, тизлек белән тикшерү башларга гына кала. Хәл киеренке, хәвефле, безгә төрле яктан куркыныч яный...

Без Аристов белән аны бүлдермичә генә тыңлап утырабыз.

— Крепость казармасындагы солдатларны бу көннәрдә юри начар ашаталар. Ашка исле кәбестә тутырганнар! Советка һәм аның солдатлар секциясенә үч итеп эшлиләр. Кием-салым складының киштәләрендә әллә никадәр обмундирование саклана: артиллеристларга кирәкле зәңгәр инглиз сукносы, инглизләрдән килгән яшел диагональ шевиот. Ә солдатларның өстенә карарга куркыныч! Кызыл Армия ирекләрләренә яңа кием тиеш булса да, алар һаман алама-сәләмә өстерәп йөриләр. Күбесенең аягында чабата! Ни өчен?! Интендантларны беркем юньләп тикшерми, шуның нәтиҗәсендә «сорочий» базарында өр-яңа солдат киемнәрен уңга-сулга саталар. Кием-салым складларын бөтен җирдә элеккеге офицерлар саклый. Байлык — алар карамагында! Гарнизон комитетын анархист матрослар Сметанин белән Краюхин үз кулларына алган. Артиллерия бригадасының командиры полковник Почтин алар белән бергә рәхәтләнеп эчә, юмарт сыйлый һәм теләсә ни эшли ала. Аңа диңгез тубыктан! Хәлнең һәр ягын искә алып, без Ольkenицкий белән бергә большевиклар партиясе губкомы председателе Яков Семенович Шейнкманга кисәтү ясадык: крепость казармасындагы содатларның тузынып чыгуы бик ихтимал! Губком крепостьтагы элекке губернатор сарaeннан Грузинская урамындагы Александров йортына күченә. Башкача аларның иминлеге өчен җавап бирү кыен. Губкомны саклау өчен Карл Маркс исемендәге интернациональ батальон составыннан бер взвод сугышчы җибәрми булмас. Алар карамагына ун пулемет тапшырырга кирәк. Без хәзер үк оператив чаралар күреп, баш калкытып маташкан контраның койрыгын басмасак, соңга калуыбыз ихтимал.

Бер минутка киеренке тынлык урнашты. Ачык тәрәзәдән урам шаушуы агылып торды. Тавышлар, безне шикләндереп, тагын да катырак яңгырый иде. Тәрәзә төбенә ятып, аска, урамга карадым. Уңга да, сулга да солдатлар йөгерә, берни аңлап булырлык түгел иде. Ул ара да булмады, очып, ишек ачылды һәм аннан, атылып, чека буенча дежурный керде, Брауде каршына басты.

— Вера Петровна! Әле генә телефоннан хәбәр иттеләр: бер төркем солдат һәм өс-башларын алышкан офицерлар, гарнизон комитеты исеменнән, Рыбнорядск урамындагы аракы складын басып алганнар. Хәрби кием кигән һәркемне аракы белән сыйлап, Советларны куарга чакыралар икән!

— Башланды,— диде Вера Петровна, йодрыкларын йомарлап.

Димәк, башланды...

Әллә юкмы?

— Тагын шул,— дип дәвам итте дежурный,— Дмитриева шалтыратты.

— Дмитриева контроль аппаратта утыра,— дип аңлатты Брауде.— Гарнизон членнарының элемтәләрен тыңлый...

— Телефоннан иң күп сөйләүче Голубев икән. Ул барлык солдат

комитетларына шалтыратып чыккан, йөк машиналарын аракы алырга җибәрергә боерган. Машиналарны махсус нарядлар озатсын дип кушкан.

— Кичекмәстән чара күрергә! — диде Брауде.

Аракы шәһәр буйлап сәфәргә чыгып, солдатлар исерешеп бетсә?

Без Ольkеницкий янына ашыктык. Григорий хәбәрдар икән инде: ул, без кергәндә, телефоннан сөйләшә иде, нишләргә, нинди чаралар күрергә кирәклеген Шейнкман һәм Межлаук белән тәгаенли икән.

Брауде белән Таһиров бүген төнлә гарнизон комитеты членнарын кулга алырга тиешләр. Хәрби частьләргә хәзер үк җаваплы кешеләр чыгып китеп, агымдагы хәлләр турында дөреслекне сөйләсеннәр... Завод-фабрикаларда митинглар уздырырга карар кылдык. Хәзер үк котkынын башына басарга, исерекләр кузгалышына ирек бирмәскә кирәк.

Межлаук телефоннан:

— Бер-ике йөз контрреволюционер чынлап торып хәрәкәт итәргә тотынса, безнең хәл мөшкел булачак, чөнки Советларны сакларга билгеләнгән кораллы көчләр, белүемчә, шактый таркау һәм аларга ышанычта аз,— дип кисәтте.— Контр элементлар алар арасына да барып кергән!

Аларга ышаныч аз! Кемгә ышанырга соң? Аракы эчеп, миләре сөремләнгән, контр сүзләр белән котырынган солдатларны кем ипкә китерер?.. Эш бездә, чекистларда иде. Бар булган иптәшләрне кыска арада хәрби частьләргә озатып калдык. Алар нык һәм хәрәкәтчән булырга тиешләр. Әле вакыт бар...

Төн үткәнче заговорчылар кулга алынды, завод-фабрикаларда ашыгыч митинглар уздырылды. Эшчеләр җыелышларында башбаштаклык һәм хаос тудырган гарнизон комитеты каты тәнкыйть утына эләкте. Ләкин башында шикле офицерлар торган комитетны тәнкыйтьләп кенә җиңеп булыр идеме икән? «Поляр» фабрикасы эшчеләренең гомуми җыелышы «гарнизон комитетының саксыз эшләрен, исерек хәлдәге кыланышларын» каты хөкем итте һәм комитетны Советларның солдат секциясенә буйсындыруны таләп итте. Башка урыннардагы эшчеләр дә шушы сүзне куәтләделәр: гарнизон комитетын бетерергә вакыт!

Иван Иванович Межлаук соңыннан сөйләде:

— Көн уртасында минем янга Казан мөселман комиссариатыннан комиссар Садыйк Әхтәмов белән 1 нче мөселман социалистик полк командиры Нур Алимов килеп керделәр. «Менә, Иван Иванович,— диләр, полк комитетында бер карарга килдек әле: Казанда бер үк вазифаны башкара торган ике хәрби оешма яшәвен истә тотып, гарнизондагы чуалышларда төп гаеп гарнизон комитетына кереп оялаган чит күләгәләрдә икәнен аңлап, комитетны Советларның солдат секциясенә кушарга да ярамаган бәндәләрне аннан куарга! Ярыймы диләр». Ярамаган кая, дим, искиткеч акыллы карар, бик вакытлы чыгарылган!.. Хәзер беләбез: бу карарны тормышка ашырсак, таянырлык абруйлы оешмаларыбыз булачак.

Алимовның полкы Хәрби комиссар белән Мөселман комиссариатына буйсына иде. Дәртләнеп киткән Межлаук Алимовка:

— Хәзер үк бер рота солдат ал да аракы складларын, кибетләрне каты сак астына ал, сату-алуны туктат. Шәһәр эчендәге патрульләрне дә арттырырга! — дип боерык биргән.

Кулга алынган гарнизон комитеты членнары арасында мине элекке штабс-капитан Голубев кызыксындырды. (Контрольдәге Дмитриева тиккә генә аның исеменә игътибар итмәгән булырга тиеш!)

Голубевның Казанга май башында ук Савинков «Союзы» йомышлары белән килүе ачыкланды. Хәзер ул йомышларның нидән гыйбарәт булуы да безгә мәгълүм! Голубевтан сорау алдык, безнең кулда какшамас дәлилләр барлыгын күреп, ул бик тиз җебеп төште, аны ашыгыч этап белән Мәскәүгә, Лубянкага, савинковчыларның җыелу үзәгенә озаттык.

Әйдә, «йомышларын ничек йомышлавы» турында үз теле белән анда сөйләсен... Монда аның авантюрасы барып чыкмады!

17 июньдә газеталарда, аерым листовкаларда губерна Советының белдерүе басылып чыкты: «Атна буе барган тикшерүдән соң контрреволюцион заговорның яңа тармаклары ачылды. Эшче, крестьян һәм солдат депутатларының Казан шәһәр Советы президиумы, төрле коткы таратучыларның ишәйгәнен күздә тотып, эшче, крестьян һәм солдат депутатларының шәһәр Советы президиумы боерыгыннан тыш бер генә приказ да гамәлгә ашырылмасын дип белдерә».

Казан Советының гарнизон комитеты вәкилләре белән уздырылган гомуми җыелышына мөмкин кадәр күбрәк кеше чакырырга тырыштык: завод-фабрикалардан эшчеләр, төрле сәяси партияләрдән вәкилләр килде. Җыелыш давыллы һәм кайнар булды. Аны губбашкарма рәисе Колегаев алып барды.

— Иң куркынычы — сүнгән учакта калган күмерләр,— дип башлады ул сүзен.— Бәләкәй генә җил дә күмерләрне кузгата, җанландыра ала. Сүнгән учагында күмер асраучы гарнизонны таратуны шәһәребезнең барлык эшчеләре таләп итә.— Колегаев кулындагы газеталарны селкеп күрсәтте.— Мөселман социалистлар комитеты — эшчеләрнең иң алдынгы отрядларыннан берсе — гарнизон комитетының барлык хокуклары яңадан сайланган Советларның солдат секциясенә бирелсен дип чыга. (Комитет членнары утырган якта көчле кул чабулар). «Контрреволюция, армый-талмый, төрле яктан баш калкыта,— диләр алар,— шул чорда Советка каршы чыгуларның берсен дә кичерергә ярамый, булган хәлдә аларның тамырын йолкып ташларга вакыт!» Иптәшләр, Солдат секциясе бүгенге хәлне дөрес юлга салыр дип ышанабыз. Безнең кайбер кызылармеецлар рухи яктан шундый йомшак булып чыктылар ки, алар гарнизон комитеты исеменә ышыкланып сөйләнгән һәртөрле уйдырма-әкиятләргә ышанып, бер чәркә аракыга сатылып, Совет властена каршы киттеләр. Димәк, без моңарчы солдатлар арасында тиешле эш алып бара алмаганбыз. Гарнизон комитеты ни эшләсә, шуңа риза булып утырганбыз.

Ул ара да булмады, алгы рәттә утырган меньшевик Рясенцев сикереп торды, председатель кыңгыравы тәртипкә чакырып өзлексез чыңласа да, кәҗә сакалын селкетеп, яшел нәзек тавыш белән:

— Ирек бирмәбез! Булмас! — дип чинады.

Вак буржуаз партия вәкилләре, җылы яңгырдан соңгы гөмбәләр сыман, аннан да, моннан да калкып чыктылар, тәмәке төтене белән тыгызланган һавада сөякчел йодрыклар, фуражкалар уйнады, төрле яктан:

— Ирек бирмәбез! Без каршы! Булдыра алмассыз! — дигән, безнең колакка бик ямьсез ишетелгән тавышлар яңгырады.

Казан Советында ул чакта 215 депутат булып, состав ягыннан ул гаять чуар һәм эш итү өчен искиткеч катлаулы иде. Нибарысы сиксән большевик һәм аларга теләктәшләр янында, 45 сул эсер һәм аларның яраннары, 18 кеше социал-демократ интернационалистлар, калган 72 кеше уң социалистлар иде. Чуар, авыр состав. Соңгы төркемнән җыелышны ялгыш юлга өстерәделәр, ялгыш карар чыгартырга тырыштылар.

Большевиклар тиз генә бирешергә теләмәде, трибунага оратор артыннан оратор чыгып кайнарланып сүз әйтте, озак тартышканнан соң, кычкырыштан тамаклар карлыгып беткәч, депутатлар бер-берсенең якасына ябыша башлагач, җыелыш күпчелек тавыш белән гарнизон комитетын таратырга, аның вәкаләтләрен Советның солдат секциясенә тапшырырга карар кабул итте...

Мин бу фактны күзгә кереп торган дөреслекне яклап чыгу ул чакта ифрат кыен булганлыгын хәтергә төшерү өчен теркәп киттем. Шул ук көнне, күңелдән гел китмәслек тагын бер утырыш җыелды. Казан

Советының Президиум членнары, большевистик һәм сул эсерлар оешмалары житәкчеләре, социаль-демократ интернационалистлар, Мөселман социалистик партия комитеты әгъзалары, фабрика-завод комитетларыннан җаваплы иптәшләр — барлыгы иллedән артык кеше килгән иде. Көн тәртибендә тизлек белән хәл ителәсе бер генә мәсьәлә: губернадагы һәм шәһәрдәге контрреволюцион күтәрелешкә чик кую.

Докладны Ольκеницкий ясады.

Әлбәттә, контрреволюционерлар белән көрәшергә, аларны кулга алып, ачык суд каршысына бастырырга беркем дә каршы килмәде. Соңгы чик килеп җиткәнен һәммәбез дә аңлый идек. Я без аларны — я алар безне... Монда беркем дә каршы төшеп, икеләнеп маташмады: түземнең чигенә, актыккы ноктасына җиттек! Фикерләр бер ноктага тупланды дигәндә генә өр-яңадан таркалды да куйды: нишләргә — контрреволюционерларны атаргамы әллә юкмы? Яшәү хакына, тормыш намына җиңгән революциянең андый хакы бармы?

Ольκеницкий ышандырып, кыска-кыска җөмләләр белән сөйләде.

— Үзеңне кыйнап ташламасыннар дисәң, дошманны тукмарга өйрән. Канга-кан көрәш барганда ясалган ударларның кайсысы артык та, кайсысы бик урынлы икәнен кем белгән? Кем аны санаган?.. Без революция сагында торабыз. Эшли башлаган көненнән бүгенгә тиклем Казан чекасы әле беркемне дә — революциянең иң явыз дошманнарын да үлем җәзасына хөкем итмәде. (Бу урында Ольκеницкий миңа карап алды, нигәдер, икебез дә Винокуровны хәтергә төшермәдекме, дип уйлап алдым.) Безгә чека коллегиясе членнарына, бер тавыштан булганда, судсыз-нисез дә дошманнарны атарга хокук бирелгән. Моңарчы без ул хокуктан файдаланмадык. Әмма без төче камыр түгел, без Совет власте, пролетариат диктатурасы исеменнән эш итәбез. Без дошманнарга шәфкатьсез була белергә, ахыр чиктә, алар белән күз бәйләш — сукыр тәкә уйнарга җыенмавыбызны ачыктан-ачык белдерергә тиеш. Ак чехлар фетнәсе уңае белән чыгарылган, Ленин кул куйган Совнарком мөрәҗәгатен тагын бер кат җыелганнарның исләренә төшерәм: 10 июнь, 1918 ел. Барлык совдепларга җирле буржуазияне кискен күзәтү һәм фетнәчеләр белән каты куллы булу бурычы йөкләнә... Заговорчы офицерларны һәм хыянәтчеләрне мәрхәмәтсез рәвештә юк итәргә... Халык дошманнарына үлем! Иптәшләр! Әлерәк кенә юстиция халык комиссары итеп билгеләнгән Стучканың телефонограммасындагы карар белән дә танышыгыз.

Урта рәтләрдән һавада сызгырып бер кул күтәрелде, әмма Ольκеницкий аңа сүз бирмәде, үзе дәвам итте:

— Әйе, әйе, иптәш Шнуровский: сул эсер Штейнберг юстиция комиссары вазифасыннан азат ителгән, хәзер бездә яңа комиссар — большевик Стучка. Иптәш Стучка имзасы белән килгән беренче җитди сүз шуннан гыйбарәт: «Контрреволюция, саботаж өчен гаепләү чаралары кулланганда революцион трибуналларга чикләнмәгән хокук бирелә». Димәк, ревтрибуналлар суд тәртибендә үлем җәзасына хөкем итә алалар.

Залда нинди реакция булыр икән дип түземсезлек белән көтеп торам, юк, зал тын, зал уйга калган, барыбызның да күзләр Ольκеницкийда. Аның күзләре күренми дә диярлек, тонык утта пэнсне пыялалары гына тоташ ялтырый. Сүз сораучы да, калкынучы да юк.

— Әлбәттә,— дип дәвам итте Ольκеницкий, бу юлы аның тавышы тоныграк, калтырабрак чыкты.— Җинаять өстендә тотылган яки суд карары чыгарылган дошманнар, кабатлап әйтәм — Совет властеның иң явыз дошманнары — атылачак. Революция җиңгән беренче айларда эш аңа барып җитмәгән иде әле. Без революциянең тәэсир көченә дә, аның икеләнүчеләрне дә ияртә алу көченә тулаем ышана идек. (Бу урында ул тагын миңа карап алды). Хәзер хәл үзгәрде, кемнең кемлеге ачыла бара, әйтик, бүген халык судларының берәрсе генерал Красновның:«Сүз бирәм, сезгә каршы сугышмам!» — дип әйтүенә ышанып чыгарып җибәрер идеме икән? Краснов иреккә чыгуга ук Дон хезмәт ия-

ләрен канга батырды... Безгә каршы ак террор башланды! Самарадан алынган хәбәрләргә караганда, Учредительное собрание байрагын күтәреп, властька килгән уң эсерлар һәм меньшевиклар, явыз ак чехлар белән бергәләшеп, кот очарлык явызлыклар эшләгәннәр: большевизмда шикле һәр кешене тотып ябалар, үлем баржаларына, поездларга утырталар, большевикларны — совет хезмәткәрләрен, эшчеләрне судсыз-нисез аталар. Сигезенче июньдә, Самараны алган көнне «коммунистларны кыргыйларча эзәрлекләп шәһәр урамнарында тикшерүсез-нисез Самараның ревтрибунал рәисе Венцев, эшче шагыйрь Конихин, эшче большевик Аббас Алиев, әсир төшкән йөздән артык кызылармеец атып үтерелгән. Ишетәсезме, бу явызлыкны карагруһлар да, монархистлар да кылмаган, бу җинаятьләрне властька омтылган уң социалистлар эшләгән! Бездә, Казанда да, алар явызлык артыннан явызлык кылалар, мәкер җепләрен төрле якка сузып, аңнары үсеп җитмәгән эшче-крестьяннар арасына үтеп керәләр, заговор арты заговор оештыралар. Без аларның караңгы эшләрен беләбез, җирле, уң эсерларның Савинков һәм аның оешмасы белән турыдан-туры бәйләнештә торуын хәзер ачыкладык, бу юнәлештә нәтиҗәле тикшерү дәвам итә. Байтак контрларны кулга алып Мәскәүгә озаттык. Мәскәүдә, ВЧКада «Ватанны һәм ирекне саклау Союзы»ның материаллары бергә туплана. Хәзер Казан шәһәренең шушы ямanaты чыккан союзның һәм аның боевикларының җитди бер үзәге булуында һич шик-шөбһә юк. Безнең чекада Богданов, Нефедов кебек офицерларның — боевикларның эшен тикшерү тәмамланды. Болар — хезмәт халкына нәфрәтләрен яшереп тә тормаган Совет властеның кан дошманнары. Алар складларга корал туплаганнар, «өчлек»ләр оештырып офицерларны коралландырганнар. Дөрес, болар чит кеше ихтыярына буйсынып, ул ни кушса, шуны үтәп килгәннәр. Әмма чит кеше ихтыяры аларның шәхси үзмаксатларына да бик туры килгән. Эткә эт иярә, өер булып туплангач алар усалланганнан усаллана... Хәзерендә сәяси һәм хәрби хәлнең искиткеч киеренке булуын истә тотып, Богданов һәм Нефедов ише халык дошманнарының эшен ревтрибуналга тапшырырга дигән тәкъдим кертәм һәм, трибунал члены буларак, аларны атуны таләп итәчәкмен. Соңгы чик җитте!

Бу юлы тынлык озакка чыдый алмады, берничә урыннан шартлап ярылды, аннан-моннан сикерешеп торган кешеләр, бер-берсен уздырып сүз сорадылар:

— Сөйләргә телим! Миңа сүз бирегез! — дигән хәтәр авазлар яңгырады.

Казанның сул эсер лидерларыннан берәү — Казимир Шнуровский торып баскач та, тавышлар, болганулар шактый озак дәвам итте. Теге почмакта да, бу якта да кабынган аерым-аерым бәхәс учаклары, төрле якка сүз очкыннары чәчеп чатырдап, шаулап яна иде. Беркем беркемне тыңламый, һәркемнең сүз буасы бердәм ярылып киткән. Ольkenицкий керткән тәкъдим бөтенләй үк яңа булмаса да, әле бу хакта болай ачыктан-ачык, турыдан-туры сөйләшенгән юк иде шикелле. Атаргамы революция дошманнарын, әллә элекке кебек аларны тәрбия итеп, хак юлга бастырырга тырышыргамы?

Ольkenицкий кул хәрәкәтләре белән тынлык урнаштырырга тырышты, алай да булмагач бик озаклап җиз кыңгырауны селкеп, чыңлатып торды. Ниһаять, тавыш учаклары акрынлап сүнде, сүрелде.

— Григорий,— дип Шнуровский иң әүвәл Ольkenицкийга эндәште.— Хәзер без төрле партияләрдә торсак та, иске дуслар. Без университетта бергә укыдык, бер бүлмәдә яшәдек, жандармнар безне Чистайга да бергә сөрде, аннан да бергә кайтып төштек. Февраль революциясеннән соң, сәяси сәбәпләр аркасында, безнең юллар аерылды...

Кемдер калын тавыш белән:

— Шәхси мөнәсәбәтләрне калдырып торыгыз! — дип кычкырды.

Шнуровский тавышка игътибар итмичә дәвам итте:

— Сез — большевиклар — үзегезне эшчеләр партиясе дип атыйсыз,

ә без — сул эсерлар — үзебезне эшчеләр һәм хезмәтчән крестьяннар партиясе дип саныйбыз. Кемнең эшчәнлеге һәм программасы дөресрәк икәнен тарих ачыклар. Үзегезгә мәгълүм, бездә, Казанда, күптән түгел генә сул эсерлар партиясенең губерна конференциясе булып узды. Без, анысын да беләсез, революциягә катнашкан барлык партияләр белән хезмәттәшлек итү турында декларация кабул иттек. Гәрчә без сезнең, комбедлар төзеп, крестьяннарны «бусы — ярлы» «монысы исә — урта хәлле» дип аеруыгызга каршы, безнең өчен алар һәммәсе дә — бердәм хезмәтчел крестьяннар... Мин боларны залдагы иптәшләр сүзләремнең чын икәнен белсеннәр, намусыма ышансыннар өчен сөйлим. Безнең губерна газетасы «Җир һәм ирек өчен»нең «Көрәштә үз хокукыңны яуларсың» дигән девиз белән чыкканын беләсездер. Моны искәртү дә артык булмас. Бу көрәш туктаусыз дәвам итә һәм мин, иске дустым Ольkеницкий чыгышына өстәп, газетада басылган үз мәкаләмә игътибарыгызны юнәлтәм. Вәхәләнки, мин дә уң эсерларның һәм чехословакларның фетнәсенә кискен каршы чыгам! «Бездә, Казанда,— дип язам мин анда,— революциягә каршы көрәшкә чыккан акгвардияче оешма барлыгы беленүгә үк уң эсер Винокуровның кемлеге ачылды: фетнәчеләр килеп төшүгә, туп-турыдан аның квартирасына юл алганнар». Нигә Ольkеницкий аны төрмәдән чыгара? Беләм, ул үзенең тәрбия көченә, сүзенең ныклыгына ышанып чыгарган. Хәзер кайда ул? Кем аны чыгарырга булышкан?.. Беребез дә монысын белми. Бу мисал барыбызны да уйландырсын... Бүген тикшерелгән мәсьәләгә килгәндә, мин контрреволюционерларга үлем җәзасы бирү ягында. Эсерлар бер чакта да каннан курыкмадылар, үзләрен һәлак итсәләр дә, патша ялчыларын байтак кырдылар. Безнең вәкилебез Вера Брауде Казан чекасының председателе урынбасары, димәк, без сезнең эшләрне белеп торабыз. Шуны әйтмәкчемен, дошманнарны чека исеменнән атсак, бу аның абруен гына күтәрәчәк. Шуның өстенә, чека — вакытлы орган, димәк, атулар да вакытлы чара дигән сүз. Суд — аны ни дип кенә атасак та — дәүләт органы, буржуаз дәүләтләрдә дә суд бар. Акгвардияче дошман офицерларны чека исеменнән атуны яклап чыгам.

Бу мөһим җыелышта социал-демократ интернационалист Сергей Пионтковский, большевик Михаил Жаков, губком председателе Яков Шейнкман сүз сорадылар. Университет профессоры улы Пионтковский белән революциягә кадәр үк большевиклар партиясенә кергән Жаковның бу мәгълүм очракта гына түгел, башка чакларда да бер төсле сөйләүләре миңа сәеррәк тоелды...

Пионтковский (сезгә мәгълүм кеше!) Казан губернасы хезмәт комиссарының урынбасары иде. Тыштан акыллы сүзләр сөйләсә дә ул урап-урап, мәсьәләне чуалтып маташты.

— Террор,— диде ул,— сәяси көрәшнең бер төре, ачыграк әйткәндә, сәяси дошманнардан үч алу формасы. Элгәрге революцияләрнең һәр каюсында без бу форма белән очрашабыз. (Пионтковский белгечлеге буенча тарихчы иде, советта хезмәт итү өстенә ул университет профессоры Фирсовта аспирантура уза иде). Англия һәм Франция революцияләре чорында балтаны аксөякләр, корольләр генә татымаган. Маратны үтерүче Шарлотта Корденың да башы чабылган. Дөньяга һәм тарихыбызга ирек, тигезлек, туганлык идеяләрен, «Марсельеза»ны кешелеккә бүләк иткән Бөек француз революциясе мәшһүр гильотинаны да иҗат иткән. Революция уллары Робеспьер белән Дантонның башлары да шунда чабылган... Бездә исә башка төр социалистик революция. Кабатлап әйтәм — социалис-тик! Без гильотинаны куллана алабызмы? Аның белән янәшә яши алабызмы? Юк! Безнең революция үзенең иҗади эчтәлеге, кешелеклелеге, шәфкате белән дә көчле. Гильотинаны куллана алмый ул! Аның белән яши дә алмый. Узган гасырның буржуаз галиме, француз философы Тэн әйтмешли, «гыйльми кыюлык һәм ат печүче тупаслыгы белән бөтен кешенең аяк-кулын кисү» өчен түгел безнең революция. Кеше хакына ясалган революциядә кемнеңдер аңлы рәвештә җанын кыеп,

без үз сафларыбызны киметәбез. Кеше санын түбәнәйтәбез! Безнең белән килешмәгән өчен генә кемнедер таптап-сытып узарга безнең хакыбыз юк.

Тагын шау-шу, тагын тавышлар, берәүләр аны яклый, берәүләр тегене. Жаков сүзен өзеп әйтте:

— Безгә кол җаннар кирәкми. Безгә уйлау сәләтенә ия булган яңа фикер әйтерлек кеше кадерле. Революция җиле кагылмаган кеше илдә юк. Берәүләр аны шунда ук үз итте, икенчеләр икеләнде, өченчеләр ярсып-дулап каршы төште. Аның зарурлыгын, әһәмиятен, кирәген аңлар өчен Россиягә азмы-күпме вакыт кирәк. Бүгенгә берәүләр сүз белән каршы чыга, икенчеләр коралга ук тотыналар. Бүген корал тотып каршы чыгучыларның күпчелеге — офицерлар. Минемчә, аларның барысын да тотып ябарга гына кирәк. Яшәсеннәр, күзәтсеннәр, күрсеннәр. Теге дөньядан берәүне дә кайтара алмыйсың. Без француз революциясеннән үрнәк алырга тиешме? Андагы революциядә илдәге егерме дүрт миллион кешенең өч миллионы һәлак булган. Николай II ил өстеннән егерме өч ел идарә итте, самодержавие йөз илле мең кешене үтерде, бернича миллион россиян 1914 ел сугышы кырларында башын салды. Ил халкын кыруны без дә дәвам итикме? Мин барлык офицерларны концлагерьларга ябарга һәм гражданнар сугышы чорында берсен дә чыгармаска тәкъдим итәм. Уйлансыннар! Акылга килерләр бәлки. Акылга килгәч үзләренә оят булыр. Без патша генераллары, суды да түгел, шулай ук кан коючы фетнәчеләр дә түгел без! Без — законлы рәвештә туган халык власте, без җиргә «тынычлык, татулык» дигән сүзләр белән яралдык, әйдәгез алайса үз дөньябызның тынычлыгы өчен дә көрәшик.

Тагын сүзләр булды, болары артык хәтердә калмаган, мәгәр байтак чыгышларны мин язып барган идем, югарыдагы хатирәләрне күен дәфтәремнән китердем.

Йомгаклау сүзе белән Шейнкман чыкты.

— Мин Ольконицкийны хаклы дип саныйм. Җыелышта әйтелгән өч тәкъдимне тавышка куярдан элек, мин соңгы сүзне әйткән иптәшләргә каршы килүемне белдерәм. Совет власте халык дошманнарын ата аламы? Һичшиксез. Без — дәүләт, безнең җәза аппаратыбыз да, җәзалау органнарыбыз да бар. Илдә күпчелекнең тынычлыгы өчен, изелгәннәрнең ихтыярын тормышка ашырып, без изүчеләрне буйсындырабыз. Соңгыларына без кат-кат әйттек, бертуктаусыз кисәттек: басыгыз безнең сафларга, белемегезне, акылыгызны, осталыгыгызны туган халкыгызга бирегез, дидек. Сез боларның барысын да халык исәбенә ала алдыгыз. Сезгә рәхмәттән башка сүз булмас. Әгәр инде сез һаман безгә каршы атасыз икән, илдә элек булган буржуаз тәртипләрне кире кайтарырга маташасыз икән — без сезне юк итәрбез. Власть башына килгән эшче белән крестьян да моны таләп итми, идарәне үз кулына алган большевиклар партиясе дә моңа рөхсәт бирми. Без беркемне дә сүз өчен хөкем итмибез, безгә каршы коралды хәрәкәт өчен генә җәзалыйбыз. Атаклы рус язучысы Иван Сергеевич Тургеневның чәчмә белән язылган бер шигырендә шундый юллар бар: «Дошманыгызның җенен котыртып аңа зыян саласыгыз килсә,— диде миңа бер карт сукбай,— аны үзегездә булган яки барлыгы сизелгән бозыклыкта һәм гөнаһларда гаепләгез... Тузынган булып кыланыгыз... мәгәр гаепләгез!» Без Бөек француз революциясенең хаталары өчен җавап бирмибез. Җавап бирергә җыенмыйбыз да. Безнең революционерларны аскан-кискән Николайның кылган эшләрен нигезләр өчен тарихтан мисаллар эзлисе юк. Без яңа тарих тудырабыз, яңа тормыш төзибез һәм төзи белүебезне дә, төзелгәнне саклап кала алуыбызны да бөтен дөньяга исбатларбыз. Хәзер тәкъдимнәр кертү тәртибендә тавыш бирүегезне үтенәм.

Күпчелек Шнуровский тәкъдимен яклап тавыш бирде. Икенче көнне Казан газеталарында хәбәр басылды: «Контрреволюция белән көрәш комиссиясенең карары белән 18 июньдә Совет властена каршы коралды заговорда актив катнашкан Богданов белән Нефедов атылдылар».

Мин кайтканда өстәл һәрвакыт диярлек чип-чиста ашъяулык белән ябылган була. Сажидә апа я бәрәңге пешереп куя, я арыш кабартмасы. Карын ачып, арып кайтканда көнбагыш мае белән мул майланган арыш кабартмасы бик тәмле була. Сажидә апа ялынып сораса да мин самавырны кайнарлап тормыйм, аңа вакыт та, көч тә калмый, табында ни бар, салкын чәй белән шуны сыпырып куям да йокларга ятам. Сажидә апа мине көтеп тормый, йокламаган булса да үзенең нәни генә бүлмәсеннән чыкмый, сүз белән, сораулар белән мине борчымый. Бүген төн урталарында кайтып керсәм, ул тәрәзәгә карап басып тора. Минем аяк тавышларын ишетмәгән ахрысы, ишек шыгырдавына аптырап борылып карады. Мин аның нык кына борчылганын күз төбенә сибелгән күгелҗем җыерчыкларыннан ук белеп алдым.

— Хәерле кич, Сажидә апа! — дип юри тантаналы, күтәренке тавыш белән сәлам бирдем.

— Кичме, төнме, белгән юк...

— Нигә йокламыйсыз? — мин мич арасына кереп бит-кулымны юып чыктым.— Соң бит инде.

— Сезнең янга бер кыз кереп чыккан иде, Сережа улым.

— Кыз? Кем булыр икән ул?

— Сылу гына бала. Исемен Таня диде. Рус кызы.

— Бер сүз дә әйтмәдеме?

— Сезне «кайтмадымы?» дип кенә сорады.

— Хат-мазар калдырмагандыр?

— Юк.

Сүз шушының белән бетте, мин тастымалга төрелгән, әле бик суынып та өлгермәгән бәрәңге яркаларын тоз сибә-сибә бөгә башладым. Сажидә апа чыгып китми дә китми. Димәк, тагын нindидер йомышы бар аның. Мин ашавымнан туктап аңа күтәрелеп карадым:

— Авырмыйсыздыр ич, Сажидә апа? — дип сорадым.

Ул, күкрәген кулы белән тотып, ишетелер-ишетелмәс кенә йөткереп алды.

— Авырмыйм... Мәгәр йокы да алмый. Шуны сорамакчы идем, Сережа улым, синең чекада эшләгәнеңне беләм... Күршеләр әйтте. Алар каян ишеткәндер...

Мин елмаеп аны тынычландырырга теләдем:

— Эшемне яшергәнем дә юк минем,— дидем.

— Алаен алай да... миңә күршеләр бүген сөйләп тордылар... Сез мең кешене атып екkансыз димме, ун мең диме?.. Тагын атачаклар, имеш. Дөресме шул сүз?

Бәрәңгем чак тамагыма тыгылмады: ике кешене ату вакыйгасын телдән-телгә йөртеп, йөзгә-меңгә җиткергәннәр!

Ышандыра алдыммы икән Сажидә апаны, юкмы — белмим. Таңнан эшкә киткәндә ул үз бүлмәсендә калды. Безнең мөнәсәбәтләр үзгәрә башлавын мин шул төнне сиздем. Күршеләр аны туктаусыз котырталар ахрысы... Гайнулла белән ныгытып сөйләшергә кирәк әле, Сажидә апа янына кереп чыгып, мине яла-ялганнардан аралап калсын. Ягымлы татар карчыгының мәхәббәтеннән һич тә коры каласым килми иде минем!

Соңгы көннәрдә нindидер хәвеф-хәтәр сизену минем җанымны гел борчып тора иде. Сажидә апа белән сөйләшкәннән соң да җаныма тынычлык кайтмады. Таня килеп җиткән. Мин аңа кайда торуымны әйткән идем әйтүен, әмма кыз кеше, «килермен» дигән сүзе булмады... Килгән. Әллә ул да әнә шул тузга язмаган имеш-мимешләрне ишетеп борчылганмы? Әллә ул да мине Сажидә апа күршеләре сыман канлы куллы палач дип таныдымы? Әллә миңа берәр куркыныч яныймы? Әллә аның үзенә куркыныч киләме? Зоря сеңлесе ич ул, аны беләләр, аны минем белән янәшә дә күргәннәре бардыр. Сак йөрсәк тә качып йөрмибез

ич без! Сак булырга кирәген дә беләм, барыбер Таняны күрәсем килә. Урамда очрашмыйча кайда очрашырга соң безгә? Проломный урамында «Унион» кинотеатры бар. Анда барасым килми. Кафе-рестораннарга Таня керми... «Яратмыйм аракы исен, тәмәке исен женем сөйми!» — ди.

Бүген көндез Таняларга кереп чыктым, әтиләре өйдә юк иде, әнисен күрдем, Таня белән сөйләштем. «Ник безгә кердең?» дип сорамадым, ул үзе дә кереп чыгуы турында сүз кузгатмады. Димәк, болай гына, күреп чыгарга теләп кенә кергән булса кирәк. Шәһәрдә куерып арта барган гайбәтләр турында да ул аны-моны әйтмәде.

Танялардан жиңеләеп чыгып китсәм дә күңелдәге таш һаман эремәде. Кулга алынганнардан сорау алганда да, вакыйгаларны бер жепкә тезеп анализ ясаганда да таралып китә алмыйм. Гадәттә, йомгаклау сүзен Олькеницкий һәм жирле шартларны бик яхшы белүче, көннән-көн үсеп, ныгып барган Гайнулла Таһиров әйтәләр. Алар минем таркаулыкны, дәртсенеп китә алмавымны күрәләр, әлбәттә. «Шундый әле минем хәлләр!» дип зарланып алган идем, икесе тиң көлеп жибәрделәр.

— Алдан күрүчәнлек сәләтегез бармы әллә? — диде Олькеницкий.

— Моңарчы сизми идем,— дидем мин, сүзне уенга борырга теләп.

Таһиров миңа 19 июньдә чыккан «Революция байрагы» газетасын сузды:

— Алда сезнениләр көткәнен беләсегез килсә, Сергей Сергеевич, мин сызып куйган урыннарны укыгыз.

Газета битенә буйдан-буйга эре хәрефләр белән: «Бөтен Россияне иңләп капиталист, помещиклар, уң эсерлар, меньшевиклар һәм буржуазиянең Совет властена каршы контрреволюцион заговор жәтмәсе корылган. Башында уң эсерлар һәм кадетлар торган советка каршы оешма Казанда да яшәп килә. Иптәшләр, аларның коткыларына бирелмәгез, ялганнарына ышанмагыз!»

— Шәп әйткәннәрме? — диде Таһиров.

— Шәп!

— Димәк, күрәзәдән башка да әйтә алам: сезне алда зур мәшәкатьләр, моңарчы күрелмәгән хәлләр һәм йокысыз төннәр көтә.

— Куандырдың, Гайнулла, рәхмәт.

— Әле әйтеп бетермәдем!

— Әйткәнең житәрлек булды.

— Яман хәбәрләр көтә сезне, Сергей Сергеевич, һәм безне дә...

Бәхетсезлеккә каршы, яман хәбәрләрнең аягы жиңел, алар озак көттермәделәр. Андый хәбәрләр бер-бер артлы ишелеп өскә ава башлагач, бер мәлгә аптырап югалып та калдым... Теге кичне, Олькеницкий һәм Таһиров бергә утырганда, Таһиров алдагы көннәремә күрәзәлек иткәндә, Григорий Шмулевич Козьма Прутковның сүзләрен хәтергә төшергән иде:

> Есть бестолковица, сон уже не тот,
> Что-то готовится, кто-то идет.

Алай гына идеме соң монда!

Көндәлек мәшәкатьләр белән онытылып яшәгәндә кеше үзе яшәгән заман турында артык уйлап, баш ватып тормый. Яши, рәхәт күрергә омтыла, михнәткә дә чыдый. Һәркемнең үзе йөри торган сукмак-юллары, үзе белә, аралаша торган кешеләре була. Яши-яши кешенең яшәеш сферасы һаман тарая, ул үзенең бәләкәй дөньясына батып, шуннан тәм табып, юанып яши башлый.

Соңрак мин болай дип уйладым: безнең байтагыбыз тиешле дәрәжәдә әзерлекле иде, күбебез төрмә университетлары узган, күпме кыен ашаган, тукмалган, изелгән жаннар иде. Полиция камчы белән ярды безне, жандармнар, төрмә хадимнәре тукмадылар, палачлар безне издесытты, сөяк-саннакларыбызны сындырды, боларны чутлап, исәпләп бетерерлек түгел. Әйе, монысы аерата мөһим: үзләрен интеллигент санап йөрүчеләр, үзара очрашканда Бетховен, Шопен музыкасын тыңларга яраткан,

Ватан, тугрылык, изгелек турында суган саткан җәлладлар безне җәзаларга боерык бирделәр, хәер-фатыйха, сәдака белән дәртләндерделәр, кайчагында тәм табып җәзалауга үзләре дә катнаштылар. Кешеләрне кимсетү, мәсхәрәләү, кыйнау тәҗрибәсе бар иде аларда, алар аның мең төрле ысулларын уйлап тапкан, камилләштергән, җәзаны сәнгать дәрәҗәсенә җиткергән, җан ияләрен җәзалау яки атарга кушу алар өчен сукыр бер тиенгә дә тормый иде. Җәзалау, җәзаларга боеру, үтерү аларның төп кәсебенә әйләнгән иде. Без исә бу яктан бөтенләй тәҗрибәсез... Җәзаландык, әмма җәзаларга өйрәнә алмадык. Өйрәнергә теләгебез дә юк иде. Революциянең тәрбиясе бер: революциябез белән горурланган хәлдә, ул китергән чиксез зур үзгәрешләр белән куанып, без һәркемгә туганлык, дуслык кулы сузарга әзер идек. Ольксницкийның, акыллы большевикның, ата дошман Винокуровны бер җәзасыз-нисез генә чыгарып җибәрүе дә әнә шуннан килә. Революциянең бәрәкәтле җилләре канатландырды Григорийны. Мин боларын хәзер генә аңлыйм, мең кат уйлап, йөз кат үлчәп караганнан соң гына үзебезнең ул чорда бер-беребезгә искиткеч охшаган булуыбызны беләм, күңелләр киң иде безнең, күңелләр һәркем өчен ачык иде. Сузган кулыбызны һәркем жылы учына алмаслыгын белсәк тә, без көтәргә, аңлатырга, ышандырырга әзер тордык. Безнең күңелләр шәфкать-мәрхәмәт яралгылары белән тулып ташты.

Ә безгә көчләүнең сыналган ысулын — атып үтерүне тәкъдим итәләр...

Бер мин генә түгел, бик күпләр башта шулай уйлый иде: кешеләр туганда бөтенесе дә тигез булалар, бала ата-ананы сайламый, аларның кем һәм нинди булуында аның эше, гаме, катнашы юк. Милләте кем аның да иле...

Туганда тигез булалар... Вакытлар узу белән бераүләр икенчеләргә баш булып утыра...

Без властька саф йөрәк, якты йөз, иң изге теләкләр белән килдек. Жину шатлыгыннан исереп килдек, без килгәч моңарчы яшәгән дөнья тамырдан үзгәрер, властьны кулына алган халык үз-үзен кысмас дип ышанып килдек. Менә шуңа күрә дә үлем җәзасына хөкем итү, аны тормышка ашыру искиткеч кыен иде безгә. Менә шуңа күрә кешеләрнең, халыкның берне ун итеп, унны мең итеп сөйли башлавын ишетү читен иде. Күкрәкне ертып халыкка йөрәгебезнең саф, уйларыбызның якты, омтылышыбызның уртак икәнен күрсәтеп бирәсе килә иде. Революция бөтен кешене йокыдан уятты, бераүләрне, әйтик Гайнулла Таһиров кебекләрне ул якты идеаллар өчен көрәшнең иң хәтәр, иң дәһшәтле сызыгына китерде. Ә Сажидә апаның күршеләре ишеләр рәхәтләнеп сагыз чәйнәделәр, гайбәт тараттылар... Алар да уяу! Алар да революция кузгаткан дулкыннарда безнең белән бергә чайкалалар.

Бүген көндәлек хәлләргә Вера Брауде йомгак ясый...

Хәбәрләр бүген дә куанырлык түгел.

Фетнәче ак чехлар корпусы Идел буендагы барлык контрреволюцион төркемнәрне берләштерде. Моңарчы икеләнебрәк, посып яшәгән дошманнар да яктыга чыктылар: совет властеның көннәре санаулы дип исәпләде алар. Матбугатта француз хөкүмәтенең Самарадагы үз консулына махсус аңлатмасы игълан ителде: Идел төбәгендә Германиягә каршы Көнчыгыш фронт оештырырга һәм Брест солыхын юкка чыгарырга... Бурыч шул. Кыска һәм аңлаешлы. Дәһшәтле һәм кискен.

Фетнәчеләр Идел буйлап югарыга үрмәли, кушылу гына түгел, төрле урыннардагы кулаклар, элекке офицерлар, буржуа вәкилләре һәм милләтчеләр ярсыган түземсезлек белән аларны көтәләр иде инде. Куеннардан таш чыга, итәк астындагы пычаклар ялтырый, чормалардан пулеметлар төшә... Совет власте вәкилләренә ачыктан-ачык яныйлар, якынайган дошманны тантаналы каршылау өчен әзерләнәләр, чиркәү чаңнары чыңлый, мәчет манараларыннан азан тавышлары яңгырый. Итекләрне дегет белән мул итеп майлыйлар, өзәңгеләр тартыла, кылычлар

үткерләнә... Идел буе дошманнарына рух инә, җан керә. Ниһаять, большевизмны тар-мар итәрлек реаль көч килә! Меньшевиклар, уң эсерлар да тик ятмый, аларда да җанланыш: социализм, демократия дигән сүзләргә кушып ачы борыч тараталар, совет властеның көннәре санаулы калганын халыкка искәртәләр... Киләләр, киләләр, киләләр. Бетәчәк, бетәчәк, бетәчәк... Уңны сулдан аерып бетерә алмаган, пар нарат арасында аяз көндә дә адаша торган крестьян аптырап башын кашый: кемгә бил бөгәргә дә, кай якка карап чукынырга?! Меньшевиклар, эсерлар һаман бер балык башын чәйни: Россиянең киләчәген диктатурасыз-нисез генә, башында Учредительное собрание торган демократик федератив республика итеп күрергә тели алар. Властьның кайсы да булса класс интересларын якламавы мөмкин түгеллеген истән чыгарган булып кыланалар. Сүзләр, сүзләр, сүзләр...

16 июньдә кулаклар Тәтеш советын куып тараттылар. Соңыннан Тәтеш эшчеләре бу хәлгә бәя биреп: «Кулак койрыклары томана халык массаларының зиһенен чуалтты, азык-төлек белән тәэмин итүне юри кыенлаштырып, Совет властена каршы өзлексез хәйлә, коткы тараттылар, нәтиҗәдә халык массалары советка каршы күтәрелде»,— диделәр.

Әйе, авызыңнан ипине тартып алсалар, дус белән дошманны аерып бетерә алмассың. Бигрәк тә дошман дигәнең сарык тиресе ябынган булса, миләш куагына кунган былбыл булып сайраса...

Советларга, азык-төлек отрядларына, комбедларга каршы чыгышлар Чистай, Буа һәм Ядринск өязләрендә дә булгалады.

Без көне-төне эштә, мәшәкатьтә, хәрәкәттә...

Отряды белән Леонид Заковский кайтып төште. Мәшәкатьләр арасында Леонидны телгә алырга онытыбрак үтәм шикелле? Монда ул, исән-сау, кайтып та керми диярлек, кушканны җиренә җиткереп үти торган басынкы, намуслы, аз сүзле бу егетне иң авыр заданиеләргә җибәрәләр. Менә бүген алар, өч чекист, Карл Маркс исемендәге батальоннан бер взвод солдат алып Казан-Мәскәү юлындагы Свияжск станциясендә булганнар, каһәр суккан Сердобольскийны һәм шәһәрдән ычкына алган башка фетнәчеләрне эзләгәннәр. Ул үзенең кайларда булуын, ничек-ничек эзләүләрен шактый мавыктыргыч итеп сөйләсә дә, минем чыраем караңгыланганнан караңгылана барды ахрысы, Леонид ярты сүздә туктап калды.

— Авырыйсызмы әллә, Сергей Сергеевич?

— Фетнәчеләрнең шәһәрдән китеп эреп югалуларына җенем котыра! Димәк, аларны кайдадыр яхшылап каршылыйлар, яшерә беләләр. Чүп үләннең тамыры тирәнгә китә!

— Раифа монастырена сугылмакчы идек, барып җитә алмадык. Атлар хәлдән тайды. Анда Несмелов белән Копко, Лавринович һәм дүрт кызылармеец китте. Иртәгә кайтырга тиешләр.

Тик алар әйләнеп кайтмады. Кайта алмады. Шушы көнне алар һәммәсе дә һәлак булды. Аларның канлы һәлакәте болайрак булгандыр дип күз алдына китерәм...

Валентин Несмелов, Федор Копко, Петр Лавринович һәм дүрт сугышчы: Антон Барель, Иосиф Мазюк, Семен Акупов һәм Иван Бельчик монастырьга кичкырын гына барып җитәләр...

Капкадагы махсус тишектән якынаеп килгән атлыларны күзәтеп торган хадим, килүчеләрнең кем икәнен абайлагач, атлылар белән берике сүз алышып, яныл-пешеп игумен Варсонофий янына чабып керә.

— Атакай, хәрбиләр! Төн куныл чыгарга диләр. Совет властe вәкилләре дигән булалар.

— Маңгайларында йолдызмы?

— Йолдыз...

Варсонофий бер мизгелгә генә авыр уйга кала.

— Менә нәрсә, монастырьга кертмә син аларны. Бар, Сидор белән

Гаврилоны Бело-Безводный авылына җибәр. Тиз арада халыкны күтәрсеннәр. «Монастырьны таларга бандитлар килгән»,— дисеннәр. Ни бар, шуның белән коралланып таң ярылганда монда килеп житсеннәр. Ишетсен колагың: кораллансыннар! Ә мосафирларны «Килүчеләр йорты»на урнаштыр. Йокласыннар, иртән уятырбыз.

Соңгы сүзләрне әйткәндә Варсонофий хадим сизелер-сизелмәс кенә елмая, елмаюы куе сакал арасында бик тиз сүнә. Ул почмакка карап, бөгелмичә генә чукынып ала.

Игуменның тавышында зәһәр янау ишетеп, хезмәтче хадим тиз-тиз артына чигенә һәм озын чикмәненең итәгенә урала-урала чыгып йөгерә.

Варсонофий тагы бер тапкыр чукынып ала да иң ерак, иң аулак хөҗрәгә ашыга. Анда бернечә көннән бирле борынгы дусты поп Сердобольскийның улы Сергей белән тагын бер «кунак» яшеренеп ята. Сергей игуменга кунакның кем икәнен ачыкламый, ул аңа нигәдер гел фамилиясе белән «Михайлов!» дип кенә эндәшә.

Ашыгып барып кергәндә, Михайлов корал чистартып маташа, ашыгыч аяк тавышына икесе дә сискәнеп калкыналар.

— Килеп життеләр! — ди игумен уфылдап. Ашыгып йөргәннән аның майлы кабартмадай симез яңакларына тимгел-тимгел таплар бәреп чыккан.

— Шулармы? — дип сорый поп малае.

— Маңгайларында йолдыз ди.

— Ярый,— ди Сердобольский канәгатьлек белән.— Кунарга калалар алайса? Безне эзәрлеклиләр, мине.

— Мин авылга кешеләр җибәрдем,— ди игумен.— Килсеннәр, күрсеннәр...

— Дөрес уйлагансың, атакай,— ди Сердобольский тагын да ныграк җанланып.— Халык властеннан сезне гражданнар үзләре сакласын. Үзләре! Килүчеләрне мин дә күрдем. Берсен — чекист Попконы танадым да! Чекистлар алар. Безне эзәрлекли!

Алар Михайлов белән бер-берсенә мәгънәле карашып алалар, игумен белән сөйләшкәндә бер чакта да сүзгә катнашмаган Михайлов сиздермичә генә баш кага.

— Без Михайлов белән бу эшкә катышмыйбыз,— ди Сердобольский.— Без таннан кузгалабыз. Халык үзе хәл итсен. Үзләре!

Хезмәтче хадим янында Варсонофийның чыңлап торган тавышы йомшап кала:

— Шулаймыни?

Аның асылда кемгә таянырга исәп тотканын, иртәгәге вакыйгалар уртасында кемне күрергә теләвен аңлау кыен түгел.

Сердобольский өстәлдә яткан калын катыргы тышлы китапка ишарәли:

— Мин монда кайбер нәрсәләрне укыштырдым. Яше бар икән монастырьның, ике йөз илледән артык. Раифаны игумен Саватий башлап җибәргән, крестьяннарны монахларга хезмәт итәргә өйрәткән, христиан динен сакларга һәм көчәйтергә күнектергән. Аның изге гамәлләрен игуменнардан Гермоген, Герман, Адриан дәвам иткән. Хәзер менә сезнең чират, атакай. Алар дистәләгән еллар дәвамында тирә-як крестьяннарының рухына хуҗа булганнар, монастырьга карышусыз хезмәт итәргә, тукландырырга, хөрмәт итәргә һәм куркырга өйрәткәннәр. Ничә еллар дәвамында алар карышусыз буйсынып яшәгән. Карап карыйк, сез ул изге затларның эшен ничек дәвам итәсез икән? Сезнең кайсы гамәлләрегез шушы китапка язылып калыр икән, изге ата?

Игуменны эчке бер калтырау тетрәтеп уза.

— Хәзер һәркем үз эшендә булсын,— ди боерган тавыш белән Сердобольский.— Төн ярты лашкач, көнбатыш стенадагы капканы ачып куйсыннар... Шыпырт кына, сак кына!

Варсонофий абына-сөртенә чыгып китә.

Юл кешеләрне туганлаштыра. Юлда бер-береңне сыныйсың, бер-береңә күнегәсең, бер-береңнең эчен-тышын бик яхшы белә башлыйсың. Әгәр юл авыр икән, сиңа йөкләнгән бурыч читен һәм мәшәкатьле булып, ул синнән һәрдаим әзер булуны, сизгерлек һәм саклыкны таләп итә икән, юлдашларың берзаман туганнарыңа әйләнеп кала.

«Килүчеләр йорты»нда алардан башка берәү дә юк. Бу бераз сәер, чөнки монастырь атаклы, аны беләләр, изге урынга баш иярга ерак-ераклардан да халык өзелми иде. Хәерче-саилчеләр, илгизәр буш-буйдаклар, атай малын туздырып ертык ыштанга калган җилкуарлар монда кунар урын, каткан ипи сыныгы, бер җамаяк кайнар ясмык ашы өчен булса да килеп куналар иде. Бүген нигәдер йорт буш...

Шикәрсез чәйне каткан-коткан ипи кыерчыклары белән эчеп, аз-маз тамак ялгап алгач, кем кая — берәүләр ян сәкегә, берәүләр киң-киң агач караватларга ятарга җыенгач, Валентин Несмелов, гадәтенчә, фәлсәфәгә керешә:

— Заманында без Казанның политехникум студентлары идек. Хәзер чекистлар. Мин рус, Федор белән Петр белоруслар, безнең арада татарлар, украиннар, мадьярлар бар... Шуннан чыгып әйтеп була: дөньякүләм революциягә дә әллә ни ерак калмады! Без гаҗәеп бер тарихи язмышка юлыктык. Әле ярый, вакытын белеп туганбыз!.. Җир йөзендәге шакшылыкны себереп түгеп бетерүгә, һәркем үзе сайлаган якты юл белән китәр. Узган юлында эзләрнең яхшысын гына калдырырга кирәк. Брюсов, шагыйрь, болай дигән:

А мы, мудрецы и поэты,
Хранители тайн и веры,
Унесем зажженные светы
В катокомбы, пустыни и пещеры...

— Син шушы йортның түшәменә, караңгы почмакларына карап мәгарәләрне исеңә төшердеңме? — дип шаярта Копко, як-ягына карангалап. Ул ара булмый, бая чиләк белән кайнар су китергән хадим-хезмәтче килеп керә. Чиләкне алып чыгарга кергән икән, йокларга урнашып маташкан чекистларны, кызылармеецларны берәм-берәм күздән кичергәч, хадим тавышсыз-тынсыз гына чыгып китә.

— Ошамый бу хадим миңа! — ди Копко кинәт кайнарланып.

— Монда кунарга калып хаталанмадыкмы икән? — ди кызылармеецларның өлкәнрәге.— Монахлар — сатлык халык...

Валентин Несмелов кулларын баш астына кушырып чалкан яткан килеш һаман хыял дингезендә йөзә шикелле, хадимнең керел-чыгып йөрүенә аның бөтенләй исе китми.

— Без әлегә шагыйрьләр дә, хикмәт ияләре дә түгел, мәгәр без хәзер үк хикмәтле һәм шигърияттле дөньяның бер кисәге. Кисәге генә түгел, без — дөньяны үзгәртүчеләр, без халыклар яхшырак яшәсен дип тырышабыз, шуңа йөз тотып яшибез. Еллар узар, безне дә онытмаслар, безнең теләкләр тормышка ашар.

— Син, Валентин, шигырь укый-укый аз гына тегеләйгә, хыялыйга әйләнгәнсең,— ди сабыр акыллы Копко.— Халык онытмас имеш. Безне искә алып утырырга гына калган ди аларга! Йөгәнсез чаптар күк әллә кая барып керәсең. Сердобольскийны тотып аласы диген син! Шуның ишеләрне ятьрәк тотып бетерсәк, әти-әниләр белән тизрәк күрешер идек. Дошманнарның барын кырып бетерсәк, Белоруссиягә тизрәк кайтыр идек. Ошамый миңа бу урын! Хезмәтче-хадимнең майлы күзе, төче сүзе дә ошамый. Бу хөҗрәләр дә шик тудыра. Исе дә ят. Өстеннән бикләп алсалар, чыгармын димә. Болай итик без, егетләр, чиратлашып кына йоклыйк. Сез, әйдә, йоклагыз, мин сакта калам. Хәзер төн кыска...

Башкалар аның тәкъдимен хуплыйлар, кемдер «черки тешли» дип сукрангач, тәрәзәләрне дә ябып куйдылар. Копко, торып, тәрәзә бикләрен үзе тикшереп чыга...

Несмелов йокыга китеп кенә барганда кемдер аны төрткәләп уята. Копко икән, ул чамадан тыш дулкынланган.

— Торыгыз, тор,— ди ул пышылдап кына.— Йорт белән монастырь тирәсендә шау-шу, ыгы-зыгы. Каяндыр кеше җыела шикелле.

— Уят башкаларны! — ди Несмелов, йокысы ачылып.— Хәлне ачыклап карыйк.

Башкалар да тиз-тиз калкыналар, сәке такталары шыгырдый, кемдер сак кына йөткереп тә ала. Ул арада ишектән өчәү килеп керәләр. Каш астыннан бүредәй карап тын гына ишек катына басалар. Копко ишекне эчтән бикләгән түгел идеме соң? Бикләгән иде... Димәк, алар җаен белә, ача алалар.

— Сез кемнәр? — дип сорый Несмелов.

— Безнең кем икәнне белү читен түгел. Игумен Варсонофий ата ашыгыч йомыш белән китте дә мине үз урынына калдырды. Мин — Федор ата, ә болар Ермаков белән Гаврилов, крестьяннар.

— Сезгә бездән ни кирәк һәм ни өчен крестьяннарны ияртеп кердегез? Нигә алар монда? — дип сорый Несмелов тап-таза монахтан. Кара сакал арасыннан аның итләч гөреҗдә кебек калын иреннәре кызарып, майланып күренеп торалар. Түгәрәк төймә төсле зәңгәр күзләре чекистларны капшап әле берсенә, әле икенчесенә сикерә тегенең.

— Варсанофий ата монастырьны хәвеф-хәтәрдән, бандитлардан сакларга кушып калдырды.

— Нинди бандитлар? Кайда алар! Без дә шуларны эзлибез.

— Бандитлар менә сез инде.

— Без нинди бандитлар булыйк?

— Минем янымда иманлы крестьяннар. Аллага тугрылыклы алар. Кыңгырау кагып аларны мин җыйдым. Авыл бар монда, ерак та түгел, Бело-Безводное. Шуның халкы җыелып сезне хөкемгә чакыра. Карышмагыз, бирелегез.

— Без бандитлар түгел.— Несмелов белән Копко, үзләре дә сизмәстән, бер авыздан сөйли башлыйлар.— Без законлы совет власте вәкилләре, җинаятьчеләрне һәм бандитларны эзәрлекләп монда кердек.

— Алла йортына басып кергән бандитлар сез ул! — ди, ниһаять, крестьяннарның да берсе, телгә килеп.

— Берничә офицер-контрреволюционерның монда качып ятуы безгә мәгълүм булды,— дип тыныч кына дәвам итә Несмелов.— Без беркемне дә таларга, җәзаларга җыенмыйбыз. Монахларның тынычлыгын саклап, хәтта кичен дошманнарны эзләп тә маташмадык. Хәзер эш башка, бандитлар монда икән, аларны безгә тапшырасыз да, без китәрбез.

— Документларыгыз бармы? — дип сорый Ермаков атлы крестьян.

— Булмыйча! Менә, карагыз! — Несмелов белән Копко чека пичәте басылган, куллар куелган таныклыкларын сузалар. Федор атаның төймә күзләре кәгазь өсләп тәгәри, Ермаков та кәгазьләрне күзенә якын китерепкитереп карый.

— Ялган кәгазьләр! — дип кычкырып җибәрә Федор ата.— Ялган!

— Сез талаучылар, бандитлар! — дип куәтли арттарак торган Гаврилов.— Чыгыгыз әйдә! Без сезне кулга алабыз.

Лавринович наганын чыгарып кычкырып җибәрә:

— Әй сез, салам сыйраклар, кулларыгызны күтәрегез.

— Туктап тор, Петр,— ди Несмелов аңа.— Чыннан да бандит• дип уйларлар. Без хезмәт халкын яклаучылар, крестьяннарны, аңлыйсызмы? Әгәр безгә кул салсагыз, совет власте моны кичермәс. Бу бер. Соңра сезнең балаларыгызга, аларның балаларына оят булыр. Күрәсез, безнең явызлык кылганыбыз юк. Сезнең бәхетегез өчен, эшчеләр бәхете өчен көрәшәбез. Ә сез дошман сүзенә карап безне харап итәргә җыенасыз. Әйдәгез, егетләр.

Кызылармеецлар дүртәүләшеп сәке йөзлеге янында укмашып торалар, беренче булып ишеккә атлаган Несмеловка алар теләр-теләмәсрәк

иярәләр. Лавринович та, арттан килә-килә: «Кирәкмәс иде, Валентин!» — дип пышылдый.

Менә алар җидәү басып торалар: яшьләр, коралсызлар, һәлакәткә дучар ителгәннәр. Аларны сәнәк-балталар, мылтык һәм винтовкалар белән коралланган ике йөзгә якын крестьян камап алган. Арада картлар да, яшьләр дә, хатын-кызлар да бар. Нәфрәт, дошманлык тулы күзләре белән җиде егетне капшыйлар.

— Туганнар! — дип кычкырып җибәрә Федор ата, төркем өстеннән яшен чатнап узамыни, бөтен кеше уртага тартылып, кыймылдап куя.— Менә алар, күрегез: денсез дәһриләр, изге монастырьга, сезнең генә түгел, әллә ничә буын ата-бабаларыгызның терәге, яклаучысы булган изге урынга кул ягучылар. Алла каһәрләгән явызларны ни көтә? Аларны үтерергә, юк итәргә кирәк. Ходай үзенекеләрне таный һәм яклый ала.

Халык төркеме җанлы бер йодрык булып йомарланып, тагын бер адым алга күченә. Сулыш алулар ешая, борын яфраклары киерелә, таң йокысыннан айнып кына килгән күзләрне кан баса.

— Туктагыз! Нишлисез? — Вәкил булып кергән икенче крестьян Ермаков шулай дип кычкыра.— Документларын үзем күрдем. Җаныгызга язык өстәмәгез, христианнар!

— Ах, син алар беләнмени әле?! — Икенче вәкил Гаврилов Ермаковның баш түбәсенә балта түтәсе белән китереп ора.— Җәмәгать, кырыгыз динсез дәһриләрне. Безнең изге яклаучыбызны пычратып йөрмәсеннәр.

Халык, мичкәдәге балык кебек тыгызланса да, әле беркем дә алга ыргылып чыкмый, бер-берсенә кысылышып диярлек басып торган җиде егет, арадан яклау сүзе, теләктәшлек көтәләр. Лавринович кына кесәсендәге наганын капшап: «Эх!» — дип пышылдый.

Менә чекистларның аяк астына канга манчылган Ермаков егылып төшә, кан күргәч якындагылар ухылдап ала, һәм менә шушы кан аларны тәмам котырта. Кан чыгаручының Гаврилов, үз ишләре икәнен алар бер секундка оныталар, алар бары тик ермак булып агып төшкән кып-кызыл юлны гына күрәләр. Кан? Димәк, безнекеләрне кыйныйлар, гомер буе җәбер-җәфа күргән крестьян канын агызалар?!

Кыска һәм шәфкатьсез, уңны-сулны белми торган кыйнау башлана. Бертуктаусыз хәрәкәтләнгән — типкән, таптаган, сикергән аяклар арасыннан танырлыгы калмаган бер кызылармеец үрмәләп килеп чыга, аның корсагын сәнәк белән ярып җибәрәләр...

Ун минут та үтми, әле генә аякларында басып торган сау-сәламәт, яшь, чибәр, көчле кешеләр урынына туралган, суелган, изелгән канлы кисәкләр генә кала. Аларның чак-чак селкенгән, хырылдаган, яман ыңгырашкан гәүдәләре өстендә, арыш көлтәләре өстендә уйнаган чабагачлар кебек, балта-сәнәк, мылтык түтәләре уйнап тора.

Ниһаять, алар тына. Җәзачылар гына тынмыйлар, арттагы рәтләрдә басып торган хатын-кызлар, мыексыз егетләр, гомуми үлем исереклегенә бирелеп, алда торганнарны ера-ера уртага узалар, канлы ит кисәгенә әйләнгән гәүдәләргә һаман-һаман типкәлиләр, изәләр, балчык белән аралаштыралар...

—Кардәшләр! — дип кычкыра битенә, сакалына кан чәчрәгән Федор ата.— Гөнаһкяр җаннарны ут аша уздырыйк! Як учакны!

Гөрс-мәрс килеп торган имәндәй таза мужиклар, корып аугач агачларны тамыры-ние белән җирдән суырып чыгарып, китереп өяләр дә ут кабызалар. Кайсыберләренең җаны да чыгып бетмәгән гәүдәләрне дөрләп торган ялкын арасына ыргыталар.

— Ишегалдына боерыгыз! — дип чакыра кичәге хадим-хезмәтче. Ул арада кемнәрдер мичкәсе белән ачы бал тәгәрәтеп чыгаралар, ипи, бәрәңге, пешкән ит китереп өяләр. Варсонофий ата боерыгы белән төн буе пешкән ит калҗаларын чапы-чопы ашарга, сөякләрне шытыр-шытыр кимерергә керешәләр, җирән, кара сакалларның канын юып иякләргә ачы бал ага...

Икенче көн иртә белән Казан урамнарыннан канга манчылган башы ак сөлге белән уралган, кырынмаган, яңаклары суырылып эчкә кергән бер кеше ава-түнә бара иде. Очраганнарны туктатып ул чеканың кайдалыгын сорый да тагын кузгала. Аңа трамвайга утырырга киңәш биреп карадылар, ул кул гына селкеде дә, тагын җәяүләп китте. Бераз баргач чеканың кайдалыгын тагын сорады. Бу кеше Ермаков булып, часовой янына килеп җиткәндә аның аяк өстендә басып торырлык хәле дә калмаган иде. Алай да часовойга пышылдарга өлгерде:

— Анда... Раифа янында... сезнекеләрне яндырдылар...

Аны шул секундта ук госпитальгә озаттылар...

Өч пулемет белән коралланган интернациональ батальонның ярты рота солдатлары атларга менеп туктаусыз юрта-юрта монастырьга таба элдерә... Иң алдагы алмачуар атта Леонид Заковский бара. Аның йөрәгендә һәлак булган иптәшләре өчен үч белән бергә вөҗдан газабы да кайный. «Нигә аларны җибәрдем мин? Нигә? Яшь, тәҗрибәсез дусларымны һәлак иттем... Үзем анда булсам — мондый фаҗигага юл куймас идем!»

Кем болай булыр дип уйлаган?

Ул бу минутта үзенә дә нибарысы егерме дүрт яшь икәнен, әле алдагы көрәшләрдә, бөтен ил киңлегендә барган бәрелешләрдә, контрреволюционерларны эзәрлекләгәндә моннан да хәтәррәк хәлләр белән очрашасын күз алдына да китереп карамый иде. Ул иң шәп аттамы, әллә ирдәге хуҗасының йөрәк какканын ишетеп хайван ашкынамы, алмачуар шактый алга киткәч, Федор авызлыкны тартып, аны тыя, борылып иптәшләренә кул болгый:

— Тизрәк, тизрәк!

Ни ашыксалар да ярдәм инде соңга калган...

Бу үкенеч, бу кыйналу Леонид Заковскийның мәңге хәтерендә калачак. Мондый вәхшәтне, кешелексезлекне әле ул беренче тапкыр күрә...

Җан-фәрманга юрттырып килсәләр дә монастырьга якын бара алмадылар, бөтен яктан аны урап, тыгызланып җирдә крестьяннар ята иде. Атлар сөрлегеп шып туктадылар.

— Кайда безнең иптәшләр? — дип кычкырды ярсып Заковский.

Дәшмиләр, мышныйлар гына...

— Кайсыгыз башлады?

Җавап бирү түгел кымшанмыйлар да...

Заковский аттан төште:

— Безнең иптәшләрне харап иткән явызларны бирмичә торып без моннан китмибез! — дип тагын да катырак кычкырды Заковский. Сугышчылар аның янына пулемет сөйрәп китерделәр.— Ягез!

— Гөнаһтан курык! — диде ятканнардан берәү.

— Безне шүрләр дисеңме әллә?— диде икенчесе.

— Ил белән хөкем иттек. Я таптат, я кулыңнан килмәсә, юлыңда бул.

Заковский пулеметка тотынып, ятучылар өстеннән пуляларны сиптереп җибәрде. Кинәт тып-тын булып калды. Ул арада ялгыз аткан тавыш яңгырады һәм Заковскийның алмачуары баскан җирендә янтая башлады. Ул яңадан пулеметка тотынды. Ләкин кемгә атасың? Ничек? Алмачуарның шәмәхә күзләре ачык калды, ярасыннан күбекләнеп кан акты, бераздан ул бөтенләй тынды.

— Яхшы,— диде Заковский икеләнеп.— Без китәбез. Иптәшләрдән ни калса, шуны бирегез.

— Әнә, учактан ни калса, шуларны җыегыз. Христиан җаннар иде бит, әйбәтләп күмегез. Тик монда буталмагыз, монастырьны таларга барыбер ирек бирмәбез,— диде бая сүз башлаган тавыш. Кемдер, мыгырдап, аны куәтләде:

— Үлсәк үләрбез!

Сугышчылар юынылмаган калын такталардан берничә тартма ясап,

һәлак булганнарның сөякләрен шунда тутырдылар да Казанга юнәлделәр...

Допрос вакытында шул билгеле булды: 1918 елның апрелендә үк Бело-Безводная һәм Осиново авылларыннан таза тормышлы алтмышлап крестьянны игумен Варсонофий монастырьга чакырып ала. Ашка! Аш янына ачы бал да чыга, ак башлы шешәләр дә елтыр-елтыр йөреп китә, ике авыл «делегаты» шактый кызгач, күзләр томаланып, колаклары томалангач, игумен речь тота:

— Большевиклар динне дә, изге монастырьны да, беребезне дә җәлләмәсләр! Әгәр монастырьга һөҗүм-мазар була калса, православныйлар, ярдәмгә килерсезьбит?

— Безме, без хак юлда үлсәк үләрбез! — дип күкрәк кага «делегатлар»...

Кулга алынган монахлардан Голышев, Ретин исемнәрен, Бело-Безводныйдан Гаврилов, Осиново авылыннан Яныкин, Макаров һәм башкаларның исемнәрен атадылар. Чекистларны һәм интернациональ батальон сугышчыларын шулар газаплап үтергән икән.

Кулга алынганнар монахлар сүзенә тулаем ышанганнар, үзләрен хак эш, ходай кушканны башкарганнар дип исәплəгәннәр...

Большевистик «Рабочий» газетасы болай дип язып чыкты:

«Зөя өязе Раифа җирлегендә булып узган канлы фаҗига шаһитларын тыңлаганда ачудан һәм сыкранудан чәч үрә тора, йөрәк кысыла. Майлы пирогтан коры калган кара козгыннар — поплар һәм монахлар — аерым кешеләрне үлемгә дучар итеп революциядән үч алырга азапланалар. Эшче-крестьян властен тәмам юк итә алмасалар да, алар ачуларын шулай чыгармакчы булалар. Иң кабахәт, нәкъ менә руханиларча, попларча ысуллар белән эш итәләр...»

Иптәшләрдән калган изге сөякләрне күргәч,ниләр кичергәнемне аңлату кыен түгелдер. Контрреволюция корбаннарын — үз иптәшләремнең асыл сөякләрен беренче күрүем... Канлы җинаятьнең җиргә Тынычлык иңдерергә килгән Гайсә пайгамбәрдән фатыйха алып калган чиркәү әһелләре тарафыннан башкарылган булуы ачуымны тагын да ныграк арттыра. Белмим, нәфрәтләнүем шул кадәр көчле иде, үз-үземне белештермәс хәлгә килеп, Каллистов белән Шнуровский ишеләрне пыр туздырып ташлавымнан куркып, кабинетыма кереп бикләндем дә беразга ялгыз калдыруларын үтендем...

Телефон шалтырады. Трубканы озак кына алмый тордым. Һаман шалтырый... Минем монда икәнемне, эчтән бикләнүемне белеп шалтыраталар булса кирәк дип алсам, телефонда Таня!

— Сергей Сергеевич!

— Тыңлыйм, Таня.

— Сез мине күрергә теләмисезме?

— Син бездәге хәлләрне ишеткәнсеңдер инде?

— Ишеттем. Башта мин Сезне дә харап иткәннәр икән дип уйладым. Бик нык җыладым...

— Җыладыңмы?

— Бу дөньяда япа-ялгыз калам икән дип уйладым... Берүк үзегезне саклагыз, Сергей Сергеевич. Зорядан кала сез — миңа иң якын кеше.

— Рәхмәт, Таня.

Якын араларда кереп чыгарга вәгъдә биреп, трубкамны куйдым, чак кына тынычландым. Белә идем, чиркәү хуҗаларының «Чиркәүне дәүләттән һәм мәктәптән аеру» турындагы декретны бер дә өнәмәүләрен аңлый идем. Монастырь һәм чиркәү биләмәләренең дәүләт кулына күчүенә котырынулары да мәгълүм иде. 1918 елның гыйнварында чиркәү соборының «Православный халыкларга» мөрәҗәгате дә хәтеремдә. «Берләшегез, православныйлар! Ир һәм хатыннар, картлар һәм яшьләр, берләшегез дә изге урыннарыбызны саклаулык союзлар төзегез! Христиан

динен аяк астында калдыруга караганда бу дөньяда кан коеп, теге дөньяда рәхәт күрүе яхшырак!»

Нәкъ шул чорда Казан митрополиты Иаков «Православный динен саклауның Казан кардәшлеге»н оештырды, яшерен җыелышлар уткәрә башлады, листовкалар таратты. Совет властен бәреп төшерергә бөтен көчен җигеп, акча чыгымнары түкте. Монастырь биләгән җирләрне, башка мал-мөлкәтләрен саклап калыр өчен, монахлар «Хезмәт әртилләре» укмаштырып маташтылар. Аларның бу адымнарын аңлап та була иде әле: үз малларын кайгырталар! Дин әһелләре һәм монахлар якын-тирә крестьяннарын котыртып, куркыту максаты белән шундый канлы җинаятькә, губерна күләмендә беренче зур террорга җөрьәт итәрләр дип уйлау, аңа ышану кыен иде. Моңа үзләре генә тәвәккәлли алмас иде алар, моңа ук куллары бармас, куркырлар, шикләнерләр иде. Руханилар — сак халык. Алла «саклангынны сакларнын» дигән. Монда шәфкатьсез, тәҗрибәле кеше кулы уйнаган Сердобольский түгелме, әллә Михайловмы? Әллә алар икесе бергәме?..

Шушы, вакыйгалардан соң мин тагын бер нәтиҗәгә килдем. Без, кулыбызда булган күп санлы материалларга нигезләнеп, илдә барган фетнә җепләренең бер кулда булуын уйлап ялгышмыйбызмы? Аерым-аерым кешеләрнең, төркемнәрнең, группаларның ихтыяры туры килеп, алар бер-берсен белмәсәләр дә бер үк юнәлештә көрәш алып бармыйлармы икән? Чекистлар Раифага очраклы рәвештә диярлек барып кергәннәр. Аларны юк итү мәсьәләсен кемгәдер хәбәр итеп, киңәшеп эшләмәгәннәрдер ич!..

Эзләүләрне һич туктатырга ярамый, җөмләдән берсе, игумен Варсонофийдан да ныклы сорау алырга кирәк!

Ишек шакыдылар. Ольkеницкий керде.

Без аның кабинетында ешрак очрашабыз. Ул сирәк кенә, бик ашыгыч һәм мөһим булганда гына минем янга килеп керә. Мин Мәскәү вәкаләте белән килгән булсам да, ул монда чека башлыгы. Чека башлыгы гына да түгел, большевиклар партиясенең житәкчесе. Безнең очрашулар төрле характерда була. Ул миңа Казан турында, тирә-юнебездәге кешеләр турында озынрак та сөйләп ала, мин аның якты хәтеренә, меңнәрчә исемнәрне, саннарны күңелендә тота алуына гаҗәпләнәм һәм сокланам. Әгәр бер кеше турында бәһа әйтә икән, тормыш аны һичшиксез раслый. Ольkеницкий, кешеләрне бәяләгәндә, бер чакта да ялгышмый. Бу аның — тормыш тәҗрибәсе белән ныгытылган тумыштан килгән сәләте. Без моңарчы бер-беребезгә тулаем ышанып, ярдәмгә атлыгып, кулга-кул тотынышып эшләдек. Булды, хыянәтче Владимиров аркасында миңа да авыр сүзләр ишетергә туры килде. Тик монда бер мин генә түгел. Дзержинский да, Петерс та хаталана язганнар иде... Винокуров мәсьәләсендә мин дә Григорийга гаепләү ташлый ала идем... Ул чакта Григорий тагын бер зирәклек, акыл күрсәтте.

— Винокуровка теләктәшлек күрсәтмәдем мин, юк... Сезнең дустыгызның үлемендә аның да өлеше барлыгын белә идем. Мәгәр мин Винокуров өчен үтенгән югары кешене кызгандым. Хатыны! Хатынына хуҗа була алмады бичара. Тезгенсез, йөгәнсез зат булып чыкты хатыны... Әирләрнең һәркайсында да йомшак як була. Хатыннар аны тиз сизеп ала...

— Әсез, Григорий, кайчан өйләнергә уйлыйсыз?

Ольkеницкий уйга калды.

— Минем аңа вакытым житми. Миңа эшләр бераз җиңеләйсен инде,— диде. Шунда ук сорап куйды.— Ә сез?

— Бөтен дөньяда революция җиңгәннең икенче көнендә үк өйләнәм.

Ольkеницкий дәшмәде, ничектер, сынап, уйчан гына карап алды.

Бүген ул гадәттән тыш борчулы иде. Аның мондый минутларын очрата идем мин, ләкин күп вакытта, борчуларның сәбәбен белмәгән чакларда, ничектер кешенең халәтенә игътибар итеп бетермисең. Кешенең

үзе генә белгән серләре азмы әллә?.. Ә бүген, әле көрәштәш иптәшләрнең тавышы колак төбендә чыңлап торганда, безгә бер-беребезнең хәлен аңлау кыен түгел иде.

Керде, утырды. Минем хәлне сорашты, тазалыгың ничек диде, ашау-эчү мәсьәләсе белән кызыксынды. Сажидә апага рәхмәт укыдым. «Юкны бар итә белүче тылсымчы ул апа!» — дидем... Аннары икебез дә тындык. Тынлыкны бозарга мин дә ашыкмадым. Әгәр Ольkеницкий ашыкмый икән, аңа уйларга вакыт бирергә кирәк. Уй күп чагында ялгызлыкны ярата. Ялгыз түгел чакта да ялгыз гына уйланып була! Мин, мәсәлән, ялгыз йөргәндә күбрәк уйлыйм. Уй сиңа ияреп бара башлый, хуҗа булып алгач, уйны син ияртеп китәсең. Бара ул, очын гына югалтма. Һәм кайчагында һич көтмәгән нәтиҗәләргә китереп житкерә. Баштарак бөтенләй игътибар ителмәгән фактлар яңача яктырып китәләр. Уй — кодрәт ул! Уй фактларны үзе эзләп таба, үзе аралый, эресен хәтердә сендереп, вак-төяген жилгә очыра.

— Юк, монахлар үзләре уйлап чыгара алган нәрсә түгел бу! — дидем мин, баягы уйларымны аңа белдереп.— Монда кемнеңдер оста кулы уйнаган. Көпә-көндез чекистларны үтерергә базмаслар иде алар. Һәм кемнәрнеңдер бу канлы фажиганы гади «үч алу», «мужик бунты!» дип йомшартырга тырышуы да юкка түгел...

— Сез Каллистов, Шнуровскийлар нидер белгән дип расларга телисезме?

— Киресенчә, белмичә дошман тегермененә су коялар! Аларның теләк-ихтыярлары соңгы вакытта бик еш дошман ихтыярына туры килә. Әнә шул туры килүләр безне ялгыштырмый микән: без һаман бер кешене, үзәк фигураны эзлибез. Бәлки ул юктыр да?!

— Ә Савинков?

— Сәнәк күтәреп чыккан крестьяннар Савинковның барлыгын белмиләр дә булыр...

— Анысы шулай...

Без тегеләй дә, болай да фараз итеп утырганда, поп малае Сердобольский белән капитан Михайловның, крестьян арбасына утырып, Казан арты ягына китеп барганын без ул чакта белми дә, белә дә алмый идек... Алар арасында менә мондыйрак сөйләшү булганын да күз алдыбызга китерә алмадык...

— Шулай булырга тиеш,— ди Михайлов.— Шулай булыр да. Без баскан җирдә эз калырга тиеш. Канлы эз! Халыкны тетрәтеп, большевикларны яклаучыларга шом салып торсын безнең эзләр. Үзең читтә кала бел, башкалар кулы белән учактан ут көрә. Көрәсеннәр! Кемдер көрәргә дә тиеш. Ихтыярыңа буйсындыр, артыннан иярт һәм үзең юкка чык, югалып тор. Хәзерге көрәшнең бердәнбер ысулы шул. Иртәгәге көн тагын ни күрсәтер, әлегә без шулай көрәшергә тиеш.

— Бирсен ходай,— дип, Сердобольский чукынып ала.

Ярты төндә капка ачык булса да, алар еракка югалмый, шунда Раифа урманында «жирле хәл»нең ни белән бетәчәген бик кызыксынып көтәләр. Көтүләре бушка китми, эшлисе эш эшләнә, теләкләре тормышка аша...

— Мөгаен, сез хаклыдыр,— диде Ольkеницкий.— Иптәшләр арасында бик күп дошманнарны танып белгән Федор Копко бар иде. Хәзер мин калдым. Федор белгәннәрне мин дә беләм, бәлки артыграк та беләмдер әле... Алай да Федор Копконы югалту — Казан чекасы өчен зур югалту. Безгә чак кына җәһәтрәк кыймылдарга вакыт! Дошман хәзер беребезне дә аямый. Социалистларның сүз боткасы пешереп утыруы дошман файдасына...

— Сез Казимир Шнуровский белән һаман бергә яшисезме?

— Яшьлек дусты,— дип ачы елмайды Григорий.

— Шулаен шулай да...— дидем мин канәгатьсезлек белән.

— Бүген шимбә, 22 июнь,— дип дәвам итте Ольkеницкий.— Анда

матбагачылар пыр тузына икән. Меньшевиклар коткысына бирелгәннәр дә: «Әгәр меньшевик һәм эсер газеталары чыкмаса, эш ташлыйбыз!» — дигән шарт куйганнар. Барып сөйләшеп кайтасызмы әллә, Сергей Сергеевич? Үзем барырга уйлаган идем дә, бик ардым. Хәлем юк. Займищега Шейнкман янына барып кайтырга исәп. Шундый авыл бар безнең, Идел ярында, Мәскәү юлы өстендә. Табигате матур. Урман, коры чокырлар. Һава! Беркая чыга алган юк. Сөйләшергә дә кирәк...

«Тагын Винокуров турында түгелдер бит?» — ди уйлап алдым.

— Аз гына һава үзгәртәсем килә. Дүшәмбе иртәсеннән контрреволюционерларны күпләп кулга ала башлыйбыз. Кәнфитләнеп торуга чик куярга бик вакыт. Урыныма Вера Петровнаны калдырам.

— Бәлки сак алырсың? — дидем мин.— Хәлне беләсез: тынычлык юк.

— Булса ни? Партия комитеты секретаре сак астында йөри башласа, беләсеңме?..

Без кул бирештек, саубуллаштык...

Бөтенләйгә икәнен кем белгән?!

Матбагачылар янына бардым, сөйләшергә ярата торган халык, сүз бозау имезгән булыр иде, ярый., минем бәхеткә, арада коммунистлар да, теләктәшләр дә бар икән. Сүзне кыскартырга алар ярдәм итте, меньшевикларга тәлинкә тотучыларның тавышын алар тиз басты. Шаулаучылар да тынды, берсе, кызарынып-бүртенеп, уртада япа-ялгызы калды. Буаны ерып җибәрергә тырышучы ул икән. Шулай була бит, арага кергән бер бушбугаз кайчагында бөтен төркемнең тавышын баса, һушын ала һәм ялгыш юлга кертеп җибәрә.

Аннан соң туп-туры Зоряларга киттем. Капка төбендә мине көтеп торучы, иненә юка ак яулык салган Таняны күргәч, шактый ук гаҗәпләндем.

— Мин сезнең янга барырга чыккан идем, Сергей Сергеевич.

— Ә мин сезнең янга ашыктым!

— Әле ярый аймыл булмаганбыз. Өйгә рәхим итегез.

— Ярыймы соң?

— Әти өйдә. Аның да сезне күрәсе килә.

— Әллә?!

— Шәһәрдә төрле хәбәрләр йөри. Имеш-мимеш.

— Бары шуның өчен генәме?

— Белмим. Һич югында әрләргә түгел инде!

— Сезнең тәрбияме?

— Минем тәрбияме, аны да тормыш чарлыймы, ул сезне аңларга тырышып карый.

— Нәтиҗәләр өметле алайса?

— Шулайга юрыйк, Сергей Сергеевич.

Казанка елгасыннан ерак та түгел сирень агачлары эчендә утырган бер йорт, аулак ишегалды миңа торганнан-торымга ошый бара. Сиреньнәр азайган, аларның байтагысын төпләп, кояшлырак урыннарга бәрәңге, суган утырткannар. Әнә алар калкып, үсеп киләләр. Мин Таняны шушы түтәлләр арасында кайнашкан итеп күз алдыма китердем...

Безнең эшнең гаҗәп яклары бар инде! Көне-төне ыгы-зыгы арасында кайныйсың, сорау алулар, очраштырулар, усал сүзләр, каргышлар, нәләтләр, хәйләләр, алдаулар, ялганнар... Үзе бер бөтен дөнья! Бу дөнья синең җелегеңне суыра, бөтен барлыгыңны ала, башкача ярамый да: дошман белән көрәш синең бар көчеңне, булдыклылыгыңны сорый. Алай да... Шулардан арынып, тәрәзә төпләренә кына гөле үскән, суганлы шулпа исе аңкыган, өстәлгә чиста эскәтер җәелгән бүлмәгә килеп керү сәер... Аяклар тыңламый — кая басарга белмисең, урындык җайсыз, шыгыр-шыгыр китереп, төрле якка боргаланасың, табын янына утырсаң, кулдан кашык төшеп китә...

Сүзне Таняның әтисе башлады.

— Сезнекеләрне анда бик күп кырганнар дип сөйлиләр.

— Бар, андый күңелсез хәлләр дә бар.

Таняның әтисе дә, гадәттә, дөнья эшләреннән читтәрәк булырга тырышкан, катнашмау гына түгел, телгә алырга да яратмаган кеше бүген, һич икеләнүсез явыз үтерүчеләрне хөкем итеп, аларга нәфрәтен белдереп утыра. Мин Таняга борылып карадым. Ул сүзсез генә миңа баш иде. Чәй белән кинәнеп, шактый утырдым, аш та тәкъдим иткәннәр иде, ашыйсым килми дип, ризыктан баш тарттым. Чыннан да шулай иде, минә күпме вакыт тамагымнан аш үтми, укшыта, тагын әллә ниләр... Алар аңладылар, артыгын кыстамадылар. Таняның әтисе тагын шул темага әйләнеп кайтты.

— Һәлак булучыларны бик яшь булганнар дип сөйләделәр.

— Асылда яшьләр,— дидем мин.

Ул чекистларны һәм кызыл сугышчыларны, вакытсыз улларын югалткан әти-әниләрне кызганып, тагын ниләрдер сөйләп алды.

Таня мине капка төбенә кадәр озата барды. Аннан ары барырга үзем рөхсәт итмәдем.

— Мин синең өчен бик курыктым, Сережа,— диде ул, телефоннан әйткәннәрен кабатлап. Телефоннан бер нәрсә, хәзер ул үз сүзләрен моңлы күз карашы белән беркетте, минем учларымны ике куллап кысып алды.

— Әлегә исән-саумын, Таня.

— Сезне үтергәннәр дип уйладым. Хәтерлисезме, теге чакта: «Алда һәммәсе дә яхшы булачак!» — дигән идем.

— Хәтерләмимме соң, Таня?!

— Хәзер тагын бер кат юрадым: әгәр бу юлы исән икән, Сережа, бик озын гомерле була дидем.

— Бергә яшик, Таня.

— Мин дә озак яшәячәкмен. Ходай миңа Зоряның гомерен дә бирәчәк.

«Ходай» сүзен ишетеп, кинәт куырылып киттем, тәнем буйлап ут йөгерде, анда, Раифада да ходай исеменә ышыкланып җаннарын кыйганнар бит безнең иптәшләрнең! Ходай исеме белән, аллага таянып, аның шәфкатенә ышанып....

Ул минем кулны озак кына җибәрмичә торды, алай да без башка чактагыдан корырак аерылыштык сыман. Ходай сүзе миңа шулай тәэсир иттеме? Шулдыр, башкача булмас. Тик ул аны аңламады, күзләрен тутырып карап басып калды. Борылып карадым, ул һаман басып тора, күзе юлда, Таня йомшак кына итеп кул болгады...

Ярдан тауга менеп җиткәч, нәни генә бакча бар. Шунда мин Таһиров белән Фәридәне очраттым. Алар бергәләп каядыр баралар иде. Җәй... яшьлек... Дөнья, ничек буталган булса да, һаман үзенекен итә. Гайнулла белән Фәридә арасында нидер барын моңарчы да сизенгәли идем, тик минә хәзер, бөтен дөньяларын онытып янәшә баруларын күргәч кенә барын да аңлап алдым... Яшьлек, яшьләр... Аларның мине күрмәүләрен теләдем. Икәү генә баруның тәме югалмасын... Култыклашмаганнар, янәшә генә баралар. Татар яшьләренең бер-берсенә мөнәсәбәттә ифрат дәрәҗәдә чиста, саф булулары хакында миңа кемдер сөйләгән иде. Гайнулла үзе түгелме?

Күңелемә динчеләр яккан учакта яндырылган иптәшләрем килде. Несмелов, Копко, Лавринович... Дөнья! Син нинди мәрхәмәтсез! Сөрсеп беткән игуменнар, монахлар ихтыярына буйсынып, күпме яшь иптәшләрне харап иттең. Алар да нәкъ минә шулай, Гайнулла Таһиров кебек, чәчләрен иңенә үреп салган сылу кызлар белән янәшә бара алалар иде бит. Мин дә бүген, алкаланып аккан Казанка суына карап, куанып, Зоря белән бергә уза ала идем ич...

Ә иртәгә? Иртәгә без булырбызмы?! Таня «озак яшим»ди. Бу теләк кенә ич. Барлык теләкләр тормышка ашса икән ул!

Ашса икән дә...

Якшәмбе — бездә ял көне түгел, бездә, гомумән, ял көне юк, якшәмбе агымдагы эшләр белән узды.

Дүшәмбедә мин соң чиккә җитеп дулкынланган, борчылган Шейнкман каршысында утыра идем... Ул китергән хәбәр коточкыч, аңа ышануы кыен...

— Безне атарга алып киттеләр. Алдан Олькеницкий белән Коршунов бара, хатыным белән мин алар артыннан. Үтерүчеләр хатыныма: «Син кал!» — диделәр, әмма ул калмады. Рәхмәт аңа: өйдә калырга ризалашмады. Ялынмыйбыз да, карышмыйбыз да, ни булса булган, сабыр гына барабыз. Урман ешлыгына кердек. Коры елгадан ерак та түгел: «Тукта!» — дигән команда яңгырады. Үтерүчеләрнең берсе Коршуновка: «Ә син китә аласың!» — диде.

— Коршунов китмәдеме?

— «Бәхил булыгыз, иптәшләр»,— диде дә китә башлады. «Ханым да китә ала!» — диде шул ук кеше. Коршунов бераз ерагайгач. Хатыным безне ташлап китүдән өзеп баш тартты. «Үтерсәгез, бергә үтерегез!» — диде. Аның белән артыгын вакланып тормадылар. Мин Софья белән дә, иптәш Олькеницкий белән дә бәхилләштем. «Без әзер! — диде хатыным.— Тизрәк атыгыз». Хатынымның кыюлыгына да, минем яннан китмәвенә дә сокландым... Кинәт: «Таегыз моннан икегез дә!» — дигән боерык яңгырады. Мин: «Без үлемнән курыкмыйбыз, нигә җилкәгә атарга? Күкрәккә атыгыз!» — дидем. Безнең борын төбендә наган көпшәсе уйнатып торган матрос: «Китегез, кит!» — дип кычкырды. Нишләргә? Григорий Шмулевичны ялгызын калдырып китәргәме, юкмы? Мин аңа таба борылдым, ул үзенә төбәлгән револьверга карап тыныч кына басып тора иде. Күз карашымны сиздеме, борылып миңа карады. Күз чите белән генә китәргә ымлады. Без күз карашларыбыз белән саубуллаштык та китә башладык. Кемдер арттан Олькеницкийга: «Ә син каласың!» — диде.

Кырык-илле адым китә алдыкмы икән, арттан бер-бер артлы өч тапкыр аткан тавыш яңгырады... Үлем күзенә тыныч һәм горур карап торган Олькеницкийны мәңге онытасым юк.

Үтерүчеләрне табу нәкъ миңа Шейнкманга йөкләнде. Һәм ни өчен Олькеницкий гына атылды дигән сорауга җавапны да ул табарга тиеш булды.

Ни булганын чекада безгә шаһитлар: Шейнкман үзе, аның хатыны Софья, Казан өяз советы председателе сул эсер Коршунов сөйләп бирделәр. Берсенең сөйләгәне икенчесенекенә рас килде. Коршунов болай диде:

— Алар бишәү иде. Егерме биш белән утыз арасындагы кешеләр. Икесе матрос киеменнән, икесе яшелдән киенгән, берсе кибетчегә охшаган, башында картуз...

Мин Коршуновны кыстым:

— Займищега нигә бардыгыз? Җитмәсә үзегез белән портфельдә йөз мең сум казна акчасы да алгансыз. Бусы бик шикле! — дидем. Җавабында шик-мазар күренмәде:

— Ял көне алган акчамны банкка тапшырырга өлгермәдем. Кайда калдырыйм ди аны? Өяз җир бүлеге акчалары. Банкка тапшырырга дип шуннан алган идем. Юлда барганда Григорий Шмулевич очрады. Займищега барыйк, дип ул әйтте. «Янымда казна акчалары»,— дидем. «Иплэп кенә йөрербез әле»,— диде.

— Займищеда ниләр булганын бөртекләп, җентекләп сөйләп бирегезче.

— Григорий Шмулевич белән Шейнкман дачасына бардык. Кичкырын, эссе бераз басылгач, дүртәүләшеп Идел буена төштек, көймәдә йөздек. Каефләр яхшырды, Григорий Шмулевич студент җырларын җырлап барды, ишкәккә дә утырды. Ярга чыгып тагын дачага юнәлдек. Кич

булды, карангы төште, авыл янындагы күпергә җитәрәк биш кешене очраттык.

— Кайда?

— Нәкъ безнең каршыга киләләр иде. Мин иң алдан бара идем, каршыга килүчеләрне крестьяннар дип уйладым. «Дачага дөрес барабызмы?» — дип тә сорадым җитмәсә. Анда күлләр, әрәмәләр, адашуың да бик тиз. Алар җавап биреп тормадылар, якынрак килделәр дә корал чыгардылар: «Күтәрегез кулларыгызны!» — дип акырдылар. Акча янда чакта кесәмдә ике револьвер йөртәм, икесе дә янымда. Яков Семенович та коралны. Ялдан кайтабыз бит, ваемсыз идек, күз ачып йомганчы алар безне коралсызландырды. Ольковицкийдан корал чыкмады. Алар эшне законлаштырып маташкан булалар, ниндидер таныклыкмы, буш кәгазьме сузалар, ә укып карарга рөхсәт итмиләр! Янәсе, алар намуслы совет кешеләре, хәзер безне — Болак арты заманында бай татарлардан талап алган алтыннарны дачада качырып яткыручыларны — тикшерәләр! «Алтынны үз ихтыярыгыз белән тапшырыгыз, аны хезмәт халкы арасында намус белән бүләбез!» — дип шаулыйлар. Бирмәсәк, тентеп бездән сорау алачаклар...

Нишлибез, аптырадык. Дачага якынайсак, анда кара болыт булып халык җыелган, бөтен авыл тузгыган: власть вәкилләренең алтын кайтарганын карарга килгәннәр. Бандитлар закончa кыланган булалар, халык арасыннан пүнәтәйләр сайлап алып, дачаның бөтен почмакларын актарып чыктылар. «Сумкага күзләре төшмәсә генә ярар иде!» — дип дер калтырап торам... Әлбәттә, бернинди дә алтын тапмадылар, күз төшәрлек әйберләрнең барысын җыеп алдылар, иң ахырда гына минем сумканы абайладылар... Акча чыккач, шашып сөенделәр! «Әһә, күрәсезме, менә ничек яши комиссарлар! Безгә сукыр бер тиен бирмиләр, ә үзләре ялга да меңәр сум акча тыгып йөриләр!» Бандитлар шашына, ә крестьяннар ләм-мим, дәшми, авызларын йомганнар да тик карап торалар. Бандитлар: «Халык, без кулга алынганнарны шәһәргә алып китәбез!» — дип белдерделәр. Ә үзләре безне яңадан Идел ярына алып төштеләр. Егерме икенче июньнән егерме өченә төнге сәгать икеләр чамасы иде. Яктыра башлады... Раифа вакыйгалары гел истә, безне дә шулай харап итәләр икән дип уйлаганда, мине беренче итеп җибәрделәр. «Бар,— диләр,— ычкын тизрәк моннан!» Нигә икәнен белмим, аңлата да алмыйм. Мин тиз генә авылга чаптым, крестьяннар таралмаган иде әле, нидер сөйләшкәләп аптырап басып торалар. Мин: «Бандитлар алар, яхшы кешеләргә ярдәм кирәк! Зинһар, булышыгыз!» — дип ялынып-ялварып, каткат үтенсәм дә, беркем селкенеп тә карамады. «Сезне белер хәл юк, барыгыз бер чыбыктан сөрелгән, без катнашып, ни файда?» — диделәр. Ат сорыйм, бирмиләр, акча вәгъдә итәм,тыңламыйлар. Беренче поезд белән үк шәһәргә кайттым һәм чекага йөгердем. Шейнкманны азат итеп Ольковицкийны үтерүләрен соңыннан гына белдем. Булганы шушы, Сергей Сергеевич...

Якшәмбедә Шейнкманнар да, ирле-хатынлы, шәһәргә кайткан...

Җинаять урынына машинага төялеп чекистлар китте, атлы милиция отряды кузгалды. Беркемне дә таба алмыйча, алар мәрхүмнең гәүдәсен алып 24 июньдә көндезге уникеләрдә генә кайттылар. Займище урманнарын аркылыга-буйлыга тарап, Идел буе әрәмәләрен, күл тирәләрен караштырып бетерсәләр дә бер дә ят кеше күренмәгән. Крестьяннар беравыздан: «Кая киткәннәрдер, белмибез»,— дип җавап биргәннәр.

Казанның иң тәҗрибәле, иң яхшы чекистлары дошманны эзли чыкты. Барлык эзләү эшләре белән Вера Брауде җитәкчелек итте. 25 июньдә Таһиров аргы Үсия тирәсенә урнашкан хәрби частьтә ике исерек матросның «Без комиссарның башына җиттек!» — дип мактануын ишеткән... Матрос киемле Емельянов белән Плотников дигән бандитлар, җинаятьтә катнашкан өченче кеше белән бергә, тиз арада кулга төштеләр.

Өчесеннән бик күп акча һәм Шейнкман белән Коршуновның револьверлары табылды...

Таһиров белән Брауде сорау алалар, мин катнашып тыңлап утырам. Оператив яктан караганда монда артык катлаулы нәрсә юк иде, өчесе дә чак кына айну белән җинаятьләрен таныдылар, әмма төп гаепне иптәшенә сылтап үз хәлен җиңеләйтергә маташтылар.

Өчесе дә бер исемне — моңарчы безгә бер дә ишетелмәгән Александр Ивановичны атады.

Өчесе беравыздан:

— Комиссарны Александр Иванович белән килгән офицер өч тапкыр тәрәп атып үтерде. Мәетне ташлап калдыргач Идел буена төштек, чылбырдан өзеп алып балыкчы көймәсенә төялдек тә Ерак Үсия тирәсендә Иделне кичтек. Болында акчаны бүлештек. Һәркемгә унбиш-егерме мең сум тиде. Аннан кем кая таралдык, без частька кайттык,— диделәр.

Тагын ике кеше... Алар бик теләп тегеләрнең тышкы кыяфәтләрен сурәтләп бирделәр, утыра торгач, берсе тагын да мөһим фактны хәтерләде.

— Аткан офицер белән сөйләшкәндә Александр Иванович бер сүз ычкындырды: «Михайлов Ольконицкийны һичшиксез юк итәргә боерды»,— диде. Әйе, ишеттем! «Моның өчен бүләк икеләтә булыр!» — дип тә өстәде...

Бандитларны шул ук көнне аттылар. Шнуровский, Каллистовлар да бандитларны яклап авыз ача алмады, явызлыкның нәтиҗәсе күз алдында иде.

Калган ике бандитның эзе икенче көнне Биектауда калыкты.

Браудега чеканың яшерен хезмәткәре Галимов шалтыраткан. «Бу тирәдә ике качкын йөри»,— дигән. Брауде, тизлек белән өч-дүрт милиционер табып, Галимовка качкыннарны чекага алып кайтырга боерган. Галимов тәҗрибәсез шул. Ялгышкан, өч милиционерны качкыннар кәефләнеп утырган бай йортына озаткан да үзе телефонга киткән. Өч милиционер, ачык авызлар, бай йортына барып кергәннәр, әмма аларга авыз ачарга да ирек бирмәгәннәр, бандитлар үз яннарындагы кешеләрне котыртып өлгергәннәр.

— Мужиклар,— дигән алар,— милиция формасы киеп алган бу кешеләр — талаучылар, алар Казаннан бирле безнең эзгә басып килә, документларны күрдегез, без — совет хезмәткәрләре, намуслы кешеләр, ә боларны тотыгыз да ычкындырмагыз!

Милиционерларны камап коралсызландыралар һәм подвалга бикләп тә куялар. Ә бандитлар, атка төялеп, көлә-көлә чыгып чабалар...

Бер-ике сәгатьтән мыштырдап Галимов килеп җитә, ул телефон аша: «Бандитларның эзенә төштек, милиционерлар аларны кулга ала, тагын нишләргә?» — дип сорарга барган икән.

Кайтып керсә, күрә: бандитларның эзе суынган! Җирле халык Галимовны таный — эшнең ничек булганын сөйләп бирәләр... Милиционерларны чыгаралар, алар пыр тузып эзләп китәләр, тик кая ул, җил артыннан куып җитеп кара... Юк инде, ычкынганнар, сызганнар.

Ул чакта аларны тотып булмады, атна узгач кына, Казанда бандитлар барыбер килеп каптылар...

Башта ук мине дә, Браудены да, башкаларны да бер сорау газаплады: нигә алар Ольконицкийны гына үтергәннәр соң? Нигә башкаларны азат иткәннәр?

Шейнкман бу җәһәттән болай дигән иде:

— Нигә безне җибәрделәрме? Тулаем аңлату кыен... Китәргә кузгалуга ук, безне арттан аталар дип көттек. Инде исән-имин җибәргәч, болай дип уйладык... Алар башта: «Кайсыгыз Шейнкман?» — дип сорадылар. Безнең кемлекне алар бик яхшы белә иде! Бәлки минем өчен акча алганнар да, качып китте дип, тагын да зуррак бүләккә өметләнгәннәрдер?.. Пычрак халык, шакшы алыш-биреш! Бик ихтимал!

Болай дип тә уйларга була...

Шейнкман белән Брауде үтерүне сәяси җинаять дип санадылар. Әмма, үзен үтерергә ниятләп, Ольkеницкийны очраклы гына харап иттеләр дип уйлап, Шейнкман ялгыша иде. Якын киләчәк бандитларның нәкъ менә чека председателен үтерергә әзерләнүләрен раслады да. Контрреволюционерлар аны — Григорий Шмулевичны юлдан алып ташларга ашкынганнар һәм теләкләренә ирешкәннәр дә.

Брауденың тагын бер җитди шиге бар иде.

— Ольkеницкийның Займищега баруын бандитлар Коршунов аша белмәделәрме икән? Ул да минем кебек үк сул эсер. Әмма мин аңа ышанып бетмим. Аның үзе белән шул кадәр акча алуы да бик шикле. Бандитларның беренче булып аны азат итүләре дә юкка түгел. Ничек аңлатырга моны? Коршунов аларның элемтәчесе булган да эзгә ул төшергән. Бүтәнчә аңлату мөмкин түгел.

Казан өяз комитеты башкачарак хәл итте: Коршунов гаепсез, аның талануы — очраклы вакыйга, моннан болай совет члennарына җәмәгать акчасын тотырып йөрү катгый тыела дигән карар чыгарды.

26 июньдә бөтен Казан Григорий Шмулевич Ольkеницкийны, Раифада һәм Осиновада һәлак булган чекистлар белән сугышчыларны соңгы юлга хөрмәтләп озатты. Ольkеницкийның табутын студенты буларак, университетның Баш бинасыннан алып чыктылар...

26 июньдә газеталарда Петроградта Володарскийның явызларча үтерелүе һәм Александра Коллантайның Казанга килүе хәбәр ителде... Газеталарда төрле хәрби частьләрдән хәбәрләр басылган. Уч, уч, уч... Дошманнарга аяусызрак булырга чакырулар...

Газеталарны читкә куеп, уйланып ятам: күңелдә таш, уйларда өермә. Таня белән очрашырга вәгъдәләшкән идек, ул кереп тә чыккан, ә минем кылны кырыкка яра торган көннәрем. Сәҗидә апа: «Ябыктың, бала, суырылып калдың, ашамыйсың, йокы күрмисең»,— дип әрли.

Ятам уйланып. Уйларым һаман шул бер тирәдә әйләнә.

Үтерүчеләрнең икесен табарга, җинаятьнең асыл сәбәбен ачыкларга кирәк әле... Димәк, Казан контрреволюционерлары беренче адымнары итеп чекистларны үтерүдән башлап җибәрделәр... Димәк, «Чекистлар нидер белә!» — дип шүрләгәннәр... Димәк, чекистлар дөрес юлдан барганнар. Димәк, алар эзгә төшкән...

Ә моны контра каян белгән? Кем аларны сагайткан да кем чекистларның нидер белүен хәбәр иткән?

Июнь ахыры... Көннәр озын, төннәр кыска. Төннәр, кыска булса да, вакыйгаларга бай, мәшәкатьле. Фатирга чекадан якын гына урнашуыма сөенәм: кирәк чагында иптәшләр бик тиз артымнан килеп җиталәр.

Ай азагында яңа мәшәкатьләр туды. Борчылулар өстәлде... Боларны бергә төйнәргә дә яңадан үзебез теләгәнчә чишәргә дә кирәк иде. Вакыйгалар аерата куерып киткәндә, барыбыз да Григорийны юксынабыз.

— Ул булсамы? — дип ярсый Таһиров.— Бер минутта җавабын табар иде!

— Эх, монда хәзер Ольkеницкий җитми! — дип уфтана Леонид Заковский.

Вера Петровна дәшми, ул иреннәрен генә тешли... Без аның да сугышчан иптәшне юксынуын аңлыйбыз.

Көнчыгыш фронтның командованиесе Казанда ныгыды. Озаккамы? Шәһәр партия оешмасы барлык коммунистларны корал тотарга, сугыш эшенә өйрәтә башлады. Акрынлап хәрби коммунистик дружиналар оешты. Мөселман эшчеләр һәм кызылармеецлар атаклы Юнысов мәйданында җыелыш уздырып, Ленин исеменә телеграмма суктылар, мөселман пролетариаты исеменнән юлбашчыны: «Халык Комиссарлары Советының изге чакыруларына җавап итеп, корычтай нык бирелгән сугышчылар булып калырбыз, революция дошманнары белән көрәштә юлдан тайпылмабыз!» — дип ышандырдылар.

Губсоветның мандат комиссиясе Казан Советы составыннан уң пар-

тияләрнең бөтен вәкилләрен чыгарып ыргытты. Ун эсерларның, меньшевикларның һәм бунтчыларның вәкаләтләре гамәлдән чыгарылды. Большевистик оешмаларда партия таләбе ныгыды: комитетлар өч тапкыр җыелышка килмәгән әгъзаларны партиядән чыгару турында карар кабул иттеләр.

Казан чекасының яңа председателе итеп Павел Андреевич Кин билгеләнде.

Таныштык. 1903 елдан большевиклар партиясе члены, Харьковта совет власте урнаштыруда актив катнашкан, июнь аенда хезмәткә чекага җибәрелгән.

Яңа кеше белән эшли башладык. Кеше яңа булса да мәшәкатьләр шул ук, хәтта бераз киңәйде дә. 1918 елның 1 июлендә Казан губерна башкарма советының Президиумы чеканың исемен бераз тулыландырып «Контрреволюция, спекуляция һәм саботаж белән көрәш буенча Гадәттән тыш тикшерү Комиссиясе» дип атарга карар чыгарды, сметасын раслады, тентергә һәм кулга алырга ордер бирергә хокук бирде. Хезмәткәрләргә өләшенгән «Кагыйдәләр»дә мондый таләпләр бар иде: «Йомшак телле, нык, каты куллы булырга... революцион тәртипне тайпылмыйча сакларга», әгәр, явыз ниятлеләрнең эзенә төшсәң, «чаң кагып, шылтырап йөрмәскә, кабаланып эшне бозып куюың бар, шыпырт кына өсләренә барып чыгып, җинаятьләрен какшамас дәлилләр белән раслый алсаң, иң яхшысы шул булыр!»

Төштән соң безне Брауде җыеп алды. Заковский, Таһиров, өчәү янәшә утырдык. Көтәбез. Брауде барыбызны да чакыра икән — уен түгел, димәк, нииндидер хәвеф килә, аны бергәләп кенә хәл итәргә мөмкин. Июнь ае тәҗрибәсе безне шуңа өйрәтте.

Чыннан да, хәл тагын да кыенлаша, куркыныч тагын да тармаклана, киңәя иде...

— Иптәшләр,— диде тигез, нык тавыш белән Брауде.— Ак чехларның һәм комуч гаскәрләренең Идел буйлап өскә таба үрмәләвен барыгыз да беләсез. Алардан дәрт алып, контрреволюция кара канатын ныграк җәя. Кулак фетнәләре ешая һәм усаллана бара. Контрреволюция ачык террорга тотынды. Бөгелмә өязендә Совет власте өчен көрәшкә чыгарга өндәп йөргән ике иптәшне — Екатерина Петровская белән Степан Просвиркинны ак патруль кулга алган. Аларны, поездга утыртып, Самарага озатканнар. Туймазы белән Ютазы станцияләре арасында иптәшләр тәрәзә ватып качарга маташканнар. Шунда аларны атып үтергәннәр...

Хәвефле хәбәрләр куанычлар белән аралаша — бөтен ил буйлап бәрелеш, көрәш кыза бара: Смоленск чекистлары «Безнең ватан» дип аталган монархия яклы союзның көнбатыш бүлек штабын тар-мар иткәннәр. Штаб башында генерал-майор Дорман торган. Кулга алынганнар арасында иске армиянең штабс-капитаны Борис Урядов та була. Тыңлагыз әле, менә гаҗәп: Борис Урядов ул якларга, Казан савинковчыларына ярдәмгә дип, Идел буе ак гвардия отрядларына офицерлар җыярга барып чыккан икән! Димәк, казанлы ак эмиссарлар савинковчыларны бер урынга мәрхәмәтсез булсыннар!»

Дошман, көч туплап, һаман тынмый икән, безгә дә оешканрак төстә эшли башларга вакыт түгелме? Июль уртасында Мәскәүдә Гадәттән тыш комиссияләрнең 1 нче Бөтенроссия конференциясе булып узды.

Аның материаллары безгә килеп җитүгә, Казан чекистлары бергә җыелдык. Конференция «Чека бөтен тармакларда Совет властеның таянычы булырга тиеш!» — дигән резолюция кабул иткән иде. «Советлар Россиясе дошманнары нинди төскә кереп маташсалар да, чекистлар аларга мәрхәмәтсез булсыннар!»

Җыелышта чыгыш ясаган Николай Углов болай диде:

— Тәкъдим кертәм: хәлнең киеренке икәнен искәреп, совет власте дошманнарын, яки дошман булулары ихтимал икәнлеге күздә тотыл-

ганнарны кырып-себереп кулга алырга да, концлагерь ачып, һәр барчасын шунда тутырырга!

Гайнулла Таһиров аңа каршы төште:

— Ансат! Революцион законлылык кайда алайса? Коммунист һәм чекист намусы, вөжданы кайда?

— Башкача мөмкин түгел! — дип әтәчләнде Углов.— Алар безнекеләрне һаман кыралар. Кайчанга кадәр түзәргә?

— Әгәр үзеңне гаепләү материалларыннан башка хөкем итсәләр? Гаепләүчеләр турында ни уйлар идең? Куркытып һәм җәзалап кына халыкны үзеңә ышандырырмын дип уйлыйсыңмы? Вакытлыча буйсындырырсың, анысы булыр, әмма бер көнне шеш тишелер, без капчыктан төртеп чыгар! Син үзең бәреп төшергәннәрдән кай ягың белән аерыласың алайса? Мин дә контра белән парма-пар сугышырга әзер, тик ул закон белән нигезләнгән булсын. Кылган гамәлләреӊ өчен соңыннан үкенергә калмасын инде.

Мәрхүм Ольковицкийның Таһиров турында әйткән сүзләре хәтеремә төшеп, сөенеп куйдым: егет ай үсәсен көн үсә! Кулында гел китап күрәм, Фәридә белән укып утыралар, бәхәсләшәләр...

Угловны да аңларга мөмкин. Чекистлар көне-төне аяк өстендә, юлда, яңгыры-җиле аларга юк кебек, чыгалар да китәләр. Төн дәвамында керфек какмыйча постта. Өйләнмәгәннәр өйләнмичә йөри, өйләнгәннәр гаиләләрен, балаларын күрми: очрашырга вакытлары да, җайлары да табылмый. Карышып торучы юк, зарланмыйлар. Дошманны тизрәк юк итәсе килә, хисләр ташый, күңел ашкына, ә мөмкинлекләр чамалы гына... Кайчандыр укылган Гете сүзләре хәтеремә килә: «Кеше гәүдәсе хачка, тормыш теориягә охшаган». Әлбәттә, тормыш үзенекен итә, һәр теориягә төзәтмәләр кертә. Теория практика белән генә раслана ала... Без җәзалау практикасын да тормышка ашырырга тиеш. Ашырабыз да. Әгәр бөек Пушкин хакында «гашыйк булган саен, тормышның гүзәл мизгелләрен бөек каләме ярдәмендә мәңгеләштереп калдырган» дисәк, без хезмәт халкы дошманнарын тар-мар итеп, аларның тамырын корыту өстенә, нәсел-нәсәбен дә каһәрле язмышка дучар итә идек... Нишлисең, каһәрле исем тагып, хурлык баганасына кадаклап без дошманнарны да үлемсез иттек... «Революция дошманнары» дигән кара тамга тагып, тарихта без аларның да исемен озайттык... Бу исем белән шаярырга ярамаганын без ул чакта ук аңлый идек, атылган дошман үзе генә түгел, аның варислары, нәсел-нәсәбе дә шушы исем күләгәсендә гомер итәчәк! Балта чапсаң — йомычка чәчри диләр руслар. Углов һәммәсен концлагерьларга тутырырга тели, ә без — күпчелек, йомычкаларның азрак очуын теләдек. Каһәрләнгән язмышка дучар булганнар үзләренең ни сәбәпле шушы хәлгә төшкәннәрен аңласын дип тырыштык...

Әйе, боларның барын да үлчәп-нитеп тора башлагач, көндәлек гамәлләрдә дә ялгыш җибәрүең дә, хаталануың да бик ихтимал иде, мәгәр без курыкмадык, каушамадык, дөреслекне эзләдек һәм табарга теләдек. Әгәр үзең ялгыш җибәреп, азагында үзең генә михнәт чиксәң, бер хәл! Инде синең ялгышларың аша башкалар интегә икән, бу ялгышларыңның дәвамы аның нәсел-нәсәбенә күчеп бара икән — монда сак булырга кирәк! Сак булырга! Теләсә кемгә гаеп ташлау җиңел ул. Гаепләнүчене аңларга кирәк, аңларга! Безнең максат шул иде.

Әйтик, җыелышта: «Барыбыз да укырга омтылыйк!» — дип сөйләшкән идек, комендант ротасыннан берәү торды да:

— Барыбыз да укысак, эшне кем эшләр? — дип сорады.— «Син дә мулла, мин дә мулла, атка печән кем сала?» — дип татарлар юкка гына әйтмәгән.

Һәркем укып, үз эшен белемгә нигезләп башкарса, гомуми эшкә файда гына булыр! дип аңлатып кара син ул туң күчәнгә. Әйттек, көлемсерәде, башын иеп утыра бирде. Уенда ни — кем белсен. Акыллыны аңлау кыен түгел, акылсызны аңлау читен.

Чекистлар арасында белем дәрәҗәсенең тигезсезлеге, белемнең чамалы булуы бик нык сиздерә иде. Гомуми карарлар кабул иткәндә дә иптәшләрнең әзерлек дәрәҗәсен бик нык истә тотарга кирәк иде. Шаушу, сүзләр, кул чабулар, бар да кул күтәрә, ә асылда? Җыелыштан соң алар ни сөйләшә? Ни аңлады алар? Сөйләп, эшне бозып куюың да бар. Бозылган эшнең дәвамы озакка, елларга сузылса, ни хәл итәрсең?..

Уйлар өзек-өзек килсәләр дә, бер юнәлештә иде, ялгызлыгымны бүлеп, кабинетка Фәридә Ибраһимова килеп керде. Чырае көлсыман сорыланган, кулын, бәйләп, муенына аскан.

— Сезгә ни булды? — Сикереп торуымны сизми дә калдым. Госпитальдә очрашканнан бирле мин аңа аерата җылы мөнәсәбәт саклыйм, Гайнулла белән дуслыгын белгәннән соң бу мөнәсәбәт тагын да җылынды.

— Без Галимов белән «Москва» кафесында әлерәк кенә, Олькеницкийны үтерүчеләрнең тагын берсен тоттык. Атты явыз. Менә, күрәсез... Кафеда утырабыз, карыйм: бөтен төс-кыяфәте килә. Галимовка күрсәтәм. Икәүләшеп күзәтәбез: ул! Галимов аның янына барды...

— Кайда ул?

— Таһиров кабинетында.

— Докторда булдыгызмы?

— Булдым. Бәйләде, ятып торырга, әз-мәз хәл алырга кушты.

— Чыннан да, ял итегез. Үзгәреш булса, шунда ук хәбәр җиткерегез.

Бер ачылган ишектән Фәридә белән чыктык: мин, кабаланып, Таһиров янына кердем.

— Сөйләшмәскә маташа! — диде шактый ярсыган Таһиров, урыныннан калкынып.— Галимовка аткан, Фәридәне яралаган. «Бандитлар дип белдем!» — дигән була. Галимов чека таныклыгын күз янына китереп күрсәткән мөртәтнең.

— Сез кем буласыз? Сөйләгез! Сез контрреволюция белән көрәш комиссиясендә. Чека председателе Олькеницкийны үтерүдә гаепләнәсез,— дидем мин аңа тын тартырга да ирек бирмичә.— Өч мәртәбә аңа сез аттыгызмы?

Тынлык берара дәвам итте, Фәридәне яралаган кешенең төксе чыраеннан көләгә йөгереп узды.

— Әйе, мин аттым. Бу егет мине күзмә-күз очраштыру белән өркетә. Ни пычагыма? Хәзер хыянәтләр заманы. Берәүгә дә ышанмыйм. Беркемгә дә! Мин элеккеге поручик. Исемем Михаил Коростылев. Председателегезгә мин аттым һәм обоймадагы пуляларны чәпәдем! Берсе дә бушка китмәде... Нәрсә? Мин ундүртенче елдан бирле җан кыям. Төннәрен күз алдымда канлы шәүләләр уйный, барыбер кыям!.. Без Керенский белән Гатчинога бардык. Ул миңа яхшы, тыныч тормыш вәгъдә итте. Алдады! Мине гел алдадылар! Шуңа күрә әйтәм — туйдым революцияләрдән. Яшермим, мин большевикларга көн күрсәтәчәк түгел, шул хәлгә житкерермен, аларның варислары, «революция» сүзен ишеткәндә, дер калтырый торган булыр. Туйдым!

— Өметең бушка,— дидем мин.— Житешә алмассың. Менә мин үк синең юлыңны кисәрмен! Сез әле дошман гына түгел икән, сез — куркыныч авыру йоккан җинаятьче! Нормаль кеше җан кыюга иялəшә алмый. Хәзер әйтегез: сезнең иптәшегез кем иде? Кайда ул? Александр Иванович кайда? Җавап бирегез!

Коростылевның яңак итләре тартышты, сул күзе йомылып-йомылып алды, ул буыннарын шытырдатып бармакларын язды.

— Менә кем кирәк икән әле сезгә! Ул минем сыман үтерүче түгел, аның иманы сакланып калган. Әйдә, аны да тотыгыз, бергәләп үлү күңеллерәк булыр! Бик күп җаннарны җәһәннәмгә олактырдым, инде үземә чиратмы? Бәйрәм булсын әйдә, тотыгыз аны да! Мин — үтәүче, ә ул шул гамәлләрнең асылын ачыклап бирер. Бүген кич, соң гына, без аның бе-

лән очрашырга сүз куешкан. Ул мин эләккәнне белми, барам көрешергә! Вәт тамаша булачак!.. Ул мине урамда, йорт артында көтеп торачак. Әгәр килүче мин булмасам, яки янымда башка берәү барса, каршыга чыкмаячак. Аны буш кул белән ала алмассыз. Ул иманлы кеше. Ә мин туйдым, кабар җирем калмады. Ул эләкмәс!..

— Безне карама көленә утыртыргамы ният? Сезне ялгыз чыгарып җибәрәбез дә әл-лүр аннары, ә?!

— Нигә? Баш төзек чакта уйлап карарга ярый.

— Адресы? Фамилиясе?

— Малая Проломная, 7, квартирасы 2. Вадим Вырвач. Кисәтеп тормый, төп-төз ата.

— Кулга алынганны одиночкага! — дидем мин конвойга.— Күз карасы кебек саклагыз.

Авыр аяк тавышлары колакны ярды...

Ни өчен Коростылев «Москва» кафесына килгән? Кем белән очрашырга теләгән? Башын куркыныч астына куеп шәһәр уртасына кадәр үтеп кергән икән, мөгаен, аның бик ашыгыч йомышы булгандыр... Әгәр Мөнәвәр Галимов белән Фәридә чак кына көткән булсалар... Әгәр... Юк, юк, алар көтә алмаганнар, түземнәре җитмәгән: күз алдында Олькеницкийны үтерүче утырсын әле! Ярый, тегә матрослар үз иптәшләренең төскыяфәтләрен бөтен ваклыкларына кадәр дөрес тасвирлаганнар икән. Фәридәнең күзе үткен, ул чамалап алган...

— Кин янына керик,— дидем мин Таһировка.

— Сергей Сергеевич,— диде Гайнулла тукталып.— Рәхмәт инде сезгә.

— Ни өчен?

— Дошманнарның бер эше минем тәҗрибә азлыкны чамалап ала. Миңа карышып маташкан иде, сезне күргә, шунда ук җебеп төште. Нинди сихерегез бардыр...

Кин янына киттек, барышлый Заковский белән Николай Городецкийны ияртеп.

Сүзне үтә кыска тоттык: белгән адреска дүрт чекист белән Городецкий барачак. Йортта кем булса — шуны кулга алырга. Квартира буш икән — икәү эчтә засадага калырга. Кемдер адашырмы, атап килеп керәме, эчтәге егетләр аны чыгармыйлар, тоткарлыйлар. Якын-тирә йортларын күзәтү өчен алты кеше алып, Таһиров сакка бара. Мин Коростылевтан сорау алуны дәвам итәм. Кем өчен һәм нигә килгән ул кафега?

Эш ашыгычка киткәч һәм кыенлашкач, алдан корган планнар сүтелеп тә куя...

Городецкий бара, йортны таба, буш квартираның ишеген җайлап каерып ачып, эчкә уза. Төне буе эчтә утыралар. Таң алдыннан гына билгесез берәү ишек шакый. Ишек ачып, аны эчкә уздырабыз дигәндә генә тегә бәндә ике револьвердан ата башлый. Атыш тавышына Таһиров группасыннан ике кеше йортка якынлаша. Бандит чекистларның берсенә ата, икенче чекист, яраланган иптәшенә булышырга дип, бер секундка гына неләә. Ул арада өйдән засадагылар да атылып чыга... Таһиров бандит артыннан үзе чаба. Тегә, борылып, нәкъ аның аяк астына граната ташлый, бәхеткә каршы граната ярылмый. Бандит йортлар арасына кереп югала. «Эх, ычкындырдым!» — дип уйлый, граната килеп төшкәч бер читкәрәк тайпылган Гайнулла... Ул арада ишектән себеркесен тотып урам себерүче килеп чыга һәм, сакалының очын селкеп, ишегалды почмагындагы сарайга күрсәтә. Гайнулла акрын гына алга бара, почмак артында качып торган бандитның тупас итек башларын абайлый. ул да булмый атыш тавышы яңгырап, Таһировның яңагын пуля сыдырып уза...

Кара-каршы атыш барышында бандит үлә... Карыйлар, коралларын алалар, документлары юк...

Байтак вакыт үткәч, ике чекист утырган квартирага ир белән хатын

керә. (Городецкий белән Таһиров: «Атыш тавышын бөтен шәһәр ишетеп бетергәндер, әйтелгән адреска инде беркем дә килмәс!» — дип, хәлне аңлатыр өчен чекага кайтып китәләр, таныр өчен мәетне дә үзләре белән алалар).

Өй эчендәгеләр «чакырылмаган кунаклар»ны тавыш-тынсыз гына эләктереп алалар, коралсызландыралар һәм тып-тын гына утырырга боералар. Чекистларның берсе телефоннан шалтыратып, машина һәм конвой сорарга чыгып китә.

Шактый утыралар. Ир кеше:

— Су эчәсем килә,— дигәч, сакта калган чекист, револьверын каешына кыстырып, чүмеч белән су алып килә. Чүмечкә сузылган кул билдәге коралны суырып чыгара. Хәзер урыннар алышына, бандит чекистка тын утырырга боерык биреп, ишек янына сакка баса, икенче чекист бусаганы атлап керүгә, тегенең башына револьвер сабы белән берне кундыра. Ир белән хатын ике чекистны да ныгытып бәйлиләр дә авызларына мендәр почмагы тутырып чыгып та сызалар...

Берзаман конвой килеп житә һәм «ачык авызлары» мендәр белән томаланган «житез»ләрне коткара. Ары-бире чабып карыйлар, тү-тү, жиләр искән...

Йортны да, тирә-юньне дә күзәтеп торганнар.

Атыш тавышларын, һичшиксез, ишеткәннәр. Йортта засада барында чамалаганнар: бала-чага түгел. Шуңа карамастан йортка яңа кешеләр — ир белән хатынны жибәргәннәр. Нәрсә мәжбүр иткән Вырвачны? Йортка аны ни тарткан? Әллә бандитлар иң кирәкле нәрсәләрен алып китеп өлгермәгәнме?

Квартираны бик жентекләп тентергә куштым. Күпме кирәк булса, шунча монда утырырга кушып, өч иптәшне тагын засадада калдырдык.

Бәхетсезлек белән башланган көннең мажаралары моның белән генә бетмәгән икән әле. Кичен, Коростылевны чакырырга ниятләп, кайсы яктан тотып алыйм икән дип уйланып-әзерләнеп утырганда, минем янга Таняның әтисе килеп керде. Шул ук таушалган киемнәрдән, сәгать чылбыры гына юк та күлмәк төймәләрен ялгыш каптырган, якасы тырпаеп калган.

— Сергей Сергеевич,— диде бу керә-керешкә.— Сез мине икенче кызымнан да коры калдырырга жыенасызмы?

— Аңламадым.

— Мин аңлыйммы?

— Ни булды?

— Менә. Укыгыз.

Ул китергән саргылт калын кәгазьдә мондый юллар бар иде:

«Дустыгыз — Мәскәү чекистына житкерегез: әгәр бүген кич, 22 сәгатьтә, Зур Проломный урамында, банк бинасы янына Коростылевны алып килмәсә, сезнең кызыгыз Таняны жәзалыйбыз!»

— Таня кайда?

Коты чыккан ата сорауны ишетми торды...

— Алар аны алып китте. Шушы язуны тоттырдылар да алып киттеләр.

Бичара ата елап жибәрде.

Сәгатькә карадым, сигез тулып килә. Димәк, көтелмәгән һәм хәвефле очрашуга кадәр әле ике сәгать вакыт бар. Ике дә уйлап тормадым:

— Барам. Сез, зинһар, дип әйтәм, хафаланмагыз. Таняны ничек тә аралап алырбыз.

— Инде бу бәлаләрдән исән-аман котылсак, бер көн Казанда тормас идек.

— Кая китәрсез? — дидем мин, үз уйларымны уйлап.

— Кая китсәк тә риза. Жәһәннәмгә барып керер идем, ишеген генә белмим.

— Кайда да бер. Дошманнар кайда да бар.

— Йөрмә дидем, тыңламады... Зоряга да әйттем мин, кисәттем,

революция яхшылыкка илтми дидем... Хәзер менә икенче баламнан да калам...

Өеннән чыкмаска, беркемгә дә ишекне ачмаска кушып, мин аны озатып җибәрдем. Әзерләнергә кирәк, уйларга, ә ул вакытны алып тора... Ялгыз калгач, бандитлардан килгән ультиматумны тагын бер кат укыдым. Ничә кеше яздылар икән? Кин янына кердем.

— Хурлык, ультиматумнар көненә калдык! — дидем.

Тавышымны көр чыгарырга ниятләгән идем, барып чыкмады. Кин, аптырап, күтәрелеп карады, кәгазьне аңа суздым. Бер-ике минуттан аның бүлмәсенә оператив группа җитәкчеләре җыелган иде.

Июль төне. Көннәр күзгә күренеп кыскара, менә бүген дә ярым караңгы дип әйтерлек. Халык, вакыт соң булса да, берән-сәрән йөреп тора.

Мин аларны шунда ук төсмерләдем: икесе банк ягында, икесе каршы як тротуарга басканнар. Качарга да, посарга да уйламадылар, исләре китмәгән кыяфәт белән бәгрәеп карап торалар. Коростылевны уң кулыннан таза бау белән минем сул кулга бәйләгән идек. Әлла миңа гына шулай тоелды, без банкка якынлашканда, халык азайган кебек булды, кичкырын гына көчәя башлаган җилдән урам фонарьлары тирбәләләр. Кара-каршы баскан бандитларның күләгәләре дә аларга ияреп тирбәлә, бер караганда, алар дүртәү генә түгел, күп булып, ишле булып күренәләр. Банк янындагы ике сакчы, нидәндер шигәеп, әле безгә, әле бер-берсенә карыйлар, андый-мондый һөҗүм башланса дип, винтовкаларын ике куллап алга сузганнар. Күренмәсәләр дә, мин Таһиров, Заковский, тагын дүрт чекистның монда якында гына икәнен беләм. Зур Проломный урамыннан параллель ике яктагы урамнарга да йортлар астыннан, ишегалларыннан үтәргә мөмкин икәнлеге дә безгә мәгълүм. Бандитлар да шуңа һәм халык күплегенә исәп тотканнар булса кирәк...

Атыш башланса, мине Таһиров, Заковскийлар капларга тиеш. Атлы милиция юлда, командирлары хәзер сәгатьтән күзен алмый, алар да хәзер килеп җитәчәк...

Урам уртасыннанрак барырга тырышам, Коростылевның сулышы ешайды: дулкынлана, тартылып-тартылып ала. Мин аңа:

— Читкә китмәскә, китмәскә! — дип пышылдыйм, үзем көчәнеп елмаям.

Минем янга дәү имән кискәсе кебек бер ир килеп басты, икенчесе Таня белән банк алдында калды.

— Хәзер үк Коростылевны ычкындырасың. Кызыкайны аласың да яңадан очрашканга кадәр аерылышабыз. Хуп!

— Килештек! — дидем дә, Коростылевны үземнең алга чыгарып бандитны атып ектым. «Таня, ят!» — дип кычкыруым атыш белән бергә яңгырады. Бандит Таняга түгел, миңа атар дип уйлаган идем, шулай булып чыкты. Коростылевны кысып кочаклавым мине коткарды, ул үлде, пуля аны үтеп минем иңбашыма керде. Чекистлар һәм нәкъ вакытында килеп җиткән атлы милиционерлар ишегалларына кереп сибелгән бандитларны куа киттеләр. Банк алдында басып торган сакчылар да арлыбирле чаба башлады. Коростылевны чишеп ташлагач, бер минутка гына хәлем китте...

Заковский, Таһиров, Таня — өчәүләп мине санчастькә алып бардылар. Ярам куркыныч түгел иде. Алай да мине әйбәтләп бәйләделәр. Аннан өчәүләп Таняны озата киттек.

Капка төбенә җитәрәк, Леонид мине арткарак алып калды да:

— Без Гайнулла белән сезне калдырып китсәк, үпкәләмәссезме? — дип сорады.

— Нигә?

— Безгә кайтырга кирәк, ашыгыч эш бар! Калдырырга да уңайсыз!

— Син дә булмасаң... Мәскәүдән бергә килдек ич без. Син миңа иң якын туганым кебек...

Мин сыңар кулым белән Леонидны кочаклап алдым, тиздән аерылышуымны белә идем...

Иң элек Таняның исән-аман кайтып житүен өйдәгеләргә кереп белдердек. Ата белән ана шатлыгының иге-чиге булмады, нинди генә тәмле сүзләр әйтеп бетермәделәр алар исән калган кызларына. Әле кичке сигездә генә: «Бер көн дә монда калмыйм, кызымны да алып китәм»,— дип кызган ата, Таня мине озатырга жыенгач, бер сүз дә каршы әйтмәде, әни кеше кызының жилкәсенә мамык шәл китереп салды.

Без капка төбендәге эскәмиядә утырабыз. Койма өстеннән узып, безнең иңнәргә сирень ботаклары асылган.

— Авыртамы? — диде Таня минем яралы иңемә карап.

Ул тартылып килеп, мине үбеп алды, битем аның күз яшьләренә чыланды. Кызның язмышы кыл өстендә иде бит! Әле аны да сакларга, саклап алып калырга кирәк иде... Мин шаяртып:

— Син безнең икебезгә дә озын гомер юрадың, Таня. Шуңа таянып кына бардым мин очрашуга! — дидем.

Озакламый Таһиров белән Заковский жибәргән ике чекист килеп житте, алар бу араларда Танялар йортын күзәтергә тиешләр. Таняны, әти-әнисен: «Яхшы белгән кешеләрегез булмаса: берәүгә дә ишек ачмагыз!» — дип кисәттек.

Аларга һөжүм булуы бик ихтимал иде...

*Ахыры бар.*

## Рәшит Әхмәтҗанов

### Тукайның соңгы рәсеме

*Кайтмады уч, бетте көч, сынды кылыч...*

Г. Тукай.

Күзләр — кара кояш! Гамь яктысы...
Гөлҗамаллар төнлә җеп эрләр.
Иреннәрдә сүзләр: «Сынды кылыч...
Бар ышаныч сездә, тереләр!»

Кайтмаган уч булып, һаваларда
Яшен балкыр... яңгыр кояр күк.
Күз йомарга курка,—
Кара төндә
Столыпин кеше суяр күк.

— Үлеп аңлатам,— ди,— яшәр өчен —
Көтмә, татар, шәфкать патшадан.
Юккамыни бабаң әкиятендә
Тере килеш кеше ашаган
Аждаһаның башын өзә батыр...
Суккан җирдән сез дә өзегез!
Күрәсегез килсә үзегезне —
Кылыч йөзе булсын көзгегез.
Юкса, алар һаман кеше суя...
...Ютәлли дә Тукай... туктала.
Өши ләса,—
　　　　　　балкып чык та, кояш,
Бер генә уч җылы бир аңа!

Бер генә уч җылы, бер генә нур
Тиештер бит инде бу җанга —
Яна-яна... янып беткән өчен,
Нурын бирә-бирә җиһанга.

Карурманнар уртасында калып,
Тарихларның кылын тарткан бар:
Асрамага бушлай бирсәләр дә,
Тукай булгач, шактый сатканнар!

Көн дә үтергәннәр әкрен генә.
Кага-суга торгач — бер үлгән.

---

РӘШИТ ӘХМӘТҖАНОВ (1941) — шагыйрь, «Хыялларым үзем белән», «Ак канатлар», «Кавышыр көн» һ. б. шигырь китаплары авторы. Казанда яши.

Әмма җирдә күпме телсезләргә
Тел ачкычы биреп өлгергән...

Халкым булып күзләренә багам:
Күз нурлары иңә җаныма.
«Китмибез»не ясин итеп укыйм,
Иелеп мин шагыйрь алдына.

— Телдән калмагыз,— ди, җанкаралар
Йөрәк туктаганын чамалар,—
Ильминскийлары балта бирер,
Ишмиләре башны чабарлар!

Күзләр — кара кояш.
Гамь утыннан
Кем кабынып китәр, кем дөрләр?!
Иреннәрдә сүзләр: «Сынды кылыч...
Бар ышаныч сездә, терелэр!»

## Үзең уйла

Кичә сиңа нинди ямьле иде дөнья,
Бүген менә... болытлы һәм гамьле дөнья.
Ә иртәгә нинди булыр икән дөнья? —
Утыр да бу җиргә, балам, үзең уйла.

Үзең уйла: балкып торган бу дөньяда
Нигә кирәк, ямьсез булса, озын гомер?
Гомергә бер күзен ачып көлгән гөлнең
Гүзәллеген күрергә син, балам, өлгер.

Балам, өлгер: синең өчен генә ул гөл;
Гомергә бер күзен ачып, күзен йома.
Кем дә сине гаепләмәс, шул мизгелнең
Матурлыгын алып кайтсаң үз йортыңа.

Үз йортыңа алып кайт та, һәм үзеңнең
Йөзләреңә, күзләреңә кунсын әле.
Күңелеңә чәчелсен дә... уңсын әле,
Барыбызга да җитәрлек булсын әле.

Булсын әле! Ә калганы гомер буе
Сагындырып-сагындырып төшкә керер.
Дөнья ямьсез булса — нигә матур гомер?
Гомер буе матурлыклар эзләп йөгер.

## Яшәүләрне яклап

*З. га*

Еллар уза, энем, гомер уза.
Эшләрең күп иде — эшләдеңме?
Сулар ага, энем, сулар ага.
Кыя белән авып төшмәдеңме?

Утлар яна, энем, утлар яна.
Максатларсыз утка кермәдеңме?
Утлар яндырса да көлмәгеңне —
Сакла йөрәгеңне!

Чынлык сине дәһшәтләргә салгач,
Җирдә — ут дип, күкне күзләдеңме?
Дөнья канатса да йөзләреңне —
Сакла күзләреңне!

Ялган адаштырса ком чүлендә,
Берүк, энем, каушап калма анда.
Адашу ни — күзләр ук булганда,
Йөрәк ут булганда!

Күзләр күргән гөлләр кисәтәләр:
Йөрәкне дип, илдән генә аер,—
Үз анасын таный алмас булып,
Аерылган кеше... сукыраер.

Язылмаган язмышыңа, энем,
Ил сагышын язар көннәр алда.
Бу дөньяның һәлакәте түгел,
Хәрәкәте ага синең канда.

Тирә-якта буш калганнар сирәк:
Кемгә чынлык, кемгә ялган кирәк...
Бары яшәүләрне яклап кына
Һәлак булса булыр безнең йөрәк!

## Кайда алар?

Уналтыда сөеп, унҗидедә
Аерылганнар еламасын ла...
Башның кичергәне —
Кичәгенең
Утлар алмас легендасында.

Кичәгеләр — Иделләрне кичкән,
Бергә утлар эчкән юлчылар,—
Кайда алар,
безне кешеләрчә
Яратучы, сагынучылар?

Легендарның берсе — шигърияттә
Җидегәнгә менгән каһарман!
Беләм: сиңа бүләк булып калды
Бер классик роман... аңардан.

Шул романның соңгы битләренә
Соң булса да өстәп яз әле:
«Һәм Рәшит тә мәхәббәттән диеп,
Мәңгелеккә алды җәзаны».

Гашыйкларга җәзаларсыз калу
Мөмкин хәлләр түгел, күрәсең.
...Әйт аңарга: гомер буйларына
Төшкә генә кереп йөрмәсен;

Килсен әле, килсен.
Бер мыскал ямь
Салсын әле дәрья-гомергә.
Елар яше — еланнарга төшсен,
Көлүләре керсен шигырьгә.

Үзем барыр идем... Минем өчен
Тау башларын кискән җилләр ни! —
«Мин — гомерең. Минсез үләрсең» дип,
Гашыйк булган көнем җибәрми.

Җибәрми дә... Әгәр кичәгеләр
Килеп чыкса монда иртәгә —

Син теләсәң нишлә,
Ә мин әзер
Алар белән бергә китәргә.

Шигърияттнең аның акчасы юк,
Юк җигәргә аты-арбасы,—
Асыл агачларга асылынмый
Калган башны гына аласы...
Һәм китәсе чыгып.
Күрәселәр —
Маңгайларга күптән язылган.
Инде безне тәңре үзе хәзер
Туктаталмас шигырь язудан.

Гашыйк булган көннәр калса-калыр,
Тик йөрәкләр алга барсын ла
Беренче һәм соңгы мәхәббәтнең
Туплар ватмас легендасында!

●

Йолкый-йолкый хәле беткән җилләрнең:
Тамыр — җирдә, яфрак күктә иманнең!

Әйләндереп кара, әйдә, киресен —
Син барыбер шундый ук хәл күрерсең.

Җир белән күк тоташканнар имәндә...
Безне нәрсә кавыштырыр, дигәндә,

Бу дөньяда бер тылсым да калмаган —
Мине — сиңа, сине миңа ялгаган.

Буйсыныйкмы инде шуңа, ни дисең?
Уйлый торгач... ут өстендә биерсең!

## Бишек җыры түгел

Баш куеп җырның, балалар,
Әллие-бәллиенә,
Йоклыйсыз... Инде торырга
Вакыт та җитте менә.

Уяныгыз, уяныгыз! —
Юксынып сорый еллар:
Кайларга китте дип, болар,
Кайларда югалдылар?

Төн җитсә, сезне эзли ил,
Кайда дип, балам нуры?
Тор, бала! Илнең йөзенә,
Күзенә кара туры.

Уян да илнең күгенә
Йолдызлар булып калык!
Йотар, юкса, төптә сине
Йокламый торган балык.

Еллар сезне санамасын,
Сез елларны санагыз.
Йоклар өчен тудырмаган
Җиргә безне анабыз.

Бәлаләрне бәгыренә
Яшергән көннәрендә —
Сездән башка таянырга
Юк аның кемнәре дә.

Көтә сезне, көтә... Сезне
Үз кочагына алып,
Бер тузаннан кеше итеп
Үстергән бөек халык.

Уяныгыз! — Инде күптән
Узды күз йомар чаклар.
Күзеңне йомсаң, шул йокы
Илеңне дә кочаклар.

# Еллар буйлап

Җир әйләнә Кояш тирәсендә,
Әнкәй тирәсендә — кара йомгак...
Гомер буе, әнкәй, сине уйлап,
Йомгак сүтеп йөрим еллар буйлап.

Нинди генә ташкын бәрми миңа,
Нинди генә ташлар бәрелмиләр! —
Син танымас халгә китереп мине,
Сиңа күрсәтергә «әзерлиләр».

Белми әле алар үлгәнеңне.
Миндә яшисең син,
мин белдермим.
Минем аша сине җәзаларга
Ирек бирмим әле, ирек бирмим!

Без яшибез әле, без яшибез,
Кояш тирәсеннән ераклашмый.
Үлем күренүгә,— туганнарым
Мәхәббәттән туып балкый башлый.

Син дә кушыласың... кычкырасың:
— Тимә, кечесенә, олысына! —
Һәр баламны бер фәрештә итеп
Тудырдым бит,— диеп,— дөнья, сиңа.

Ә балага... яшәү авыр аңа,—
Аның әле алга барасы бар.
Ким дигәндә, Кояш тирәсендә
Әйләнүче булып каласы бар...

Синнән калгач, әнкәй,
шактый гына
Балаң каны юды бу дөньяны.
Ничек бәргәләнә! Һәм әйләнә
Кояш тирәсендә аның җаны.

Әйләнәм дә шулай, мин әйләнәм,—
Бер минут та җирне ямьсезләмәм.
Дөрлим! Сүнәр көннәремне беләм,—
Шуңа менә җырга әвереләм.

Гомер озын булсын, юллар ерак...
Сүтелмичә калыр юкса йомгак.
Улың, әнкәй, шул турыда уйлап,
Йомгак сүтеп йөри еллар буйлап.

## Мөсәгыйт Хәбибуллин

# ЙӨРӘККӘ ТАМГАН ЯЗГЫ ТАМЧЫЛАР

ХИКӘЯ



Сугыштан соң Фатыйма зарыгып көтеп алган беренче яз килде. Башта ул моңа игътибар итмәде. Кичтән һавада дымсулык артты, әңгер иңүгә, күк йөзен куе болыт томалады. Ишегалдында йөргән Фатыймага күрше карчыгы әйтә салды:

— Язгы ләйсән яңгырына бу, килен.

Күрше карчыгының колак очына эләгеп калган бу сүзе, иртән күзен ачкач, Фатыйманың янә хәтеренә килде. Фатыйма тыштагы үзгәрешкә колак салды. Чынлап та өй кыегыннан тып-тып тамчы тама иде. Бераздан тәрәзә башына кунарга кергән чыпчык кыштырдарга тотынды. «Нигә инде хет сиңа йокламаска, ни кайгың бар? — дип уйлады Фатыйма. Аннары: — Нигә алай дим әле мин аңа? Бәлкем, аның да яз килүен сизүедер, саласы сипкелле күкәйләрен, томшык төртеп чыгасы сары авызлы кошчыкларын күз алдына китерәдер. Күрше өй кыегында гомер иткән күксел-кара бүрекле чыпчыкның былтыр нәкъ шушы вакыт җиткәч үзе тирәсендә чырылтый-чыркылтый уралуын исенә төшерүе дә ихтимал. Чыпчыклар яз кавыша, көз җитеп, балаларын очыруга, яңадан төрлесе төрле якка тарала ди бит».

Фатыйма, гәүдәсен турайтып, киерелеп-сузылып алды, теләсә-теләмәсә дә:

— Их-ма! — дип куйды.

Мәгънәсе Фатыймага билгеле дә, түгел дә бу хикмәтле сүзне Харис бигрәк тә иртән уянгач һәм бераз дөнья хәлләре турында сөйләшеп яткач әйтер иде... Шулай дип әйтер иде дә, Фатыйманың төн буе сүрелеп җитмәгән кайнар битләреннән үбеп алыр иде... Алар нибарысы елга якын бергә торып калды. Харис кебек ирләр сугыш башланыр көннәрдә печән чабарга йөрде, хатыннар чүмәлә куйды. Әле булса күз алдында Фатыйманың, сугыш хәбәре килүгә, кырыклап ир-егет, печән өстеннән диярлек, колхозның «полуторка»сына утырып, Бөгелмәгә китте. Хатыннар ирләрен хәтта станцаһа хәтле булса да озата бара алмады. Ирләрнең күбесе шул китүдән әйләнеп кайтмады. Ике атна үткәч, Харисның: «Смоленск шәһәре тирәсендә сугышабыз»,— дигән беренче хаты килде. Ай үтүгә алган икенче хат Харис кулы белән язылмаган иде...

Фатыйма ул көнне кырга эшкә килгәч, үзе сөргән кара җир өстенә ятып, үксеп-үртәлеп елады. Сабанчы хатыннар аны юатмады, сугышка киткән ир турында: «Хәбәрсез югалды»,— дигән кәгазь алу җиңел түгел икәнен беләләр иде. Сабанга җиккән атлар гына, гаҗәпләнгәндәй пошкырынып, башларын чайкап тордылар.

Шул хәлдән соң өч ел гомер узды, дүртенче яз — Җиңү язы килде. Сугыштан авылга берән-сәрән ирләр кайта башлады. Сугышта югалу хәбәреннән гайре Харис турында һични ишетмәгән Фатыйманың күңеле, язгы ташкынга эләккән йомычкадай тулганды. Ахырда, өметен өзмәскә теләп: «Азмы аның

---

**МӨСӘГЫЙТ ХӘБИБУЛЛИН** (1927) — прозаик, «Чоңгыллар», «Сулар үргә акса да», «Кубрат хан» романнары һәм күп санлы повестьлар, хикәяләр авторы. Татарстанның атказанган культура хезмәткәре, Татарстан Язучылар союзы идарәсе секретаре. Казанда яши.

кебек хат-хәбәрсез сугышта югалучылар һәм көтмәгәндә исән-сау әйләнеп кайтып төшүчеләр»,— дип үз-үзен юатты. Ә үзе һаман көтте, сабыр итте. Харисы салып калдырган өйдә берьялгызы яшәде. Кайчак аңа өерләре белән солдаткалар килеп керде, җыелышып моңсу җырлар җырладылар, аннары ялгызлыкларыннан зарлана-зарлана, фашистларны, кабахәт Гитлерны каргадылар.

Беренче тынычлык язының чалт аяз көнендәге кояш мул итеп нурларын сипте. Нурлы, якты иде дөнья. Әйтерсең илдә фаҗига да булмаган иде. Фатыйма, тәрәзә пәрдәсен күтәреп, урам якка карады. Шунда аның йөрәге җуу итеп китте. Урам тутырып, әсир немецларны куалар иде. Әсирләр артыннан адым да калмый диярлек яланаяк авыл малайлары ияргән, кулларын болгый-болгый нидер сөйләнәләр, кычкырышалар. Ә немецларны озатучы солдат шау-гөр килеп торган балалар төркемен кугалый, ләкин малайлар бераз гына тукталып калалар да янә әсирләр артыннан тагылалар.

Урам тулып килгән әсирләрне күргәч, Фатыйманың күңеле әллә нишләде, тере немец солдатын аның беренче тапкыр күрүе иде. Немецлар барысы да сары чырайлылар, ямьсезләр кебек күренде аңа. Кая куалар икән үзләрен?

Ул арада, сулышына кабынып, каршы як күршесе Камилә килеп керде.

— Ахирәткәем, Фатыйма, күрдеңме, әсир нимечләрне куалар. Бездә эшләячәкләр ди. Актауга әсфәлт юллар салдырачаклар ди үзләреннән. Барак корганчы кайберәүләрен фатир таратачаклар ди.

— Шул гына җитмәгән тагын. Өемә нимеч кертәм ди! Бәлкем ул минем Харисымны үтергән нимечтер. Мин ул кабахәтне үз кулларым белән буып үтерәчәкмен...

Фатыйма, бармакларын тырпайтып, Камиләгә таба кузгалды.

— Кит, тиле, нишләвең бу? Ниемә шулай күзләрең яна башлады? Нимечме әллә мин сиңа?!

Камилә чыгып киткәч, Фатыйма морҗа буендагы эскәмиягә күчеп утырды да, хәлсезләнеп китүен тоеп, күзләрен йомды.

Шул чакта тәрәзәдән бригадир:

— Фатыйма, бүген фермага салам ташырга барырсың! — дип кычкырып, эшкә дәшеп китте.

Фатыйма юында-киенде дә, чиләк-көянтәләрен алып, беренче нәүбәттә суга китте. Бизәкле көянтә-чиләкләрне аңа Хариска чыкканда әтисе алып биргән иде. Харис чишмә суын ярата иде, шуны белгәнгә, Фатыйма, ераграк булса да, суга чишмәгә йөрде. Чишмә тау астыннан тибеп чыга, кояш чыгышына каршы торгангамы, аны Таң чишмәсе дип йөриләр. Таң чишмәсенең суында чәй әйбәт чыга, хуш исле була. Харис яратыр иде Таң чишмәсе суыннан кайнатылган куе-кара чәйне баллап эчәргә.

Фатыйма, кечкенә күперчекне чыгып, тау итәгенә таба юнәлде. Чишмә өстендә сыек томан тулгана, томан эчендә әкият кызлары бии сыман. Юк, алар салкын чишмә суы белән алсу битләрен юалар имеш. Шулай юса, Фатыйманың да ефәк шикелле була торган иде чәчләре. Харис андый чакта борынын төртер иде дә:

— Тукта, зинһар китми тор. Бу чәчтә, биллаһи дип әйтәм, мең төрле хуш ис бар,— ди торган иде, җуләркәй.

Якыная төшкәч, абайлады Фатыйма, Таң чишмәсе янында әкият кызлары түгел, ә бая урамнан узган әсирләр утырышкан, үзләренең ят телендә гөҗләшәләр, яшел кәтәлүкләренә су алганнар да тәмләп чишмә суы эчәләр. Арада берәүсе чишмә янындагы зур таш өстенә менеп урнашкан да тырыша-тырыша авыз гармуны уйный.

Иңбашы аша көянтә салган, бизәкле туй чиләкләрен кулы белән тоткан Фатыйма килеп чыгуга, әсирләрнең барчасы да шым булды, күктән төшкән алиһә күргәндәй, бөтенесе дә аңа текәлеп катып калды. Фатыйманың гүя аяклары җиргә ябышты. «Кая китте икән теге яшь солдат, нигә болар үзләре генә Таң чишмәсе янында, Актау халкы өчен изге урынны хәрамлый?!»

Фатыйманың миеннән мизгел эчендә әнә шундый уйлар узды. Әсир немецлар һәммәсе диярлек ак кашлылар, су күзлеләр, ач яңаклылар иде. Күрче, нәкъ шундые Фатыймага таба атлый түгелме?!

— Фройлейн...

Фатыйма чак кына кычкырып җибәрмәде, шул мәлдә кемдер:

— Сидеть! — дип боерды.

Фатыйма тавыш килгән якка карады һәм, җилкәсе аша автомат асып, таш өстендә утырган солдатны күргәч, тынычлана калды. Солдат уңып беткән гимнастеркасының якаларын ычкындырып җибәргән, бармак арасында «кәҗә мөгезе» көйри.

— Я ходаем, куркуларым лэгънэттэн.

— Курыкмагыз. Әй, Һанс, булыш әле апайга су алырга! — дип боерды солдат бер әсиргә.

Һанс дигәне авыз гармуны уйнаучы булды, күрәсең. Үз исемен ишетүгә, әсир, гармунын кесәсенә тыгып, Фатыймага каршы кузгалды.

— Бирмим. Кит, ягылма, фашист!

Фатыйма шундый иттереп карады ки, тегесе әпен-тәпен артка чигенде. Фатыйма, башын чөя төшеп, улак янына килде, чиләкләрен мөлдерәмә тутырып су алды да чиратлап көянтәсенә элде һәм, авызларын ачып торган немецларга күтәрелеп тә карамыйча, җай гына, иплә генә адымнар белән кузгалып китте. Чиләктәге суының тамчысы да таммады, ә Фатыйманың зифа сыны, авыр эш эшләп күнеккән гәүдәсе авырлыкны сизмәде дә, тик юанрак балтырларының елтырап, кашларының уйнаклап алуы гына күзгә бәрелде бугай. Таң чишмәсеннән ераклашканда Фатыйма әсир немецның авыз гармунында ят та һәм гаҗәеп таныш та кебек бер көй уйнавын ишетеп, үзе дә сизмәстән туктап, артына борылып карады. Аңа су алып бирергә теләгән немец авыз гармунында Штраус вальсын өздерә иде. Фатыйма, яман эштә тотылган кеше шикелле оялып, ашыгып китеп барды.

Икенче көнне өенә авыл советы председателе килде һәм аңа:

— Бараклар салынганчы, ике әсир синдә торыр,— диде.

— Кертмим. Шул гына җитмәгән тагын,— дип каршы төште Фатыйма.

— Карарны үтәми хәлең юк, алар безгә юллар салачак,— дип китә башлады авыл советы председателе.— Бер сиңа гына фатир кертмибез...

— Барыбер кертмим,— дип сүзен сүз итәргә тырышты Фатыйма...

...Кичке якта аның капка төбенә ике әсир килеп туктады. Кече капканы төртеп карадылар — ачылмады. Фатыйма шудыргычны чөйләп үк куйган иде. Аннары ят телдә нидер кычкырдылар, үтенделәр, әмма Фатыйма селкенмәде дә. «Көтәрсез-көтәрсез дә олагырсыз әле»,— дип кенә куйды. Ләкин әсирләрнең башка барыр җирләре юк иде күрәсең, бөкшәйгән килеш капка төбендә кагаеп тора бирделәр.

Шулай бер сәгатьләр чамасы вакыт узды. Фатыйма әсирләр турында онытурга теләп, бәйләм бәйләп карады, чынын гына әйткәндә, йөрәгендә аларга карата мыскал да кызгану хисе юк иде аның. Вакыт-вакыт берсенең кулындагы кәгазен тәрәзә алдында болгап торуына да исе китмәде.

Эңгер иңгәч, сибәләп яңгыр яварга тотынды. Әсирләр һаман китмәделәр. Фатыйманың бу хәлгә ачуы килә башлады. «Ялгыз хатын янына әсирләр кертергә ни хаклары бар? Үтереп китсәләр? Фашист фашист инде».

Караңгы төшкәндә кемдер кече капканы шакыды. Ул шундый иттереп шакыды ки, Фатыйма, иңбашына шәлен салырга да онытып, ишегалдына йөгереп чыкты.

— Апа, җаным, мин бу, ач әле капкаңны. Керт инде шуларны, күшегеп беткәннәр бит. Курыксаң, яннарында үзем дә кунармын...

Солдатны танығач:

— Үзең кунсаң гына,— дип, Фатыйма капканың шудыргычын тартты.— Әйтәм бит, куркам мин алардан.

— Иң юашларын гына китердем. Әнә тегесе, озыны — антифашист. Һанс. Кечкенә буйлысы — Вольф.

— Барыбер фашистлар,— диде Фатыйма.

— Я, инде, апай, чын фашистларны без иске мәктәпкә урнаштырдык. Болар — безнекеләр дим ич. Һанс,— дип немецка дәште солдат,— уйна әле гармуныңны.

— Ни-ихт, туңды Һанс,— диде немец. Ул күшегеп беткән кулларын солдатка күрсәтте.

— Ярый, бар кер, җылынгач уйнарсың,— диде аңа солдат.

Фатыйма әсирләргә алгы якта урын җәйде, баш асларына мендәр ташлыйм дигән иде, тукталып калды, мич арасыннан иске пальтосын гына чыгарып салды. Немецлар дәшми-тынмый гына чишенделәр дә, өсләренә яшькелт шинельләрен ябынып, йокларга яттылар.

— Син алардан курыкма, тәкәбберлекләре коелган инде аларның. Аннары болары — безнекеләр. Һансның әтисен төрмәдә черетеп үтерә Гитлер. Коммунист булганы өчен.

— Нигә соң монысы безгә каршы сугышкан?

— Сугышмаган ул. Музыкант. Торба өреп йөргән.

— Коммунист улының Гитлер армиясендә музыкант булырга да хакы юк.

— Яшисе килгәндер...

— Яшисе...— дип кабатлады Фатыйма.— Әрсез үзләре. Китмиләр дә китмиләр.

— Әмер. Китәләр икән, баш долой,— диде солдат.— Карале, апа, мин башкаларның ничек урнашуларын карап кайтыйм инде. Бәлкем, синең кебек кертмәүчеләр тагын бардыр?

— Бик дөрес эшлиләр, тапкансың тансык кунак. Бел аны, энекәш, үзең кайтмыйсың икән, кисәү таягы белән куам да чыгарам үзләрен.

— Әйтәм бит, юашлар алар, әүлияләр,— дип көлемсерәде солдат.

— Әүлияме, түгелме, анысын белмибез. Кайтмыйсың икән, немечләрең тышта куначак. Ипи тотып ант итәм менә!

— Я хода, булса да булыр икән, кайтам бит инде, тикшереп кенә чыгам үзләрен.

Солдат шулай диде дә үз юлына китте. Фатыйма түр якның ишеген барып япты, келәсен төшерде, бераздан, ишек тоткасына аркылы китереп, кисәү агачы тыгып куйды. Шуннан соң гына тынычланып, урынына барып ятты. Сөян бүрәнәсеннән буралган стена аша агач башларын шаулатып җил йөгергәне ишетелә, тәрәзә пыяласына кыеклап язгы ләйсән яңгыр ява, урамны уятып, майламаган тәгәрмәчен шыгырдата-шыгырдата, атлы уза, бу тавышлар күңелгә әллә ниткән шом сала, болай да курка-курка яткан Фатыйманың йөрәген кага. Вакыт-вакыт Фатыймага өй эчендә әллә кемдер йөри кебек тоела башлый, гүя ул әле стенага килеп сөялә, әле ишек янына килеп баса, әле мыштым гына бусагага утыра. Аның аяк тавышы йөрәккә үтеп керә, арка буйлап салкын боз шикелле тәгәри. «Шушындый чакта күрше Нәсимә әби дә килеп керми ичмасам. Кая олакты соң бу солдат? Нигә һич югы автоматын биреп калдырмады?» — дип уйланып ятты Фатыйма.

Алгы якта кайсысыдыр йөткереп куйганнан соң, Фатыйма шым булды. Немецлар үзара акрын гына сөйләшә башлады. Бераздан алар да тынып калды, Фатыйма үзенең йөрәк тибешен колак янында ук ишетә башлады. «Их, бу солдатны. Исемен дә сорамадым ичмасам, рәхәтләнеп исемен әйтеп тә сүгә алмыйм байгышны. Хәзер кайтам дигән булды бит. Һич югы автоматын калдырсын иде,— дип янә уйланып алды Фатыйма. Ләкин икенче мәлдә инде бу уеннан да курка калды.— Кереп кулыңнан суырып алырлар иде дә китәрләр иде бөтен Актау халкын кырырга. Аз кырганнардыр безнекеләрне эттән яралган нәстәләр. Солдатын да әйтер идем, антифашист дигән була. Алай икән, нигә әсир булып йөриләр?! Мылтык бирсәләр, ике дә уйлап тормас идем, кырыр идем үзләрен. Харисым өчен, Камилләнең Идрисе өчен...»

Алай да аруы үзенекен итте, Фатыйма тәрәзәгә сибәләгән яңгыр тавышы, агач башлары шаулавы астында йокымсырап китте.

— Апа дим, апа! Ач! Мин бу — солдат!

Фатыйма, әүвәл һични аңламый, ярсынып сикереп торды, йөрәге ашкынып тибүен тоюдан гаҗиз калып, тавышка колак салды. Солдат икән. Алай да тәрәзә пәрдәсен сыдырып, ишегалдына күз салды. Янә солдат икәненә инангач кына, иңенә шәлен салып, ишек ачарга чыкты.

— Кайттым. Әллә инде ятып та өлгергәнсез?

— Кер әйдә, түр якка ятарсың. Мич кырындагы сандык өстенә урын җәйдем үзеңә.

Солдат аңа ияреп түр якка керде, плащын чөйгә элде, сүзсез генә итекләрен сала башлады. Фатыйма солдатның мыш-мыш килеп чишенүен сагаеп тыңлап торды.

— Авырмы, солдат, хезмәт итүләре?

Солдат дәшми, әллә аруы житкән, әллә Фатыймага ачуы чыккан. Тик ятып бераз торгач кына:

— Тыныч йокы, апа,— диде.

Аның шулай дию енә Фатыйма бөтенләй тынычланып, күзләрен йомды. Соңгы мәлдә ул тәрәзә кыегындагы чыпчыкның кыштырдавын гына ишетеп калды.

...Немецлар бик иртә уянды. Шыбыр-шыбыр яуган яңгырга сукрануларымы, акрын гына сөйләшәләр. Фатыйма уянса да, урыныннан кузгалмый ятты. Агачлар шаулый, җил тагы да көчәйгән булса кирәк, яңгыр һаман кила-кайта тәрәзәне чыбыркылый. Тәүлеккә якын ява бит, юл өзелгәндер инде. Бригадир Чулак Галиәкбәр кушуынча, кичәгенәк саламга ике барганнар иде, бүген, мөгаен, кулдан килмәстер.

Фатыйма ашыкмый гына торды, киенде, солдатның өстеннән шуып төшкән юрганын рәтләп япты. Солдат изрәп йоклый, кымшанып та карамый, борын астындагы аксыл-сары мыеклары, өлгергән тарыдай, бөтерелеп торалар. «Са-

бый гына, ә үзе бер өер нимечне куып йөртә»,— дип көлемсерәп уйлап куйды Фатыйма. Кинәт кенә аның кылгандай солдат чәченә кагыласы, күпереп торган яңагыннан сөясе килеп китте. Шул ният белән ул кулын сузды, мәгәр шундук тартып та алды. Акрын гына ишек ачыла башлады.

— Комрад...

— Нәрсә кирәк сиңа?

Ишек ягыннан немецның су сыман күзләре елтырады.

— Уята... Комрад.

— Тор әле, солдат, әнә сиңа нимечең дәшә,— дип Фатыйма солдатның җиңелчә генә җилкәсенә кагылды.— Нимчәләрең уянды, дим, нидер сорыйлар, уян инде!

Солдат күзләрен ачты; ишектәге әсирнең су күзләренә төбәлде.

— Йөреп керергә исәпләре, чыгар үзләрен,— диде солдат һәм икенче ягына әйләнеп ятты.

Фатыйма немецларга тышкы ишекне ачып бирде. Үзе алгы өйгә чыгып, ике толымга чәчен тарап үрде, кулларын, битен юды. Аннары баздан ярты чиләк бәрәңге алып менде. Бераздан мичтә ут дөрләп янып киткәч, немецлар да өйгә керде, утка каршы утырып кулларын җылыта башладылар. Алар сөйләшмәде, Фатыйма мич янына килгән саен читкә тайпылып, үзара күзгә-күз карап кына аңлаштылар. Һанс дигәне, Фатыйма күрмәгәндә генә, аңа күзен алмый карап торды, хатын аның күз карашын үзендә тойса да, немецны гел күрмәгәнгә салышты. Мич каршында утыра-утыра немецларның битләре алсуланды, йөзләренә кеше төсе керде.

Мичтәге бәрәңге кайный башлады, чуен читеннән күбекләнеп су ташып чыкты. Моны күреп, немецлар икесе берьюлы:

— Картоф! — диештеләр.

— Анысы бар, менә әпекәй генә юграк,— диде немецларның ни турында сукалауларын абайлап алган Фатыйма. Хатын самавыр куйды, өстәл хәстәрләргә кереште.

Солдат уянды, аякларын сузыбрак җибәрде, күзләрен ачты.

— Карале, солдат, мин бу нимечләреңне ашатырга да тиешме?

— Юу-ук,— диде солдат.

— Аруың җиткән икән әсирләр көтүен көтә-көтә. Тор инде,— диде Фатыйма.— Янбашыңа тоз төшәр.

— Яңгыр явамы?

— Ява. Төн буена яуды.

— Димәк, беркая да бармыйбыз. Ял.

— Тор әйдә, бәрәңге пешә хәзер, ашап алырбыз. Башка нәрсәм юк, чәй куйдым әнә.

— Рәхмәт, Фатыйма апа. Безнең паек бар. Әсирләргә әпекәй бирәбез. Ә бәрәңгең жәл булмаса, әйдә, ашат үзләренә. Әнә тегесенә, озын бармаклысына күбрәк бирсәң дә жәл түгел. Әйтәм бит, антифашист улы, музыкант. Искитмәле итеп уйный. Авыз гармунында сыздырып җибәрсә, җаннарны актара, сары шайтан. Интернационалны сиптерә, Катюшаны!..

— Каян белдең минем исемне? Кем әйтте?

— Авыл советында әйттеләр. Мин үзем — Дима. Коми егете. Күрәсең ич, татарча да сукалыйм. Бу вакытта кыш әле бездә, шулай да кояш карый инде, түбәләрдән тамчылар тамадыр.

— Әйдә тор, юын да, ашап алырбыз.

Фатыйма мичтән бәрәңге алды, һәм аны коштабакка салып, өстәлгә куйды. Әсир немецларга да салып бирде. Савыт тулы бәрәңге эләгүгә, немецлар алгы якка чыгып китте. Ул арада Дима да юынып өстәл янына килеп утырды.

— Минем дә ипи-май бар, кичкә алып килермен.

— Куелганына рәхим ит әле, синдәйләргә ризык жәлме, солдаткаем. Ни сөйләп утырган буласың тагын? Ят кешеме әллә син? Солдат ул бар кешегә дә кардәш кеше.

— Рәхмәт, Фатыйма апа. Ә бәрәңгең тәмле, мондыйны күптән ашаган юк иде инде. Сыерың бармы соң?

— Юк, Дима.

— Ирең ни яза?

— Смоленскидан килде соңгы хаты. Аннары хәбәрсез югалды.

— Анысы шәп түгел. Әйе,— диде Димка, олыларча фикер йөртеп,— бу фашистларны җиңүләре җиңел булмады.

— Синең үзеңә ничә яшь соң?

— Унсигез. Карт солдат инде мин. Яшьтәшләремнең сугышта катнашкан-

нары да булды. Менә мена шушы хәсрәтләргә бәйләделәр дә... Ничек сугыш-каннардыр, бер авыз сүз русча белмиләр.
— Ә син үзең немесчә беләсеңме соң?
— Нигә кирәк ул миңа? Мин аларда түгел, алар миндә әсир. Өйрәнсеннәр. Җиңүчеләрне хөкем итмиләр. Хәер, музыканты бераз сукалый сукалавын.
— Миндә боларны кайчанга хәтле тотарга исәбегез?
— Бараклары салынып бетү белән алырбыз.
— Күрәселәрем бар икән әле. Антифашист булсалар да, мин барыбер куркам алардан, солдат.
— Курыкма. Фатир тоткан өчен акча түләячәкләр. Хәтта ике йөз грамм ипи бирәчәкләр.
— Тамагыма тыгылмасмы соң ул ике йөз грамм? Әпәең дә кирәкми, алып кит немечләреңне!
— Мин урнаштырмадым аларны, авыл советыгыз. Сез Совет властен танымыйсыздыр ич?
— Я ходаем, авызыңнан җил алсын.
— Димәк, бараклары салынып беткәнче яшәячәкләр инде.
— Солдат кына димәссең үзеңне.
— Генерал буласы кеше мин, апакаем. Мена ишетерсең әле Димка Сорокин турында.
— Әй, ходаем, сибә бөрчакны бертөрле итеп. Житеп тормасмы, әйдә чәеңне эч тә...
Солдат чыгып китүгә, алгы яктагы немецлар буш савытларын керттe, икесе беравыздан рәхмәт әйттеләр. Алар чыгуга, ишектә Камилә күренде.
— Фатыйма, ахирәткәем, сиңа да икәүне керттеләрмени? Миндә дә икәү. Сөяк тә тире бичараларда. Карап-карап тордым да бәрәңге пешереп бирдем әле үзләренә. Берсе дүрт балам бар ди. Дүрт бармагын тырпайтып күрсәтә, хәсрәт. Икенчесенең авызында сөте кипмәгән, иртән торды да лышык-лышык җылый башлады. Нигә яшь соң үзеңә дип сорыйм. Унжиде дип язып бирде. Маңка көенә сугышып йөргән бит, эт җан.
Алгы якта немец авыз гармунында уйнап җибәрде. Ят булса да, күңелгә моң сала торган көй иде.
— Миңекеләр юашлар, авыз ачып сүз әйткәннәре булмады.
— Савыт белән бәрәңге биргәндә кулымны үбәргә үрелгәне әнә теге гармунда уйнаганы, беләсең килсә. Чак кына авызына сугып җибәрмәдем,— диде Фатыйма.
— Куй инде. Саламга барабызмы соң?
— Һай алла, көне көн булса икән. Димка солдат: «Мондыйда әсирләрне дә чыгармыйбыз»,— диган була.
— Аларга карап безгә чыкмыйча ярамас, Фатыйма,— диде Камилә кисәк җитдиләнеп.— Көнне төнгә ялгый-ялгый эшләгәнгә жиңдек без аларны, ахирәткәем, беләсең килсә.
Фатыйма аның сүзләрен куәтләп, ияк кагып торды. Солдаткалар арасында Камилә агитатор кебегрәк кеше иде, җыелышларда актив катнаша, ял сәгатьләрендә кычкырып газеталар укый. Үзе бар нәрсәдән дә хәбәрдәр.
— Әйдә алайсаң,— дип күтәрелде Фатыйма һәм киенә дә башлады.
Ул арада Димка-солдат кайтып керде.
— Әллә эшкәме? Шундый көндәме? Өстән яңгыр явып торгандамы?
— Без тылда әнә шундый чакта да эшләгәнгә җиңдегез бу нимечне, туганкаем,— диде аңа Фатыйма. Солдат ни әйтергә белми авызын ачты да калды.
Урамга чыккач, Камилә:
— Ә синең ул музыкант әсирең бераз кешегә охшаган, нур тамчысы бар сыман йөзендә,— диде.
— Сөйлә тагын.
— Ай, ахирәткәем, әсир кеше — кол кеше, бәйле этка тиң кеше, бирәсе җәзасын бирганнәрдер инде үзләренә. Аннары... Ир-атны гелән сугышыр өчен генә туган дип уйлыйсыңмы әллә? Беләсең килсә, табигать аларны безне сөяр өчен яраткан, мал табар өчен...
— Алла диген, малыкаем, әйтмә алай, Камилә. Идрисең рәнҗер.
— Рәнҗемәс, Фатыймакаем. Кичерер. Без алар эшләгәннең барысын да эшләп карадык, барысын да күрдек. Мена ничә көн инде сул як җилкәм сызлый, сәнәк тота алмый башладым. Әллә Нәсимә әбигә кереп тиганәк яфрагы яптырасы инде. Теге вакытта тәнемә май сөртеп шуны яптыргач, гелән җиңеләеп киткән иде.

...Көньяк-көнчыгышта күк йөзе ачылды, дөньяга мул булып яктылык тула башлады. Эшкә килүчеләргә бригадир:

— Катыннар, Фатыйма, Камилә, бүген саламга барып булмас, абзардан тирес чыгарырбыз,— диде.

...Кичке якта фермадан кайткач, Фатыйма яңгырда чыланган сырмасын мич башына җәеп салды, шәлъяулыгын киштәгә элде, аннары иске пиджагын киде дә мунчага су ташыды, утын кертеп, мичкә ут төртеп кайтты. Мунча әзер булгач, Фатыйма Камиләгә керде, ахирәтен мунчага дәште. Ул да түгел, тышта эңгер инде. Фатыйма бәрәңге арчыды, аш салды да тәрәзә янына килеп утырды. Уйга чумды. Күзе карт өянке күләгәсенә төште, шул күләгә аны хатирәләр дулкынына алып кереп китте. Шушы йортка төшкәч, атна үтүгә, ул беренче тапкыр мунча ягарга килде. Мунчага сөялеп диярлек үскән карт өянкене күргәч, Фатыйма шаклар каткан иде. Өянке шундый карт, шундый карт иде ки, көнчыгыш ягындагы ботакларының күбесе корыган, кәүсәсе киртләч-киртләч килеп кантарланып беткән, бил тирәсенәрәк уралган тимер чыбык тәнен ертып кергән, шул төштә өянкенең кәүсәсе буынланып тора. Мунчаны Харисның әтисе салган, нигез буенда үскән яшь талны әтисе кисеп ташларга иткән дә, әнисе ирек бирмәгән, үссен безнең бәхеткә дигән имеш. Өянке янына килдеме, Фатыйма әле булса таң кала: карт тал аңа кем беләндер сөйләшә, кемгәдер зарлана шикелле. Өянкенең яфраклары шыбырдап тора, җил каты искәндә, кемгәдер ачуланыпмы, карт тал ябалдашлары белән мунча түбәсен чәбәкләргә керешә. Мунчаны ачуланамы шулай, үгетлиме, өйрәтәме, һич аңламассың. Нәкъ менә үлем түшәгендә яткан, яшәп-яшәп тә дөнья хәлләренең асылына төшенеп җитә алмаган, әмма үзе ясаган хаталарны оныкларыннан ясатмаска тырышып, акыл өйрәтергә, үгетләргә яратучан картлар кебек кылана өянке. Чынлап та, кеше дә бит бер картайдымы, кысылмаган җире калмый, барысын да күрә, барысына да өлгерә, һәммәсен белә, аңлый сыман, ә бактың исә, барысына да соңга калган икән инде.

Фатыйма якты көздә мунча керергә яратмый, тәне оялa, ул караңгы төшкәч кенә юынырга килә. Бу вакытта аны карт өянкедән башка берәү дә күрми, ә өянке шул хәтле картайган ки, төннәр буена сукранып чыга. Караңгы төндә агач әллә ниткән карачкыга охшап кала, җил чыктымы, котны алып, шыгырдарга тотына, шундый вакытта Фатыйма аны кызганып куя. Җил туктауга, карт өянке авыр итеп сулыш ала, җиргә чүгеп, кемнәндер мәрхәмәт сорый кебек.

Фатыйма инде икенче тапкыр чабына, ә Камилә һаман килми дә килми. «Әллә ут алмаганга килмәве моның?» — дип уйлый Фатыйма, үзе исә караңгыда, эссе мунчаның ләүкәсендә изрәп утыра бирә. Бик эсселәнә башласа, алгы якка чыга, чүмеч белән салкын су ала да калку күкрәгенә коя. Рәхәт булып китә. Аның чыкканын сизгәндәй, карт өянке ябалдашлары белән мунча түбәсен чәбәкли башлый. Фатыйма аны гүя ишетми, ул почмактагы ләгәннән янә чүмеч тутырып салкын су ала, янә кайнар тәненә коя; салкын су тәнне җилкендереп, тәмле итеп кытыклый-кытыклый, култык асларына агып төшә. Шул мәлдә Фатыймага кемдер аны йомшак кына сөя, иркәли, назлый кебек тоела. Фатыйманың шундый уйларын сизгәндәй, карт өянке мунча түбәсен тагын да куәтлерәк чәбәкләргә керешә. Фатыйма эссе мунчага керә, ләүкәгә менә һәм парларга куйган кайнар себеркесен йөзенә каплый да тирән итеп сулыш ала, әчкелтем-татлы каен исе күкрәгенә тула, Фатыйманың күңеле сафланып китә. Хатын үзенең йөрәк тибешен ишетә. Шул мәлдә аңа мунчада чынлап та берәү бар кебек тоела башлый. Йорт иясеме шулай эрсезләнеп йөри, ул тәгаен ләүкәгә таба килә шикелле, менә-менә үрелеп Фатыйманың аягыннан эләктерер кебек. Шунда хатын:

— Ах! — дип, киерелеп, себерке белән аркасына суга, мизгел эчендә күңелендәге шом юкка чыга, Фатыйма үзалдына сөйләнә-сөйләнә, ахылдый-ухылдый чабынырга керешә.

Бераздан ул хәлсезләнеп, астагы сәкегә төшеп утыра һәм шунда тыштагы өянкенең янә мунча түбәсен чәбәкләвен ишетә. Фатыйма чүмеч ала да, һичнигә игътибар итмәстән, Таң чишмәсенең суы белән чәчен юа башлый.

— Ахирәт, ахирәт дим! Менә мунча пәрие дисәң дә мунча пәрие инде. Ут алмый утырасыңмы әллә, тилекәй! — дип кычкыра алгы яктан Камилә.

Мунчага ахирәте Камилә килеп керә, аның кулындагы сукыр ут дерелдәп, күләгәләр уйната.

— Беләсеңме, ахирәткәем, Димка-солдат синдәге һансны татарча көйләр уйнарга өйрәтәм ди, аккордион табып биргән үзенә. Тегесенең түбәсе күккә тигән менәтерәк, ышанмасаң үзең кайтып кара. Җибәрик үзләрен мунчага.

— Алардан соң бу мунчага үзем ничек керермен?!

— Юып чыгарырмын мунчаңны. Керсеннәр, ахирәткәем. Алар да кеше бит. Житмәсә, сиңдәгеләр дә, миндәгеләр дә безнең яклы кешеләр ди.

— Миңа алар барыбер нимеч. Керсәләр дә, башта солдатны җибәрәбез...

— Ярый-ярый, шулай итәрбез,— Камилә ләүкәгә менеп китте, ташка су бөркеде.— Һә-һә, яккансың бертөрле итеп, ахирәт. Монда өч бөртек кеше түгел, бер полк солдат кереп чыгарлык...

— Бик җилпенмә, утны сүндерерсең.

— Сиңа аның барыбер кирәге юк, синең янда мин дә курыкмыйм, беләсең килсә.

Мунчадан кайтып керүгә, Димканы җибәрделәр. Солдат рәхмәт әйтә-әйтә чыгып йөгерде. Фатыйма белән Камилә чәй эчәргә утырды. Фатыйма чәчен икегә тарап төшергән, кара чәчләре иңбашларына сибелгән, битләрендә мунчадан соңгы алсу нурлар биешә иде.

— И-и, ахирәткәем, бу Харисымны төшемдә күрүләр бер бетәр микән, юкмы икән? Көн аралаш янымда йоклый сыман. Ул сөя, ул ярата, ул назлый, әллә ниләр шунда. Саташумы икән әллә? Уянып китәм дә котларым алынып ятам, әллә, мәйтәм, исән микән үзе? Исән булмаса, төшләремә шулай ап-ачык булып кермәс иде дим. Беркөнне Җәмилә әбигә сөйләгән идем, үзе булмаса да, җаны килә аның, балам, ди. Хәер биргәлә, ди. Килүдән туктар, ди. Ә минем аны күргән саен күрәсем килә.

— Сугыш бетүгә ничәмә айлар булды бит инде. Исән булса, хаты килмәсә дә хәбәре килер иде, юктыр, шулай хәбәрсез югалуларыдыр бахырның, ахирәт. Әй, ахирәт-ахирәт, ни әйтер идең дә бит таштай-тукмактай кайтып төшсә. Һай яратадыр идең үзен бертөрле итеп әй! Син бит Харисыңны бигерәкләр яратадыр иең, Фатыйма.

— Син Идрисеңне яратмый идеңме, җүләрем? Әле булса хәтеремдә, бер тапкыр мунчага дәштек үзегезне. Ис тигәнме үзеңә шунда, бермәлне сине күтәреп алып килеп керде бу. Ир башы белән җылады, мескенкәем. Үлде бит, мине ташлап китте бит, җанкисәгем, дип өзгәләнде. Нашатыр иснәтә-иснәтә исеңә килгәч, әй куанган иде, бичаракай.

— Юк инде, Фатыйма, синең Харисыңа җитмәс. Көнләшеп бетә алмыйдыр ием гөрләшеп яшәвегезгә...

Фатыйма күзләрен идәнгә текәде, башына салган яулыгын иңенә сыдырып төшерде. «Күр әле бу күңелне,— дип уйлады хатын.— Гел юкка куанып утырам, ә рәхәт булып китте».

Әйе, Харисны яратты ул. Аның сөюләрен онытып буламы соң?! Бер тапкыр алар югары болында куна калдылар. Харис чалгысын печән чүмәләсе өстенә ташлады да:

«Я, Фатыймакай, кабарга ниең бар, ашыйк та ятыйк»,— дип урын хәстәрләргә керешге. Айшап-эчеп алгач, алар яңа чабылган печән «түшәккә» яттылар. Энгер иңеп килә. Әле анда, әле монда йолдызлар кабына иде. Бераздан күк йөзе, алтын тәңкәләр сипкәндәй, чуарланып калды. Елга ягыннан томан канат җәйде. Сарут койрыклары муенны кытыклый. Харисның иреннәре битне пешерә. Шул төндә Харис аңа багышлап җыр җырлады. Ык суыдай талгын, саф, чиста, моңлы көй иде ул. Төнлә Фатыйма төш күрде. Имеш, күккә ашкан икән дә йолдызларны уятып йөри, үзе Харис җырлаган җырны җырлый. Йолдызлар нигәдер сүнгәннәр, әмма Фатыйманың килеп кагылуы була, алар зыңлап китә һәм, гөлт итеп кабынып, нур чәчә башлый. Ул да түгел, Фатыйма болынга төшә, бәйләм-бәйләм чәчәкләр җыя, чүмәлә төбендә йоклап яткан Харис янына килә. Ләкин чүмәлә төбендә Харис юк, имеш, аны кемдер алып киткән. Фатыйма күз яше белән еларга тотына.

Ул шунда чынлап та елап уянып киткән иде. Караса, Харисы янәшәсендә ята. Фатыйма иренең куенына кергәч, ире уянып китә һәм хатынын кысып-кысып кочаклый.

«Җүләрем, кысма шул тиклем, үтерәсең бит Фатыйманны... Карале, Харис, Таһир белән Зөһрә дә шулай яратышканнар микән?»

«Без алардан киммени?»

«Их, элегрәк белгән булсам, берәр ел алданрак чыккан булыр идем үзеңә».

«Ә нигә чыкмадың соң? Тәкъдим ясадым ич?»

«Курыктым. Гармунчы. Янында кызлар сырпалана».

«Ә мин сине генә яраттым. Күрүем булды: менә ул миңа дигән кыз, дип юрадым»...

— Күрче, күрче бәрәүне, әллә гел йокыга китеп утыра инде. Фатыйма дим, тилекәй, уян,— диде Камилә.— Хәзер солдатың кайтыр, самаварың яңарт.

Ялгызы калгач, Фатыйма урын җәйде, киштенә башлаган чәчен тарады, шунда берәүнең карашын тойды. Башта ул аны күрмәмешкә салышты һәм шундук үзенең сылу гәүдәсен күз алдына китерде. Әйдә карасын, тонсын күзе. Фатыйманың өстендә биленә сыланып торган алсу төстәге күлмәк, балтырларына чаклы кара чәчләре сибелеп төшкән. Озын иде чәч Фатыймада. Харисы аның толымнарына уралыр иде дә иләсләнеп: «Мин синең әсирең»,— дияр иде.

— Фройлейн!

— Ни кирәк? — Фатыйма башын чайкап, чәчләрен тузгытып җибәрде. Әсир һанс ишарәләр белән нидер сорый иде. Кулында иске аккордеон.

— Энструмент...

Немец бармагын бармакка ышкып күрсәтте. «Кораллар сорый, ахры»,— дип Фатыйма чәчен баш түбәсенә өеп куйды да тасма белән бәйләде, аягына чүәк элеп, алгы якка чыкты, Харисның кораллар әрҗәсен табып бирде.

Немец телне аңламады, әмма хатынның күз карашыннан төшендe булса кирәк, тиз генә аккордеонга барып ябышты.

— Музика, гу-гу...

— Яса инде бик теләгәч.— Фатыйма почмактагы иске киез өстендә йокымсырап утырган икенче әсиргә күз төшереп алды. һанс рәхмәт әйтә-әйтә эшкә керешге.

Фатыйма алгы якка керде дә көзге каршына басты. Күрер күзгә юантыграк гәүдәле, җалпаграк борынлы иде ул; күзләре гүя як-якка йөгереп китәргә тора, тулы иреннәрендә әйтелмәгән сүз калган сыман — елмайганда бит очларында кәҗә бәтие тоягы хәтле генә чокыр хасил була.

Солдат кайтып керде дә, ах-ух килә-килә, чәй эчәргә утырды. Димка өстәл тутырып чәй-шикәр куйды, букчасыннан бер бөтен ипи чыгарды, тушенка ачты.

— Фатыйма апа, әйдәгез, чәй эчәбез.

— Рәхмәт, мин эчтем инде,— диде Фатыйма чаршау артыннан.—Нимечләреңне мунчага җибәрәсеңме соң?

— Бара күрсеннәр,— Димка алгы якка чыгып, немецларга нидер әйтеп керде.— Башлары күккә тиде... Ә син,— дип кинәт «син»гә күчте ул,— кин күңелле хатын икәнсең. Өйләнсәм мин дә, боерган итсә, синдәй хатынга өйләнәм. Матур, таза булсын, күзләре җете кара, мәченеке кебек янып торсын.

— Бик телеңә салынсаң, чүәк янда гына, алдым салдым башыңа берне.

— һм-м, бетте, бетте, гафу... Бер йомыш бар иде сезгә, Фатыйма апа. Моннан ике өй аша гына бер кыз бар, Валя исемле. Киләм дип вәгъдә иткән иде.

— Бар инде, бар, алып кер,— диде Фатыйма. Ул күрше авыл кызы Валяны белә иде. Кибеттә сатучы булып эшли. Телгә җор Димка, күрәсең, аның белән танышып та өлгергән иде.

Күп тә үтмәде, Димка әйләнеп тә кайтты, артында бусагадан узарга оялыбрак, әлеге Валя басып тора иде.

— Узыгыз инде, узыгыз. Кич утырыргамы? Рәхим генә итә күрегез.

— Әйдә, Валечка, түргә узып утыр,— диде Димка кинәт дәртләнеп һәм кыюланып.— Хәзер музыка да булдырам. Фатыйма апа, сез каршы түгелдер бит?

— Каян алмакчысың ул музыканы?

— һә,— солдат ишекне ачып, әсиргә эндәште.— һанс, кер әле монда.

Немец керде, аккордеонын тез өстенә куеп, бусагага утырды.

— Сыздыр әле бер татар көен.

— Юк, натчар белә.

— Өйрәнергә вакыт. Әйдә соң белгәнеңне, Штраус вальсын.

Фатыйманың күптән мондый моңнарны ишеткәне юк иде инде. Әллә нишләтә күңелне, һәр аһәң бөтен тән буйлап чымыр-чымыр йөгерә. Күрче, күрче бу һансны, бармакларын гына күрче, ни тамаша йомшак кына итеп баскан кебек, ә көе тәмам күңелне айкый. Өй эченә моң тулды, ул ишеккә килеп бәрелде, тәрәзәләргә чиртте, почмакларга ташланды, ахырда, чыгар урын табылмагангамы, өй тутырып яңгырарга кереште. Штраус. Харис уйнарга ярата иде шул вальсны. һансның кылган чәчләре маңгаена төшкән, аккордеон көенә сихерләнгән бер кыяфәттә почмакка төбәлгән дә уйный да уйный. «Туган илен исенә төшерәме икән әллә? Йөргән кызынмы?» — дип, кул эшен бер якка куеп, дөньясын онытып тынлап утырды Фатыйма. Көй аның йөрәген кузгатып җибәрде, хәтта күңелендә әсиргә карата кызгану хисе уянды. һанс кинәт кенә «Катюша»га күчте. Димка белән Валя күзгә-күз карашып алдылар да беравыздан диярлек

жырлап жибәрделәр. Фатыйма башына япкан яулыгын иңнәренә төшерде, белгән кадәр җырга кушылды.

...Расцветали яблони и груши,
Поплыли туманы над рекой...

Күр инде бу җырны тагын, ничек шул тиклем күзгә күренә сурәте. Язгы бакча, иртәнге томан, бакча башында Харис басып тора, кул изи, үзенә дәшә ире. Я инде, нишләвең бу тагын? Харис та Харис! Күмү тигән булса, сөякләре череп барадыр инде Харисының.

— Фатыйма апа, әллә елап утырасыз инде,— диде Валя.— Минем әни дә елый шул көйне ишетсә...

— Юк, Валя, болай гына ул, моңсурак булып китте.

Һансның уйный-уйный бит очлары алсуланды, сары кашлары уйнакланды, күзләре елмайды. Ул да күрде Фатыйманың күзенә яшь тулуын һәм нигәдер тагын да дәртләнебрәк уйнарга кереште.

Җыр беткәч, Димка Фатыймага:

— Әйдәгез, без татар көен дә җырлыйбыз. Ну, Валя, син беләсеңме теге ничек әле?..

— Галиябанунымы?

— Әйе,— диде Димка югалткан әйберен тапкандай шатланып.— Һанс, Фатыйма апа җырлый, син, давай, җайлаш. Булдырасың син аны.

Немец, җырның сүзләрен аңламаса да, Фатыйма җырлый башлауга, дикъкать белән тыңларга кереште.

Тәрәзә төбе каты бал,
Ашыйсың килсә ватып ал...

Һанс чынлап та көйне шундук отып алды, икенче мәлдә инде ул башын кырын сала төшеп, уйнап та җибәрде. Өйдәгеләр тын калдылар. Гаҗәпләнмәслек тә түгел иде, немец бик үк җиренә җиткермәсә дә, «Галиябану» көен уйный иде. Һансның бармаклары аккордеон теленә баскан саен, моң да нәфисләнә бара. Гуя ул шул озын бармаклары белән тоткынлыкта яткан моңнарның әле бер капкасын, әле икенчесен ача, ирекккә чыккан моң исә йөрәкләргә былбыл булып килеп куна, бәгырьләрне телә. «Күрче бармакларын, шүрәленекемени»,— дип уйлады Фатыйма, немецның уйнавына сокलануын яшермичә. Ул да түгел, яшьләрнең ни теләүләрен аңлапмы, Һанс вальска күчте. Димка белән Валя күзгә-күз карашып алдылар да биергә керештеләр, дуу килеп бөтерелә башладылар.

Төнлә ул бер ялгызы калды, Димка-солдат Валяны озата китте. Фатыйма, тоткасы аша кисәү таягы үткәреп, ишекне эчтән бикләп куйды. Ни күңеле тынычланып ятса да, берничә тапкыр сискәнеп, уянып киткаләде. Моңа кадәр гамьсез генә йөри иде бит әле, Диманың Валя белән дуу килеп биюе, кылган чәчләрен туздырып, як-якка селкенә-селкенә Һансның дәртләнеп аккордеонда «Галиябану» көен уйнавы күңелгә әллә ниткән шик-шом салды да куйды.

Һансның болай кылануын иптәше өнәми, ачулана, я көннәр буе сөйләшми иде. Аның шулай турсаюына Һанс бөтенләй игътибар итми, алданрак кайткан булса, Фатыйманы күреп йөгереп килеп, кече капканы ача, һич югы чиләкләр алып, чишмәгә суга китә иде. Кич белән ул капка каршына чыга, урамда җырлап йөргән егетләрнең көйләрен ота һәм икенче көнне үк шуны сыздырып уйнап утыра башлый иде. Беркөнне «Каз канаты» көен откан. Шундый килештереп, бар җирен-җаен китереп уйнап җибәрде ки, Фатыйма тамагына төер тыгылып, идән юган җиреннән туктап калды. Харис өздерер иде шул көйне, күңелләр айкалып китәр иде шул чак. Күр әле моны, гел килештерә бит бу да!

Фатыйма түзмәде, түр якның ишеген ачып куйды, көй алгы өйгә керде, йөрәкләрне җилкендерә, бәгырьләрне телә башлады. Һансның өстендә яшькелт гимнастерка, ул аны атна саен юып тора, шуңамы, кием уңган ситсага охшап калган. Ә йөзендә язып та, әйтеп тә бетермәслек җитдилек. Фатыйманың күңелен күрер өчен «Каз канаты» көен өздерә, солдатканың болай да әрнүле йөрәгенә көлтә-көлтә ут сала, хәсрәт өсти, мөртәт немеч.

Фатыйма шапылдатып ишекне япкач, түшәмнән чүп коела, бермалгә тәрәзә пыялалары зыңлап тора. Һанс уйнаудан туктый, аккордеонын сак кына агач караватка куя һәм музыка коралын иске яулык белән яба. Шунда ук яулыкка борынын төртә дә озак итеп иләсләнеп сулый, иптәше моңа карап тора-тора да:

— Җүләр! — ди. Һанс аның ягына күз сирпеп тә карамый, ул яулык япкан аккордеонны ала да, ишекне ачып, мунчага таба чыгып китә. Иптәше белә: ул анда «Галиябану», «Шахта», «Каз канаты» һәм аңа таныш булмаган әллә ниткән татар көйләрен төне буе өйрәнәчәк. Ә иртән, таң беленер-беленмәс кайтыр да, шыпырт кына кереп, ятып йоклар. Кичке якта Фатыйма эштән кайтуга, яңа көй өйрәнгән булыр, сыздырып-сыздырып уйнар, аның шулай уйнавына мөкиббән китеп, күрше карчыгы Нәсимә апай коймa аша тыңлап торыр һәм яулык очын күзләреннән алмас. Икенче көнне Фатыйманы күрсә, карчыкларга хас кызгану белән:

— Татармы әллә ул синең нимечең, татар булса, чык та куй үзенә, синең дә күзләреңә уй төшкән, тикмәгә түгел бу, балам. Уеңны уй итмәсәң, гомер бакыена бәхет күрмәссең,— диде.

Фатыйма нәзек кыйгач кашларын җыерды, шомырт кара күзләрен кыса төште дә, ни әйтергә белмәүдән тәмам чарасыз калып, тулы иреннәрен бөрештереп беразторгач: «Ни сөйлисең син, мәнсез карчык, ни булсын минем уемда?» — дип ярсына-ярсына китеп барды. Өенә кергәч, ул караватына капланып, тамагына килеп тыгылган төерне үткәреп җибәрә алмый ятты. Шунда аңарда үз-үзен кызгану хисе уянды, аяз көндә яшен сукса гына күз салса салыр ул әсир немецка. «Юрама юкны, Нәсимә әби. Рәнҗетмә болай да китек күңелле кешене»,— дип үртәлде ул күрше карчыгына.

Шул вакыт кыштыр-кыштыр күрше карчыгы үзе килеп керде. Карчык төкереген йотып, башына бәйләгән француз яулыгын рәтләп торды, аскы ияген күтәрә төшеп, юка иреннәрен елмаюга җәйде.

— Япа-ялгыз хатын янында япа-ялгыз ир яшәми, балакай. Сөләйман пәйгамбәр әйткән ди, зат янында зат ятканда таң атмас, таңнар атса да, җан атмас дип әйтеп әйткән ди, җүләркәем. Ике гомер яшәрмен дип беләсеңме, гүргә кереп чермәс сөякләрең бармы әллә?! Зифа сының, кайнар каның бар икән, хафалы уйлар бар да бар инде ул синдә, балакай... Күзең әйтә, йөзең әйтә, йөрәгең купкан, күңелең ятмаса — саклан, ятса — баш тартма. Чык та куй шул солдатка. Карык хатынга бер ир кайтты, ир янында хатын үлмәс, ил өстендә ир үлмәс, бала...

Фатыйма үртәлеп-үксеп елап җибәрде. Аннары тынычлана төшкәч, түшәмгә карады. Торып утырды. Бу хәлне күреп, күрше карчыгы дәшми-тынмый гына чыгып китте.

Фатыйма уңып калган яулыгын, башыннан сыдырып алып, битенә каплады. Кемдә юк ул нәүмизлек? Әсирнең үзендә яшәве Фатыймага тора-бара кызык тоелды, булдыра алган кадәр аңа татарча сүзләр өйрәтте. Ә күрше карчыгы әнә ни сөйли.

Кич белән шулай тел өйрәнеп утырганда Фатыйма Һанстан сорап куйды:

— Кем идең син сугышта?

Татар телен шактый тиз сукалый башлаган, аш-суны гына түгел, өйдәге һәр әйбернең исемен-затын үзенчә сакаулап булса да аңлата алган Һанс әүвәл бу сорауны аңламый торды.

— Бүләм. Сугаштэ,— Һанс самавыр торбасын алды.— Пум-пум,— диде. Аннары бер тәлинкәгә ике кашык белән суккалап торды.— Музыка.

«Димәк, син рәтләп сугышмагансың да икән, музыка уйнап кына йөргәнсең,— дип үз-үзен тынычландырырга тырышты Фатыйма.— Нәсимә әби мине, солдат белән тора дип уйлый, ахры. Чит кеше күңелләрен белеп кенә бетереп булса икән ул...»

Яхшылык эшләү, изгелек кылу, кызгану-җәлләү Фатыйманың холкына сыймаган нәрсә түгел иде, хатын-кыз буларак кешегә инәлеп бәйләнә белмәде, юк-барга кычкырынмады, күрше-тирә белән бер тапкыр да телгә килмәде, әйткән белән күнсә-күнде, күнмәсә — юк, мәгәр кешегә авыз ачып каршы сүз әйтмәде. Бик тә ачуы килсә дә, кешегә ишеттерми генә: «Кадалып кит!» — ди торган иде. Бу сүзне дә ул Харистан отып калган иде. Күп вакытта ул үзен мескен, нәүмиз итеп тоя, аның бу халәтен сизеп алган ахирәте Камилә:

— Ишен югалткан дуадак каз сыман йөрмә әле, күпме сагынсаң да, күпме зарыксаң да, үлгән артыннан үлеп булмый, әграк акыл белән яшәргә вакыттыр инде сиңа да, ахирәткәй,— диде.— Мине әнә аксак Төхфәтуллага димлиләр. Килде беркөнне, ярты кыстырган. Бордым да җибәрдем үзен. Күчеп киләсең икән, яртысыз гына кил дидем. Ап-аек көе килде. Күндем әнә...

Шул сөйләшүдән соң бер атнадан аксак Төхфәт Камиләгә күчеп килде. Гөрләшеп яши башладылар, ике көнгә бер Фатыйманың мунчасын яктылар. Фатыйма мунчага алардан соң төн канат яргач кына барды. Караңгы мунчада

йорт иясе белән генә сөйләшеп, озак итеп, хәлдән тайганчы мунча керде. Шулай иткәндә төш күрергә дә өлгерми йоклый торган иде.

Беркөнне Камилә белән Төхфәтулла Фатыйманы ашка дәштеләр. Ичмасам гармунында уйнар дип, Камилә Һанска да әйткән булды. Һанс, рөхсәт сорагандай, Фатыймага карады. Аннары түр якта китап укып утыручы Димкага карады.

— Керсен,— диде Димка-солдат.

Камиләгә Төхфәт белән бергә булу килешкән күрәсең, хатын җорланып киткән, табын белән мич арасында җил-җил килеп йөри, ир дә барысын да тапкан берәүдәй өстәл янында кәперәеп утыра. Төхфәт киң кашлы, зур борынлы, кара-кучкыл чырайлы, аксаганда аның бер җилкәсе түбән төшеп китә, җиргә җитмәгән аягын тотып алырга теләгәндәй, кинәт сул якка үрелеп куйган шикелле итә. Язмышын шул инвалид белән бәйләвенә Камилә дә үкенми ахры, кияүгә чыкканнан соң, хатынга тәмам канат үсте: күзләре елтырый, күкрәкләре тулышып китте, йөрешенә кадәр үзгәрде. Фатыйма кебек ир-аттан бер дә тартынып тормый, үткәндә дә, сүткәндә дә Төхфәтнең чәчен туздырып китә, я агач аягына баса.

— Бас-бас, барыбер сизмим,— ди Төхфәт һәм тәмле итеп, үз итеп Камиләсенең йомшак җиренә шапылдатып сугып ала.

Һанс өстәлнең бер читендә көлемсерәп тик утыра бирә, бер чынаяк чәй эчкәннән соң, аның какча сары йөзенә алсулык йөгерә, кылган чәчләре тырпаебрак китә, әсир юк-юк та моңаеп Фатыймага күз ташлап ала. Әмма Фатыйма, аңарда гамьнәре бөтенләй булмагандай, эченнән Харисы белән сөйләшә иде. Бераз утыргач, җырларга тотындылар. Һанс гармунын тартты, ул шул тиклем бирелеп уйнады ки, кылган чәчләре маңгаена төште, күзләренә нур өстәлде. Харис та шулай дөньясын онытып уйный торган иде. Фатыйма Һанс янына күчеп утырды да «Галиябану»ны уйнарга кушты.

— Казер.

— Карале, моның Һансы татарча сөйләшә башлаган бит,— диде Камилә иңгә-иң орынып утырган Төхфәтенә төртеп.

Фатыйманың күкрәк читләрендә нидер чатнап китте, ул үтергеч карашы белән ахирәтенә карады, торды да, ялт кына чөйдәге шәлен эләктереп, ишеккә ташланды.

Бу төнме? Бу төн көзнең ямьсез вә шыксыз бер төне иде. Төньяктан ачы җил исә, карлы яңгыр ява, аяк астында мәте лыжырдый. «Аһ, бу Камиләне, күрче, үзенә ир табып алган да кеше җанын кыйный, үтереп мыскыл итә, мәсхәрәли».

Кайтты да түр якка кереп бикләнде һәм, караватына капланып, туйганчы, күз кабаклары әчеткәнче елады.

Шуннан соң ул Камиләләргә бер тапкыр да кермәде, эштә дә аңардан бер читтәрәк булырга тырышты. Камилә эчтән көя, әйткәненә үкенә, үртәлә иде күрәсең, гел аның тирәсендә уралды, хәл-әхвәлен сораштырган булды, әмма Фатыйманың аңа барыбер җаны эремәде.

Беркөнне Һанс эштән берүзе генә кайтып керде.

— Иптәшең кая? — дип сорады Фатыйма. Ул немецка ачулана алмады, җаны Камиләгә генә әрнүле иде.

— Госпиталь ята,— диде Һанс.— Чүрли.

...Көн кичкә авышып килә, күк чалт аяз, салкынча, карлы яңгыр явганнан соң, янәдән аяк астын туңдырып җибәрде, тәрәзәдән кояш үрелеп карый, табын әзерләнгән өстәлгә төшә, күңелләргә җылы иңдереп, әллә ниткән өмет чаткылары өсти иде. Һанс алгы якта гармун тарта. Харис Фатыймага багышлап җырлаган көйне уйный. Берме, икеме генә җырлаган иде Фатыйма югыйсә, отып алган тагын үзе. Гаҗәеп җиңел итеп уйный, Фатыйманың йөрәге сулкылдап, ярсынып тибеп-тибеп куйгалады. «Ниләремә болай ярсуланам соң але, Димкасы да кайтмый ичмасам!» — дип үз халәтенә үзе төшенә алмас бер халдә өстәлен җыештырды Фатыйма. Ут кабызып, Димканың китабын укырга керешә. Ләкин укый алмады. Йокларга ятты. Тәрәзә башындагы чыпчык кыштыр-кыштыр килә, шылт итеп, өй бүрәнәләре утырып куя, өй кыегына кагылып, җил йөгереп узып китә.

...Бер чиратып, бер йомшартып торган язгы көндә Харис аны кич клубка спектакльгә алырга килгән иде. Дәшми-тынмый гына җыена башлаган кызына әнисе:

«Йөрмәсәң дә ярар иде инде, кызым»,— диде. Фатыйма белә: бу — әнисенең, «Бар-бар, кызым, тик иплә йөр»,— дигән сүзе иде.

Капка төбендә аны Харис көтеп тора иде. Фатыйманың чыгуы булды, егет аны кулына күтәреп алды да йөгерә-атлый олы юлга алып чыкты.

«Җүләрем, егасың бит. Беләсеңме, мин нигә пот?»

«Җил син, мамык син минем өчен, Фатыйма. Мин синең белән күккә оча алам»,— диде Харис, сулышы кабып. Сер бирергә яратмый иде, бахыр.

Төн бик акрын уза, башка әллә нигкән уйлар тула. Фатыйманың зиһенен йокы пәрәвезе урагандa: «Ишекне бикләдемме?» — диган уй килә, ләкин йокы сөреме көчлерәк тәэсир итә. Шундук төш күрә башлый. Ул, гүя, көймәдә икән. Ыкның аръягына йөзеп чыкмакчы, җил дә юк, кулда ишкәк тә юк, агымсу көймәне түбән таба алып китә. Фатыйма курыкмый, көймә аккан җайга бара бирә. Шунда көймәнең койрык очыннан Харис күтәрелә, көймә төбендәге йомшак печәнгә сузылып яткан Фатыйма янына килә. Тик нигәдер иренең чәче дә, кашлары да ап-ак. «Нишләдең син, Харис?» — дип сорый Фатыйма. Ире җавап бирми, бармаклары белән Фатыйманың күкрәген капшый, иңнәренә кагыла, түшенә башын салып, тынып кала. «Картайдыңмы шулай, чәчләрең гелән ап-ак булган, Харис җаным? — дип сорый Фатыйма.— Күзләрең дә уңган сыман. Картайгач, күзләр дә уңа микәнни, Харис? Нигә дәшмисең?! Китче, кая йөрдең моңа кадәр, нигә туры Актауга кайтмадың?.. Әсир төшсәң соң. Әнә миндә дә торалар бит әле, тиздән аларны да кайтарып җибәрәләр ди. Соң шулай дими, исән булгач,менә кайттың бит... Кысма мине, үпмә шул тиклем, көймә капланса нишләрбез, җүләрем...»

Фатыйма сискәнеп уянып китә. Тын. Күкрәгендә кемнеңдер кулы ята сыман... юрган бөкләнгән икән. Тынычланып, стенага таба әйләнеп ята һәм кинәт аңа карават янында берәү басып тора шикелле тоела башлый. Зиһене сафлана, әйләнеп карый.

— Кем бар монда?

«Беркем дә юк. Нишләвем бу? Саташам инде әллә?»

Әкрен генә тора, шәлен җилкәсенә сала, тышка чыгарга җыена. Һансны уятмас өчен, ишекне сак кына ача. Алгы якта караңгы, иске агач карават шыгырдап куя. «Ул миңа тимәс, җүләр түгел бит. Миңа кагылса, аны атарлар»,— дип уйлый Фатыйма баскычтан төшкәндә.

Ләкин әйләнеп кергәндә аның Һанска дәшәсе килеп китә, ул хәтта бер мизгелгә ишек янына туктала, салкын корычтан ясалган тоткага кулын салгач кына, айнып китә, кабаланып түр якка уза, ишек келәсен төшерә. Йөрәге дөп-дөп тибә, колак янында нидер гөжли, дулкынланудан шулай бу. «Тиле дә соң үзем, башы ике мәллә аның миңа тиярга!» Фатыйма тынычлана, урынына ята...

Иртән ул торганда Һанс эшкә киткән иде инде. Яулык япкан аккордеонга кагылып алгач, нишләптер аның бөтер тәне кымырҗып китте. «Уф аллам, нигә шулай куркам соң әле мин бу немечтән? Миндә гаме дә юк ич аның!..»

Кич эштән кайткач, аш пешерде,тамак ялгады, Һанска бер тәлинкә аш чыгарды, аккордеон шыгырдатып утырган немец, ризыкны күргә, ни әйтергә белми аптырап калды.

— Миңгә?

— Әйе, аша,— диде Фатыйма.— Әпәең бармы? Иптәшең кая соң?

— Баг-баг. Казер кайта.

— Баг түгел, бар.

— Баг, барр,— дип, Һанс нечкә бармаклары белән кашыкка тотынды. Сәер итеп тота иде немец кашыкны, авыр көрәк тоткан сыман, учлап, йомарлап.

«Кашык та тота белми, бигрәк ят инде, бичара». Холкына сыймаган нәрсә булса да, Фатыйма бер заман немецка күнегә башлады. Димка ике көнгә бер генә куна-кайта йөрде.

— Син начар йокладың, әйе? — диде беркөнне иртән Һанс Фатыймага.

— Саташтым. Син тиледән куркып яттым.

— Син түкел, мин курка синнән.

«Курка, куркытырсың син мөртәтне»,— дип уйланды Фатыйма.

Ашагач, Һанс ишегалдына чыгып китте, мунчага таба юнәлде, ул анда бик шакылдый башлагач, Фатыйма да шунда килде.

— Нишлисең син монда?

— Ишек салынган. Ясау кәрәк...

Чынлап та ишекнең бер күгәне суырылып чыккан, шуңамы, әйбәтләп ябылып җитми иде. Һанс ишекне күтәреп алды да, күгән тишегенә агач чөй ясап тыкты, күгәнне балта түтәсе белән сак кына кагып куйды, аннары ишекне әлде, ябып карады.

— Гуд. Якшы булдым...

Фатыйма үз-үзен тирги-тирги өйгә атлады. Бу тырыш кеше җегәрен кая куярга белми интегә, мин, тиле, аның артыннан аптырап-йөдәп йөрим. Өйдә эш беткәнме?

Бүген ул кырга сабанга чыккач, тургай сайраганны ишетте. Атларын туктатып, кошчыкның моңын һушы китеп тыңлады. Зеңгер-зеңгер кояр да кояр моңын кыр өстенә мескен кошкай. Кемгә шулай дәртләнеп-өзгәләнеп сайрый, кемне чакыра икән? Бәлкем, ул да минем кебек япа-ялгыздыр, сайрый-сайрый иптәшен эзлидер. Ә тегесе еракта-еракта, кайтмый да кайтмый. Бер тапкыр көлтә бәйләргә килгәч, Харис аны шушы басуда утыртып куйган көлтәләр арасына алып кереп үпкән иде. Лобогрейкада эшләгәнгәме, Харистан тир исе килә, сулышы кайнар, иреннәре каты иде. Шундагы көлешү, үртәшү-шаяртуларны, яшерен генә каш сикертүләрне, күз кысуларны, кибән артына качып, мыштым гына иреннәрне көйдергәнче үбешүләрне онытып буламы, онытырлык хәлләрме алар...

Кичке ашка ул Һансны үз өстәле янына дәште. Итле аш иде, әсир ике тәлинкәгә якын ашады, ике-өч чынаяк чәй эчте.

— Бу ишек ясаган үчен, әйе? — диде ул көлемсерәп.

Нәрсә-нәрсә, ипи, тоз, чәй, ишек, савыт, кашык кебек сүзләрне Һанс нәкъ татарча итеп әйтә башлаган иде. «Әйе»не ул сүз саен әйтә, «әйе» аның өчен килешүне дә, сорауны да, тагын әллә нинди мәгънәләрне аңлата иде, күрәсең.

Аннары ул аккордеон уйнады, татарча җырларга тырышып карады. Фатыйма аңа карап, бәйләү бәйләп утырды.

Урын җәя башлауга, Һанс чыгып китте, бик озак алгы якта йөренде. Фатыйма ятты. Йокыга китәр алдыннан тагын: «Ишекне әллә бикләдем, әллә юк»,— дип уйлап алды. Мәгәр торып карарга ихтыяры җитмәде, ару тәмам хәлен бетергән иде. Бүген ул гектарга якын җир сөрде, хисапчы аксак Төхфәт: «Беренче урын синдә, Фатыйма!» — дип мутланды. Эштән кайтканда идарәгә керде, кузенә ташлануы сәбәп булдымы, күптәнге нияте идеме, күкрәгенә орденнар, медальләр таккан яңа председатель Галләм Кыямов Фатыйманың терсәгеннән алды да:

— Фатыйма, без сине сыер саварга күчерергә булдык бит әле, ничек уйлыйсың? — диде.— Сабан сөрүне тракторларга, ирләргә бирер вакыт җитте кебек.

— Ярый соң,— диде Фатыйма килешеп. Сабан сөрү аңа чынлап та бик авыр иде.

Фатыйма һичкайчан зарлану-сыктану дигән нәрсәне белмәде, сугыш елларындамы, соңыннанмы, нужа арбасын иң төпкә җигелеп тартты, олысы-кечесе аны хөрмәт итә, яхшы яктан гына телгә ала, яманлыгын күрүче булмады. Юантыграк балтырлы, ирләрнекенә генә хас зуррак куллы, карсаграк гәүдәле, тулы янбашлы, кыскарак билле хатында чынлап та көч-гайрәт мөлдерәп тора иде шикелле.

Күзләрен йомуы булды — тагын шул көймә. «Нигә көймә? — дип уйлады Фатыйма.— Алар Харис белән печән эчендә йоклаганнар иде ләбаса, нигә бу көймә һаман күз алдына килә икән?»

Ни генә булмасын, көймә эчендә ятып йокыга китүе рәхәт иде. Тиздән янына Харисы килер, кочар, иркәләр, назлар, сөяр. Аннары рәхәт-рәхәт булып китәр. Тик чәчләре генә нигәдер ак бу Харисның, кашлары да уңган сыман саргайган, тырпаеп торалар.

Көймә чайкала, Фатыйма янына янә Харисы килә.

«Харис, нигә син болай бик озак кайтмый йөрдең? Мин бит сине бик тә, бик тә сагындым, җанкисәгем... Әй, белсәң икән ялгыз яшәүләрнең кыенлыкларын, Харисым... Кочакла, кочакла, нык кысып кочакла... Их, Харис! Бу кадәр булмастыр инде... Кай арада кайттың соң әле син... Камилә әнә Төхфәткә кияүгә чыкты, ә мин сине көттем. Көттем дә көттем. Кайта икән ул ирләр бик көткәч... Менә кайттың ич... Берәү дә күрмәсә ни, иртәгә үк ишетерләр, күрерләр... Хәтерендәме, бер тапкыр печән чүмәләсе төбендә кунган идек... Шул мәлләрне сагыныпмы, кочак...»

Фатыйма үз тавышыннан үзе куркынып уянып китте. Куллары белән юрганны бөтәрләп кыскан, бөтен тәне калтырана, аркасында салкын тир.

Әй, ходаем, бу нинди төш инде тагын?

Өй эче тыныч, әмма алгы якта кемдер йөренә кебек. Бер тын яткач, күргән хәлләре бары тик төш кенә икәненә ингангач, Фатыйма торды, юынды, киенде дә казан астына ут салды.

Иртән кояш чыгып, ишегалдына аяк басуга, Фатыйма нигәдер өй кыегында утыручы чыпчыкка игътибар итте. Чыпчык тырыша-тырыша үзенчә сайрый, кемнедер үз янына дәшә иде. Ә инде бүрекле иптәше янына килеп кунгач, канатларын җәеп, йоннарын кабартып, чыр-чыр килеп кинәнә башлады, ахыр килеп ни кыланырга белми, бөтерелергә тотынды.

Фатыйма көянтә-чиләк алды да чишмәгә суга китте. Урамга чыгуы булды, югары очта әсирләр төялгән машинаны күреп алды. Ул кемнеңдер өй каршына туктаган иде. Фатыйманың нишләптер йөрәге жуу итеп китте.

Әрҗәдә — әсир немецлар. Алар арасында Һанс та күренде. Ул Фатыймага кул болгый, туктарга кушамы, әллә нишли шунда. Әмма Фатыйма туктап тормады, тиз-тиз атлап, чишмәгә юнәлде.

Җай гына, көйле генә чишмәдән кайтып килгәндә, өе каршына туктаган машинаны күрүгә, Фатыйма үзе дә аңлап бетермәгән тәэсир хафасында адымын тизләтте.

Ни булыр бу? Нигә аның капка төбендә тора ул машина! Әллә соң? Ходаем!..

Фатыйма килеп җитүгә, капкадан Димка-солдат килеп чыкты.

— Фатыйма апа, коткарабыз үзеңне немецлардан, илләренә китәләр. Котыласың...

Фатыйма көянтә-чиләкләрен җиргә куйды да, ни әйтергә белми, катты да калды. Аның янына Һанс килде.

— Эчү ярый,— диде ул Фатыйманың күзләренә туры карарга тырышып.

Фатыйма сизелер-сизелмәс кенә ияк какты. Һанс җиргә тезләнеп, чиләкне чак кына аудара төшеп, салкын һәм саф чишмә суын эчте. Озак, бәлзәмдәй тәмләп эчте.

— Монда су тамлы, дуньяда юк! Сыйн да дуньяда берау гына, Фатыйма, мин сыйне йурагым болан алып китам...

— Рәхмәт сезгә, Фатыйма апа. Мең яшәгез,— диде Димка һәм Фатыйманың кулын кысты. Һанс та аңа таба бер адым ясады. Әмма Фатыйма чак кына артка тайпылгандай итте. Немец моны сиздеме, машина әрҗәсендә бөкшәеп утырган иптәшләреннән яхшысынмадымы, китәргә дип борылды, мәгәр ике адым ясамады, каерылып:

— Сыйн айтсаң, мин кала, Фатыйма,— диде.

Ул арада шофер машинасын кабызды, әрҗәдәге немецлар шаулаша башладылар. Фатыйма, Һанс аңларлык кына итеп, башын чайкады.

Менә машина кузгалды, ул ерагайганнан-ерагая барды, ә Фатыйма һаман бер урында басып торды. Бары тик йөрәге генә, күкрәк читлеген җимереп чыгарга җитешеп сикеренде, ни кылырга белми бәргәләнде.

................

# Әмир Мәхмүдов[1]

## Атакага бара шигырьләр...

Яу кырында, тыгыз окопларда
Ятып калсалар да шагыйрьләр,
Халыкларга авыр вакытларда
Атакага бара шигырьләр.

Атакага бара Фатих Кәрим,
Бар җисеме, тәне талса да.
Атакага бара Муса Җәлил,
Моабитта башын салса да.

Оста генераллар җиңеләләр,
Атакага шагыйрь барганда.
Шигырьләре Берлиннарны ала,
Шагыйрьләре ятып калганда.

Үлемнәрне җиңеп үлә шагыйрь...
Шигърияттә яши чын ирләр...
Шашынмагыз, дөнья җәлладлары!—
Атакага чыга шигырьләр.

## Үткәннәргә салават

Ялгыз калган чакларымда
Тынгы бирми төстәшем.
— Эч серләреңне сөйләп бир,—
Дигән сыман яшьтәшем
Сынап карый күзләремә.
Нинди җавап көтәсең?
— Мең сукмак,— ди,— синең алда,—
Кайсы юлдан китәсең?

Мең сукмакның берсе генә
Илтә сөйгән ярыма.
Бердәнберем өзелеп көтә,
Барып җит, тик арыма...
Зур дөнья адаштырдымы
Сөйкемле сөйгәнемне?!

---

[1] ӘМИР МӘХМҮДОВ (1947) — тәнкыйтьче галим һәм шагыйрь, филология фәннәре кандидаты, «Матурлык тантанасы» исемле шигырь китабы авторы. Казанда яши.

Кемнәр урлап, киң җиһанга
Таратты серләремне?!
Сөйгәнемнең серен ачып
Бирде бер көн сердәшем:
— Ул башканы сөя инде!
Алар яши гөрләшеп.

Ялгыз юлга чыккан чакта
Эзләп тапты төстәшем.
— Сөйгән ярыңнан хат бар!— дип,
Юкка чыкты сердәшем.
Кулларымда язган хаты,
Аның һәр сүзе алтын:
«Хатларым да, күз яшем дә
Булыр, ахры, сиңа ят,
Гафу ит, сөекле ярым,
Үткәннәргә салават!»

—Үткәннәргә салават!— дип,
Кабатлады иреннәр...
Яшеннәр кавыштыралса,
Гашыйклар көнләшерләр!
...Күңел күгендә яңгырый
Инде менә ничә кат:
— Сибәли бәхет яңгыры —
Кайгыларга салават!
Яшьлегеңә йөгереп кайт!
Мәхәббәткә кире кайт!

Сөйгәннәренә кайтала
Җирдә бары кыюлар.

Үз халәтемә кайттым мин,
Алып кайтты кыл юллар.

Яшьлегем тугайларында —
Алмачуар колыннар.
Зәңгәр күкне яңгыратып
Теләк тели былбыллар:
«Сез очрашкан бакчаларда
Сиреньнәр серләшерләр,
Гашыйкларны көнләштерер,
Кавыштырыр яшеннәр...»

## Сыкрау

Сыкрый күңел, сызлый йөрәк,
Кая куйыйм бу җанны?!
Кояшлы көн. Тирә-юнь тын...
Озатабыз Туфанны.

Тынычлан, җан! Тыныч җиһан...
Күзләреңнән ку яшьне!
Җиһан белән ул — бөек Җан!
Күмеп булмый Кояшны!

## Хыяллар иле

Юалы тугайларыма кайтып юаныйм әле,
Янар чәчәкләр эчендә
тагын югалыйм әле...
Ерак сукмаклардан урап, сиңа юл алыйм әле!

Сулар кипкән, тугайлар юк,
калган хыяллар иле...

## Елан агуы

Искәртмәстән чага елан...
Кешем, авыр тын алуың.
Әҗәл белән көрәш бара,
Бармы җирдә җан даруы?

Искәртмәстән чага елан...
Коткармый елап алуың...
Син чыдамлы, син түзәсең,
Сизсәң дә җаның талуын,
Сөйгән ярың — алиһәңнең
Белсәң дә елап калуын.

Могҗиза! Күзләреңдә — нур,—
Әйтерсең еллар януы.
Тормыш бүләк итә сиңа
Тылсымлы елан агуы:
Үзеңдә икән даруы!
Ярың килә көлә-көлә...
Кайгы ярып, бәхет килә...

## Рахмай Хисмәтуллин

### Сабан туена!

Читенлек белән саклаган
Саф күңел Акларымны,
Ят капкаларны какмаган
Уйларым-затларымны,
Дөньядан күптән аласы —
Алмаган Хакларымны,
Күп күңелләргә баглап та,
Салмаган Хатларымны,
Беркемгә яшь күрсәтмичә,
Җиде төн урталарында
Елаган Чакларымны
Чыгарам Сабан туена —
Чыгарам
Яшерен Чаптарымны!

### И Ватан

Ниләр булса да ил белән:
Тәмугым, оҗмахым да.
Гафу ит, кайчак сөйләнсәк —
Хагын да, нахагын да...

Нинди чакларың булмасын,
Син илем — газиз Ватан.
Син миңа гомер — җан биргән,
Син — анам һәм дә атам.

### Яңгыр яуганда, читтә...

...Туган якта аяз, нурлы, корыдыр.
Кайтсаң, кәкре юллары да турыдыр,
Һәр кешесе Алып кебек олыдыр,
Гүя анда каберләр дә җылыдыр...
Килми калмас, килер соңгы көнебез:
Чит җирләрдә рәнҗер микән көлебез?
Кемгә әйтим: «Туган якка күмегез...» —
Рәхәт эзләп, читкә киттек үзебез.
Зират үтәм: белмим, кемнәр гүредер...
Карлы яңгыр... Тешләр тешкә тиярдер.
...Туган җирдә үлгәннәр дә тередер...

Борынгыдан калган тыйнаклыкмы?
Яшерәбез, никтер, белгәнне.
Өйрәнгәнбез изгеләштерергә
Үзебездән өскә менгәнне,
Белер-белмәс бездән көлгәнне.
...Тау башына, шиксез, нур мул төшә,
Күләгәләр төшә үзәнгә.
Өстәге үзен бик зур сыман тоя —
Бары тик без башны игәнгә...

## Саумысез, ирлек елларым!

Шулмы яшьлекнең китүе,
Килдеме вакчыл гакыл?!
Нәрсәдер булды күңелгә,
Өзелде ниндидер кыл...
Нишләдең син, диңгез кебек
Давыллап торган күңел,
Бер гөл керфеген какса да,
Шатлыклар тулган күңел?!
Ни булды кырлар, урманнар,
Океаннар сыйган күңел,
Мең төрле телләр, күзләрдән
Энҗеләр җыйган күңел?
Сарды шул тирә-ягымны
Вакчыл уй, вакчыл гакыл:
«Дөнья бу! Яшим дисәң, син
Куй җырны, малга сатыл!».
...Хушыгыз, шигъри елларым,
Сау бул, даһилар юлы.
Хыяллар куйды канатын,
Уйларым сагыш колы...
...Ләкин, юк! Яшьлек үтсә дә,
Җырсыз юл миңа түгел!
Җыр-моңсыз яши алмыйдыр
Күк кебек иркен күңел!
Үтте еллар. Дулый-дулый
Яуды карлар, исте җил.
Очты кошлар... Кайтты кышлар...
Ялганды өзелгән кыл!
Ялганды кыл, яңарды кыл,
Моң тулып яшәрде кыл!
Тоташып яңа кылларга,
Җаным, күкләргә атыл!

Саумысез, ирлек елларым!
Саумы, хөр кеше юлы!
Хыялым — халкым канатлы,
Уйларым — илем тулы!

Минем тәнем үземнеке түгел,
Үземнеке түгел бу җаным.
Бар нәрсәмә материя хуҗа,
Узгынчысы мин бу дөньяның.
Материя мине тудырган да
Яшәештә иткән бер чәчәк.
Нинди асыл булса җан-кальбемдә,
Чиксезлеккә шуны илтәчәк.
Карт бакчачы — вакыт елларына
Җаным аша тәннән нур ала.
Һәр мизгелем мәгънә, гыйбрәт тулып,
Мәңгелеккә кереп урала.

Үзем теләп тумадым мин бу җиргә,
Хак табигать үзе чакырып китергән.
Кирәк булганмын мин, димәк, аңарга:
Минем аша үзен тоеп карарга.
Кайгырыйммы килер диеп үлем бер?
Туу-үлү — минем эшем түгелдер...
Үлем-китем — материя кайгысы,
Табигатьнең мин бары моң нервысы.
Моңым уйнап, китәм үтәп йоласын,
Дөнья үзе бер утырып еласын!

## Радик Фәизов

# ЯҢА КҮРШЕЛӘР

хикәя



Хөрмәт төштән соң ярты гына сәгать булса да черем итеп алырга күнеккән иде. Барып чыкмады бүген. Ул башын мендәргә төрткән генә иде, күршеләр тарафыннан ниндидер авазлар ишетелде.

— Ни бар тагын анда? — диде ул инде тәрәзәгә барып капланырга өлгергән хатыны Асылбикәгә.

— Күченеп килделәр ахры. Яңа күршеләр...— Асылбикә юан гәүдәсе белән тар тәрәзәгә кереп китәрдәй булып карана, ул менеп баскан урындык яман шыгырдый, таралып төшәргә әзер иде.

— Идәнгә кадаласың бит инде! — диде тәмам кәефе кырылган Хөрмәт. Өйдә хәзер алар пенсиядәге Асылбикәсе белән икәү генә, картлы-карчыклы уң як күршеләр тарафыннан шылт та юк, сул якларындагы йорт ничәмә еллар буш тора — тынычка, тәртипкә тәмам күнеккәннәр иде. Шайтан алгыры, инде кемнәрне генә җил ташлады икән.

— Кемнәр анда, нинди бәндәләр? — диде ул киенә-киенә.

— Ирле-хатынлы.

— Балалары да бармы тагын?

— Ниткән булмаган! Берәү, икәү... уф, җаным, бишәү! — дип хәбәр бирде Асылбикә.

Чәнчелеп киткерләре! Бар икән әле күрәселәр!.. Хөрмәт, сукрана-сукрана, ишеккә таба киткән иде дә, шулчак нидер чартлап сынган тавыш ишетелде. Ашыгып, мич арасына керсә, бөгеп ясалган борынгы урындык, алты потлы Асылбикәне күтәрә алмыйча, тәки изелеп төшкән, ярый әле үзе мәтәлеп китмәгән, бәрелгән тезен уып маташа иде.

— Әткәй мәрхүм төсе урындыкны... Бу кадәр бегемот булырсың икән! — диде Хөрмәт.

Мондый чакта бер дә җавапсыз калмый торган Асылбикә бу юлы әйткәләшеп тормады. Тагын күршеләрен сүз итте:

— Ул килеш-килбәтләрен күрсәң... Ире бер кара шадра, битендә женнәр борчак суккан диярсең. Ул хатыны, хатыны...

Хөрмәт артыгын тыңлап та тормады. Хатынының инде җилкапканы тиз генә япмасын белә иде. Эшнең асылы килеш-килбәттә түгел әле монда.

— Син торып тор. Мин үзем генә разведка салып керим әле,— диде ул һәм ишеккә китте.

Сәрбиҗамал әбинең өе авылның иң читендә, әби үзе инде күптән вафат, балалары бар да калада, йорты тузган, капкасы янтайган, койма такталары кайсы кая бару юлына чыккан иде. Менә хәзер шушы йорт янында ике машинадан йөк бушатып мәш киләләр.

---

РАДИК ФӘИЗОВ (1931) — прозаик. «Беренче адымнар», «Юлда», «Бәхет» һәм бүтән кыска хикәя китаплары авторы. Татарстанның атказанган культура хезмәткәре. «Коммунизмга» район газетасы редакциясендә эшли, Арча эшчеләр поселогында яши.

Артистлык та ярыйсы гына бирелгән иде Хөрмәткә. Капкадан килеп чыкканда, инде аның төсендә кәеф кырылуның әсәре дә юк, түгәрәк яңакларында елмаю, кашлар югары күтәрелгән иде. Ул, буй-сынны бик төз тотып, дәрәҗә саклап кына якын килде.

— Әһә, яңа күршеләр. Хуш киләсез!

Гаилә башы — ак лампаслы зәңгәр трико кигән ир, төенчеген куеп, аңа кулын бирде:

— Нургаян.

Яше белән инде Хөрмәтне куа килгән, буйга таманча, әмма бик киң иңсәле, авыр сынлы бер агай иде бу. Яңакларына әллә кара чәчәк кагылган, әллә башка берәр ни — шактый эре бөрчекләр бар, уртасы батмалы ияге алга чыгып тора. Бөтен кыяфәтеннән инде эшләп ватылган, дөнья басып килгән бер кеше икәне күренә. Тик менә аның күзләрендә генә егетләрчә дуамаллык, ниндидер бер дәрт бар, шаян чаткылар уйнап ала иде. Хөрмәт әченнән генә нәтиҗә чыгарып куйды: белеп булмый мондый кешеләрне.

— Хатыным Гөлбикә,— диде Нургаян, өстенә шулай ук трико гына кигән, бик тулы гәүдәле хатын ягына ым кагып. Анысы кулындагы әйберен куймыйча гына Хөрмәткә таба борылды, башын иеп кенә сәлам бирде. Түм-түгәрәк йөзле, сызылып киткән кашлы, ярыйсы гына ханым икән.

— Уһу, бикәләр ишәйде алайса безнең түбән очта. Минеке — Асылбикә. Үзем Хөрмәтулла булам,— дип таныштырды Хөрмәт.

— Әнә булышчылар да үсә,— дип сөйләп китте Нургаян, шау-гөр килеп төенчекләр ташып йөргән малайларга-кызларга күрсәтеп. Инде өчесе башка чыгып яши, менә бу тырпайган чәчле үсмер быел унынчыга керәсе, ә кече кызларына быел алты гына тула икән.— Сигезне үстердек, күрше, сигезне. Тулы бер отделение! — диде Нургаян.

Отделение түгел, хет взвод үстер идең, тик менә монда төянеп килүләрең... Алай да Хөрмәт күрми калмады: әлегә тәртипле генә күренә бу гаскәр. Менә тора-бара ни булыр?

— Кайсы яклардан үзегез?

— Шәһәрдән кайттык. Шахтер мин, пенсиягә чыктым,— диде Нургаян.

— Һмм, алай икән, алай икән... Әлеге дә баягы шәһәрдән очып кайткан кошлар икәнсез әле. Ул суреттә, күршекәем, бик озаклап сайрамассың да әле монда. Кайткан иде былтыр каладан башына тай типкән ике бәндә. Яңа мода чыгарып, янәсе. Берсе күптән инде табанын ялтыратты, икенчесе дә чак кына эләгеп тора. Сәрбиҗамал әбинең бу иске куышы шәһәр квартирымыни сиңа. Безнең урамнарга таш түшәлгәнмени. Җитмәсә шушы кадәр бала-чагаң белән, һи, җанашым...

Хөрмәтнең күңелендәге чамаладымы — Нургаян аңа гафу үтенгәндәй карап куйды.

— Гомерем буена авыл җирен сагынып яшәдем, күрше. Тамырларымны туфракка җибәрәсем килеп,— диде ул ихластан.— Ә үзебезнең Каргалы, бәлки беләсез дә булыр, инде таралып беткән. Тоттык та бире сугылдык менә.

— Ә нигә, бик мөбәрәк эш бу,— диде Хөрмәт һәм монда чыгуының төп сәбәбенә кереште.— Тик, ниме соң?.. Бик өшәнгән йортны сайлагансыз әле сез, күрше. Югары очта колхоз салып куйган квартирлар да бар бездә. Буш торган яңа йортлар дип әйтүем.

— Бар кайтуым җирне, иркенлекне теләүдән булды. Монда урынын җайлы таптым. Ә өйне яңартабыз аны. Аңлык кына чамабыз бар, күрше,— диде Нургаян һәм төенчеген кулына алды.

Хөрмәт яңа күршесенең киң аркасына карап, борыны аша һава өреп куйды. Барын да алдан исәпләп, ныклы уйда кайткан бу. Алай да сабыр итик әле, күпкә җитәр микән аның бу ныклыгы. Һәм Хөрмәт өенә таба атлады.

— Я,ниләр белдең анда? — дип каршылады аны хатыны.

— Шәһәрдән кайтканнар. Шахтадан.

— Һай, җаным. Бар икән адәмнәр! — диде Асылбикә.

Мәсьәләне уртага салып тикшергәч, мондый карарга килделәр: кырыклары бик тулып җитмәгән бәндәләр булырга тиеш болар. Тора бирсеннәр, монда бик озак юанмаслар әле. Алай да саграк булырга кирәк.

Әмма, сак булып та, ул кадәр ни кырасың әле? Яңа күршеләр килде дип, күзне йомып, колакларны мүкләп яши алмыйсың.

Иртәгәсен Хөрмәт, гадәтенчә, алтыда торып ишегалдына чыкты, бер көтү тавыкларына зур табак белән ачытки бирде. Көннәр көзгә авышып бара, иртәләр салкынча, ә салкын тию — иң әшәкесе, иң хәтәре. Хөрмәтнең аякта йон оекбаш

белән әбиләр галошы, өстә сырма, башта бүрек иде. Ул, тавыклар ашаганны карап, уйга калды. Әйе, кайбер мәшәкатьләр булыр инде. Менә бу ике арадагы койманы тагын да биегәйтеп яңадан коясы булыр. Хөрмәт шулай дип уйлаган гына иде, яңа күршеләр тарафыннан ниндидер авазлар ишетеп сагаеп калды. Койма ярыгы янына чүгәләп, теге якка күз салды. Нәкъ ярык турысында трикодан гына Гөлбикә басып тора иде... Менә Гөлбикә кулларын җәеп җибәрде, алга иелде һәм... Артка чигенеп барган Хөрмәт, үзе дә сизмичә, «лап» итеп ачыткы табагына утырды. Куркынган тавыклар чын гарасат күтәрделәр. Ә әтәч мәлгунь, нәкъ күзгә төбәп, биткә үк сикерде. Ярый әле җиңнәре белән капланып өлгерде Хөрмәт. Шунда күзеңне чукып алса, ни булыр иде!..

Ул актык сүзләре белән тиргәнеп, табактан торды. Күр инде бу хурлыкны, бу чалбар төбен күр... Тик алай да өенә кереп китәргә ашыкмады әле. Бу ниткән әкәмәт булды бу тегеләр ягында? Белми калырга һич тә ярамый моны. Һәм ул икенче, киңрәк ярыкка иелде. Яңа күршеләр бар да бакчада, ирләр билгә тикле ялангач, дәррәү гимнастика ясыйлар, синең салкыныңа төкереп тә бирмиләр иде. Кечкенә кызларына кадәр ут борчасымыни! Кара әле, нинди бердәм иелеп-бөгеләләр, иртәнге һаваны күкрәкләрен киереп, нинди тәмле итеп сулыйлар... Хөрмәт дөньясын онытып карап тора иде, шунда күзе түр тәрәзәгә төште. Ә тәрәзәдә Асылбикә калкына, авызы колагына җиткән. Шымчы! Берсен дә калдырасы түгел. Табакка ничек итеп килеп төшкәнне күргән булса тагын...

— Нәрсә дип күзләрең ул кадәр майланган иде анда? Әллә шул Гөлбикәне күзләвең идеме? — дип каршылады Асылбикә Хөрмәтне.

— Нәрсә? Чыгып азрак селкенсәң, менә сиңа да зыян итмәс иде. Чүмәләгә әйләнеп барасың бит инде.

— Ә үзең, җаныем? Шушы көндә бүрек киеп, сырмалар бөркәнеп. Үзең син бер бабай хәзер!

Һәм алар иртәдән үк яхшы гына әйткәләшеп алдылар.

Китте шуннан хәлләр!

Бу иртәдә Хөрмәткә чәен дә тәмләп кенә эчү язмаган икән. Асылбикә белән табын янына килеп утырулары булды, күршеләр тарафында нәрсәдер дөпелдәгәне ишетелде. Ул арада нидер яман чытырдады, ахры агач авып төште, ботаклары белән өй түбәсе шиферын тырмап үтте. Күз ачып йомган арада Асылбикә тәрәзә катында иде инде. Тик моны сыннан берни күреп тә, аңышып та булмый иде. Элеккесеннән дә хәтәр чатырдау ишетелде.

— Хөрмәт дим, чыгып карап кер әле. Әллә ни җимерә алар анда,— диде шөбһәләнгән Асылбикә.

— Ниткән эш ул әле анда. Чәйне дә эчеп бетермәс борын,— дип каршы төште тегесе. Ул инде байтак еллар ашказанында бер авырлык сизә, аш вакытын кичектерүдән бик саклана иде.

— Һай җаным, бу тикле хөрәсән булыр икән,— диде Асылбикә еламсырап һәм кисәк ачы тавыш белән кычкырып җибәрде.— Бар дим җәтрәк!

Хатынының кайчак, дөрләп, ут кибәненә әверелә торган гадәте барлыгын белә һәм бу гадәттән яхшы үк шүрли дә иде Хөрмәт. Чыгып хәлне ачыкламыйча ярамый.

Күршеләр капкасын ачып керүгә, ул тукталып калды. Тегеләр кыр чирүеләй бакчага ябырылган, җиңнәрен сызганып куйган өч малай Сәрби әбидән калган, яртылаш корып беткән алмагачларны, чияләрне ега. Гөлбикә белән кызлар коры ботакларны лапас буена өя. Нургаян үзе, кулындагы озын саплы балта белән киң селтәнеп, тамыр чаба, хәтта иң кече кызлары да биредә, кулына таяк алган да еллар буе котырып үскән чытырманны кәлә-кәлә кырып йөри, бакчада мәхшәр иде. «Алай, бу килештән тамырыңа ук балта чапмагайлары әле болар»,— дип уйлады Хөрмәт.

Нургаян аны күреп алды да төп янына тезләнеп утырган җиреннән торып басты. Ул майкадан гына, тырпаеп торган чәчләренә чүп кунган, маңгаенда эре-эре тир бөртекләре ялтырый, үзе нәкъ алга сузып елмая иде.

— Әйдүк, күрше, хуш киләсең.

— Бакчаны яңартумы? — диде Хөрмәт.

— Исәп бар иде,— диде Нургаян.

Шунда Хөрмәтнең күңел түреннән ниндидер бер кайнарлык елтырап үтте. Яңа күршекәйнең комагай күзләре алар ягына кереп калган

өч-дүрт кенә метр киңлектәге буш яткан җиргә текәлгән иде. Һәм ул кактырып-суктырып та маташмады, туп-туры сорап куйды:

— Ә синең ник гидай ята әле монда, күрше?

Соң, буш ятса, нигез якын ләбаса. Кемнең ни эше булырга тиеш? Тик шулай да мондый кистереп сораудан Хөрмәт бераз каушап калды:

— Гидай дип, нигез буе бит... Күләгә җир, кемгә хаҗәт?

— Миңа хаҗәт, күрше, миңа хаҗәт! — дип ялгап китте Нургаян тын алырга да бирмичә. — Җирнең карышын исраф яткызуны да зур гөнаһка санаям мин. Ә монда синең төшкә кадәр мул гына кояш төшә. Җитеп арткан алмагачка. Утыртабыз анда, күрше! Ике... юк, өч төпне утыртабыз да куябыз.

Инде чын-чынлап пошаманга калды Хөрмәт.

— Анысы алай, күрше, утыртуы булыр да. Тик минә ни бит әле... Аның җире минем өлешкә тигән бит әле, күрше... Болай сүз җаеннан гына әйтүем анысы, җәлләп түгел, хи-хи...— дип кеткелдәп куйды ул.

— Ә ул ягына кайгырма син, күрше! — диде Нургаян күңелле итеп.— Җире синең өлештә, һичбер дәгъва юк. Аның алмагачларын мин утыртам. Һәм карап үстерәм дә. Шикәр кеби сортларны гына үстерәм мин. Ә җимешләрен... рәхим ит, күрше. Җимешләрен аның син җыеп аласың.

Гомере буе кешенекенә нәфес сузмады, үзенекен учта нык тотты Хөрмәт. Нәкъ бүтәннәр кебек, һәр нәрсәдә исәпле булуны кагыйдә итеп яшәде. Асылбикә белән ике бөртек бала үстереп, аларны калага озаттылар. Инде олы улын машиналы итте, ачуы килсә, кечесенә дә алып бирергә җегәре җитмәс түгел. Хәзер бит аның дөньясы исәпле. Ә бу күршекәй... ни сөйләнеп тора әле бу? Ничек инде ул алай: берәү көч салып үстергән җимешне икенче берәү җыйнап ала? Исәпсезләнүме бу, әллә кыланып сөйләшү генәме? Хөрмәт ачыклык кертүне кирәк тапты.

— Син, күрше, чынлап сөйлисеңме соң әле?

— Чынлап, күрше! Миңа аның җимеше әллә ни важный түгел, агачларны карап үстерүе кызык. Җирдә бакчалар үстерәм дип кайттым да мин. Бар хикмәте шул аның,— диде Нургаян һәм, учларына төкереп, балтасын кулына алды.

Булмады болай булгач, марканы тотмады бу күрше. Әшкә болай дәртләнеп тотынгач, Хөрмәт аны төпле, абруйга лаек кеше дип чамалаган иде. Җимеше кыйммәт түгел имеш. Бу заманда бәһане белмәгән ни бәндә? Һәм Хөрмәт ашыккан аякларын көчкә тыеп, өенә юнәлде. Бу хәбәрне җәтрәк Асылбикәгә җиткерергә кирәк иде.

Хөрмәт идарәгә менгәнче, тиз генә киңәшмә үткәреп алдылар һәм мондый карарга килделәр: күзгә төтен җибәреп, нииндидер хәйлә кормагае бу күрше. Әгәр хәйләгә керми икән, бәс, утырта бирсен безнең өлешкә дә. Үстереп биргәнне җыйнап алуы авыр булмас.

* * *

Сәрбиҗамал әбинең йорты әллә ни арада гына деңгә керде. Кыегайган капка түбәсе инде шифер «киеп» турайды, түнгән коймалар торып басты. Бакча, җыен коры-сарыдан арынып, ялт итеп калды. Хәтта аны китмәнләп яшь үсентеләр утыртыласы чокырларны да казып куйды яңа күршеләр. Хөрмәтләр өлешендәге җир дә эшкәртелгән, анда да чокырлар әзер иде. Моның бик мөбарәк бер эш икәнен белеп торса да, ниндидер бер ризасызлык, тараю калды Хөрмәт күңелендә.

Ул арада Нургаян, ишегалдына гына сыймады ахры, урамга да килеп чыкты. Алар турысында су колонкасы бар, аның тирәсе язын-көзен тездән баткак була, авыл Советы Хәйдәргә ни әйтеп тә, һаман да шуны юньгә китерә алмыйлар иде. Беркөн идарәдән төшкә кайтканда, Хөрмәт шундый хәлгә тап булды: Нургаян, малайларын ияртеп, кирәкләр алып, колонка янына чыккан, алар аның тирә-ягына таш түшәп, цементлап яталар иде. Шунда су алырга килгән хатыннар бу эшне карап торалар. Хөрмәт тә туктамыйча үтеп китүне яхшысынмады.

— Эшләр барамы, күршеләр?

— Эшләр тәгәри генә, күрше! — диде Нургаян киң күңел белән.— Минә улагын да ясап куябыз әле. Су агып төшсенгә.

Шунда хатыннарның берсе аска карап елмайган көе сүз кыстырып куйды:

— Кулың житеп керешсәң, була инде ул, Хөрмәтулла абый. Тирә-күрше — ничә ир, шуны рәтләп куя белмәдегез. Менә бит...

Моңа каршы дәшеп тору дәрәҗә төшерү булыр иде. Шуңа күрә Хөрмәт илтифат итмичә, сүзне Нургаян белән генә дәвам итте:

— Бик әйбәт була инде ул алай, күрше. Хезмәтегез дә бер дә бушка гына чыкмас әле. Авыл Советына мин үзем кереп әйтермен моны. Сметасын төзетеп...

Нургаян ияген сузып көлеп җибәрде.

— Куйсана, күрше, нинди хезмәт ул. Үзебез үк су аласы колонка лабаса. Инде аңа да хак сорап торсаң, үзең бер смета булырсың!

Шунда хатыннар да көлеп җибәрделәр. Менә монысы инде иң хәтәре иде. Авыл хатыннары теленә бер керсәң...

Эченнән генә тәмам кара коелып, үз капкасына таба атлады Хөрмәт. Ни пычагыма дип тукталды, бу килмешәк белән ник авыз чайкап торды соң әле ул? Үз белдеге белән эшли янәсе, бушка эшләп үрнәк күрсәтә. Шушы заманда, авылны төзекләндерү чутында тотылмый яткан акча барында Сәмән бардыр ахры моның, шахтадан оекка тутырып кайтканы бардыр. Шуңа кылана булса кирәк.

Авыл җирендә шулай бит ул: кешенең сүзе үзеннән алда йөри. Төштән соң Хөрмәт идарәгә килеп кергән генә иде, экономист Вәдүт, коеп куйган төлке, бер дә кирәкмәс урында: «Смета, ах, смета!» — дип көйләп куймасынмы! Ни арада килеп ирешкән диген.

Уңмады Хөрмәт яңа күршеләрдән.

Асылбикә инде ике ел пенсиядә, өйдә көнозын ялгызы интегә иде. Менә хәзер аңа шөгыль табылды. Ул мич арасындагы тәрәзә турысына иске булса да аюны күтәрерлек имән өстәл кертеп урнаштырды. Аннары аңа ястык салды — күзәтү пунктының кәттәсе әзер! Улларыннан калган иске бинокль белән коралланып алды да көн саен кичен хәбәр итә торды: тегеләр лапаска яшеренеп кенә ниндидер шахыр-махыр ясап маташа. Лапаска җыен иске тимер-томыр, калай кисәкләре ташыйлар, аннан көнозын чыңлаган тавышлар ишетелә. Ул да булмады, әлеге лапас ягыннан бик тә әшәке буяу исе аңкыды, бөтен ишегалдын тутырды, ишек ачкан саен, өйгә нярел керде. Баш миләреңне сыеклый торган ис иде бу.

— Нинди завод-фабрикалар ачты алар анда? Ни кыра инде алар? — дип төпченде Хөрмәт хатыныннан. Ә тегесе үзе гаҗиз иде.

— Соң ул кадәресен үк кайдан белим ди инде мин?

— Син бит сакта. Биноклыләр тагып... Күзле бүкән булмасаң! — дип җенләнде Хөрмәт.— Һич югында үзләренә кереп чыгарга иде! Беткәнмени йомыш?!

— Кереп тә караган инде. Капкага килеп җитмисең, Гөлбикәсе үзе каршыңа чыгып баса бит аның,— дип акланды Асылбикә.

— Һе, син алпан-тилпән килгәнче, әлбәттә... Әнә кеше хатыннары пенсиядә дә эшләп йөри. Сиңа да гөнаһ булмас иде. Җиңеләер идең азрак.

— Һай, җаным! Әллә ниләр сөйләнә башладың. Үзең зур эш кырган бер кешедәй.

— Ничек мин... эш кырмаган?! — диде Хөрмәт кыза башлап.

— Кеше эшләгәнне генә чутлап, кәнсәләрдә утыру нинди эш кыру ул, җаныем? Ир башың белән, гомер буена,— дип кызды Асылбикә дә.

Бу — Хөрмәтнең авырткан төше иде. Бүтән ирләр тракторда, комбайнда эшләгән бер заманда үзенең хисапчы булып калуыннан ниндидер үкенү, кимсенү бар иде аның күңел түрендә. Тик инде хәзер ни кырмак кирәк? Инде гомер үтеп бара. Шуңа күрә ул хатынының бу чәнечкеле сүзләренә кулын гына селтәде.

Тынлык китте йорттан.

Бераздан председатель Ханнан Хөрмәтне үз янына дәштереп алды. Председатель әле яшь кенә, тиешле урында тапкыр сүзне, уен-көлкене дә ярата торган кеше иде. Бусагадан бик авыр атлап үтте Хөрмәт.

— Сезнең теге яңа күршене әйтүем әле, Хөрмәтулла абый. Ниндирәк кеше күренә үзе? — диде ул.

— Нәрсә дип кенә әйтим... — диде Хөрмәт сак кына.

— Болай тәртип, салу яклары дигәндәй...

— Әлегә анысы-монысы сизелми. Алай да, Ханнан Васильевич, бик төпле кеше түгел ул,— диде Хөрмәт.

Председатель, күзләре белән генә көлемсерәп, аңа карап алды. Аның бер гөрләтеп, рәхәтләнеп көлеп җибәрәсе килә, тик олы кешегә ихтирам йөзеннән генә үзен тыеп тора иде.

— Миннән эш сорап килде әле ул күршең.
Менә монысын инде Хөрмәт һич көтмәгән, уйламаган иде.
— Шулаймы? Кара син аны, ә... Монда чынлап ук төпләнергә микәнни исәбе? Пенсиядә диюем, шәһәр кошы... Аңа ышанып, бер-бер эш тапшыруың да инде,— диде ул, шактый буталып.
— Ә ник әле ышанмаска! — диде Ханнан нык итеп.— Теләге бар икән, бездә бит эш җитәрлек. Әнә фермага куябыз аны, оператор итеп. Шәһәрдән кайткан һәрбер кешегә бездән аерым игътибар кирәк, Хөрмәтулла абый. Шәхси мәнфәгатьләрне азрак тыя төшеп... Без бит сезнең белән шушы колхозны җитәкләп баручы кешеләр,— дип тәгәлләде сүзен председатель шактый мәгънәле итеп.
Аның кайсы якка төрттерүен бик сизсә дә, председатель яныннан чыкканда Хөрмәтнең күңелендә тантана иде. Димәк ки оператор! Бик әйбәт... Бу заманча сүзнең ни аңлатуын бик белә хисапчы. Шул ук маллар астыннан тирес көрәүче, салам-силос ташып чиләнүче инде ул оператор. Башка берни дә түгел. Аның куйган механизмнары, транспортерлары эшләп кенә торамы әле сиңа... Вәт, бик әйбәт, менә күрсәтеп карасын әле үзен.
Нургаян фермага менеп эшли башлаган гына иде, ул тарафтан да яңа хәбәрләр килде. Фермага менүенең беренче көнендә үк төнлә өенә кайтмаган. Төне буе шунда казынып, тирес чыгара торган транспортерны төзәткән. Иртән эшкә килсәләр, абзардагы чисталыкка, андагы тәртипкә исләре киткән сыер савучы апайларның. Телгә тапкыр апайлар тиз арада аны Нургаян дип түгел, Нурлыгаян дип йөртә башладылар. Җитмәсә, үч иткәндәй, әледән-әле идарәгә килеп сайрый тордылар:
— Вәт ичмасам Нурлыгаян! Безнең фермага да кулы булган бер ир кеше килде ичмасам. Бөтен эчергечләрне, краннарны гөл итте бит.
— Беләсезме, Хөрмәтулла абый, «бу — синеке, бу — минеке» дип торуны да белми ул Нурлыгаян. Теләсә нинди эшне ялт итә дә куя.
— Булган кеше шул, булган кеше! Безнекеләр ише салган баш кына түгел.
Хөрмәт хатыннарның бу сүзләрен җөпләп елмая, ә үзен эчтән генә һаман бер уй кимерә иде: төпләнә ахры авылда теге кыбырсык, тамыр җәя.

* * *

Тәмам да ал-ялны белми торган нindидер тимер кеше, хыялый бәндә булып чыкты бу яңа күрше. Фермада хәзер ике смена, операторлар, бер көн эшләсә, икенче көнне ял итә. Андый ял көннәрендә Нургаян һич тик тормады. Үз бакчасына да, Хөрмәт өлешенә дә яшь алмагачлар утыртты, малайлары белән бергәләп лапасында ниләрдер майтарды. Бер заман өй түбәсендә төрле рәвешкә кереп чабып барган пошилар, боланнар, кабан дуңгызлары, аркаларына балалар утыртып очкан аккошлар чикләвек ярып утырган тиеннәр, тагын әллә нинди җәнлекләр калкып чыкты.
Урам як койма буе да тора-бара чын бер әкияти дөньяга охшап калды. Нургаянның үзе шикелле елтыр күзле, тырпа чәчле малайлары ул җирне яхшылап тигезләделәр, ком китереп җәйделәр. Бүрәнә башларыннан шлемлы баһадирлар, шүрәлеләр, бу дөньяда бөтенләй дә булмаган хыялый җанвар сыннары юнып, шунда урнаштырдылар. Алар арасына ниндидер матдә сеңдереп, бик матур итеп ясалган тиеннәр, куяннар эленде, кошлар өчен җимлекләр куелды. Монда Нургаянныкылар янына бөтен авылның бала-чагасы җыела башлады, чыр-чу китте. Бу могҗизалар кичләрен дә күренеп торсын өчен, Нургаян капка түбәсенә баш чаклы электр лампасы чыгарып элде. Кыланышларына чик-чама калмады бу кешенең.
Көннәрдән бер көнне Асылбикә сүз кузгатты:
— Хөрмәт дим, мин шуны уйлап йөрим әле... Әллә, мин әйтәм, без дә күченеп китәбезме?
Тегесе берни төшенмәде.
— Ничек инде китәбез? Кая китәбез?
— Ник, әнә югары очка.
— Анда ни пычагым калган безгә?
Асылбикә, алъяпкычына капланып, елап ук җибәрде.
— Тора алмыйм мин монда. Теләсәң ни эшләт.
— Туктале, ни сөйлисең син?
— Җык чиккәннәремне сөйлим! Үткән-сүткәне күзен бәрәңгеләндерә дә шушында туктый. Ишегалдына чыксам, керләр элсәм... Колагымда көнозын балалар чыр-чуы. Ичмасам, инде кичкә кергәч тә тынычлык юк бит миңа. Әнә үзең тыңлап бак әле бер,— диде тегесе үкси биреп.

Соңгы елларда колакка яхшы ук катыланган Хөрмәт юри тыңлап торды. Чыннан да, урам ягыннан балалар килгәне, төрле авазлар ишетелә иде. Тик алай да... моңа карап кына, инде гомер иткән ата-баба нигезен ташларга дигәнмени? Мөмкин эш түгел бу.

— Югары очта ничәмә йорт буш тора. Паравой кертелгәннәре,— дип һаман үзенекен сукалады Асылбикә.

— Җанкисәгем! Ул йортларны колхоз синең белән минем өчен дип салмаган. Авылыбызга яшь белгечләр килсен, яңа семьялар күбрәк оешсын дип салган. Синең белән мин нәрсә хәзер? Сөте беткән карт кәҗәләр бит инде без.

— Сорасаң, сиңа да бирми калмаслар иде әле. Гомерең буе шунда чалбар төбе туздырып.

— Вәт нәрсә. Әгәр дә тавыш сөймисең икән, колагыңны мүкләп куй. Әнә сиңа мамык! — дип җене кузгалды Хөрмәтнең.

* * *

Карлар ятып, кышлар җиткәч, капка төбендәге балалар тавышы тына төште. Нургаян үзе дә, башкаларга ияреп, Кустанай якларына салам әзерләргә китте. Хөрмәт белән Асылбикә иркен сулап куйдылар.

Кышкы бер таңда Хөрмәт төшләнеп ята иде. Имеш, ул үзе армиядә хезмәт иткән Урта Азия якларында икән. Ниндидер елга яры буйлап атлый иде, кисәк кенә аның каршысына фил чаклы искитмәле бер ишәк килеп чыкты. Ул ишәк аны йотарга теләгәндәй, авызын кеше сыярдай итеп ачты да иләмсез тавышлар белән бакыра башлады. Бу хәлдән коты алынган Хөрмәт уянып китте һәм шунда... төшендәгедән дә битәр курыкты. Елга дигәнең дә, Үзбәкстанның зәңгәр күге, фил чаклы ишәк тә юк, Хөрмәт үз өендә юрган астында ята, ә менә ишәкнең акырганы һаман да ишетелә иде. Тәрәзә пыялалары зыңгылдап тора бу тавыштан. Армиядә дә гарык иткән бу иләмсез авазларны гомерендә онытасы юк Хөрмәтнең. Ул арада Асылбикә дә уянды, соң дәрәҗәдә куркып пышылдады:

— Хөрмәт дим, тагын нинди афәтләр килде безгә? Монысы нинди ерткыч инде тагын?

— Һе, ерткыч имеш... Ерткычларың бер якта торсын хәзер, җанкисәгем. Ишәк була бу, бик беләсең килсә. Озын колаклы, бакыр бугазлы ишәк! Аның акырулары бөерләреңә төшеп җитәр әле.

— Китче, нинди ишәк булсын ди монда!

— Нургаянияртеп кайткандыр инде. Кустанай якларында иде бит. Иш ишен таба, билләһи! — дип, идәнгә төкерде Хөрмәт һәм ашыгып киенә башлады. Юк, булмый бу болай хәзер. Чынлап сөйләшер вакыт килеп җитте бу бәндә белән.

Ул чыкканда, Нургаян да инде аяк өстендә, капка төбендә кар көри иде.

— Бу нинди эш була инде бу, күрше, җә! — диде Хөрмәт исәнлек-саулык та сорашып тормастан.

— Ни бар, күрше?

— Бүтән кыланышларыгыз җитмәгән идеме? Инде ишәк тә булсын дидегезме?

Нургаян эшеннән тукталды, каршысында еламсырап торган бу тәбәнәк кенә, түгәрәк кенә кешегә текәлде. Кисәк аның күңелендә ургылып ачуы күтәрелде, күзләрендә гөрләп нәфрәт кабынды. Хөрмәт хәтта артка чигенеп куйды. Тик ул арада Нургаян үзен тыеп өлгерде.

— Әйе, күрше, ишәк тә булсын дидем,— диде ул.

— Ни кырырсың инде син шул ишәк белән?

— Хуҗалыкта ярдәме тими калмастыр.

— Һе, ярдәме... Соң, тормый бит ул бездә. Ката ул безнең як суыкларында. Кәкрәеп ката, боерган булса.

— Ә бәлки катмас? Шул тәҗрибәдән алып кайттым да инде мин аны, күрше. Бүтән урыннарда яшәгән ишәк ник безнең якларда да булмаска тиеш әле? Менә бит нәрсәсе кызык,— диде Нургаян ихластан.

— Соң, тәҗрибә дип... Син шул хайванны ашатып ятарсыңмы?

— Карт ишәк бу, күрше. Инде үсүдән туктаган. Тамагы да шул гына аның.

Тәмам да гаҗиз булган Хөрмәт бу сүзгә чат ябышты:

— Әһә, карт ишәк дидеңме? Алайса син, күршекәем, авылга авыру алып кайткансың. Хайван авыруы.

Нургаян сүзсез генә капка баганасына үрелде, түбәдәге утны кабызды. Куен кесәсеннән бер кәгазь алып, аны күршесенә сузды.

«Белешмә

Авыл Советы Нургаян Газизовның Филлип Филлипович Вальхер хуҗалыгыннан сигез яшьлек ишәк сатып алуын раслый. Ишәк ветеринария каравын үткән, сау-сәламәт, аны бер өлкәдән икенчесенә күчерү рөхсәт ителә.»

Җен ачулары чыкты Хөрмәтнең моны укыгач. Нинди ләззәт белән бу кәгазьне умырып, вак кисәкләргә теткәләп ташлар иде ул. Хәтта аның күңелендә бер кыргый омтылыш кузгалып та куйды. Тик янында күршесе басып тора, ә аның кулында кәрәк... кем белә ул бәндәне? Хөрмәт тәртәне икенче якка борып карады:

— Соң, күрше, үзең уйлап кара әле. Үләчәкбез бит без ул ишәк тавышыннан. Әнә күршең Асылбикә ярты мәет инде.

— Менә монысы өчен, күрше, гафу үтенәм. Зинһар кичерә күрегез! — диде Нургаян бик борчылып.— Тик сүз бирәм тагын өч көннән ишәкнең тавышын чыкмас. Яңа урынны яратмый әле ул. Карт ишәк нәкъ өч көндә ияләнә. Монысына мин тулы гарантия бирәм.

— Тфү дә кеше икәнсең син үзең, күрше! — диде тәмам чыгырыннан чыккан Хөрмәт.

— Шулайрак шул, күрше. Ни хәл итәсең,— диде Нургаян һаман да тыныч калып.

Тиз арада чыннан да тынды ишәкнең тавышы. Тавышы аның тынды тынуын да...

Чалт иткән аяз, салкын бер көндә Нургаяннар капкасы ачылып китте һәм аннан чанага жигүле ишәк килеп чыкты. Шомырт карага буялган чанада келәм, аксыл төстәге зур ишәкнең йөгәне, шлеясы җиз таңкалар белән бизәлгән, тәртәдән кызыл тасмалар асылынып төшкән, сырлы дугада көмеш кыңгырау чылтыры иде. Чана башында няген алга сузган Нургаян үзе утыра, аның артында балалары. Бу әкәмәт экипаж югары очка юнәлде. Ярты сәгать тә үтмәде, авылның барча бала-чагасын ияртеп, кире әйләнеп тә кайтты. Менә балалар уртасына Нургаян чыгып басты. Ул бүреген егетләрчә кырын салган, кыска тунының төймәләрен чишеп җибәргән иде.

— Яле, кемнең ишәккә утырып йөрисе килә? Рәхим итәсез! — диде ул, кулларын киң җәеп.

Күз ачып йомганчы балаларның озын чираты тезелде. Нургаян чана башына менеп утырды, нәкъ паровоз кебек итеп гудок салды, һәм бала-чага тулы чана кузгалып та китте. Балаларның куанычына чик-чама юк, алар шау-гөр киләләр, әүмәкләнеп чанадан карга тәгәриләр, тагын сикереп меңәләр иде.

Менә язлар җитте, көннәр җылынды. Кояшлы бер көндә Асылбикә тәрәзәләрне көздән сыланган кәгазьләрдән арындырып, киң итеп ачып куйды. Алар көндезге аш янына утырганнар гына иде, тәрәзәдән безелдәп бер бал корты очып керде. Очып та керде, Хөрмәтнең нәкъ борын очына килеп тә кунды. Асылбикә утырган җиреннән генә тастымалга үрелде.

— Кузгаласы булма! — дип боерды Хөрмәт хәтәр пышылдап.— Селкенә дә күрмә, ишетсен колагың!

Ул гәүдәсен уклау йоткандай төз тотып, берара урынында катеп утырды. Очып китми бит каһәр корт! Алай булмагач, мең төрле саклык белән урыныннан торды, нәкъ акрынайтылган кинодагы кебек кенә атлап, тәрәзә янына килде. Әгәр дә бал корты сиңа кунып, афәткә таргансың икән, җансыз кал, үрә кат, әмма селтәнә күрмә инде син, җаныкаем. Кулыңны күтәреп өлгермисең, китерә дә чага ул сине.

— Умарта алып кайтканнар. Биш оя! — дип хәбәр салды Асылбикә үзенең күзәтү пунктыннан.

Шул кичтә үк озак утырып, озын итеп гариза язды Хөрмәт. Авылның теге очындагы буш торган йортларның берсен үзенә бирүләрен үтенеп. Бер генә сүз кыстырып та үзенең яңа күршеләреннән зарланмады ул. Инде карчыгы белән икәүләп картаеп килүләрен, торган йортларының тузып баруын, ягулык әзерләү мәшәкатьләрен, пар белән җылытыла торган йортка күчәселәре бик килүен бәйнә-бәйнә аңлатып язды.

Идарәдә аның бу гаризасын Ханнан үзе дикъкать белән укып чыкты. Председатель һаман да җитди, тик бер гөрләтеп көлеп җибәрәсе килүе әллә кайдан күренеп тора иде.

— Яңа күршеләрдән дә уңмадык инде, Ханнан Василович. Әллә ниткән, адәм төшенмәслек бәндәләр булып чыкты алар,— дип, телдән өстәмә кертүне кирәк тапты Хөрмәт.

Ханнан аны-моны дәшмәде, гариза өстенә: «Канәгатьләндерергә!» — дип сырлады да имзасын салды.

••••••••••••••••

# Хәкимҗан Халиков

## Минем бабай

...Сабантуйда
Җиңелүне
Белмәгән ул.
Дәү булгач та
Ниләр генә
Күрмәгән ул.
Ә шулай да
Аһ-ваһ килеп
Йөрмәгән ул.
Кулак аткан
Пулядан да —
Үлмәгән ул...

Әйе, үлем
Аны дүрт ел
Сагалаган,
Бабай исә
Фашистларны
«Дагалаган».

Ерткычларны
Өннәренә
Чаклы куган,
Рейхстагка:
«Җиңдек!» — диеп
Язып куйган.
Әнә шулай
Җиңү яулап
Һәр адымда,
Катнашкан ул
Бөек Җиңү
Парадында...

Сиксәнне дә
Узып бара
Инде бабай.
Менә нинди
Безнең бабай!
Ул, чыннан да,
Җиңү бабай!

## Үзе өйрәтә икән

Курчагын күтәреп
Килгән дә яныма,
«Күлмәк тек, абый»,— дип,
Сеңелем ялына.

Нишләргә? Текмәсәм,
Үпкәләр Гөлчәчәк.
«Энә-җеп тотканым
Юк»,— дисәм, көләчәк.

Ни генә дисәң дә,
Мин аның абыйсы.
Әллә, дим, шулай да
Тотынып карыйсы?

Бер тектем, бер сүттем,
Шулкадәр интектем.
Әнием бик ансат
Тегә соң ничек дим.

Башлаган эшемне
Алай да ташламыйм.
Ташларлык булсаммы —
Мин аны башламыйм!

....Ниһаять, тап-таман
Курчакның күлмәге:
Эш үзе өйрәтә
Икән бит, күр әле!

---

ХӘКИМҖАН ХАЛИКОВ (1933) — татар һәм рус телендә дистәдән артык («Йолдызлар ничәү», «Октябрятлар шәһәре», «Иң шатлыклы көнем» һ. б.) китап авторы. Казанда яши.

## Яшел шар

Очып килеп кунганмы,
Берсе элеп куйганмы,
Бер шар тора тирәктә,
Матур инде бигрәк тә,
Яшел болын төсендә.
Мена шуның өчен дә
Җир шарына охшаттым.
— Чынлап бит, әй, Иршат,— дим.

«Мин күрдем,— дип,— иң элек»,—
Ирек килде йөгереп,
Ә артыннан — Әхмәтхан...
Тарта торгач як-яктан,
Берзаман «шарт!» — шарыбыз.
Тып-тын калдык барыбыз.

Нәрсә генә дисәк тә,
Вак-вак кына кисәкләр
Калды аннан нибары...
Әгәр шулай Җир шарын
Шартлатсалар, ни калыр?
Җир шарында кем калыр?

## Кемгә бал, кемгә ял

Бакчачы карт чирәмдә
Ял итеп утырганда,
— Нишлисең? — дигән ялкау,
Аңа карап торган да.

Бабай әйткән: — Арысаң,
Кил, ял итеп ал,— дигән.
Ялкау исә: — Балмы ул,
Нәрсә соң ул ял? — дигән.



**Б. Ф. Захаров,**
КПССның Бөгелмә шәһәр
комитеты беренче секретаре.

# ҖАВАПЛЫЛЫК АРТА

Бөек Пушкинның остазы һәм дусты Василий Андреевич Жуковский безнең яклар турында: «...Бу сәфәр җанны иркәли. Шаулы иген кырлары. Хәтфә ябылган таулар. Иманнәр, каеннар. Борма-борма юллар. Бөгелмә — үр өстендә, соклангыч манзара»,— дип язып калдырган. Бөгелмә хакындагы истәлекле язмаларны Аксаков һәм Шишков әсәрләрендә дә, Россия Академиясенең беренче член-корреспонденты Петр Рычков хезмәтләрендә дә очратырга мөмкин. Чехословакиянең күренекле сатиригы Ярослав Гашек Россиядә булып кайтканнан соң язган егерме дүрт хикәясенең вакыйгалары һәммәсе Бөгелмәдә бара.

Шәһәрнең элек-электән еракларга билгеле булуы тикмәдән түгел. Картага гына күз салыйк: Бөгелмә Казан — Куйбышев — Уфа — Оренбург дүртпочмагының үзәгенә урнашкан. Димәк, иң әһәмиятле сәфәрләр Бөгелмә аша үткән. Шәһәрнең үсешендә Россияне Көнчыгыш белән тоташтырып торучы Оренбург тракты аеруча зур роль уйный. 1781 елда ук Бөгелмә өяз шәһәре дип таныла.

Бөек Октябрь революциясенә кадәр Бөгелмә сәүдәгәрләр һәм вак һөнәрчеләр шәһәре буларак билгеле. Ул — әйләнешендә миллион сумнар исәпләнгән ярминкәле зур административ үзәк. Шул ук вакытта өяз элек-электән үзенең тынгысызлыгы белән дә дан тота. Пугачев хәрәкәте елларында, патша чиновниклары шәһәрне баш күтәрүчеләргә каршы торырлык бер таяныч итеп файдаланырга теләсәләр дә, бик күпләр, Бөгелмәдән китеп, Пугачев гаскәрләренә кушылалар. Алар арасында Муса Мостафин, Осип Енгалычев, Аит Уразматов, Степан Синебрюхов, Усман Тимеров кебек каһарманнар да була.

1904—1906 елларда крестьян күтәрелешләре Бөгелмә өязен кабат дер селкетә. Бәйрәкә авылы халкының чыгышы Самара губернасыннан җибәрелгән коралны гаскәр тарафыннан туктатыла. Канлы бәрелештән соң авылның кырык кешесе, шул исәптән чыгышның җитәкчесе Вәли Яппаров та, Себергә сөрелә. 1905 елның гыйнварында жандармнар Карабаш авылындагы баш күтәрүчеләрне дә шундый ук шәфкатьсезлек белән бастыралар.

Совет власте Бөгелмәдә 1918 елның 22 февралендә урнаштырыла. Большевикларга һәм Совет оешмалары вәкилләренә коточкыч авыр шартларда эшләргә туры килә. Кызыл гвардиянең беренче командиры П. Ненастьин, ревком членнары С. Просвиркин, Е. Петровская үзләрен тугрылыклы ленинчылар итеп таныталар.

Гражданнар сугышы чорында Бөгелмә берничә мәртәбә кулдан-кулга күчеп тора. Революцион комитетның беренче членнары, барысы да диярлек, һәлак булалар. Шәһәрне легендар командарм М. Тухачевский җитәкләгән 5 нче армия гаскәрләре революция дошманнарыннан тулысынча азат итә. Армия политбүлегендә интернационалист язучы Ярослав Гашек та була. Ул берничә ай буе Бөгелмәдә хәрби комендант урынбасары вазифасын үти.

Коллективлаштыру хәрәкәтен Бөгелмә крестьяннары хуплап каршылыйлар. Авырлыкларны бергә-бергә җиңү, зур эшләрне өмәләр белән башкару — аларның электән килгән гадәтләре, шуңа күрә күмәк хуҗалыкка берләшергә алар рәхәтләнеп риза булалар. Күмәк хуҗалыкларны машиналар белән тәэмин итү авыллар белән шәһәр арасындагы мөнәсәбәтләрне якынайта. Бу күренешкә икенче бер рухи яңарыш — стахановчылык хәрәкәте кушыла. Хезмәттәге мондый революцион борылышлар кешеләрнең фикерендә, аларның хезмәткә карашында да күренә башлый.

1935 елны Бөгелмәдә җыелган ударниклар киңәшмәсендә П. Миргородская болай дип сөйли: «Безнең эштәге норма — көнгә 300 көлтә бәйләү. Мин иген шәп үскән урыннарда көненә 1200 көлтә бәйлим. Иптәшләрем башта миңа сәерсенеп карадылар.

Кайберәүләре килде. Ачуланучылар да булды. Аннары үзләре дә минем кебек эшләргә тырыша башладылар.

Минем хәзер 500 хезмәт көнем бар. Хакын алгач, өлешемә тигән ашлыкның артыгын дәүләткә сатам да тун алам. Кышын кар тотарга йөргәндә җылысына рәхәтләнермен...»

Бөгелмә тимер юлчыларыннан беренче булып Николай Спиридонов стахановчылык хәрәкәтен башлап җибәрә. Кышкы юлда 1460 тонналы состав белән Пронино станциясеннән Бөгелмәгә китә ул. Юл үргә табан. Чорына күрә, йөге дә бик авыр булганлыктан, аның расписаниегә сыюына берәү дә ышанмый. Әмма состав шәһәргә нәкъ вакытында килеп җитә. Беренче уңышы белән рухланган Спиридонов, яңадан Пронинога барганда, йөкнең 1800 тонналысын тага һәм станциягә 17 минут алданрак килә. Ленин ордены һәм Почет Билгесе орденнары белән бүләкләнгән машинист СССР Верховный Советына депутат итеп сайлана.

Һәр тармакта яңача эшләүгә күчкән район үз җиренең уңдырышлылыгын арттырырга тырыша башлый. 1940 елны «Тигез басу» колхозының уңышлары Бөтенсоюз авыл хуҗалыгы күргәзмәсенә куелып, агроном Г. Бешенов Мәскәү күргәзмәсенең көмеш медале белән бүләкләнә...

Бүген Бөгелмә шәһәренең уртасында, каһарманнар истәлегенә багышлап салынган һәйкәл каршында көне-төне мәңгелек ут дөрли. Бөек Ватан сугышына районның 15 мең кешесе киткән. Шуларның өчтән бере яу кырында ятып калган. Сигез егетебезгә Советлар Союзы Герое исеме бирелгән. Ун офицерыбыз — Александр Суворов ордены кавалеры.

Укучылар хәтерлиләрдер: күптән түгел кино экраннарында «Алар актерлар иде» исемле нәфис фильм барды. Әсәрдәге үзәк персонажларның берсе кырыгынчы еллар башында Симферополь драма театрында баш рәссам булып эшләгән Бөгелмә егете Николай Барышев язмышын күздә тотып иҗат ителгән. Николай сугышка кадәр Казан сәнгать техникумын тәмамлый. Симферопольдә исә «Лачын» исемле яшерен оешманы җитәкли, фашистларга каршы көрәш алып бара. Шәһәрне дошманнан азат итәргә нибары өч көн кала, «Лачын» группасының сере ачыла, Николай Барышевны һәм аның иптәшләрен җәзалап үтерәләр.

Бөгелмәлеләр тылда да бөтен осталыкларын, көчләрен җиңү көнен якынайтуга юнәлдерәләр. Танк колоннасы төзергә, «Бөгелмә колхозчысы» исемле самолет ясарга акча җыеп тапшыралар. «Бөгелмә колхозчысы» сугышның ахырынача дошманнарны дөмбәсли, Берлинны утка тотуда катнаша.

Үз төбәгең турында язу кызык та, катлаулы да. Чөнки районда ирешелгән барлык уңышларга тукталасы килә. Әмма бу мөмкин түгел. Арада аерым бер баскыч булып торган бер вакыйга бар: 1981 елны, 200 еллыгы уңаеннан, Бөгелмә шәһәре Почет Билгесе ордены белән бүләкләнде. Хөкүмәтебез һәм партиябез район хезмәт ияләренең соңгы елларда ирешкән уңышларын шулай зурлады.

Бөгелмә — Татарстандагы иң биек урынга салынган шәһәр. Аны катнаш урманнар, иген кырлары, калкулыклар уратып алган. Шулар арасында борынгы авыллар, шәһәрчә салынган яңа поселоклар сибелгән. Илленче елларда Бөгелмәдә Татарстан нефтен үзләштерү юнәлешендәге зур эшләр башланды. Бу яңалык шәһәргә дә, бөтен районга да көтелмәгән үзгәрешләр китерде. Шәһәр индустриясенә яңа тармак кушылды: «Бөгелмәнефтемаш» берләшмәсе нефть табу һәм аны эшкәртү аппаратурасы җитештерә башлады. Аның Дәүләт сыйфат билгесе белән чыгарыла торган продукциясе илнең күп якларына гына түгел, утыздан артык чит илгә дә озатыла.

Башка предприятиеләребез дә, әйтик, өй җиһазлары фабрикасы, ипи пешерү, кирпеч сугу заводлары, ит комбинаты үз әйберләренең 60 процентлабын Сыйфат билгесе белән чыгаралар.

Шәһәрнең көнчыгышында «Татнефтегеофизика» предприятиеләре тезелеп киткән. Узган бишьеллыкта Бөгелмә егетләре нефтьнең 68 яңа чыганагын ачтылар. Шуның өчен аларның икәвенә — техник фәннәр кандидаты Лев Воронковка һәм кыр геофизикасы партиясенең операторы Владимир Кочкинга СССР Дәүләт премиясе бирелде.

Татарстан кешеләре өчен иң яңа һөнәрдән саналган чынаяк заводы да — безнең шәһәрдә. Анда ясалган савыт-саба республика ихтыяҗларын канәгатьләндерүгә сизелерлек өлеш кертте.

Бөгелмәнең икенче ягында автотранспорт оешмалары, «Нефтеавтоматика», «Сантехдеталь», электротехник җиһазларны ремонтлау заводлары гөрли. Бу коллективлар узган бишьеллык планнарын иң беренчеләрдән үтәделәр. Бөгелмә промышленносте 1985 елда гына да планнан тыш 11 миллион сумлык продукция чыгарды. Хәзер, КПССның XXVII съезды карарларын тормышка ашыру йөзеннән, хезмәт коллективлары эшне интенсивлаштыруга тагын да зуррак әһәмият бирәләр. Бу юнәлештә завод-фабрикаларга, аерым цехларны үзгәртеп кору буенча, шәһәрнең төзүчеләре зур ярдәм күрсәтә. 5 нче төзү-монтаж тресты коллективын аерып мактарга мөмкин. Трестның иң уңган бизәкчесе Елена Леонтьева Ленин комсомолының бүләгенә лаек булды.

Хәзер без шәһәрнең һәм, гомумән, районның шушындый булдыклы кешеләре ял

сәгатьләрен, эштән буш вакытларын да күңелле һәм файдалы итеп уздырсын өчен мөмкин кадәр уңайлы шартлар булдырырга тырышабыз. Бөгелмәдән читтәрәк, урман аланында сәламәтлек саклау һәм спорт комплексы булдырдык. Кышын шунда ук чаңгыда шуарга мөмкин. Теләгән кеше чаңгыны вакытлыча моннан гына ала. Буфет эшли. Юыну бүлмәләре дә бар. Әле тагын трамплин, волейбол, баскетбол, теннис мәйданнары ясарга кирәк. Тимераякта чабарга яратучылар, бәләкәй тәгәрмәчле тимераякта җәен дә күнекмәләр узсын өчен, махсус юллар сузарга исәп.

Безнең Олимпия уеннары, дөнья һәм Европа чемпионы булган штангачыбыз Николай Колесниковның күрсәткечләре күпләргә таныш. Бөтенроссия «Труд» спорт җәмгыяте чемпионнары Р. Миңлегулов (дзюдо), Д. Ткачев (авыр атлетика), «Локомотив» спорт җәмгыяте чемпионы И. Фәттахов (дзюдо) кебекләр Николайның юлын дәвам итәләр.

Хәзер авыллардагы яңарыш күзгә аеруча нык бәрелә. Калинин исемендәге колхозда яңа мәктәп салынды, «Прогресс» совхозында 300 урынлы балалар бакчасы өлгереп килә. Бөгелмәдәге балалар бакчасының янәсында бассейн да бар.

Мөмкинлекләр ял итүнең яңадан-яңа төрләреннән файдаланырга өйрәтә. Газинур Гафиятуллин исемен йөртүче урамга багышлап, аерым бәйрәм үткәрү дисеңме, тимер юлчылар династиясе көне дисеңме, «Кечкенә авыллар көне» дисеңме — ни генә юк! «ТатНИПИнефть» институтында «Җизнәкәй» исемле фольклор ансамбле оештырылган иде. Хәзер ул бик популярлашып бара. Шәһәрдә чәчәк үстерүчеләр, сәяхәтчеләр, күп белергә теләүчеләр, шахматчылар клубы эшли. Аучылар һәм балыкчылар ирекле җәмгыятькә берләштерелде.

Район хезмәтчәннәре Бөгелмә рус драма театрының һәр спектаклен көтеп ала. Тамашачыларга ТАССРның атказанган артистлары И. Демидов, Р. Сәлимов һәм В. Чумаков, Н. Чижик, В. Бухало кебек актерларның уены аеруча ошый.

«Ленин байрагы» газетасының редакциясе каршында әдәбият сөючеләр берләшмәсе эшли. Аның утырышларына татар һәм рус телләрендә язучы яшь шагыйрьләр, прозаиклар катнаша, осталыкларын чарлыйлар, иҗат серләрен аңларга омтылалар.

Бөгелмә районының мәктәпләрендә биш йөзгә якын укытучы эшли. Моннан да күбрәк педагог һәм инженерлар җиде училищеда яшүсмерләрне төрледән-төрле һөнәргә өйрәтә. Уку-укыту системасына мәктәп реформасы таләп иткән яңалыкларны мөмкин кадәр тизрәк кертү өчен янып-көеп йөрүче Галия Вәлиәхмәтова, Светлана Гайдай, Галина Максимова, Анатолий Ефремов, Людмила Смирнова, Владимир Сотников, Галина Денисова, Нина Горшунова кебек оста педагогларыбыз бар. Аларның эшкә бирелгәнлекләре үзе үк яшь буынны дөрес тәрбияләүдә беренче үрнәк булып тора.

Хезмәте никадәр генә күпкырлы булса да, районыбызның төп мактанычы — әлбәттә, нефть промышленностена бәйле эшләр. Татарстан нефть фәнни-тикшеренү һәм проект институтында җитмештән артык фән докторы һәм кандидаты бар. Аларның хезмәте илнең нефтькә бай барлык өлкәләрендә һәм Алжир, Сүрия, Ирак кебек чит илләрдә дә киң кулланыш таба. Институтта хәл ителгән егермеләп ачыш АКШ, Англия, Канада, Франция, Япония, ГФР, Мексика һәм башка илләр тарафыннан патентланган. Институт хезмәткәрләренең ике йөзләбендә СССР Халык хуҗалыгы казанышлары күргәзмәсенең медальләре бар. Нефтьне җир асты юллары буйлап ташу идарәсе исә Почет Билгесе ордены белән бүләкләнде.

Республикабызда беренче буларак орден алган Бөгелмә шәһәренең промышленносте күп тармаклы, ә районның авыл хуҗалыгы исә специальләшә бара. «Семеновод» — иң яхшы орлыклар җитештерүче совхоз «Пугачевский» совхозы республикакүләм танылган комплекста дуңгыз үрчетә. «Восточный» совхозында затлы тиреле җәнлекләр үсә. Карабаш совхозы яшелчәчелек белән шөгыльләнә. Шулай да һәр хуҗалык игенен дә игә, терлеген дә асрый. Арышның һәр гектарыннан уртача 28,3 центнер уңыш җыеп, Татарстанда рекорд куйганыбыз да бар. Бу бишьеллыкта бөртеклеләрнең һәр гектарыннан 26-27 центнер уңыш алырга чамалап торабыз. Кайбер хуҗалыкларыбыз иген үстерүнең бик матур үрнәкләрен күрсәттеләр. «Восточный» совхозы, мәсәлән, гектардан 47,6 центнер ашлык җыйды, «Птицевод» — 31,2 центнер; «Семеновод» — 28,6 центнер. Маяклар бар, максатыбыз тормышчан.

Терлекчеләребез дә республика күләмендә мактап телгә алырлык. Р. Лотфуллина, К. Хөснетдинова, М. Горланова, Л. Малышева, А. Захарова, Н. Корноухова, А. Слесарева кебек савымчылар һәр сыердан елга 6200-6400 шәр литр сөт ала.

Киләчәк көннәребезгә дә маяк булырдай эшләр башында коммунистлар атлый. Бер генә мисал. Соңгы вакытта безнең нефтьчеләр Көнбатыш Себердә дә зур эшләр алып бара башладылар. Урьевта геофизика конторасы бүлек начальнигы коммунист В. Виноградовның бик үтемле конкрет тәкъдимнәре булды. Себер шартларында эшләүче коллективларга аның зур ярдәме тиячәк.

Кыскасы, Бөгелмә хезмәтчәннәре КПСС-ның XXVII съезды карарларын тормышка ашыруда көчләрен кызганмыйлар.

## Тәүфикъ Әйди

# ҺӨНӘРЛЕ ӘЛӘЗӘН

Татарстанның Күгәрчен, Чиләбе өлкәсенең Караболак авылларында булганым бар. Зурлар. Шуңа күрә Күгәрченне якын-тирәдә хәтта «Шанхай» дип тә шаярталар. Караболакның төп урамы исә ике-өч чакрымга сузыла. Әмма барыбер Әләзәннән калыша алар. Моңа мәктәпләре дә шаһит: әле кайчан гына 800 бала укыган Караболакта бүген нибары 130лап кеше белем ала. Чөнки игенчелектә, терлекчелектә техника файдалану бу тармакларда эшләүчеләр санын бик нык киметте. Күпләр, эш эзләп, шәһәрләргә китәргә мәҗбүр булды. Бигрәк тә яшьләр. Шуның аркасында Күгәрчен дә күз алдында туза, картая башлады. Ләкин Әләзән...

Әләзән? Кайсы Әләзән?

Әләзәннәр Пенза өлкәсе Городище районында чыннан да өчәү. Бүген Түбән Әләзәндә 480, Югары Әләзәндә 700 укучы бар. Урта Әләзәннең ике урта мәктәбендә исә ике мең чамасы бала укый. Монда өченче мәктәпне корырга да әзерләнәләр, чөнки соңгы вакытта Урта Әләзәндә ел саен 280 бәби табалар. Яшьләр авылда төпләнә баргач, бу санның тагын да үсүе мөмкин ич.

Тимер юл яки олы бер елга буена да урнашмаган, район үзәге дә түгел Урта Әләзән. Казылма байлыклары да, уңдырышлы кара туфрагы да юк. Мондый авыллар соңгы елларда тәмам бушап калды. Әмма Урта Әләзән һаман үсә, күтәрелә генә бара. Һәм киңәя. Соңгы вакытта гына да совхоз бүлеп биргән 180 гектар җирдә өр-яңа йортлар калкып чыкты, халык саны тугыз меңгә якынлашып килә. Мин белгән татар авылларының иң зурысы булган Урта Әләзән ничек шулай яши икән соң? Авылмы соң ул, шәһәрме?

* * *

Бу сорауны мин Рәүф Әбүзәревкә дә бирдем. Урта Әләзәндә туып-үскән егет. «Әләзән» совхозы директоры Хәмзә Исләев аның турында:

— Эштә беренче, әмма сүзгә юмарт түгел,— дигән иде.— Шулай да күрерсез әле сез аны. Үзе дә, гаиләсе дә күпләргә үрнәк.

Дөрес әйткән икән директор: әллә ни гәп куертып булмый гына бит. Соравыңа бер-ике сүз белән җавап бирә дә, көрәк кулларын кая куярга белми тынып кала. Мин аның кытыршы учларына, юан бармакларына, эре сөякле гәүдәсенә караштыргалап:

— Сез тракторда эшлисез икән? — дим.

— Егерме алтынчы ел.

— Сукалыйсызмы, чәчәсезме?

— Аз-маз.

— Ә хатыныгыз?

— Суганда.

Сорау арты сорау биреп, Рәүфнең биш бала үстерүен, олы улы Мозаффарның бишенче ел инде, атасы кебек, тракторда эшләвен, кызы Галиянең тегү тегүен, Вилданның шоферлыкка укуын, Гали белән Асиянең мәктәпкә йөрүен белдем. Унга уникe метр иттереп, ташпулат салуларын, сыер, сарык, кош-корт асрауларын, җиләк-җимеш, яшелчә үстерүләрен ачыкладым.

— Бала үстерү мәшәкатьле түгелме соң? Сүзне тыңлыйлармы?

— Билгеле.

— Ничек итеп?
— Терлек, бакча багалар. Үзебезнең андыйларга кул тими.
Чәчү, урак өстендә Рәүфнең эше иртәнге биштән кичке сигезгәчә дәвам итә икән. Егерме алты ел шулай!
— Туйдырмыймы соң бу? — Рәүф миңа берни төшенмәгәндәй шаккатып карап торгач, өстим: — Арытмыймы?
— Вакыт юк бит.
Нәрсәгә вакыты юк: арыргамы, минем белән сөйләшергәме? Рәүф аңлатып торуны, гомумән, кирәк тапмый. Бары тик:
— Хәзер егерме дүрт көнлек ялыбыз да бар,— дип кенә куя.
Тормышларының житешлеге әллә кайдан күренеп тора. Хатыны Рәшидә:
— Рәүфнең мактау кәгазьләрен карыйсызмы? — дип сорый.— Ел саен бүләкләр, бик күп. Менә бу радио, телевизор кебек әйберләрне бүләк акчаларына алдык. Келәмне Бөтенсоюз күргәзмәсеннән бирделәр, көмеш медальне дә шуннан.
— Хезмәт хакы әчемлеккә генә кала икән,— дим шаяртып.
— Безнең өйгә аракы белән тәмәкенең кергәне юк. Шуңа күрә балалар һәрвакыт этиләренә сарыла, тракторы тирәсендә бөтереләләр.
Хезмәт Кызыл Байрагы орденын күргәч, мин Рәүфтән:
— Монысы нәрсә өчен? — дип сорадым.
— Ул елны мең гектар чәчү чәчкән идем.
Менә сиңа «Аз-маз»!

• • •

Әләзәндә, «Сезне уйлап, яшь түгәбез суган тураган саен»,— дигән жырны ишетмәссез. Юк, халкы жыр сөймәгәнлектән яисә каты бәгырьле булудан түгел бу. Күпләр кыш буе суган турый, дөресе, кыш буе суган каезлый монда. Житкереп кара яшьне! Яшь түкмәгәч, сүз уйнатуның да кызыгы юктыр.
— Кышын арчыйбыз, жәен үстерәбез,— ди Таифә Булатова.— Безнең өчен куаныч булды әле ул. Күпләргә жәен генә түгел, ел әйләнә эш табылды. Суган игү бик күп кул хезмәте сорый. Чәчүен машина чәчсә дә, аны тәзәткәләп чыгасы, аннары өч кат чүбен утыйсы, төбен йомшартасы, жыясы, киптерәсе бар. Бик мәшәкатьле. Бер гектарны багарга кочкә өлгерәсең.
«Әләзән», нәкъ менә эш күче күп булганга күрә, суган үстерергә алынган да инде. Хәзер бу үсемлек 820 гектарда игелә. Корылыклы елны да гектардан уртача сиксәнешәр центнер уңыш жыелган.
— Минеке утыз бераәр центнерга артыграк булды,— ди Булатова.— Сугардык. Мин үзем эшне вакытында үтәргә тырыштым. Басуга машинада барып-кайтып йөрибез, төшке ашны кырда ашыйбыз. Иптәшләрем дә тырыша, хезмәт хакыбыз уңыш исәбеннән бит.
Таифә — егерме дүрт кешеле звено башлыгы. Колхоз эшенә дүртенче класста укыганда ук катнаша башлаган — башак жыйган, чүп утаган.
— Әтинең белмәгән эше юк иде,— дип сөйли ул.— Атаклы балта остасы. Гармунчы. Беләзек, йөзек, алка коюу дисеңме, сәгать төзәтүме — барын булдыра иде. Гражданнар, фин, Бөек Ватан сугышларында катнашып, орден-медальләр тагып кайтты. Без — биш бала. Әти үз гадәтләрен, сәләтен һәммәбезгә сеңдерергә тырышты, аннары егерме жиде оныгына, аларның балаларына да канат булды. Сиксән сигез яшендә инде, әле һаман безне кайгырта, ил-көз алдында лаеклы кеше булуыбызны тели.
Таифә минем белән сөйләшеп торган арада ике чиләк суган арчыды. Ул әнә шулай, бөтәннәр илле-алтмыш килоны каезлаганда, сиксән-туксанга өлгерә икән. Егерме ел буе авыл советына, инде менә икенче мәртәбә район советына депутат итеп сайланган. Дүрт баласының һәркайсы урта махсус яки югары белем алган.
— Депутатлык дәрәжәгенә түгел, байтак вазифалар да йөкли,— ди ул.— Мәктәптә укыту-тәрбия, урамнарны яшелләндерү, юл төзәтү эшләре — хәлемнән килгәнчә һәммәсенә катнашам. Әле менә бер яшь гаиләне яңадан тергезеп жибәрүемә шатланам. Үзләре эшчәннәр, ике балалары бар. Яшьлекләре белән берзаман кызыбрак, дуамалланыбрак киткәннәр. Икесен дә үгетләгән идем, кушылдылар, тату гына яши башладылар.
— Бу суганнарны нигә арчыйсыз?
— Кулланырга әзерлибез. Моны әле әйбәтләп юачакбыз, киптерәчәкбез, аннары капларга тутырачакбыз. Әләзән суганының сыйфаты яхшы, шуңа күрә аны былтыр ГФР, Голландия дә сатып алды.

• • •

Совхозның партком секретаре Ибраһим Бадаев:

— Таифә кебекләр суган үстерү буенча алган йөкләмәләрне арттырып үтәргә мөмкинлек бирә,— ди.— Хәзер керемебезнең байтак өлешен суганнан алабыз. Дөрес, без яшелчә дә үстерәбез, иген дә игәбез. Гектарыннан уртача егерме бишәр центнер бөртекле ашлык алабыз, кукурузның яшел массасы 355 әр центнер чыга. Ике мең ярым мөгезле эре терлек, шул исәптән мең дә илле савым сыеры асрыйбыз...

Совхозның Югары Әләзән бүлегенә барабыз. Таш түшәлгән юл ямь-яшел кырларны ярып уза, тирә-якта үзе тәгәрәп сугара торган җайланмалардан шифалы «яңгыр» ургылы, кояшлы күктә күзгә күренмәс тургайлар чутылдый.

— Менә Нурияне генә алыйк,— ди Ибраһим.— Әнисе укытучы, әтисе — авыл советы председателе иде. Сигезенче классны тәмамлагач, үзем мәктәпкә секретарь итеп урнаштырдык. Әмма мәктәптә калмады бит, фермага күчте. Хисапчы итеп куйган идек, үзе теләп сыер сава башлады.

Нурия Хуҗиәхмәтова белән очрашкач, мин дә бу күчүнең серен сораштым.

— Эшнең яхшысы, койтысы юк аның,— диде ул.— Тырышсаң, кайда да уңышка ирешәсең. Уңыш китергән эш күңелгә дә үз була, яхшы да тоела.

— Шулай да фермада эшләүне кайберәүләр өнәп бетерми, исен, пычрагын яратмыйлар.

— Нәрсә ул аяк астындагы пычрак? Җыйдың, юдың — бетә китә. Кешенең эче пакь, таза булсын!

— Дөрес, Нурия,— дип хуплый аны Ибраһим.— Юкка гына депутатлыкка сайлаганбыз икән үзеңне.

— Авылныкымы, район советыныкымы? — дим мин.

— Авылныкы идем, бу юлы өлкәгә сайладылар әле.

«Әләзән» совхозында һәр сыер уртача ике мең ярым литр сөт бирә икән. Ә Нурия үзенекеләрдән 3709 арны сава. Сөйкемле сөяге булып, яхшырак сыерларны биргәннәрме икән әллә үзенә? Азыгын да аңа мулрак тамызалармы?

— Таналарны һәр савымчы үзе сайлап ала,— дип көлә Нурия.— Аларның нинди буласын алдан белү бик кыен. Ә азыкны бездә терлеккә малчылар сала, бу эшкә савымчылар катнашмый.

— Алайса күрсәткечләрегез аермасы нигә болай зур соң?

— Сайлаганда, тәҗрибә кирәк. Аннары мал астын үзебез тазартабыз. Сыерларыңны яратыбрак, җиренә җиткеребрәк кайгыртсаң, нәтиҗәсе көттерми аның. Өч мең литр савучылар бездә хәзер берәү генә түгел. Фермага эшкә керергә атлыгучылар да хәтсез, урын гына юк.

— Хезмәт хакыгыз ничегрәк?

— Минеке елга 3400 сум чыкты.

Нурия алтынчы ел шушы хезмәтендә икән инде. Былтыргы уңышлары өчен Почет билгесе орденына лаек булган.

• • •

Бүгенге Әләзән барлык техник казанышлардан файдаланып яши. Мотоциклларны санаучы да юк, җиңел машиналары гына да йөз илле тирәсе. Совхозда туксанлап йөк машинасы, йөз утыз трактор, аларны иярләгән тракторчы, шоферлар, бу техниканы «имли» торган слесарь, механиклар, бүтән белгечләр йөзәрләгән. Әле кайчан гына боларның барысы урынына да атлар, аларны дагалаучы һәм дирбияләренең тимертомыр өлешен төзәтеп торучы бердәнбер тимерче генә булган.

Тимерче? Урта Әләзән тимерчесеме? Бер, әмма берәгәйле булган ул. Әле дә махы бирми Фәттах Тугышов абзагыз. Ун ел буе райсобес кешеләрен тинтерәтүче дә шушы зат икән. Ул әле җитмеше тулгач та:

— Пенсия? Нәрсәгә ул миңа? Тәнем таза, беләгем дәрманлы, эшлим әле. Эшләп тапканым да бик җитә, бүтәне кирәкми! — дип киреләнә.

Быел ул сиксән бергә аяк баскан. Әмма әле һаман атлар дагалауны берәүгә дә ышанып тапшырырга теләми.

— Ничек инде таза-сау килеш тик ятасың? — ди ул.— Эш әҗерендә түгел. Шөкер, дүрт балам да мал таба, унбиш оныгымның да тамагы тук, өсте бөтен. Әмма алай дип мич башында ничек аунап ятыйм инде.

Тынгысыз, булдыклы, үҗәт Фәттах. Фашистлар илебезгә басып кергәч, ул 1941 елда ук үз иреге белән ут эченә ыргыла — Ленинградны сакларга китә. Яралана. Савыккач, тагын алгы сызыкка бара. Тиз арада танкка каршы мылтыктан атарга

өйрәнә. Фашистларда техника мул да, көчле дә. Аларны җиңәр өчен гайрәт һәм тәз ату кирәк. Синявинская биеклеге өчен сугыш аеруча каты була. Бер якта — Ладога күле, икенчесендә — урман. Дошман әнә шул урман эченнән һөҗүм итә. Ядрә яңгыры, шартлау, сызгыру, гөрселдәүләр, ыңгырашу, сүгенүләр. Сафлар сирәгәйгәннән-сирәгәя, дәһшәт көчәйгәннән-көчәя. Гитлерчыларның «Фердинанд»лары аеруча хәтәр: төгәл ата, хәрәкәтчән, бронясы нык. Автоматчы, пулеметчы дошманнар башны күтәрергә дә ирек бирми. Ләкин Фәттах та җебегән-юашлардан түгел. Тәвәккәл, үчле. «Фердинанд» агачлар арасыннан килеп чыгуга, Әләзән егете Фәттах аңа — бах! Фашист машинасын шунда ук ялкын һәм төтен чолгап ала, аңардан сибелешкән гитлерчыларны исә дәртләнеп киткән укчыларыбыз өтә башлый. Фәттах нәкъ менә шушы егетлеге өчен Кызыл Йолдыз ордены белән бүләкләнә. Аннары Эстония, Латвияне азат итүләр, сугыш җиңү белән тәмамланганчы тагын дистәләгән, йөзләгән чәкәләшү, батырлык үрнәкләре.

Урта Әләзәнгә килүче һәркем хәзер үзәк мәйдандагы һәйкәлгә игътибар итми калмый. Бөек Ватан сугышында катнашучылар хөрмәтенә куелган ул. Урта Әләзәннән Фәттах Тугышов шикелле дүрт йөздән артык ир-егет баса Ватан сагына. Аларның яртысы яу кырында ятып кала.

Ә исән-сау туган нигезенә әйләнеп кайткан сержант Фәттах элекке эшен дәвам итә — тырмалар төзәтә, атлар дагалый, агачлар утырта. Яңа шөгыле дә бар — онык-лар тәрбияли. Кая ул пенсиягә чыгып, мич башын җылытып яту!

* * *

Тугышов Искәндәр Фәттах улы. Юк, югарыда сурәтләнгән тимерче Фәттах малае түгел. Авыл зур булгач, Урта Әләзәндә адашлар җитәрлек. Әмма үзенең ачык йөзе, базык гәүдәсе, ипле мөгамәләсе, кылтан эшләре һәм тоткан юлы белән Искәндәр өлкән авылдашына — атаклы тимерчегә бик охшаган, аның дәвамы саналырлык шәхес. Ул да үзенең хезмәте белән күпләргә шатлык китерә. Тик, яңа заман кешесе буларак, ул тимерче Фәттахтан шактый аерыла да. Югары белемле төзүче, инженер. Авылына ямь, тормышка уңайлык өстәгән эшләрне ялгызы гына түгел, кул астындагы 180 кеше белән күмәкләп башкара.

— Совхозыбыз елдан-ел үсә, ныгый бара,— ди ул.— Төзелеш бригадабызда гына да егермеләп һөнәр иясе бар. Аларның өчесе техникум, икесе институт тәмамлаган. Барысы да Әләзәндә туып үскәннәр. Хәзер ел саен җиде йөз мең сумлык капиталь төзелеш алып барабыз.

Ике йөзәр баш терлек асрый торган сигез сыер, ике бозау абзары. Ике мең тонна суган саклый торган келәт. Суган киптерү цехы. Урта Әләзәндә 300 урынлы культура йорты, 1174 урынлы мәктәп. Югары Әләзәндә шундый ук корылмалар 200 һәм 784 урынга исәпләнгән. Элек бу авылларда кечкенә генә бер кибет (берсе саман-нан!) булса, хәзер Урта Әләзәндә универмаг бар. Азык-төлек кибете өчәү. Китап һәм хуҗалык товарлары өчен махсус магазин ачылган. Югары Әләзәндә шулай ук уңайлы ике кибет халыкка хезмәт күрсәтә. Йөз урынлы шифаханә, дистәләгән өйләр, хуҗалык биналары, асфальт заводы...

Төзүчеләргә эш җитәрлек. Балалар комбинаты, 612 мең сумга төшәчәк сыт-кәргеч кору, ике Әләзән арасындагы юлны, үзәк урамнарны асфальтлау, калганнарына таш түшәү — болар барысы да Искәндәр Тугышов һәм аның иптәшләрен көтә.

— Өлгерербез,— ди ул ышанычлы тестa.— Хәзер асфальт заводына кадәр үзебезнеке ич. Егәрлеге сәгатенә унбиш тонна. Дөрес, комташ, битум, доломитны Сызраньнан ташырга туры киләчәк. Дүрт белгеч тә укытып кайтардык. Шулай да кайбер урамнарда җәяүле сукмагын гына асфальтларга исәп. Уртасын күтәртеп, таш түшәячәкбез. Авыл бит, аның эчендә машина гына түгел, тракторлар да керәли.

Шулай, бар байлыкны да акыл белән файдалану яхшы.

Мин үзе турында сөйләүне үтенгәч, Искәндәр:

— Сезгә Казим абый Якупов белән очрашырга иде,— диде.— Алтын куллы оста. Әләзән капкаларын, өй карнизларен шул челтәрли инде. Бу өлкәдә авылыбызның борынгыдан килгән казанышларын да күрсәтер иде.

— Әләзәннең бер матур казанышы — күп балалы тату гаиләләр. Кайберәүләр хәзер бала үстерүне авырсына башлады.

— Без Әләзән гадәтләренә тугрылыклы,— дип елмая Искәндәр.— Биш бала үстерәбез. Өчесе мәктәптә. Кызым Гөлсем энисе кебек укытучы булмакчы, пединститутта чит телләр өйрәнә. Улым Рафаил төзелеш институтына керде...

Алмашка яшь төзүче дә үсә. Димәк, Әләзәндә янарыш ышанычлы дәвам итәчәк.

* * *

Урта Әләзән гомер буена иген игә, терлек асрый, йорт-җир кора. 1862 елда монда 287 хуҗалык санала, 1800 кеше яши. Илле елдан соң хуҗалыклар 626 га, халкы

3644 кә җитә. Хәзер инде аның йортлары меңнән ашкан, кешеләре тугыз меңгә якынлашып килә. Югары Әләзәндә халык саны өч мең ярым чамасы. Шушы ике авылны берләштергән «Әләзән» совхозының бөтен җире исә 9500, шул исәптән, сөрүлеге 7600 гектар. Кеше башына исәпләсәң, бик аз. Дүрт мең ярымлап эшкә яраклы кешене гадәти игенчелек, терлекчелек, төзүчелектә генә файдаланып бетерү, димәк, мөмкин түгел. Кул көчен күп сорый торган тармакларны үстерүгә карамастан, совхозда нибары мең ярым гына эш урыны бар. Кыш көне анысы да юкмы. Туган авылын ташлап китәргә теләмәгән, бер хезмәттән дә чирканмаган бүтәннәргә нишләргә соң? Ә Дашкин Габбас кебек ун бала үстерүчеләр унысын ун якка таратсынмы? Аларны бер күрер өчен генә дә ун сәфәргә чыгу ата-анага артык кыенга килмәсме?

Каршымда әнә шул унның берсе — Гөлсем утыра.

— Мин сигезенчене бетергән ел иде,— ди ул.— Совхозыбыз ат заводы өчен бина корган. Директорыбыз Хәмзә абый, авылыбызда эш таба алмый интеккән кешеләр турында уйлап, озак баш ваткач, тота да Кузнецк аяк киемнәре фабрикасына китә. Урта Әләзәндә аның филиалын ачарга килешеп кайта. Әзер бина менә шуннан соң бөтенләй башка максатка билгеләнә, ә без — иллеләп яшь-җилкенчәк Кузнецкига юнәлдек. Фабрикада ике ай буе өйрәнгәннән соң, туган авылыбызга кайтып, аяк киемнәре тегәргә керештек.

Тиздән яшь коллектив аерым өлешләрне әзерләүдән аяк киемен тулаем тегүгә күчә: чүәк, аннары кроссовка, балалар түфлие. Филиал беренче елны ук смена саен мең урынына мең ике йөз пар чүәк тегә. Тора-бара эшчеләр саны да арта, 280 гә җитә. Алар хәзер төрле модельле унбиш төрле аяк киеме озата, дүрт ел эчендә 5,2 миллионлык хезмәт башкарылган. Филиал үсә, ныгый, аның белән бергә кешеләр дә үсә. Гөлсем оста тегүчегә әйләнү белән бергә кичке урта мәктәпне дә тәмамлый. Аның апасы Наилә исә шушында ук мастер булып күтәрелә.

Филиалда күбесенчә хатын-кызлар. Уртача айлык хезмәт хаклары — йөз егерме дүрт сум. Үз терлеге, үз бакчасы булган, туган-үскән өендә яши торган кешегә азмыни?

Әмма филиал Әләзән халкын җирдән аермый. Тегүчеләргә дә иксән гектар суган үстерү йөкләнгән. Шуңа күрә тегүчеләр җәен кырга йөриләр. Алар суган караган көннәр өчен фабрика уртача хезмәт хакларының яртысын түләп бара. Совхоз исә араны уңыш исәбеннән өзә. Узган ел ул, мәсәлән, һәр эш көненә биш сум чамасы туры килгән. Димәк, филиал эшчеләренең гомуми хезмәт хакы шактый арта икән!

Совхозның үз тегү цехы да бар. 1980 ел башыннан монда халат, сырма, бияләй кебек эш киемнәре тегәләр. Дашкиннар гаиләсеннән өченче кыз менә шунда 160 иптәше белән бергәләп файда китерә. Дүрт ел эчендә бу цех 3,7 миллионлык товар җитештерә һәм 747 мең сум табыш ала. Бу цехның да суган кыры бар.

Суган киптерү цехында ике йөзләп кеше эшли. Бу цех барлыкка килгәннән бирле 3,8 миллион сумлык кипкән суган сатылган, табыш — 1,4 миллион сум.

Ничә һөнәр иясе яши икән бүген Әләзәндә? Берәү дә исәпләп карамаган әле аны. Барлаганда, мөгаен, йөз санын кулланмый булмас кебек. Ә менә элек күпмегә җыйналуын картлар тизрәк әйтә алыр. Бүгенге казанышларны бәяләү өчен үткәнгә борылып карау бигрәк тә гыйбрәтле.

* * *

Пенза якларында йөргәндә: «Безнең бабайлар — Идел буеннан», «Фәлән нәсел казанлылардан килә»,— дигән сүзләрне еш ишетергә мөмкин. «Әләзән»нең баш агрономы Рифкать Бибарсов миңа өзеп: «Безнең ата-баба Болгардан чыккан»,— дип белдерде. Соңрак мин бу хәбәрләрнең нигезсез түгел икәнлегенә, шәҗәрәләр белән дә раслануына шаһит булдым.

Гыйльми тикшеренүләр ясалмаса да, Әләзән тарихы күпләрне кызыксындыра икән. География укытучысы Җәгъфәр Янгуразов беренче урта мәктәптә хәтта авыл тарихы музееп да оештырган, фәнни китапларны караштырган элекке губерна үзәге Саратовка барып, архивларда да казынган.

— Әләзән якларында кеше таш гасырында ук яшәгән,— ди ул.—Геродот хезмәтләрендә, мәсәлән, монда безнең эрага кадәр бишенче гасырда күчмә будин һәм утрак гелон кабиләләре теркәлә. Тимер кулланган бу кабиләләрнең беренчесе терлекчелек, икенчесе игенчелек, ядгынчылык белән шөгыльләнгән. Унынчы гасыр гарәп сәяхәтчеләре будиннарны инде бортас дип яза. Әләзән ягында халык үрчү, һөнәрчелек үсү, шәһәрләр салыну, сәүдә җанлану исә Алтын Урда заманында көчәя. Ләкин Тимер яуларыннан соң бу төбәк бөлгенлеккә төшә, яу кырына әйләнә. Халык чебендәй кырыла, исәннәре яңа күчмә кабиләләр басымы астында төньяк-көнбатыш-

тагы урман араларына кача. Рус биләмәсенә әверелгәндә, бу яклар шактый дәрәҗәдә бушап калган була.

Халык хәтере раслаганча, Идел буеннан күчеп килүчеләрнең монда ике дулкыны — Болгар һәм Казан дәверләре абайлана. Аларның бер өлеше морза катламыннан була. Урта Әлзәндә тупланган алты нәселнең кайберләре, чуралары — бәйле кара сөякләре белән килә, әмма алардан 1756 елда колак кагалар. Җәгъфәр Янгуразовның раславынча, Агишевлар Идел буеннан, Якуповлар һәм абыйлы-энеле Таһировлар (алтынчылар!) Казан ягыннан, Дашкин, Бибарсов, Янгуразов, Бәхтиевләр Темников ягыннан килеп урнаша. Әлзән якларының кайчандыр Болгар һәм Казан ханлыклары эчендә булуы, бу дәүләтләр зәгыйфьләнгәч һәм юкка чыккач, җирле халыкның кая таба кысрыклануы билгеле. Шуңа күрә Темников ягыннан 1680 елларда Әлзәнгә күчеп килгән әлеге нәселләрнең байтагы үзенең элгәреге илеҗиренә генә кайткандыр сыман. Үзләренең «болгарлы» икәнлекләрен онытмаулары нәкъ менә шул хакта сөйли дә инде.

Әлзәндә өлкән буынның байтак гарәп-фарсы сүзләре катнаштырып, борынгырак әдәби телдә, яшьләргә караганда күпкә сафрак һәм баерак әдәби телдә сөйләшүләре игътибарга лаек. Җитмеш бишне тутырган Гомәр Дашкин әле дә булса Мәскәү басмалары белән бергә Казан журналларын да укып бара, борынгы китапларны, кульязмаларны барларга тырыша.

— Революциягә кадәр Урта Әлзәндә биш мәчет булган, алар каршысында дүрт мәдрәсә,— ди ул.— Билгеле, шәкертләребез башлыча дин сабагы укыган. Әмма укый-яза белү бездә бик киң таралган була. Басма китап та, кульязмалар да кулданкулга йөри. Соңрак Казан укытучылар мәктәбен тәмамлап килгән мөгаллимнәр дөньяви фәннәрне дә кертә. Муллалардан Хафиз Бәхтиев бигрәк тә алдынгы карашлы була. Революциядән соң ул үз җирен фәкыйрьләргә бирә, ярлылар комитетына керә, шуның өчен 1919 елда кулаклар тарафыннан үтерелә. Бездә татар матбугаты революциягә кадәр үк кызыксынып укылган. Кирасировларның берсе хәтта Тукай белән хатлар алышкан. Безнең бай гына шәхси китапханәбез 1930 елгы янгында харап булды.

Заманына күрә казанышы. Архив раслаганча, 1911 елда Урта Әлзән халкы егерме биш тимер сукага һәм ике иләк машинасына ия була. Урак белән чалгыдан, балта-пычактан кала бүтән эш кораллары — агачтан. Төп таяныч — ат. Керосин лампасы, җил тегермәне, каурый каләм.

* * *

Урта Әлзәндә тугыз врач, егерме сигез фельдшер һәм акушер эшли торган шифаханә. Китап кибете. Өч урта мәктәп (берсе кечке), дүрт китапханә. Культура йорты, элемтә бүлеге. Һәр өйдә радио-телевизор, вакытлы матбугат. Ике йөзләп югары белемле белгечнең һәммәсе диярлек шушында туып-үскән. Әнвәр Янгуразов, Дәүләтша Янгуразов, Асият Таһиров шикелле офицерлар, дистәләгән врачлар, инженерлар туган авылдан еракта хезмәт итә. Асият Дашкин Татарстан республика шифаханәсендә эшләгән, биология фәннәре кандидаты Зөфәр Кирасиров — Таҗикстанда, биология фәннәре докторы Фатыйх Бәхтиев Мәскәүдә фәнни эш алып бара. Болар — Урта Әлзәннең совет заманындагы казанышлары.

Бу казанышларны телгә алганда, әлзәнлеләр Себер егете Габделхәмит Ибраһимовны хәтергә төшерми калмый. Казан институтын тәмамлап килгән егет укытуның сыйфатын күтәрүгә, авылның рухи тормышын җанландыруга онытылмаслык өлеш кертә. Туган әдәбиятыбыз һәм телебезгә мәхәббәт тәрбияләүче Татарстан кызы, Мәнгәрдән килеп шушында тамыр җибәргән Нәкыя Хафизова да истән чыгарылмый. Югары Әлзәндә физика укытучысы Мамадыш егете Фаил Гыйльманов та хөрмәт ителә. Г. Камалның «Бүләк өчен» пьесасын һәм башка әсәрләрне сәхнәләштерүдә, концертлар куюда дәртләнеп катнашуы, җәмәгать эшләренә бүтәннәрне дә һәвәсләндерә белүе белән танылган укытучыны күптән түгел авыл советы председателе итеп сайладылар.

Әлзән Мәскәүне һәм Казанны тыңлый, зәңгәр экран аша бөтен җир шарының тормышы белән таныша, совет һәм чит ил әдәбиятларын укый. Башка күп төрле басмалар җөмләсеннән Татарстан газета-журналларына да күз салып яши — «Азат хатын»ны гына да авылның 360 гаиләсе алдыра.

Әмма бу өлкәдә барысы да ал да гөл түгел әле. Өч Әлзәндә унбиш меңгә якын татар халкы яши, тик китап кибетендә ана телендәге бер генә басма да, туган әдәбиятыбызның хәтта тәрҗемәләре дә сатылмый. «Әлзән» совхозына нибары уналты данә «Казан утлары» журналы килә. Аларның да икесен китапханәләр алдыра. Сов-

хозның берничә йөз белгече ни өчен туган әдәбияты, сәнгате белән кызыксынмый икән соң? Берсе генә дә язылмаган лабаса!

— Чыннан да бик сәер хәл бу,— ди партком секретаре, «Почет билгесе» ордены кавалеры Ибраһим Бадаев.— Тәрбия эшендә, күрәсең, күп нәрсәгә өлгерә алмыйбыздыр. Татарстан белән бәйләнешләребез юклыгы да үзен сиздерә. Әдәби телне, туган әдәбият, сәнгатебезне яхшы белә торган яшьләр культура йортыбызга, мәктәпләребезгә эшкә килсә, хәл тизрәк үзгәрер иде.

Әләзәндә, Казаннан икәнеңне белсәләр: «Әллә концерт куярга килдегезме?» — дип сорып алалар. Өметләре акланмаса: «Татарның язучылары, композитор-рәссамнары, артистлары кайда гына йөри икән?» — дип сукраналар. Сүз генә кузгат, меңләгән китапка, җыр тәлинкәсенә заказ яудыра башлыйлар.

Матурлыкка сусау. Бу да күңел байлыгы лабаса!

* * *

Совхоз директоры Хәмзә Исләев белән очрашкач, мин халыкның әнә шул рухи ихтыяҗларын да телгә алдым.

— Аңлыйм,— диде ул,— ни әйтсәң дә, кайчандыр «Галиябану»да Хәлилне уйнаган егет ич мин. «Асылъяр»ны да, «Хаҗи әфәнде өйләнә»не дә куя идек. Халык ябырылып килә иде. Аннары шул спектакльләр белән күрше авылларга гастрольгә дә чыга идек әле. Яшьлек дәртем дә, укытучы һәм бухгалтер чагымда вакытым да иркенрәк булгандыр инде. Ә хәзергеләрне аңламассың. Культура йортлары уңайлы, киеме, җиһазы, музыка кораллары күп, яшьләр авыл тулы, ә шулай да спектакль куярга читтән килгәнне көтеп яталар. Бәлки үзебез дә нәрсәнедер күздән ычкындыргандыбыздыр — әлегә кадәр матди якны яхшыртуга күбрәк игътибар бирдек.

Бәхеткә каршы, бу тырышлык бушка китмәгән. Әләзән совхозы унсигез ел эчендә, дәүләтнең олы ярдәменә таянып, үзенең төп байлыкларын ун тапкыр арттыра — уналты миллионга җиткерә. Шул вакыт эчендә совхоз кешеләренең хезмәт хакы 760 меңнән 2,5 миллионгача үсә. Хәзер ул ел саен биш миллион сумлык байлык житештерә, дәүләткә биш мең тонна суган, 2300 тонна сөт һәм 380 тонна ит тапшыра. Бу казанышларга ирешүдә совхоз директорының өлеше дә зур.

Авылның үткәнен, совхоз хәлләрен телгә алганда, Гомәр абзый Дашкин:

— Директордан уңдык без,— дигән иде.

Мин инде шунда ук колакларымны торгызып, Исләевнең агроном чагында ук югары уңыш алуы өчен «Мактау билгесе», директор булгач, барлык планнарны үтәве өчен, «Октябрь Революциясе», Ленин ордены белән бүләкләнүен санап китәр дип көткән идем. Әмма картым:

— Авылыбыз зур, анда төрле киек, арада гөнаһлысы да очрый торгандыр, тик Хәмзә иптәш берәүне дә әллә кайларга сөрмәде,— дип сүзен төгәлләде.

Чын сабырлык, тәрбияче осталыгы һәм, алардан да бигрәк кешеләрне ярату хисе кирәктер моның өчен. Җәй җитүгә, әле дә ике мең әләзәнле читкә эш эзләп китә ич. Кирпеч заводларына, төрле төзелешләргә. Кышка таба алар инде туган ояларына җыйнала. Байтагы кесә калынайтып кайта, арада шуңа масаеп, «мин кем?» дип мөгез чыгаручылары, зыян-зарәт ясаучылары да табыла.

— Озын берлек яратучылар да бар барын,— ди бу хакта директор.— Әмма халыкның күбесе үзебездә эшкә урнаша алмаганлыктан читкә китә. Аларга «шабашник» дип бәйләнгәнче, авылыбызда яңа хезмәт урыннары булдыруны ныграк кайгыртырга кирәк.

Исләев моңа директорлык вазифасын үти башлагач ук игътибар итә. Әмма яшь совхозның башта мөмкинлекләре чикле була. Аякка баса барган саен, Хәмзә Рәятуллович бу мәсьәләгә ешрак әйләнеп кайта, Мәскәү, Ленинград, Липецк өлкәләре колхоз, совхозларында ярдәмче хуҗалыклар оештыру тәҗрибәсен өйрәнә, булышуны үтенеп, югары оешмаларга мөрәҗәгать итә. Городище район советы депутаты, партиянең райком бюросы әгъзасы, аннары өлкә советы депутаты буларак.

— Кешене ата-баба җирендә яшәтү яхшы,— ди директор.— Авылда ул табигатькә якынрак. Аннары Әләзән кебек авылның сәламәт рухлы үз микроклиматы да бар ич әле. Бездә халык тотнаклырак, нечкә күңеллерәк, итагатьлерәк. Игътибар иттегезме: Әләзәндә ят кешегә дә сәлам бирел узалар. Авыл кешесе яшьтән эшкә күнегеп үсә, аларның гаиләләре дә тотрыклырак. Аннары безнең әләзәнлеләр туган авылларына ябышып ята ич, нигә аларның бу теләге белән исәпләшмәскә?..

Кешеләрне аңлар өчен, үзеңә дә дөньяның ачысын-төчесен татып карау кирәк. Атасы Мәскәү янындагы сугышларда ятып калганда, Хәмзә әле нибары сигез яшьтә генә була. Биш баланың иң өлкәне! Шуңа күрә энеләрен, сеңелләрен дә бага ул, бабасыннан урман кисәргә, чабата үрергә, сынык чалгы белән печән чабарга да өйрәнә.

Башлангыч мәктәпне тәмамлагач, бакчачылыкта, аннары кырчылыкта хисапчы. Кырыс елларның михнәтен күтәрү аңа шактый озак укуын дәвам итәргә мөмкинлек бирми. Туган авылы Югары Әләзәннән Урта Әләзәнгә йөреп белем алуы бишенче класста ук өзелеп кала. Әмма омтылышы бик нык була малайның. Кием, ризык кытлыгы да туктата алмый, җиденче классны бетерүгә, Пенза авыл хуҗалыгы техникумына китеп бара. 1957 елда инде ул туган авылына — «Алга» колхозына агроном булып кайта. Колхоз «Сура» совхозына кушылгач, Югары Әләзән бүлегендә идарәче хезмәтләрен башкара. Эшчән Хәмзәне менә шуннан Городище районы авыл хуҗалыгы идарәсенең баш агрономы итеп күтәрәләр.

— Без инде байтак нәрсәләр булдыруга ирештек,— ди Исләев.— Әмма алдагы бурычларыбыз да бихисап. Якын киләчәктә совхозның агач эрҗә ясау, торак йортлар кору өчен стандартсыз детальләр җитештерү цехларын ачачакбыз. Кузнецк аяк киемнәре фабрикасы филиалын тагын да киңәйтергә, читек тегүне юлга салырга ниятлибез. Сура постау комбинаты — эрләү-туку цехын, Пензаның «Пушинка» берләшмәсе — мамык-йон әйберләр бәйләү бүлеген төзиячәк.

Әмма ярдәмче хуҗалыклар, исеменнән үк күренгәнчә, киләчәктә дә ярдәмче генә булып калачак. Әләзән халкы иген игү, терлек асраудан биздерелмәячәк. Тәҗрибә исбатлаганча, филиаллар ачылу совхозда хезмәт җитештерүчәнлеген шактый күтәрә. Филиал эшчеләре үз кырларында суган уңышын кырчылыкта гына эшләүчеләрдән егерме өч центнерга күбрәк үстерә, аларның көнлек хезмәт хакы да совхозныкылардан дүрт сумга артыграк. Цех эшен кырдагы белән аралаштыру филиалдагыларга шулай ук бик ошый. Игенче нәселеннән ич алар!

— Күргәнсездер, бездә хәзер тавык кетәгенә кадәр кирпечтән,— диде Исләев.— Совхоз үз эшчеләренә төзү материаллары табуда даими булыша. Урта Әләзәндә яңа ашханә, 1174 урынлы яңа мәктәп, тәүлегенә егерме дүрт тонна икмәк пешерә торган пекарня, утыз биш эш урынлы көнкүреш хезмәте күрсәтү комбинатын сала башлаячакбыз. Озакламый авылдашларыбыз кер юу, кием тегү, чәч алдыру, телевизор, сәгать төзәтү кебек бик күп йомышларын Әләзәннең үзендә үти алачак. Инде быел ук музыка мәктәбе ачарга җыенабыз. Үз музеебызны, халык театрыбызны тергезәсе килә. Колачыбыз киң, тиздән еллык саф табышыбыз бер миллионга җитәчәк. Сәламәт тәндә сәламәт рух була диләр. Тәнебез сәламәт булуы, матди нигезебез ныклыгы шик уятмый хәзер. Киләчәктә тук, иркен, бөтен гөнә түгел, матур, кызыклы һәм күңелле яшәргә дә өйрәнербез дип уйлыйм.

Буш хыял түгел бу. Әләзәннең киләчәге дә котлы.

*Казан — Пенза.*

Энҗе Мөэминова

# ДӘВАМ

Күзгә төртсәң күренмәслек көзге төн. Бөтен нәрсә караңгылык диңгезенә чумган. Тәрәзәләрдәге якты нокталар гына төрлесе төрле биеклектә җемелдәшәләр. Вакыт узган саен аларның саны да кими бара. Төн урталары җиткәндә, инде бөтенләй бетәләр. Авыл йокыга тала.

...Чү! Туктагыз!
Кемдер йокламаган:
Тәрәзәсеннән аның кояш карый,
Якты нур көлтәсе бөркелә!

Авыл кешеләренә бу тәрәзәләр яхшы таныш. Мәктәп директоры Гөлчирә Латыйповна Рәхмәтуллинаныкы ул тәрәзә.

Гөлчирә Латыйповна һәр көнне шулай, бик озак кич утырып, алдагы көннең эшләрен планлаштыра. Аңа иртәгәге дәресләргә хәзерләнергә генә түгел, ә укучылар һәм укытучылар коллективы беләнниләр башкарасын да, хуҗалыкта ниләр үтәргә икәнен дә чамалап куярга кирәк. Ул — совхозның партком члены, агитколлектив җитәкчесе дә, пропагандист та. Авыл советы депутаты буларак, халык үтенечләре буенча эш алып барырга да, РОНО советы члены буларак, район мәгариф бүлеге эшчәнлеге үзәгендә кайнарга да кирәк. Аның вазифасына ата-аналар алдында педагогик темаларга чыгышлар ясарга да туры килә. Шулар янына өйдәге «тавык чүплəп бетерә алмаслык» көндәлек мәшәкатьләр өстәлә. Кабаланмыйча, чәбәләнмичә генә менә шуларның барысына да өлгерергә кирәк.

Гөлчирә РСФСРның милли мәктәпләр буенча фәнни-тикшерену институты белән берлектә тәҗрибә дә алып бара. Республика һәм союз күләм үткәрелә торган фәнни-практик конференцияләрдә системалы рәвештә катнашып, методик докладлар ясый. Класстагы һәм класстан тыш эшләре буенча уңышлы тәҗрибәләрен уртаклашып, педагогик матбугатка мәкаләләр яза.

Педагог, әлбәттә, вакытлы матбугат, радио-телевидение тапшырулары, педагогика һәм әдәбият өлкәсендәге яңалыклар белән дә танышып барырга тиеш. Шул эшләрнең барын да күз алдында тотып, төгәл кысага кертелгән планың булмаса, сиңа тапшырылган бурычларны үтәү шактый кыенлашыр иде. Гөлчирә Латыйповна үзе дә шулай аңлата.

— Син җиңел эшлисең диләр миңа. Чыннан да шулай бу. Тыныч кына, кабаланмый гына барын да бер-бер артлы җиңә киләм. Сәбәбе шул: һәр эшемне әнәсеннән җебенә кадәр җентекләп планлаштырам,— ди ул.

Дөрес әйтә директор. Уйлап төзелгән дөрес план — уңышка китерүче иң туры юл ул.

Минем кулда «Совет мәктәбе» журналы. «Рус теле һәм әдәбияты» бүлегендә Гөлчирә Латыйповнаның зур гына мәкаләсе урнаштырылган. Мин беләм: Гөлчирә бу журнал белән 1960 елдан бирле эшлекле элемтәдә тора.

Арада бер мәкаләсе «Класстан тыш уку дәресләрендә съезд материаллары» дип атала. Автор КПССның XXVI съезды материалларына бәйләп, матур әдәбиятның тәрбия эшендәге ролен ачып бирә. Дәресләргә, әнә шул көчле йогынты чарасыннан ничек файдалану мөмкинлеген күрсәтә.

Фикерләрен раслау өчен автор күп милләтле әдәбиятыбызның ике әсәренә: Чыңгыз Айтматовның «Гасырга тиң бер көн» һәм Юрий Бондаревның «Сайлау» әсәрләренә туктала. Бүгенге көннең әдәби җәмәгатьчелеге арасында күп бәхәсләр кузгатып, миллионлаган укучыларның игътибарын җәлеп иткән бу ике әсәрнең җанны тетрәндерә алырлык көченнән яшьләрне тәрбияләүдә ничек файдаланырга икәнен күрсәтә.

Юрий Бондаревның «Сайлау» әсәрендәге художник Владимир Васильев образына съезд трибунасыннан бирелгән бәяне Гөлчирә Латыйповнага карата да әйтәсе килә: «...Аның

дөньяда яшәве мәгънәле, аңарда — Ватанга чиксез мәхәббәт хисләре. Әнә шул бетмәс — төкәнмәс көч чыганагы аны куәтле итә, тормышының иң кыен моментларында яшәүгә омтылыш бирә».

Гөлчирә Латыйповна тормышында да кыенлыклар очрап кына тора. Аның сабый җанына беренче тетрәндергеч җәрәхәт 1931 елның май азакларында ясала. Кулаклар Гөлчирәнең әтисе Латыйп аганы Сарман районының Рангазар авылы басуында җәзалап үтерәләр. Ул вакытта Латыйп ага Иске Әлмәт авылында балалар укыта. Авылның берданбер коммунисты буларак аны партия райкомы Рангазарга колхоз оештыру эшенә җибәрә. Җыелыш үткәрәләр. Күпләр колхозга язылалар. Аннары Латыйп ага, иптәшләренең куна калырга киңәшләренә карамастан, тәүлеккә, күлкә каршы юлга чыга, һәм шунда һәлак була.

Гөлчирә бу вакыйганы болай хәтерли.

— Әткәйне мин кан эчендә күрдем. Ерактa, уҗым өстендә аның эшләпәсе ята. Барып аласым килә, кузгалып булмый... Бөтен нәрсә кара булып хәтеремдә калган. Кешеләр әткәйнең битенә каплаган ак япманы ачкан саен, сеңлем: «Әттә!» — дип куя. Ул шулай әйткән саен, кешеләр елап җибәрәләр. Мин елый да алмыйм. Ул чакта әле мин үлемнең ни икәнлеген белмим, шунлыктан аның кабат өйгә кайтмавына да ышана алмыйм. Ишек алдында аның белән бергә ясаган балчык уенчыклар аунап ята. Шкафта — түшенә кадап йөргән значогы. Значоктагы рәсемне әткәй дип уйлыйм... Кабер өстендәге бик күп чәчәкләрне, зур-зур җиз торбалардан агылган көчле музыканы хәтерлим.

Үсә төшкәч, мин значокта Ленин рәсеме булганлыгын белдем.

Авыл халкы мине «коммунист кызы» — дип, хөрмәтләп йөртә. Бәйрәмнәрдә байрак янында басып торырга чакырып алалар. Шуңа күрә мин үземне «бик яхшы»га гына укырга тиеш дип хисаплый идем.

Фаҗиганың аннан да хәттәррәге 1941 елны килә. Сугыш дәһшәте үзе белән ачлык, ялангачлык, кайгы-хәсрәт, әче күз яшьләре китереп кенә калмый, Гөлчирәнең ак чәчкә кебек ак,чишмә суларыдай саф, кояш нурларыдай якты күңел йолдызын — яшьлек мәхәббәтен тартып алып, көлгә әйләндерә.

Сугыш аның хыялларын чәлпәрәмә китереп, тормыш сукмакларын Урта Азиягә үк илтеп тоташтыра. Бу еллар Гөлчирәнең рухи ныклыгына чын-чынлап сынау еллары була. Иң элек ул үзлегеннән үзбәк телен өйрәнергә керешә, һәм Ташкент шәһәрендә, үзбәк телендә укып, «отлично»га техникумны тәмамлый. Уку елларында ук ул актив комсомолка була. Төннәрен, М. Горький исемендәге тегү фабрикасында эшләп, фронттагылар өчен җылы киемнәр әзерләшә.

— Хезмәтнең изге нәрсә икәнлеген мин шул чорда аңладым. Шул хис миңа күтәрә алмаслык авырлыкларны җиңәргә ярдәм итте.

Мине шәһәр комсомол конференциясенә делегат итеп сайладылар. Шуннан соң миндә хезмәтнең кешене олылавына ышаныч туды.

Хезмәт юлына аяк басуы турында сөйләгәндә Гөлчирәнең күзләрендәге нурлы караш тагын да яктырак балкый.

— Техникумнан соң мин Фиргана өлкәсе кышлакларында балалар укыттым. Үзлегемнән рус теленә өйрәнә башладым. Фирганәнең укытучылар институтына читтән торып укырга кердем,— дип дәвам итте ул. — Муеннан эшкә чумдым. Көне буе мәктәптә булам, төнге уникеләргә кадәр халыкны мамык чистартырга оештырып йөри идем. Аларга кич утырып китаплар, газеталар укыйм, фронт хәлләре белән таныштырам. Үзешчәннәр белән концертлар куябыз.

Үзем дә үзбәк халкының күренекле язучылары, шагыйрьләренең әсәрләре белән таныштым. Сәнгатен, гореф-гадәтләрен аңларга өйрәндем. Иң яраткан шагыйрем — Зөлфия. Мин аның шигырьләрен сәхнәдә яттан сөйли идем,— дип, Гөлчирә минем алдыма Ташкентта чыга торган хатын-кызлар журналы төпләмәсен китереп куйды.— Бу журналга ел саен язылам. Зөлфия шигырьләре булса, ул саннарын төпләп барам.

Гөлчирә Зөлфиянең «Уйларым» исемле шигырен сүзгә-сүз миңа аңлатып бирде, без бергәләп шигырьне татарчага тәрҗемә иттек:

...Йөрәгем ярсып типкәндә,
Тәнемдә җегәр барда,
Хезмәтемне, илһамымны
Багышлыйм мин Ватанга!

— Бу юлларны мин үз сүзләрем кебек хис итә идем,— ди Гөлчирә.—Кышлакларда, үзбәк яшьләре белән бергәләп, ниләр генә эшләмәдек без?! Мин комсорг идем. Фирганәнең өлкә комсомол конференциясенә катнашып, анда чыгышлар ясадым. Шушы елларда мин рус һәм совет классикларының әсәрләрен укый башладым. Дөнья әдәбияты белән таныштым. Үзешчәннәр белән эшләргә дә өлгерә идем. Безнең коллектив ярышлар вакытында өлкә күләмендә беренче урыннарны алды. Үзем өчен, кайчандыр, буй җит-

мәслек биеклек саналган укытучылык һөнәренең серләренә дә мин шушы елларда төшенә башладым. 1951 елның июнь аенда, институт дипломы алу шатлыгымны бөтен кышлак белән, зур бәйрәм итеп, билгеләдек. «Шул елларда миңа хөкүмәтебезнең бик кадерле бүләген — «1941 — 1945 Ватан сугышы елларындагы намуслы хезмәт өчен» медален дә бирделәр...

Халык тикмәгә генә: «Рәхәт булса да торган җир, сагындыра туган ил» — дип җырламаган икән. Туган якның тарту көче җиңә, Рәхмәтуллиннар гаиләсе кабат Татарстанга, Әлмәткә кайтып урнаша. Гөлчирә өч ел Миңлебай урта мәктәбендә эшли, 1954 елдан хәзергәчә — Кәләй урта мәктәбендә.

Гөлчирәнең тормышында яңа күтәрелеш чоры шушы мәктәпкә бәйле. Бу вакыт эчендә ул Казан дәүләт педагогия институтының рус теле һәм әдәбияты факультетына читтән торып укырга керә һәм аны уңышлы тәмамлый, партия сафларына кабул ителә. 1964 елны аңа мәктәп белән җитәкчелек эшен тапшыралар.

• • •

Гөлчирә Латыйповна белән без беренче мәртәбә Әлмәт районының «Хезмәт байрагы» газетасы редакциясендә очраштык. Газета каршында оештырылган әдәби берләшмәгә ул үзенең «Чишмә» исемле шигырен алып килгән иде. Истә калырлык детальләре булган матур яңгырашлы шигырь иде ул. Шулай да мин шигырь язучылар арасында аны кабат очратмадым.

Гөлчирә үзенең олы юлын педагогия өлкәсендә тапты. Бик дөрес һәм вакытлы тапты. Ул чакта республика мәктәпләрендәге укыту-тәрбия алымнарын яхшырту буенча зур яңалыклар кертелә башлаган иде. Гөлчирә Латыйповна Рәхмәтуллина яңалык өчен көрәшүчеләрнең алгы сафында килүчеләрнең берсе булды.

Ул татар мәктәпләрендә рус теле һәм әдәбияты укытуны яңача оештыру проблемаларын хәл итүдә җаны-тәне белән бирелеп эшләде. Уңышлар да озак көттермәде. Аны Мәскәүгә чакырдылар. Гөлчирә Рәхмәтуллина Татарстан мәктәпләрендә рус телен өйрәтү буенча ирешкән уңышларын башкалабыз трибунасыннан торып пропагандалады. 1965 елны исә Мәскәүдә үткәрелгән үзәк педагогик укулар вакытында ясаган методик доклады өчен ул СССР педагогия фәннәре Академиясенең мактау грамотасы белән бүләкләнде.

Гөлчирә Латыйповна фәнни-практик тикшеренүләр белән дә шөгыльләнә. Рус теле һәм әдәбияты дәресләрендә техник җайланмалар куллану буенча тәҗрибә дәресләре үткәрә. 1981 елның мартында Мәскәүдә узган тәҗрибә алып баручы педагоглар семинарында шул эшләренең нәтиҗәсе буенча чыгыш ясады.

Минем Гөлчирә Латыйповнаның дәресләрендә булганым, класстан тыш эшләренә катнашканым, трибунадан сөйләгән сүзләрен тыңлаганым бар. Өендә кара-каршы сөйләшеп утырып, таңнар каршыладык. Вакытлы матбугатта басылган хезмәтләрен укыйм. Аның турында укучыларының, хезмәттәшләренең, партия-совет җитәкчеләренең, ата-аналарның, авыл халкының фикерен ишетеп торам.

Алар барсы да Гөлчирә Латыйповнага карата соклану хисләре тудырдылар һәм хәзер дистә меңләгән укытучылар сафыннан очерк герое итеп аны сайлап алуыма сәбәпче булдылар.

• • •

Сарман юлы буенда тимер чардуган белән уратылган һәйкәл бар. Бу — революционер укытучы Латыйп ага Рәхмәтуллинның изге каны тамган урын. Рангазарлылар, һәр язны беренче буразнаны шуннан башлап сызалар. Рангазар урта мәктәбе каршындагы бакча эчендә батыр кыяфәтле бер кешенең бюсты тора. Бу — Латыйп ага Рәхмәтуллин бюсты. Укучылар аңа чәчәкләр салалар. Аның каршында пионер сборлары үткәрәләр. Иске Әлмәт авылы зиратындагы тимер чардуганлы кабер өстендә мәрмәр һәйкәл тора. Бу — авылның беренче укытучысы, беренче коммунисты Латыйп ага Рәхмәтуллин кабере. Әлмәтлеләр аны кадерләп саклыйлар.

1981 елның 31 маенда партиянең Сарман райкомы тәкъдиме белән, Латыйп аганың кулаклар тарафыннан ерткычларча үтерелүенә 50 ел тулган көнне билгеләп үттеләр. Сарманга Әлмәт районы делегациясе составында Гөлчирә Латыйповна да барды. Латыйп аганың кабере янында уздырылган митингта ул чыгыш ясый.

— Моннан 50 ел элек әткәм каберенең нәкъ менә шушы урынында басып торган идем мин... Әткәй минем рус телен өйрәнүемне теләгән. Хәзер мин үзем балаларга шул телне өйрәтәм. Партия, Ватаным, халкым минем бу тыйнак кына хезмәтемне бик олылый,— дип сөйли ул үзенең чыгышында.

Гөлчирә Латыйповна өенең стенасында хәрби форма кигән, горур кыяфәтле бер рәсем бар. Латыйп аганың эзләп табылган бердәнбер фоторәсеме ул. Фаҗигалы һәлакәтен искә алу уңае белән, зурайтып ясап, Гөлчирә Латыйповнага бүләк иткәннәр аны.

Әлмәт шәһәреннән 10—12 чакрымнар гына ераклыкта урнашкан Кәләй авылында, шул авылның үз егете Советлар Союзы Герое Токорликов исемендәге урта мәктәп бар.

Ул мәктәптә, инде егерме елдан артык, Латыйп ага Рәхмәтуллинның кызы Гөлчирә балаларга рус теле һәм әдәбияты укыта. Мәктәпнең алыштыргысыз директоры, Мәгариф отличнигы, ТАССРның атказанган укытучысы, коммунист Гөлчирә Латыйповна Рәхмәтуллина, әтисенең якты гомер юлын дәвам итә.

* * *

Алмагачларга күмелеп утырган мәктәп бинасының зур тәрәзәләреннән тирә-якка нур көлтәләре бөркелә. Алар авылның икенче башындагы терлекчелек йортларында кабынган яктылыкларга барып тоташа. Бу балкышта моннан ярты гасыр элек Латыйп ага Рәхмәтуллин эш өстәлен яктырткан җиделе лампа яктысы да бар сыман.

Мәктәптә дәресләрдән тыш та күп төрле чаралар оештырыла. «Икмәкне һәм хезмәтне олыла!», «Безнең конвейер» кебек исемнәрдәге ял кичәләре, пионер сборлары үткәрәләр. Анда укучыларның авыл эшчәннәренә ярдәме, киләчәккә планнары хакында сөйләшәләр.

Мәктәп уңган хуҗабикәнең оста җыештырылган өен хәтерләтә. Кабинетлар бай. Рус теле һәм чит телләрне өйрәнү өчен лингафон кабинетлары бар.

— Киләчәктә без башлангыч класслар өчен дә лингафон кабинетлары булдыруны күздә тотабыз,— ди Гөлчирә Латыйповна.

Укучылар батыр авылдашлары үрнәгендә тәрбияләнәләр. Бөек Ватан сугышы каһарманнарына багышланган күргәзмә дә шул хакта сөйли. Аның янында «Батырлык дәресләре» үткәрелә. Алар Токорликовны производство бригадасы членлыгына кабул иткәннәр. Аның өлешенә тигән керем «Тынычлык фонды»на күчерелә. Шулай да Гөлчирә Латыйповна җитәкләгән укытучылар коллективы хезмәтенең төп нәтиҗәсе — кадрлар.

Инженермы, врачмы ул, төзүчеме,
Нефтьчеме, кырда иген игүчеме —
Кем булса да, акыллы һәм көчле булып,
Килеп баса ил алдына Кеше булып.
Шул чакта син чын күңелдән шатланасың:
«Бу бит минем укучым!» — дип мактанасың, укытучы!

— Укучыларның производство бригадасы бик әйбәт эшли,— диде совхозның партком секретаре.

— Совхозда эшләүчеләрнең җитмеш процентган артыгрcalled — үзебезнең мәктәпне тәмамлаган кешеләр. Әйбәт эшлиләр. Быел да социалистик ярышта Күчмә Кызыл байрак яулап алдык,— диде совхоз директоры.

Бу сүзләр — Кәләй укытучыларының бүгенге көн таләбенә җавап бирүен, азык-төлек программасын үтәүгә дә зур өлеш кертүләрен раслаучы дәлилләр.

Казан утлары
АЭС
әдәби пост

## Илдар Низамов

# НИГЕЗ САЛГАНДА

Партиянең Татарстан өлкә комитеты беренче секретаре Г. И. Усманов XXVII съезд трибунасыннан: «...Татарстан атом электр станциясен төзү өчен аерым җаваплылык тоябыз,— диган иде.— Кызганычка каршы, биредә дә СССР Энергетика һәм электрлаштыру министрлыгын телгә алырга туры килә. Станциянең заказчысы һәм подрядчысы буларак, министрлык төзелешне тизләтүдә тиешле кызыксынучанлык һәм ныклык күрсәтми. Шул сәбәпле күп кенә мәсьәләләр үз вакытында хәл ителми...»

Республикабызның бу җитди төзелешендә эшләр, чыннан да, байтактан бер урында таптана, һәм бу хәл барыбызны да борчый иде. Съезд «1986—1990 елларга һәм 2000 елга кадәрге чорга СССРның экономик һәм социаль үсешенең Төп юнәлешләрен» раслады. Анда Татарстан атом электр станциясенең дә куәтләрен сафка кертү каралды. Беренче блок 1989 елда эшли башларга тиеш дип билгеләнде.

Съезд гомумән дә капиталь төзелештә моңарчы яшәп килгән җитди кимчелекләрне ачып салды, аларны бетерү юлларын да күрсәтте. Иң беренче чиратта, «үткән елларда дисциплина һәм җаваплылыкның гомумән кимүе төзелешләрдә эшнең барышына һичшиксез йогынты ясады»,— дип басым ясап әйтелде. Татарстан өлкә комитетының съезддан соң үткәрелгән беренче пленумында да станция төзелешендәге тоткарлыклар кискен тәнкыйтьләнде, аларны бетерү юллары күрсәтелде, «капитал салуларны планлаштыруны камилләштерү белән бергә, төзелештә бөтен эш конвейерын, төзү подразделениеләрендә хезмәтне оештыруны яхшыртырга, тәртипне һәм дисциплинаны ныгытырга, ...дәүләт планнарын берсүзсез үтәү өчен җаваплылыкны күтәрергә кирәк».

Димәк, башлап таяныр ноктабыз, этәргеч көчебезнең берсе бүген — җ а в а п л ы л ы к. Хәзер җаваплылык иң әһәмиятле ихтыяҗга әйләнде. Җаваплылык хисе исә бары тик үзеңдә үзең булдырсаң гына барлыкка килә ала. Абстракт җаваплылык юк. Синдә, миндә, иптәшләребездә булса гына, ул реаль чынбарлыкны, сизелерлек көчне, иҗтимагый күренешне тәшкил итә.

Җаваплылык хисе, иң беренче, хуҗа була белүгә бәйле. Чын хуҗалар гына үзе өчен, йорты-җире, эше-коллективы, иле өчен җаваплылык тоеп яшиләр, гомуми эшебез өчен борчыла, кайгырта, көрәшә беләләр. Димәк, бүген безгә тәүге чиратта чын хуҗалар кирәк.

Хәер, Кама Аланына килеп төшкән сәгатьләрдә, куанып дулкынланган минутлар да булды. Бирегә килеп чыккан саен шатлыклы үзгәрешкә юлыкмыйча калмыйсың. Я ул биш, тугыз катлы өр-яңа йортлар булыр, я мәктәп, бакча, кибет, ашханә булыр. Биш елда Кама Аланында торак мәйданы гына 60 мең квадрат метрдан күбрәк төзелде. Культура-көнкүреш объектлары да салына тора. Тау итәгенә сыенып, үзенчәлекле бер шәһәр төсмерләнеп килә. Тауның каршы итәгендә — булачак станция ягында — янә бер шәһәрчек: җиңел өйләрдән тулай тораклар, туклану, сәүдә объектлары, ремонт, техника базалары.

Ә шәһәрдән шактый еракта промышленность базасы калкып чыккан: бетон-изма заводы, котельный, йөк причалы, хезмәт күрсәтү объектлары булачак станциягә якын ук урнашкан, болары турыдан-туры шуңа кирәк.

Бу юлы Кама Аланына аяк басуга иң сөендергәне шул булды, ниһаять, төп төзелеш үзе дә башланган. Съездан соң ук, 19 мартта, күк йөзе тәмам зәңгәрләнеп җиткән бер көнне, 1 энергоблокның атом реакторы куелачак урында казу эшләре



*Язучы Илдар Низамов үзенең илле яшьлеген дистәләрчә публицистик язмалар, лирик парча, хикәя, повестьлар авторы буларак, иҗади муллыкта каршылый.*
*Аның әсәрләрендә төп игътибар бүгенге көндә барыбызны да борчый яки дулкынландыра торган актуаль мәсьәләләргә юнәлдерелә. Хезмәт кешесенең асыл сыйфатларын («Кул җылысы»), халыклар дуслыгының кыйммәтен («Илдә мин дә сандугач»), туган тел мәсьәләләрен («Матбугатның тәэсирле сүзе») яктырткан әсәрләрне укучы бик теләп үз итте.*
*В. И. Ленин идеяләренең Идел-Кама буйларында гамәлгә ничек ашырылуы турындагы «Ул кабызган утлар» китабы өчен язучыга Татарстан журналистларының Хәсәен Ямашев исемендәге премиясе бирелде.*
*Илдар Низамовның китаплары арасында «Киерелгән җилкәннәр», «Өмет», «Мәхәббәт хаты» кебек лирик парча, хикәя һәм повесть җыентыклары аерым урын алып тора. Монда язучының туган ил табигатенә, кешеләр язмышына, саф хисләргә булган мөнәсәбәте аеруча калку гәүдәләнә.*
*Язучының хезмәте күп тармаклы. Ул әдәби әсәрләр иҗат итүе, нәшриятта эшләве белән бергә, читтән торып, Казан дәүләт университетының аспирантурасын тәмамлады. Татар әдәби теле мәсьәләләренә кагылышлы фәнни хезмәте өчен аңа филология фәннәре кандидаты дәрәҗәсе бирелде.*

башлана. Биредә «Камгэсэнергострой» берләшмәсенең Умат Камбулатович Наурбиев җитәкләгән атаклы механизаторлар бригадасы төзелешнең иң җаваплы этабына керешә.

Сөенерлек, сокланырлык күренеш иде бу: караш җитмәслек киң мәйданда йөзләгән экскаватор, автоскрепер, бульдозер, үзбушаткычлар, дөньяны дер селкетеп, җир казыйлар, балчык ташыйлар, тигезлиләр. Нигез чокыры күзгә күренеп тирәнәя, киңәя бара. Бер максат, бер теләк белән янган бердәм кешеләр генә, үз эшен, шушы куәтле техниканы биш бармагы кебек белгән осталар гына һәм, иң мөһиме, шушы эш өчен үзен ил алдында җаваплы тойган кешеләр — чын хуҗалар гына шулай эшли ала. Биредә теләсәң-теләмәсәң дә, алар адымына күчәсең, алар сулышы белән сулый башлыйсың. Бүген безнең барыбыздан да заман таләп иткән үсеш, тизләнеш темпы менә шушына охшаштыр инде.

Шушындый темпны станция төзелешендә Наурбиев бригадасы башлап җибәрүе — бер дә очраклы хәл түгел. Әнә бригадир үзе дә котлованның читенә килеп баскан. Көн кояшлы. Умат Камбулатович чокырның арыгы ягына карый да уйланып тора.

Хәзер тасвирланачак күренеш, сез бу юлларны укыганда, дөньяда инде барыбер булмас. Бүген без аны соңгы тапкыр күрәбез. Фотограф чакырырга берәрсенең башына килде микән? Юктыр. Алайса игътибар биребрәк карыйк, хәтергә тирәнрәк уеп калдырыйк. Карыйк һәм уйланыйк.

Котлованның колачын безгә зур-зур саннар белән тасвирладылар. Без исә, күз алдына ачыграк килсен дип, бер чагыштыру гына китерик: мәйданның картасын сызганда, урта кул Беляхча авылы, мөгаен, зур өстәл читендәге бер бит кәгазь чаклы гына күренгәндер.

Күренгәндер дибез, чөнки авыл инде юк. Күчкән. Урынын менә шушы чокыр-котлованның бер почмагы алган. Әмма авылның урынын да, хәзерге мәйдан нигезеннән нинди биеклектә торганын да бүген әле белеп-күреп була. Бер хуҗалык калган. Басу уртасындагы ялгыз агач төбе кебек тырпаеп тора. Авыл юк, бөтен тормыш, хәрәкәт — яңа мәйданда, ә бу хуҗалык берүзе өстә — төп башында.

Юк, ул — чокырның тирәнлеген күрсәтүче ориентир түгел. Якында гына шул максатка калдырылган махсус «төп»тә бар. Казырга кыен булганга янсә башка берәр техник сәбәп аркасында тиелмәгән участок та түгел. Бер хуҗалык, киреләнеп, күчмәгән, шунда яшәп ята.

«Төп башына» якынрак килик. Яшисен яшәгән, бераз кыйшайган, түбәсе йөз ямаулы өй. Тәбәнәк кенә җилкапка. Күптән инде яңа кадак, балта-чүкеч күрмәгән каралты-кура. Ишегалдында мал-туар, кош-корт. Арт якта, җәй якынлашып килүгә карамастан, башланмаган диярлек печән кибәне.

Хуҗа колхоз фермасында терлекче икән. Берүзе калып, механизаторлар эшенә, гомуми төзелеш темпына нык аяк чалганга җитәкчеләрнең, бригадирның, гомумән, барлык төзүчеләрнең түземлекләре тәмам төкәнеп, ачулары тәмам кабарса да, алар әле сабырлыкларын

жуймаганнар, аңа хәтта өенә менеп йөрергә сукмак-баскыч та әмәлләп биргәннәр. Шуннан менеп бара. Ир уртасы таза ир. Чырайда үҗәтлекме, мин-минлекме, әллә гамьсезлекме — тәгаен генә аңларлык түгел, чөнки карашы авыр, мәнесез. Аның каравы, ферма печәнен тутырган капчыкны кысып тоткан...

Сизеп торам: «Туктале син, тел төбеңнән ук ярылып ята: белер-белмәс кешене гаепләргә торасың»,— дияргә җыенучы бар сыман.

Юк инде, туктатмагыз! Хуҗасы, чиртсәң, кан чәчрәп чыгарлык таза ир булып та, өйнең тәрәзәләрендә якты кашагалар урынына муртайган такталар гына икән, өй каршында, койма буйларында агач-куак урынына кычыткан, алабута котырып утыра икән, башкаларның терлек тагарагы такырайган көннәрдә дә, аның башланмаган диярлек печән кибәне бүксәсен киереп утыра икән, һәм шул бәндә үзенә башкалардан өстенрәк хокуклар даулый икән, барыннан да бигрәк, менә хәзер — төзүчеләр бер омтылыш, бер сулыш белән алга ыргылганда, бөтен ил, кискен үзгәреш дип, күмәк янганда, ул аркылы килеп маташа икән, мине, аның күзләренә карап, Ят кеше син, дип әйтүдән тыймагыз, зинһар!

Кызганычка каршы, без хәл-вакыйгаларны, кешеләрнең холык-фигыльләрен, эшхәрәкәтләрен гадел бәяләргә, акны — ак, караны кара дип кистереп әйтергә тартынабыз, хакыйкатьне кемдер бүтән әйтер дип көтәбез. Без әлегә моны үзебезнең гражданлык бурычыбыз дип санарга күнекмәгәнбез.

Хәзер бу аеруча кирәк. Партиябез һәм социаль-экономик өлкәдә, һәм тәрбияидеология өлкәсендә алга баруда кискен борылыш курсы билгеләгән икән, шул юлдан җәһәт адымнар белән атлау өчен һәркайсыбызга җаваплы бурыч йөкләнү белән бергә, тулы хокук та бирелеп, моңарчы булмаган мөмкинлекләр дә ачылган икән, моннан бик тә файдаланырга кирәк иде.

Моның өчен үзеңне хуҗа итеп тою хисе — үз өеңдә, үз коллективыңда, республикаң, бөтен илеңдә чын хуҗа булу хисе яшәргә тиеш. Хуҗачыллык хисе дә тумыштан килми, ул бары үзеңдә тәрбияләнә генә ала. «Үз заводыңда яисә колхозыңда, цехыңда яки фермаңда чын хуҗа булмый торып, ил хуҗасы була алмыйсың»,— диде М. С. Горбачев XXVII съездда сөйләгән Политик докладында.

Үзен хуҗа итеп тойган кеше исә начарлыкка нәфрәт белән караудын тайчынмас. Ул халыкның, бурычын яшергән — бөлгән, чирен яшергән — үлгән дигән акыллы сүзен яхшы аңлый.

Вакытында шундый таләпчән, гадел карашка юлыккан булса, менә бу Ят кеше дә бүген авылдашлары белән бергә яшәр иде, ә япа-ялгызы «төп башында» утырмас иде, алга баручылар көпчәгенә таяк тыгып азапланмас иде.

Кызык хәл: аны телгә алганда да «хуҗа» сүзе ишетелгәләде. Сүзнең элекке мәгънәсе дә яши бирә. Әмма безнең чынбарлыкта «хуҗа» сүзенең бөтенләй башка мәгънәсе туды. Ч ы н х у җ а дип без бөтенләй бүтән кешене күз алдына китерәбез. Безнең уртак милкебез — туган җиребез, туган авыл, шәһәребез, андагы уртак социалистик милкебез, Туган илебез бар. Шушы милеккә карата мөнәсәбәтебез, фикеребез бар. Шул иман-фикернең нинди булуына карап, без кешенең нинди Хуҗа икәнен бәялибез.

Моннан өч ел элек әле авыл җыенында күчену турында киңәш-табыш иткәндә, аларга төрле-төрле тәкъдимнәр әйттеләр: ерак та түгел коттедж тибындагы йортлардан өр-яңа поселок төзелә, шунда төпләнергә мөмкин; телисең икән, йорт-җиреңне күрше авылга күчерәбез; мәшәкатьләнәсең килмәсә, Кама Аланындагы шәһәрчә йортка кер, диделәр.

Билгеле, туып-үскән нигездән кубу берәүгә дә җиңел түгел. Әмма гомуми эшебезгә кирәгрәк икән, ил, халык сорый икән, һәм бу киләчәк тормыш өчен беркемгә дә, хәтта Ят кешенең үзенә дә зыянга түгел, бары яхшыга гына икән, ник моңа каршы килергә?! Җыенда да шулай хәл ителгән иде, һәм көне-сәгате җиткәч, һәркем үзе теләгәнчә күченә-урнаша башлады.

Ят кешенең бизмәне бер генә тәлинкәле иде. «Илгә кирәк», дигән тәлинкәсе юк, «Миңа кирәк!» дигән тәлинкәсе генә бар. Менә шушы «Миңа кирәк!»не дә ул әле кабат-кабат үлчи — ничек күбрәк файда каерып калырга?!

Шушы ук айларда Брежнев шәһәрендә тагын бер кеше уйга калып утырды. «Камгэсэнергострой» җитәкчеләре, бригадирларны җыеп, берләшмә коллективына яңа бер

җаваплы эш — Татарстан атом электр станциясе салуны тапшыруларын әйттеләр.

Карашлары әледән-әле чал чәчле, шулай да егетләрнекедәй тәз, мәһабәт гәүдәле бригадир Умат Наурбиевка төшә. Теләсә кайсы корылма нигездән башлана, ә нигез ул, иң башта, җир эше. Наурбиевның бригадасы — җир казу техникасын иярләп, бу эшнең бөтен нечкәлекләрен белгән осталар. Соңгы елларда республиканың барлык күренекле корылмаларына башлап алар аяк басты: КамАЗ, Зәй көпчәк заводы, Бигеш аэропорты. Дан-шәһәрте еракларга таралган коллектив.

Әмма бригадир уйлана. Төзелешне башлап җибәрү — кыен эш. Теләсә кем тотына алмый. Теләсә кемгә бирмиләр дә. Тик бит ул үзе дә, күп кенә башка механизаторлар да инде яшь түгел, алтынчы дистәгә якынаючылар шактый — дан-шәһәрт ымсындырмый, орден-медальләр, мактаулы исемнәр җитәрлек. Квартир да әйбәт, эшкә дә җылы автобуста сәгате-минуты белән кайтып-китеп йөрисең, техниканы да җылы гаражда гына карыйсың. Яңа төзелешкә барып төшсәң...

Башта техниканы япа-яланда карарга, ремонт-фәләнгә исә йөз чакрымдагы Брежневка кайтарырга туры киләчәк. Кешеләр дә башта кайтып-китеп йөрер. Аннары тулай торак. Күнегелгән, уңай квартираң сагындырыр.

Ул уйлый. Хәлбуки үзе белә: озак икеләнергә вакыт юк, көтәләр. Ул башын чайкаса, җитәкчеләр башка бригадирларның кылын тартыр. Шулай да ул кабаланмый. Җиде кат үлчәп, бер кат кына кисә. Наурбиев гомер буе нигез салды, шуңа күрә белә: нигез дөрес, нык булса гына, корылмалар тәз, ышанычлы торыр. Җиде үлчәү бәлки аңа җиңел түгелдер. Ул — кеньякта туып-үскән кайнар канлы кеше. Әмма ул үзендә уйлану сәләте булдырган. Азактан үкенмәс өчен, терсәкне тешләп азапланмас өчен.

Коммунист буларак, тынгысыз җан буларак, ул уртак эш өчен җаваплылык тоеп, кайда яңа башлангыч, кайда гомуми омтылыш, шунда юнәлергә күнеккән, бүтәнчә яши алмый: Кыенлыкка түзеп, аның белән көрәшеп яшәргә өйрәнгән. Монда да кыен булыр, монда да ул үзе түзәр. Хатын, балалар да аңлар — алар аны яхшы беләләр.

Ә бригада аңа иярерме? Монда эшкә кереп, уңай шартларда гына яшәгән яшьләр дә шактый. Һәм бригадир үз коллективындагы җитмешләп кешене берәм-берәм барлап утыра — ул бит барысы исеменнән дә җитәкчелеккә вәгъдә бирергә тиеш. Димәк, җиде тапкыр гына түгел, җитмеш тапкыр үлчәү сорала. Күңеле инде әллә кайчан хәл иткән: сиңа бит өмет белән карыйлар, «синең килешүең уртак эш өчен, ил, халык мәнфәгате өчен кирәк», дип ышаныч белдерәләр, мондый чакта синең беркайчан да кире какканың булмады...

Ниһаять, бригадир, башын күтәреп, өметле, ышанычлы караш белән җавап бирә.

Шулай итеп, атаклы бригада бу юлы да мөһим төзелешкә беренчеләрдән кузгалды. Бульдозер, скреперлар, йөзләрчә үзбушаткыч, экскаваторлар шәһәр буласы, промбаза буласы нигезләрне казу, ныгыту, тигезләү эшенә керештеләр. Тирән-тирән ермаклар күмелеп, тигезләнде, юллар күтәрелде.

Их, барлык бригада, участокларда, идарә, трестларда да шушы бригададагы кебек тәртип, темплар булсын иде дә бит! Кызганычка каршы, бу төзелештә дә аңлашылмаучылыклар, тәртипсезлек шактый очрый. Бригадир көткән-уйлаган, коллективның беренче җыелышында ук төшендереп-кисәтеп куйган җитешсезлекләр берсе артыннан икенчесе өскә килеп төшә торды: юлга, техниканы карауга, ашау-эчү, ялны оештыруларга кеч, вакыт артык күп китте.

Башка участок, бригадаларда бу хәлләрне авыр кичереп, ризасызлыклар белдереп, хәлне тагын да катлауландырдылар.

Наурбиев бригадасында исә кыенлыклар каршында аптырап калып, вакытны, көчнервларны әрәм итмәскә күнеккәннәр. Килешү төзеп, эшкә алынгансың икән, кыенлыкның якасына ябыш, бөтенең бер булып җигел, уйла, эзлә, иҗат ит, кыен хәлдән ничек тә чык — закон шундый. Бу да хуҗаларга бик кирәкле сыйфат.

Әйтик, техниканы йөз чакрымдагы базага кайтарып ремонтлау янса шыр яланда карап, кешеләрне интектерү чын хуҗаларчамы, ә?! Әлбәттә, АЭСның үзен салырга керешер өчен башта промбаза, торак-көнкүреш объектлары корыла. Станция салырга алары да җитешер. Промбазаның үзен коручыларга ничек? Бу эш бит бер айда, ярты елда гына бетми, аңа да еллар кирәк. Механизаторлар исә бүген үк нормаль яшәп, нормаль эшләргә тиеш. Шунлыктан, Умат Наурбиев килә-килешкә бригадага база әзерләү хәстәрен күрә башлады. Тик бу нәрсә бер генә план-сметада да каралмаган,

димәк, аңа бер кеше дә урын, акча, материаллар бирми. Үзең тотынасың икән, син — тәртип бозучы.

Объектта җиңел йортлардан тулай торак әзер булгач, бригада көн саен кайтып йөрүдән туктады, вахталап эшләүгә күчте. Бер атна эшлиләр дә икенчесендә, кайтып, ял итәләр. Шунда бригадир белән кайбер өлкән эшчеләрне ял иткән көннәрдә элекке базада еш күрә башладылар. Исәптән чыккан автомашина бортларыннан-фәләннәрдән җыеп, турайтып, тигезләп, калай әзерлиләр, шуларны ямыйлар, ялгыйлар. Панельләр барлыкка килә. Иске объектлардан тимер-бетон, торба ташландыкларын да шулар янына кайтарып өяләр. Яр буенда яртылаш комга күмелеп яткан вагончыкны искә төшерәләр, аны да алып кайталар.

Өлкәннәрнең ни-нәрсә белән маташуларын аңлап алып, яшьләр дә аларга ярдәмгә килә. Хәтта Кама Аланында да алар эштән бушаган берничә генә сәгатьтә дә «тимер-томыр җыю» белән мавыгудан туктамыйлар.

Бригадир урын булдырырга йөри. «Бер ашъяулык» җир кирәк, шуңа рөхсәт алып булмый. Җитәкчеләр тыңларга да теләми: вакытлы корылмаларга проект та, акча да, урын да бүленми. «База бары файдага гына. Без аны ял сәгатьләрендә үзебез эшлибез. Җыелма була — хаҗәте беткәч, сүтеләчәк»,— дип тә карый бригадир. Юк!

Теләсәң — ела, теләсәң — көл, башка сыймаслык парадокс монда да кабатлана. Наурбиев төзелешнең башлангыч стадиясендә техникага хезмәт күрсәтүне кыр шартларында оештыру алымын Украинаның атаклы төзүчесе Социалистик Хезмәт Герое В. Цветков бригадасыннан өйрәнеп кайтып, беренче тапкыр КамАЗ төзелешендә үк гамәлгә ашырган иде. Бер машинаны базага алып кайтып, гади генә төзәткәләп чыгару өчен ким дигәндә ике-өч көн кирәк. Мондый ремонт айга ике ясала. Йөзләп машина, механизм булганда, күпме вакыт исраф ителүен санау бер дә кыен түгел. Ә моны эшләгән җирдә оештырсаң, чыгымнар берме-бер кими. КамАЗ төзелешендә бригада, үзенә вакытлы база корып, махсус ремонт звеносы оештырып, бик зур отышка иреште. Аның тәҗрибәсе үрнәк дип табылды, ил күләмендә үткәрелгән семинарлар шул базада булды. Башта анда да, аннан соңгы төзелешләрдә дә аяк терәп каршы торганнар иде. Инде сыналган, файдасы һәркемгә ачык хакыйкатьне янә тәкрарларга тотын инде! Парадокс булмыйча ни булсын!

Мәсьәләнең әхлакый ягы да бар бит — кеше, иң башта, эшләгән урынында нык таяныч тоеп яшәргә тиеш, Кама Аланында эшләп, Брежневтагы ярдәмгә генә таянып торып буламыни!?

Волокита, бюрократизм иҗади эш каршына шундый биек койма булып килеп басалар ки, югалып калуың да ихтимал. Чын хуҗа исә шундый чакта үзенең асыл холкын күрсәтә дә инде: ул тәвәккәл, батыр, кыю һәм усал була ала.

Наурбиев бу очракта Казаннан бер зур җитәкче килүдән файдалана. Төзелеш җитәкчеләре белән объектларда йөргәндә ермак читендә туктап калганнар иде, гозерен сөйләде дә бирде. Мондый әңгәмә булып алды.

— Бу урында проект буенча нәрсә каралган? — диде җитәкче.

— Бернәрсә дә каралмаган. Яшел зона. Ермак чите ныгытылырга, яшелләндерелергә тиеш.

— Димәк, вакытлы база беркемгә дә комачауламас?

— Ә проект, инструкция? Кем җавап бирә? — дип каршы төшәләр.

Җитәкче Наурбиевкә борыла:

— Нигә нәкъ шушы урынны сайладыгыз? Сезнең бит төп эшегез станция төзелешендә булачак?

— Беренчедән, котлованга керешкәнче, берничә ел шушы объектларда эшләячәкбез. Икенчедән, станциянең икенче, өченче чиратларын да күз алдында тотарга кирәк. Без киткәч, бу мәйдан яшьләргә ял, спорт өчен урын ясарлык булып калачак, тирәсенә бакча утыртырбыз...— дип аңлата Умат Камбулатович.

— Бирегез участокны! — диде җитәкче, ике сөйләшмәслек итеп,— ул бит барыбызга караганда да киләчәкне күбрәк уйлаган, мондый кешегә дә ышанмасак...

Озын сүзнең кыскасы шул, бүген менә алдыбызда Наурбиев бригадасының яңа базасы — «йорты-хуҗалыгы» тора. Таш түшәлгән тигез мәйдан. Ермак читендә эре-эре калай блоклардан биек, иркен мастерской бинасы. Асфальт идән, кирәкле механизмнар, хәтта катлаулы станокларга кадәр бар. Җылы, якты мастерской буш. Бригаданың барлык техникасы эштә, димәк. Мондый база булгач, машина тик торамы соң!? Янәшәдә берничә вагончык бар: кызыл почмак, ял бүлмәсе, чәйханә. Бер вагончык кием-салым киптерү өчен җайланган.

Мәйдан алма, чия һәм башка төрле агач-куаклар белән әйләндереп алынган.

— Авыллар куәтенгәндә калган агачларның төбен дә әрәм итмичә алып кайтып утыртып бетердек,— ди Умат Камбулатович.

Монда килер алдыннан гына берничә авылда, Казан тирәсендәге бакча-дачаларда булып, аларда сыерчык ояларының юклыгына җан әрнеп йөргән иде, монда миңа әрнүләргә дәва булды — бакчадагы сыерчык ояларында кагына-очына сыерчыклар сайрый.

Мастерской артында иске агач деталь-механизмнар күреп, Умат абыйга карагач, ул елмаеп җибәрде:

— Җил тегермәне ул! Сүтеп атканнар иде. Җыеп алып кайттык менә. Бу вакыт табып корып та куябыз әле без аны. Мәктәп балаларын, яшьләрне экскурсиягә чакырырбыз. Кеше ул, үткәнен аңласа гына, бүгенгесенең кадерен белә.

Киләчәкне уйлап эш итү, алга карап яшәү, максат куеп, шуңа әзлекле омтылу чын хуҗаның канында-җанында булырга тиеш. Бүгенге белән генә яшәү безнең әхлакка туры килми. Ләкин бу сыйфат әле күбебезгә җитенкерәми. Шуның аркасында өйдә дә, эштә дә безне вакыт-вакыт һич көтелмәгән мәшәкать, күңелсезлекләр, чыгымнар сагалап тора. Мондый хәлләр аеруча төзелешләргә хас. Аларда планлаштыру, проектлаштырудагы җитди кимчелекләр XXVII съездда да бик урынлы тәнкыйтьләнде. ТатАЭС төзелешендә дә планы расланып та аңа әле проект документлары, акча, материаллар хәстәрләнмәгән булу һәм, киресенчә, документлар әзерләнеп тә объектның планга кертелмәү янсә икенче бер объектка бәйләмичә калдыру очраклары бар.

Юлларны гына алыйк. Станция урыны тәгаен билгеләнгәч тә булачак шәһәр белән ике арада капиталь юл салырга мөмкин түгел идемени?! Дүрт ел узды, вакытлыча дүрт юл салынды, хәзер берәү дә юк, барысы да эштән чыккан. Күпме акча түгелгән, кылдыйбылдый юлларда күпме техника ватыла, күпме кеше азаплана. Артык бензин ягуны, кеше вакытын, ниһаять, нерв тузуларны да санасаң... Юньле хуҗа барысын да исәпләр иде, гаеплеләрдән түләтер иде. Бүтәнчә кабатланмас өчен сабак булыр иде.

Электр линияләре белән дә шул ук хәл. Котлован вакыт-вакыт җансыз кала. Күпме техника, кеше тик тора. Вакытлыча сузылган линияләрнең я баганалары ава, я чыбыклары өзелә, я трансформаторлары яна. Күрмиләр түгел, күрәләр, шуларга әрнемәгән, «алай ярамый» дип өстәл төймәгән җыелыш бик сирәк. Телгә алына, ә кабатламау өчен катгый чаралар күрелми. Конкрет гаеплеләрне тапканда, чыгымнарны үз кесәләреннән түләттергәндә нәтиҗәсе тизрәк сизелер иде, сүздән эшкә күчү шушы булыр иде. Без барында котлованда ике йөзләп кеше эшли иде. Ашханә юк. Механизаторлар төшке ашка, автобусларга төялеп, биш-алты километрдагы ашханәләргә йөрергә мәҗбүр. Күпме вакыт, бензин әрәм китә.

Үзем язам, үзем уйлыйм: бу язмалар басылып чыккач: «Әйе, андый кимчелекләр бар иде, әмма без аларны бетердек, нигә искә төшерергә, үткән эшкә салават»,— диючеләр табылыр.

Юк, андыйлар белән дә килешмәскә, ризалашмаска рөхсәт итегез зинһар! Кимчелекне бетерәннәр — бик яхшы. Әмма безнең юл кимчелекләрне бетерә-бетерә, шулар өстеннән бару юлы түгел, бәлки алардан башка бару юлы. Хуҗа кеше үз җитешсезлегеннән дә, күршенекеннән дә сабак алыр, әлбәттә, бүтәнчә кабатламау өчен тырышыр. Бүген без дә төзелешебезнең барлык этапларын, азагына чаклы, бөтен вагы-төягенә чаклы күз алдына китереп бетергәнбезме соң, һәр стадия, һәр операция өчен җаваплы кешеләр һәм барысын да бер кулда туплаган бер хуҗа бармы? Һәр башкарасы эшебез алдан, төпле уйланып, фәнни нигезләнеп планлаштырылганда гына аның вакытында, яхшы сыйфатлы итеп үтәлүенә шик булмас. Әгәр хуҗаның планы ышанычлы икән, атлаган саен үзгәрә торган түгел икән, ул башкаларга да катгый таләпләр куя ала. ТатАЭС төзелешендә йөзләгән субподряд оешмалары катнашуын искә алганда бу таләпнең үтәлүе аеруча әһәмиятле шартка әверелә.

Алга карап, төпле план белән эшләүдә подряд ысулы ныклы таяныч була ала. Моңарчы бу алым ТатАЭС төзелешендә бик сүлпән, шикләнеп, як-якка каранып кына керә барды. Хәзер илдә бер генә төзелешне дә бу прогрессив алымнан башка күз алдына китерү мөмкин түгел. Биредә дә омтылучылар бар. Корбангалиев, Уразаев бригадалары һәм башка кайбер коллективлар үз инициативалары белән яңача эшли башладылар. Азмы-күпме тәҗрибә дә туплана. Ләкин, әлеге дә баягы, төзелештә хуҗаның бер генә булмавы, план, проектларның тәмам ачыкланмаган, бер-берсенә бәйләнмәгән хәлдә торуы бу прогрессив алымга да аяк чала.

Наурбиев бригадасының тәҗрибәсе киң колач белән таратылмавы да шуны күрсәтә. Хәлбуки бригада, республика төзелешләрендә беренче булып, өзлексез подряд ысулын кертте һәм аны бу объектта да туктаусыз камилләштерә бара. Яңача эшләүнең мәгънәсе шунда: килешү төзеп, бригада үз объектында чын хуҗага әверелә, анда эшнең барышы өчен, аннан да бигрәк, азагына кадәр уңышлы очлануы өчен тулысы белән үзе җавап бирә.

Биредә тәртип шундый: бригада планын тикшерүдә һәр механизатор катнаша, чөнки

эш хакы эшнең нәтиҗәсенә бәйле. Кем генә булсаң да — төп механизатормы син, ремонтчымы, скреперчымы әллә шофермы, прорабмы — барыбер эшнең азаккы нәтиҗәсенә карап алачаксың. Шуңа күрә планны кабул итеп, килешүгә кул куйганчы, коллектив аны җиде кат үлчи, нигезле, реаль булмаса, бәхәсләшә, ресурс, материаллар белән тәэмин ителүенә шик калса, кире кага. Шулай итеп ул башкаларны да планга аек карарга мәҗбүр итә.

Инде килешүгә кул куелган икән, вәгъдә биргәнсең икән, аны үтәми кала алмыйсың. Чын хуҗаның сүзе эштән аерылмас. Наурбиев бригадасында бу — беренче закон. Ул үтәлсен өчен бригаданың һәр члены — барысы бер кешедәй — бөтен көчен, сәләтен бирергә омтыла.

Бу төзелештә дә инде коллектив членнары һәм хезмәтне оештыруга, һәм дисциплинаны ныгытуга, һәм эш шартларын, ялны тагын да яхшыртуга юнәлгән күп санлы тәкъдимнәр керттеләр. Эзләнү, иҗат итү туктамый.

Умат Камбулатовичның бер фикерен аерып күрсәтәсе килә. «Өзлексез подряд ысулының нигезен алдан уйланган, фәнни төгәл инженерлык әзерлеге, югары дисциплина, оста җитәкчелек, өзлексез материаль тәэминат тәшкил итә. Менә шушы шартлар үтәлә торган булса, аны безнеке кебек җир эшләре бригадасында гына түгел, башка коллективларда да кулланырга кирәк»,— ди ул.

Игътибар итик, кабатлыйк: өзлексез подряд ысулын, димәк, тулы хуҗалык исәбен төзелештә һәр подразделениедә кертеп була! Ягъни бригадада да, участокта да, идарәдә дә, ниһаять, бөтен төзелеш масштабында да. Бүген бит төзелешкә нәкъ шул үзе кирәк тә! Шунсыз биредә кискен борылыш ясап булмас, шунсыз съезд куйган срокларга сыешып булмас.

Умат Наурбиев бригадасы егетләре бүген шул яңалыкның башында баралар. Үзләре икеләтә энергия белән эшләп, тынгысызлык, иҗади инициатива белән яңалыкны камилләштереп кенә калмыйча, башкаларга да ярдәм кулы сузарга, үзләренең һәр яңа казанышларын бүтәннәрнең дә казанышы итү өчен омтылалар. Бу да чын хуҗаларга хас сыйфат.

Умат Камбулатовичка мин, Өмет абый, дип эндәшәм. Ул риза. Исеме безнеңчә шулай яңгырый. Холкы-фигыленә дә, яшәү рәвешенә дә туры килә: ул гел алга карап, өмет белән, яшьләрчә зур максатлар белән яши; аңа да, ышанып, өмет белән карыйлар, ул исә өметле җавап кайтара.

Менә ул котлован ярына килеп басты. Аргы ярга карап тора башлады. Берничә бульдозер һәм башка машиналар «төп башына» якынаялар иде. Ят кеше кичә, ниһаять, йортын күчерергә ризалык биргән. «Әллә кайчан кирәк иде дә бит! Кеше үзен генә уйларга күнексә, аңа барыбер «төп башында» утырып калу яный»,— дип куйды Өмет абый. Шулай да бу минутта аның карашы якты, йөзендә елмаю иде. Хәзер аның механизаторлары эшкә керешәчәк, булачак нигез урыны тагын да киңәеп китәчәк.

Мәһабәт корылма калкачак нигез чокырының ике ярында ике хуҗалык. Берсе үзе өчен генә яшәгән, кешеләрдән тәмам аерылып «төп башында» калган кешенең хуҗалыгы. Икенчесе күмәк эш өчен борчылып, тиеннәрне янга калдырып, изге ният белән, киләчәккә карап салынган хуҗалык. Тегесе менә-менә бетәргә тора. Монысының тирәягында бакча чәчәк ата, күгендә сыерчык, тургайлар сайрый.

Ике хуҗа, ике нигез. Берсе бетә, берсе кала. Мәңге яшәргә кала.

# Алсу Гайфуллина

⁂

Уйларны ирекка чыгарам
Кайвакыт —
Елга бер,
айга бер.
Читлектəн котылган хыяллар
Биектə очканда күренер:
Һавада салават күпере
Бөгелə-бөгелə сүз төзи.
Кояшның нурына уралып,
Мин очам — хыялда берүзем.
Сүзлəрдəн очкыннар чəчелə —
Берешəр,
икешəр,
өчешəр!..
Очкыннар шикелле уйларым:
«Мин сезне яратам,
Кешелəр!»

## Көнлəшү

Йолдыз-йолдыз сипкеллəрен
Балкытып елмайды төн.
Безнең бүген хыял тулы,
Бəхетебез — бербөтен.
Йолдызларны карарга дип
Текəлгəн идек күккə,
Ай елмаеп бер күз кысты —
Күзəткəн икəн күптəн!
Ə мин читкə карадым да,
Көнлəдем сине айдан.
Кем белə бит — күктəге ай
Кызмы, яки малаймы?

⁂

Көзге төнгə үпкəлəмик:
Аерырга телəмəде.
Яфрак-яфрак хыял очты —
Йөрəклəрне телгəлəде.

Болай да ким бəхетебез
Берничəгə бүлгəлəнде.
Көз бер жырга чорнап барды
Үз төнендə йөргəннəрне.

Йолдыз сипте бер кагынып
Сары канат — бөтен күккə,
Һəм син миңа якын булдың,
Əйтерсең лə сөям күптəн.

Үпкəлəмик көзге төнгə,
Аерырга телəмəде.
Күңелдəге уйларымнан
Ала күрмə күлəгəңне...

Йөгерә,
йөгерә,
йөгерә,
Гасырны
узарга
тырышып,
Вакытка
үтәргә булышып.
Бик тирән ала ул сулышын,
Әйтерсең,
бөтен Җир шарының
Һавасын сыйдырып бетерә!
Йөгерә,
йөгерә,
йөгерә
Кыз бала,—
Финишта
җыр көтә.

## Шомлы көннәр

*Бөек Җиңүнең 40 еллыгына*

Кешелек бәхетле чак иде,
Тик тиздән бары да үзгәрде:
Кешеләр атарга өйрәнде —
Бәхеткә аттылар үзләре.

Күгәрчен — тынычлык билгесе —
Кунмады корыган гөләпкә.
Дәһшәтле көннәрнең ритмына
«Ты-ныч-лык!» — дип типте йөрәкләр.

«Сугыш» дип аталган бу афәт
Анадан улларын урлады.
Егетләр — Ватанның куллары,
Ил данын күтәрде югары.

Кап-кара күмергә әйләнгән
Үләннәр яшәрде яңадан.
Бүгенге көннәрнең сулышы
Шул кара көннәргә ялганган.

Ә Ана сагаеп күзәтә:
Болытлар таралмый — карала,
Ананың йөрәге бик сизгер:
Яңадан яралар яңара.

Күгәрчен — тынычлык билгесе,
Кешеләр белән бер теләктә.
Дәһшәтле көннәрнең ритмына
«Ты-ныч-лык!» дип тибә йөрәкләр.

## Күктәтәй

— Исәнме,— диярмен елмаеп,
Җавабың өзгәләр күңелне:
— Кайчандыр үзең үк мәңгегә
Хушлашыйк, дип әйттең түгелме?

Йөгереп китәрсең янымнан,
Хәтерең әрнүгә түзалмый.
Артыңнан кычкырып калырмын:
— Күралмыйм мин сине, күралмыйм!

Үткәнгә, хатама үч итеп,
Еламам — янармын утымда.

Барыбер гөлләрем үсәрләр,
Яп-якты ут янар йортымда.

Берәү дә аңламас:
Ни өчен
Бакчамда үстерәм күктәтәй.
Ул — минем хыянәт,
Ул — безнең юксыну,
Ул — синең күзләрең —
Күктәтәй.

## Тынычлык дәресе

Мин төшемдә серле дәрес күрдем:
Бер класста дөнья кадәр халык.
Укытучы сорау биреп торды —
Һәрберсенә җавап биреп бардык.

Кемдер белми торса, ярдәм иттек,—
Пышылдадык, мәктәптәге кебек.
Арабызда шулчак кап-карадан
Киенгән бер сәер кеше күрдек.

Ул утырды озак кына посып,
«Дуслык» дигән сүздән калтыранып.
Тынычлыкка багышланган дәрес
Кызыксындырмады бугай аны.

Укытучы аңа сорау бирде:
«Нәрсә җитми, нигә шомлы тормыш?»
Мин: «Ты-ныч-лык!» — диеп пышылдадым,
Ә ул әйтте: «Сугыш,
сугыш,
сугыш!»

# ЯҢА ИСЕМ — ЯҢА СҮЗ

### АЛСУ ГАЙФУЛЛИНА ШИГЫРЬЛӘРЕ ТУРЫНДА

Шагыйрьләр мәйданга төрлечә чыга. Бер төрлесе, әйтерсең, күккә фейерверк төсле атыла да, бөтен тирәне сокландырып, бөтенләйгә онытылыр өчен, яки исә күңелләрдә мәңгелеккә балкып калыр өчен, тиз арада юкка чыга. Икенчесе йокымсырап утырган залда мылтык атылгандай яңгырап сискәндерә. Өченче төрлесе төзелеш мәйданындагы корыч арматуралар, каркаслар, яңа йорт, яңа урамнар төсле бетон һәм комны, балчыкны аралап калка. Кемнеңдер авазы көзге һәм кышкы җил сыман җан сызлатып, яисә җәйге урман, кыр сулышы, чишмә агышы, үлән үсеше сыман ишетелер-ишетелмәс башланып, тиз арада күмелеп, тынып кала, яки әкертен-әкертен үзенең моңлы серенә күңелләрне буйсындыра.

Бүтәнчә булулар да ихтимал.

Менә яңа сүз, яңа исем — Алсу Гайфуллина.

Аны шигъри мәйданнарда очратканым булды. Чәчрәп килеп чыкмады, шауламады. Авыл кызларына хас булганча, тыйнак, басынкы гына килеп чыкты. Шулай да без аны күрдек, ишеттек. Журналда басылган әсәрләре беренче тәэсирне куәтләделәр.

Алсу беркемгә дә әйтелми торган серләрен толымнарына кушып үрә белә. Толымнар сү-

телеп, серләр чишелгәч, үкенә, ояла, кичерә белә. Бу инде — кешедә лирик тоемлау бар дигән сүз.

Әлбәттә, лирика — барлык проблемаларны берьюлы хәл итә торган кодрәт түгел. Аның альбом тынлыгына сыеп бетүе, ишетелми калуы, чын кичерешләрнең сентиментальлек белән алмашынуы, ялган булып чыгуы ихтимал. Шәхсилекне саклаган халдә, зуррак мәнфәгатьләр белән яшәгәндә генә, шагыйрь дөнья киңлегенә чыга ала. Шигырьнең халык алдында, дөнья каршында мәңгелек бурычлары бар. Шагыйрь, үзе теләп, тормышны, кешене, аның җанын камилләштерә, үзгәртә, төзекләндерә бару эшен үз өстенә ала. Югары поэзия — мәңгелек матурлыкның сизелерлек күренешләргә әйләнә барган хәле, җан хезмәте, тойгылар хәрәкәте. Хезмәт итмәгән күңел юкка чыга.

Шундый таләпләрне искә төшереп, шигырьләргә әйләнеп кайтабыз:

Иң йомшак күңелгә
Кададлар кагылган.
Иң изге кешегә
Гайбәтләр тагылган...

Бу хисләр миңа да бик яхшы таныш. Димәк, Алсу, үз дөньясыннан чыгып, башкалар турында кайгырта башлады, кешелек сыйфатлары, яхшылык һәм яманлык турында, гаделлек һәм гаделсезлек турында уйлана башлады диярг мөмкин. Бүтәннәрнеке белән чагыштырганда сизгеррәк, кискенрәк булган гаделлек тойгысы шагыйрь итә кешене. Шагыйрь — халыкның вөҗданы. Кайчакта, әлбәттә, киресенчә дә булгалый: халыкның вөҗдансызлыгы дип аталырга тиешле кешеләр дә шагыйрь яки язучы исемен йөрткали. Курыкмыйча турысын әйтсәк, болар — ялган геройлар. Яшьләргә мин тормышның, шул җөмләдән әдәби хәрәкәтнең дә идиллия түгеллеген искәртергә, изгелек чапаны кигән яманлыкны таный белергә, аларга каршы көрәшергә өйрәнегез дип киңәш итәргә телəр идем. Үз дәверенең вөҗданына кагылырлык сүз әйтә алса, шагыйрьгә башка бурыч йөкләмәскә дә мөмкин дип исәплим. Әлбәттә, беренче шарт — сәнгать ысулы. Шул онытылмасын. Кешенең күңел эше тасвирлансын, рухи портреты барлыкка килсен — тәне дә булсын, җаны да. Без бит инде теләсә кем иҗат итә алган купшы һәм ялган декларацияләрдән байтак ары киттек.

Литва шагыйре Э. Межелайтис декларативлыкны сәнгатьнең сабыйлыгы* дип атый. Сабыйлыктан ераграк иткән саен, тормыш катлаулана, әсәр язу кыенлаша. Кайчандыр кешенең кияр киеме булса, ертык булмаса, һәм ул шуның белән канәгать булса, хәзер аңа оригиналь фактура — сирәк тесләр, затлы бизәкләр кирәк. Тегелеше дә иң соңгы мода кимәлендә булсын.

Сәнгать — ярату дибез. Сәнгатьтә нәфрәт тә ярату хакына була дибез. Ләкин пассив ярату гына җитми, хәзер аны гамәл белән — поступоклар белән — ә сәнгатьтә конкрет сурәт, күренеш, сәбәпле хәл, вакыйга белән расларга кирәк. Исбатсыз фикер, гәрчә бик дөрес булса да, безгә инде тәэсир итә алмый, ышандыра алмый. Хәтта әсәрнең эчтәлеген тәшкил иткән, аның тирәнлеген билгеләгән югары философия дә поэзия өчен ахыргы максат түгел, бары тик чара гына.

Сүзләрдән очкыннар чәчелә —
Берешәр, икешәр, өчешәр!
Очкыннар шикелле уйларым:
«Мин сезне яратам, кешеләр!»

Ярату турыдан-туры әйтелсә дә, монда без аның төсен, рәвешен очкыннардан гыйбарәт икәнен дә күз алдына китерә алабыз. Икенче урында төннең портреты, чалымнары, әйтер идем, хәтта холкы-фигыле төсмерләнә:

Йолдыз-йолдыз сипкелләрен
Балкытып елмайды төн.

Ишетү дә әйбәт, ләкин күз белән күргәнгә ышану җиңелрәк шул.

Шунысын да өстәргә онытмыйк: образлы сүз шулай ук шигырь өчен үзмаксат түгел, ә бары тик фикер һәм настроение тудыру өчен чара гына. Образ гадәттә карыша — шигъри идеягә әверелмәскә, бөтенлеккә зыян китерергә тырыша. Образлар каршылыгын җиңү өчен, поэтика белгечлеге, тәҗрибә таләп ителә. Алсуның кайбер шигырьләрендә әле тәҗрибә җитмәү шактый сизелә. Бөтенлек, табигыйлек, ә аннары музыкальлеккә тоташасы иҗади киеренкелекнең гомерлек мәшәкатьләре алда, әлбәттә, күп булачак. Ләкин яшь шагыйрәнең иң тәгәл юллары һәм шигырьләре киләчәктә аның материаль каршылыгын уңышлы җиңә барачагына өмет һәм ышаныч тудыра. Дәлилләрнең берсе сыйфатында «Тынычлык дәресе» шигырен күрсәтер идем.

Җыйнак һәм хәрәкәттәге сурәткә өлгәшкән бу шигырь авторның яшьлегенә дә, аның әйбәт ниятләренә, ныгый барачак гражданлык сыйфатларына да дөрес ишарә итә дип уйлыйм.

Тормыш катлаулы булып кала. Җир йөзендә зәңгәр әләм тоткан Кабил дә, кара флаг тоткан Һабил дә йөри бирә. Тормыш атом энергиясенә каршы тора алырлык рухи көч таләп итә.

Заман шагыйрьдән шундый сүз көтә.

Әхсән БАЯНОВ.

## Алексей Налепин

# ЯШӘҮ БЕЛӘН ҮЛЕМ АРАСЫНДА

Вакыт кешене дәвалый диләр, авыр истәлекләрдән арына алган кеше рәхәт яши диләр... Гасырлардан-гасырларга күчеп килгән бу сүзләр белән килешергә дә мөмкин һәм алар белән бик үк ризалашып бетмәскә дә була. Ләкин, ничек кенә булмасын, халыкның әхлакый йөзен барлыкка китерүче бөек Хәтер каршында бу хакыйкать көчсез. Нәкъ әнә шул Хәтер безне халык дигән олы бердәмлеккә берләштерә. Нәкъ әнә шуңа күрә кырык беренче елның салкын кышындагы Мәскәү яны сугышлары, чолганышта калган Ленинград каһарманлыгы хәтердә, Сталинградны һәм Севастопольны яклаучыларның батырлыгы онытылмый. Бөек Ватан сугышы еллары һәр совет кешесенең шәхси язмышын ил язмышы белән тыгыз итеп үрде.

Совет халкы Бөек Ватан сугышында җиңүнең 40 еллыгын бәйрәм иткән көннәрдә башкалабыздагы «Советский писатель» нәшрияты күренекле татар язучысы Нәби Дәүлинең «Яшәү белән үлем арасында» исемле китабын рус телендә бастырып чыгарды. Үзенең беренче шигырьләрен инде 1931 елда ук матбугатта күрсәткән авторның исеме укучыга яхшы таныш иде. Ә 1957 елда беренче мәртәбә Казанда басылган әлеге повесть исә язучының яңа жанрда чыгыш ясавы иде. Һәм ул уңышлы булды — әсәр күп мәртәбәләр дөнья күрде, укучының яраткан китабына әверелде. Шуңа күрә повестьның башкала нәшриятында басылуы әдәби җәмәгатьчелектә дә, укучылар арасында да яңа кызыксыну дулкыны уятты.

«Яшәү белән үлем арасында» повестен укыганда, тагын бер кат шул хакыйкатькә ышанасың: совет халкының сугыш чорындагы батырлыгы, аның рухи көче, җиңүгә омтылуы — чыннан да, күп милләтле совет әдәбияты өчен бетмәс-төкәнмәс илһам чыганагы икән! Әсәр бик үзенчәлекле, гаять күп кырлы. Ул фашизм белән көрәшнең чагыштырмача азрак билгеле булган сәхифәләрен дә ача, шул ук вакытта, кырык беренче елның җәендә хәбәрсез югалып, нацистларның концентрацион лагерьларына эләккән, әмма сынмаган, рухи яктан җиңелмәгән солдатлар язмышын да яктырта.

Нәби Дәүли — фашист тоткынлыгының коточкыч газапларын үз башыннан кичергән язучы. Бу китапка кергән әсәрләрдән «Яшәү белән үлем арасында»ны укыйсыңмы, яисә «Җимерелгән бастион»га тукталасыңмы — һәр икесендә йөрәк каны белән язылган юллар, күңел түреннән әрнеп чыккан сүзләр күрәсең. Автор укучыны үзе кичергән җан тетрәткеч хәлләр белән таныштыра.

Ә шулай да кечерәк кенә күләмле «Яшәү белән үлем арасында» повесте язучы иҗатында аерым урын алып тора. Хәер, бу әсәрнең повесть дип билгеләнүе белән бик үк килешеп тә бетәсе килми. Чөнки, гадәттә, әлеге жанр автор фантазиясе булуны күздә тота, аңа шактый урын калдыра. Нәби Дәүли әсәре исә бу гадәти билгеләмәгә генә сыя алмый. Ул — аяусыз әдәби документ. Аның каршында теләсә генә нинди фантазия дә калыша. Бу уңайдан П. В. Палиевскийның «Әдәбият һәм теория» исемле китабында язылган түбәндәге сүзләр хәтергә килә. Бүгенге әдәбиятта документ уйнаган роль турында уйланып һәм сугыш турындагы әсәрләрдә документның иҗат фантазиясенә караганда һичшиксез зуррак әһәмият ала бару тенденциясен билгеләп, ул болай дип яза: «Әлеге сугыш вакытында, чыннан да, кешенең мөмкинлекләре һәр ике якка да бик нык зурайдылар — алар язучы уйлап чыгара алырдай дәрәҗәдән бик узып киттеләр. Һәм нинди ир иң чик, иң кырый ноктага диярлек килеп җиттеләр. Мисал өчен, әгәр кино режиссеры тамашачыга Хиросима турында әйтергә теләгән икән — ул бернинди аңлатусыз-нисез документаль кадр гына күрсәтә. Ә анда исә яңып

беткән күзләр, үзенңән-үзе кубып торучы баш тиресе, чәчләр... Мена болардан да ары инде бернинди дә образлылык була алмый, моннан да узарлык мәхшәрне инде бүтән күрмәсәк иде дияргә генә кала».

«Яшәү белән үлем арасында» китабы — корбан булганнарга һәйкәл, ә фашист канэчүчеләрне гаепләү, нәфрәт авазы. Моның кше әсәрләрнең укучыга тәэсир көче гаять тә зур, чөнки алардагы һәр юл, һәр сүз артында әдәби герой гына түгел, ә конкрет кеше тора. Безнең илебезнең күпмиллэтле әдәбияты бу темага багышланган байтак кына яхшы әсәрләрне белә. Мисал өчен Михаил Шолоховның «Кеше язмышы»н һәм Василь Быковның «Альп балладасы»н күрсәтергә мөмкин. Соңгы елларда А. Адамович белән Д. Гранин язган «Блокада китабы» һәм С. Алексиевичның «Сугыш — хатын-кыз эше түгел» әсәре шушындыйлар рәтенә килеп кушылды. Н. Дәүлинең без сүз алып бара торган повестьлары да алар арасында үзенең лаеклы урынын ала.

Китапны укыганда, андагы аяусыз дөреслек тетрәндерә, йөрәк түреннән чыккан һәм һәрбер аерым очракта гаять көчле гәүдәләнүче нәфрәт тәэсир итә. Фашизмга нәфрәт хисе лагерь комендантын яисә «йомшак күңелле» фрау Яковны күргәндә дә, сатлык староста белән очрашканда да — һәрвакыт безнең күңелне биләп ала. Болар барысы да кешене һәм кешелекне буйсындырырга, тыңлаучан җан иясе итәргә теләгән һәм шул максат белән гаять зур көчләү системасы төзегән фашизм идеологиясенең төрле кыяфәте генә бит!

Китапны укыганда, эсэс мундирының кара формасы күп явызлыклар символы булып гәүдәләнә. Бу уңайдан «Вопросы литературы» журналының 1984 елгы 6 санында басылган Алесь Адамович мәкаләсе искә төшә. Бүгенге бер кыланчык кызның: «Миңа менә аларның формасы ошый» — диюенә борчылып, ул анда болай яза: «Кемнәр турында, нәрсә турында әйтелә соң бу сүзләр?! Кызганыч, әлеге яшь кыз кинода гына күргән эсэс мундиры турында ул сүзләр... Аларны ишеткәндә, үзебездә туган ачу килү, ярсу хисен бераз тыйыйк та — ул сүзләр әйтелүнең сәбәбен тикшереп карыйк. Яшь кыз аңында бер үк күренешнең эчтәлеге белән формасы ничек алай икегә аерыла алган соң? Бу бит сугышны үзе күргән өлкәннәр өчен үтә гади хакыйкать! Моңа кем, нәрсә гаепле — ул кыз үземе, әллә бик күп санлы һәм җиңел генә эшләнгән мажаралы киноларммы, детектив әдәбиятмы? Күп санлы әнә шундый җиңел әсәрләрдән һич уйламаганда әлеге начар нәтиҗә килеп чыкканмы әллә?»

Тыныч чорда туып үсеп, дошманны кинода гына күргән әлеге кызга үз вакытында Нәби Дәүли повесте кебек әсәрләр килеп эләкмәгән шул! Мин шулай уйлыйм — бу китап алданрак басылган булса, әлеге яшь кыз сыман байтак укучылар үзләренә онытылмаслык рухи сабак алырлар иде. Без алдарак күреп киткән җан өшеткеч сүзләр дә ишетелмәс иде... Әлбәттә, биредә әдәбият үзе генә мәсьәләне тулысынча чишеп бетерә алмый. Ләкин әдәбият ул тормыш китереп чыгарган проблеманы хәл итү юлын күрсәтә ала. Бу яктан караганда да Нәби Дәүли китабы иң яхшы мәгънәсендә тәрбияви көчкә ия — ул дөньяга дөрес караш тәрбияли.

Мещанлык һәм әхлакый битарафлык — фашизмны үстерү өчен, аның агулы агачы өчен уңдырышлы туфрак булды. Әсәрдә сурәтләнгән фрау Якобның «үрнәк» хуҗалыгы һәм анда эшләүче тоткыннар тормышы белән танышканда, моңа тагын бер мәртәбә ышанасың. Биредә барысы да тыныч кебек — кешене җәзаламыйлар да, үтермиләр дә, кайвакытта хәтта әйбәт кенә ашаталар да. Ләкин бу, барыбер — физик көчне генә санга сугуга көйләнгән мохит, шәүләләр кебек яшәүче обывательдөньясы. Шуңа күрә, биредә күпмедер вакыт эшләгәннән соң, тоткыннарның яңадан үз иптәшләре янына, чәнечкеле тимер чыбык артына кайтуы — әсәрдә үзенчә бер иркенлек сыман кабул ителә. Ерактагы азатлыкның бер кечкенә генә кисәкчеге сыман...

Повесть лирик геройның үзендә һәм әйләнә-тирәдәгеләрдә кешелек хисен, кешелек тойгысын саклап калу өчен барган көрәш турында. Анда лагерьдагы яшерен оешма хакында да, кыю планнар кору һәм качу турында да язылмый. Ләкин китапның һәр юлы, һәр бите көрәш хакында. Көн саен, сәгать-минут саен бара торган каршылык турында. Чөнки лагерьдагы һәр үлем батырлык булса, исән яшәлгән һәрбер көн — икеләтә батырлык. Нәби Дәүли геройларының башыннан кичкән хәлләр — совет халкының җиңелмәс рухын һәм көчен күрсәтүче дәлилләр.

Лагерьдагы коточкыч хәлләр, гадәти кеше күз алдына да китерә алмастай яшәү тоткыннардагы өметне һәм тиздән килеп җитәчәк җиңүгә булган ышанычны сүндерә алмый. Чыдап булмаслык ачлык, әллә нинди газаплы авырулар, эчке борчулар да аларның рухын сындырмый. Сатлык җан власовчыларның үгетләве дә файда итми. Тоткыннар йөрәгендә илгә булган тугрылык хисе кимемичә яши бирә.

Әлбәттә, тормыш булгач, арада төрлесе очрый. Автор андыйларга да күз йоммый. Мәсәлән, Поляков дигән адәмнең куркудан илен сатуы һәм ахырда үз-үзен үтерүе — әсәрдә закончалыклы күренеш итеп тасвирлана. Чөнки ул үзе утырган ботакка үзе

балта чапкан, моңа кадәр көч, өмет биреп торган чыганагын югалткан. Аның инде бүтән юлы юк.

Әмма баш бирмәс һәм буйсынмас кешеләр повестьта чагыштыргысыз дәрәҗәдә күп. Алар — Василий Петрович дигән доктор, Никита Лазарев дигән гади солдат һәм тагы бик күп исемсез батырлар. Нәкъ менә алар, дошман кулында калуга карамастан, көн саен үзләренең тыныч батырлыкларын эшлиләр, әйләнә-тирәдәгеләрнең рухын күтәрәләр, хәле авыррakларга соңгы кисәк азыкларын бүлеп бирәләр, булдыра алганча ярдәм итәргә тырышалар.

Автор үз повестьларында икенче бер мөһим моментка да басым ясап бара. Ул — тоткыннарга төшкән мораль җаваплылык, үзләрен ил каршында гаепле итеп тою. Ерактa, алардан кәнчыгыштарак яткан сугыш кырында, үз иптәшләренең, кулларына корал тотып, фашистларга каршы көрәшүен белү, ә биредә чәнечкеле тимер чыбык эчендә тешне кысып нәфрәтләнергә генә мөмкин булу тоткыннарны җан газабына сала. Әнә шундый газаплы уйлардан соң күпләр котылуга һәм исән калуга бөтенләй диярлек өмет күренмәсә дә — качып карыйлар. «Яшәү белән үлем арасында»-ның 71 битендә әлеге тәвәккәл адымнарның берсе болай сурәтләнә: «Безне Никита үлекләр белән бергә каберлеккә алып чыгарга җыена. Без, төн җиткәч, кабердән чыгып качарга тиеш идек. Чөнки каберлекне урап алган тимер чыбык койманы узарга авыр түгел. Анда төнлә белән сакчылар да тормый... Лагерьдан качар өчен бу, әлбәттә, бердәнбер юл иде. Ләкин куркыныч иде бу. Берничә сәгать үлекләр белән бергә, янәшә, кабердә ятарга кирәк булачак».

Әйе, тоткынлыктан котылып, фронт сызыгына таба якынлашу һәм үзебезнекеләр ягына чыгу өчен солдатлар барысына да түзәргә риза: вакытлыча җир астына күмелергә дә, сап-салкын гәүдәле үлекләр белән янәшә ятарга да — тик котылу гына һәм яңадан корал тотып газиз Ватан өчен сугышу гына мөмкин булсын! Әнә шул уй, шул өмет күпләрне, бик күпләрне җилкендерә, күпләр кача. Ләкин үзебезнекеләргә хәтле сирәкләр генә кайтып җитә...

Фашизм совет кешесен җиңә алмады, аннан көчсезрәк булып чыкты. Фашизм сугыш кырында да һәм хәтта кулында коралы булмаган тоткын солдатка да оттырды. Шуңа күрә совет солдатыныңныклыгы, социалистик Ватанга бирелгәнлеге турындагы түбәндәге ялкынлы юллар һич тә риторика гына түгел, ә фашист тоткынлыгында дүрт ел тилмергән кешенең йөрәк каны белән язылган юллар. Алар дүрт ел буе кичергәннәрдән, күргән газаплардан соң бер олы нәтиҗә ясап әйтелгән сүзләр.

«Фашистлар өчен совет солдаты — иң куркынычлысы. Совет кешесе — үзенең мылтыгы белән генә түгел, җирдә яшәве белән дә фашизмга дошман. Моның сәбәбе, әлбәттә, аңлашыла. Совет кешеләре Ленин акылы белән коралланганнар, ә бу коралны беркайчан да кулдан сугып төшерергә мөмкин түгел. Совет солдаты — үзенең җирдә барлыгы белән генә дә «кызыл пропагандист». Ә кызыл пропаганда киртәләрне белми. Чөнки ул хаклык! Ә хаклык ул үлми, үлми генә түгел, ул үсә, тарала. Гитлер менә шуннан бигрәк тә курка иде. Курыккан саен, аның ерткычлыгы да арта бара. Шуңа күрә фашист инде кулыннан коралы алынган, яраланган, хәлсез әсирләрдән дә өркә».

Дошман совет кешеләренең күп кенә адымнарын аңлый алмый. Күпләрнең үз тормышын куркыныч астына куеп, бүтәннәрне коткарырга, яшәтергә тырышуын да төшенә алмый фашизм. Мәсәлән, тоткыннарга ипи һәм кием ыргытырга теләгәндә, фашист солдаты тарафыннан атып үтерелгән Дуся исемле кыз турындагы онытылмаслык эпизод әнә шундый... Инде йончыган һәм хәлсез ат үзенең хуҗасын танып алганнан соң, фашистларның аны суярга кушкан приказлары үтәлмәү дә — дошманны сәерсендерә, алар кешедәге моның ише хисне аңлый алмый. Шулай ук совет солдатының үзе билгесез булып калса да, ни өчен соңгы тамчы канына кадәр сугышуын да төшенә алмый дошман... Менә шушындый күп күренешләр безнең укучыга ике төрле яшәү, ике төрле караш хакында бик ачык сөйли.

Нәби Дәүли әсәрләренең теле гади һәм хәтта документлардагыча берникадәр корырак та дияргә мөмкин. Бу хакта әсәрләрнең бүлек исемнәре дә әйтеп тора. Менә беренче повестьтагы кайбер бүлекләр: «Титан»ның үлеме», «Стенага язылган тарих», «Рус җыры», «Немец чабата кияме?» Әлеге бүлекләр эчтәлекләре буенча да аерым бер трагик новелла сыман укыла. Шулай ук аларның һәрберсе зур күләмле әсәр нигезенә дә ята алыр иде. Ләкин биредә автор бары тик хакыйкатькә нигезләнгән әсәр язуны гына максат иткән.

Алдарак без Нәби Дәүлинең документальлеккә якын стильдә язуын билгеләп үткән идек. Ләкин шунысы кызыклы: бу стиль белән сурәтләнгән күп кенә эпизодлар тәэсир көче ягыннан югары сәнгать дәрәҗәсендә килеп чыкканнар. Мөгаен, биредә эш шундадыр — аларга югары трагик пафос хас, алар әсәрне укыган һәркемнең җанын актарырлык итеп язылганнар. Түбәндәге күренеш әнә шундыйлардан берсе.

«Бүген бер төркем әсирләрне лагерьдан эшкә алып чыктылар. Алар арасына

мин дә әләктем. Безне җимерек урамнар аша шәһәр читенә үк алып килделәр.

Без биредә тәрәзәләре төтен белән каралып беткән, бер як стенасы җимерелеп төшкән бер таш бина күрдек. Немецлар әсирләрнең бер өлешен шунда күчерергә уйлыйлар булса кирәк. Чөнки без килеп җиткәндә, монда чәнечкеле тимер чыбык төягән ике машина туктап тора иде.

Безне бина эченә алып керделәр. Бүлмәләрдән көйгән ит исе чыга. Шундый авыр ис иде бу, безнең бер иптәшебез шундук укшый башлады. Немец бер кулы белән борынын кысып, икенче кулы белән идәнгә төртеп күрсәтте. Идәндә янып күмергә әйләнгән кеше сөякләре ята иде. Аларны кеше сөяге дип әйтерлек тә түгел. Дөресрәге, бу сөякләр инде көлгә әйләнгәннәр, бары тик баш сөякләре генә үзләренең формаларын җуймаганнар. Ләкин алар да, кул тию белән, сибелеп китеп, күз алдында юкка чыгалар.

Шул сөякләр янында агач түтәләре янып беткән мылтык көпшәләре һәм кул пулеметлары ауный. Идәнгә бик күп гильзалар сибелгән. Алар янып кып-кызыл булып калганнар, әйтерсең, әле хәзер дә кызып торалар кебек. Һәр тәрәзә турысында идәнгә җәелеп калган тапка карап, бу урында сугышчы яткан икәнлеген аңлап була иде.

Моннан атна-ун көн элек менә шушы бинада безнең кызылармеецлар батырларча сугыш алып барганнар. Бу таш бина героик бастионга әйләнгән. Һәм аның бусагасыннан атлап узардан элек, меңләгән фашист башсыз калган. Батыр совет солдатлары үзләренең соңгы сулышларына кадәр көрәшкәннәр. Алар дошман снарядлары бина стеналарын җимергәндә дә, бүлмәләрне ялкын урап алганда да чигенмәгәннәр.

Бәлки кайчан да булса бер вакыт бу бинаның стенасына аларның исемнәре алтын хәрефләр белән язылыр. Алар билгесез калмаслар. Ә хәзер... Ә хәзер безнең алда аларның көлгә әйләнгән сөякләре генә ята. Моны кем генә күрсә дә, совет солдатларының батырлыкларына сокланыр иде.

Без шул көлгә әйләнгән сөякләрне җыярга тиеш идек. Кемдер бер калай тартма алып килде. Без сөякләрне шул тартмага тутырдык».

Менә бу өзекне бер генә кеше дә тыныч күңел белән укый алмый. Әлеге күренеш сугыш дигән явызлыкның чын йөзен ачып сала. Тагын шунысын бик яхшы төшенәсең: мондый кичерешләр үзенең егерме миллион улын һәм кызын югалткан совет халкы өчен бигрәк тә аңлашыла. Күрәсең, әнә шуңа күрә дә автор үз әсәрләрендә гади һәм бераз корырак стильне сайлый.

«Совет халкының 1941—1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында җиңүенә 40 ел тулуны билгеләү турында»гы КПСС ҮК карарында түбәндәге юллар бар иде: «Сугышка багышланган матур әдәбият, документаль һәм мемуар әсәрләрнең иң яхшыларын үз вакытында бастырып чыгарырга». «Советский писатель» нәшрияты да Нәби Дәүли әсәрләренә тукталып дөрес эшләгән — алар чыннан да, талантлы повестьлар, тирән уйларга тарта торган әсәрләр.

Бу китапта зур күләмле әлеге ике әсәрдән кала тагын кечерәк күләмле «Булган ди бер кеше» хикәясе дә урнаштырылган. Ул да сугыш чоры турында һәм шул ук вакытта бу хикәя теманы йомгаклап та куя сыман. Ялгыз картның буранлы көнне басуда калып, катып үлүе — шулай ук фашизмның гаебе. Бу да фашизм эшләгән күп җинаятьләргә килеп кушыла.

Нәби Дәүли җыентыгына кергән әсәрләр күңелне тетрәндерерлек әнә шундый хәлләр турында. Андагы геройлар бик авыр ситуацияләрдә калалар. Ләкин шунысы бар: ул геройлар, ул кешеләр безгә беркайчан да мескен булып тоелмыйлар. Алар укучыда фашизмга карата нәфрәт уяталар.

Бүгенге көндә — Көнбатыш Европаның кайбер илләрендә фашистларның яңа төре баш калкытырга маташканда — мондый китаплар безнең өчен бигрәк тә әһәмиятле. Алар халыкларның изге көрәшендә ярдәм итә, фашизмның нәрсә икәнен, нинди икәнен гел исә төшереп тора.

Әйе, илебез халкы үткән сугышта күп корбаннар бирде. Ләкин совет кешеләре барыбер буйсынмаган килеш, фашизмга тез чүкмичә, рухи яктан нык калып үлделәр. Чөнки аларга безнең гүзәл Ватаныбыз көч бирде. Алар барысы да кыю рухлы ватандашлары Муса Җәлил сыман болай дия алырлар иде:

> Кайгырма, дус, яшьли үлдебез дип,
> Без алмадык сатып гомерне.
> Үзебезчә яшәп, үзебезчә
> Без чиклибез аны түгелме?!

Нәби Дәүли китабындагы геройлар да шундый ышаныч белән яшиләр һәм көрәшәләр. Без, укучыларга алар: «Кешеләр, онытмагыз!» — диләр. Һәм без онытмаска тиеш!

*Мәскәү.*

## Гәрәй Рәхим

# ТУГАН ИЛ ХИСЕ

Яңа гына унны бетереп, үземнең истәлек дәфтәренә генә шигырьләр язып, кулыма эләккән бөтен газета-журналлардан, китаплардан комсызланып «поэзия әчеп» йөргән чак иде. Безнең Лениногорск районы «Ильич васыятьләре» газетасыннан еш кына Шамил Маннапов дигән авторның солдат хисләрен чагылдырган шигырьләрен укыйм. Безнең газетада алар 1959—60 елларда аеруча күп басылдылар. Соңыннан белүемчә, Шамил Маннапов бу елларда Совет Армиясендә хезмәт иткән һәм «Ильич васыятьләре» газетасы каршындагы әдәбият-иҗат түгәрәге җитәкчесе Шамил Бикчурин белән хат алышып торган икән...

Менә шул чордан бирле мин Шамил Маннаповны совет кешесенең, аеруча бүгенге яшь кешенең патриотик хисләрен җырлаучы, катлаулы тормышыбызның фәлсәфи тирәнлекләренә омтылучы, табигатьне, кешеләрне, тормышны яратучы шагыйрь итеп беләм. Бүгенге көндә Шамил Маннапов — киң катлау татар укучыларына билгеле булган, әсәрләре белән поэзия, җыр сөючеләрнең күңеленә үтеп кергән, үзәк нәшриятларда җыентыгын чыгарып, аерым әсәрләре илебезнең тугандаш халыклары телләренә тәрҗемә ителгән, иҗади яктан актив шагыйрьләребезнең берсе. Шул ук вакытта ул әдәби тәрҗемә, проза, сатира-юмор өлкәсендә дә уңышлы гына эшләп килә.

Ул үзенең әсәрләрендә «тамырлар» образына еш мөрәҗәгать итә, «давылдан соң актарылып чыккан тамырларга башын иеп» уйлана. Чыгышы, тормыш юлы аның үз иҗатын да яшәү көче белән туктаусыз сугара.

Шамил 1938 елның 1 гыйнварында Татарстанның Әлки районындагы Татар Мулла авылында дөньяга килә. Әтисе — Мәгыйзь абзый — гомергә солдат булган кеше. Беренче бөтендөнья сугышында, аннары Гражданнар сугышында катнашкан ул. Легендар Чапаев дивизиясендә йөргән чакларын улына горурланып сөйли торган булган... Бөек Ватан сугышында Мәгыйзь абзый артиллерия туплары таккан атлары белән Берлингача барып җиткән... Абыйлары да — солдатта булган ир-егетләр. Шулар өстенә әнисе Сәрмәдия апа — авылның шагыйрәсе. Шамилнең күңелендә балачактан ук шигърият орлыклары шыта башлый.

Унъеллык белем алып, совхозда механизатор булып эшләгәндә дә, аннары Совет Армиясендә хезмәт иткәндә дә аның шигырьләре район һәм республика газеталары битләрендә күренгәли. Солдат тормышы авылдан килгән яшь егеткә тирән тәэсир ясый, һәм ул дәртләнеп яңа рухтагы шигырьләр яза башлый. Шамил Маннаповның киләчәктәге иҗади юлының иң матур бер сукмагы нәкъ менә шул солдат елларыннан, шул чактагы әдәби тәҗрибәләреннән башлана дисәк, һич кенә дә хата булмас. Инде торабара «Казан утлары» журналында, республика газеталарында зур-зур циклларын, нәшриятта үзенең аерым шигъри китапларын бастыра башлагач та шагыйрьнең патриотизм, кайчакта оптимистик юмор белән сугарылган солдат шигырьләре һәр циклда, һәр китапта аерым урын алып торды. Аның җыентыкларында һәрвакыт диярлек солдат шигырьләре тупланган аерым бүлек була.

Татар әдәбияты гомумән дә хәрби темага бик бай. Атаклы рус шагыйре Алексей Сурков юкка гына татар поэзиясен солдат поэзиясе дип атамагандыр. Гражданнар сугышы елларындагы Ибраһим Иосфилар, Шамун Фидаилар башлаган бу тема Бөек Ватан сугышы елларында аеруча күтәрелеп китте. Татар әдәбияты бу тема белән дөньяга Муса Җәлилне бирде. Ул чакларда сугышта катнашкан, яки сугыштан соң гына әдәбиятка килгән бик күп шагыйрьләребез Бөек Ватан сугышы темасын зур итеп, калку итеп күтәрделәр. Шунысы кызык, сугыштан соң әдәбиятка килгән һәм армиядә хезмәт иткән байтак шагыйрьләребез күбесенчә үзләренең солдаттагы хезмәте турында түгел, ә совет солдатының

Бөек Ватан сугышында кылган батырлыклары турында яздылар. Әйтәсе дә юк — Бөек Ватан сугышындагы фидакарьлек гомум совет әдәбиятына бинһая зур темалар калдырды.

Шамил Маннапов татар әдәбиятындагы хәрби тема традицияләрен уңышлы дәвам итте, үзенең чордаш шагыйрьләре арасында берданбер буларак бу теманы иҗатының төп үзәне итеп алды. Алтмышынчы еллар совет солдатының татар поэзиясендәге иң калку образын ул иҗат итте. «Чехолдагы ракеталар», «Солдатта булган диләр...» кебек әсәрләренең чын мәгънәсендә халыклашып китүе моның ачык мисалы булса кирәк.

Ялгыш очып китмәсеннәр диеп,
Башларына чехол кигездек.
Ракеталар,
Чик буенда без тотабыз сезне,
Сез тотасыз безне ирексез.

(«Чехолдагы ракеталар»)

Билен кысып буган диләр,
Бигерәк уңган диләр.
Әллә каян күренеп тора —
Солдатта булган диләр.

(«Солдатта булган диләр...»)

Язылу манералары белән бер-берсеннән гаять ерак торсалар да (беренчесе — фәлсәфи лирика, икенчесе — шаян җыр), бу ике әсәр уртак образны — бүгенге көн совет солдаты образын, аның чын мәгънәсендәге тирән фикерле, Җирдә тынычлыкны саклауда бөтен дөнья каршындагы олы миссиясе булган («без тотабыз сезне, сез тотасыз безне ирексез»), тыныч тормыш коруны максат итеп куйган («комбинезон алган диләр, шинелен салган диләр») образын күз алдына бастыралар. «Тыңланмаган моңнар», «Увольнениегә чыккач», «Сакта», «Карт солдат», «Хат яз дигән идегез» һ. б. шигырьләрдә дә автор шушы мотивны үстерә, бүгенге совет солдатының уй-хисләрен җырлый.

Совет Армиясе сафларыннан әйләнеп кайткач та Ш. Маннапов солдат тормышы турында язуны төп максат итеп саный. Армиядән кайткан елны ук ул В. И. Ульянов-Ленин исемендәге Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегенә укырга керә. Рус, татар, чит ил әдәбиятлары белән чынлап танышу, илебезнең иң өлкән югары уку йортларының берсе булган Казан университеты тормышы, андагы татар әдәби иҗат берләшмәсендәге чын иҗади мохит яшь шагыйрь иҗатын тагын да активлаштырып, әсәрләренең колачын киңәйтеп җибәрә. Шушы еллардан Ш. Маннапов иҗатында фәлсәфи-лирик агым өстенлек итә башлый. Иҗатының башлангыч чорында бөтен иҗади көчен бер теманы эшкәртүгә багышлаган шагыйрьнең әсәрләрендә теманың төрләнәнә, ә жанр ягыннан фәлсәфи лириканың ныгый баруы күренә.

Күккә түгел,
Һаман җиргә ябышып,
Җирнең үзәгенә үсә тамыр.
Бәлки, шуңа ботак, яфраклардан
Гомере аның күпкә озын дадыр.
Тик яшәми үзе өчен генә,—
Яңа буын үсә аннан гөрләп.
Ул аларны күккә ашкындыра,
Яңгыр тамчысының тәмен сөйләп...

(«Тамырлар»)

Чыннан да, Ш. Маннапов соңгы 15-20 елда шигырьдә фәлсәфи башлангычка, тормыш-көнкүреш, табигать һәм кеше, аларның үзара мөнәсәбәтләре, тарих һәм бүгенге көн турында уйлануларга, шигъриятта шушы юнәлештәге эзләнүләргә күбрәк урын бирә. Бу юнәлеш аның традицион солдат темасына да, туган як, туган ил, туган халык, заман һәм замандашларга багышланган әсәрләренә дә бердәй тәэсир итә. Үзе дә шигъриятебездә фәлсәфи тирәнлеккә өстенлек биргән күренекле шагыйрь Әнвәр Давыдов әле 1968 елда ук Ш. Маннапов поэзиясендәге шушы башлангычны тоеп алган иде. «Туган ил хисе аңарда бөтен чишмәләрнең чишмәсе — елгалар, диңгезләр чыганагы кебек тирән ята...» — дип язды ул. («Татарстан яшьләре», 1968 ел, 25 март саны).

Поэзиядәге фәлсәфи уйланулар, фикри тирәнлеккә омтылу кайчакларда Ш. Маннапов шигырьләренең бизәкләргә сараланyына, образларның катлаулануына да китерә.

Ләкин бу күренеш шагыйрьнең төсмерләргә бай, кабатланмаган-таушалмаган бизәкләр эзләүгә, шигъри сүзләре саллы, күп мәгънәләргә ия булган яңа образлар иҗат итәргә омтылуыннан килә. Ш. Маннапов үзенең иҗатында яңача фәлсәфи агым һәм халыкчан-традицион шигырьләрнең синтезына ирешүне максат итеп куя, һәм бу алым аның әсәрләренә үзенчәлекле төс бирә. «Йомык» бөҗра эчендә», «Ташкүмер уйлары», «Күпләр чакыра мине үзенә генә...», «Аерылышу», «Бу хакта киекләр уйланмас» һ. б. шигырьләрендә без шагыйрьнең зур темаларга катлаулы шигъри алымнар белән мөрәҗәгать итүен күрәбез. Ш. Маннаповның мондый омтылышын бүгенге татар поэзиясенең гомуми үсеш тенденцияләре белән бәйләп карарга кирәк, әлбәттә.

Шамил Маннаповның юмор-сатира өлкәсендәге эзләнүләре турында аерым әйтеп үтәсе килә. Хәлбуки, аның чордаш шагыйрьләренең күбесе үз иҗатларында халкыбызның, татар әдәбиятының бу иң популяр һәм күркәм жанрына бөтенләй күз йомдылар. Гомумән, 60-70 нче еллардан соң поэзиягә килгән шагыйрьләребез арасында әлеге жанр нык сүрәнләнде. Моннан үзгә буларак, Шамил Маннапов үз иҗатының буеннан-буена юмор-сатира жанрында каләм тибрәтүен ташламады. Дөрес, юмор аның төп жанрына әверелеп китмәде. Шулай да Ш. Маннапов татар әдәбиятына бик күп әйбәт юмористик әсәрләр бирде. «Грипп һәм гадәт», «Карт солдат», «Малайлар гына җитсен...», «Маһруй әби теләге», «Мишәрләрем» һ. б. шигырьләре әнә шундыйлар. Солдат тормышы турындагы әсәрләренең дә байтагына халыкчан шаянлык күркәм бер рух сирпеп тора.

Шамил Маннаповның лирик герое без эшләгән, йөргән, ял иткән, укыган һ. б. урыннарда үзара очрашып торган замандашларыбыз кебек уйлана, фикер алыша, борчыла, шатлана, моңлана, үзенчә нәтиҗәләр ясый. Ләкин бу лирик геройның без очрашып торган кешеләрдән бер аермасы бар — ул берүзе бик күпләр уен уйлый, бик күпләр шатлыгын яки кайгысын кичерә, бик күпләр хыялы белән хыяллана.

Әйе, Шамил Маннапов — заман гаме белән яшәүче, замандашларыбыз хисләре белән янучы шагыйрь. Бүгенге көн проблемаларын, замана үзенчәлекләрен шигырьдә ачып салу никадәр зарури булса, шулкадәр үк катлаулы да. Инде үзе дә ир уртасы булып өлгереп җиткән, поэзиябездә солдатча ныклык белән атлап баручы шагыйрь Шамил Маннаповка бу юлда без киләчәктә дә яңадан-яңа уңышлар телик.

Мәскәү.

# ТӘРҖЕМӘ ТУРЫНДА СӨЙЛӘШӘБЕЗ

**Журналыбызның 2 санында тәрҗемә турында сөйләшү башланып киткән иде. Аннан соңгы саннарда М. Рафиков, Р. Кукушкин, Н. Арслан, Р. Юсупов, Ә. Баянов, Л. Хәмидуллин, Ә. Исхак, Р. Гатауллин, Ф. Садриев, Г. Мөхәммәтшин мәкаләләре урнаштырылды.**

**Бу санда сөйләшүне язучы Фәнис Яруллин һәм укучыларыбыз дәвам итә.**

## Фәнис Яруллин:

Шигырь кеше күңеленә, кеше хисенә эмоциональ тәэсир аша керә. Һәр шигъри әсәрнең үзенең эчке бер музыкасы, ритмы, моңы, кыскасы, җанга тәэсир итә торган компонентлары бар. Подстрочникка әйләндергәч шигырьнең әлеге компонентлары югала, ул коры информация чыганагына әйләнә.

Рәис Сафаров үзенең «Киңәшергә кирәк» исемле мәкаләсендә подстрочник башкаручыны тәрҗемәче дип атарга кирәк ди. Сүз проза әсәрләре турында барганда, бәлки, ул хаклыдыр да. Чөнки прозада «кара эш»нең бөтен авырлыгы подстрочник ясаучы өстенә төшә. Подстрочник яхшы эшләнгән очракта тәрҗемәчегә редакторлык роле генә кала. Ләкин прозада да күп кенә очракта тәрҗемәчегә әсәрне өр-яңадан, хәтта композициясеннән башлап, эшләп чыгарга туры килә. Ә инде шигырь подстрочниклары турында сүз барганда, подстрочник ясаучыны тәрҗемәче дип атасак, һич дөрес булмас иде. Ни генә әйтмә, шигырь подстрочнигы — әле ул чимал гына. Образлырак итеп әйтсәк, сынчы художник кулына бирелгән үзле балчык. Ул үзле балчыктан сынчы (бу очракта тәрҗемәче) нәрсә ясар, аңа нинди юллар белән җан өрер, сәнгать әсәре дәрәҗәсенә күтәрәлырмы яки җансыз таш курчак кына ясап куярмы — бу яклары художникның осталыгына, үзе алынган эшкә ничек каравына һәм тагын бик күп нәрсәләргә бәйләнгән. Дөрес, укучы минем бу чагыштыруым белән килешмәскә дә мөмкин. Сынчы художник үзенең балчыгыннан теләсә нәрсә ясый ала, ә тәрҗемә итүче кеше оригиналдагы фикерне, оригиналдагы образларны сакларга тиеш дияр. Бер яктан караганда, ул шулай кебек. Ләкин художество әсәрен бер телдән икенче телгә күчергәндә, күп кенә образлар, идиомалар, фразеологизмнар, мәкаль яки әйтемнәр, бары тик бер халыкта, бер телдә генә кулланыла торган канатлы сүзләр төссезләнә яки бөтенләй беренчел мәгънәсен җуя. Кыскасы, шигырь киредән чималга әйләнә. Формасы да югала, җөмлә конструкцияләре дә үзгәрә, әчтәлек тә тулысынча бирелеп бетми. Ә подстрочник эшләүче исә оригиналдагы образ ясаучы, шигырьне шигырь итүче детальләрне башка телдә ничек тәгәлрәк бирү турында озак баш ватмый. Чөнки ул художестволы тәрҗемәнең сыйфаты өчен дә, подстрочникның сыйфаты өчен дә беркем алдында җавап бирми. Подстрочник яхшымы-яманмы икәнлеген автор күп очракта тәрҗемәчеләр белән эшли башлагач, яки «кульязмагыздагы әсәрләрнең күбесе безнең таләпләргә туры килмәде» дигән җавап белән подстрочникларны үзенә кире кайтаргач кына таныша. Дөрес, һәр автор подстрочникны кабул итеп алганда, аның белән танышырга тиеш.

Минемчә, күп очракта подстрочникларның сыйфатсыз булуына әнә шушы җавапсызлык сәбәпче. Икенче бер сәбәбе — подстрочникларның очраклы кешеләр тарафыннан ясалуы. Хәзер яшәп килгән: «Подстрочник ясар өчен, ике телне дә яхшы белсәң, бик җиткән»,— дигән тенденциянең дөрес түгеллегенә күңелебез белән инансак та, телне яхшы белүче әйбәт шагыйрьләрнең подстрочник ясарга алынмаулары аркасында теләсә кемгә бирергә мәҗбүр булабыз.

Русчаны «су кебек эчкән» әдипләр дә һәр әсәренә үзе подстрочник ясап утыра алмый. Хәтта башкалар тарафыннан ясалган подстрочникны тикшереп чыгу өчен генә дә әдипнең күпме вакыты, күпме көче сарыф ителә. Ә бит әле әдипнең яңа әсәрләр дә язасы бар. Үз баласын институтка кертер өчен башкалага җитәкләп киткән ата-ана

кебек һәр язган әсәре артыннан үзе йөри башласа, авторның яңа әсәрләр иҗат итәргә вакыты да калмаячак.

Менә шушы мәшәкатьләрен күз алдына китерә дә автор подстрочникларны рәтләп укымаган да килеш тәрҗемәчегә җибәрә. Тегенди-мондый җитешмәгән җирләрен тәрҗемәче ничек тә җирен җиткерер дип өметләнә. Ләкин тәрҗемәче подстрочниктагы юк әйберне бар итә алмый. Киресенчә, әле ул подстрочниктагы байлыкның да ниндидер өлешен кертми калдыра. Менә шулай итеп төрле этапларда әкрен-әкрен энҗеләр югала.

Укучының күңелендә: «Подстрочник алай бик үк әйбәт нәрсә булмагач, ансыз гына эшләп булмыймы соң?» — дигән сорау тууы бар. Әйе, турыдан-туры әйбәт тәрҗемә итүчеләр булса, югалтулар кими төшәр иде шикелле. Әмма нинди генә очракта да, минемчә, подстрочникны бөтенләй гамәлдән сызып ташлап булмый әле. Телләрне яхшы белү генә тәрҗемәнең сыйфатын гарантияли алмый. Подстрочник белән эшләгәндә дә бик әйбәт тәрҗемәләр туарга, «телне су кебек эчүчеләр» дә урта кул тәрҗемәләр бирергә мөмкин. Әдәбиятта моның классик мисаллары бик күп. Әйтик менә Жуковский «Одиссея»ны подстрочник аша тәрҗемә итә һәм уңыш казана. Шул ук вакытта Россиядә яратып укыла торган немец шагыйре Генрих Гейнене немец телен яхшы белгән Тютчев тәрҗемә итә, ләкин уңыш казана алмый.

Подстрочник — XIX гасыр җимеше. Элек, күбесенчә дворян тәрбиясе алган язучылар, Европа телләрендә яхшы сөйләшкәннәр, Европа культурасын (рус әдәбияты вәкилләре турында сүз бара) ныклап үзләштергәннәр. Безнең үзебезнең классикларыбызны гына алсак та — шул ук хәл. Шәрык телләреннән аларга беркем дә подстрочник ясап бирмәгән. Ул телләрдә чыккан әсәрләрне алар оригиналда укыганнар. Тәрҗемәгә алыналар икән, оригиналдагы ниндидер идея, ниндидер яңалык аларның күңелен тартканга, тәрҗемәгә тотынганнар.

Октябрь революциясеннән соң хәл бөтенләй үзгәрә. Элек үз язуы булмаган, әдәбиятлары бары тик фольклор аша гына билгеле булган милләтләрнең язма әдәбиятлары туа башлый. Ә әдәбият тудымы — ул инде үзенең милли кысаларында гына кала алмый, киңрәк мәйдан яулый. Менә шуннан инде милләтләр, халыклар арасында әдәбият алмашу өчен чаралар эзләнә. XIX гасырда сирәк очракларда гына кулланылган подстрочник егерменче гасырда әдәбиятта законлы прописка ала.

Дөрес, үз вакытында подстрочникка каршы төшүчеләр дә булмады түгел. Шул ук «Дружба народов» журналында тәрҗемә турында барган бәхәсләрдә: «Подстрочник — әдәбият кырында үсеп чыккан чүп үлә», — диючеләр булды.

Минемчә, тәрҗемәне подстрочник аша мы яки турыдан-туры башкару яхшыракмы дигән сорау бик үк урынлы түгел кебек. Боларның берсен икенчесенә каршы куярга ярамый. Әйбәт тәрҗемәне ничек эшләргә, сыйфатсызларын ничек булдырмаска — сүз шул турыда гына барырга тиеш. Подстрочникны чүп үләне кебек йолкып атып булмый әле. Әйтик, менә чуваш, мари, латыш, литва, эстон яки башка телләрдән шигырь тәрҗемә итәргә утырдык ди. Телләрне белмибез, ә укучыны ул халыкларның әдәбияты белән таныштырырга кирәк. Мондый очракта ике юл бар. Беренчесе — бу халыкларның русча чыккан художестволы тәрҗемәләре аша, икенчесе — әлеге дә баягы подстрочник аша. Боларның кайсы яхшырак? Һичшиксез, подстрочник аша эшләнгәне. Чөнки русчага тәрҗемә иткәндә, ул шигырьнең инде каеннарын — усакка, чыршыларын имәнгә әйләндереп бетергән булалар. Ә подстрочник аша эшләгәндә, әле оригиналдагы образларны сакларга, һич югы аңа тәңгәл детальләр табарга мөмкин. Ә русча тәрҗемә аша эшләгәндә, авторның акценты югалу куркынычы бар.

Тәрҗемәдә иң мөһиме нәрсә соң? Минемчә, әсәрнең рухын, җанын тою. Ләбиб Лерновның мәкаләсендәге Әхмәт Фәйзи сүзләре белән бик килешәм мин. Тәрҗемә итәргә алынган әсәрнең авторын, ягъни «...шәхесен, иҗат йөзен, хыял омтылышларын» белү тәрҗемәчегә бер дә артык түгел. Шунсыз ул аның иҗатына ачкыч таба алмаячак. Әсәрнең рухын, җанын тотып алгач инде аны нинди формада бирүне тәрҗемәче үзе уйларга тиеш. Чөнки татар шигъри калыплары руска яки башка телләргә бармаска мөмкин. Бер формада сүзләр очышын уңышлырак биреп була, икенче формада мәгънәви тирәнлеккә басым ясау кулайрак, өченче формада шаянлык, җорлык элементларын кертеп җибәрү уңышка китерә. Әлбәттә, бер әсәрдә боларның һәммәсенә ирешеп булмый. Шуңа күрә тәрҗемә иткән кеше әсәр авторының стилен, образлар белән эшләү алымнарын, шигъри детальләрне үстерү юлларын, гомумиләштерүдә нинди чаралар куллануын яхшы белергә һәм теге яки бу әсәрне тәрҗемә иткәндә, фикергә басым ясаргамы, шаянлык-җорлыккамы, сүзләрнең йөгереклегенәме, кыскасы, әсәргә карап хәл итәргә тиеш. Ә әсәрнең рухын, моңын бирү өчен тәрҗемәчегә талантлы булу гына җитми. Талант өстенә тәрҗемәченең үзе тәрҗемә итә торган автор белән рухи якынлыгы да кирәк. Билгеле, чынбарлыкта моңа ирешү авыр. Әйтик, менә безгә кайсы да булса республика язучылары киләләр ди. Тиз арада аларның әсәрләрен тәрҗемә итәргә, матбугатта күрсәтергә кирәк. Язучылар союзына кочак-кочак подстрочниклар килеп төшә. Мондый очракта берничә профессиональ тәрҗемәче генә коткара алмый. Әшка язучылар, шагыйрьләр тотына. Рухи якын-

лык турында уйланып утырырга вакыт калмый. Рәис Сафаровның: «Бездә күптәннән инде бер бик ялгыш фикер яшәп килә: имеш, танылган язучы, шагыйрь бер үк вакытта талантлы тәрҗемәче дә була ала. Шул хата фикердән чыгып, аларга тәрҗемә тапшыралар»,— дигән фикере белән минем һич килешәсем килми. Минемчә, үзе әйбәт шагыйрь булмаган кеше әйбәт шигъри тәрҗемәләр дә бирә алмый. Үз шигырьләре белән артык танылмаса да, тәрҗемәченең җанында шагыйрь ятарга тиеш. Безнең Мәскәү нәшриятында чыккан күп кенә китапларыбыз ни өчен үзәк матбугат битләрендә рәтләп телгә дә алынмый? Чөнки аларны әлеге дә баягы тәрҗемәчелекне кәсепкә әйләндергән кешеләр эшли. Дөрес, яхшы шагыйрьләр дә кайчак начар тәрҗемә бирәләр, ләкин начар тәрҗемәчеләр нинди генә яхшы подстрочниктан да әйбәт шигырь тудыра алмый. Аерма менә шунда. Шуңа күрә, әгәр миннән: «Үз әсәрләреңне танылган шагыйрь тәрҗемә итүне теләр идеңме, әллә тәрҗемәчеме?» — дип сорасалар, һичшиксез, өстенлекне шагыйрьләргә бирер идем.

Моннан берничә ел элек, каракалпак язучыларының бер җыентыгын тәрҗемә иткәндә, миңа да катнашырга туры килде. Дөресен әйтергә кирәк, подстрочникларны беренче тапкыр укып чыккач утырып еларлык иде. Ярый әле каракалпак дуслар әсәрләренең подстрочнигын гына түгел, үз телләрендә чыккан оригиналын да җибәргәннәр. Икесен дә чагыштыра-чагыштыра (безнең телләр шактый якын) эшләгәч — матур гына, безнең үз әдәбиятыбыз югарылыгындагы китап килеп чыкты. Рәис Сафаровның югарыда әйткән фикерен шушы мисал белән дә кире кагарга була. Чөнки бу китапны чыгаруда танылган язучылар, шагыйрьләр катнашты. Аннан әлегрәк азәрбайҗан теленнән «Каспий дулкыннары» дигән шундый бер җыентык чыккан иде. Бу җыентыклар безнең әдәби процессыбызда нинди дер эз калдырган һәм укучылар күңеленә юл тапкан икән (ә ул китаплар тиз сатылып бетте), димәк, тәрҗемәчеләр, бу очракта язучылар, шагыйрьләр үз эшләрен югары профессиональ югарылыкта эшләгәннәр дип әйтә алабыз.

Кайбер әдипләр, шагыйрьләр тәрҗемә эшенә теләмичә алыналар. Анысы икенче эш. Чөнки авырсынып тотынганда яки тәрҗемәне чын иҗат дип карамаганда, уңышка ирешү икеле. Ныклап тотынганда да әле әсәрнең рухына, стихиясенә кереп китү авыр. Бервакыт миңа В. Шукшинның «Энергичные люди» пьесасын тәрҗемә итәргә туры килде. Г. Камал исемендәге академия театры аны «Эшнәләр» исеме белән сәхнәгә куйды. Ләкин бу әсәр сәхнәдә озак бара алмады. Монда тәрҗемәче (бу очракта мин) гаебе дә булгандыр дип уйлыйм. Чөнки мин Шукшинның теленә ачкыч таба алмадым шикелле. Ә телгә ачкыч таба алмасаң, әсәрнең рухына төшенеп булмый. Шул ук әсәрне күпмедер вакыттан соң миңа Ленинград артистлары уйнавында карарга туры килде. Һәм шунда мин аларга исем китеп утырдым. «Безнең артистларыбыз да бит талантлылар, димәк, әсәрнең канатсыз чыгуына мин сәбәпче булганмындыр»,— дигән уй күңелне кимерде. Мин тәрҗемәмне яңадан укып чыктым, күп кенә урыннарда чынлап та уңышсыз калькалар киткән, үткен сүзләр үзенең үткенлеген югалта төшкән иде.

Безнең иң авырткан җиребез — татарчадан русчага тәрҗемә итү мәсьәләсе дисәм, ялгышмамдыр. Союз укучысы башка милләт әдәбиятлары белән рус теле аша таныша, рус телендә чыккан тәрҗемә китаплардан чыгып, теге яки бу әдәбиятның зурлыгы турында фикер йөртә.

Әдәбият казанында әзме-күпме кайнаган кеше белә: Мәскәүдә китап чыгару җиңел түгел. Күпчелек очракта Мәскәү нәшриятлары монда эшләнгән тәрҗемәләрне кабул итми, чөнки аларның үз тәрҗемәчеләренә эш кирәк. Шуннан инде автор, үз әсәрен кем тәрҗемә итәчәген дә белмәгән килеш, подстрочник хәлендәге кульъязмасын башкалага юллый. Кульъязма шактый еллар буена үз чиратын көтеп ята, чөнки Мәскәүдә китап чыгарырга теләүчеләр күп. Менә бервакыт аның подстрочник хәлендәге кульъязмасын әдәбият тирәсендә йөргән берәр кешегә эчке рецензиягә бирәләр. Ул әлеге халыкның традицияләрен, культурасын, милли үзенчәлекләрен белгән кеше булса ярый да — ләкин күп очракта алай булмый. Китапның язмышын бик үк әйбәт булмаган подстрочникларга карап, синең иҗат алымнарыңны, образлар белән эшләү юлларыңны төшенергә тырышып та карамаган очраклы кешеләр хәл итеп куярга мөмкин. Озак вакыт өметләнеп йөргәннән соң, кульъязмаң, таушалып, искереп кире үзеңә кайтып керә. Әйе, чын мәгънәсендә искереп. Чөнки ул әсәрләрне инде син моннан шактый еллар элек иҗат иткәнсең. Ни генә әйтмә, башта үз телеңдә китап чыгарыр өчен байтак чәч агартырга туры килә. Мәскәүгә барып җиткәнче әсәрең дә, үзең дә картая башлыйсың. Ә бит үз вакытында әйтелгән сүзнең генә кыйммәте бар. Талантлы кешенең таланты сүзне үз вакытында, үз урынында әйтүдә дә күренә. Әмма безнең күп кенә талантлы әдипләребезнең сүзләре үз вакытында зур аудиторияләр аша ишетелерлми. Тәрҗемә ителми яткан әсәрләребездәге оригиналь идеяләр, яңа образлар башка әдәбиятларда күренә башлый. Шуннан соң гына без: «Кара әле, мондый характерлар, мондый проблемалар безнең әдәбиятта фәлән язучының фәлән әсәрендә күтәрелгән иде»,— дип, шул әсәрне тәрҗемә итә башлыйбыз. Ләкин бу әсәр инде әллә ни зур яңгыраш ала алмый. Чөнки бөтенсоюз уку-

чысы өчен инде ул үтелгән этап була.

Тәрҗемә эшенең үз агымына куелуы аркасында аерым авторлар гына түгел, безнең әдәбиятыбыз да күп югалта. Шул ук вакытта өлгерләр, ертлачлар, шомалар әллә нинди ярык-тишекләрдән узалар, ниндидер юллар белән китапларын чыгаралар. Биредә, Мәскәүдә чыга торган авторларыбыз барысы да шундыйлар гына икән дип аңлашылмастыр шәт. Әйе, әйбәт китаплар, әдәбиятыбыз йөзенә кызыллык китермәслек әсәрләр дә чыга. Алары күбрәк тә.

Әдәбият тирәсендә йөрүче очраклы кешеләрнең әсәрләренә юлны ябу һәм зур тиражлар белән бөтенсоюз укучысына таратмау өчен тәрҗемә эшендә ниндидер үзгәреш кирәклеге барыбызга да мәгълүм. Бу үзгәрешнең асылы нәрсәдән торырга тиеш — менә аны бергәләп уйлашасы бар әле. Минемчә, яхшы әсәрләребезнең подстрочнигы начар булуы аркасында гына кире кагылуын булдырмас өчен, нәшриятлар эчке рецензиягә биргәндә, үзе рецензияли торган авторның иҗаты белән әзме-күпме таныш булган һәм шул милли әдәбиятның үзенчәлекле якларын башка әдәбиятлардан аера белә торганрак кешегә бирергә тиешләр. (Юкса рецензия белән генә кәсеп итеп йөрүчеләр кулына эләгеп, союз күләмендә яңгырарлык әсәрләребез дөнья күрми, яки күпмедер вакытка томаланып калуы мөмкин). Беренче карашка бу булмастай эш кебек тоелса да, моңа ирешердәй юллар табарга мөмкин. Әйтик, безнең кайсы да булса язучыбыз яки шагыйребез Мәскәү нәшриятына үзенең кулъязмасын җибәрә, ә нәшрият ул кулъязманы (подстрочнигы белән оригиналын бергә) рецензияләү өчен кире үзебезнең союзга кайтара. Монда татарчаны да, русчаны да яхшы белгән язучылар эчке рецензия вакытында подстрочник белән оригиналны чагыштырып карап объектив бер нәтиҗәгә килә.

Монда: «Мәскәү безнең рецензияләребезгә карап кына нәшрият планнарына китабыбызны кертер микән соң?» — дигән сорау туарга мөмкин. Ә нигә кертмәсен икән?! Ә инде Мәскәү нәшриятлары белән безнең союз арасында кәгазь киртәләр калкып чыкмасын дисәк, Мәскәү нәшриятына теге яки бу әсәребезне баштан ук үзебезнең язучыларыбыздан рецензияләтеп җибәрергә кирәктер.

Тәрҗемә әсәренең җаны калсын дисәк, минемчә, әсәрдәге һәр сүзгә ябышып ятарга ярамый. Тәрҗемә — ул әсәрне яңадан тудыру. Икенче тапкыр туган җан иясенең бераз башкачарак булуына гаҗәпләнмәскә кирәктер. К. Чуковский: «Точная, буквальная копия того или иного произведения поэзии есть самый неточный, самый лживый из всех переводов»,— дигәндә, мөгаен,карап торуга бөтен нәрсәсе булган, ләкин җаны гына булмаган тәрҗемә турында әйткәндер. Әйтик, Хәсән Туфан шигырьләренең моңын, Һади Такташның юморын, Җәлилнең читлеккә ябылган коштай талпынуын яки сагышлы елмаюын башка телләргә ничек бирергә? Әллә без бары тик татарча гына моңая, татарча гына елмая алабызмы?

Тәрҗемә эше — зур эш, катлаулы эш. Һәр съездда бу мәсьәләгә кагылышлы кайнар-кайнар сүзләр сөйләнә. Ләкин йөк һаман үз урынында кала бирә.

Әсәрләребезне рус теленә генә түгел, башка тугандаш халыклар телләренә дә тәрҗемә итү турында уйларга вакыт. Моннан берничә ел элек казах телендә татар язучыларының повестьлары, каракалпак телендә шигырьләр һәм хикәяләр җыентыклары чыккан иде. Мондый җыентыкларны бәйрәмнән бәйрәмгә (алар безгә, без аларга барганда) генә түгел, системалы рәвештә чыгару юлларын табасы иде. Грузин, әрмән, эстон, латыш әдәбиятлары кебек бай традицияләре булган әдәбиятлар арасында иҗади күпер салынса, безнең әдәбият та, алар да отар гына иде. Чөнки безнең илебез халыкларына бер дә оялмыйча күрсәтерлек байлыгыбыз бар.

«Казан утлары» тәрҗемә мәсьәләсенә кагылышлы дискуссия башлап җибәреп, бик күркәм эш эшләгән. Бу бәхәстә тәрҗемә эшен яхшырту турында уртак бер фикергә киленер дип ышаныйк.

## Венера Вәлиева:

Без, Татарстан язучыларының чираттагы съездына барган бер төркем кунаклар, Мәскәүгә кайтып килә идек. Поездда шулай бит инде ул — һәммәсен сөйләшәсең, тикшерәсең, аңлашасың... Без дә юл буе үзебезнең фикерләребез, тәэсирләребез белән уртаклаштык, Казанда күзебезгә чалынган яңалыклар хакында сөйләштек... Әле дә булса исемдә: әдәби тәрҗемә турында сүз чыккач, танылган яшь шагыйрә болай дип әйтеп куйды:

— Шигъриятне башка телгә тәрҗемә итү бик тә авыр эш булып тоела миңа. Аңа көчем җитмәс иде минем... Бигрәк тә тәрҗемә ителергә тиеш шигъри әсәрне нечкәләп тойган кешегә тәрҗемә итү авыр эш...

Ул вакытта үземнең аңа ни дип җавап биргәнемне инде хәтерләмим, әмма бу сүзләргә гаҗәпсенүемне онытмыйм. Бүгенге татар шагыйрәсенең шулай дип әйтүенә мин чын-чыннан аптыраган идем әлеге әңгәмәдә.

Шигъри әсәрләрне тәрҗемә итү авырмы? Безнең аксакалыбыз Нури ага Арслановка үзенең яраткан шагыйре Пушкин-

ның түбәндәге юлларын татарчага тәрҗемә итү авыр булгандыр:

Күкне каплый җил дә давыл,
Кар бурап, уйнап йөри,
Бер бүре кебек улый ул,
Бер бала кебек елый.

Менә бу юлларны уку үзе генә дә шуның хәтле зур ләззәт бирә, ә ул тәрҗемәнең авторы булу әле нинди бәхеттер?! Мин моңа чагыштыру да таба алмыйм...

Әлбәттә, кыенлыклар да бардыр, ансыз булмас. Анысы табигый. Ләкин алар — кояшның күзне чагылдыруы, каты салкын көнне сулыш алу кыенлашу кебек — табигый кыенлыклар. Алардан куркырга кирәкми!

Ә чыннан да телне белгән кешегә тәрҗемә итү авырракмы соң? Дөнья әдәбияты тәҗрибәсенә мөрәҗәгать итсәк, күрербез: биредә телне белмәгән килеш, подстрочник аша гына тәрҗемә итү — мәгънәсез эш санала. Оригиналны үз телендә уку, аңлау, тою биредә мәҗбүри таләп булып яши. Тик безнең татар поэзиясен тәрҗемә иткәндә генә, ни өчендер подстрочник аша да эшләргә мөмкин. Сәер! Хәтта әле үзебез, киресенчә, телне белү тәрҗемәчегә эшне авырайта дип торабыз.

Фикерне раслау өчен әллә ни ерак барырга кирәк түгел. Шул ук Н. Арсланов мисалын алыйк. Пушкинны үз телендә укымаса, аңламаса, тоймаса — аның тәрҗемәсе шуның кадәр уңышлы килеп чыгар иде микән? Юк, мин алай дип ышандыра алмыйм!

Әлбәттә, начар шигырьләр килеп эләксә, үзеңне мәҗбүр итү авыр. Ә менә подстрочник аша эшләүчегә мондый хәлдә үзеннән өстәргә мөмкинлек кала. Ләкин шунысы бар: әле мондый юл белән бер генә тәрҗемәченең дә яхшы поэзия әсәре китереп чыгарганы юк. Бу — урта кул поэзияне ишәйтү юлы гына. Чын-чыннан поэзия әсәре булган шигырьне исә, һичшиксез, шагыйрьнең үзенчә тәрҗемә итәргә кирәк. Мисал өчен, әгәр дә Әнвәр Давыдов бер әсәрендә:

Хәтерләмим, кайда соң
Мин сине күргән идем?
Охшап тулы айга син
Төшкәме кергән идең? —

дип яза икән, ул инде русча да нәкъ Әнвәр Давыдов сыман яңгырарга тиеш:

Не припомню, где ты мне
В первый раз явилась?
Полною луною во сне,
Может быть, приснилась?

Һәм инде укучыларга яхшы билгеле булган «Сабантуй» поэмасын алсак та, рус укучысы аның беренче юлларыннан ук татар шагыйре Ренат Харисның үзенчәлекле поэтик йөзен күреп алырга тиеш:

Хорошо пройтись деревней
на горячем скакуне,
вызывая восхищенье
яркой сбруей на коне,
гривой, карим конским оком,
звонким цоканьем копыт,
как прилип народ у окон,
у ворот народ стоит.

Без, һәр шагыйрь үз йөзен саклап калырга тиеш дибез. Ләкин бу үзенчәлекне, аерымлыкны кайсы укучы танып алырга тиеш соң? Әлбәттә, татар шагыйрен русчага тәрҗемә итәм икән, мин инде аның рус поэзиясе өчен күренеш булып өлгерүен телим. Бүгенге көндә бик күбәйгән тәрҗемә әсәрләр арасында һәр автор үз йөзен саклап калган булырга тиеш. Моңа ничек ирешергә соң? Минемчә, иң беренче чиратта, тәрҗемә оригиналга аһәң, яңгыраш ягыннан охшаш, адекват булырга тиеш. Ә моны кем белә һәм тикшереп карый ала? Бары тик ике телдә укучы кеше генә. Хәзер бит инде безнең мондый укучыларыбыз да аз түгел.

Чыннан да, әнә инглиз шагыйрьләренең тәрҗемә әсәрләре ике телдә дә басыла бит. Бер якта әсәрнең оригиналы була, ә икенчесендә — аның тәрҗемәсе. Минемчә болай эшләү оригиналга хөрмәт дигән сүз. Укучыга аның рухын да, формаль якларын да күзалларга ярдәм итү дигән сүз. Бездә сирәк кенә басыла торган сувенир китаплар, кызганычка каршы, андый максатны бик үк күздә тотмыйлар.

«Сез, татар шагыйрьләре, үз иҗатыгызга игътибарлы караш булсын өчен тырышасызмы соң?» — дип сорыйсым килә минем кайвакыт кешеләрдән. Һәм Муса Җәлилнең яшьлек шигырьләреннән берсен — «Мин булырмын» шигырен русчага тәрҗемә итү процессы хәтергә килә. Бу әсәргә яшь егетнең керсез хисләре һәм алдан ук ниндидер трагедия сизенү тойгысы шулкадәр мул сыйдырылган — миңа аны русча яңгырату өчен ике еллап вакыт кирәк булды. Яшь Җәлилнең кристаллдай сафлыгына һич кенә дә хыянәт итәсем килмәде! Ә инде үземнең әнә шул тәрҗемәмне бастырыр чак җиткәч, шагыйрьнең һәр сүзе, һәр ноктасы өчен чын мәгънәсендә көрәштем. Менә әлеге шигырьдән бер өзек:

И из кувшина твоего напьется,—
Не осуждай его за вольность эту:
То при последнем издыханье бьется
Святое сердце — я буду это.

Тагын подстрочниклар турында берничә сүз. Алар, әлбәттә, телне белмәгән тәрҗемәчеләргә ярдәм итү өчен эшләнә. Безнең күп кенә зур шагыйрьләребез рус укучысына әнә шул юл белән җиткерелә. Бу ысулның зур таләпкә җавап биреп бетерә алмаганлыгы хәзер инде көннән-көн ачыграк күренә бара. Чөнки үзең ишетмәгән нәрсәне ничек итеп башкаларга көйләп бирмәк кирәк? Подстрочник әнә шул бит инде ул! Минемчә, подстрочникны музейга куяр көнгә инде бик үк ерак калмаган булырга тиеш!

Югарыда әйтеп үтелгән ике телдә укучы кешеләрне дә мин уйлап чыгармадым. Югары культуралы һәрбер кеше башка телне белү өстенә хәзер үз телен һәм культурасын яхшы аңларга, белергә тиеш. Бу — безнең тормышыбыз кагыйдәсе. «Сабантуй» поэмасында ул хакта менә мондый юллар бар:

Чтобы зваться человеком —
это понял я давно —
нужно быть не только с веком,
а с народом заодно!

«Ул вакытта бәлки тәрҗемә эше гомумән дә бетәр?» — дип каршы төшүчеләр табылуы мөмкин. Юк, ул бетмәс — бары тик тагын да югарырак баскычка гына күтәрелер! Чөнки тормыш шуны таләп итәчәк!

*Мәскәү.*

## Илдус Миңнеханов:

Күргәнегез бардыр инде: хатын-кыз, кер юганда, затлырак киемнәрне аралап куя, беркайчан да кайнар суга китереп тыкмый. Шулай да беркөн үземнең иң «фыртный» дигән күлмәгем ялгышлык белән машинага салынып, кайнар суда ярты сәгатьләп пешкәч, карарлыгы калмаган иде...

Кайбер әдәби әсәрләрнең дә, әнә шулай, тәрҗемәдән соң нык кына «уңып» калуын күрәсең. Моның сәбәпләре билгеле дә була: я тәрҗемәче ике телне дә җитәрлек яхшы белми, я ваемсызлык күрсәтә. Ләкин кайчакта оригиналның төсе китүен сизеп торасың, нигә икәнен аңлап булмый. Милли колорит юк дисәң, ул «апа-абзый»лар җөмлә саен диярлек, әчтәлек туры килми дисәң, чатнап тора, хәтта тылмач та шулкадәр төгәл итеп бирә алмас. Шулай серле рәвештә былтыр минем зәңгәр кәчтүмем дә химчисткадан «агарынып» кайткан иде. Сәбәпләре соңыннан билгеле булды — тик былтыргыны быел сөйләп тормыйм. Ә менә әлеге тәрҗемәләр турында бер фикер бар — уртага салам.

Билгеле булганча, һәр язучының үз стиле була. Укучыны әсәрдәге тормыш әченә гаҗәеп маҗаралар, кызыклы «тарихлар» түгел, ә бәлки нәкъ менә көчле, үзенчәлекле стиль алып керә дә инде. Әгәр дә тәрҗемәче язучы стиленнән аерылмаса, башыннан ахырына кадәр «бер аяктан» барса — бу гаять зур уңыш булыр иде. Гәрчә бүген андый «җимешләр» белән артык мактана алмыйбыз әле. Стиль югалту һаман да зур югалту булып кала. Чөнки кайбер тәрҗемәчеләр стильне бөтенләй исәпкә алмый, ә бер ишеләре, әһәмият бирсә дә, әчтәлек белән мавыгып китеп, күздән ычкындыралар. Шуңа өстәп, стиль бит ул өстә генә ярылып ятмый, кайчагында аны күрүе, тануы да кыен. Менә язучы җөмлә укылышын юри әкренәйтә: өтерләр тутыра, «гаҗәбрәк» яисә авыр укыла торган сүзләр кыстыра — ничек тә укучы бу урынны тиз генә узып китмәсен, ди. Әгәр ди инде син бу җөмләне кыска гына, «нормальный» бер-ике сүз белән тәрҗемә итәсең икән, әчтәлек никадәр төгәл бирелмәсен — язучы теләгән эффект барып чыкмаячак. Бушлык туачак. Мондый бушлыклар, ахыр килеп, тәрҗемәне тоныкландыра, әсәрнең йөзен боза. Ә инде бүгенге әдәбият дөньясына чыга икән, ул анда үзенә урын таба алмаячак.

Нәтиҗә чыгарып, шуны әйтәсе килә: тәрҗемә процессында иң мөһиме — язучының стилен күздән ычкындырмау. Үз стилеңне һәрвакыт тезгендә тотып, һәртөрле редакцион үзгәртүләрне соңгы чиктә генә кулланырга кирәк.

*Әгерҗе.*

# «КӨМЕШ ЧЫЛБЫР» БОҖРАЛАРЫ

Рухи тормышын сүз сәнгатеннән башка күз алдына да китерми торган һәр укучы, мөгаен, вакыт-вакыт, башына кинәт уй төшеп, туган әдәбиятының киләчәген күзалларга омтыладыр — яшь иҗат көчләрен күңеленнән генә булса да берәм-берәм барлап карамыйча булдыра алмыйдыр. Мин үзем, мәсәлән, шулай уйлангалыйм. Ләкин, әдәбиятка бу хезмәт итәчәк әле дип, тәгаен ышаныч багларлык андый талантларның исемлеге һәр очракта да, кызганычка каршы, бик кыска килеп чыга. Күңелемдә үзем өчен генә төзегән шул кыска исемлектә Солтан Шәмси исеме дә бар. Мин аны анда моннан өч-дүрт ел элек, «Казан утлары» журналында бер-бер артлы дөнья күргән «Балконда» һәм «Соңгы юаныч» дигән хикәяләрен укыгач, теркәп куйган идем. Әлеге әсәрләр сәләтле каләм иясенең әдәбият мәйданына аяк басуын хәбәр итеп кенә калмады, ә бәлки әдәбият мәйданына чыккан һәр яңа исемгә теләктәшлек белән караучы укучыларның күңелен яулап алырга да өлгерде. Һәм менә аның әсәрләре аерым китап рәвешендә басылып чыкты [1].

Дөресен генә әйткәндә, бу күптән көтелә иде инде. Чөнки М. Горький исемендәге әдәбият институтында укып кайтканнан соң әдәби тәрҗемә эше белән шөгыльләнүче бу егетнең төпле әдәби әзерлеккә ия икәнлеге күренеп тора иде. Аның киң катлам укучыларга әйтәсе сүзе булмау мөмкин түгел иде. Әдәби түгәрәкләрдәге әңгәмәләрдә булсын, яшьләр арасындагы төрле бәхәсләрдә булсын, ул үзенең тормышка, әдәбиятка карата үзенчәлекле карашлары, дәлилле фикерләре белән күзгә ташлана иде. Һәм шул ук вакытта аның күңел төбендә, җанын кымырҗытып, нindидер сер ятканлыгы, нindидер мөһим нәрсәне әйтеп бетермәве дә сизелеп киткәли иде. Ул язган икән. Шауламый-кабаланмыйча гына, әдәбиятка килергә, анда үзенә лаек урын табарга әзерләнгән икән.

Кайчандыр С. Шәмсинең журналда басылган «Соңгы юаныч» исемле хикәясе турында үз фикеремне язып чыгарга туры килгән иде инде. Бу әсәр мине, беренчедән, ифрат катлаулы мәсьәләләрне мөмкинлекләре чикләнгән кечкенә жанр кысаларында шактый сыйдырышлы чагылдыра алуы белән җәлеп иткән булса, икенчедән — һәм монысы, мөгаен, иң мөһимедер — яшь язучы үз каләменең бик әһәмиятле көчкә ия икәнлеген күрсәтүе — гадәттән тыш вакыйганың безнең бүгенге тормыш өчен асылда бик табигый булуына ышандыра алуы белән күңелемне яулаган иде.

Хикәя нигезендә яткан вакыйга менә нинди. Гомеренең ахыргы елларын шәһәрдә уздыручы карт, карчыгы дөнья куйгач, сәер-сәер эшләр эшли башлый. Дачасындагы җиләк-җимеш агачларын кисә һәм түтәлләрен казый. Анда үлән чәчеп үстерә, аны чаба, киптереп, кибәнгә куя, шул эштән хозурлык табып йөри. Менә шушы гайре табигый вакыйганы тасвирлау барышында автор укучыны кеше һәм аның табигый асылы турындагы уйлануларга, хәзерге тормышның гаять катлаулы процессларын күңелдән кичереп, зур гомумиләштерүләр ясауга китерә. Бу вакыйга — баксаң, авылда туып үскән, ярты гомерен авылда үткәргән Картның үз табигатенә, асылына туры килми торган шәһәр шартларына каршы, тагын да гомумирәк карaганда, хәзерге шәһәр паркларына, басу читләрендәге урман полосаларына, Карт ише гамьле, моңлы кешеләрнең күңел төпкелләренә сыенып, сакланып калган Табигатьнең үзенә зыян китерүче цивилизациягә, дөресрәге, аның кара көчләренә каршы баш күтәрүе икән. Шушы хәл вакыйганың чын булуына, табигыйлегенә ышандыра, хикәядә азмы-күпме чагылыш тапкан башка четерекле проблемаларны аңлауга җирлек була. Проблемаларның башкалары да бик актуаль һәм, әйтергә кирәк, хәтта җан

---

[1] Солтан Шәмси. Көмеш чылбыр. Татарстан китап нәшрияты, 1984.

әрнеткеч. Болар — урбанизация процессы бара торган хәзерге тормышта милли культура казанышларын, өлкән буын күңелендә саклаучы рухи тәҗрибәне яшь буыннарга тапшыру мәсьәләсе, яшьләрнең урбанизация нәтиҗәләре йогынтысына ныграк бирелүе аркасында буыннар бәйләнешенә өзеклек янавы...

Менә шушы катлаулы мәсьәләләрнең үзара диалектик бәйләнешен, асылын тоя, аңлый һәм аңлата алуы, кечкенә генә бер хикәя мәйданында аларны бер төенгә төйнәп, сәнгатьчә гәүдәләндерә алуы белән С. Шәмси үзенең җитди каләмгә ия булуын раслады.

Сәнгатьлелек телгә алынган икән, фикер сөрешен өзеп булса да, хикәянең художество камиллеген бозып торган бер кимчелекне әйтеп үтмичә ярамас. Хикәядә шундый эпизод бар. Карт шаулап үсеп килгән печәненә карап утырырга ярата, кичләрен аның янына күрше-күлән җыела, сөйләшеп утыралар. Шундый сөйләшүләрнең берсен автор тулысынча китерә. Чөнки ул — укучыга әсәрнең төп идеясен аңлауда ярдәм итәргә тиешле, табигать белән кеше арасындагы мөнәсәбәтләр турындагы бик мөһим сөйләшү. Ләкин бу эпизод әсәр тукымасыннан ничектер бүселеп чыгып тора, артык сыман тәэсир кала. Ә хикмәт — шунда. Персонажларның берсе, яшь галим, әңгәмәдәшләренең соравына җавап биреп, озын һәм озак итеп, әлеге проблема турында сөйли. Яшь галимнең проблемага карата оригиналь үз концепциясе булса иде ул, төс-кыяфәтсез персонаж булып түгел, истә кала торган образ сыйфатында ачылып китәр иде яшь галим. Эпизод тәэсирлерәк килеп чыгар иде, хикәянең төп идеясен ачуга нәтиҗәлерәк тә хезмәт итәр иде, танып-белү, информацион яктан да укучыга файдалырак, димәк, кызыклырак булыр иде. Әмма автор яшь галимнән соңгы елларда көндәлек матбугатта, фәнни-популяр китапларда кат-кат язылудан төссезләнеп беткән фикерләрне генә әйттерә. Шуңа күрә эпизодның эстетик йөкләмәсе чамалы булып чыга. Шушы хәл эпизодның, димәк, хикәянең дә, художество әһәмиятенә берникадәр күләгә төшерә. Шулай да теманы ачудагы оригинальлеге, мәгънәви тирәнлеге, әһәмиятлелеге белән әлеге әсәр китаптагы башка ун хикәянең барысыннан да аерылып тора. Бәлки, шуңа күрәдер, тагын да әйбәтрәк язылган берәр хикәя очрамасмы, язучы тагын берәр матур ягы белән ачылып шатландырмасмы дип өметләнеп укысам да, китап минем С. Шәмси иҗаты турындагы фикеремне әллә ни үзгәртә алмады. Димәк, аның башка әсәрләренә әлеге дә баягы «Соңгы юаныч» һәм «Балконда» хикәяләре югарылыгыннан карап бәя бирергә туры килә.

«Балконда» хикәясендә тасвирланган вакыйга, «Соңгы юаныч»тан аермалы буларак, шактый гади. Әсәрнең герое Җиңү бәйрәме көнне ерак туганы — Бөек Ватан сугышы ветераны, инвалид абыйсы янына хәл белешергә керә, бергә сөйләшеп утыралар... Хикәя мәгънә төсмерләренә бик бай, анда чагылган хис-тойгылар, җем-җем уйнап, үзгәреп тора. Мондый әсәрне кат-кат укырга була. Укыган саен, күңел халәтеңә, кәефең торышына карап, анда яңадан-яңа нюанслар, мәгънәви тирәнлекләр табасың. Төп идеясе гади кешенең күңел олылыгын күрсәтүгә, аның һичшиксез, илтифатка лаек икәнен искәртүгә кайтып кала кебек.

«Балконда» — хикәяләү рәвешенең бездә канунлашкан формасын яшь язучының ни дәрәҗәдә яхшы үзләштерүен күрсәтүе белән характерлы. Биредә һәр деталь «эшли», һәркайсының үз йөкләмәсе бер, һәркайсы укучыны язучы аңлатырга теләгән төп фикергә таба илтә. Бер мисал алыйк. Герой белән инвалид карт сөйләшеп утырганда, чырт-чырт иткән сәер тавышлар чыгарып, эт узып китә. Сәер тавышны аның озын тырнаклары чыгара икән. Иң элек бу деталь кызыклы күзәтү буларак игътибарны җәлеп итә. Ләкин мондый сыйфат кына әле аны художестволы деталь итә алмый, билгеле. Аның хикәядәге төп йөкләмәсе — инвалид карт белән геройның әңгәмәләре ябышып китә алмыйча торган уңайсыз бер моментта бүлмәдә нинди тынлык хөкем сөрүен күрсәтү. Шәһәрдә, бөтен илдә бәйрәм шау-шуы, ә монда ниндидер уңайсыз тынлык. Эт адымнарыннан чыккан тавыш түгел, әнә шул тынлык сәер икән. Ә тынлыкны күрсәтү хикәя өчен шулай ук мөһим, ул, бүлмәдәге халәттән тыш, карт белән карчыкның тыйнак һәм тыныч күңелләрен характерлау өчен дә кирәк.

Янсә менә икенче бер мисал:

«Ишектә кабат Гайшә апа күренде.

— Әйдагез өстәл янына, чәй әзерләдем,— диде ул һәм, картына аркасын куеп, карават кырыена килеп утырды. Кадыйр абый аны кочаклап алды. Гайшә апа картын, аркасына асып, күрше бүлмәгә алып чыгып китте һәм урындыкка китереп утыртты. Урындыкны мин өстәл янына этәрдем».

Шушы бер күренештә бу өй эчендәге бәләнең никадәр тетрәнгеч һәм зур икәнлеге дә, карт белән карчыкның аңа никадәр иләшкәнлеге дә, алар арасындагы мөнәсәбәтләрнең никадәр гади һәм җылы икәнлеге дә ачылып китә. Хикәя шушындый детальләре белән күңелне әсир итә. Кыскасы, автор хикәя язу сәнгатенең төп хикмәтләреннән саналучы детальләштерү алымын яхшы үзләштергән. Моны китап-

тагы «Бәхетле песи», «Беренче кар», «Нәни дус» кебек хикәяләр дә расльй. Болар — шактый тигез язылган әсәрләр.

Әмма китаптагы әсәрләрнең барысы турында да болай әйтеп булмый. Үзенчәлекле манерада язылулары белән өч-дүрт хикәя бигрәк тә аерылып тора. Аларга аерым тукталырга кирәктер. Минә калса, алар С. Шәмсинең иҗади эзләнүләре характерын аңларга ярдәм итәрләр шикелле.

Әдәбиятта күренекле немец язучысы Б. Брехт исеме белән бәйле «интеллектуаль әдәбият» дигән бер күренеш бар. Сәнгать әсәре кешенең иң элек хисенә һәм шуның аша гына акылына тәэсир итә дип өйрәтә традицион әдәбият фәне. Ә менә Б. Брехт — шушы традицион кагыйдәгә каршы чыгып, үз концепциясен төзегән һәм шуның буенча иҗат иткән язучы. «Интеллектуаль әдәбият» күбрәк укучының акылына тәэсир итүне һәм шул юл белән аны тәрбияләүне бурыч итеп ала. С. Шәмсинең әлеге хикәяләрен мин менә шушы концепция корбаннарыдыр дип уйлыйм. Моның шулай икәнлеген расльй торган дәлилләр аларда шактый җыела. Ул тасвирлау аша түгел, ә сөйләп аңлату аша, ягъни укучының хисенә түгел, бәлки турыдан-туры акылына тәэсир итәргә тели. Әлеге хикәяләргә нигез итеп, махсус рәвештә, яңалык дәрәҗәсе бик чамалы булган коллизияләр — көндәлек тормышның вак конфликтлары алынган. Хискә, гадәттә, иң элек, яңалык, көтелмәгәнлек тәэсир итә. Әсәрләрдә шушы фактор аңлы рәвештә төшереп калдырылган. Мәсәлән, «Якты утрау» хикәясендә сурәтләнгән вакыйганы алыйк. Ир белән хатынның аралары суына башлаган була. Күңел ихтыяҗлары югарырак булган ирне яшь хатын юк-бар таләпләр, шикләнүләр белән борчый, аны аңлый алмаудан үзе дә җәфалана. Хатыны балага узгач, ирне ике айга командировкага җибәрәләр, ул аннан өен, гаилә тормышын сагынып кайта. Хатыны исә туачак бала турындагы уйларга баштанаяк чума, аңарда яңа төр хисләр уяна, ул вак-төяк бәйләнүләрен оныта, ирен сагынып көтеп ала. Бәхетле гаилә тормышы шулай яңадан тернәкләнеп китә. Әсәрнең фабуласы шуннан гыйбарәт. Язучыны биредә (шулай ук «Нихәл, дустым?», «Сагыну» хикәяләрендә дә) кешеләр арасындагы каршылыкларның нигезендә яткан психологик көчләр җәлеп итә. Ә кешеләр фикергә иллюстратив материал кебегрәк кенә тоела. Әсәрнең төп герое — әнә шул тотып карап, күрсәтеп булмый торган, чырай-килбәтсез гомуми көчләр. Абстракт рухи көчләр. Ә боларга, мәгълүм ки, бары тик акылның гына «теше үтә».

«Нихәл, дустым?» исемле хикәясендә автор ир белән хатын арасындагы мөнәсәбәтләрнең үтә дә нечкә булганнарын, четерекләләрен ачып бирергә алына. Язучы ул мөнәсәбәтләрне диалектик катлаулылыкта тоемлый. Әмма менә шуны күңел канәгатьләнер дәрәҗәдә тулы итеп укучыга җиткерә алмый. Тасвирлыйсы урында аңлата башлый. Ә аңлатуның иң әйбәте дә берьяклырак була, ахыр чиктә гадиләштерү булып чыга. Мөнәсәбәтләрне картина аша, халәт аша аңлату түгел бу, бәлки сөйләп аңлату. Барысын да аңлатыйм дисәң, сүзләр бик күбәеп китә. Күпсүзлелектән качыйм дип, мөнәсәбәт-бәйләнешләрнең бик үк мөһим тоелмаганнарын телгә алмый башласаң — примитивлаштыру, схема килеп чыга.

Тасвирлау урынына проблеманы сөйләп аңлату стихиясенең бу ике төре һәммәсе дә әлеге төркем хикәяләрдә үзен сиздерә. Бөтенесен дә аңлатып бирергә омтылу хәтта әсәрләрнең архитектоникасында да чагылыш таба. Әйтик, «Сагыну» хикәясендә язучы, урыны-урыны белән хикәяләү процессын өзеп, әсәр тукымасына газета материалын хәтерләткән информацион блоклар китереп кертә. Әлеге өзекләрнең теле дә сәнгать әсәре теленнән шактый кайтыш. Анда стереотип гыйбарәләр, публицистик «клише»лар ярылып-ярылып ята. Фикерне турыдан-туры җиткерергә омтылу аркасында «Нихәл, дустым?» хикәясенең кайбер өлешләре бөтенләй шәрәләнеп калган — алар нниндидер зур бер әсәрнең эчтәлеген кыскача сөйләп чыгуга охшап торалар. Авторның аңлый белү сәләте — күренешләрнең асылын билгеләүдәге, гомумиләштерүләр ясаудагы тапкырлыгы гына әлеге әсәрләрне сәнгать чикләре эчендә калдыра. Мәсәлән, «Якты утрау» хикәясен дөрес тотып алынган психологик күзәтүләр генә тулысынча таралып китүдән коткара. Яшь язучы хикәяләүнең яңа формаларын эзли. Традицион формада иҗат ителгән һәм уңыш китергән «Балконда», «Соңгы юаныч» һ. б. хикәяләреннән соң аның кинәт башкача язып карарга теләвенең сәбәпләрен, теләсәң, аңларга буладыр дип уйлыйм. Эзләнмичә, ялгышмыйча гына әле берәүнең дә уңышка ирешкәне юк.

Шагыйрь Р. Харис журналда басылган бер әңгәмәсендә, әдәби иҗат турындагы кызыклы күзәтүләрен уртаклашып, менә нәрсә дигән иде: «Эзләнү — иҗат итү, ягъни иҗат процессы... Процесс күренмәскә, сизелмәскә тиештер дип уйлыйм. Эзләнү иҗатның эчкәрге, яшерен ягы. Аны күрсәтмичә генә укучы аңын шигъри табышка алып барып җиткерә белү осталыктан килә». Төрек шагыйре Н. Хикмәт сәнгать әсәренең формасын хатын-кыз аягындагы нәфис оек белән чагыштырырга яраткан. Үзе күренми, ә аякны матурайта. Кигән оегы җыерылган хәлдә күзгә ташланып

торса, әлбәттә, андый аякны сылу дип булмый. С. Шәмсине әлеге хикәяләрендә шул «оек»ның күренеп торуы харап итә. Күрәсең, осталык җитмидер.

Шулай да мин, китаптагы бик үк уңышлы килеп чыкмаган берничә хикәягә карап кына, төшенке уйларга бирелү дөрес булмас иде дип саныйм. Бөтенләй үк нәтиҗәсез эзләнү түгел ич бу. Әйтик, китапны тәгәлләп куючы «Урталыкта» дигән хикәя — әнә шул эзләнү җимеше. Исеме, дөрес, бик үк яңа түгел. Шуңа күрәдер, мин бу кечкенә новелланы әллә ни яңа нәрсә өмет итмичә генә укый башлаган идем. Ләкин әсәрнең берниче җөмләсен күз йөртеп узуга, бу битарафлыктан арынырга туры килде.

«...Аякларын көч-хәл белән сөйрәп баручы бер әбине күрдем. Өстендә төсен салган иске пальто, аякларында берәрсеннән арткан зур туфлиләр, үзе ябык, кулында гади генә сумкасы, сумканы бер яккарак басып, читеннән ике кефир шешәсе күренә. Җыерчыклы саргылт йөзе тәмам кипкән, күзләре сүнгән, юкарган чәчен шакмаклы яулык белән каплаган...»

Теләсә, тасвирлый белә икән бит С. Шәмси. Шушы берничә җөмлә ялгыз шәһәр карчыгының имәнеп китәрлек портретын күз алдына бастыра. Моннан соң инде әсәрне битараф җан белән уку мөмкин түгел. Автор шулай укучыны кызыксындыра да кеше гомере, яшәү мәгънәсе турындагы уйларын — әсәрнең төп мәгънәви эчтәлеген тәшкил иткән фикерләрен язып китә. Бу фикерләр үзләре генә күңелгә болай тирән үтеп керә алмаслар иде, әлбәттә. Ләкин әсәрләнгән җанга алар сары май булып яталар икән. Юк, язучы ялгызак карчык язмышын сөйләп тормый, ул бары новелла герое «мин»нең билгеле бер мизгелдәге уй-кичерешләрен күрсәтеп бирә. Аның кинәт үзен бәхетле, гамьсез яшьлек белән сырхаулы, сыкранулы картлык арасында — урталыкта торуын ничек итеп үткер рәвештә тоеп алуын, шушы аңлау-тоюның ничек итеп тууын — менә шул хис җилпенешен язучы шактый оста тасвирлый. Менә дигән психологик этюд!

«Көмеш чылбыр» исемле китапка кергән хикәяләрне укыгач — көмеш чылбырның бөҗраларын барлап чыккач туган уйларымны йомгаклап, шуны әйтергә ярыйдыр: кызыклы гына прозаик формалашып килә. Әдәбият турында үз концепциясе бар, үз иҗат кредосы бар. Безгә бары Солтан Шәмсидәге иҗади ниятләрнең чынга ашуын күтәргә, тагын да активрак эшләвен теләргә генә кала.

Фәиз ЗӨЛКАРНӘЕВ.

# ЯЗУЧЫ МИРАСЫНДА НИЛӘР БАР?

Кеше, иле турында кайгыртып, гомерен намуслы хезмәт белән бизәп үткәрә икән, җирдә аның яхшы аты, исеме кала, халык аны онытмый. Бу хикмәт әдәбият-сәнгать әһелләренә икеләтә карый. Аларның һәркайсы үзләре иҗат итеп калдырган мирасларында яши. Чөнки һәр авторның дөньяга карашы, изге теләкләре, якты хыяллары, киңәшләре әсәрләрендә чагылган була. Шуңа күрә алар дөньяны тагын да матуррак итеп күз алдына китерергә, аның гүзәллекләре белән канатланып яшәргә, сөяргә, кеше дигән бөек затның кадерен белергә, намуслы булырга әйдиләр.

Г. Минский да әсәрләре аша арабызда яшәвен дәвам итә. Быел сентябрьдә аңа сиксән яшь тулган булыр иде...

Кулына бик яшьли каләм алган Габдрахман совет чоры татар әдәбиятының революцион идеяләр белән рухланып күтәрелгән вакытында мәйданга чыга. 1926 нчы елда Казанга килгәч, аның бер-бер артлы китаплары басыла, пьесалары сәхнәләрдә куела. Г. Ибраһимов, Һ. Такташ, Г. Кутуй яшь язучының әсәрләренә уңай бәя бирәләр һәм аңа зур өмет баглыйлар.

Г. Минский шул заманның алдынгы көчләре белән әдәби процесста, культура, театр эшләрендә актив катнаша, газета редакцияләрендә эшли. 1930 елда ул Казаннан аерылып, Уралда яши, яңа корылып яткан Чиләбе трактор заводы каршында чыккан «Төзү ударнигы» газетасы редакциясенең секретаре була. Мәскәүдә Бөтенсоюз дәүләт кинематография институтында укып, сценарий факультетын тәмамлагач, әзербайҗанлы дуслары аны үзләренә эшкә чакыралар, ул анда Баку киностудиясендә эшли. «Артем атавы», «Яңа тормыш үзәне» исемле документаль картиналар чыга, «Ватан улы» дигән нәфис фильм эшләнә,— аларның авторы Г. Минский. Бөек Ватан сугышының башыннан ук ул фронтта була. Тамань ярымутравын азат итүдә катнаша. Кырымны азат итү өчен барган каты сугышларда авыр контузия ала. Госпитальдә дәваланганнан соң, чик буе гаскәрләрендә хезмәт итә. 1946 елда демобилизацияләнгәч, Бакуда эшли. 1952 елда ул яңадан Казанга кайтып, гомеренең соңгы көннәренә кадәр актив әдәби һәм җәмәгать эшчәнлеге белән яши.

Озак еллар дәвам иткән иҗатында ул «Карт имән», «Ана мәхәббәте», «Язның беренче көне», «Яшенле яңгыр» кебек матур-матур хикәяләр, повестьлар бирде. Аның актуаль темаларга язылган пьесалары вакытында театр сәхнәләрендә куелды, сатирик парчалары, очеркләры басыла килде. Азербайҗанның күренекле язучыларыннан Җ. Җаббарлының «Айдын», М. Хөсәеннең «Апшерон» романнарын татар теленә тәрҗемә итте.

Габдрахман Минский данлы чорыбызның алдынгы омтылышлары белән яшәде һәм истә калырлык матур әдәби образлар иҗат итте. Авторның әдәби архивы да бай. Анда татар әдәбиятының башка милләт язучылары белән элемтәдә яшәүләре, М. Горькийның Казанга килүе, аны каршылаудагы шатлыклы минутларны сөйләгән язмалар, Башкортстанның халык шагыйре С. Кудаш истәлекләре, И. Хәйруллин көндәлекләре, Һ. Такташның кайбер әсәрләренең караламалары, Х. Мөҗәй, К. Нәҗми һәм башка бик күп танылган язучыларның, культура эшлеклеләренең хатлары, Назим Хикмәт, Чыңгыз Айтматов кебекләрнең автографлы бүләк китаплары бар. Болар барысы да, әһәмиятле документлар буларак, киләчәктә өйрәнелер дип өметләнергә кирәк.

Г. Минский дөньяны, тормышны сөеп яшәде, ул кешеләрне яратты. Урамда каршына килгән һәр сабыйга елмаеп үтүендә олы җанлы Габдрахман Минскийның

кечкенәли дөньядан киткән сөекле Фәрхадына булган мәхәббәтенең гомере буена сүрелмәгән чагылышы булган икән.

Язучының сугыш елларында язылган ике хаты укучыларга тәкъдим ителә.

**Шакир АБИЛОВ.**



*Рәсемдә: Габдрахман Минский (сулдан беренче утырган) бер төркем татар әдипләре белән.*

1.VI.42.

Кадерлем, Сәлимә![1]

Сәлам сиңа, сагынып-саргаеп сәлам. Кадерлем Фәрхадыма кайнар сәламнәремне күндерәм. Шулай ук әнигә сәламемне әйтерсең һәм сәламәтлек теләрсең. Барыгызны да бик күрәсем килә. Мин бит хәзер сездән бик үк ерак булмаган җирдә генә яшим,— бары бер тәүлеклек юл. Мин хәзер госпитальдә. Бу турыда сиңа 23 ендә телеграмма белән белгерткән идем. 29 ында дәвалаучы врач синең телеграмманы күрсәтте. Барыгыз да сау-сәламәт икәнсез, бик әйбәт...

Мин үземнең ничек кенә исән калуым турында, ничек итеп кенә диңгез уртасындагы Керчь ярым утравыннан бу як җиргә чыга алуым турында уйлап карасам да, акылым җитми. Бу турыда мин күргәннәрне язып кына аңлатырлык түгел.

7 майда каты сугышлар башланды. 12 көн һәм төн буенча Кырым далаларында кан эчендә, үлекләр арасында, сугыш уты эчендә каңгырып йөреп, 19 ынчы майда иртә белән сәгать биштә мин җир астында калганмын. Бу — минем тереләй күмелүем булган. Күрше окопка төшеп, җәһәннәм тавышлары чыгарып шартлаган снаряд көче белән актарылган җир мине дә күмеп ташлаган... Мин үзем бер нәрсә дә белмим. Мине санитарлар казып алганнар, нindидер бер арбага салып, хуҗасына: кайда кадәр барасың, шунда кадәр алып бар, дигәннәр.

Шулай итеп, арбадан-арбага, машинадан-машинага күчерелеп гизә торгач, Керчьтән ерак түгел Яңа кала диген, диңгез яры буендагы авылга китерелгәнмен... Авылга немецлар керә башлагач, балыкчылар көймәсе белән диңгезне кичеп, икенче якка Тамань авылына, аннан Новороссийск янындагы Тоннельная станциясенә, шуннан Анапайга (Анапага), аннан госпитальнең санитар поезды белән Минеральные Водыга китерделәр. Аннан электричка белән Ессентукига килдем. Монда килеп төшкән

көннән алып, миңа бик ашыгыч һәм чын-чыннан яхшы докторлар ярдәме башланды. Иң элек өч көн буенча күзләремне юып даруладылар. Алар бик начар күрә, уң күзем бөтенләй күрми иде. Доктор авыру тарихына: тәнендә өлешчә травматик контузия, уң як күзе һәм кулы имгәнгән, дип язып куйды. Дәвалану процедуралары бик күп. Дәвалавы бик яхшы, врачлар да бик ягымлы. Мине Шазали дигән врач дәвалый. Бер тапкыр профессор Теситта булдым (ул — атаклы Клара Цеткинның улы)... Докторлар әйтүенә караганда, мин әле бер ай ярым дәваланырга тиешмен... Аннан икенче бер хәрби формированиегә элэгүем мөмкин. Мин бит синең килеп китүеңне дә телим, ләкин Фәрхад белән килеп булмас дип икеләнеп торам. Килгәндә, үзеңнең һәм Фәрхадның икмәк карточкаларын алып кил. Монда башкасын табып була диләр. Билет ала алсагыз, әни дә килсен. Бер өч-дүрт көн торып китәр идегез. Әгәр дә инде бала белән килү авыр була дисәң, кузгалып та торма, я юлда Фәрхад авырып китүе ихтимал, чөнки хәзер вагонда чисталык юк, һавасы начар...

Мин хәзер үземнең частемнан аерылдым, ялгыз калдым инде, егетләрнең күбесе үлеп, таралып беттеләр. Әгәр мине яңа формированиегә җибәрсәләр, бөтенләй яңа частька эләгәм булып чыга...

Сездән бернинди хәбәр юк, һәм тагын да хәбәрсез калырмын, ахры, чөнки синең бирегә язган хатың килеп җитә алмас кебек сизенәм. Әгәр дә терелеп чыгып, китеп барсам, яңа урыннан хат язып салырмын.

Хәзергә хуш-сау булып торыгыз. Бу хатны алгач, Фәрхадның саулыгын белдереп телеграмма бирерсең.

*Апушың.*

Әни![2] 18.XII.44.

Сиңа бик күп сәлам. Башың сау булсын. Кадерле Фәрхадыбызны[3] җирләгәнсез икән. Әнисе дә, син дә бик көчле яратадыр идегез шул үзен. Ярату-мәхәббәт, бик көчле булса, гомерсез була. Фәрхад белән Ширин мәхәббәте көчле булганы өчен кыска гомерле булган. Нишләмәк кирәк, язмышка каршы барып булмый. Шулай да булса, сугыш белән авырайган өч ел гомерегездә сезгә (ул) бик юаныч һәм шатлык булып яшәде. Тик мин генә рәхәтләнеп, бер туйганчы юана алмадым, кочаклап сөя алмадым, култыгыма алып йоклый алмадым, кулыннан тотып йөри алмадым. Минем өчен ул бала бер матур рәхәт төндә күргән матур, рәхәт төш кебек (кенә) булып калды.

Бүген Фәрхадымның тәттәсе Әминә[4] янына китүенә кырык көн. Кайгыгызны шул кырык белән озатып җибәрегез. Бик озак кайгырырга ярамый. Фәрхадка булган мәхәббәтегезне бер-берегезгә бәйләгез дә яхшы гына, әниле-кызлы булып яшәгез. Авыр еллар бетәргә күп калмады инде. Алдагы елларыбыз җиңел булсын. Тизрәк мин кайтып, бергә шат-бай яшәвебезне теләп дога кыл. Сәлимәгә дә әйт, бик артык кайгырмасын; үгетләп, үзенең күңелен ач...

Үзегезнең ничек яшәвегезне белдереп, миңа хат яз. Нинди теләкләрең, сүзләрең булса, әйтеп яз. Авырмыйсызмы, туңмыйсызмы, ач тормыйсызмы?

Сез анда, көн-төн кайгырып, аш-суыгызны онытмагыз. Мине көтегез. Мин кайткач, насиб булса, яхшы булыр. Хәзергә хуш-сау бул. Миңа хат яз.

*Углың Габдрахман.*

---

[1] Сәлимә Җиһанша кызы Алимова — Г. Минскийның хатыны.

[2] Әнисе — Калбиби Хаҗимөхәммәд кызы.

[3] Фәрхад 1941 елның 23 октябрендә дөньяга килеп, 1944 елның 8 нче ноябрендә үлгән. Атасы аны күрә алмаган.

[4] Әминә — Минскийларның кызы, кечкенәли үлгән.

# ӨМЕТНЕ АКЛАГАН КАЛӘМ

АТИЛЛА РАСИХКА — 70 ЯШЬ



Атилла Расихның исемен атау белән, күз алдыбызга инде күптән әдәбият сөючеләрнең күңел байлыгына әверелгән хикәяләр, повестьлар һәм романнар килеп баса. Ул әсәрләр инде меңләгән татар укучыларының рухи ихтыяҗын үтәүгә, халкыбызның катлаулы һәм бай тормышын сәнгатьчә гәүдәләндерүгә кертелгән җитди өлеш дип танылды, башка телләргә тәрҗемә ителеп, Татарстаннан еракларда да яратып каршыланды.

Атилла Кадыйр улы Рәсүлев 1916 елның 16 сентябрендә Троицк шәһәрендә укытучы гаиләсендә туа. Бала чагыннан ук китап укырга ярата һәм аңарда бик яшьли иҗат дәрте уяна. Үзенең әйтүенчә, ун-унбер яшьләрендә үк инде ул шигырьләр, хикәяләр генә түгел, пьесалар да яза башлый, шуларны күрше балалары белән бергә уйнап та карыйлар. Ундүрт яшендә инде Мәскәүдә чыга торган «Октябрь баласы» журналында аның «Борылышта» исемле беренче хикәясе басыла.

Ләкин чын язучы булып киткәнче әле аңа дөньяның ачысын-төчесен байтак татырга туры килә. 1928 елда Казанга күчеп килгәннән соң, иң элек ФЗӨ мәктәбендә белем ала һәм Вахитов исемендәге заводта токарь булып эшли, аннары ветеринария институтын тәмамлаганнан соң, әүвәл Дагстанда, шуннан соң Татарстанда зоотехник вазифасын башкара.

Язучы чын мәгънәсендә иҗат эшенә 1934 елда керешә. Әнә шул елларда «Атилла Расих» дигән исем белән «Чаян» журналында телле-тешле, усал гына юмористик һәм сатирик хикәяләре басыла башлый. Озакламый ул инде «Совет әдәбияты» журналына да аяк баса.

Бөек Ватан сугышының беренче айларында ук А. Расих фронтка китә. Белоруссия, Польшаны азат итүдә, Берлинны алуда катнаша, сугышны Эльба елгасына җитеп тәмамлый.

Фронтта күргән-кичергәннәре А. Расихның иҗатына яңа рух, яңа буяулар һәм бизәкләр өсти. Ул хәрби темага мәкаләләр, очерклар, хикәяләр яза, яшьләр өчен «Бәхет орлыклары» мажаралы повестен тәмамлый. Әйтергә кирәк, ул сугыш елларында татар каләмдәшләре арасында иҗади активлыгы белән аеруча күзгә ташлана — әсәрләре «Фронт хакыйкате» газетасында да, Татарстан матбугатында да бик еш күренгәләп тора. Утызынчы еллардагы иҗатына әче сатира, усал ирония хас булса, фронтта чакта һәм аннан соң А. Расих талантының яңа кырлары ачыла. Бу дәвердә язучының күңелен солдат батырлыгы, фәнни эзләнүләр романтикасы били. Балалар өчен «Хәвефле сынау», «Урланган хәзинә», «Сәхи бабай мажаралары» дигән повестьлар иҗат итә. Җиңел укыла торган мавыктыргыч сюжетлы бу әсәрләр хәзерге көндә дә татар балаларының иң яраткан китапларыннан санала. А. Расих бу әсәрләре белән туган әдәбиятыбыз тарихында мажаралы жанрны яңартып, көчәйтеп җибәрүче һәм тулы канлы чын детективны барлыкка китерүчеләрнең берсе рәвешендә танылa.

Язучы үзенең төп һөнәре булган зоотехник эшен дә ташламый. 1950 елда, аспирантура тәмамлагач, диссертация яклап, авыл хуҗалыгы фәннәре кандидаты дигән гыйльми дәрәҗә ала. Казан ветеринария институтында башта ассистент, аннары доцент вазифаларын үти, терлекләрне тукландыру буенча республикада яхшы белгеч булып танылa.

Тормыш белән тыгыз бәйләнештә яшәү, әледән-әле авылларга чыгып йөрү, читтән күзәтүче булып түгел, бәлки тормышны үзгәртеп коручы, актив катнашучы булып йөрү А. Расихның иҗади үсеше өчен ныклы бер нигез була. Илленче елларда аның иҗатында яңа бер борылыш башлана — ул җитди реалистик алымда, эпикысулда язуга күчә. Әнә шулай әдипнең күп тармаклы, социаль-көнкүреш һәм тарихи-революцион эчтәлекле «Дустым Мансур» (1955), «Язгы авазлар» (1963), «Ике буйдак» (1965), «Ямашев» (1967—1984), «Каһарманнар юлы» (1972), «Сынау» (1981) романнары басылып чыга.

«Дустым Мансур» әсәрендә язучы беренче бишьеллыклар дәверен сурәтли. Зур төзелештә күмәк хезмәтнең эшчеләрне яңа рухта тәрбияләүдәге ролен, төрле милләт кешеләренең бер гаиләдәй тату яшәвен гәүдәләндерә.

«Каһарманнар юлы» романында исә Гражданнар сугышы елларында Беренче Татар бригадасы үткән данлы көрәш юлы һәм безнең көннәрдә шул тарихны өйрәнүче яшь

галим Хәйретдинев, сугыш ветераны Хәбибрахман абзый һәм башкаларның фидакарь хезмәте һәм тормышы яктыртыла.

А. Расих киң катлам укучыларга, барыннан да бигрәк, бүгенге авыл тормышы һәм авыл хуҗалыгы фәне кешеләре турындагы романнары белән танылды. Алар — «Язгы авазлар», «Ике буйдак» һәм «Сынау».

«Язгы авазлар»да илленче еллардагы зур социаль үзгәрешләр көткән бер татар авылы тасвирлана. Язучы республикабыз авыл хуҗалыгының артта калуын, эшкә фән кушканча тотыну, фән белән практиканы бергә үрү кирәклеген, бүгенге көн таләбенчә, бик кискен итеп куя. Башка әсәрләрендәге кебек, автор монда да тормыштагы җитешсез якларны каты тәнкыйтьли һәм кайнар дәрт белән яңалыкны яклый.

«Ике буйдак»та автор турыдан-туры авыл хуҗалыгы фәне, гыйльми этика мәсьәләләренә кагыла, теория белән практиканы чын-чыннан кушу кирәклеген күтәрә. Әсәрнең үзәгендә — ике яшь галим — Рәхим белән Заһид образлары. Алар икесе ике төрле характердагы, катлаулы тормыш юлы үткән һәм уй-теләкләре белән бер-берсеннән нык аерылып торган кешеләр. Рәхим образында язучы заманыбызның яңа рухлы алдынгы галимен — абруйларга сукыр килеш буйсынмаучы, хакыйкатькә ирешү юлында теләсә нинди авырлыкларны да күтәрергә әзер торучы чын иҗат кешесен сурәтли.

Роман үзенең бөтен эчтәлеге, бөтен сулышы белән тормышка җайлашучыларга, карьеристларга, мещанлык карашларын алга сөрүчеләргә каршы юнәлтелгән.

«Сынау» романында шушы ук рух — авторның яңалыкны яклавы, тискәре күренешләргә сугыш игълан итүе тагы да үткенрәк булып күз алдына баса.

«Сынау» романында Фәрит белән Әлфия образлары аша әдәп-әхлак, тормышка, хезмәткә намуслы мөнәсәбәт мәсьәләләре күрсәтелә. Әсәрдә тормышка ике төрле караш очраша. Беренчесен гәүдәләндерүдә кешеләр өчен бөтен барлыгын биреп тир түгүче Галиәкбәр карт образы да мөһим роль уйный. Ул авыр сугыш елларында Ватанны яклап сугышкан, укыган, хезмәттә дә сынатмаган — кафедра җитәкләгән, хәтта пенсиягә чыккач та әле ул яраткан шөгылен дәвам иттерә, соңгы сулышына чаклы бүтәннәргә кирәкле булырга омтыла. Кафедра хезмәткәрләренең, кош фабрикасы эшчеләренең дә күбесе шундыйлар.

Романда тормышка, яшәешкә икенче төрле караш Галиәкбәрнең үз кызы Сафура образы аша ачыла. Сафура — фәкать үзе өчен, үз рәхәте өчен генә яшәүче бер эгоист җан. Дус-ишләренә, хәтта әтисе белән сөңелесенә дә ул матди файда күзлегеннән генә карый: үзе азрак биреп, башкалардан күбрәк алырга тырыша.

Язучы бу романда замандашларыбызны уйландыра торган байтак башка мәсьәләләрне дә кузгата, гыйбрәтле язмышлар, тормышчан образлар иҗат итә һәм реаль чынбарлыкта шома, тигез юллар булмавын, кайберәүләрнең язмыш сынауларына каршы тора алмауларын сурәтләп, укучыларны кабат-кабат уйландыра, аларны матур һәм мәгънәле яшәргә өнди.

Язучының «Язгы авазлар», «Ике буйдак», «Сынау» романнары җәмәгатьчелек тарафыннан авторның һәм, гомумән, татар прозасының зур казанышы төсендә кабул ителде. Шушы трилогиясе һәм «Ямашев» романы өчен А. Расих 1981 елда Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе белән бүләкләнде.

Егермедән артык китап бастырып чыгарган әдип бүген дә актив иҗади тормыш белән яши. Ул хәзер элегрәк язган «Утлы сәхифәләр» пьесасы каһарманнарына — комиссар М. Вахитов, юлбашчыбыз В. И. Ленин образларына кабат әйләнеп кайтты — давыллы революция елларын күләмле проза әсәрендә гәүдәләндерергә алынды. Бер үк вакытта автобиографик әсәренең дә яңадан-яңа бүлекләрен кәгазьгә төшерә.

А. Расих берьюлы ике җирдә — институтта һәм Язучылар союзында күп кенә җәмәгать эшләрен үтәве белән дә мәгълүм. «Казан утлары» журналының редколлегия әгъзасы, Татарстан Язучылар союзының проза секциясе җитәкчесе, Язучылар союзы идарәсе әгъзасы сыйфатында ул озак еллар әдәби хәрәкәтебезнең үзәгендә кайнап килде. Аның әдәби алмаш тәрбияләү эшчәнлеге бүген дә дәвам итә — яшь иҗатчыларны Язучылар союзына алу комиссиясе члены ул.

Әдипнең беренче хикәясен заманында Муса Җәлил редакцияләп бастыра. Ул яшь егетне соңыннан да күз уңында тота, аның иҗади үсешенә зур өметләр баглап, матбугат битләрендә:

— Үзенең оригинальлеге, фикер һәм иҗат эзләнүләрендәге кыюлыгы белән күзгә бәрелгән яшь автор А. Расихны күрсәтеп үтәсем килә,— дип белдерә.

«Хезмәт Кызыл Байрагы», II Дәрәҗә «Ватан сугышы», «Мактау билгесе» орденнары һәм байтак медальләр кавалеры Атилла Расих үз остазының бу өметләрен тулысынча аклады. Шуңа күрә, меңләгән укучылары белән берлектә, без аны бу көннәрдә ихлас күңелдән котлыйбыз һәм иҗатында яңа уңышлар телибез.

**Т. ӘЙДЕЛДИНОВ.**

# МАТУРЛЫК САГЫНДА

## ГАБДУЛЛА ШӘРӘФИГӘ 60 ЯШЬ



Габдулла Шәрәфи һәм аның яшьтәшләре Бөек Ватан сугышы башланганда 14—15 яшьлек үсмерләр булып, алар шәхесенең өлгерүе дә нәкъ менә шушы авыр сугыш чорына туры килә. Үз буыны турында уйланып, әдипнең: «Алар кеше һәм гражданин буларак дәһшәтле елларда, солдат шинеле эчендә формалаштылар һәм күңелләре белән гомер буена солдат булып калдылар»,— дип язуы тикмәгә түгел, әлбәттә. Фронтка киткән ир-атларны алыштырып, сугышның беренче көненнән үк тылдагы төп авырлыкны үз җилкәсенә алган әлеге яшьләр бөтен барлыкларын олы хезмәткә багышладылар. Ә бер-ике ел үтүгә инде алар үзләрендә кодрәтле ир-егет көче тоеп, үч һәм нәфрәт тойгысы белән янып, көрәшнең тагын да зурысына, чынына — канлы ут эченә ашкындылар. Күрексез генә бу авыл үсмерләре, үзләрен фронтка җибәрүләрен үтенеп, военкомат сукмагын таптарга керештеләр. «Повестка» хикәясендә язучы яшьлегенең әлеге романтик-киеренке чоры бик матур чагылыш таба:

«...1942 ел. Габделбәр, инде ничәнче тапкырдыр, военкомат урнашкан монастырь янына килә. Йөрәксенеп килә дә, керергә кыюлыгы җитмичә, кире әйләнеп китә. Бәлки бинаның борынгылыгы, тәкселеге шомландыргандыр, ә бәлки... Сугыш вакыты лабаса. Шул бинадан күпме туганнары, таныш-белешләре озатылган. Кайберләре инде һәлак булган, кайсылары хатсыз-хәбәрсез... Ә бер килүендә, тәвәккәлләп, барыбер керде ул анда... Өч өстәл янында — өч хәрби. Кайсысы янына барырга, кемгә дәшәргә белмичә, ишек төбендә тора бирде...»

Олырак иптәшләренең сугыш кырында булуына көнләшеп яшәгән кечкенә буйлы, кыюсыз, уналты яшьлек бу авыл малае, бер елга якын йөреп, «үзе барып, үзе юллап» фронтка китәргә повестка алуга ирешә. Хәер, Г. Шәрәфиләр буынының хәрби язмышы да башка бик күп фронтовикларныкыннан аерылып тора. Күпләренең солдат хезмәте, сугыш тәмамланганнан соң да дәвам итеп, дистәләп елга сузыла. Үзенең көрәштәш-каләмдәш дусларына багышланган бер мәкаләсендә язучы ул елларны түбәндәгечә искә ала: «Сугышка киткәндә безне, уңҗиде-унсигез яшьлек малай-егетләрне, капка төбеннән ялан тәпиле энекәшләребез, сеңелкәшләребез озатып калды. Озак һәм озын булды безнең солдат юллары. Исән калганнарыбыз, кайту белән, эшкә чумдык, әле шинельләребезне дә салмаган килеш, унар ел тукталып торганнан соң кабат парта араларына кердек, кайчандыр ялан тәпи калдырып киткән шул ук энекәшләрдән, сеңелкәшләрдән гыйлем алдык. Алар тупылдатып бала сөйгәндә, без әле һаман да өйләнмәгән карт егетләр, сакаллы студентлар идек. Әле менә шушы көнгә кадәр ике нәрсә безнең төшләребезгә кереп йөдәтә. Берсе аның солдат чагыбыз, сугыш юллары, икенчесе — өлгергәнлек аттестатына имтихан тоту».

Шулай итеп, алар фронтта һәм хәрби хезмәттә генә түгел, ә бәлки һәрвакыт «солдатларча тырыш һәм сабыр булырга өйрәнделәр», тормышта, эштә, иҗатта бөтен гомер буена «чын мәгънәсендә, матур мәгънәсендә» күңелләре белән солдат булып калдылар. Г. Шәрәфинең язучылык сәләте дә, табигый ки, шушы дәһшәтле сугыш китергән тетрәндергеч тормыш вакыйгалары тәэсире астында формалаша. Аны прозаик итеп таныткан беренче җитди әсәре «Сусыз дәрья» (1969) повесте да Совет Армиясенең данлы юлы сәхифәләрен җанландыруга багышланган. Автор иҗатын тулаем дип әйтерлек үз эченә алган «Гомернең агышлары»[1] китабында, бу повестьтан

[1] Шәрәфи Г. Гомернең агышлары. Казан, 1986, 352 б.

тыш, «Тәфтиләү», «Мут Галләм», «Мирас», «Полковник кияве» кебек хикәяләре, фронтовик каләмдәшләреннән Г. Әпсәләмов, Р. Төхфәтуллин, Ә. Маликов, И. Беляев иҗаты турындагы әдәби тәнкыйть, истәлек мәкаләләре дә сугыш һәм солдат хезмәте темасына карый.

Соңгы кырык ел эчендә сугыш афәтен тасвирлаган әсәрләр әдәбиятыбызда аз язылмады. Дөресен әйтергә кирәк,билгеле бер укышлар белән беррәттән, әсәрләрнең сәнгати эшләнеш дәрәҗәсе бик чамалы булганнары да, билгеле бер модага бирелеп, «кемнеңдер сөйләвенә янсә аерым документларга таянып» язылганнары да шактый гына. Һәм шул соңгылары, гадәттә «ясалма булулары, авторларның укучыларны шаккатырырга тырышулары, ялган пафослары белән ачуны китерәләр, күңелне рәнҗетәләр». Г. Шәрәфинең исә әлеге темага җитди үз мөнәсәбәте, үз иҗат концепциясе бар. Сугыш — аның өчен үтә изге тема. «Сугыш ул — халыклар тормышында иң зур сынау,— дип яза ул.— Монда бөтен илнең барлык материаль һәм рухи ресурслары хәрәкәткә килә. Вакыйгасын да, баш әйләндергеч маҗараларын да уйлап чыгарасы түгел, барысы да үзендә, барысы да күз алдында. Бөек Ватан сугышы кебек зур, җаваплы темага язылган әсәрләрдә дөреслек, табигыйлек, фәлсәфи тирәнлек, көрәсең, теләсә нинди башка әсәрләргә караганда да күбрәк булырга тиештер. Әлеге әсәрләрне совет халкының фидакарьлегенә, батырлыгына... һәйкәл дип карарга кирәк».

Язучы Г. Шәрәфи әсәрләрендә тасвирланган сугыш вакыйгаларының тагын бер үзенчәлеген әйтеп китмичә булмый — алар Көнчыгыш фронтта япон самурайларына каршы барган көрәшне гәүдәләндерәләр. Немец фашистлары белән булган сугыш әдәбиятта шактый киң яктыртылса да, сугышның бу тарафын чагылдырган җитдирәк бер генә әсәр дә соңгы елларгача күренми иде әле. Г. Шәрәфи исә, беренчеләрдән булып, бу пәрдәне алып ташлады. Күренекле прозаик Г. Әпсәләмов, авторның бу яңалыгын ассызыклап, «Сусыз дәрья» повестена зур бәя бирде.[1] Соңрак Көнчыгыш фронт вакыйгалары башка фронтовик язучыларыбыз иҗатында да чагылыш тапты. Ә. Маликовның «Яшьлек утравым» (1974), И. Беляевнең «Солдат төймәсе» (1974) китаплары әнә шундыйлардан. Әдәбиятыбызда Бөек Ватан сугышының географик чикләре тагын да киңәеп, тулыланып китте, бүгенге яшь буын укучысы алдында япон илбасарларына каршы көрәшнең үзенчәлекле яклары ачыла төште.

Әлеге Көнчыгыш фронтта да якташларыбызның гаять зур активлык күрсәтүен, кайбер рота, взводларның яртылаш диярлек татар егетләреннән торуын әйтеп үтәргә кирәк. Язучы әнә шушы берникадәр дәрәҗәдә күләгәдәрәк кала килгән ерак сугыш вакыйгаларын документаль төгәллек белән, әсәргә алынган геройларның хәтта исем-фамилияләрен дә үзгәртмичә, укучы күз алдында яңадан тергезүгә ирешә. Шунысын да искәртик: фактик-документаль җирлеккә кору әсәрнең сулышын һич кенә дә тарайтмый, чөнки автор биредә художестволы иҗатның күп төрле мөмкинлекләреннән дә бик иркен файдалана. Шуңа да әсәр бер үк вакытта кырыс һәм реаль дә, җанлы һәм мавыктыргыч та. Әмма кабатлап әйтәбез: аның мавыктыргыч булуы — баш әйләндергеч вакыйгалар белән бизәкләнүендә түгел, ә бәлки — реальлегендә. Язучы үзенең иҗат кредосына, иҗат принципларына биредә ахыргача тугрылыклы булып калган. Сугышчылар әсәрдә көндәлек гади һәм авыр солдат тормышы белән яшиләр. Әмма алар сугышчан походта. Аларны һәр адымда үлем сагалый. Алар рәхимсез кояш эссесе астында, бер йотым суга тилмереп, әлегә кадәр үтеп булмаслык дип саналган Гоби чүле, Зур Хинган сырты аша узып, һич көтелмәгәндә, Квантун армиясенең тылына бәреп керәләр. Кырыс табигать, ерак чакрымнар, сопкалар артына поскан дошман пулялары — безнең солдатлар алдына мәкерле дошман тарафыннан куелган төп киртәләр әнә шулар. Иң куәтле көч — гаделлек, кешелеклелек, изге ният белән коралланган совет сугышчысы, тиңдәшсез зур чыдамлык күрсәтеп, бу каршылыкларны җиңеп чыга. Көндәлек намуслы хезмәт, сабырлык, кыюлык, түземлелек, каһарманлык сораган бу поход чын-чынлап солдат батырлыгына әверелә.

...Солдатлар «үлем сахрасы» — Гоби чүленә якынлашып килгәндә, һавада болыт күренеп, аңардан «җиргә таба кара-кучкыл толымнар» сузыла. Потлаган йөк асып, шушы эсседә кырык чакрым юл узган сугышчылар тамак чылатырлык булса да су җыелмасмы дип, палаткаларын җәеп, зур өмет белән болытны көтә башлыйлар. Менә ул колонна турысына килеп җитә. «Ләкин ни гаҗәп,— дип яза автор,— баш өстендә коеп

[1] Әпсәләмов Г. Сахраларны кичә егетләр. «Социалистик Татарстан», 1969, 12 декабрь.

яңгыр ява, ә безнең палаткаларга ник бер тамчы су төшсен! Һава шулкадәр кызган, яңгыр тамчылары җиргә төшеп җиткәнче үк парга әйләнеп бетәләр».

Полк тагын утыз чакрым җир уза. Ниһаять, җәһәннәмдәй кызуда җитмеш чакрым юл үтеп алҗыган солдат халкы тулар-тулмас берәр кружка кайнар чәй эчү бәхетенә ирешә. Өч-дүрт сәгать йоклап алгач, полк яңадан аякка баса. Алда — сузылып киткән яңа чакрымнар... Инде Гоби чүле дә артта. Тау тезмәләре башлана. Әмма хәрәкәт тукталмый, тизлек акрынаймый. «Алга, алга, мөмкин кадәр тизрәк алга! Дошман мәкерле. Койрыгына бассаң, елан каты чага. Әгәр бу тирәдә чакса, шеше яман булачак. Шуңа күрә ашыгырга, ул ис җыйганчы, бугазына басарга кирәк. Ә юл текә, хәвефле. Тупларга һәм фургоннарга җигелгән атлар адым саен туктыйлар. Солдатлар, шабыр тиргә батып, аларга булышалар. Юл бормалы булганга, алда нәрсә бары күренми. Кайвакытта көне буе тауга менеп, таудан төшеп, аның тирәли элмәк ясап, иртән үк узган урынга барып чыгасың».

Солдат — көрәшче. Сусыз дәрьяда яки тоташ ишелеп төшкәндәй туктаусыз койган яңгыр эчендә атлар барудан туктый. Әмма «ат түзмәгәнне солдат түзә». Пулемет станоклары, патрон тартмалары «пот өстенә пот булып» аның җилкәсенә төшә... Ватан алдындагы, халык алдындагы изге бурычны тою аларга бетмәс көч, тирән оптимизм, һәртөрле авырлык-югалтуларга каршы торырлык сәләт бирә. Үлем-яшәү, явызлык-гаделлек, нәфрәт-шаянлык шулай итеп аларның көндәлегендә бер бөтенгә әверелеп яши. Тормыш чынлыгы әнә шулай туа. Солдат батырлыгы купшы маҗаралар дөньясында түгел, ә бәлки шушы көндәлек табигый авырлыкларны җиңә белгән гади солдат язмышлары аша чагыла. Шуңа да японнар тарафыннан кара җиргә калдырганчы тапталган иген кырларын, җәберләнгән ач-ялангач кытай картларын һәм балаларын күргән солдатларның Совет Армиясенең гадел көрәше, кешелеклеге өчен горурланудан, шатланудан күзләреннән яшь бөртекләре тамуы безне ышандыра һәм дулкынландыра.

Г. Шәрәфинең «солдат шинеле эчендә формалашкан» һәм гуманизм тойгысы белән сугарылган язучылык таланты, һичшиксез, аның тыныч тормыш вакыйгаларына багышланган әсәрләрендә дә сизелми калмый. Барыннан да элек, бу — язучының үзен чолгап алган җанлы табигатькә, кешеләргә булган мөнәсәбәтендә күзгә ташлана. Үзенең 1976 елда язылган «Аккошлар кайтыр әле» повестен ул бүгенге көннең иң актуаль проблемаларыннан берсе — табигатьне саклау темасына багышлаган. Әмма автор аны табигать матурлыгын югалтмау итеп кенә күзалламый. Г. Шәрәфи өчен табигатьне саклау — иң элек кеше җанының матурлыгын саклап калу, табигать һәм кеше күңеле арасында туган гармоник бөтенлеккә ирешү дигән сүз. Кешенең чын бәхетен әнә шунда күрә әдип. Һәм ул элеккечә үк, үзендә солдатларча җаваплылык тоеп, кулына каләм алып, хикәя-повестьларында да, публицистик язмаларында һәм мәкаләләрендә дә шушы зур бәхет өчен актив көрәш сафына баса. Табигатьне саклау, автор уенча, халыкның һәм кешелекнең иң матур традицияләрен югалтмау. Икмәк, дуслык, намус кебек гади нәрсәләрнең изгелеген һәм кадерен аңлый белү. Бу уңайдан язучының хатын-кызга булган мөнәсәбәте, хатын-кызның тормышыбызда тоткан чиксез зур роле турындагы уйланулары аерым игътибарга лаек. Бөек пролетар язучысы М. Горькийның «Кешедә булган гүзәллек кояш нурыннан һәм ана сөтеннән килә...» дигән мәшһүр сүзләрен китереп, үзенең фикерен түбәндәгечә дәвам итә: «Ни өчен әле без күңелебезгә иң якын, иң газиз нәрсәләрне ана сүзе белән янәшә куеп әйтәбез: «Җир-ана»,— дибез. Сынлы сәнгатьтә Ватан образын гәүдәләндерергә кирәк булгач, әнә, рәссам да пьедесталга хатын-кызны бастырган. Көчле кулына тотып күтәргән кылычы гаделсезлекне, явызлыкны җәзаларга һәрвакыт әзер. Югыйсә, Ватан символы итеп, пьедесталга шундый ук мәһабәт гәүдәле бер Алып батыр сынын да бастырырга булыр иде. Ләкин юк бит, мондаен бөеклекне, олылыкны хатын-кызга табигать үзе бирә. Кешелек моны күптән аңлаган...»

Әдипнең гади, әмма үтемле итеп әйткән, олы хакыйкать белән сугарылган бу сүзләрен битараф кына укып китү мөмкин түгел. Бу урында Г. Шәрәфинең инде менә егерме елдан бирле, ир-атлардан бердәнбер кеше буларак, республикабызның хатын-кызлар журналы «Азат хатын» редакциясендә эшләвен һәм, элеккечә үк — солдатларча, рыцарьларча, олы матурлык сагында торуын әйтеп үтәсе килә.

Әгәр игътибар итсәгез, язучы иҗатында картлар һәм балалар темасы да үзәк урыннарның берсен алып тора. Бәхетле, тыныч картлык, шау-шулы, тынгысыз балачак — шул ук олы матурлыкның, табигать бөтенлегенең аерылгысыз бер өлеше түгелмени?!

Алар да табигать кебек үк саклауны һәм яклауны, үтә нечкә мөнәсәбәт — аңлау, кадер-хөрмәт, тәрбия таләп итмиләрмени?!

Язучы тормышның гел алга хәрәкәт итүен бик яхшы аңлый. Китабын «Гомернең агышлары» дип атавы да тикмәгә түгелдер, билгеле. Туу, үсү, өлгерү, картаю — тормышның табигый бер хәрәкәте. Шуңа да, күрәсең, авторның йөрәге олы яшьтәге — «гамәлдән чыгуга якынлашкан» геройларына аеруча сизгер. Аларны әдип, сугыштан кайтмый калган солдат уллары исеменнән сөйләшкәндәй, якын итә, төрле кыланышларын эчке бер ярату белән сабыр гына күзәтә. «Энҗе бөртекләре», «Яңа йортка күчкәч», «Өмет», «Рәхмәт төшкерләре» хикәяләрендәге әбиләрнең язмышына, кичерешләренә язучының мөнәсәбәте әнә шундый. Бу мөнәсәбәттән билгеле бер моңсулык та, әдипнең үз геройлары янына кушылып, күпмедер дәрәҗәдә әрнүе дә, җиңелчә генә шаяртуы да, иң әһәмиятлесе — аларны тирән аңлап ратуы бөркелеп тора.

«Гомернең агышлары», «Повестка» хикәяләренең геройлары ир-ат булсалар да, монда да шул ук нота — актив тормыштан читкә чыгуны тойган олы яшьтәге кеше кичерешләре — үткән гомергә карап, җиңелчә бер көрсенү, тирән уйга калу. Алда телгә алынган «Аккошлар кайтыр әле» повесте да, тулысы белән, олы матурлык өчен көрәшүдән туктарга теләмичә, тормышта актив көрәшче булып кала белгән картларның бүгенге көндәге рольләрен күрсәтүгә багышланган. Аларның табигатьне саклау проблемасы белән янып йөрүләре очраклы түгел. Бу — үзенә күрә символ да. Табигатьне саклау, шул рәвешчә, монда бөтен кешелекне саклау проблемасы булып үсеп китә. Әлеге геройларның үз күңел матурлыклары белән бергә, аларның үзләренә булган мөнәсәбәт тә игелекле. «Рәхмәт төшкерләре» хикәясендә әбигә булган хөрмәт, яратуны күреп, без үзебез дә канатланып, яктырып китәбез. Ни әйтсәң дә, кешелеклелек белән очрашу безнең үзебезне дә олы җанлырак итә, көчлерәк итә. Тормышның тулы канлы агышын тоярга, яшәү гармониясен сиземләргә булыша. Шуңадыр, күрәсең, Г. Шәрәфи күп төрле жанрларга мөрәҗәгать итә, үзенең чынбарлыкка булган мөнәсәбәтен күп төрле психологик аспектларда ачып бирергә омтыла: кайчак ул әрнүле, моңсу; кайчакта яңгырлы кояш сыман, әсәргә мөлаем, ягымлы җылы юмор килеп керә («Ярыш», «Дәгъва», «Бушка килгән мал» хикәяләрен генә искә төшерик); гармоник бөтенлекне югалта башлаган, идеалдан, дөресрәге, нормадан аз гына читкә чыгып киткән геройларын ул сизелер-сизелмәс кенә итеп сатирик көлү белән чеметтереп тә куя белә («Полковник кияве», «Бушка килгән мал» хикәяләре — әнә шуның ачык мисалы).

Яшәү матурлыгының гармоник бөтенлеген сакларга омтылуы язучы әсәрләрендәге геройларның яшь үзенчәлеген чагылдыруда аеруча ачык күзгә ташлана. Аның солдатлары, картлары янына нәни геройларын китереп куйсак, бу бөтенлек тагын да тулыланып китә. Ә бераздан соң инде Г. Шәрәфинең без чын-чынлап балалар язучысы булуына төшенәбез. Әйе, әдипнең кешеләргә солдатларча, аталарча кайгырту белән тулы йөрәге балалар өчен язылган әсәрләрендә тагын да ачыла төшә сыман. Хәер, тикмәгәмени, балалар өчен язу соңгы елларда аның төп жанрына — эчке күңел хасиятенә әверелде. Нәниләргә ул «Күрше малае» (1981) повестен бүләк итте. «Кәҗәләр, кыяр һәм без», «Муйнак», «Әниләргә бүләк» кебек үзенчәлекле хикәяләрен язды. Тәнкыйть мәкаләләрендә дә Г. Шәрәфи балалар әдәбиятына торган саен якынрак килә (Ә. Бикчәнтәева, Л. Ихсанова һ. б. лар иҗатына караган мәкаләләрен искә төшерик). Аның публицистикасында да педагогика, тәрбия мәсьәләләре үзәк урынны алып тора. Алда телгә алынган «Икмәктә-хикмәт», «Кыз баланың яше төшмәсен», «Ата үрнәге» һ. б. язмалары әнә шул хакта сөйли.

Матур әдәбият әсәрләрендә Г. Шәрәфи, гомумән, бөтен язылганнары белән диярлек балалар язучысы булып кабул ителә. Менә аның «Сусыз дәрья» повестен гына алыйк. Әсәрнең сугыш темасына язылган булуы аны һич кенә дә балаларныкы түгел дигән нәтиҗә ясарга мөмкинлек бирми. Киресенчә, бу теманың балалар тарафыннан ни дәрәҗәдә яратып кабул ителүен без бик яхшы беләбез. Әсәрнең документаль җирлеккә корылуы исә аны танып-белү чарасы буларак та киң мәгълүматлы итә. Повесть сәнгатьчә эшләнеше белән дә балалар күңеленә бик якын. Алда без аның шактый гына өзекләрен китереп тә үткән идек инде. Повестьның фольклор элементларына, хыялга юмарт, бай булуы, һичшиксез, бала күңеленә туры юл суза! Сюжет сызыгының мавыктыргыч итеп төзелүе, табигать күренешләренең, сугыш эпизодларының конкретлыгы, ачык буяуларда образлы итеп тасвирлануы, теленең халык сөйләменә нигезләнүе, җанлылыгы нәни укучыларны битараф калдырмый. Ул гына да түгел, балаларның үз-

ләреннәке дип әйтерлек специфик детальләр дә биредә шактый еш очрый. Төп героебыз — радистның, әнә авазларны ничек ишетүенә генә колак салыйк:

«Телефон колакчыннарында әйтерсең лә кошлар базары. Һәр радиостанциянең үз тавышы. Кайсы — йомыркадан әле яңа гына чыккан каз бәбкәләренеке кебек зәгыйфь кенә, нәзек кенә; кайсы бака, кайсы үрдәк һәм каз тавышы чыгара. Болары куәтле радиостанцияләрнеке. Ул да булмый, трансмиттерны (морзе аппараты — Р. К.) эшләтә башлыйлар. Баш өстендә тургайлар сайрыймыни! Барысы да бер дулкында, барысы да бер урынга өелгән. Радист шулар арасыннан үз «кошын», үзе элемтә тота торган станцияләрне таный, аера белергә тиеш. Әле ул гынамы, һәркайсы сукыр чебеннәр кебек колагыңа керергә торганда, минутлар буе син, үз адресатыңны бутамыйча, аннан радиограмма кабул итәргә тиешсең».

Әсәрдәге төп геройның чынбарлыкны шигъри күзаллавы гына түгел, аның тыйнак һәм сабыр холыклы булуы, оптимистлыгы, шул ук вакытта уйчанлыгы, кешелеклеге, эчкерсезлеге, беркатлылыгы, тапкырлыгы һәм башка бик күп психологик үзенчәлекләре дә балалар күңелен әсир итә. Әнә ул караңгыда дошман пулялары астында штаб начальнигының ашыгыч радиограммасын тапшырырга тиеш. Ут яндырырга ярамый, хәзер мишеньгә әйләнәсең. Күңелдән ятларлык түгел — радиограмма озын. Нишләргә? Шунда героебыз японнарның татарча белмәүләреннән һәм икенче якта Казан егете утырудан файдаланып, дошманның кайда, ничек засада оештыруын дивизиягә татарча ачык текст белән хәбәр итә: «Өлкән абзыйга әйт: кысык күзләр безгә менә шушы җирдә... ут ачтылар, хәзер сугыш алып барабыз». Әмма радиограмманы ачык текст белән тапшырганы өчен дивизия штабында аңа шактый гына «маңгаеннан салкын тирләр» агызырга туры килә. Текстның татарча булуы гына егетне коткарып кала. Һәм трибунал каршысына бастыра язган бу вакыйга соңыннан «сугыш шартларында күрсәткән тапкырлык» дип бәяләнеп, героебыз «Сугышчан хезмәтләр өчен» медале белән бүләкләнә.

Әсәрнең геройлары белән берлектә укучыны да дулкынландыра торган мондый киеренке психологик ситуацияләр повестьта шактый. Шунысы әһәмиятле, геройлар укучыдагы бу теләктәшлекне һәм олы ихтирамны таң калырлык батырлыклар эшләп түгел, ә бәлки үзләренең көндәлек авыр, җаваплы сугышчан бурычларын намус белән үтәп, табигый ки, шуның өчен янып, борчылып, әзләнеп, көрәшеп яшәүләре белән яулап алалар.

Язучының табигатьне саклау янсә карт һәм карчыклар темасына язылган әсәрләре дә, һичшиксез, барыннан да бигрәк, яшьләр колагына нидер ишеттерү өчен иҗат ителгәннәр, һәм алар яшь буынга гуманистик идеяләрне, тормышның гармоник бөтенлеген җиткерүдә гаять мактаулы һәм зур эш башкаралар. Әби белән бабайларның холкын аларның оныкларыннан да яхшырак күзаллаучы һәм үз итеп аңлаучы кеше тагын булырмы икән?! Бер-берсенә бәйләнгән уртак җепләр һәм сыйфатлар чыннан да шактый бит биредә. Үсеш циклының бөтенлеген булдырган, аның очын-очка ялгаган, шуның белән диалектик механизмны хәрәкәткә китергән ике зур көч түгелмени ул бабай белән онык?! «Өмет», «Гомернең агышлары» хикәяләрен генә укып карагыз, алардагы хикмәтле фикернең үгы балалар күңеленә төбәлмәгәнмени?! Авторның «Ачу йоту — таш йоту» кебек олылар өчен язылган хикәяләрендә исә балаларны тәрбияләү мәсьәләсе ачыктан-ачык сюжетның нигезенә үк алына.

Шул рәвешчә, сабыйлар психологиясе белән бәйле үзенчәлекләр Г. Шәрәфи иҗатының буеннан-буена сузыла. Ә инде балалар дөньясын үзәккә куеп, турыдан-туры аларның үзләренә атап язылган әсәрләрдә бу сыйфатлар бигрәк тә тулырак гәүдәләнә. Бу уңайдан «Кәҗәләр, кыяр һәм без» хикәясеннән бер өзек кенә китереп узыйк: «Галәви бабай белән дуслашып киттек. Балык тотарга да һаман шул бакча башына киләбез. Без дә киләбез, кәҗәләр дә киләләр. Кәҗәләр килдеме, шундук куалап җибәрәбез. Кәҗә кудың исә, бакча аркылы узарга кирәк. Бакча аркылы уздыңмы, кыяр түтәлләре яныннан үтәргә кирәк. Ә кыярларны күрдек исә, нәкъ шул җирдә безнең аяклар сөртенә. Сөртендеңме инде, туп-туры әлеге кыяр янына егыласың. Егылсаң да — бик каты төшәсе килми бит — учың белән җиңелчә генә шул ак башлы яшел кыярга таянасың. Ә торганда инде ул да синең кулыңа иярер менә».

Күренә ки, балаларча шаянлык та, хәйләкәрлек тә, хыялый бер уен да ярылып ята биредә. Иң әһәмиятлесе, монда без бөтен каршылыклары белән тотып алынган тере бала җанын, аның олыларга булган ихтирамын, тирән ярату хисен тоябыз. Язу-

чының кешеләргә, тормышка һәм, гомумән, бөтен табигать дөньясына булган олы мәхәббәте аның башка хикәяләрендә дә кызыл җеп булып сузыла. Авторның «Күрше малае» повесте бу уңайдан аерым игътибарга лаек. Нәни укучыларыбыз бу әсәрне «Яшь ленинчы» газетасы битләрендә зур кызыксыну белән каршы алдылар. Тикмәгә түгел, билгеле. Күрше малае Айдарны монда башка бик күп балаларга якын, үз итә торган бер үзлек бар — ул көчсезләрне, нәниләрне һәм кыерсытылганнарны һәрвакыт якларга һәм аларга ярдәм кулы сузарга әзер тора. Айдарның өйләренә төрле җәнлекләр алып кайтып, тәрбия итәргә алынуы да нәкъ менә шуның белән бәйле түгелмени?! Эт, мәче, карга, күгәрчен, балык, әрлән, шөпшәләр белән әвәрә килеп яши торгач, аның үз тормышы да мәгънәлерәк һәм җанлырак төс ала. Әйтик, бик күп балаларның әле мәченең дүрт куллап, юк, дүрт аяклап... пианинода уйнаганын күргәннәре дә, ишеткәннәре дә юктыр. Ә менә Айдарның Багира исемле мәчесенә пианино клавишларына баскалап йөрү берни түгел. Мондый хикмәтләр повестьта аз очрамый, һәм алар әсәрне тагын да җанлырак итәләр. Әлеге җәнлекләр нәни геройның характеры һәм шәхесе формалашуга да үз өлешләрен кертми калмыйлар, билгеле. Гомумән, повесть баланы тәрбияләүдә табигатьнең, тереклек дөньясының, кешелекнең гармоник бөтенлеге җимерелергә тиеш булмавын тирән ышандырырлык итеп күрсәтеп бирә алган. Айдарның әтисе образында исә без кайчандыр кешеләрнең иминлеген, тыныч, матур тормышын саклап, көрәш сафында торган олы йөрәкле солдатны күргәндәй булабыз.

Алда әйтүебезчә, Г. Шәрәфиләр буыны тыныч тормышка соңлабрак кереште. Г. Шәрәфинең язучылык сәләте ачылуы хакында да шуны ук әйтергә мөмкин булыр иде. Әмма әдәбиятыбыз, шул исәптән татар балалар әдәбияты, мондый соңлап ачылган һәм әдәбиятыбызны баетуга зур өлеш кертеп киткән каләм ияләрен әйбәт хәтерли. Б. Рәхмәт, З. Туфайловаларны, әйтик, без шундый әдипләр итеп беләбез. Г. Шәрәфине дә без, соң булса да уң булсын дигәндәй, иҗатының иң биек үрләрен яуларга керешер дип өмет итәбез. Аның елдан-ел ачыга һәм ачыклана барган иҗат мөмкинлекләре безгә шулай дияргә тулы нигез бирә. Гомерегезнең киләчәк агышлары сабыйлыктан килгән саф сулы илһам чишмәләре белән сугарылсын. Озын иҗат гомере телибез Сезгә, олы йөрәкле, тыйнак солдат дустыбыз!

**Равил КУКУШКИН.**

# ОМТЫЛЫШ ҺӘМ БИЕКЛЕК

## ВАХИТ ХАКОВКА 60 ЯШЬ



Озак еллар татар тел гыйлеме өлкәсендә эшләүче галим, филолог-тюрколог, филология фәннәре докторы, Казан дәүләт университетының татар теле кафедрасы профессоры Вахит Хаковка 60 яшь тулды. Ул — 200 гә якын фәнни-теоретик, методик-практик хезмәтләрнең, шул исәптән 10 китап һәм монография авторы. Инде чирек гасырдан артык университетта фәнни-педагогик эш алып бара. Бөек Ватан сугышы ветераны.

В. Хаков Татарстанның Буа районы, Күзби (Урта Лашчы) авылында 1926 елда укытучы гаиләсендә туган. Әтисе Хөжжәт Хаков (1901 — 1984) — гражданнар сугышы һәм Бөек Ватан сугышы ветераны, 1919 елда Күзби авылында беренче совет мәктәбен ача һәм 40 елдан артык башлангыч мәктәптә укытучы булып эшли.

Китапка-белемгә омтылыш Вахитта бик яшьли башлана. Моңа өйдәге шактый бай китапханә дә зур этәргеч ясый. Анда К. Насыйри, Ш. Мәрҗани, Г. Тукай һ. б. әдипләрнең әсәрләре белән беррәттән, XX йөз башында басылып чыккан күп кенә газета һәм журналлар да була. Көнчыгышның, төрки халыкларның классик әсәрләре —«Ләйлә вә Мәҗнүн», «Кыйссаи Йосыф», «Таһир вә Зөһрә»ләрне кышкы кичләрдә җыелып уку гаиләдә зур тәрбияви роль уйнаган.

Үз авылында башлангыч белемне алгач, Вахит Кильдураз урта мәктәбендә укый башлый, ләкин 8 классны гына бетереп кала. Сугыш бөтен киләчәк планнарны өзә. 1943 елда, 17 яшь тулар-тулмас вакытта, ул Совет Армиясе сафларына баса. Сугыш юллары аны илебезнең Көнчыгыш тарафына илтеп ташлый. 1945 елда милитаристик Японияга каршы сугышларда катнаша, Гоби чүлен һәм Хинган тавын кичә. Көнчыгыш экзотикасы, борынгы төрки бабаларыбыз яшәгән җирләр, элекке төрки культура аңарда зур кызыксыну уята. Ташка чокып язылган төрки рун язуларын да ул беренче мәртәбә шунда күрә, алар белән якыннан таныша. Болар барысы да аның киләчәк профессиясе формалашуда нәтиҗәсез калмагандыр дип уйларга кирәк.

1949 елда армиядән кайту белән үк В. Хаков укырга керә: Тәтеш педучилищесын, Казан дәүләт университетын тәмамлый. Ә 1957 елда СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы Тел, әдәбият һәм тарих институты каршындагы аспирантурага керә. Аңа кадәр Буа районы мәктәпләрендә башлангыч мәктәп мөдире, укытучы, урта мәктәптә завуч, татар теле һәм әдәбияты укытучысы булып эшли. Аспирантураны тәмамлагач, XX йөз башы әдәби тел мәсьәләләренә багышланган кандидатлык диссертациясе яклый һәм университетның татар филологиясе бүлегенә укытучы итеп чакырыла. В. Хаковның бөтен фәнни-педагогик эшчәнлеге нигездә Казан университеты белән бәйләнгән. 1965 елдан — доцент. 1971 елда «Татар милли әдәби теленең барлыкка килүе һәм үсеше» дигән темага докторлык диссертациясе яклый. Ә 1974 елда аңа профессор исеме бирелә. Аның төп фәнни юнәлеше — төрки һәм татар әдәби телләре тарихы, андагы стилистик категорияләрнең үсеше, татар язма истәлекләрнең теле. Ул үзенең игътибарын, шулар белән бәйләнешле рәвештә, гомуми тел мәсьәләләре, лексикология, терминология, фразеология, орфография, этимология, сөйләм культурасы, хәзерге стилистика, мәктәптә телне өйрәнү мәсьәләләренә дә юнәлтә. «Тел һәм стиль мәсьәләләре» (1961), «Татар теле стилистикасына кереш» (1963), «Татар әдәби теле тарихыннан очерклар» (1965), «Татар милли әдәби теленең барлыкка килүе һәм үсеше» (1972), «Стилистика һәм сүз сәнгате» (1979), «Татар теле стилистикасы» (1980), «Татар әдәби теленең совет чорында үсеше» (1985) һ. б. китап, монографияләрендә ул татар әдәби теленең лексик, фонетик, грамматик һәм стилистик нормалары үсешенә, аларның тарихына тукталa.

Әдәби тел белән язучылар теле бик тыгыз бәйләнгән. Шуңа күрә тарихи юнәлештә матур әдәбият әсәрләре теле шул чорның әдәби нормаларын бик нык саклыйлар. В. Хаков хезмәтләрендә әдәби тел тарихы, язучылар теле, стилистик нормалар үзара аерылгысыз мөнәсәбәттә тикшерелә. Тулаем алганда, бу тел — әдәбият-культура тарихын ачарга да ярдәм итә. Аның Кол Гали, Мөхәммәдъяр, Г. Тукай, Ф. Әмирхан, Г. Ибраһимов, Ш. Камал, М. Җәлил һ. б. язучыларның теленә караган хезмәтләре шул турыда сөйли. «Мәктәптә стилистиканы өйрәнү», «Мәктәптә язучылар телен өйрәнү» һәм шул юнәлештәге башка эшләр укытучылар өчен кулланма-ярдәмлек рәвешендә әһәмиятле материаллар булып тора. Һәм менә ул озак еллар хыялында йөрткән хезмәтен — татар әдәби теленең тарихи үсешенә багышланган 35 табаклы зур хезмәтен тәгәлләде.

Төрки халыкларның фәнни җәмәгатьчелегендә В. Хаков хезмәтләре киң яклау тапты һәм кызыксыну уятты. Ул Мәскәү, Алма-Ата, Баку, Ташкент, Ашхабад, Фрунзе, Уфа, Махачкала, Карачаевск, Нальчик шәһәрләрендәге тюркологлар белән тыгыз элемтәдә тора. Алар белән күп кенә бәхәсле мәсьәләләрне чишүдә катнаша, тәҗрибә уртаклаша, тугандаш республикалар һәм өлкәләрдәге яшь тюркологларга булыша, Бөтенсоюз тюркология конференцияләрендә докладлар белән чыга.

Төрки-татар тел гыйлемендә әдәби тел тарихы мәсьәләләрендә ачыклыйсы урыннар бик күп. Бу катлаулы өлкәдә язма ядкарьләрның телен тикшерү — аеруча әһәмиятле проблемаларның берсе. Казан, Башкорт университетлары, Казан һәм Алабуга педагогия институтларының татар теле һәм әдәбияты бүлекләрендәге студентлар «Әдәби тел тарихы», «Стилистика» курсларын В. Хаков хезмәтләре нигезендә укыйлар. Ул, мөстәкыйль предмет буларак, бу фәннәрне беренче мәртәбә системага салып, программа төзеп, Казан университетының татар филологиясе һәм журналистика бүлекләрендә укыта башлады. Махсус курслар төзүгә һәм укытуга да ул зур игътибар бирә. Мәсәлән, «Әдәби телләрнең үсеш этаплары», «Функциональ стильләр», Социолингвистика нигезләре» курслары шуны ачык раслыйлар.

Яшь буынга белем бирүгә, аны коммунистик рухта тәрбияләүгә В. Хаков аеруча зур көч куя. Аның күп кенә шәкертләре бүгенге көндә Татарстанда гына түгел, илебезнең башка өлкәләрендә дә халык хуҗалыгының төрле тармакларында нәтиҗәле хезмәт итәләр. Алар арасында мәгариф хезмәткәрләре, укытучылар, галимнәр, язучылар, журналистлар, культура, партия-совет аппараты, нәшрият хезмәткәрләре күп.

Җәмәгать эшләрен үтәүгә дә В. Хаков җаваплы карый. Ул күп еллар буе университетның татар филологиясе бүлегендә партия оешмасын җитәкләде. Татар сөйләм культурасының актив пропагандисты, «Белем» җәмгыяте члены. Фәнни белемнәрне халыкка таратуда киң эш алып бара. Аның катнашында Татарстан радиотапшырулар программасында «Тел күрке — сүз» исеме астында махсус бүлек оештырылды.

Фронтовик буларак һәм хезмәттәге уңышлары өчен В. Хаков Икенче дәрәҗә Бөек Ватан сугышы ордены һәм медальләр, СССР Югары белем министрлыгының «Хезмәттәге иң яхшы уңышлар өчен» билгесе, Мактау грамоталары белән бүләкләнде.

Журнал укучыларга күренекле галим Вахит Хаковның туган телебез мәсьәләләренә багышланган мәкаләсен тәкъдим итәбез.

**Вахит Хаков**

# КҮҢЕЛ КЫЛЛАРЫН ТИБРӘТҮЧЕ

Халык шагыйре Габдулла Тукай үзенең табигый сәләте, сихри моңы һәм әсәрләрендәге җанлы сөйләмнең эчке яңгырашы белән кеше күңеленең иң нечкә кылларын тибрәтүче һәм хәрәкәткә китерүче бөек шәхесләрнең берсе иде. Ул татар халкы тарихының иҗтимагый-политик вакыйгаларга бай, катлаулы бер чорында мәйданга чыкты. Аның әдәби тел тарихында тоткан урыны да XX йөз башындагы шул вакыйгалар белән тыгыз бәйләнештә карала. Тукай хәзерге әдәби телнең нигезен салды, әдәби телне халык сөйләменә якынайтуда, матур әдәбият һәм публицистика стильләрен үстерүдә гаять зур эш башкарды, телнең киң мөмкинлекләреннән файдаланып, тирән эчтәлекле һәм халыкчан әсәрләр иҗат итте. Ул әдәби телне элекке тар стиль кысаларыннан чыгарды, заман таләпләренә туры китереп, аңа киң үсеш юлы ачты. Татар әдәби теле тарихында гасырлар буе килгән уңай традицияләр Тукай иҗатында бер ноктага җыйнала һәм киң күләмдә гомумиләштерелә. Аның осталыгы да шунда: Тукай халыкны тел гадилеге һәм матурлыгы белән тәэсирләндереп кенә калмады, аны рухи азык итте, сүзнең көчен дәлилләп һәм раслап күрсәтте. Татар теленең эчке хасиятен һәм иң нечкә төсмерләрен бик ачык тойган Җ. Вәлиди Тукай әсәрләренең теле турында болай дип язды: «Тукайның иң сөйдергән ягы,— ди ул,— шөбһәсез, аның тел вә өслүбедер. Тукай кадәр җиңел вә тәкәллефсез, шуның белән бергә аһәңле вә сәлис язучы шагыйрь әле һәнүз татарда килгәне юк. Давыт кулында тимер ничек балавыз кебек булып эресә, Тукай авызында татар теле шулай эри». [1]

Тукай татар әдәби телендә генә түгел, бөтен төрки әдәби телләр үсешендә тирән эз калдырды. Шагыйрь үзенең иҗаты белән XX йөз башында яңа юнәлештә үсеп формалашып килгән азәрбайҗан, казах, үзбәк, төрекмән, башкорт, каракалпак, кыргыз, комык әдәби

[1] Вәлиди Җ. Тукайның шагыйрьлеге.— «Мәгариф», 1923, 3 — 4 сан.

телләренә дә зур йогынты ясады. Урта Азия, Казахстан, Урал буе, Кавказ язучылары Хәмзә, Кадыйри, Кербабаев, Аткай, Батырмурзаевлар, Юлтый, Кудаш, Юсупов һ. б. лар Тукай иҗаты үрнәгендә үз әдәбиятларын һәм әдәби телләрен тагы да үстерделәр һәм баеттылар. Менә ни өчен Октябрь революциясенә кадәр үк Тукай әсәрләренә игътибар иттеләр, аларны төрле телләрдә бастырып чыгардылар, шагыйрьнең иҗатына багышланган мәкаләләр яздылар. Казах («Айкап»), азәрбайҗан («Мелла Насретдин»), үзбәк («Садойи Төркстан»), төрек («Тюрк йурди»), инглиз телләрендә басылып чыккан мәкаләләр шул турыда сөйли. Революциядән соң 20 — 30 елларда ук Тукай иҗаты турында хезмәтләр һәм аның әсәрләре илебезнең күп телләрендә һәм чит илләрдә (француз, немец, венгр һ. б.) дөнья күрде.

Г. Тукай әдәби телне халыкның җанлы сөйләм теле нигезендә үстерүне иң әһәмиятле юл итеп сайлады. Бу юнәлеш аңа татар поэзия телен яңача үзгәртеп корырга мөмкинлек бирде. Шагыйрьнең татар әдәби телен үстерүгә һәм баетуга керткән иң зур өлеше дә шуның белән билгеләнә. Әдәби телдәге халыкчанлык юнәлеше дигәндә, Тукай һич тә сөйләү теле үзенчәлекләрен генә күздә тотмый, бәлки язма һәм сөйләмә форманың үзара тыгыз үрелеп, кушылып бару тенденциясен яклый. Аның бу карашлары төрле стильләрдә язылган күп әсәрләре белән ачык дәлилләнә. Ул әдәби телнең язма традицияләренә тугрылыклы булып кала. Шагыйрь элек-электән килгән язма-китап теле үзенчәлекләреннән дә, сөйләү теленең киң мөмкинлекләреннән дә дөрес файдалана. Тукай әсәрләрендә телнең тарихи үсешендә күзәтелә торган борынгы төрки-татар сүзләре дә, шактый кулланылышта булган гарәп, фарсы алынмалары да очрый. Шагыйрь рус теле һәм Европа телләреннән кереп, телдә нормалашып бара торган сүзләргә дә зур игътибар бирә. Шулай итеп ул җанлы сөйләмне әдәби тел дәрәҗәсенә күтәреп, киң мәйданга чыгаручы, аны бөтен халык өчен уртак һәм культуралы телгә әйләндерүче булды.

Тукайның замандашы һәм иҗади дусты, татар халкының классик әдибе Ф. Әмирхан шагыйрьнең үлеменә бер ел тулу уңае белән язган мәкаләсендә үк Тукай иҗатының нигезендә халыкчанлык ятканлыгын күрсәткән иде: «Милләтебезнең бөтен халык җырларындагы төп аһәң, кайгы, хәсрәт, авыр моң аһәңе, аның шигырьләрендә дә төп көй, әсас иде. Менә шуңа күрә аны халык бик яшьләй үз шагыйре итеп таныды; аны аңлады, ул җырлаган нәрсәләрнең үз рухындагы нәрсәләр икәнен тойды»[2].

Әдәби телдәге халыкчанлык юнәлешенә ул үзенең мөнәсәбәтен яшьли билгели. Моңа халык авыз иҗаты әсәрләрен өйрәнү аеруча ярдәм итә. Шагыйрь фольклор әсәрләрен җыя, аларны туктаусыз өйрәнә һәм андагы үзенчәлекләрне әсәрләрендә бик оста файдалана. Аның турында Ф. Сәйфи-Казанлы юкка гына «татар халкының телен шомарткан, зиннәтләгән, шул тел белән халкының кайгысын, шатлыгын җырлый-җырлый уртаклашкан Габдуллабыз»,— дип әйтмәгән.

Халык иҗаты әсәрләре шагыйрь күңелендә гаять зур көч булып гәүдәләнә. Тукай халык җырларында гаҗәеп тел байлыгын, халыкның осталыгын һәм телнең камиллеген күрә, моны аеруча басым ясап күрсәтә: «Халык җырларына әһәмият бирергә кирәк, дип кат-кат әйтелде инде. Ни өчен әһәмият бирергә кирәк? Шуның өчен ки, чын халык телен, чын халык рухын безгә тик халык җыруларыннан гына табып була»[3]. һәм шагыйрь үзенең фикерен болай дәвам иттерә:

«Халык җырлары чын үземезнеке генә булганда, анда читләрдән гарәп, төрек, сарт кебиләрнең тәэсире булмаганга, мин аларга әһәмият бирәм һәм мәхәббәт итәм».

Иҗатының беренче көннәреннән үк Тукай шул юнәлешне сайлап ала һәм әдәби тел үсешендә моны берданбер дөрес юл итеп күрә. Үзенең шигырьләрендә һәм публицистик мәкаләләрендә шагыйрь әдәби телне төрек һәм гарәп телләренә нигезләргә тырышучыларга каршы чыга. «Шартлар» (1906), «Янә «Тәрҗеманга» (1906), «Тәрҗеман»ның татарларга галәкасы» (1906) һ. б. әсәрләрендә ул төрекчелек агымын алга сөрүчеләрне һәм бу юнәлешне яклаучыларны каты тәнкыйть итә. «Бармы анда бер генә татарча сүз?— ди Тукай «Тәрҗеман» газетасы турында.— Көчләре беткәнче: «Без «Тәрҗеман» бабай артыннан калмыйбыз»,— дип маташкан иске өлфәтче вә башка да мөхәррирләрнең тәхрирләрен алыгыз. Бармы аларда татар рухы вә татар сүзе? Андый мөхәррирләребез татарларны төрекләштерергә аз тырышмадылар. Ләкин булдыра алмаслыкларына тәмам күзләре җиткәч кенә туктадылар»[4].

Шагыйрь тарафыннан кулланылган халык сөйләменең бик тәэсирле булуы турында Г. Рәхим болай яза: «Тукаевның теле — саф халык теле. Ул — чит сүзләр катышмаганга күрә генә түгел, үзенең бөтен төзелеше, бөтен тарзы ифадәсе (стиле) белән халык теле. Аның һәммә сүзләре «чат!» итеп бәрәләр. Ул күңелдә эз калдырырлык сүзләрне бер дә мәшәкатьсез таба ала, чөнки ул аларны төпсез кое шикелле булган халык теленнән чупли»[5].

---

[2] Әмирхан Ф. Азмы какканны вә сукканны... — «Кояш», 1913, 88 сан.

[3] Тукай Г. Әсәрләр. 4 томда. 4 том. Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1977. 279 бит.

[4] Тукай Г.— Халык әдәбияты.— Әсәрләр. 4 том, 1977, 279 б.

[5] Рахим Г. Тукаев — халык шагыйре.—«Аң», 1913, 8 сан.

Тукай иҗат итә башлаган чорда татар әдәби теле үсешендә зур үзгәрешләр һәм яңа күренешләр барлыкка килә. Халык теле киң күләмдә бердәм әдәби нормалар югарылыгына күтәрелә. Җанлы сөйләм әдәби телне билгеләүдә төп күрсәткечкә әйләнә. XIX гасырда һәм аннан да элегрәк башланган бу үзгәреш — тамырдан үзгәреш чор таләпләре белән бәйләнгән иде. Заман гасырлар буе Кол Галиләр, Котби, Сараи, Мөхәммәдьярлар, М. Колый, У. Иманиләрдән килгән традицияләрне үзгәртүне таләп итте. Яңа чор мәгърифәтчеләре мәйданга чыкты. Күренекле мәгърифәтче К. Насыйри тел белемен һәм әдәби тел нормаларын яңа баскычка күтәрде, татар теленең үз кануннарына нигезләнеп үсәргә тиешлеген яклап чыкты, фәнни-практик әһәмияткә ия булган әсәрләр язып, география, тарих, лингвистика, математика, биология, медицина һ. б. фәннәргә караган атамаларны эшкәртүдә зур хезмәт күрсәтте.

Татар әдәби тарихында К. Насыйри һәм Тукайның тоткан урыннарын Г. Сәгъди болай билгели: «Язудагы чын татар әдәби теленең нигезен,— ди ул,— К. Насыйри салды, назымда исә бу телнең нигезен салучы, аның шәкерте бөек шагыйрь Г. Тукаев булды» [6]. Поэзия телендә (Ә. Каргалый, Ш. Зәки, Акмулла, Г. Чокрый һ. б.) җанлы сөйләм үзенчәлекләрен киңрәк, югары поэтик яңгырашта, эмоциональ югарылыкта файдалану өстенлек алды. Мәсәлән, Г. Кандалыйның без XIX йөздә поэзиядә борылыш ясаучы һәм халыкның бай тел үзенчәлекләрен, шигъри сурәтләр тудырырга ярдәм итә торган тасвирлау алымнарын оста кулланучы буларак беләбез. Прозаның тагы да үсүе һәм тел чараларына баюы М. Акъегет, З. Бигиев, Р. Фәхретдинев әсәрләрендә ачык чагылыш таба. Халыкның сөйләү телендә язылган яңа драматургия стиле формалаша (Г. Ильяси, Ф. Халиди, Г. Камал драмалары).

XX йөз башы татар әдәби теле тарихында зур үзгәрешләр һәм тел тирәсендә барган көрәшнең иң кызган вакыты булды. Нәкъ шушы чорда әдәби телнең, тулысынча җанлы сөйләмгә нигезләнеп, шул юнәлештә үсеп китүе өчен яңа иҗтимагый-тарихи шартлар барлыкка килде. Җәмгыятьтәге катлаулы иҗтимагый-политик вакыйгалар, буржуаз-демократик революция алып килгән яңалыклар телнең үсешенә дә зур йогынты ясады. Нәкъ шушы чорда татар халкы арасында беренче мәртәбә марксизм-ленинизм тәгълиматы тарала башлый, яңа иҗтимагый мөнәсәбәтләр үсә һәм революцион хәрәкәт киң күләмдә җәелеп китә. В. И. Ленин 1905 — 1907 еллардагы беренче рус революциясенең тарихи әһәмияте турында болай язган иде: «Беренче революция (1906 ел) туфракны тирән казып йомшартты, гасырлар буена килгән хорафатларны тамырыннан йолкып ташлады, миллионнарча эшчеләрне һәм ун миллионнарча крестьяннарны политик тормышка һәм политик көрәшкә уятты, рус җәмгыятенең барлык сыйныфларын (һәм барлык төп партияләрен), аларның чын табигатен, алар интересларының, алар көчләренең, эш итү ысулларының, аларның якындагы һәм киләчәктәге максатларының чын чагыштырмасын бер-берсенә һәм бөтен дөньяга күрсәтте» [7]. Көн тәртибенә әдәби телне киң хезмәт ияләренең теле итү, иҗтимагый-политик төшенчәләрне халык аңына барып җитәрлек сүзләр белән белдерү, үткен агитация һәм пропаганда теле булдыру, уңышлы һәм нәтиҗәле тел-стиль чараларыннан файдалану мәсьәләләре килеп басты. Чор шуны таләп итте. Әдәби телне халык теленә якынайту язма телне аңлаешсыз чит сүзләрдән арындыру, аны җанлы сөйләм үзенчәлекләре белән тыгыз кушу юнәлешендә барды. XIX гасырда мәгърифәтчеләр башлап җибәргән бу юнәлешне, XX йөзгә чыккач, Хөсәен Ямашев, Гафур Коләхметов, Габдулла Тукай, Галимҗан Ибраһимов, Фатих Әмирхан, Мәҗит Гафури, Галиәсгар Камал, Шәриф Камал һ. б. лар яңа баскычка күтәрделәр. Бу чорда нәшрият эшенең киңәеп, матур әдәбият, публицистик һәм фәнни әдәбият әсәрләренең күпләп чыгуы, иң әһәмиятлесе — беренче мәртәбә вакытлы матбугатның мәйдан алып, киң халык арасында таралуы милли әдәби телнең нормалары ныгуга зур этәргеч ясады.

XX йөз башында әдәби телнең җирлеге киңәя, анда бөтен халык өчен уртак һәм бердәм нормалар үсеп чыга. Алар гасырлар буенча формалашып килгән күренешләрне үзләренә берләштерәләр. Шулай булганда гына нормалар тотрыклы була һәм төрле төбәкләргә тарала ала. Бу чорда әдәби телнең бөтен катламнарын хәрәкәткә китергән киң күләмдәге стилистик бүленеш башлана, яңа жанрлар туа һәм функциональ стильләр зур үсеш ала. Матур әдәбият стиле, публицистика һәм фәнни әдәбият теле эчтәлек һәм форма ягыннан тагы да байый. Үз чиратында, бу күренеш сөйләмнең дәрәслеге, төгәллеге, ачыклыгы һәм гадилеге кебек төшенчәләр белән бәйләнештә торган тел нормаларында да ачык чагыла.

Тукай телнең сүзлек хәзинәсе белән оста эш итә, лексик чараларның төрле үзенчәлекләреннән файдалана. Бер үк сүз аңарда төрле мәгънә төсмерләре белдерүгә ярдәм итә. Күпмәгънәлелек (полисемия) дип йөртелгән бу күренеш Тукайда аеруча еш күзәтелә. Сүзләрнең мәгънәләрен ачуда контекст зур урын тота. Тукайда х а л ы к сүзенең мәгънә төсмерләре күп. Киң мәгънәдә ул җәмгыятьтәге барлык иҗтимагый катлаулар һәм сыйнфый төркемнәрне белдерә. Хезмәт ияләре, эшче-крестьян мәгънәсендә бу сүз еш очрый: «Быел

[6] Сәгъди Г. Татар халкының үсешендә К. Насыйриның роле.— «Совет әдәбияты», 1944, 10 сан, 53 б.

[7] Ленин В. И. Әсәрләр. Дүртенче басмадан тәрҗемә. 23 т. 1960, 322 б.

ул әфәнде халыкны чакырса да, халык сарык тиресе ябынып килгән бүрене таныды» («Тәшәккер»). Шул юнәлештә Тукайда бик күп фразеологик әйтелмәләр барлыкка килә (халык моңнары, халык хисе, халык теләге, халык уе һ. б.). Шулай ук аңарда, сөйләү телендәгечә, х а л ы к сүзен кош, хайван, бөҗәк исемнәренә кушып әйтү киң таралган. Мәсәлән: «Аны шунда ч е б е н  х а л к ы тынычсызлый» («Ялкау мәзмай»), «Мин карыйм да һәм дә күрәм к о ш  х а л к ы сез» («Өч хакыйкать»). Халык сүзе милләт, кешеләр төшенчәсендә дә һәм башка төсмерләрдә дә киң кулланыла. Сүзләрне күпмәгънәле иткәндә, аларны көчерелмә мәгънәдә куллану омтылышы өстенлек ала. Төп мәгънәсендә бирелү белән беррәттән, сүзләр башка төшенчәләргә дә күчереләләр. Мәсәлән, диңгез, йөрәк, дәрәҗә, дөнья, җәмгыять, иш, ерак, ис, йөзү, йөрү һ. б. бик күп сүзләрнең яңа мәгънә төсмерләре барлыкка килә. Шагыйрь поэтик сөйләмнең яңгырашын һәм аһәңен көчәйтүдә мәгънә ягыннан бер-берсеннән ерак торган авазлаш сүзләрдән (омонимнар) дә оста файдалана. Бу чараның киң күләмдә поэзия телендә урын алуына без Тукайга бурычлыбыз. Поэтик каламбурлар шул авазлаш сүзләр нигезендә барлыкка килә. Мәсәлән:

Тегермән әйләнә-әйләнә дә, тартылмыйдыр ярма,
Мәшәкатьләнмә бушка көчләнеп, юл уртасын ярма.

(«Мөтәшагыйрьгә»)

Ул баш әйтте: «Син вагоннан т ө ш  х ә з е р,
Бик якынлашты кирәкле т ө ш  х ә з е р.

(«Печән базары, яхуд Яңа Кисекбаш»)

Бу алымны Дәрдмәнд һ. б. шагыйрьләр дә нәтиҗәле файдаландылар.

Татар әдәби телендә градация алымының да киң кулланыла башлавы, бу алым белән поэзия теленең баюы Тукай исеме белән бәйләнгән. Бер-бер артлы тезелеп килгән сүзләр, мәгънә ягыннан көчәйтелеп, әйтелә торган фикернең эзлекле рәвештә күтәрелә баруын яки түбән таба төшүен белдерәләр. Кайбер мисаллар:

Җәй көне. Эссе һавада мин суда коенам, йөзәм;
Чәчрәтәм, уйныйм, чумам, башым белән суны сөзәм.
...Күрмимен алны вә артны, и чабам мин, и чабам;
Ашыгам, тирлим, пешәм һәм кып-кызу уттай янам.

(«Су анасы»)

Шул рәвешле тиңдәш кисәкләрнең үзләренә хас стилистик үзенчәлекләре барлыкка килә. Мәгънә ягыннан градацияләрдә үзара синоним сүзләр дә катнаша, әмма бу алар өчен бердәнбер шарт түгел. Градацияләрдә теге яки бу күләмдә аерым җөмләләр дә катнаша ала:

Тик көнә торганда капланды томанга бар һава;
Кар оча, кар себерелә, кар котрына һәм кар ява.

(«Буран»)

Төрле иҗтимагый-политик фикернең динамик үсешен тәэмин итүдә, аны калкурак итеп күрсәтүдә дә градацияләр зур әһәмияткә ия.

Кибеп беттек,
Саргайдык без,
Корып беттек
Таяклардай.

(«Мәдрәсәдән чыккан шәкертләр ни диләр?»)

Шагыйрь бу алым белән өстен сыйныф вәкилләренә үзенең карашын да белдерә.

Бетер! сындыр, кырып ташла, мөгальүррә вә билбанзай!

(«Сорыкортларга»)

Г. Тукай татар революцион-демократик публицистикасын һәм аның телен үстерүгә зур өлеш кертә, аны жанр ягыннан баетуда һәм вакытлы матбугат аша әдәби телне киң халык массасына җиткерүдә әһәмиятле эш башкара. Ул иҗтимагый-политик публицистиканың очерк, памфлет, фельетон, сатирик мәкалә кебек жанрларын күп куллана. Шагыйрь аларны сатирик, фаш иткеч тел белән сәнгатьчә югарылыкта иҗат итә. Шунлыктан Тукайның публицистик әсәрләре тел-сурәтләү чараларының байлыгы, сөйләмнең эмоциональ яңгы-

рашы белән матур әдәбият теленнән аерылмый. Анда киң җәмәгатьчелекне дулкынландыра торган, заман таләпләренә туры килгән иҗтимагый-политик һәм тормыш-көнкүреш мәсьәләләре күтәрелә. Шагыйрь халыкны җәмгыятьтәге кимчелекләргә һәм искелеккә каршы көрәшкә чакыра, яңалыкны тоткарлап, белемгә-мәгърифәткә бару юлында киртә булып торучы һәрнәрсәне юк итәргә өнди. «Безнең милләт үлгәнме, әллә йоклаган гынамы?» исемле сатирик әсәрендә Тукай азатлыкка һәм киләчәк якты идеалларга ирешү максатын тормышка ашыруны бөтен кискенлеге белән куя: «Тагы да ул кортлар вә ул козгыннарның милләтне ни рәвешле ашаганнарын рәссамнар хезмәте илә милләтнең үзенә күрсәтик, милләтне аларга каршы ачуландырмыйк, чәчләрен аягүрә торгызыйк; борынгы кыйлган эшләре өчен милләт аларны аяк астына салып изсен, һич дөньяга килмәгән кеби итсен; каргаларны муеныннан кысып, борынгы ашаганнарын кырылдатып чыгарсын».

Кош, хайван, бөҗәк исемнәрен күчерелмә мәгънәдә кулланып, Тукай көчле сатирик эффектка ирешә, үткен сүзләр, сатирик-метафорик бәяләмәләрне киң куллана, аларны сүз уйнату алымы белән бергә куша. Әйтергә кирәк, бу бик уңышлы чыга. Мәсәлән: Тәрҗеман бабай, мәкъбуль озын вә биек папаха (И. Гаспринский), ахмакҗан, кабан дуңгызы («Бәянелхак» редакторы Әхмәтҗан Сәйдәшев), интеллигентный монах (М. Бигиев). Эчтәлеккә туры китереп, шагыйрь мондый әйтелмәләргә дә шактый урын бирә: курчак уены (думага сайлаулар), сыра мичкәсе (байлар), теләнче фабрикасы (мәдрәсәләр), дингә мишәйт («Дин вә мәгыйшәт» журналы) һ. б.

Тукай поэзиясе һәм публицистикасы сатирик тел-стиль чараларына гаять бай. Шагыйрь, сүз уйнату, сатирик характеристикалар, образлы комик сыйфатлау һәм чагыштырулар, ирония, пародия, риторик өндәү һәм сорау, кабатлау алымнары, бер-берсенә капма-каршы куелган сөйләм берәмлекләре, сәнгатьчә сурәтләү чараларының күп төрләрен кулланып, үзенең дошманнарын һәм җәмгыятьтәге кимчелекләрне рәхимсез фаш итә. Бу алымнарның һәрберсе сөйләмдә нинди дә булса бер максатны үти. Мисалга Тукай стиленә хас алогик чараларны — оксюороннарны алыйк. Кайбер очракларда теге яки бу тезмәләр, фразалар эчендәге сүзләр арасында үзара логик бәйләнеш бозылырга да мөмкин. Тукайда ул капма-каршылык мөнәсәбәтен белдерүче үзенә бер сатирик алым булып китә. Теге яки бу объекттан көлү һәм аны фаш итү өчен, шагыйрь аннан бик оста файдалана. Хосусый милекчелек белән бәйләнешле аптекалардан һәм аларның хуҗаларыннан көлү өчен, ул «Алырга ашыгыгыз!» дигән фельетонында болай яза: «Сукырайта торган, баш авырттыра торган, эч күптерә торган дарулар сатыладыр». Монда дарулар сүзен ачыклап килүче сүзләр логик бәйләнештә түгел. Шунлыктан ул үзенә бер алымны — оксюморонны барлыкка китерә.

Төрле вакыйгалар яки күренешләр арасында каршылыкны белдергәндә, Тукай еш кына антитеза алымына да мөрәҗәгать итә. Мондый сөйләмдә вакыйгалар бер-берсенә каршы ике яссылыкта сурәтләнә. Җәмгыятьтәге тигезсезлекне биргәндә, бу алым аеруча отышлы.

Ул хәзер туктар сиңа, и ач авыл, мохтаҗ авыл!
Җимрек өй каршында ич оҗмах кеби кәйфиясе.

(«Сайфия»)

Антитезалы сөйләм ясауда шагыйрь антоним сүзләрне генә түгел, төрле лексик берәмлекләрне ала. Болай эшләү сурәтләү мөмкинлекләрен бермә-бер арттырырга мөмкинлек бирә. «Ит базарында тәрәккый» шигырендә нәкъ шуны күрергә була.

Тукай әсәрләрендә контекст белән бәйле рәвештә төрле стилистик төсмерләр алган лексик берәмлекләрнең аерым катламнары бергә кушыла. Әйтик, публицистик әсәрләрдә иҗтимагый-политик төшенчәдәге сүзләр аеруча зур урын ала. Җәмгыять, хөкүмәт, сыйныф, җыелыш, берләшү, сайлау, алмашмак, чыгару, бәһа, акча, эшне бүлмәк, товар кыйммәте, акча кыйммәте, хезмәт вакыты, сорау-сорату кебек сүзләр һәм сүзтезмәләр белән беррәттән, рус, Европа телләре сүзләре дә шактый киң кулланыла. Мәсәлән: капитал, социалист, политика, конкуренция, депутат, бюрократ, локаут, аристократ, дума, вексель, манифест, банкрот һ. б. Халыкара сүзләр белән шулай баету юнәлешен Тукай тагы да үстереп һәм киңәйтеп җибәрә. Аның әсәрләрендәге иҗтимагый-политик фразеология дә публицистик стильнең бер үзенчәлеген тәшкил итә, гадилеккә, югары яңгырашка, сәнгатьчә югарылыкка ирешүдә уңышлы чараларның берсе булып тора. Бу төркемгә кергән фразеологик әйтелмәләр мәгънә ягыннан иҗтимагый төшенчәләрне белдерүгә, шул чордагы тарихи вакыйгаларны аңлауга һәм төшенүгә ярдәм итәләр. Мәсәлән, *җанлы мал* әйтелмәсе, эшче сүзенә синоним буларак, капитал дөньясының эчтәлеген, завод-фабрикалардагы эш шартларын ачык күзалларга мөмкинлек бирә. *Җәза таңы, җәза мәйданы, кайгы болытлары, наданлык урманы, тормыш дулкыннары, җәһәннәм газаплары, милли болытлар* кебек әйтелмәләрдә дә иҗтимагый-политик вакыйгаларга бәйләнешле мәгънә төсмерләре салынган. Бу чорда *милләт, халык* сүзләреннән торган әйтелмәләр киң кулланылышта була. Тукайда болар үзенчәлекле стиль тудыра. Мисалга *милләт тамырлары, милләт йокысы, милләт сурәте, милләт балалары, милләт акчасы, милләт җилкәсе, милләт кортлары,*

миллэт микроблары, миллэтне юату, миллэтнең һушы киту, миллэтне ашау кебек эйтелмэлэрне алырга мөмкин. Халык кызы, халык диңгезе, халык аңы, халык уянуы,халык азатлыгы һ. б. фразеологик берэмлеклэр дэ шул өлкэгэ карый. Әсэрнең идея эчтэлегенэ карап, аларда тегe яки бу күлэмдэ төрле мэгънэ төсмерлэре күзэтелэ. Гомумэн, Тукай поэзиясе үзе дэ революцион-публицистик пафос белэн сугарылган. Бу — тел-стиль чараларында да ачык күренэ. «Государственная думага», «Иттифак хакында», «Сорыкортларга», «Китмибез», «Көзге җиллэр» кебек шигырьлэр шуны ачык раслыйлар.

Бирэдэ тагын бер хакыйкатьне билгелэп үтмичэ мөмкин түгел: төрле халыкларның классик шагыйрьлэрендэ язу-стиль алымнарында аерымлыклар, шэхси-индивидуаль үзенчэлеклэр булу белэн берраттэн, аларның хис-тойгыларында, психологик кичерешлэрендэ, фэлсэфи фикер йөртүлэрендэ һэм иҗади алымнарында зур охшашлык та күзэтелэ. Тукайның «Туган җиремэ» дигэн шигырендэге:

> Айрылып китсэм дэ синнэн гомремнең таңында мин,
> И Казан арты! сиңа кайттым сөеп тагын да мин,—

дигэн юлларны укыгач, үзеннэн-үзе М. Лермонтовның «Кавказ» шигыре искэ төшэ.

Лермонтовка Кавказ кадерле булган кебек, Тукай өчен Казан арты да шулай ук якын. Әсэрдэге мондый охшашлыкларны, бердэн: халыклар тарихында гомуми культура байлыгы нэтиҗэсе итеп бэялэргэ, традиция рэвешендэ буыннан-буынга күчеп килгэн төрле алымнар һэм фикер үсеше белэн бэйлэп карарга мөмкин. Икенчедэн, кешелек дөньясында гасырлар буе иҗат ителгэн эдэбиятны файдалану һэм тэрҗемэ итү юлы белэн дэ үз эдэбиятыңны баетырга мөмкин. Тукай моннан да киң файдалана. Ул гомумтөрки һэм Көнчыгыш иран-гарэп культурасы белэн бэйлэнешле традициялэргэ дэ тугрылыклы булып кала, эдэби телне рус һэм Көнбатыш Европа эдэбиятындагы тел-стиль, сурэтлэү алымнары белэн дэ баета. Башка эдэбиятлардан үрнэк алганда, Тукай эсэрне үз стиле аша үткэрэ, аны төрки-татар поэтик традициялэренэ яраклаштыра, классик шигырь төзелешенэ якынайта һэм аны күлэм ягыннан да үзгэртэ. Мэсэлэн, ул А. Пушкинның «Евгений Онегин»ындагы 14 юллы бер өзекне файдаланып, «Кемне сөяргэ кирэк?» дигэн 20 юллы яңа эсэр иҗат итэ. Ирекле тэрҗемэ рэвешендэ язылган «Алтын этэч» экияте Тукайда 16 иҗекле классик шигырь төзелешенэ буйсындырыла һэм юл саннары ягыннан шактый кыскартыла (224 юлдан 194 юлга калдырыла), э һэр юлдагы иҗек саннары икелэтэ арттырыла (Пушкинда строфалар 8—8—7—7 үлчэмендэге шигъри юллардан тора). Лермонтовтагы 20 юллык шигырь Тукайда «Вэгазь» исемендэ 38 юллык шигырь булып китэ. Шагыйрь башка эдэбиятлардагы фикерне җанлы сөйлэм чаралары белэн күңелгэ ягымлы итеп халык күңеленэ җиткерэ. Татар поэзия һэм проза телен Көнчыгыш һэм Көнбатыш классик эдэбиятындагы стилистик алымнар, тел-сурэтлэү чаралары белэн баета. Яңа эйтелмэлэр, киңэйтелгэн чагыштырулар, күчерелмэ мэгънэдэге символик-метафорик сүзлэр, теземнэр, сорау һэм җавап алымы һ. б. тел-сурэтлэү чаралары татар эдэби телендэге башка тел-стиль үзенчэлеклэре белэн бергэ кушыла.

Тукай татар сөйлэменең эчке мөмкинлеклэрен киң рэвештэ эшкэ җигеп, тел-сурэтлэү чараларын гаять оста куллана белүче, эдэби теллэрнең стильлэрен, бигрэк тэ матур эдэбият һэм иҗтимагый-публицистика телен яңа юнэлештэ үстереп җибэрүче һэм аларны тагы да баетучы, эдэби телнең үсешенэ йогынты ясаучы, аңа сизелерлек өлеш керткэн шагыйрь һэм эдип булып тарихка кереп калды. Шиһап Рамазанов бу хакта бик урынлы эйткэн иде: «Тукай иҗаты, бер яктан, татар халкының эдэби үсеш процессын һэм эдэби теле оешу тарихының үткэннэрен чагылдырса, икенче яктан, татар эдэбияты теленең җитлеккэн гүзэл үрнэклэре булып тора»[8].

Шуны да эйтергэ кирэк: эле бездэ Тукайның теле, язу алымнары бер эзлеклелектэ тиешенчэ тикшерелмэгэн һэм өйрэнелмэгэн. Бу мэсьэлэдэ моңа кадэр чыккан мэкалэлэр һэм берничэ диссертация белэн генэ чиклэнеп булмый. Пушкинны, Горькийны, Шолоховны өйрэнгэн кебек (аларның иҗаты, тел-сурэтлэү, язу алымнары турында йөзлэрчэ диссертациялэр, фэнни монографиялэр бар), Тукайны да җентеклэп өйрэнергэ вакыт җитте. Берничэ томнан торган «Тукай сүзлеге»н чыгару мэсьэлэсен дэ хэл итэсе иде. Русларда күп томлы «Пушкин сүзлеге», үзбэклэрнең «Навои сүзлеге» безнең өчен матур үрнэк булып санала.

Тукай: «Минем һэр минутым бөтен дөнья бэһасенэ тора»,— дип, үзенең бөеклеген бик дөрес күрсэткэн иде. Әйе! Без моңа көннэн-көн инана барабыз. Тукай башкарган эш шагыйрь иҗатының һэр минуты дөнья бэясе тора. Татар халкының бөек улы Габдулла Тукайны без шулай бэялибез һэм аны шулай тэкъдир итэбез.

***

[8] Рамазанов Ш. А. Татар теле буенча очерклар. Казан, 1954, 90 б.

# Иван Ионенко



*Иван Михайлович Ионенко (1913) — Казан дәүләт университеты профессоры, тарих фәннәре докторы, Татарстан АССРның атказанган фән эшлеклесе. Ул — Татарстанда Бөек Октябрь революциясе, Казан хәрби округындагы солдат массалары арасында революцион хәрәкәт һ. б. күп кенә проблемалар буенча язылган берничә монография һәм дистәләрчә мәкаләләр авторы. И. Ионенко Бөек Ватан сугышының беренче көннәреннән алып ахырына кадәр хәрәкәттәге армиядә була. Сугыштан соң ул яшьләр арасында совет халкының фашистлар Германиясен тар-мар итүдә күрсәткән батырлыкларын пропагандалауга күп көч куя; сугыш вакытында Татарстанда, Идел буенда формалашкан хәрби частьларның сугышчан юлын өйрәнү һәм хәрби-патриотик тәрбия эше белән шөгыльләнүче «Кар десанты» хәрәкәтенең республика штабы фәнни консультанты булып тора. Тиздән Татарстан китап нәшриятында И. Ионенконың Курляндия ярымутравындагы дошман гаскәрләрен тар-мар итүнең соңгы көннәрен тасвирлаган истәлекләр китабы дөнья күрәчәк. Укучыларга шул әсәрдән бер өзек тәкъдим итәбез.*

## ШТАБ ОФИЦЕРЫ ЯЗМАЛАРЫ

Илебез бөек Җиңүнең 41 еллыгын билгеләп үтте. Берлин өстендә тантаналы салют булып яңгыраган соңгы залплардан соң күп сулар акты.

Онытып буламы соң әлеге май көнен?! Җиңүгә илткән озын һәм авыр юлны онытып булмаган кебек, бу көнне дә онытып булмый. Әлеге юл дәһшәтле сугышлар, миллионнарча үлем хәбәре, күз яшьләре, шатлыклар һәм өметләр белән тулы булды. Безнең Җиңүебезгә бөек ышаныч белән тулы булды!

Без, сугыш мәхшәрләрен күргән, аннан туган өйләребезгә әйләнеп кайткан кешеләр, исән калганнар һәм һәлак булганнарны салкын акыл белән түгел, ә кайнар йөрәк хәтере аша искә алабыз. Менә шуңа күрә дә безнең һәрберебездә сугыш турында үз сүзеңне әйтү, гражданлык һәм әхлакый бурычыңны үтәү теләге яши...

1946 елда ук инде мин Суворов орденлы 334 нче Витебск укчы дивизия сугышчыларының батырлыгы хакында истәлекләрем белән уртаклашкан идем. Казанда, Татарстан АССР Берләштерелгән үзәк дәүләт музее фронтовик хезмәткәрләре җыелышында булды бу. Шул ук елны хәрби округ штабы начальнигы генерал Долговның үтенечен тыңлап, Курляндия ярымутравындагы сугышлар, фашистлар Германиясе армияләренең Курляндия группасын тар-мар итү турында офицерларга ике лекция укыдым.

Эш шунда, 1945 елның 9—15 маенда Курляндия группасының төп штабын юк итү буенча Ленинград фронты штабы төзегән комиссиядә мин оператив идарә вәкиле идем, һәм миңа әлеге комиссия дошман штабында эшләгән вакытта да, Мажейкяйдагы [1] фронт штабына әйләнеп кайткач та комиссиянең төп документларының каралама вариантын әзерләү йөкләнде. Бер үк вакытта, сугыш тәҗрибәсен өйрәнү бүлегендә хәрби хәрәкәтләр тарихчысы буларак, комиссия эше буенча көндәлекләр дә алып бардым. Комиссия

[1] Истәлектә телгә алынган шәһәр, авыл, елга, күл һ. б. атамалар шул чордагыча калдырылды.

председателенең ярдәмчесе сыйфатында «Курляндия» группасы штабы житәкчеләре белән булган сөйләшүләрнең барысында да катнаштым. Алтмышынчы елларда «Литературная газета» ның «Чәнечкеле мәкаләләре»нә «Генерал Ферч ничек итеп әсир төшүен онытмадымы икән?» дигән язмамны әзерләгәндә, төрле материалларны өйрәндем һәм хәрби-тарихи очерк яздым.[2] Аннан алдарак сержант Степинның 1941 елның июлендә Оршадан ерак түгел Могилев шоссесында күрсәткән батырлыгы турында беренче язмам дөнья күргән иде. Шәхси архивымда 18 нче дивизия сугышчыларының батырлыгына багышланган телевизион тапшыруның машинкада басылган күчермәсе, 1971 елның апрелендә Үзәк телевидение буенча «Батырлык» тапшыруында күрсәтелгән «Смоленск өчен сугыш» дигән сценарий һәм башка материаллар сакланган.[3] Боларның барысы да мине яңадан кулыма каләм алырга кызыктырып торды, әмма төрле сәбәп аркасында моны эшли алмадым.

Профессиональ тарихчының хәтере һәрвакытта да үткен вакыйгалар һәм үзара бәйле күренешләрнең датасы, урыны, үзенчәлеге белән тулы. Әмма ничәмә-ничә дистә еллар үткәннән соң бары тик хәтергә генә ышану дөрес тә һәм мөмкин дә түгел.

Шәхси архивымда көндәлек формасындагы язмалар, документлар, фронт газеталары, штаблар урнашкан торак пунктлары исемлеге, фронт хатлары, бергә хезмәт иткән дусларым белән сугыштан соң язышкан хатлар, истәлекләр, фоторәсемнәр һәм башка материаллар саклана.

Минем фронтта булуым гадәттән тыш рак диярга була. Беренче ел ярымны исәпкә кертмичә, хәрби хәрәкәтләр «елъязмачысы» һәм тарихчысы булып эшләдем. Шуның аркасында күп нәрсәләр белергә, күп кешеләр белән очрашырга һәм сөйләшергә туры килде. Алар арасында төрле дәрәҗәдәге командирлар һәм политработниклар, хәтта политбүлек начальниклары, эре штаб начальниклары, Хәрби совет членнары һәм армия командующийлары да бар иде.

Армиядәге хезмәтемнең өч елга якыны Россиянең төньяк-көнбатыш кинлекләрендә узды. Көнбатыш Двина, Идел һәм Днепрның югары өлешләре: Торжек, Торопец, Смоленск өлкәсе һәм Белоруссиянең борынгы шәһәрләре Россиянең әлеге төньяк-көнбатыш калканының изге үткәне, буыннар бәйләнеше, Валдай калкулыгында, Белоруссиядә, Балтик буенда Ватаннарын үз тормышлары бәрабәренә саклап калган баһадирлар турында искә төшерде.

Сугыш ветераны, бүгенге көндә танылган тарихчы, академик А. М. Самсонов бик хаклы рәвештә болай дип язды: «Үткәннәр истәлекләрдә дә (аеруча тарихта) чынбарлыкта булганча калырга тиеш». «Сугышның үзе кебек үк, фронтның кырыс чынбарлыгы хаталарсыз, ялгышсыз һәм «негатив момент» дигән нәрсәләрсез була алмый».

Без өйрәнгән, хәтердә нык уелган материаллар, факт һәм хәлләр К. Симоновның сугыш турындагы тирән күзәтүләре белән килешүне таләп итә. 1977 елда алган кайбер хатларга җавапларында ул бу хакта бик дөрес яза. Генерал М. Дударенкога җавап хатында ул теләк һәм чынбарлыкны, устав положениеләрен һәм сугышның реаль практикасын бутамаска киңәш итте. «Ә бит боларның бөтенесе чынлап та бер-берсенә туры килми, еш кына туры килми иде. Үзегезнең зур тәҗрибәгез белән, Сез моны миннән яхшырак беләсез».

Хәтергә хокук — изге хокук. Сугыштан әйләнеп кайтачак кешеләрнең язмышы нинди буласын берәү дә белмәде, әмма фронтовиклар соңыннан, дистә еллар үткәч тә, тормышның бөтен яктан хаклыкка нигезләнәчәгенә ышандылар.

Алтмышынчы елларда яшьләр арасында массовый хәрәкәт — КПСС һәм совет халкының революцион, сугышчан һәм хезмәт даны урыннары буйлап Бөтенсоюз походы җәелеп китте.

Миңа В. И. Ульянов-Ленин исемендәге Казан дәүләт университетының «Кар десанты»н оештыручыларның берсе булу бәхете тиде. Анда катнашу-

---

[2] «Литературная газета», 1963 елның 23 феврале. Кулъязманың машинкада басылган нөсхәсе 1964 елда СССР Оборона министрлыгының хәрби тарих институтына, генерал Н. И. Шеховцевка тапшырылган.

[3] Авторның шәхси архивында фронт тормышы белән бәйле меңнән артык материал саклана. Йөзләгән хатны О. В. Меньшикова-Ионенко саклап калган. Туганнардан һәм дуслардан, шул исәптән фронтовиклардан килгән 300 дән артык хатны 1943 елның көзендә кыска сроклы ял бирелгәч һәм армиядән 1945 елның көзендә кайтканда үзем белән алып кайттым.

чы студентлар, илебездәге башка күпләгән отрядлар кебек үк, сугыш юллары буйлап йөрделәр.

Походтан кайткан десантчылар белән очрашкан, аларның сөйләгәннәрен тыңлаган, дулкынланган йөзләрен күргән саен, мин шуны аңладым: әйе, боларның барысы да яшьләргә бик тә кадерле, һәм мин үзем күргән, кичергән нәрсәләрне үз әчемдә бикләп яткырырга тиеш түгел.

1944 елның көзендә Курляндия ярыматавында фашистлар Германиясе гаскәрләренең зур группасы кысрыкланды.

Безнең командование ифрат авыр шартларда, — юлларда үтә алмаслык пычрак, туктаусыз салкын яңгыр ява иде, — яңа һөҗүм әзерләде. 4 нче удар армия сугышчылары алдына Октябрь революциясенең 27 еллыгына Вента елгасы ярына чыгу бурычы куелды. Командарм генерал-лейтенант П. Ф. Малышев белән Хәрби совет члены генерал Т. Я. Белик гел дивизияләрдә булдылар. Яңа һөҗүмнең беренче көннәрендә 1941 елда Казанда оештырылган 334 нче Витебск дивизиясе частьлары һәм подразделениеләре массовый батырлык үрнәкләре күрсәттеләр. 1126 нчы укчы полк рядовойлары А. Ф. Кухтин белән И. С. Смирнов, оста һәм кыю сугышып, дошманның ике танкын яндырды. Күрше дивизия разведчигы В. М. Яглинский дошманның 26 солдатын әсирлеккә төшерде, алты тапкыр яраланса да, сугыш кырыннан китмәде. Ул Советлар Союзы Герое исеменә лаек булды, Ленин ордены һәм Алтын Йолдыз медале белән бүләкләнде.

Ноябрь башында чираттагы һөҗүмгә әзерлек башланды. 20 ноябрь төнендә 4 нче удар армия гаскәрләре Вента елгасын кичеп чыкты. Бу вакытта күргән кыенлыкларны, киренкелекне, газапларны сүз белән генә аңлатып бетерерлек түгел. Һөҗүм 21 ноябрьдә башланды, әмма аның нәтиҗәләре әллә ни куанырлык булмады. Ул көннәрдә рота командиры Прохоров зур батырлык эшләде, үлгәннән соң аңа Советлар Союзы Герое исеме бирелде. Сержант Т. П. Лоскутов Александр Матросов батырлыгын кабатлады.

Вентаны кичү һәм шуннан соңгы һөҗүм безнең сугышчыларның көчен сынаган иң югары нокта булды дияр идем. Бары тик үз бурычларын югары дәрәҗәдә аңлау гына кешеләргә аякларында басып торырлык көч бирде, аларны гади солдатлардан әкияттәге баһадирларга әверелдерде.

Өстән көне-төне карлы яңгыр яуды. Урман катнаш сазлыклы җирдә юллардан үтәрлек түгел иде. Манма су булган, өшегән солдатлар, җилкәләрендә күтәреп, ерак араларга снарядлар, миномет һәм пулеметлар алып бардылар.

Пулемет ротасы командиры Риза Таһировның 1944 елның 20 гыйнварендә язган соңгы хаты бу көннәрне бик ачык күз алдына китереп бастыра:

«Хәзер генә тиешле хезмәт урынына билгеләндем. Балтик ярында бүленеп калган немецларны дөмбәсләүне дәвам иттерәбез. Берәр ничек исән калсам, бу хатны язганнан соң бер атна узгач, үзем турында хәбәр итәрмен. Эш шундый күп, көн шундый начар, — кар, яңгыр, салкын. Менә мин, түмгәктә утырып, сиңа хат язам... Әгәр исән калсак, бу хатлар тарихи хатларга әвереләчәк. Ул чакта мин бу хатны язганда ниләр булганын барысын да сөйләрмен...

Хатны укыгач, минем өчен балаларны кочаклап үп».

Хатын яза башлагач та Риза: «Кием әйбәт, ашау яхшы, тукбыз, тик борын гына дары исенә тыгылган», — дип хәбәр итә.

Курляндия сугышлары героена яраткан хатыны Әминәгә әлеге хатны язганда һәм язганнан соң булган хәлләрне сөйләргә насыйп булмый. Риза Таһиров батырларча һәлак була. Хәзер аның уллары гаилә ядкаренә әверелгән әлеге хаттагы сүзләрне зур горурлык белән укыйлар.[1]

1944—45 еллардагы авыр шартларда 2 нче Балтик буе фронты гаскәрләре, Балтик флоты белән бергәләп хәрәкәт итеп, дошманның яхшы ныгытылган оборонасына берничә уңышлы һөҗүм ясадылар, аның үз көчләрен Германия территориясенә күчерү, частьларын азык-төлек һәм сугыш кирәкярагы белән нормаль тәэмин итү мөмкинлеген бетерделәр.

2 нче Балтик буе фронтына кушылгач та маршал Говоров җитәкчелегендә актив хәрәкәтләр тукталмады. Дошманның бу группировкасын таркатып, аны тулысынча капитуляция ясарга мәҗбүр итү өчен, хәлиткеч һөҗүмгә әзерлек башланды.

1945 ел маеның беренче көннәрендә, совет гаскәрләренең Берлин опера-

[1] Укытучы Әминә Каюмовна өч ул үстерә, аларда һәлак булган әтиләренә карата тирән мәхәббәт һәм хөрмәт тәрбияли. Өлкән улы Дамир Ризакович — төзүче мастер, Индус Ризакович — КДУ профессоры, тарих фәннәре докторы, кафедра мөдире, Энгель Ризакович — Казан дәүләт культура институты проректоры, доцент.

циясендә искиткеч уңышларга ирешүеннән соң, Гитлер Германиясен тулысынча тар-мар итү фактка әверелде.

Әмма Германия, Чехословакия, Австриядә һөҗүм итүче гаскәрләребез дошман частьлары һәм берләшмәләренең көчле каршылыгына очрады. Бары тик 7 майда гына немецларның баш командованиесе гомуми капитуляция турында карар кабул итте. Төн урталары тирәсендә «Курляндия» группасы штабы гроссадмирал Деництан капитуляция турында приказ ала.

7 майдан 13 майга кадәр ниләр булганын аңлар өчен «Төньяк» армияләре группасының соңгы командующие, пехота генералы Гильпертны характерлый торган кайбер мәгълүматларга мөрәҗәгать итик. Сугышның соңгы елында ул фюрердан күп нәрсә ала. 1944 елның җәендә — корпус, 1945 елның язында армия группасы белән командалык итә, пехота генералы дәрәҗәсенә күтәрелә, күп кенә бүләкләнә, 1944 елның сентябрендә ул тантаналы итеп үзенең туган көнен үткәрә. Әмма аңа ул көннәрдә хәтта саташу рәвешендә генә булса да әлеге туган көнгә чакыру билеты артына соңыннан, бернича ай узгач, совет маршалы Говоров исеменә язу язачагы төшенә дә кермәгәндер. Бу «соңгы» документ иске готика шрифты белән язылган, аннары машинкада күчерелгән, әмма аңа имза куелмаган. Күрәсең, хатның проекты 8 май иртәсендә язылгандыр, ул котылгысыз һәлакәтне берәр ничек җиңеләйтергә тырышу чарасын эзләү нәтиҗәсе булгандыр. Шул ук вакытта Гильперт күпмедер дәрәҗәдә русларның җиңелгән дошманга карата гуманлы мөнәсәбәте турында да уйлангандыр.

Шунысын искә төшерик: Берлин операциясе башлануга өч көн кала гаскәрләр Австрия башкаласын азат итә, һәм дөнья Америка президенты Франклин Делано Рузвельтның үлүе турындагы хәбәрне ишетә. Ул көннәрдә сүз бер-берсенә бөтенләй бәйләнеше булмаган шушы ике вакыйга, факт хакында барды. Без, Тәһран һәм Ялта конференцияләрендә катнашып, исемен тарихта калдырган президент Рузвельтның үлеме уңаеннан үзебезнең кайгы хисләребезне яшермәдек. Аның фашистлар Германиясе һәм милитаристик Япониянең тулы капитуляция ясау көннәренә кадәр яши алмавына кайгырдык.

Ул көннәрдә Курляндия группасының төп штабында хәлләр бик тә мөшкел була. 10 һәм 11 апрельдә үк инде штабны «...рус самолетлары» бик каты бомбага тота. Вилладан бункерга күчәргә туры килә. 16 апрельдә генерал Гильперт штаб начальнигы Ферч белән яңашә блиндажда, ә 18 апрельдә инде Берлинда була.

Потсдамда җир астында традицион төстә Гитлерның туган көнен бәйрәм итәләр. Аның якын фикердәшләре хәзер Черчилль белән Американың яңа президенты Трумэнга өмет баглый. Алар, Рузвельт үлгәч, Англия белән АКШның идарәче даирәләре арасындагы өченче Рейхның хәрби потенциалын саклауны һәм Советлар Союзына каршы тору өчен берләшүне яклаган группаларның активлыгы артырга тиеш дип уйлый.

Генерал Гильперт белән оператив идарә начальнигы Рихтер Потсдамда Гитлерның туган көне уңаеннан үткәрелгән кабул итү мәҗлесендә булалар. «Курляндия» группасы командующие белән Гитлер арасында барган әңгәмә хакында Рихтер безгә 12 майда болай дип сөйләде: «Гильперт гаскәрләренең зур группасының (390—400 мең солдат һәм офицер) киләчәктә дә Курляндиядә торуының максатка ярашлы булуына шик белдерде. Ул саклык белән генә Курляндия дивизияләрен диңгез аша Берлин юнәлешендәге фронтларга — Жуков һәм Рокоссовский гаскәрләренә каршы чыгару турындагы фикерен белдерде. Моңа каршы Гитлер, ачулы төстә, Берлин Совет һәм аның союзниклары гаскәрләре кулында калган очракта да Курляндия ярыматавын сакларга кирәк, дип җавап бирде. Командующийның аптырашта калганын күргәч, фюрер үзенең Черчилль белән союзына ышануын, Балтикадагы әзер плацдармны һәм гаять зур техникасы булган армияләр группировкасын инглизләр кулына бирергә өлгергән очракта, нацист җитәкчеләге шактый дәрәҗәдә амнистия алачагына исәп тотуын әйтте».

Ул чакта безгә Рихтер сөйләгән бу сүзләр «фюрерның саташуы» гына булып тоелган иде. Әмма сугыш беткәч үк Черчилльнең безнең илгә каршы сөйләвен, Трумэнның «атом шантажы»н ишеткәч, уйланырга мәҗбүр булдык.

Күптән түгел Англиядә архив идарәсе «Уайтхол серләре»н өйрәнү мөмкинлеген тудырды. Документлар раслаганча, У. Черчилль сугыштан соң «алты атналык өченче бөтендөнья сугышы» стратегиясенә өмет баглаган икән. 1953 елгы документларның берсендә «СССРга һөҗүм итү»нең Көнбатыш өчен бердәнбер нәтиҗәле чара икәнлеге әйтелә.

1945 елның язында штаб начальнигы Ферч һәм полковник Рихтер баш командующийга басым ясарга тырышалар. Алар котылу чарасын гына эзләмиләр, әлбәттә. Кенигсбергны кулда тоту өчен армияләрнең бөтен группасын Курляндиядән Көнбатыш Пруссиягә күчерүдән дә яхшырак юл күрмиләр.

Безгә шундый мәгълүматлар да билгеле: апрель ахырында сапер подразделениеләре Виндава белән Либавага причаллар төзергә китәләр. Биредән гаскәрләрне Германиягә озату күздә тотыла. Солдатлар арасында: Англия властьлары үзләре торган портларга күчәргә ризалык биргәннәр икән, — дигән хәбәр дә тарала.

Монда иң төп рольне, әлбәттә, Гитлерның тыюы түгел, ә безнең гаскәрләрнең, Балтик флоты һәм Ленинград фронты авиацияләренең һөҗүмне туктаусыз көчәйтә баруларында иде.

Гаскәрләрне эвакуацияләү планы барып чыкмагач, гаепне «җиңеләйтү» өчен мөмкин булган барлык вариантларны файдаланырга туры килә. Гильперт 30 апрельдән 3—4 майга кадәр контр-адмирал Дениц биргән беренче боерыкларны юк итәргә куша. Чөнки Берлин алынгач, паника башлана, тәртипсез рәвештә Швециягә качу очраклары күбәя.

Генерал Ферч безгә Гильперт белән Рихтер Берлинга китәр алдыннан үзләренең өчәүләп гаскәрләрне Штеттин һәм Любек районнарына күчерү вариантын җентекләп тикшерүләрен сөйләде. Маршал Рокоссовский гаскәрләренә флангтан һөҗүм итү варианты да күздә тотылган булган икән.

Әмма дошман бернәрсәне дә үзгәртерлек хәлдә түгел. Курляндия группасының язмышы совет командованиесе кулында иде инде. Үзе икърар иткәнчә, Ферч үзләрен «тулысынча һәм берсүзсез капитуляция, әсирлеккә газап чигү ояты» көткәнлеген бик яхшы аңлый.

Февраль ахырында Ферч баш командующий ставкасына юл тота, анда гаскәрләрне кичекмәстән Германиягә күчерү зарурлыгын тагын бер кат дәлилли. Фленсбургтан Курляндиягә ул 3 майда кайта һәм командующийга эвакуация турында приказ һәм җентекле күрсәтмәләр тапшыра.

1945 елның 6 маенда Реймста союзниклар каршында капитуляция турындагы сөйләшүләр һәм башлангыч беркетмәгә кул кую барып чыкмагач, Курляндиядә ашыгыч төстә гаскәрләрне Германиягә күчерүгә әзерлек эшен җәелдерәләр. 7 май иртәсендә 16 нчы армия берләшмәләре һәм частьлары «дингез позициясе» дип аталган урынга чигенә башлыйлар.

Маршал Л. А. Говоров уң фланг сугышчыларына дошманны эзәрлекләргә приказ бирә. Шул ук көнне Тукумс, Салдус, Браңаны шәһәрләре алына. Шулай да «Курляндия» группасы командованиесе Германиягә 40 меңнән артык солдат һәм офицерны озатып өлгерә, шуларның 25 меңләбе 7—8 майда диңгез юлы белән китә.

Кечкенә генә кәгазь кисәге — чакыру билеты, ә аның артында Гильперт хатының караламасы Гильпертның йокы бүлмәсендә табыла. Аның өстендә өр-яңа «Маузер» пистолеты ята. Ул чакта без, Гильперт өметсез хәлдән чыгу юлын хурлыклы төстә әсирлеккә төшеп, тиешле җәза алуга караганда атылып үлүдә күргәндер, дип уйлаган идек. Әмма Курляндия группасы идарәсендә Гитлер белән Геббельс үрнәгенә иярергә теләүчеләр булмаган. Бу да, күпмедер дәрәҗәдә, хәрби җинаятьчеләр нәрсәгәдер өметләнгәннәрдер күрәсең, дигән фикер тудырды.

Либавага күчәргә ниятләү дә Гильпертның аптырашта калуын раслый. Бу хакта миңа 12 майда штаб коменданты капитан Кошерек әйтте. 7 майда Деництан капитуляция турында приказ алгач, командующийның адъютанты Либавага (хәзерге Лиепая) шәраб, шоколад һәм тәмәке төялгән ике машина җибәрү турындагы боерыкны җиткерә. Әмма, Либавага килгәч, беренче машинаның шоферына йөкне кире Пелчи замогына илтергә кушыла. Штабка 9 майда гына әйләнеп кайткан икенче машина белән дә шундый хәл була.

Әмма хат проектына — Гильпертның маршал Л. А. Говоровка мөрәҗәгате эчтәлегенә әйләнеп кайтыйк. Аңа 1945 елның 8 мае датасы куелган. Гильперт әле нинди приказ аласын белмәгән көн була бу. Ул маршал Говоровны үз кулы астында булган Курляндия группасының боерык алырга әзер икәнлегенә һәм «...аларны каршылыксыз үтәргә» ышандыра. Шуннан соң ул, моңа җавап итеп, маршал Говоров, бәлкем, гаскәрләренең күрсәткән батырлыкларын «исәпкә алып» һәм «хөрмәт итеп», аларга салкын коралларын үзләрендә калдырган хәлдә ирекле һәм мактаулы төстә Рейх территориясенә чыгарга рөхсәт итәр дигән өмет белдерә. Ниһаять, ул болай дип яза: «Әгәр дә Сез, маршал әфәнде, үзегезне минем үтенечне канәгатьлән-

дерергә вәкаләтле дип санамыйсыз икән, әлеге үтенечемне үзенең җинүләре белән Европаның беренче солдатына әверелгән маршал Сталин әфәндегә җиткерүегезне үтенәм.

Зур хөрмәтемне белдереп калам».

Инде хәзер, 41 ел үткәч, бу документ хакында ни дә булса өстәп әйтү кирәкме икән? Әмма шунысын искә төшереп үтми булмый, комиссия членнары аны бик җентекләп тикшерделәр һәм төрле фикерләрен белдерделәр. Чөнки Гильпертның мондый адымы көтелмәгән һәм гаҗәпләнерлек иде. Әмма без моны Курляндия группасының тулысынча капитуляциягә әзер булуыдыр дип тә фараз иттек. Шуның өстенә дошманга карата безнең гаскәрләр күргән түбәндәге чараларны да онытмаска кирәк. 7 майда маршал Говоров һәм Хәрби совет члены генерал В. Богаткин Курляндия ярыматавында урнашкан фашист гаскәрләре өстенә немец телендә язылган листовкамөрәҗәгать ташларга дигән карарга килделәр. Листовканың текстын 51 нче армия типографиясенә бирделәр һәм аны тиз генә 70 мең данәдә бастырдылар. Фронт политидарәсе начальнигы генерал Пигурнов исә бөтен фронт линиясе буена тавыш көчәйткеч аппаратлар куярга һәм 7 майда кичке сәгать 8 дән Курляндия группасы командованиесенә маршал Л. Говоров ультиматумы текстын тапшыра башларга приказ бирде. Боларның барысы да дошман гаскәрләренә тәэсир итми калмагандыр, әлбәттә.

Вакыйгалар күз иярмәс тизлек белән барды. 8 майда сәгать 7 дә һәм 8 сәгать 45 минутта Ленинград штабы радиостанциясе радиограмма текстын язып ала. Анда болай диелә: «Икенче Балтик буе Фронты командующиена. Гомуми капитуляция кабул ителде. Элемтә урнаштырам һәм сорыйм: фронт командующие белән нинди дулкында элемтә урнаштырырга мөмкин? Безнең дулкыннар: 3050 һәм 2175 (98.3 һәм 137.9м.). Курляндия гаскәрләре группасы командующие пехота генералы Гильперт».

Безнең оперативниклар дошманның төп штабында 2 нче Балтик буе фронтының бетерелүен һәм аның гаскәрләренең маршал Говоров командалыгына бирелүен белмәүләренә һәм өстәвенә безнең фронтны Ленинград фронты дип белүләренә гаҗәпләнделәр.

Озак та үтмәстән, маршал Говоров түбәндәге җавапны бирергә кушты: «Курляндия группасы командующие генерал Гильпертка. 1. Минем белән элемтәне 98.3 м. дулкында тотарга. 2. Реймста килешенгәнчә, капитуляция турында сөйләшүләр алып бару өчен Сезне яки хәрби хәрәкәтләрне туктату һәм капитуляцияне кабул итү, аның тәртибе» турындагы килешүгә кул кую өчен вәкаләтле вәкилегезне көтәм. Фронт линиясен бүген, 8.5.45 елда Мәскәү вакыты белән 15.00 дә Скрунда — Пампали юлындагы Сунас пункты янында чыгарга тиешсез. Сезне яки Сезнең вәкилне алгы сызыкта минем вәкил көтәчәк. 3. Сез яки Сезнең вәкил фронт линиясен үтеп чыгу өчен шартлы сигнал итеп түбәндәгеләрне куям: ак флаг күтәрелсен һәм быргычы трубада «Барыгыз да тыңлагыз»ны уйнасын. Минем яктан да шундый ук сигналлар булыр. 4. Үзегезнең гаскәрләрегезгә 1945 елның 8 маенда көндезге сәгать 2 дән Сили участогында (Салдустан 16 км. көньяк-көнбатыштарак) һәм Вента елгасы участогында хәрби хәрәкәтләрне туктатырга боерыгыз. Бу хакта Сезнең гаскәрләр оборонагызның алгы сызыгында, күрсәтелгән участокта, ак флаглар куеп, миңа ышанып тапшырылган гаскәрләргә хәбәр итәргә тиеш...»

Маршал Л. А. Говоровның һәм аның штабының карары 5—7 көн эчендә фашистларның Курляндиядәге группасын әсирлеккә төшереп, аны коралсызландыруны, бөтен Курляндия ярыматавын биләп алуны күздә тота иде. Капитуляция шартларын 9—10 майда түбәндәге тәртиптә үтәү планлаштырылды: 8 майда Урта Европа вакыты белән 23.00 дә җирдә, һавада, диңгездә барлык хәрби хәрәкәтләр туктатылып, барлык пехота дивизияләре үзләренең көчәйтелгән средстволары белән берлектә оборонаның алгы сызыгыннан туплану районына, ә алгы сызыктан 4—5 километр ерактагылар 9 майда сәгать 11 дән башлап чыгарылсын. Либава, Кулдига һ. б. шәһәрләрдән һәм әлеге шәһәрләр районнарындагы аэродромнардан, зур торак пунктларыннан немец гаскәрләре 9 майга сәгать 8 гә чыгарылырга тиеш.

Бу шәһәрләрдә һәм немец гаскәрләре урнашкан барлык территориядә корылмаларны җимерү, җиһазларны, техниканы һәм милкәтне юк итү катгый тыелды. Немец частьларын һәм берләшмәләрен махсус әзерләнгән

лагерьга чыгаруның төгәл тәртибе билгеләнде. Беренче булып 81, 19 нчы латыш, 11, 263, 225, 13 нче пехота дивизияләре, 12, 14 нче танк дивизияләре чыгарыла. Группа командующие, 16 һәм 18 нче армияләр командующийлә-ре 9 майда сәгать 12 гә корпус командирлары кичке сәгать 4 кә үз машиналарында үз рацияләре һәм хезмәт күрсәтүче персоналлары белән бергә Мажейкяй шәһәре районына килергә тиеш иде. Аларга капитуляция вакытында үз гаскәрләре белән идарә итү мөмкинлеге тудырылды.

Капитуляция турындагы килешүгә кул кую моментыннан башлап Курляндия группасы командующие, 16 һәм 18 нче армияләр командующийләре совет командалыгы приказларын һәм күрсәтмәләрен берсүзсез үтәделәр. Капитуляция тәртибен маршал Говоров вәкиле — генерал-полковник Попов 8 майда кичке сәгать 4 тә Курляндия группасы баш командущие вәкиле — командующийның тыл буенча урынбасары генерал-майор Раузерга тапшырды. Аңа генерал Раузер 1945 елның 8 маенда төнге 10 сәгать 6 минутта кул куйды.

Маршал Говоров приказы нигезендә безнең фронтның һәрбер армиясе кирәкле күләмдә берләшмәләр һәм частьлар бирергә, алары исә 9 майда билгеләнгән маршрут буенча максималь тизлектә ярыматауга кереп, портларны, аэродромнарны, төп шәһәрләрне, юл узелларын биләп алырга тиеш. Ә гаскәрләрнең төп массасы үз урыннарында кала һәм бары тик, немец дивизияләрен әсирлеккә төшереп, коралсызландыргач кына, өлешчә алга таба хәрәкәт итә. Гаскәрләрнең төп өлеше Курляндиягә берничә көннән соң гына керде һәм тыныч лагерь тормышына күчте.

8 май вакыйгаларына әйләнеп кайтыйк. Безнең гаскәрләр уң флангта һөҗүмне дәвам иттерделәр һәм берничә шәһәрне, зур торак пунктын алдылар. Башка армияләр сугышмады, 150 километрдан артык озынлыктагы фронтта тыныч иде.

8 майда таң ату белән үк һавада безнең самолетлар күренә башлады. Аларның саны арткannan-артты. Курляндиянең беркайчан да бер көн эчендә бу кадәр самолет күргәне булмагандыр. Совет авиациясе Балтик суларын контрольдә тотты, ярыматау портларыннан судноларның чыгуына ирек куймады. Либава, Виндава портлары даими күзәтү астына алынды.

Көннең икенче яртысында дошман ак флаглар элә башлады. Ак флаглар эленгән һәм атыш тукталган участокларда солдат һәм офицерлар төркем-төркем яки ялгыз безнең гаскәрләр урнашкан якка күчә башладылар.

Кичке сәгать 3 тә армия станцияләре баш командующий генерал Гильперт приказын тапшыра башлады: «Маршал Говоров 1945 елнын 8 маенда 14.00 сәгатьтән сугыш хәрәкәтләрен туктату турындагы тәкъдимне кабул итте. Кичекмәстән гаскәрләргә фронтта ак флаглар элү турында хәбәр итәргә. Бу чараның каршылыксыз үтәлүенә ышанам. Чөнки безнең киләчәк язмышыбыз шуңа бәйле. Частьлар үз позицияләрендә калырга тиеш».

Бер үк вакытта безнең радиостанцияләр корпус һәм дивизия командирларының приказларын да тотты. Алар арасында, мәсәлән, менә мондыйлары да бар иде: «Көндезге сәгать 2 дән сугыш хәрәкәтләрен туктатырга, һәркайда ак флаглар эләргә. Бернинди каршылык күрсәтмәскә. Руслар безнең позицияләргә якынлашса, урыннарда калырга». Яки: «Сәгать 14.00 дән ут ачмаска боерык бирәм».

Радиотелеграммалардагы һәм армияләр группасы штабы документларындагы күрсәтмәләрне чагыштырып карау баштагы югалып калуны гына түгел, ә гаскәрләрне Курляндиядән чыгару турындагы буш хыялларны да расслый. Бер яктан, 8 майда җиңелгән фашистик Германиядән бик тиз рәвештә «немецларны Көнчыгыштан чыгару» турында телеграммалар ява, икенче яктан, командование капитуляция шартлары турындагы карарга кул куйганга кадәр совет командалыгының ниндидер ташлама ясавы турындагы буш өметләрдән ваз кичми.

Группа командующиеның «...якын көннәрдә власть бирелгән рус офицерларының килүе» һәм «алар белән лояль мөгамәләдә булырга кирәклеге» турындагы приказларыннан генерал Раузерның Ленинград фронтыннан кичке сәгать 4 ләр тирәсендә «Капитуляция шартлары»н алганнан соң тулы капитуляция турындагы актка ни өчен алты сәгать үткәч кенә кул куюы бик яхшы аңлашыла.

Гомумән немец гаскәрләре үз командованиеләренең сугыш хәрәкәтләрен туктату турындагы приказларын тыныч каршылыйлар. Бары тик 19 нчы латыш һәм 12 нче танк дивизияләрендә генә паника булып ала. 16 нчы армия штабының оператив бүлеге бу дивизияләрдәге паника һәм тулы

капитуляция турындагы приказны үтәмәү очраклары турында хәбәр итә.
9 майда иртүк маршал Говоров Гильпертка приказ тапшыра: «9 майда Мәскәү вакыты белән сәгать 10 да Балтик фронтының хәрби суднолары Либава һәм Виндава портларына керәчәк». Аннары бу судноларны кабул итү һәм аңлашылмаучылык ихтималын булдырмау чараларын күрергә кушыла. Ә иртәнге сәгать сигезләрдә генерал Ферч штаб начальнигы генерал-полковник Поповка командованиенең Мажейкяйга килергә тиешлеге турында 8 майда маршал Говоров биргән приказның үтәлүен хәбәр итә. Чынлыкта исә Гильперт фронт штабына 9 майда иртәнге тугызларда гына юл тота. Ул ялгызы гына булмый. Аның белән бергә 16 нчы армия командующие генерал Фолькаммер һәм 18 нче армия командующие генерал Беге килә.

Безнең армияләрнең штабларыннан алынган хәбәрләргә караганда, турыдан-туры алгы сызыкта торган барлык немец частьларын һәм берләшмәләрен коралсызландыру һәм әсирлеккә алу дәвам итә. 9 май ахырына 50 000 немец солдаты һәм офицеры әсирлеккә төшә. 10 майда инде бу сан 110 000 гә җитә, алар арасында 20 генерал була.

Безнең армиянең махсус билгеләнгән корпус һәм дивизияләре Җиңү көнендә ярыматауның эченә үк үтеп керәләр һәм 10 майда стратегик яктан әһәмиятле булган Либава, Виндава, Павилоста һәм башка шәһәрләрне билиләр.

Курляндия группасының төп штабы белән 16 һәм 18 нче армияләрнең штабларын кичекмәстән контрольгә алырга һәм юк итәргә кирәк иде. Җиңү көнендә фронт штабының күп кенә офицеры гаскәрләрдә була, ә Мажейкяйда калганнары Җиңү көне шатлыгын бәйрәм итә. Кыска гына митинг булып ала. Кыска, әмма гадәттән тыш тәэсирле чыгышларда Ленин партиясенә, тылдагы совет кешеләренә рәхмәт сүзләре яңгырый. Ватан өчен гомерләрен биргәннәр тирән кайгы хисе белән искә алына. Бар кеше тирән дулкынланган. Шатлыкны тылдагы туганнар һәм дуслар белән уртаклашу теләге туа. 9 майда Казанга хат яздым. «Бүген Җиңүне бәйрәм итәбез. Әле генә митингтан кайттым да ашыгып хат яза башладым. Кичен Ленинград артистлары концерты булачак...» Бу көн турында җентекләп язарга вакыт булмады, шунлыктан 14 майда язылган хатта да Җиңү көне турында әйтелә: «Җиңү көнне өйләгә кадәр эшләдем, аннары бераз шәһәрдә йөрдем. Кичен задание алдым да төн буе мөһим һәм мавыктыргыч эшкә әзерләндем. Иртәнге дүрттә Курляндиягә фронтның төп штабына киттем. Анда кичәге көнгә кадәр булдым».

9 майда үткәрелгән митингка «Суворовец» исемле фронт газетасы чыкты. Бу бәйрәм санын аеруча көтеп алдык, чөнки анда тарихи ике документ басылган иде. Беренчесе — СССР Верховный Советы Президиумының «9 майны Җиңү бәйрәме итеп игълан итү» турындагы Указы, икенчесе — «Германия кораллы көчләренең берсүзсез капитуляция ясавы турындагы актка кул кую» хакындагы хәбәр. Газетаның өченче битен ул вакытта бик популяр фронтовик-шагыйрь Яков Хелемскийның «Җиңү байрагы» дигән поэмасы алган иде.

Көннең икенче яртысында фронт командующие приказы нигезендә штаб начальнигы Курляндия группасы армияләре штабларын һәм төп штабны кабул итеп алу һәм юк итү өчен вәкаләтле комиссияләр төзү белән шөгыльләнде. Идарә һәм бүлек начальникларына төзелә торган комиссияләр составына кертү өчен офицерлар бирү турында приказ җибәрелде.

10 майга каршы төндә комиссияләргә инструктаж ясалды. Комиссия начальниклары итеп: төп комиссиянеке (яки № 1 нөке) — полковник Малинский, 16 нчы армия штабын кабул итү буенча (№ 2) — подполковник Марченко, 18 нче армия штабын кабул итү буенча (№ 3) — безнең бүлектән майор Шеховцев билгеләнделәр.

Төп комиссиягә түбәндәге офицерлар керде: оператив идарәдән капитан Ионенко, разведка бүлегеннән капитан Мутилов һәм тәрҗемәче кече лейтенант Кулагин, артиллерия идарәсеннән подполковник Головин, бронетанк һәм механикалаштырылган гаскәрләр идарәсеннән подполковник Рассомахин, инженерлык идарәсеннән подполковник Бигунов, элемтә идарәсеннән подполковник Коржик, хәрби әзерлек бүлегеннән подполковник Евсеев, тыл идарәсеннән подполковник Монастырский, типография бүлегеннән подполковник Макаров, шифр (8 нче) бүлегеннән өлкән лейтенант Соколов һәм махсус бүлектән майор Смертин. Комиссия ундүрт кешедән тора иде.

Төп комиссия белән махсус машина, сак сыйфатында дүрт автоматчы, азык-төлек төялгән полуторка, полуторкада военторг вәкиле белән ирекле эшләүчеләрдән чибәр бер кыз барды. Офицерлар һәм сакчылар җиде «Виллис»ка урнашты.

10 майда, пәнҗешәмбе көнне, иртән комиссия Мажейкяйдан чыгып китте. Кулдига шәһәренә бара торган юлның сул ягында автомат көпшәсенә ак флагчык бәйләгән солдатны очратканда иртәнге тугызлар иде. Ул Пелчи замогына илтә торган юлда тора иде. Ниһаять, утар һәм Пелчи замогы бинасы күренде. Безнең элемтә машинасы карт сирень куагы янында тора иде. Шунда ук унлап солдат җыелган. Алар безнең автоматчылар һәм шоферлар белән шактый кыю сөйләшәләр, сигарет тәкъдим итәләр, әмма кызыксынуларын һәм борчылуларын яшермиләр. Офицерлар безне сәламләп уздылар, әмма туктамадылар һәм сүз башламадылар.

Полковник Д. Л. Малинский берникадәр вакыт штаб начальнигы генерал Фридрих Ферч бункерында булды. Озак та үтмәстән, штаб бункерлары ягыннан өлкән офицерлар төркеме килде. Комиссия председателе, разведка бүлеге начальнигы подполковник Лизонг һәм аның ярдәмчеләре совет комиссиясен элеккеге баш командующий пехота генералы Гильперт резиденциясенә озата барачаклар, дип белдерде.

Бераздан безне чәйгә чакырдылар. Һәрберебез, дошманлык хисләрен тышка чыгармаска тырышып, капитуляция шартларын үтәү буенча эшлекле сөйләшүләр алып барырга әзер икәнлегебезне күрсәтеп утырырга мәҗбүр булдык. Безнең үз-үзебезне тотышыбызның «үзара аңлашуга» ярдәм итәчәгенә штаб генераллары һәм офицерлары белән очрашуга кадәр үк ышана идек.

Кунак бүлмәсендә әзерләнгән өстәл шаккатырлык ук түгел иде: коры печеньелы бутерброд, швед пирогы һәм берничә шешә шәраб. Безнең өстәл өстендәге әйберләргә игътибар итүебезне сизенгәннәрдер, күрәсең, подполковник Лизонг, без «ярлы», совет самолетлары һәм Балтик флотының хәрби средстволары аеруча соңгы көннәрдә Германиядән азык-төлек китерергә ирек бирмәделәр, диде. Иртәнге чәй ярты сәгатьләп дәвам итте. Сүзгә комиссия председателе генә кушылды. Чәйдән соң элекке командующийның кабул итү бүлмәсенә күчтек һәм озын өстәл тирәли утырдык. Председатель урынын полковник Д. Л. Малинский алды. Уң якка генерал Ферч, аның белән янәшә полковник Рихтер, разведка бүлеге начальнигы подполковник Лизонг һәм бүлек начальниклары урнашты. Штаб начальнигы артына тәрҗемәче майор сыенды. Өстәл янында егермедән артык кеше бар иде.

Генерал Ферч белән подполковник Рихтерга мөрәҗәгать итеп, комиссия председателе болай диде: «Безнең комиссия гаскәр төрләре буенча белгеч-офицерлардан тора, һәм комиссиянең һәр члены тиешле рәвештә сезнең төп штаб вәкилләре белән эш алып барачак».

Генерал Ферч, идарә һәм бүлек начальниклары сезне булган документлар белән таныштырачаклар, диде һәм әле 7 майда ук документ һәм материалларның күп өлешенең юк ителүен дә яшермәде. «Вәкаләтле» генерал һәм өлкән офицерларның күрше бүлмәдә көтеп утыруларын әйтте ул. Минем хәрби хәрәкәтләр журналлары турындагы соравыма полковник Рихтер җавап бирде. «Хәрби хәрәкәтләр көндәлеге»н алып баручы ярдәмчесе 5 майда ук инде ике чемодан белән Швециягә киткән икән. Часть һәм берләшмәләрнең штандартлары (байраклары) юк ителгән. Бу эшләр үч алудан куркып эшләнгән. Әмма без бу чараларның «СС» һәм гестапо ягыннан басым, приказ нәтиҗәсендәме яки стихияле төстә эшләнгәме икәнлеген төшенмәдек. Оператив идарә начальнигына яңадан бер тапкыр сорау белән мөрәҗәгать итәргә туры килде. Полковник Рихтер минем сорауга бик кыска итеп җавап бирде. Часть һәм берләшмәләрдә штандартлар бөтен кеше күңелен биләп алган өметсезлек һәм курку нәтиҗәсендә юк ителде, диде ул.

Киңәшмә тиз бетте, шундук оператив документлар белән танышу, гаскәрләрнең кайда урнашуын, алар белән идарә итүнең, хәрби составның ничек оештырылуын, махсус мөлкәтнең нинди хәлдә булуын һ. б. тикшерү башланды.

Бер үк вакытта полковник армия, һава флоты штабларына һәм тыл начальнигына совет командованиесе комиссиясенә кирәкле мәгълүматларны бирү турындагы боерыкка кул куйды. Алар арасында түбәндәгеләр бар иде: гаскәрләр составының саны, 9 майга дислокация картасы, тиешле

парламентарийлар җибәрмәгән 19 нчы латыш, 12 нче танк һәм 11 нче пехота дивизияләренең дислокацияләре хакындагы мәгълүматлар. Әлеге документларны әзерләгән вакытта сугышчылар санын «штаб идарә итә торган» частьлар буенча гына бирү күздә тотылды. «Мәгълүматлар дөрес булырга тиеш» диелгән иде документта.

Оператив идарә начальнигы башлыча мәгълүматларны 10 майда көндезге сәгать икегә телефон яки телеграф аша хәбәр итәргә кушты. Ахырдан ике өстәмә бар иде: тыл начальнигы өчен — «совет командованиесе госпитальләргә ярдәм күрсәтергә вәгъдә иткәнлектән, яралыларның күпме икәнлеген хәбәр итү» һәм составында «латыш ирекләләре» булган 16 нчы армия штабы өчен — маршал Говоровның аларны «СС» гаскәрләре исәбенә кертмәве турындагы хәбәрләр. Бу хакта 19 нчы латыш пехота дивизиясенә кичекмәстән хәбәр итәргә кушылды.

Комиссия председателе элемтә узелында, аеруча «ФАУ-4» установкасында, автопаркта һәм башка объектларда каравылны көчәйтергә кирәклеген әйтте, генерал Ферч белән полковник Рихтерның бу мәсьәләдә шәхси җаваплы булуларын исләренә төшерде. Кичке сәгать бишләрдә бер сәгатькә төшке ашка туктадык.

Рихтерның боерыгын үтәп, көн уртасында армия һәм корпуслардан мәгълүматлар килә башлады. Аларны идарә һәм бүлек начальниклары тикшереп чыкты, аннары безнең комиссия членнарына бирделәр.

Көн ахырында һәм 11 май төнендә гаскәрләрнең составы турындагы мәгълүматлар, хәрби берләшмә һәм частьларның 9 майга дислокация картасы, шулай ук тыл частьлары һәм учреждениеләренең дислокация картасы, тәэмин ителеше турындагы мәгълүматлар һ. б. алынды.

Кичке 9 ларда барлык төп документлар пакетларга салынды, мин аларны безнең штаб офицерына тапшырдым. Пакетны алу турында кул куйгач, фронт штабы начальнигы ярдәмчесе шундук самолетларның күтәрелү һәм төшү мәйданчыгына китте һәм документларны Мажейкяйга кирәкле урынга үз вакытында кайтарып җиткерде.

Төп эш эшләнде, әмма без алдагы көндә тагын да катлаулырак эш — штаб составындагы 1054 кешене хәрби әсирлек хәленә әзерләү торуын аңлый идек.

11 майда комиссия үз эшен сәгать 10 да башлады. Һәм төшке ашка кадәр беренче көндәге кебек үк бик киеренке эшләде.

Кичке сәгать 4 ләрдә Д. Л. Малинскийга рация аша маршал Говоровның Курляндия группасы штабын кичекмәстән барлык элемтә средстволарыннан мәхрүм итү һәм кешеләр составын хәрби әсирләр хәленә күчерү турындагы приказын тапшырдылар. Шул вакытка 10 нчы гвардия армиясеннән дүрт офицер белән автоматчылар ротасы килеп җитте, ул шундук элемтә узелын ышанычлы сакка алды. Сәгать бишләрдә вәгъдә ителгән бер сәгатьлек тәнәфес белдерелде. Комиссия председателе комиссия членнарының кайберләреннән үз сорауларына кирәкле җавапларны алды да, кабул итү бүлмәсенә сәгать алтыда җыелырга кушып, чыгып китте. Штабны юк итү тәртибе фәкать кичке алты сәгать кырык минутта гына килешенеп бетеп, председатель без көтеп утырган бүлмәгә керде. Шундук генерал Ферчны чакырып китерделәр. Полковник Малинский шактый әдәпле төстә: «Генерал әфәнде, мин маршал Говоровтан приказ алдым. Ул приказ нигезендә Сезнең штаб үз функцияләрен туктата һәм бүген, Мәскәү вакыты белән 22 сәгатьтә хәрби әсирлек хәленә күчерелә»,— диде.

Фашист армиясенең кикриге шиңгән әтәче бу сүзләрне бер караганда тыныч кына тыңлады кебек. Бары тик игътибар белән күзәтеп торгач кына без аның йөзендә югалып калу һәм курку күрдек. Бераз тынлык хөкем сөрде, аннары комиссия председателе дәвам иттерде: «Мин Сездән, генерал әфәнде, шундый боерыклар бирүегезне үтенәм. Барлык средстволары белән берлектә элемтә узелын кичекмәстән безнең сак астына тапшырырга. Штабның барлык мөлкәтен һәм автопаркны безнең офицерлар һәм безнең сак астына тапшырырга. Сезгә һәм сезнең офицерларга блиндажлардан замокка, аскы катның уң ягына күчәргә. Сул як — офицерлар составына, өске кат һәм замок тирәсендәге йортлар — рядовой составка».

Тагын кыска гына тынлык урнашты. Бар кеше аптырап ялган генералны күзәтте. Ул, башын күтәреп, һәрберебезгә күз ташлагач һәм карашын председательгә төбәгәч кенә, полковник Малинский болай диде: «Мин шуны кисәтеп куям: безнең сак астына күчкәнгә кадәр барлык мөлкәтнең сак-

лануына һәм кешеләр составын хәрби әсирләр хәленә күчерү процессындагы тәртипкә тулысынча Сез җаваплы».

Ферч безнең тәрҗемәчегә мөрәҗәгать итте. Анысы комиссия таләпләрен кабатлады. Ферч үз штабын юк итү тәртибе һәм шартлары буенча берничә сорау бирде дә үзенең шәхси тәрҗемәчесен чакыруны үтенде. Үтенеч канәгатьләндерелде. Кабул итү бүлмәсенә майор керде, аның ярдәмендә билгеләнгән шартларны үтәүнең кайбер детальләре ачыкланды. Генерал, «әгәр мөмкин булса», үзен башка тоткарламавыбызны үтенде, чөнки штабны хәрби әсирлек хәленә күчерү өчен вакыт бик аз калып бара иде. Әмма комиссия председателе аны беразга тоткарлады, генерал һәм офицерларны коралсызландырырга, фотоаппаратларны тапшырырга кирәклеген әйтте. Моңа Ферч: «Мин инде приказ бирдем, һәм ул төгәл үтәлер, дип ышанам».— дип җавап бирде. Аннары комиссия председателе: «Штаб территориясендә кайда да булса регистрациягә алынмаган рация табылу ихтималы мөмкинме?»— дип сорады. Моңа каршы: «Мөмкин түгелдер, дип уйлыйм. Мин барлык средстволарны Сезнең вәкилләргә тапшырырга приказ бирдем. Шулай да өстәмә чаралар күрермен»,— дигән җавап ишетелде.

Шуннан соң генералга үзенең элекке штабына китәргә һәм бирелгән күрсәтмәләрне үтәргә рөхсәт ителде. Шунысын әйтим, ул 8 майдан 9 майга каршы төндә үк әле барлык гаскәрләргә кичекмәстән капитуляция турындагы боерыкка кул куярга мәҗбүр булган иде. 10 майга штабка без килүгә ул штабның барлык идарәләре, бүлекләре һәм подразделениеләре өчен боерыкка кул куйган. Анда сүз безгә тимәү, лояль карау, махсус рөхсәт булмый торып, элемтәгә кермәү турында бара иде. Будапештта булган кебек берәр нәрсә килеп чыкса, үз гомеренең бетәчәген аңлый иде генерал. Шунлыктан, чәчләре бик иртә агарган, үткен карашлы, төссез күзле бу кешенең бөтен ихтыяр көче ничек тә исән калуга, үзен ихтимал «яңа» «зур эш өчен» саклауга юналдерелгән иде.

Ул Ленинград янында да, биредә, Курляндиядә дә, командующийлар приказын фәкать солдат буларак кына үтәгәнлегенә ышандырырга тырыша иде. 10 майда иртәнге аш вакытында ул үзенең беркайчан да нацизм яклы булмаганлыгын, 1944 елда «Браухич эше» буенча бәлагә очраклы төстә генә эләкми калуын, ниһаять, үз штабында гестапочыларның аның өстеннән күзәтү алып бармаганлыгына ышанып бетмәвен аңлатып маташты.

Комиссиянең төгәл һәм күп эшләве, штабның элекке җитәкчелеге тарафыннан күрсәтелгән немец педантлыгы нәтиҗәсендә 11 майда кичке сәгать 10 да штабның бөтен составы хәрби әсирлек хәленә күчерелгән иде. Нәкъ сәгать 10 да, совет комиссиясенә алынган боерыкларның өч сәгать элек үтәлүен хәбәр итәр өчен, генерал Ферч килде. Аның белән адъютанты һәм тәрҗемәчесе бар иде. Үз докладын ул: «Менә хәзер барысы да тәмам. Без — әсирләр»,— дип тәмамлады.

Комиссия председателе генералдан үзенең һәм ярдәмчеләренең ничек урнашулары турында сорады. Җавап мондый булды: «Вакыт бик тә аз иде, без әйберләребезне күчереп кенә куя алдык. Төнлә әйбәтләбрәк урнашачакбыз». Аннары ул болай диде: «Солдат һәм офицерлар урнашкан урыннарга барып, аларга тәртип һәм дисциплинаны катгый төстә үтәргә кирәклеген әйтергә рөхсәт итәлерме миңа?»

Комиссия председателе: «Рәхим итегез. Сезнең белән безнең тәрҗемәче йөрер»,— диде.

Ферч: «Дисциплинаны моңарчы булган дәрәҗәдә саклау максатында, солдат подразделениеләренә берәр-берәр офицер куярга кирәк түгелме?»

Полковник Малинский бик азга гына уйга калды, аннары комиссия члены, политик идарә вәкиле белән киңәшеп алды. Җавап кыска, әмма катгый булды: «Фельдфебельләр кую яхшырак булыр».

Комиссия председателе генералга «тырыш, оешкан эш күрсәткәне өчен» рәхмәт әйтте һәм тыныч йокы теләде. Безнең көндәлеккә: «Шулай итеп, 11 майда 22.00 сәгатьтән Курляндиядәге армияләр группасы хәрби әсирлектә»,— дигән сүзләр язылды.

Төнге сәгать 11 ләр тирәсендә комиссия членнары кабул итү бүлмәсенә тагын җыелды. Алар лагерьның һәм элекке төп штаб мөлкәтенең ничек саклануын тикшерүләре турында хәбәр иттеләр.

12 майда иртән комиссия членнары штабның элекке бүлек һәм идарә начальникларыннан сорау алуны дәвам иттерделәр. Комиссия председателе, оператив идарә вәкиле белән берлектә, полковник Рихтердан оператив-техник характердагы, аеруча 1945 елның март аенда булган сугышларга

кагылышлы мәсьәләләр турында сорашты. Әңгәмә бер сәгатьләп барды. Аның төп максаты фронт штабы начальнигы М. М. Поповка комиссия председателенең доклады өчен өстәмә мәгълүматлар алу иде. Әңгәмәбез вакытында Рихтер совет командованиесе комиссиясе белән эшләгән вакытта рус офицерлары арасында начальник һәм аңа буйсынган кешеләр арасында була торган рәсми мөгамәләне күрмәвен әйтте. Ул күзәткәнчә, «буйсынган кешеләр (ягъни без — И. И.) куенсынып яки каушап тормадылар, һәркем үз эшен эшләде, ә барысын бергә алганда, совет комиссиясе бер бөтен булып эш итте».

Аннары ул болай дип өстәде: «Председательнең боерык биргәнен, бар кешегә сиздереп, канәгать булуын яки булмавын күрү кыен иде». Безнең бер-беребезгә хәрби дәрәҗә белән түгел, ә исем-отчество белән мөрәҗәгать итүебез дә аның игътибарыннан читтә калмаган икән. Геббельс ведомствосының, Кызыл Армиядә үзара мөнәсәбәт куркуга һәм югарырак чин алдында калтырап торуга корылган дигән гайбәте белән үзе күргән чынбарлык аның миендә һич кенә дә сыеша алмагандыр.

Көндәлегемдә язылганча, Рихтер белән соңгы очрашуыбыз 13 майда төнге сәгать берләрдә чәй янында булды. Без сорау алуны юкка гына әңгәмә төсендә алып бармадык. Сораулар бирдек, безгә бирелгән кайбер сорауларга җавап кайтардык, әмма төп максатыбыздан читкә китмәдек. Ә максат штаб эше турында, аерым операцияләр буенча (төрле гаскәрләрнең үзара бәйләнештә хәрәкәт итүе һ. б.) безне кызыксындырган нәрсәләрне күбрәк белү иде. Шул ук вакытта безне хәрби психология дә кызыксындырды.

Мин аңа операцияләрнең конкрет берсе турында материаллар мисалында безнең командование һәм штаб адресына тәнкыйть сүзләре дә ишетергә теләвемне белдердем. Ул бик конкрет формада үзенең кайбер фикерләрен әйтте һәм шундук совет командованиесен һич кенә дә тәнкыйтьләргә җөрьәт итмәвен, Курляндиядәге гаскәрләрнең көндәлек хәрәкәтләре нәтиҗәсендә туган кайбер тәэсирләрен генә уртаклашуын белдерде.

«Сорау алу планы» үтәлгәч, төп мәгълүматлар теркәлгәч фашист дәүләтенең һәм аның коточкыч хәрби машинасының тулысынча һәм хурлыклы төстә җиңелүенең сәбәпләре турында әңгәмә дәвам итте. Үзе әйткәнчә, Рихтер 1944 ел башында ук инде, Ленинград янында ук, «нәрсәне исәпкә алып бетермәгәнлекләрен», «үз вакытында аңламаганлыкларын», «нәрсәне белмәгәнлекләрен» аңларга тырышкан. Фәкать соңгы көннәрдә, Германиянең гомуми һәм тулы капитуляция ясавы турында игълан ителгәч кенә «рус офицерының нинди дер аерым бер эчке көчен, аның интеллектуаль һәм әхлакый өстенлеген» тойган.

Китәр алдыннан Рихтер, Гитлер һәм аның национал-социалистик партия буенча киңәшчеләре дошманның психологиясен белмәделәр, шунлыктан сугышны оттырдылар, алдан ук үлемгә хөкем ителделәр, диде. Ул безнең әңгәмәгә менә мондый нәтиҗә ясады: «Сезнең генераллар һәм офицерлар, сезнең штаблар чынлап та шундый югарылыкта иделәр, алар безне кыен хәлдә генә калдырмадылар, ничектер югалып калу һәм зур борчылу тудырдылар. Мин, эчемнән җиңелүебезнең котылгысызлыгын 8 майга кадәр күп алдан сиздем. Хәрби машина инерциясе безне туктатып булмас рәвештә упкынга өстерәде...»

Соңгы тапкыр ул безгә мондый сорау бирде: «Әсирлектә вакытта миңа өченче рейхның мондый хурлыклы төстә җиңелүенең сәбәпләре турында язу мөмкинлеге тудырылыр микән?»

Рихтерга бу мәсьәләне без генә хәл итә алмавыбызны, хәзергә исә Курляндия группасын тулысынча юкка чыгару турындагы шартларны ахырынача үтәргә кирәклеген әйттек, әлеге группа штабының ул кул куйган схемасын көтүебезне исенә төшердек.

Үзебез генә калгач, без тәрҗемәче белән бер сәгатьләп үткән көндәге вакыйгаларны тикшердек һәм, үзебез дә сизмәстән, озакламый гаиләләребез белән очрашу ихтималы турында сөйләшә башладык.

Әмма 12 май иртәсенә әйләнеп кайтыйк. Бу көнне иртәнге унберенче яртыларда полковник Малинский ике офицер белән самолетларының күтәрелү һәм төшү полосасына Ленинград фронты штабы начальнигы генерал-полковник М. М. Поповны каршыларга китте. Без Рихтер белән озак сөйләшмәдек. Мин комиссия председателенең аның белән әңгәмәсе вакытында кузгатылган кайбер мәсьәләләрне генә ачыкладым.

Әле 12 майга каршы төндә үк дежур торган вакытта мине элемтә машинасына чакырып алдылар. Оператив идарәдән дежур майор Гильчулин

генерал Гвоздков боерыгын үтәгән икән. Безнең кыска, әмма эчтәлекле сөйләшүебезнең тасмадагы язмасы сакланып калган.

«Аппарат янында Малинскийның ярдәмчесе капитан Ионенко».

«Аппарат янында майор Гильчулин. Исәнмесез, иптәш Ионенко. Иртәгә, ягъни 12 майда... сәгать 11 дә сезгә иптәш Попов килә. Аны мәйданчыкта каршыларга һәм үз эшегез турында доклад ясарга әзер булырга кирәк. Минем сүзем бетте. Барысы да аңлашылдымы?»

«Барысы да аңлашылды. Каршылауны оештырырбыз һәм докладны әзерләрбез. Сезнең сүз бетсә, хәерле төн. Минем сүз бетте».

«Минеке дә бетте. Сау булыгыз».

Маркиан Михайлович Попов комиссия бинасына килде һәм башкарылган эш хакында башлангыч мәгълүматлар алды. Аннары, элемтә узелы һәм автопарк әсирләре урнашкан бинага тиз генә күз йөртеп чыккач, барыбыз да кабул итү бүлмәсенә җыелдык. Ул вакытка инде 18 нче һәм 16 нчы армияләр, хәрби-һава көчләре штабларын юк итү комиссияләре председательләре чакырылган иде.

Генерал М. М. Попов комиссияләрнең информацияләрен тыңлады. 18 нче армия штабын юк итү турында майор Н. И. Шаховцевның сөйләве аеруча кызыклы булды.

Аннары, аз гына тәнәфестән соң, генерал Попов комиссия председателенә мондый күрсәтмә бирде: лагерьны бик кыска срокта, 15 майга кадәр, тулысынча юкка чыгарырга. Моның тәртибе: генерал һәм өлкән офицерларны шәхси әйберләре,денщиклары белән бергә, 13 майдан да калмыйча, Тиршкляйга озатырга. Калган офицерларны машиналарда Слокадагы хәрби әсирләрнең офицерлар лагерена, рядовой составны җәяүләп Вайньодз лагерына озатырга. Техниканы транспортлау, үзләштерү, барлык машина һәм кешеләр составын Мажейкяйга җибәрү өчен җитәрлек күләмдә шоферлар һәм белгечләр калдырырга. Барлык хуҗалыкны, шул исәптән политмәгариф мөлкәтен җыярга һәм подполковниклар Седлицкий белән Недюха җаваплылыгына тапшырырга. Соңыннан аларны Мажейкяйга фронт штабына илтергә. Булган барлык документларны, өйрәнү һәм нинди әһәмияткә ия икәнлекләрен ачыклау өчен, разведка бүлегенә тапшырырга.

Комиссия членнары 12 һәм 13 майда үз эшчәнлекләрен әлеге күрсәтмәләрне үтәүгә юнәлттеләр. Рәсми өлештән соң төшке ашка тәнәфес игълан ителде. Төшке ашны әйбәт кәеф белән ашадык, аннары кабул итү бүлмәсенә җыелдык. Анда генерал Попов генерал Ферч белән очрашырга теләк белдергән иде. Очрашуда комиссиянең барлык членнары да катнашмады. Миңа «хәрби хәрәкәтләр тарихчысы» буларак язып барырга рөхсәт ителде.

Ферч үзенең тәрҗемәчесе белән килде һәм, гадәттәгечә, фуражкасын ике кулы белән корсагының аскы өлешенәрәк кысып, җиңелчә генә баш иеп, җиңүчеләрне сәламләде. Генерал Попов председатель урындыгына утырды. Ул Ферчны утырган килеш кабул итте, өстәл почмагында бер яккарак куелган креслога күрсәтте. Ферч креслога утырды, тезләрен кысып, фуражкасын тезләре өстенә куйды.

Поповның, әле Бисмарк ук Германияне ике фронтта сугышудан кисәтеп куйган, дигән сүзләренә Ферч берни дип тә җавап кайтармады. Әңгәмә үз җаен ала алмады. Моңарчы күп сөйләүчән генерал, әйтерсең лә, авызына су капкан иде. Нииндидер уңайсыз киеренкелек урнашты. Ферчка очрашуның тәмамлануын әйттеләр.

1945 елның 12 май вакыйгаларына әйләнеп кайтыйк. Озакламый Попов, Курляндия группасының элекке штабын юк итүдә Малинскийга уңышлар теләп, китеп барды.

Кабул итү бүлмәсенә әйләнеп кайткач, комиссия председателе 13 майның беренче яртысында Тиркшляйга озату өчен, генерал Ферч белән өлкән офицерларны чакыртырга кушты.

Ферчка мөрәҗәгать итеп, Малинский аңа үз машинасын, шәхси әйберләрен, адъютантын һәм тәрҗемәчесен алырга рөхсәт ителүен әйтте. Башка генераллар да үз машиналары, денщик һәм шәхси әйберләре белән баралар. Генерал һәм офицерларны озата бару өчен комиссия члены — разведка идарәсе вәкиле капитан Муталов, офицерларны озату өчен майор Иоселев билгеләнде. Рядовой состав сак астында җәяүләп барачак. Сак начальнигы итеп 10 нчы гвардия армиясеннән майор Саркисьян расланды.

Төн урталарында генерал Гвоздковтан приказ алынды: «Курляндия армияләр группасы штабы начальнигыннан сорап, 13 генералның кайдалыгын ачыкларга». Шуннан соң фамилияләр һәм хезмәт урыннары санала.

Генерал Ферчның борчулы йокысын бүләргә һәм аны тәржемәчесе белән бергә кичекмәстән комиссиянең кабул итү бүлмәсенә чакырырга туры килде. 13 генералның фамилиясен игътибар белән тыңлаганнан соң ул тәржемәчесе белән сөйләшеп алды, фикерләрен туплап, телеграммадагы исемлек тәртибен саклап тормастан, аңлатмалар бирә башлады. Аның Пелчидагы соңгы җавапларын китерик.

«Баш врач, медицина хезмәте генералы Вагнер 30 апрельдә үк, «Висла» группасындагы яралыларны тәэмин итү базасына сөйләшүләр алып бару өчен пароходта Рейх территориясенә киткән иде. Штетин тирәсендәрәк автомобиль авариясенә эләккән. «Курляндия» пехота дивизиясе командиры Флюгбайль үз дивизиясенең зур өлеше белән 8 майда пароходта Германиягә китте. Генерал Калибе 11 майда Елогеда иде. Тикшерелмәгән мәгълүматларга караганда, совет офицеры аңа автотранспорт колоннасын тылга озатырга боерык биргән. Либава крепосте коменданты генерал-лейтенант барон Дигион фон Монтетон 8 майга кадәр үз урынында иде. Шуннан соңгы язмышы билгеле түгел. Генерал-лейтенант Коляни, 11 май мәгълүматларында күрсәтелгәнчә, Кроксете лагерында. Аңа Пелчи замогына килергә кушылды. Генерал-лейтенант Фишер Курляндиядә. Аның хакында 16 нчы армия штабы начальнигы Герсдорф белергә тиеш. 6 нчы «СС» ирекле корпус командиры обергруппенфюрер һәм «СС» гаскәрләре генералы Крюгер, мөгаен, үз-үзен үтергәндер. 11 нче пехота дивизиясе командиры Феарбент дивизиянең зур өлеше белән пароходта Германиягә китте. 18 нче Армия штабы начальнигы генерал Мерктан сорарга кирәк. 19 нчы латыш пехота дивизиясе командиры, «СС» гаскәрләре генерал-лейтенанты Штрекенбахның кайдалыгы билгесез. 8 майга кадәр Салдустан 12 километр чамасы ераклыктагы районда иде. 16 нчы армия штабы начальнигыннан ачыклау дөресрәк булыр. 218 нче пехота дивизиясе командиры генерал-лейтенант Ранке 8 майда дивизиядә иде. Аны хурлыклы әсирлеккә караганда үлемне артыграк күрүче, инанган солдат дип беләм. Авиация командующие, авиация генералы Флюгбайль 9 майга кадәр Виндавадан көньяк-көнчыгышта Пильтене районында иде. 6 нчы зенит дивизиясе командиры генерал-лейтенант Антон 9 майга кадәр Айзпуте районында үзенең командалык пунктында иде. Һава флоты авиациясенең элемтә начальнигы генерал-лейтенант Затлер Флюгбайль белән бергә булырга тиеш. Латвиянең диңгез коменданты контр-адмирал Арнсвольд, ихтимал, 8 майда флоты белән Германиягә киткәндер. «СС» гаскәрләренең Курляндия буенча вәкиле бригаденфюрер Меллер 8 майга кадәр Либавада иде. Пароходта киткәндер дип уйларга кирәк».

Генерал Ферчка берничә, шул исәптән, генераллар Швеция аша китмәдеме, дигән сорау бирелде. Ул мондый сорауларга кире җавап кайтарды һәм берничә тапкыр, барлык диңгез средстволары Киль белән Любенга юл тотты диде.

Генерал Ферчның әлеге җавапларыннан соң кайбер күзәтүләр һәм нәтиҗәләр ясарга мөмкин. Беренчедән, башлап иң ерткыч хәрби җинаятьләр — «СС» генераллары качкан. Чөнки алар йөз меңнәрчә совет кешеләренең тормышы өчен, Ленинград, Новгород, рус халкының изге урыны булган Пушкин таулары, Россиянең төньяк-көнбатыш өлкәләрендәге, Белоруссия һәм Балтик буендагы исәпсез сандагы картларның һәм балаларның җәзалап үтерелүе өчен беренчеләрдән булып җавапка тартылачакларын аңлаганнар. Икенчедән, Курляндиядән чыккан транспортларны Германиянең Англия хәрби властьлары контрольлегендәге портларында кабул иткәннәр. Бу фактка безнең мөнәсәбәтебезне аңлау кыен түгел. Әлеге эпизодта сугыштан соң «салкын сугыш» башлап җибәргән һәм атом белән куркытырга уйлаган Черчилль һәм аның хөкүмәтенең позициясе чагыла.

48 генералдан 13 е турында гына төгәл мәгълүмат булмау — бу инде бик үк начар түгел. Шунысын да әйтик, безнең гаскәрләр 15—17 майда Курляндия урманнарын тикшергән вакытта 19 нчы латыш пехота дивизиясе командиры, «СС» генерал-лейтенанты Штрекенбах тотылды. Аның бер хуторда базда сөт бидоннары арасында карчык киемендә качып ятуын сөйләделәр.

13 майда, якшәмбе көнне, иртүк элекке штаб кешеләрен хәрби әсир итеп тиешле урынга җибәрергә әзерлек тикшерелде. Иртәнге аштан соң ук комиссия әгъзаларының кыска гына киңәшмәсе булып алды. Аннары Д. Л. Малинский миңа генерал һәм офицерларны озату өчен үзе белән бергә Пелчи замогына барырга тәкъдим итте. Иске замокның артында, юл

буенда, төрле төстәге машиналар тора, алар янында генераллар, аларның адъютантлары, денщиклары һәм шоферлары җыелган.

Безнең машинаны комиссиянең һәм сакчыларның берничә кешесе каршылады. Комиссия председателе тагын бер тапкыр озатуга әзерлекне тикшерде һәм сәгать 10 тулып 15 минутта кузгалырга рөхсәт бирде. Генерал Ферч безнең янга килде һәм Малинский белән саубуллашты. Кулдина-Скрунда шоссесына беренче булып аның машинасы чыкты. Барлык генераллар тыштан караганда тыныч кына баш кактылар. Артиллерия начальнигы карт генерал кулында без ак пудель күрдек. Башкаларны тоткарламыйча, кузгалып китәргә тиешле вакытта гына ул: «Капитан әфәнде, миңа бу этне үзем белән алырга рөхсәт ителерме икән?» — дип сорады. Уңай җавап алгач һәм елмаюымны күргәч, баш иде, денщигы ярдәмендә авырлык белән генә машинасына кереп утырды. Генерал арыган, әсирлек оятыннан һәм җәза алачагын сизенгән мескен кеше кыяфәтендә иде. Нәкъ шушы кеше артиллерия утларын планлаштыргандыр, ут средстволарын фронт буйлап оператив төстә күчергәндер һәм безнең артиллерия начальникларына күп мәшәкатьләр тудыргандыр дип һич кенә дә уйламассың. Безнең штабларда аны таза, энергияле сугышчы итеп күз алдына китерәләр иде.

Безнең яннан тагын берничә машина һәм автобус үтте. Фашистлар армиясенең иң зур группаларының берсенең «ми үзәге»н юк итү эше шулай тәмамланды.

Көн уртасында председатель Пелсида калган комиссия членнарын җыйды. Миңа 13 майда иртәнге якта Курляндиядәге немец гаскәрләре төп штабының тулысынча юк ителүе турында генерал Гвоздковка кичекмәстән донесение әзерләргә кушылды. Озак та үтмәстән әзерләнгән документта мондый юллар бар: «Генерал-лейтенант Гвоздковка. 1. 1945 елның 13 маенда сәгать 10.00 дә Курляндия группасы штабы юкка чыгарылды. Генерал, офицер һәм рядовойлар түбәндәге санда: 4 генерал, 63 офицер, 812 рядовой, генерал-полковниктан... 45 елның 12 маенда алынган шәхси күрсәтмә нигезендә, озатылды. Биредә шоферлар һәм мотопарк белгечләре — барлыгы 234 кеше калды».

Полковник Малинский үзенең моннан соң да Пелчида калуын кирәк дип санамады. Чөнки комиссиянең барлык членнарын диярлек эшләнгән эш турында документлар һәм гомумиләштергән информация белән бергә турыдан-туры начальниклары чакыртып алды, кайберләре хәрби әсирләрне озата китте. Өстәвенә бу вакытта Пелчида Седлицкий һәм Недюха группалары эшли башлаган иде инде.

Минем күз алдымда фронт штабына соңгы телеграмма җибәрелде: «Немецлардан калган бик үк әһәмияте булмаган документларны бүген ярдәмчем капитан Ионенко белән җибәрдем. Малинский». Ул миңа комиссиядә эшләгәнем өчен рәхмәт әйтте һәм хәерле юл теләде. Берничә минуттан инде без — автоматчылар арасыннан алынган ординарецым белән, шоферы немец булган машинага утырдык һәм Пелчи замогыннан чыгып киттек.

Пелчи замогында калган офицерларыбыз һәм комиссия председателе 14 майда көн буе штаб әйберләрен тәртипкә китергәннәр, автотранспортны фронт штабына җибәрү өчен әзерләгәннәр. Икенче көнне иртә белән бөтен автопарк, махсус машиналар (аларны төнлә төяп бетергәннәр), шоферлар, элемтә һәм картография белгечләре Мажейкяй шәһәренә озатылган. Колонна начальнигы полковник Д. Л. Малинский булган.

Фашист Германиясенең Курляндиядәге гаскәрләр группасы штабын юк итүгә сарыф ителгән һәм хәтеребездә сугышның соңгы, Бөек Җиңүебезнең беренче көннәре турында тирән эз калдырган берничә көнлек эш шулай тәмамланды.

## СССР ЯЗУЧЫЛАР СЪЕЗДЫ

Июнь аенда Мәскәүдә СССР язучыларының чираттагы съезды булып узды. Бу зур әдәби форумда Татарстаннан делегатлар булып Т. Миңнуллин, Ә. Еники, Р. Харис, М. Госманов, Н. Фәттах, Т. Галиуллин, Р. Гатауллин, Н. Орешина һәм кунак булып Р. Мостафин, Р. Вәлиев катнашты. Татарстан Язучылар союзы идарәсе председателе Т. Миңнуллин съездда чыгыш ясады.

Съездда СССР Язучылар союзы идарәсенә член итеп Т. Миңнуллин, И. Юзеев сайланды. Яңа идарә утырышында Т. Миңнуллин СССР Язучылар союзы идарәсе секретаре итеп сайланды.

## ТАТАР ЯЗУЧЫЛАРЫ ЧЕРНОБЫЛЬДӘ

Киевның «Днипро» матур әдәбияты нәшрияты, Татарстан китап нәшрияты белән берлектә, Муса Җәлилнең тууына 80 ел тулу уңаеннан атаклы «Моабит дәфтәре»н татар һәм украин телләрендә бастырып чыгарды. Китапны рәссам Рафаэль Мәсәгутов бизәгән. Ул — яшьләрнең һәм студентларның Мәскәүдә булып узган Бөтендөнья фестивале эмблемасының авторы.

«Днипро» нәшрияты чакыруы буенча татар язучылары Вакыйф Нуруллин, Равил Фәйзуллин, Ренат Харис Киевта булдылар. Украина Язучылар союзы һәм нәшрият житәкчеләре белән очраштылар.

Аннары татар язучылары Чернобыль шәһәрендә булдылар, атом электр станциясендәге авария нәтиҗәләрен бетерү эшләрен алып баручы төзүчеләр алдында чыгыш ясадылар. Чернобыльдә булган иҗади төркемгә Украина Компартиясе Үзәк Комитетының җаваплы работнигы Е. Лукьяненко, язучылар В. Беленко, П. Перебейнос, Б. Степанюк, П. Иванов, Р. Чилачава, рәссам Р. Мәсәгутов, нәшрият редакторы Н. Пилипенко кергәннәр иде. Язучылар төзүчеләргә имзалары куелган китаплар бүләк иттеләр. Иң зур бүләк исә иҗади очрашуда катнашучыларның һәммәсе дә кул куйган Муса Җәлил китабы иде.

## СОВЕТ ӘДӘБИЯТЫ КӨННӘРЕ

14—20 июльдә Куйбышев шәһәрендә Совет әдәбияты көннәре булып узды. Бу зур әдәби бәйрәм Куйбышев шәһәренең 400 еллыгы уңае белән үткәрелде. Күренекле рус язучысы Петр Проскурин җитәкләгән делегация составында Мәскәү, Ленинград, шулай ук союздаш һәм автономияле республикалардан вәкилләр катнашты. Татарстаннан шагыйрь Р. Фәйзуллин барды. Ул, Совет әдәбияты көннәрендә катнашкан бүтән язучылар белән берлектә, Куйбышев, Тольятти, Жигулевск шәһәрләрендә, шулай ук, А. Н. Толстойның туган җире Красноармейск районында булды, хезмәт ияләре алдында чыгышлар ясады. Әдәбият көннәренең ахырында Куйбышевта «Идел буе әдәбияты: партиянең XXVII съезды карарлары яктылыгында алда торган проблемалар һәм үсеш перспективалары» дигән темага иҗади конференция уздырылды. Р. Фәйзуллин анда чыгыш ясады, куелган мәсьәләләр турында фикерләре белән уртаклашты һәм Куйбышев телевидениесе аша чыгыш ясап, татар әдәбияты турында сөйләде.

## ИҖАТ СЕКЦИЯЛӘРЕНДӘ

9 июньдә Татарстан Язучылар союзының тәнкыйть секциясендә «Татар әдәбияты турында үзәк матбугат» дигән темага сөйләшү булды. Көн тәртибендәге мәсьәлә буенча яшь тәнкыйтьче Ә. Сахапов чыгыш ясады. Фикер алышуда тәнкыйтьчеләр Р. Мостафин, Ф. Мусин, язучы М. Зарипов, «Социалистик индустрия» газетасы хәбәрчесе У. Богдалов һәм башкалар катнашты.

25 июньдә язучылар союзының балалар әдәбияты секциясе утырышы булды. Анда яшь язучы Флүс Латыйповның повесть һәм хикәяләр җыентыгы тикшерелде. Фикер алышуда Р. Хәмид, Р. Миңнуллин, Б. Камалов, М. Хәсәнов, М. Вәлиев һәм башкалар авторның иҗатындагы уңышлы яклар белән бергә кимчелекләрен күрсәтеп үттеләр, киңәшләр бирделәр.

## ИГЕНЧЕЛӘР ЯНЫНДА

1—3 июльдә язучылар Ә. Рәшитов, К. Кәримов Апас районы авыл хезмәтчәннәре белән очраштылар. Алар «Гигант», Ленин исемендәге һәм «Татарстан» колхозларының терлекчеләре һәм механизаторлары белән очраштылар. Кичләрен клубларда әдәби очрашулар үткәрделәр.

Язучы М. Насыйбуллин 18—21 июньдә Кукмара районының «Таң», «Ударник» һәм «Яңа тормыш» колхозчылары белән очраштылар. Механизаторлар, печән әзерләүчеләр янында булды.

## РЕДАКЦИЯДӘ ОЧРАШУЛАР

11 июньдә «Казан утлары» журналы редакциясендә Ленин премиясе һәм СССР Дәүләт премиясе лауреаты, Социалистик Хезмәт Герое шагыйрь, драматург һәм прозаик Мостай Кәрим белән очрашу булды. Г. Тукайның тууына 100 ел тулуга багышланган тантанага килгән әдип, республика газеталары һәм журналлары вәкилләренә Казанда туган тәэсирләре, татар һәм башкорт әдәбияты, бүгенге көннең актуаль проблемалары турында сөйләде, сорауларга җавап бирде.

19 июньдә «Казан утлары» журналында бүгенге проза турында сөйләшү үткәрелде. Киңәшмәне кереш сүз белән журналның баш редакторы Р. Харис ачты. Яшьләр прозасының бүгенге хәле, үсеш перспективасы, гомумән, әдәбият алдында торган актуаль бурычлар турында сөйләшүдә Р. Мөхәммәдиев, Р. Низамиев, М. Галиев, М. Вәлиев, Т. Әйди, С. Шәмси, Н. Гыйматдинова, Ш. Җиһангирова, Э. Шәрифуллина катнашты һәм чыгыш ясадылар. Прозаның сыйфатын, идея-художество дәрәҗәсен яхшырту, тормышны өйрәнү, заманча һәм кыю яза белү, әдәби культураны үстерү хакында кыйммәтле фикерләр әйтелде.

## «ҖИДЕГӘН ЧИШМӘ»НЕҢ ЯҢА КИЧӘСЕ

Түбән Каманың «Җидегән чишмә» әдәбимузыкаль берләшмәсе энтузиастлары Эстәрлетамакка барып, «Дуслык кичәсе» үткәреп кайттылар. Кичәдә Башкортстанның күренекле шагыйре Нәҗар Нәҗми иҗаты аша татар-башкорт халыкларының дуслыгы, хезмәттәшлеге турында язучы Р. Хисмәтуллин чыгыш ясады.

Н. Нәҗми тамашачыларга Казанда һәм Кырлайда Тукай бәйрәмнәрендә катнашуы турында сөйләде, шигырьләрен укыды, сорауларга җаваплар бирде.

## МАКТАУЛЫ ИСЕМНӘР

Совет музыка сәнгатен үстерүдәге зур хезмәтләре өчен композитор Рөстәм Яхинга, СССР Верховный Советы Президиумының 1986 ел, 24 июль указы белән, «СССРның халык артисты» дигән мактаулы исем бирелде.

Совет әдәбияты өлкәсендәге хезмәтләре өчен язучы Әхмәт Әхәтович Рәшитовка, Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының 1986 ел, 22 июль Указы белән, «Татарстан АССРның атказанган культура работнигы» дигән мактаулы исем бирелде.

Театр сәнгате өлкәсендәге хезмәтләре өчен Әлмәт Татар дәүләт драма театры артистлары Идрис Мәсгутовка һәм Мөнәвәрә Нигъмәтҗановага, Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының 1986 ел, 31 июль Указы белән, «Татарстан АССРның атказанган артисты» дигән мактаулы исем бирелде.

## ХЕЗМӘТЕН ХӨРМӘТЛӘП

Совет театр сәнгатен пропагандалауда озак еллар нәтиҗәле эшләгәне өчен һәм сиксән яше тулу уңаеннан Татарстан АССРның халык артисткасы Галия Кайбицкая, Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының 1986 ел, 19 май Указы нигезендә, Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының Мактау грамотасы белән бүләкләнде.

# *Укучыларыбыз игътибарына*

Бу көннәрдә редакция почтасында газета-журналларга язылу тәртибен аңлатуны сорап язган хатлар шактый. Укучыларыбызның үтенечен искә алып, Татарстанда чыга торган көндәлек матбугат органнары турында кыскача мәгълүмат бирәбез.

ЖУРНАЛЛАР:

| | | |
|---|---|---|
| «Татарстан коммунисты» | — | Индекс — 73377<br>Бер елга язылу хакы — 3 сум |
| «Агитатор блокноты» | — | Индекс — 73946<br>Бер елга язылу хакы — 1 сум 44 тиен |
| «Чаян» | — | Индекс — 73488<br>Бер елга язылу хакы — 6 сум |
| «Казан утлары» | — | Индекс — 73210<br>Бер елга язылу хакы — 10 сум 80 тиен |
| «Азат хатын» | — | Индекс — 73002<br>Бер елга язылу хакы — 3 сум |
| «Совет мәктәбе» | — | Индекс — 73363<br>Бер елга язылу хакы — 3 сум |
| «Ялкын» | — | Индекс — 73582<br>Бер елга язылу хакы — 2 сум 40 тиен |

ГАЗЕТАЛАР:

| | | |
|---|---|---|
| «Социалистик Татарстан» | — | Индекс — 54123<br>Бер елга язылу хакы — 7 сум 80 тиен |
| «Советская Татария» | — | Индекс — 54122<br>Бер елга язылу хакы — 7 сум 80 тиен |
| «Вечерняя Казань» | — | Индекс — 54125<br>Бер елга язылу хакы — 7 сум 80 тиен |
| «Татарстан яшьләре» | — | Индекс — 54121<br>Бер елга язылу хакы — 3 сум 12 тиен |
| «Комсомолец Татарии» | — | Индекс — 54120<br>Бер елга язылу хакы — 3 сум 12 тиен |
| «Яшь ленинчы» | — | Индекс — 54124<br>Бер елга язылу хакы — 1 сум 8 тиен. |

Бу газета-журналларга илебезнең барлык төбәкләрендә чикләүсез язылырга мөмкин. Аңлашылмаучылыклар килеп чыкмасын өчен, «Союзпечать» агентлыкларына һәм элемтә бүлекчәләренә газета-журналларга язылу башлануның беренче көннәрендә үк мөрәҗәгать итәргә, квитанцияләрдә газета-журнал индексын дөрес күрсәтергә кирәк. Редакцияләр матбугатка яздыру эше белән шөгыльләнмиләр.

# НИГЕЗ

Танылган график Илдар Әхмәдиев Кама автогиганты төзелешенә беренчеләрдән булып килде һәм «КамАЗ» рәссамнар группасы составында нәтиҗәле иҗат итте. Төзүчеләр турындагы изорепортажларын ул республика матбугатында даими бастырды. Менә шулай бөтен бер серия туды. «КамАЗ юллары», «Җыр», «Чаллы тәрәзәләре», «Сменадан соң», «Вахта», «Апрель»... Әлеге линогравюра һәм акварельләрнең исемнәре генә дә рәссамның удар төзелеш мәйданын күпъяклап яктыртырга омтылуын күрсәтә.

Төзелештә рәссам бик күп эшчеләр белән дуслаша, шулай итеп, хезмәт процессының эченә үтеп керүгә ирешә. Мондый кызыксынучанлыкның нәтиҗәсе дә кызыклы булып чыга. КамАЗ турындагы картинасы өчен ул гадәти булмаган сюжет сайлый: дус күргән төзүчеләр бригадасында яңа өйләнешүчеләр туе... Рус егете белән татар кызы гомерләрендәге истәлекле вакыйганы хезмәттәшләре даирәсендә билгеләп үтәргә карар кылалар. Менә алар ЗАГСта язылышканнан соң бергәләп төзелеш мәйданына киләләр. Туй истәлеге сурәттә калсын!..

Әлеге сюжет графика кысаларына гына сыймый. Һәм рәссам беренче мәртәбә нәкыш сәнгатенә, тематик картина жанрына мөрәҗәгать итә. «Безнең бригада. Туй истәлеге»... Тормышның үзеннән алынган әлеге җанлы «кадр» рәссамга аерым вакыйганы гына түгел, ә автомобиль гигантын төзүче яшьләрнең гомумиләштерелгән портретын күрсәтергә ярдәм иткән. Бер-берсенә охшаган төрле-төрле йөзләрне бер уртак куаныч берләштерә: нигез салу шатлыгы! Төзелеш мәйданы нигезендә яңа гаиләгә дә нигез салына. Аларның бөтенесе дә яңа нигездә басып торалар. Бәйрәмчә күтәренкелек төсләр бирелешендә дә чагыла: тирә-якка аклык сирпеп торучы кәләш күлмәге, ниндидер алсулык белән өртелгән кирпеч стена, көмешсу-көрән киемнәр...

Кама автомобиль гигантын салуга үзеннән иҗади өлеш керткән рәссам Илдар Әхмәдиевка «Камаз төзелеше ударнигы» исеме бирелде, һәм ул «Аеруча хезмәт күрсәткән өчен» медале белән бүләкләнде.

**Вера ЦОЙ,**
Татарстан сынлы сәнгать музееның
бүлек мөдире.

**Тышлыкның дүртенче битендә:** күренекле шагыйрь, ТАССРның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Нури Арсланов.

**Рөстәм МАНСУРОВ** фотолары.

# «КАЗАН УТЛАРЫ» 1987 ЕЛДА

Татар совет әдәбиятының күренекле әсәрләре укучыларга иң элек «Казан утлары» журналы аша барып ирешә.

Редакция портфелендә язучыларыбызның күләмле проза әсәрләре байтак. Менә аларның кайберләре:

Нурихан Фәттах. «Сызгыра торган уклар» романының икенче китабы.

Мәдинә Маликова. «Басып сайрар талы бар». Роман.

Гариф Ахунов. «Идел кызы» романының икенче китабы.

Нәби Дәүли. «Без дөньяга килдек» повестеның икенче китабы.

Рафаил Төхфәтуллин. «Чатта тукталу». Повесть.

Миргазиян Юныс. «Таңда Босфор аша». Повесть.

Вакыйф Нуруллин. «Җавап бир...» Повесть.

Гомәр Бәширов, Аяз Гыйләҗев, Мөхәммәт Мәһдиев, Мәхмүт Хәсәнов, Мәгъсүм Насыйбуллин һ. б. журнал өчен яңа әсәрләрен төгәлләп килиләр.

«Казан утлары» поэзия һәм драматургия әсәрләренә, тугандаш халыклар әдипләренә, яшь язучылар иҗатына, бүгенге көн проблемаларын күтәргән очерклар һәм публицистик мәкаләләргә, әдәби хәрәкәт, тарих, сәнгать мәсьәләләренә киң урын бирә. Иҗат серләре турында яңа язмалар, әдәби мирас үрнәкләре, истәлекләр, хатлар укучыларыбызда шулай ук кызыксыну уятыр.


Журнал сәхифәләре сезгә киләсе елда да рухи канәгатьлек, яңа очрашулар шатлыгы алып килер дип уйлыйбыз.

«Казан утлары»ның Бөтенсоюз каталогындагы индексы — 73210. Бер елга язылу хакы — 10 сум 80 тиен.

РЕДКОЛЛЕГИЯ.

Бәясе 90 тиен.
Цена 90 коп.

Индекс 73210



КАЗАН УТЛАРЫ
(ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРИИ
(на татарском языке)